Таҗеддин Ялчыгол

# РИСАЛӘИ ГАЗИЗӘ

www.darul-kutub.com

«Хозур» нәшрияты
Казан — 2014

Әсәрне басмага әзерләүче (гарәп графикасындагы текстларны укып, басмалар арасындагы аермалыкларны күрсәтеп, гамәлдәге язуга күчерүче, аңлашылмаган сүз-гыйбарәләрне һәм юлларны тәрҗемә итүче, тиешле шәрехләр бирүче) һәм кереш мәкалә авторы Хатыйп Йосыф углы Миңлегулов.

www.darul-kutub.com

# Таҗеддин Ялчыгол һәм аның «Рисаләи Газизә» әсәре

Милли дәүләтчелеген югалтканнан соң, татар халкы аяусыз эзәрлекләүләргә, коточкыч геноцид сәясәтенә дучар ителә. Әмма шуңа да карамастан, гәрчә зур югалтулар белән булса да, үзенең милли асылын, телен, динен, моңын, гореф-гадәтләрен саклап, аларны алдагы буыннарга тапшырып килә. Милли барлыкны саклауда аеруча белем-мәгърифәт зур роль уйный. Безнең әби-бабаларыбыз караңгы елларда да мәктәп-мәдрәсәләр ачырга, китапка мәхәббәтне сакларга омтыла. Шушы чорларда без күпләгән китапларның күчерелүен, иҗат ителүен беләбез. Дәүләтле халыклар күзлегенннән, бүгенге көн югарылыгыннан караганда, бәлкем, ул чор мәгарифендә, мәдәниятендә күп төрле җитешсезлекләр, гайре, табигый урыннар да бардыр. Әмма халкыбызның колониаль изелү чорындагы рухи байлыгын, язма истәлекләрен татар җирлегендә, татарның ачы язмышы белән тыгыз бәйләнештә карарга кирәк. Шунда гына без үз зыялыларыбыз эшчәнлегенең мәгънәсен, татар китапларының вазифасын һәм әһәмиятен тиешенчә аңлый һәм аңлата алырбыз.

Дәүләтле халыкларның күп кенә әдип-галимнәре дөньяның матди һәм рухи ләззәтләрен татып, хөкемдарларының ярдәмен тоеп, затлы сарайларда иҗат итсәләр, татарның Мәүла Колый, Утыз Имәни, Ялчыголлары юньләп торыр урын да таба алмыйча, каңгырып, гомерләрен ачлы-туклы уздырырга мәҗбүр

булалар. Аларның шушындый шартларда әдәби, гыйльми, педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүләре — үзе бер батырлык вә фидакарьлек. Шуңа күрә мондый затларның тәрҗемәи хәленә, язган китапларына игътибарлы булу, кимчелекләренә киң күңеллелек күрсәтү — безнең әхлакый һәм инсани бурычыбыз.

- I -

Кыен чорларда халыкка белем һәм тәрбия бирүдә армый-талмый хезмәт түккән зыялыларыбыз шактый. Алар арасында исеме, эшчәнлеге күпләргә мәгълүм булган Таҗеддин Ялчыгол да үзенә лаеклы урынны алып тора. Аның тормыш юлы катлаулы, сикәлтәле. Тәрҗемәи хәлендә (биографиясендә) томанлы, каршылыклы сәхифәләр дә җитәрлек. Шулай да Таҗеддин Ялчыголның язма мирасына, иң беренче чиратта «Тәварихе Болгария» («Тарихнамәи Болгар») әсәренә, нәсел-нәсәбенең истәлекләренә, Г. Чокрый, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддин, Г. Газиз, Г. Рәхим, М. Госманов, Ә. Харисов, М. Гайнетдинов, Д. Гарифуллнн, И. Галяветдинов, М. Әхмәтҗанов, Р. Хәмәдиев һәм кайбер башка авторларның макалә-хезмәтләренә, үзебезнең шәхси тикшеренүләргә нигезләнеп, әдипнең тәрҗемәи хәлен һәм күпкырлы эшчәнлеген билгеле бер дәрәҗәдә ачыкларга мөмкин.

Таҗеддин Ялчыгол якынча 1768 елның октябрь аенда, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, «Әй дәрьясы илән Арша дәрьясы арасында Курмаш-елга авылында» туа. Мәгълүм булганча, Әй — Көньяк Уралдан башланып, хәзерге Чиләбе өлкәсе (Златоуст) һәм Башкортостан җирләре (Кыйгы, Мәләвез... районнары) аша Караиделгә коючы елга. Арша — аның бер кушылдыгы. Таҗеддинның әтисе Мәмәткол углы Ялчыгол (Ялчыкол) — күп мәртәбәләр хаҗда булган рухани, мулла. Әнисе, туганнары хакында мәгълүмат юк.

Таҗеддинга 8 яшьләр чагында, ягъни 1776 елда Ялчыгол мулла, улы белән бергә, Сәгыйд бистәсе,

ягъни Оренбург Каргалысы аркылы Әстерхан төбәгенә юнәлә. Максаты — хаҗга бару. Фәндә аның күчеп китү сәбәбен Пугачев хәрәкәте белән бәйләп карау да бар. Мондый ихтималлыкның булуы бик мөмкин. Ни өчен? Чөнки крестьян хәрәкәтендә бик күп мөселман зыялылары да катнаша. Пугач хәрәкәте бастырылгач, анда катнашучыларны кулга алу, төрлечә эзәрлекләүләр башлана. Мондый шартларда күп кенә кешеләр качып, күчеп китәргә, эзләрен яшерергә мәҗбүр булалар. Ялчыгол мулланың да андыйлар арасына эләгүе гайре табигый түгел. Әдипнең үзе теркәгән биографик мәгълүматларындагы каршылыклы, томанлы яклар да, бәлкем, билгеле бер дәрәҗәдә шушы тарихи сәбәпләр белән аңлатыладыр!?

Мөһаҗир Таҗеддин һәм аның әтисе. Әстерхан төбәгендә бер еллап булгач, Дагстанга киләләр. Биредә алар Җаксай (Яксай) шәһәрендә яшәгәннәр булса кирәк. Чөнки биредә элек-электән нугай, комык, татар аралашып яши. Бу шәһәргә Таҗеддин Ялчыголның соңрак, 1827-1828 еллар аралыгында да килүе мәгълүм. Р. Фәхреддин искәртүенчә, әдип 1234/1819 елда да Җаксайда булган. Бу хакта Таҗеддин Ялчыголның «Һидаятел-хикмәт» ахырында мәгълүматлар бар (Асарь, У1 җөзэ, 1904.-336б.).

Әстерхан, Дагстан якларында Ялчыгол мулла балалар укыта, руханилык кыла, хаҗ сәфәренә мая туплый.

Таҗеддин әүвәл әтисендә белем ала, аннан Кавказ якларындагы мәдрәсәдә укый. Дагстанда дүрт еллап яшәгәч, Ялчыгол мулла 13 яшьлек улы белән Төркиягә юнәлә. Биредә алар Кече Азиядәге мөһим сәүдә һәм мәгърифәт үзәкләренең берсе булган Диарбәкер шәһәрендә (ул — хәзерге Төркиянең Сүрия, Гыйрак, Иран чикләренә якын бер җирендә) туктыйлар. Ялчыгол мулла, улын бер танышында калдырып, үзе Гарәбстанга хаҗга китә. Таҗеддин бер мәдрәсәдә төрле фәннәрдән белем ала, мөстәкыйль яшәү күнекмәләрен үзләштерә. Бу хакта

әдип үзенең «Тәварихе Болгария» китабында менә ничек яза: «...Андан (ягъни Дагстаннан. — Х.М.) Диарбәкерә вардык. Ул заманда бән фәкыйрь Таҗеддин унөч яшемдә ирдем. Диарбәкердә бәне бер хуҗа әленә (кулына, — Х.М.) биреб китде. Хода өчен бу угланчыкны әфәнделәрә виреб, тәхсыйле гыйлем кылсын дийү (белем алсын дип. — Х.М.). Атамыз хөҗҗаҗел-мөслимин (мөселман хаҗилары, — Х.М.) илән хаҗ китде. Бән фәкыйрь Таҗеддин атам мелла Ялчыголны ундүрт ел көтдем. Ундүрт ел эчендә бән әнвагы голумларны (төрле гыйлемләрне. — Х.М.) тәхсыйль әйләдем (өйрәндем, — Х.М.). Ахрелә (?) (ахырда: кайчан. — Х.М.) Диарбәкердәге мөрәбби (остаз. — Х.М.) хуҗам дөньядин үтде, бән атамны эстәйү (эзләп. — Х.М.) Истанбула вардым» (Тәнкыйди текст, 38-39б.).

Күп кенә авторлар Таҗеддин Ялчыголның Диарбәкердә 14 ел түгел, ә дүрт кенә ел яшәвен искәртәләр. Чөнки тәүге сан (ул ялгыш күчерелгән булса кирәк) әдип тормышының бүтән хронологик баскычлары белән каршылыкка керә.

Ялчыгол мулланың берничә ел буена улыннан аерылып тору сәбәпләре билгесез. Бәлкем ул, изге җирләргә баргач, авырып яткандыр? Бәлкем Гарәбстан якларында күңеленә хуш килгән шөгыль тапкандыр?..

Остазы вафат булгач, Таҗеддин Ялчыгол, әтисенең кайтуын ишетеп, Госманлы мәмләкәтенең мәркәзенә — Истанбулга юнәлә.

Алар мәчеттә очрашалар. Бу күренешне автор үзе менә ничек сурәтли: «Истанбулда мәсҗеде әхйада (мәчеттә, мәчет ихатасында. — Х.М. ) атамны күрдем. Ул хөҗҗаҗ (хаҗилар. — Х.М.) илә рабигыл-әүвәлнең ахыргы пәнҗешәнбесендә Истанбула кермеш. Бән иртәсендә җомга көнне күрдем. Бәне күрдеке заманда углы ирдеке икәнне белмәде. Бән белдем. Бәндән сөаль кылды: «Нә йирлек фәрзәндесән (углы син, — Х.М.)?» — дийү. Бән әйтдем: «Болгарлык иштәкмен»[2], — тидем. Шул заман һушы китеб

екылды. Һушына килде: «Таҗеддин, сәнмесән?» — тиде. Әйтдем: «Бәли (әйе. — Х.М.), чигәргөшең (җигәргөшәң — сөекле балаң; бавырыңның пәрәсе — Х.М.), мөнгыйм (игелек иясе — Х.М.)», — тидем. Янә аһ орыб, гакылы башымдан китде. Мәсҗед әһле йаранлары хәйранә (хәйран. — Х.М.) калдылар. Шул ахшам өч мәртәбә һушы китде» (Тәнкыйди текст, 396.).

Алга таба Таҗеддин Ялчыгол «ике ел» әтисе белән Истанбулда яшәвен искәртә. Биредә ул укыганмы, эшләгәнме, — анысы мәгълүм түгел. Автор ниндидер «Әхмәд әфәнде тәрбиясендә тору»ларын белгертеп куя. Истанбулдан аларның юлы «кәрван илә Хаҗитәрханә» юнәлә. Әстерхан төбәгендә «бер ел» торгач (әтисе «дәрес әйтә»), Мәскәүгә киләләр. Биредә ата белән угыл «алты ай» яшиләр. Аннан Ялчыголларның өч атна («өч жомга») Мәкәрҗәдә («Мәкәрийә кальгасендә»), «ике ай» Казанда торулары мәгълүм.

Алдагы тормышлары хакында «Тәварихе Болгария» авторы үзе болай дип яза: «Казандан Троиски[3] каласына кырык сум илә ат әҗарийә алыб (ат яллап. — Х.М.), ямщиклар берлән чыкдык. Казандан чыкдыкымыз көн (чыккан көндә. — Х.М.) әткәм «башым агрыйдыр», — тиде вә дәхи әйде. «Әй балакаем. Әй дәрьясыны ахры күрмәмдер, — тиде. — Кайчан ки бән дөньядин үтсәм, бәнем каберемне гариб идеб, ташлаб, бәнем кабрем әтрафындан (тирәсеннән. — Х.М.) ерак китмәгел, шул урында йорт-йир әйләңел (яшә. — Х.М.) вә дәрес әйткел вә дәресне әгәрчә күздән калсаң да әйткел[4] вә һәм елында ике мәртәбә бәнем кабремә зиярәт иткел. Бу шартларымны йиренә килтерсәң, бән синдән хушындым (риза булырмын. — Х.М.), — диде. — Әгәр бивәфак («үгәмәсәң», — Х.М.), бән сәндан әбәдән (һич тә; мәңгегә. — Х.М.) разый дәгелмән, — диде, — һәм моңдан гайре васыятьләрем вардыр, — тиде, — сандык эчендә дәфтәремдә табарсән», — тиде. Әлкыйсса

(кыскасы. — Х.М.), безләр Казан шәһәреннән чыкыб, бу жанибә (тарафка. — Х.М.) килдек. Юлымыз Мамадыш өязенә уградьг (керде, — Х.М.). Урта Сөн тидеке[4а] авылга йитдекемездә, әҗәл ирешде, дөньядин үтде алтмыш биш яшендә, рәҗәб аенда, әүвәлге җомгасыны Рәгаиб киче[5] диерләр. Шул кичдә жәүзәнең (ягъни май-июнь айларының аралыгына туры килүче Игезәкләр аеның. — Х.М.) 24нче йәүмендә (көнендә. — Х.М.) тарихе һиҗрәтнең 1200нче (миладиның 1786нчы) елында, куй елында иде» (Тәнкыйди текст, 166-1676.).

Атасыннан аерылуны Таҗеддин бик авыр кичерә. «Рисалаи Газизә» китабының ахырында ул, бу вакыттагы рухи халәтен яңартып, «гариб»леге, «Сөннең тагына» әтисен җирләве, «андин соң гаять хәзәндә (кайгыда. — Х.М.) калуы», «аһ-зар итүе» хакында[6] яза.[7]

Әтисе васыятенә тугры калып, Таҗеддин Ялчыгол «Сөн карьясендә өч ел дәрес әйтә», аннан, якынча XVIII йөзнең 90 еллар башында, Зәй елгасы буйларына күчеп килә. Мәгьлүм ки, бирегә, ягъни хәзерге Түбән Кама, Зәй төбәкләренә Мамадыш якларыннан элегрәк тә күчеп утыручылар була[8]. Күрәсең, XVIII гасыр азакларында да ике арада бәйләнешләр яшәп килгәндер.

Уфа галиме И. Галяветдинов, шагыйрь Гали Чокрый (1826 — 1889) төзегән кулъязмага нигезләнеп (ул Санкт-Петербургтагы Шәрыкшенаслык Институтында саклана, — Шифры В 2673), әдипнең хәзерге Түбән Кама районында яшәү елларын болай билгели: 1792-1799 елларда, ягъни «йите ел» Җирекле (Зирекле, Каенлы) авылында, 1799-1824 елларда («екерме биш ел») — шул тирәдәге Кызыл Чапчак «карьясендә»[9]. Әдип һиҗри белән 1240, ягъни милади белән 1824 елда хәзерге Зәй районының Мәлем (Югары Налим) авылына күчеп килә һәм калган 14 ел гомерен шунда уздыра[10].

Таҗеддин Ялчыгол — халкыбыз тарихының, Рәчәй мәмләкәтенең шактый катлаулы һәм каршылыклы

чорында яшәгән әдип. Милли һәм социаль изү, төрле сугышлар һәм баш күтәрүләр, мөселманнарны эзәрлекләү, көчләп чукындыру һәм урыслаштыру, фәкыйрьлек һәм ачлык — болар бар да бу чорга хас сыйфатлар. Шушындый кыен шартларда Таҗеддин Ялчыгол, үз туган теленнән тыш, гарәп, фарсы, госманлы һәм кайбер башка телләрне белә. Шәрык гыйлемнәрен һәм мәдәниятен үзләштерә. Аны, төрле тармакларда кылган гамәлләренә, язган китапларына карап, энциклопедик табигатьле галим дип тә атарга мөмкин. Ул, әлбәттә, барыннан да элек педагог. Әтисе васыятенә тугры калып, Таҗеддин Ялчыгол Мамадыш ягында да, Зәй төбәгендә дә «дәрес әйтә», ярты гасырдан артык гомерен халыкны белемле, тәрбияле итүгә багышлый. Шул чорга хас булганча, аның мөгаллимлеге руханилык эшчәнлеге белән үрелеп бара. Әдип халыкта гасырлар буена тупланып килгән ислам рухын сакларга һәм ныгытырга, милләттәшләрен чукындыру афәтеннән коткарырга омтыла. Билгеле булганча, Таҗеддин Ялчыгол — мәгълүм табиб, дарулар ясаучы да. Аны авылдан авылга, хәтта ераграк төбәкләргә, Ык буйларына да чакырып торалар. Шушындый сәфәрләр вакытында бу могтәбәр зат халыкны физик яктан гына түгел, әлбәттә, рухи яктан да дәвалый, кавемдәшләрен инкыйраздан сакларга, иманлы, белемле итәргә тырыша. Ул язган китапларның да төп өлеше нәкъ менә тәрбияви, дини-әхлакый ихтыяҗларны күздә тотып төзелгән. Алар, нигездә, шәрхи — аңлату характерында.

Таҗеддин Ялчыголның язма мирасы әле тиешенчә барланмаган, өйрәнелмәгән. Аның тарих, әдәбият, фәлсәфә, медицина (тыйб), фикх (хокук), илаһият һәм кайбер башка тармаклар буенча дистәдән артык китап язуы билгеле. Югарыда телгә алынган Гали Чокрый кулъязмасында авторлыгы Таҗеддин Ялчыголга мөнәсәбәтле китаплар атала: «Хәдисел-баб»ка шәрех (Җирекледә языла). Кызыл Чапчакта яшәгән вакытта

www.darul-kutub.com

язган китаплары «Сөбател-гаҗизин»гә шәрех, ягъни «Рисаләи Газизә», «Кафия» китабына шәрех (ягъни «Әл-касыйдәтел-кафия». Аны «Гафия» дип гә йөртәләр), «Тәнбиһел-гафилин» («Ваемсызларны искәртү», — Бу әсәр «Рисаләи аййүһа әл-вәләд» ядкренә шәрех), «Мөфатихел-Кодури» (Кодуриның «Холасател-җәүһәри» әсәренә шәрех), «Мөфатихел-һидая» («Хикмәтел-һидая»га шәрех), «Фаваиде-әшрәфийәт» («Тәлхис»кә аңлатма), «Фәваиде-җәлалийәт» (Тәгълимет-тарик» һәм «Китабе бәһтәрин» ядкәрләренә шәрех), «Фәваиле-бәһаийәт»[13] («Гыйльме тыйб» — медицина турында), «Фәваиде-госсалийа» («Фәраиз»га тәсниф), «Тәрҗемәтес-салат» («Тәгълимес-салайа»га шәрех). 1240/ 1825 елда, Мәлем авылына күчкәч, язган китабы: «Тәфсирү сидрәтел-мөнтәһи» («Һәфтияк»кә тәфсир)[12]. Таҗеддин Ялчыголга мөнәсәбәтле язмаларның берничәсе («Рисаләи Газизә», «Шәрхел-касыйдәтел-кафия», «... Тәгаллимес-салават», ягъни «Тәгълимес-салайа», «Шорутел-салават») Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабында да телгә алына[14].

Таҗеддин Ялчыгол язган тәфсир-шәрехләрнең тик берничәсе генә басылган («Рисаләи Газизә», «Тәфсирү сидрәтел-мөнтәһи», «Тәварихе Болгария»...). Күпчелеге — кулъязма хәлендә.

Сарман районында табылган бер кулъязмада Таҗеддин Ялчыгол «24 кыллы татар гөсләсен, скрипка, думбра һәм тәгәрмәчле лираның сурәтләрен һәм алар хакында кыскача мәгълүматлар бирә»[15]. Аерым истәлекләрдә аның музыка коралларын үзе ясавы һәм аларда үзе дә уйнап-җырлавы искәртелә.

«*Тәварихе Болгария*» (1806. — Аны кайвакыт «Тарихнамәи Болгар» дип тә йөртәләр.) — әдипнең мәгълүм әсәрләреннән берсе. Аның хәзерге фәнгә дистәдән артык кулъязмасы билгеле. Күпчелеге Татарстан авылларында табылган. Әле күптән түгел генә бу әсәрнең бер нөсхәсе Раиф Мәрданов тарафыннан Кукмара районында табылып, фәнгә мәгълүм булды[16].

www.darul-kutub.com

«Тәварихе Болгария» тәүге мәртәбә, кыскартылып, М. Өмед-баевның «Ядкәр...» китабында нәшер ителә (К., 1897- 45-48 б.). Әсәргә сылтамалар, аннан аерым өзекләр татарча, урысча, башкортча чыккан төрле китапларда күзгә еш ташлана. Өфе галиме И. Галяветдинов 1990 елда бу ядкәрнең тәнкыйди текстын оригиналда һәм башкорт графикасында, урысчага тәрҗемәдә бастырды. Монографиядә әсәрнең грамматик һәм лексик үзенчәлекләре дә яктыртыла, сүзлеге дә бар[17].

«Тәварихе Болгария» — жанры белән шәҗәрәи, ягъни нәсел-нәсәбне чагылдырган, чагыштырмача кечкенә күләмле ядкәр (Тәнкыйди тексты, искәрмәләре белән бергә, 41 бит). Үзенең эчтәлеге, төзелеше һәм гомумән рухы белән ул төрки-татар әдәбиятындагы «Шәҗәрәи төрк», «Дәфтәре Чыңгызнамә», Шәрәфеддин бине Хисамеддин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» кебек китапларын да теге яки бу дәрәҗәдә хәтерләтә. Кайбер гарәпчә юлларны һәм тәгъбирләрне исәпкә алмаганда, теле шактый аңлаешлы, үтемле. Тел җәһәтеннән дә ул шул чордагы татар язма истәлекләре белән табигый керешеп китә.

Әсәр төрле чыганакларга, авторның шәхси күзәтүләренә нигезләнеп язылган. Тәүге юлларда китапның язылу вакыты, исеме искәртелә: «...Тарих мең дә ике йөздә егерменче елда (ягъни 1806 елда — Х.М.), куй елында... ирде. ...Бу рисаләгә «Тәварихе Болгария» аты бирдем» (206 б.). Алга таба файдаланылган чыганаклар атала. Алар арасында Тәбәри, имам Туси, Чәләби, имам Тәбризи, имам Тәрази, әл-Бухари һәм Шәрыкның башка билгеле затлары бар. Алга таба щәҗәрәи тема яктыртыла башлый.

Автор үз шәҗәрәсенең беренче буыны итеп Адәм галәйһиссәламне күрсәтә. Ул мең ел гомер кичерә. Адәм галәйһиссәлам үлеп бер ел үткәч, «анамыз Хәва» вафат

була. Аларның икесен дә Шәйс җирли. Ул үзе 910 ел яши. Алга таба — Әнуш һ.б. Шәҗәрәнең иң ахыргы, ягъни 84нче буыны итеп автор үзен һәм балаларын күрсәтә.

«Тәварихе Болгария»дә төрле чорларга, диннәргә, чынбарлыкка, мифологиягә мөнәсәбәтле күп санлы исемнәр, этнонимнар, ил, кала, авыллар, географик атамалар телгә алына (Һиндстан, Гыйрак, Исфәһан, Кәюмарс, Сиам, Сократ, Нәүширван, Айдар, Аксак Тимер, Идел һ.б.). Әмма үзәктә — төрки-татар, болгар дөньясы. Автор Кәнҗәне Идел-йорттагы төрки кавемнәрнең атасы дип саный. Аннан, әдип фикеренчә, Татар, Мишәр, Иштәк, Нугай исемле угыллар туа. Иштәк, — ди ул, — «камил ир», гыйлемлектә нәзыйре (тиңе — Х.М.) юк ирде». Аның бик күп балалары булды. Шуларның берсе Бәкатун «төб йорты» «Гаму-Дәрьяны» калдырып, «Миач (Миас. — Х.М.) дәрьясына килде...» (Тәнкыйди текст, 193-194 б.).

Китапта төрле сюжетлар, гыйбрәтле хәлләр, биографик мәгълүматлар да бар. Мәсәлән, автор Болгарның ислам динен кабул итүен Гарәбстаннан өч изге кеше килүе, аларның Айдар хан кызын фалиҗ (паралич) авыруыннан дәвалавы белән бәйләп карый. «Тәварихе Болгария» дә Аксак Тимер һөҗүме, Иске Казан, Буләргә нигез салынуы хакында да легенда-риваятьләр бар. Таҗеддин Ялчыгол фикеренчә, Болгар ханы Габдулланы Аксак Тимер үтертә. Аның бер углы — Галимбәк Болгар мәмләкәтендәге Кашан (Кышан) каласында «имам вә мөдәррис» була. Аннан Мирхаҗи туа. Ул утыз ел Кашанда яшәгәч, «Зай (Зәй) тамагына» килә. Бараҗ ханда имам булып, шунда ук үлә. Мирхаҗиның углы Колгали Харәземгә китеп, анда 45 ел мөдәррис була. Бераздан «атасы йорты Зай тамагына» кайта. 110 яшендә Аксак Тимер һөҗүме вакытында вафат була... (Тәнкыйди текст, 174-176 б.).

«Тәварихе Болгария» галимнәр һәм укучылар тарафыннан төрлечә бәяләнә. Берәүләр аны чыганак,

www.darul-kutub.com

әдәби ядкәр буларак уңай яктан телгә алалар, дәлил рәвешендә китерәләр. Икенчеләре бу китапның хыялый, уйдырма характерда булуын искәртәләр.

Чыннан да Таҗеддин Ялчыгол китабында бүгенге күзлектән, тарих фәне югарылыгыннан караганда очы очка ялганмаган, гайре мантыйкый урыннар шактый күп. Мәсәлән, 1336-1405 елларда яшәгән Аксак Тимер Болгар ханы Габдулланы да, аның оныгы Колгалине дә һәлак итә. Әгәр дә без соңгыларын реаль тарихи затлар дип исәпләсәк, хронологик яктан шактый төгәлсезлек җибәрербез. Таҗеддин Ялчыгол Искәндәр Руминың (Александр Македонскийның) Сократ хәким белән Болгарга килүе, аннан «абехәят» (тереклек суы) эзләп Төньякка походка китүе турында яза. Шушы юнанлылар Болгар шәһәренә нигез салалар. Сократ хәким «Болгардагы бер кыз» га өйләнә. Гофтар исемле улы туа. Һәм ул Болгарда «шаһ була...» Бу, — әлбәттә, риваять. Әмма автор ул легенданы үзе уйлап чыгармаган. Искәндәр Зөлкарнәйнең Болгарга походы, бире дәге маҗаралары Шәрыкның күп кенә язма истәлекләрендә», шул исәптән Низаминың һәм Әхмәдинең мәшһүр «Искәндәрнамә»ләрендә гәүдәләнеш таба. Аерым кешеләрнең нәсел-нәсәбен пәйгамбәрләр, мифологик һәм күренекле тарихи затлар белән бәйләү Урта гасыр Шәрык фольклорында һәм язма әдәбиятында тулып ята. Таҗеддин Ялчыгол да нәкъ шул рухта эш итә. Мифологик һәм тарихи затларның, яшәү вакытларын һәм гомер озынлыкларын күрсәтүдә дә автор Урта гасыр поэтикасына, традицияләренә тугрылыклы кала.

«Тәварихе Болгария», — гәрчә ул тарих сүзе белән башланса да, саф тарихи әсәр түгел. Ул — мифологик, әкияти, тарихи, фәлсәфи һәм эстетик башлангычларның бер җыелмасы, үзенә күрә бер синтезы. Шуңа күрә аңа саф тарих фәне үлчәмнәре белән якын килү дөрес булмас. Әдәби әсәрләрдә, дастан-риваятьләрдә чынбарлык, тарих шактый үзенчәлекле гәүдәләнгән кебек, «Тәварихе

Болгария» ядкәрендә дә тарихи вакыйгалар, фактлар теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртелеп, үзгә бер системада бирелгәннәр. Шушы хосусиятне күздә тотып тәнкыйди эш иткәндә, бу әсәрдән мөһим мәгълүматлар алырга мөмкин. Мәсәлән, андагы аерым вакыйга-хәлләр, күп кенә тарихи затларның исемнәре, эш-гамәлләре башка чыганаклар белән дә раслана. Әсәрдән төрки кавемнәрнең якынлыгы, тарихи яшәешләренең үзара керешеп баруы, дини ышанулары, төрле күчешләре шактый ачык күренә. Шунысын да хәтердә тотыйк: безнең элеккеге чорларга мөнәсәбәтле язма истәлекләребез болай да күп түгел. Әгәр дә без бар булганнарын да тиешенчә файдаланмыйча, аңлатмыйча, тәнкыйтьләү, кире кагу юлына гына бассак, — нәтиҗәсе аянычлы булыр[18]. «Таварихе Болгария»не безнең әдәбият фәнендә кабул ителгән әдәби-тарихи жанр истәлеге рәвешендә карау отышлы. Мондый ысул андагы һәм реаль, һәм хыялый урыннарны үзара тыгыз бәйләнештә тикшерү мөмкинлеге бирә.

«Тәварихе Болгария»не тикшергәндә, бәяләгәндә аның туу шартларын, нинди ихтыяҗларга җавап рәвешендә язылуын да истә тоту зарури. Хокуксызлык, милли һәм дини яктан кысу, эзәрлекләү... Халыкның күңелендә борчылу, шом. Үзе дә шушындый вазгыятьтә яшәгән Таҗеддин Ялчыгол үз нәсел-нәсәбенең, халкының җир йөзендә озын-озак гомер кичерүен, дәрәҗәле, шанлы тарихы булуын, шәҗәрәсенең дөньядагы бөек затлар, төрле илләр, кавемнәр белән бәйләнешле икәнлеген расларга омтыла. Тормыш юлы бәхет-шатлыклардан гына түгел, фаҗига-кайгылардан да гыйбарәт. Ничек кенә булса да, күңелне төшерергә ярамый, яшәеш дәвам итә. Авторга хронологик эзлеклелектән, тарихи төгәллектән бигрәк, үзенең, халкының, диненең барлыгын, кыйммәтен, якты дөньяда яшәргә хаклы булуын раслау кирәк. Моңа ирешүдә әдип һәм тарихи, һәм әкияти-мифологик материаллардан иркен файдалана, теләк-

www.darul-kutub.com

омтылышларын гәүдәләндерерлек шәкелләр, алымнар куллана.

* * *

«Тәварихе Болгария» ядкәре аша без авторның тормышы, үзенә кадәрге нәсел-нәсәбе белән билгеле бер дәрәҗәдә таныштык. Ә соң аның үз гаиләсе ничек булган? Әдипнең кайчан, кемгә өйләнүе бик мәгълүм түгел. Бу хакта язма чыганакларда да материаллар очрамады. Безгә бу турыда Таҗеддин Ялчыгол оныкларыннан Мәлемдә яшәүче Фәүзия апа Таҗетдинова (ул 1921 елгы) һәм Гамир Госман углы Таҗетдинов (1941 елгы) кат-кат сөйләшергә туры килде. Алар фикеренчә, Таҗеддин Ялчыгол Җирекле кызына өйләнгән булса кирәк. Башка өйләнгәнме, юкмы, — анысын әйтә алмадылар[19].

«Тәварихе Болгария»дәге мәгълүматка караганда, Таҗеддин Ялчыголның «дүрт улы», «өч кызы» була. «Ахырындагы гомерендә, — диелә бу китапта, — Ирнә суы буенда Мәлем дидеке карьяда тереклек әйламеш... Олуг углым Бәһаведдин Күперле карьясендә (бу авыл Чаллы белән Сарман арасында. — Х.М.) мәншүр илә (указлы. — Х.М.) имам улыб, анда тереклек әйладе. Андан кечесе — Җәлаледдиндер. Мәлем карьясендә атасы хозурында хезмәт идеб һәм мәзкүр (шушы. — Х.М.) карьядә мәншүр илә имам улыб тереклек әйламеш. Өченчесе — Шәрәфеддиндер. Ул һәм Мәлем карьясендә тереклек әйламешдер. Дүртенчесе — Госамеддиндер. Ул һәм Мәлем карьясендә тереклек әйламешдер. Олуг кызым — Биби-Нәфисә, андан кечесе — Газизә, андан кечесе — Биби-Җәмиләдер» (Тәнкыйди текст, 165-166 б.)[19]. Күрәсез: Таҗеддин Ялчыгол — шактый зур гаиләнең башлыгы, 7 баланың атасы. Барысы да диярлек үз тирәсендә гомер сөрә. Әдип балаларына белем, тәрбия биргән, алар турында кайгырткан. Кызы Газизә исемен мәңгеләштереп китап



www.darulkutub.com

язуы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Улларына да «әй углым» дип яратып кына дәшә торган була.

Ишле гаиләне карау атадан зур тырышлык, хезмәт таләп итә. Ул, укыту-руханилык, гыйльми-иҗади эшләрдән тыш, иген игә, мал асрый, йорт кирәк-яракларының күбесен үзе ясый. Аның балта остасы булуы да мәгълүм.

Таҗеддин Ялчыгол — эш-хәрәкәт, гамәл кешесе. Чыганакларда аның «җәяү йөрергә яратуы» искәртелә. Әдипне кайберәүләр «народник» дип тә йөртәләр. Үлемен дә ул адәм балаларына игелек кылганда каршылый. Бер танышының чакыруы буенча ул, сырхауларны дәвалау өчен, Мәлемнән 40 чакрымнар ераклыктагы «Имәнле карьясе»нә (Имәнлебашка) килә»[3]. Шунда кинәт авырып вафат була[21]. Бу — 1838 елның 26 июне. Мөгаен, көннең эсселеге, әдипнең «Кайда үлсәм — шунда җирләгез» васыяте аркасында әдипне Имәнлебашта күмәргә карар кылалар. Бу мөхтәрәм затны авыл һәм тирә-юнь халкы зурлап җирли. Кабере өстенә язулы таш та куела.

Таҗеддин хәзрәт — үзе исән вакытта да, үлгәч тә халыкта бик абруйлы зат. Әдипнең кабере изге хисаплана. Аңа төрле төбәк кешеләре зиярәт кылып торалар.

Таҗеддин Ялчыгол үз гомеренең төп һәм мәгънәле өлешен Зәй буенда, Зәй төбәгендә уздырып, «дарелфәнадан дарелбәкага рихләт кылган» (каберташында шулай язылган. Ягъни «вакытлы йорттан мәңгелек йортка күчеп киткән»). Якташлары Таҗеддин хәзрәтне зур хөрмәт белән күңелләрендә саклый. Каенлы, Кызыл Чапчак, Мәлем авыллары үсә, яңара. Мәсәлән, Мәлемдә заманча йортлар (коттеджлар) төзелә, асфальт юл, ике катлы мәктәп, мәдәният йорты салынды. Урта мәктәп эшли. Анда укучылар Таҗеддин бабаларын еш искә төшерәләр. Зәй шәһәренең җамигь мәчете һәм үзәк урамнарыннан берсе Таҗеддин Ялчыгол исемен йөртә. Район Үзәк китапханәсендә әдипкә багышланган махсус

www.darul-kutub.com

стенд бар, материаллар тупланган. Тууына 230 ел тулу уңае белән каберенә мәһабәт чардуган корылган. Рәссам Рушан Шәмсетдинов, Таҗеддин хәзрәтнең нәсел-нәсәбе, шул исәптән Госман ага Таҗетдинов белән очрашып, әдипнең портретын ясады.

Таҗеддин Ялчыгол тормышы, хатирәсе уңае белән янә бер мәсьәләне ачыклап китү зарури. Ул да булса аның исем-атамасын, тәхәллүсләрен бирүдә төрлелек. Ш. Мәрҗани «Мелла Таҗеддин бине Ялчыгол ал-Башгорди» рәвешендә яза (Мөстәфадел әхбар..., — К., 1900. — 250 б.). Ризаэддин Фәхреддиннең «Асаре»ндә «Таҗеддин бине Ялчыгол бине Мәмәткол бине Йантимер бине Торымтай вә гайреләр...» диелгән (VI җөзэ, 1904. -336 б.). Шушында ук «Асарь» авторы әдипнең бер кулъязмасы ахырында «Таҗеддин бине Яхшыколый әл-Болгари эл-Иштәки» дигән исемнәрнең теркәлүен дә искәртә (336 б.). Кабердашында һәм шәхси мөһерендә язучының исеме «Таҗеддин Ялчыкол углы» рәвешендә бирелгән...

Бу атамаларның күпчелеге авторның «Тәварихе Болгария» китабында да бар: Котлуг Булат-Җианчура-Йантимер-Мәмәткол — әдипнең бабалары. Шушында ук Таҗеддин: «Мәмәтколдин мулла Йалчыгол тугмышдыр», — ди. Бераздан «атам мулла Йалчыгол» — дип тә өсти. «Рисаләи Газизә»нең кулъязма һәм басма нөсхәләрендә дә автор, нигездә, «Таҗеддин Ялчыгол» рәвешендә күрсәтелә. Ә инде «Ялчыгол» һәм «Яхшыкол» атамалары, мөгаен, бер үк «Ялчыгол» исеменең төрлечә әйтелеш вариантлары гынадыр!?

Иштәки исә этнонимга бәйләнешле тәхәллүс. Әйткәнебезчә, ул — татар һәм башкорт кавемнәре составына кергән кабилә исеме. Автор үзен шул төркем белән бәйли.

Болгари кушаматы исә Урта гасыр һәм XIX йөзнең күп кенә татар зыялылары, үзләренең тәхәллүсе итә. Таҗеддин Ялчыголның «Тәварихе Болгария» исемле

китап язуы да юкка гына түгел. Ул анда үзен Болгарның бер вәкиле дип саный. «Рисаләи Газизә» китабында да күпчелек очракта татар урынына болгар атамасын куллана («безнең, болгар теле», «Безнең болгар йортында», «Болгарның нәһре Сөн буенда» һ.б.).

Таҗеддин Ялчыгол үзе Башкорди тәхәллүсен кулланмаган булса кирәк. Күрәсең, аңа бу кушамат «Тәварихе Болгария»дәге мәгълүматларга нигезләнеп бирелә. Шуңадыр ул сирәк очрый. Башкорт атамасының төрле мәгънәләрдә кулланылуын да онытырга ярамый. Тарихтан күп кенә татарларның, матди һәм сәяси якны күздә тотып, үзләрен башкорт дип яздырулары мәгълүм. Яшәгән төбәккә, административ бүленешкә мөнәсәбәттә дә бу атама еш кына этник мәгънә белән туры килми. Мәсәлән, Башкортостаннан чыккан яисә килгән кешеләрнең башкортын да, татарын да кайвакыт башкорт дип атау гадәти күренеш.

Без, әлбәттә, «Тәварихе Болгария» авторының этник яктан башкорт кавеме белән бәйләнешле булу мөмкинлеген дә инкарь итмибез. Чөнки бу ике тугандаш халык элек-электән үзара аралашып, керешеп яшәгән. Татарлар составына башкорт кавемнәренең дә теге яки бу дәрәҗәдә катнашуы тарихтан билгеле.

Таҗеддин Ялчыгол, этник чыгышы белән башкорт булган очракта да, бала вакытыннан ук туган төбәгеннән аерылган, гомеренең төп һәм мәгънәви өлешен татарлар арасында яшәп, аларча сөйләшеп, аларга хезмәт итеп уздырган[22]. Аның балалары һәм оныклары да шушы традицияне дәвам итә. Этник яктан татар белән бәйләнешле Державинны яисә Купринны, Татарстанда туган Педер Хузангайны татар әдибе дип атап булмаган кебек. Таҗеддин Ялчыголны да «башкорт галиме һәм язучысы» дип йөртү урынлы булмастыр.

«Рисаләи Газизә» авторын Г. Чокрый «мәүлана мелла Таҗеддин әл-Болгари Оруви» дип атый (Татар әдәбияты

тарихы. II том. — 1985.-430 б.). Бу тәхәллүс, мөгаен, Көньяк Урал төбәкләренә (Ор, Орск...) мөнәсәбәттә бирелгәндер.

- II -

«Рисаләи Газизә» — Таҗеддин Ялчыгол иҗатында гына түгел, ә гомумән Тукайгача чор татар әдәбияты тарихында мөһим ядкәр. Шактый күләмле бу китап кулъязмаларда, XIX гасыр урталарыннан басма рәвештә гаять киң тарала. Казан университеты Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә генә дә аның 40 тан артык тулы һәм өлешчә нөсхәләре бар [173 Т. (N 2127), N 138 Т., N 64 Т. һ.б.). Тәүге мәртәбә бу әсәр 1847 елда Санкт-Петербургта дөнья күрә / Китабе Рисаләи Газизә. — 372 б./. Ул «Нижний губернасының Сергач өязенең Яндивишә волостеның Яңапар авылының[25] Ризван Маллай (?) углының хөражате (чыгымы. — Х.М.) илән» нәшер ителә. Казанда «Рисаләи Газизә» беренче тапкыр 1850 елда басылып чыга (440 б.)[24]. Аннан соң бу китап Казанда күп мәртәбәләр (аерым елларда хәтта икешәр тапкыр) нәшер ителә. (1857.- 298 б., 1863.- 296 б.,1874.- 350 б., 1900.- 414б., 1908.- 256 б. ...). Октябрь инкыйлабына кадәрге соңгы басмасы / «Рисаләи Газизә: шәрхе «Сөбател-гажизин» / 1916 елга карый (252 б.). Бу әсәрне басып тарату белән, нигездә, Хөсәеновлар, Кәримовлар кебек күренекле матбагачылар шөгыльләнә.

«Рисаләи Газизә» халыкның төрле катламнары тарафыннан яратып укыла. Бу хакта Г. Рәхим һәм Г. Газиз үзләренең 1923-1925 елларда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» китапларында искәртәләр. «Рисаләи Газизә», — дип яза авторлар, — «безнең татарның бик яратыб укый торган китабларындан берсе; ысулы кадим мәктәпләрендә дәреслек итеб тә кулланылган» (1925 елгы басма, 156 б.). Г. Тукай да «Исемдә калганнар»

әсәрендә Кырлайда яшәгән вакытта ук үзлегеннән «Рисаләи Газизә»не укуын телгә ала.

Таҗеддин Ялчыголның бу китабы хакында Ризаэддин Фәхреддин, М. Гайнетдинов, М. Әхмәтҗанов һәм кайбер башка авторларның да төрле характердагы фикер-күзәтүләре бар. Алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томында Таҗеддин Ялчыгол турында махсус бүлек бирелгән (К., 1984, — 443-452 б.). М. Гайнетдинов тарафыннан язылган бу мәкаләнең төп өлешен «Рисаләи Газизә»не тикшерү алып тора. Соңгы вакытта бу әсәр хакында без фәкыйрегезнең дә берничә язмасы укучыларга иреште[27]. Шулай ук «Рисаләи Газизә»нең шактый өлеше, безнең тарафтан әзерләнеп, тиешле шәрех-аңлатмалар белән «Мирас» журналында басылып чыкты (1998, — 10-12 саннар; 1999. — 1-9, 11 саннар). Таҗеддин Ялчыгол әсәренең аерым өлешләре, хикәятләре 1998 елда бер китапчык рәвешендә дә нәшер ителде (К.: «Иман» нәшрияты. — 60 б.). Анда текстны басмага әзерләүче М. Гайнетдиновның әсәр турында кереш мәкаләсе дә бар.

«Рисаләи Газизә» кайчан язылган соң? Г. Рәхим һәм Г. Газиз әсәрнең тәмамлану вакытын 1807 елга нисбәт итәләр (1925, — 156б.). М. Гайнетдинов һәм кайбер башка авторлар 1796 елны күрсәтәләр. «Рисаләи Газизә»нең 1850 елгы Казан басмасында бу әсәрнең «тарихе һиҗрәтнең 1211 нче елында елкы елында тәмам» булуы искәртелә (4 б.). Бу дата милади белән 1797 елның беренче айларына туры килә. Ә инде «Рисаләи Газизә»нең тәүге (ягъни 1847 елгы С.-Петербург) һәм кайбер башка, шул исәптән 1912/ 1916 елгы Казан басмаларында нәкъ китапның керешендә, хәтта кайберләренең тышлыгында ук әсәрнең тәмамлану вакыты итеп 1221 ел күрсәтелә. Бу исә якынча 1806 елның декабрь ае.

Әсәрнең язылу вакытын билгеләүдәге мондый төрлелек нәрсә белән аңлатыладыр, хәзергә әйтүе кыен. Бәлкем,

даталарның берсе (аеруча — 1211 ел) хатадыр? Бәлкем, автор 1796 елда үз китабының беренче вариантын төгәлләгәндер? Бәлкем, «Рисаләи Газизә» 1796 — 1806 еллар аралыгында иҗат ителгәндер? Хәзергә без 1806 елга өстенлек бирәбез. Ни өчен?

«Тәварихе Болгария»нең С.-Петербургтагы Шәрыкшенаслык Институтында саклanучы кулъязма-сында (В. 2673) «Рисаләи Газизә»нең «Кызыл Чапчак карьясендә» язылуы искәртелә. Бу авылда исә автор 1799-1824 елларда гомер кичерә.

Таҗеддин Ялчыгол XVIII гасырның 90 нчы елларында гаилә кора. Газизә — аның уртанчы кызы. Әгәр дә без әсәрнең язылу вакыты дип 1796 елны кабул итсәк, табигый мантыйкны бозарбыз. Бу вакытта әле Газизә я тумаган, туса да — сабый яшеңдә генә. Китап исә аның үтенече («илтимасы») белән дә язылa. Әсәрдән инде бу вакытта кызда «Сөбател-гаҗизин» хакында билгеле бер күзаллау булуы аңлашыла. Тагын шунысы да бар: «Рисаләи Газизә» — зур күләмле, катлаулы әсәр. Аны язу автордан бай тәҗрибә, ныклы хәзерлек һәм күп вакыт таләп итә. Болар бар да бу ядкәрнең 1211/1797 елда түгел, ә соңрак, ягъни 1221/1806 елда төгәлләнүенә дәлил булып торалар.

* * *

Таҗеддин Ялчыгол әсәренең тулы исеме — «Рисаләи Газизә: Шәрхе «Сөбател гаҗизин». Теге яки бу әсәргә шәрех (комментарий) язу — Урта гасыр Шәрык, шул исәптән татар дөньясында гаять киң таралган күренеш. Таҗеддин Ялчыгол да шушы традицияләр кысасында һәм рухында эш итә.

Шәрех ысулы белән тудырылган ядкәрләр хакында фикер йөрткәндә, иң әүвәл, нигез итеп алынган, автор мөрәҗәгать иткән әсәрләр турында аерым белешмәләр бирү зарури.

«Сөбател-гаҗизин» («Көчсезләрнең ныклыгы», «Гаҗизләргә терәк» ...)— Урта Азиянең күренекле шагыйре Суфый Аллаяр (Аллаһыяр. 1616 — 1713 яисә 1707)[29] әсәре. Аның хакында Г. Газиз һәм Г. Рәхимнең «Татар әдәбияты тарихы» китапларында, Ф. Яхин хезмәтләрендә[30], М. Гайнетдинов мәкаләләрендә шактый гына мәгълүматлар, фикер-күзәтүләр бар. Шагыйрьнең тормышы, иҗат мирасы хакында фикер йөрткәндә, алар, нигездә, «Рисаләи Газизә»дә Таҗеддин Ялчыгол биргән мәгълүматлардан файдаланалар.

Суфый Аллаяр — этник чыгышы белән нугай татары. Кайбер чыганакларда аның нәсел-нәсәбенең Әстерхан төбәгеннән булуы да искәртелә. Мөгаен, шагыйрьнең әби-бабалары, күп кенә татарлар кебек, Казан, Әстерхан ханлыклары бетерелгәч, Урта Азиягә күчеп яисә эзәрлекләүләрдән качып киткәннәрдер.

Таҗеддин Ялчыгол язуынча, Аллаяр Сәмәрканд шәһәре тирәсендәге «Миңлан атлигъ» бер авылда «нәселе нугай» булган Тимерйар исемле «гаять изге, тәкъва» гаиләсендә туа. Унике яшендә Бохара мәдрәсәсендә укый башлый («Гыйлемлек үгрәнде, күп фәннәр хасыйл әйладе»). 25 яшендә Бохара шаһы аны салым җыю оешмасына түрә кыла. Катылыгы белән танылa. Әмма бераздан тәүбә кыла, Хәбибулла шәехне остазы итә. Үзе мәшһүр суфый буларак таныла. Суфый Аллаяр үз кавеменең асыл Ватаны — Идел-йорт, бабаларының туфрагы белән дә бәйләнешен өзми. «Рисаләи Газизә» авторы аның Казан каласына килүе, «Болгарның» Идрис Хафиз исемле «бер камил суфые» белән очрашуы, биредән хаҗга юнәлүе хакында яза. Әүвәл, — ди ул, — әрзе Румга (Кече Азиягә) бармыш... Андан Искәндәрия шәһәренә килә; андан дарелфәнадин дарелбәкайә (вакытлы йорттан мәңгелек йортка) рихләт әйладе (күчеп китте, вафат булды)... Аллаярның ул заманда яше туксан ел ирде» (356-357 б.).

Кайберәүләр шагыйрьнең үлгән җирен Бохарага нисбәт

итәләр. Фарсы һәм төрки телләрендә иҗат иткән бу могтәбәр зат үзенең фәлсәфи-суфыйчыл, инсани-әхлакый карашларын, кеше, яшәеш турындагы уйлануларын әдәби юлларында теркәп калдырган.

«Рисаләи Газизә» авторы Суфый Аллаярның дүрт китабын телгә ала: «Мәсләкел-мөттәкыйн» («Тәкъвалар мәсләге», «Бәхәссез караш»), «Морадел-гарифин» («Акыл ияләренең морады»). «Михрабел-мотыйгыйн» («Күндәмнәрнең михрабы»), «Сөбател-гаҗизин». Соңгысы, — ди ул, — «бу дүрт китабның арасында гүзәлрәге вә мөшкелерәгедер. Зирә ки (чөнки) әнваг лөгать (чуар тел) илә мөдәүвәндер (төзелгәндер)».

«Сөбател гаҗизин» әсәрен Суфый Аллаяр әүвәл фарсыча иҗат итә (12 мең бәеттән артык). Аннан «яраннарының «үтенече белән, кыскартып, төркичә яза[31]. Бу поэма татар дөньясында гаять киң тарала. Аның шәрехләре (Утыз Имәни...)[32]», күп санлы кульъязмалары, Казанда нәшер ителгән басма нөсхәләре бар (1802 елдан башлап). Шунысы мөһим: ул — Казанда дөнья күргән тәүге әдәби китапларның берсе.

Безнең кулыбызда «Сөбател-гаҗизин» ның 1841 елгы басмасы[33]. Ул мәшһүр Рәхмәтулла Әмирхан углы хисабына чыгарылган. Күләме — 1712 бәет. Әсәр, нигездә, 3 буынлы һәзәҗ үлчәме белән язылган.

Тулысы белән «Коръән» рухы белән сугарылган «Сөбател-гаҗизин» — лиро-эпик характердагы әсәр. Анда авторның уй-кичерешләре төрле хикәятләр («Хикәяте Рабига», «...Хәҗҗаҗ», «...Сәүбән», «...Әхмәд бине Хәнбал», «...Локман», «...Шәех Басрый», «...Хәлил углы Исмәгыйль», «...Габдулла Әнсари» һ.б.) белән үрелеп бара. Күпчелек хикәятләрнең сюжетлары һәм образлары Шәрык дөньясы өчен традицион характерда. Алар төрле чыганакларда, төрле авторларда очрый. Мәсәлән, бер хикәяттә ике дусның суга бата башлавы тасвирлана. Берәү аларны коткарырга тели. Әмма

һәлакәткә очраучылар әүвәл мине түгел, дустымны коткар дип бәхәскә керәләр.

Диде: Куйгыл мәне, ярым кулын ал.
Моны куйды, аны чөн тотты мазбут (нык),
Бу һәм әйде: Мине куйгыл, аны тот (87 б.)

Чын дуслык идеясен гәүдәләндерүгә иллюстрация рәвешендә китерелгән бу төр сюжет Сәгъди һәм Сараи әсәрләрендә дә бар.

...Ул әйтте: «И каләме (сүзе) жанына кот (бәхет),
Мәне куй, барыб ул йарым илен тот...
(«Гөлестан бит-төрки». V баб).

«Сөбател-гаҗизин» дә Газали, Гаттар, Румый, Ясәви, Нәкышбәнди, Өмми Кәмал һәм башка әдипләрнең әсәрләре белән охшаш, уртак яклар шактый. Мөхәммәдьяр кебек, Суфый Аллаяр да үз укучысын «мөлаем сүзле», «сөчүк телле» булырга, яманнардан ерак йөрергә («Ямандин кач, ямандин кач, ямандин»), яманлыкка яхшылык кылырга... («яманлык әйлагәнгә яхшылык кыл»), нәфескә бирелмәскә чакыра. Хисам Кятиб, Өмми Кәмал шикелле, ул да гомернең фаныйлыгын, үлемнең котылгысызлыгын («үлемне даимән янында белгел») раслый. Йөзеңне ак, күңелеңне пакь тоту («Әүвәл мәртәбә холкыңны кыл пакь») — аның өчен иң мөһиме.

Дини-әхлакый рухтагы «Сөбател-гаҗизин»дә Алланың бөеклегенә дан җырлана, диндар табигатьле зат идеал итеп куела, кеше холкындагы, эш-гамәлендәге тискәре күренешләр (ваемсызлык, тәкәбберлек, икейөзлелек, комсызлык һ.б.) кискен тәнкыйтьләнә. Күп кенә суфый шагыйрьләр кебек, Аллаяр да иляһи мәхәббәтне зурлый:

Кил, әй талиб, күзең гыйбрәт белән ач,
Мәхәббәтсез кешедин кош булыб кач (48 б.).

www.darulkutub.com

Әгәр фәгъфуре Чиндыр, кайсаре Рум,
Мәхәббәт әһленең алдында мәгъдум (38 б.).
(Кытай патшасы, Византия императоры булсаң да,
Мәхәббәт алдында син көчсез).

Шунысы мөһим: шагыйрьнең Аллага мәхәббәтен, иляһи гыйшыкны гәүдәләндергән юлларын еш кына инсаннарга мөнәсәбәттә дә кабул итәргә мөмкин.

«Сөбател-гаҗизин» мөселманнар өчен үз һәм якын булган дини-суфыйчыл карашларга, әхлакый һәм эстетик тәҗрибәгә, көнегелгән зәвык-ихтыяҗларга нигезләнеп туган. Аның популярлык сәбәпләренең берсе шул. Икенче яктан, Суфый Аллаяр поэмасы әдәби яктан да шактый камил һәм үтемле. Автор төрле шигъри чараларны (эндәш, мөрәҗәгать, риторик сорау, кабатлау, аллитерация, чагыштыру һ.б.) уңышлы гына куллана:

Ятырсын яңа өйләнгән егетдик» (21 б.).
Аның дик һадига (пиргә, юлбашчыга) кылсаң тагать.
Сәгадәтдер, сәгадәтдер, сәгадәт (37 б.).
Теләсә бүркене, бирмәк кирәк баш,
Әгәр жан эстәсә, кайтармагыл каш (49 б.).
«Тот ул дустыңны сөт өстендә каймак» (71 б.)...

Шагыйрьнең күп кенә юллары хикмәтле сүз, афористик гыйбарә кебек яңгырый: «Яман хатын — шайтан камчысыдыр» (54б.); «Еланның ташыдыр (тышы) — йомшак, эче — зәһәр» (60 б.) һ.б.

«Сөбател-гаҗизин» турыдан туры да, «Рисаләи Газизә» аша да халыкка, әдәбиятка нык тәэсир итә. Аның бер хикәятендә мондый бәет бар:

Бала диб сал магыл жаның бәлагә,
Бала берлә булырсың мөбтәләгә (авыр хәлдә) (53 б.).

Бу юллар миңа кечкенә вакыттан ук таныш. Әнкәй ягыннан әби — 13 бала анасы — ул бәетне «Бала дип башың салма бәлагә, ... калырсың мөбтәләгә» рәвешендә еш кабатлый иде. Суфый Аллаяр әсәрендәге аерым юллар, гыйбарәләр, деталь-сурәтләр Утыз Имәни, Ш. Зәки, Кандалый, Акмулла, Гафури һәм башка авторларның әсәрләрендә күзгә ташлана. Мәсәлән, Утыз Имәнинең «Горбәтнамә» поэмасы Суфый Аллаяр әсәрендәге бәетләр белән башланып китә. «Сөбател-гаҗизин»дәге «Әгәр солтан үзе кылса яманлыг, Канчан булгай рәгыятьдә әманлыг» юллары (76 б.), өлешчә генә үзгәреш алып, билгесез авторның «Мәкәрҗә бәете»ндә кабатлана[34].

«Сөбател-гаҗизин» — дини-суфыйчыл карашларның, әхлакый кагыйдәләрнең үзенә күрә бер шигъри белешмәсе, энциклопедиясе кебек. Шуңа да ул игътибар үзәгендә тора. Әмма аны уку, төшенү шактый хәзерлек сорый. Бу исә китапка төрле шәрех-аңлатмалар язуны таләп итә. Шундыйларның берсен, мәсәлән, Утыз Имәни төзи. Таҗеддин Ялчыгол әсәре дә нәкъ әнә шул әдәби-педагогик ихтыяҗлар юнәлешендә туган күренеш. Авторның үзе искәртүенчә, ул «Сөбател-гаҗизин»нең берничә нөсхәсе белән эш итә.

* * *

«Рисаләи Газизә» традицион кереш белән башланып китә. Әүвәл Аллага, аннан пәйгамбәргә мактау-сәналәр бирелә. Алга таба китапның язылу сәбәбе[35] аңлатыла. Биредә әдип бу әсәрне үзгәләрнең, иң беренче чиратта, кызы Газизәнең үтенече белән язуын искәртә. Шунысы мөһим: бу юлларда авторның үз кызына хөрмәт һәм ярату хисләре бөркелеп тора («үземнең күзем нуры, бәгърем пәрәсе... кыз балам»). Әсәрнең «Рисаләи Газизә» дип аталуы да күп нәрсә хакында сөйли. Китапның ахырындагы шигъри юлларда да атаның кызына жылы мөнәсәбәте сизелеп тора: «Кил, әй бадәи саба (таң җиле) — сахибе фәзаил (затлы хуҗа); Сәламем әйлә Газизәмә васыйл» (Газизәмә сәламемне ирештер).



www.darul-kutub.com

«Рисаләи Газизә» чәчмә һәм тезмә юллар берлегеннән гыйбарәт. Анда Суфый Аллаяр әсәре гәүдәләнеш тапкан. Кайбер бәетләр Таҗеддин Ялчыголның үзе тарафыннан иҗат ителгән. Алар, нигездә, әсәрнең кереш һәм бетем өлешләрендә; эчтәлеге белән автобиографик характерда. Оригиналь тезмәләрнең шигъри ягы уртача.

«Рисаләи Газизә»нең традицион багышлау һәм хатимә (бетем) өлешләре, китапның язылу сәбәбен аңлаткан бүлекчә «Сөбател гаҗизин»нән шактый аерым тора. Әсәрнең төп өлеше исә, нигездә, оригинал эзлеклегендә бара.

Таҗеддин Ялчыгол Шәрык, шул исәптән татар рухи тормышында тупланган шәрехләү традицияләре кысаларында эш итә. Ул әүвәл оригиналның бер яисә аерым очракларда берничә бәетен китерә, алга таба аларның эчтәлеген ачыклый, мәгънәсен аңлата, аерым сүзләрнең, детальләрнең лексик, шигъри төшенчәләрен яктырта. Кайвакыт вәзен, кафия үзенчәлекләрен дә ачыклый. Бу төр анлатма-шәрехләр берничә юлдан алып, кайвакыт тулы-тулы битләргә сузыла. Әгәр «Сөбател-гаҗизин»нән китерелгән бәет болай да аңлашылып тора икән, андый юллар (әмма алар бик аз) шәрехләнмичә генә тәкъдим ителә. Бик сирәк очракларны исәпкә алмаганда, гарәпчә, фарсыча юллар татарчага тәрҗемә ителеп бара.

Оригинал байлыгын укучыларга мөмкин кадәр тулырак һәм үтемлерәк җиткерү өчен, Таҗеддин Ялчыгол өстәмә чыганакларга һәм материалларга мөрәҗәгать итә. Болар арасында гарәп, фарсы, төрки телләрдәге китаплар да, турыдан-туры тормыштан алынган факт-мәгълүматлар да бар. Автор аеруча «Кыйссасел-әнбия», «Мөхәммәдия», «Гаҗаибел-мәхлукат», «Җәмигы-мишкат» кебек ядкәрләрне, Румый, Җами («Йосыф-Зөләйха»), Ясәви, Нәкышбәнди әсәрләрен алдын күрә. Арага «Сөбател гаҗизин» дә күзгә ташланмаган аятьләр,

хәдисләр, гыйбрәтле сюжетлар кертеп җибәрә. Татарча текстта Суфый Аллаяр әсәренең Казан басмаларында булмаган хикәятләр дә очрый.

«Сөбател-гаҗизин» белән «Рисаләи Газизә» арасындагы мөнәсәбәтләрне шәрехләү өчен, төп өлештәге гадәти бер хикәяткә мөрәҗәгать итик. Ул — «Локман хикәяте». Суфый Аллаяр әсәренең 1841 елгы Казан басмасында бу сюжет болай бирелгән:

Нәсыйхәт кыйлды фәрзәндигә (улына) Локман:[36]
Сәңа жаһил (надан) кеше бәхәс итсә, әй җан;

Җаваб әйгел аңа ширин (татлы) вә йомшак,
Мәгәр булгай җәһаләт (томаналык, наданлык) хәмерендин (исереклегеннән) саг (сау).
Әгәр нәфгъ (файда) итмәсә, кылма агадә (кабат),
Булыр әйган сари җәһали зийадә (наданлыгы артыр).

Аңа сәүд (суд-файда) итмәсә, әймаг савабы,
Сөкүт итмәкдер (эндәшмәүдер) аңдыйн соң җавабы (70 — 71 б.).

Инде хәзер Локман хикәятенең «Рисаләи Газизә»дәге бирелешенә игътибар итик.

«Нәсыйхәт кылды фәрзәндигә Локман,
Сәңа жаһил кеше бәхәс итсә, әй җан;

Ягъни Локман хәзрәтләре углы Кайдарга нәсыйхәт әйладе бөйлә дию (болай дип): «Әй җан, күзем нуры, углым, һәркайчан сәнең берлә бер надан сүзгә килеб, бәхәс әйләсә, аңа ачыгланыб җаваб бирмәгел», — диде.

Әймешләр: Локманның хакыйкый (чын) исеме Борһан ирде. Аллаһу Тәгалә дөшендә хәбәр вирде: «Йа, Борһан, сәңа пәйгамбәрлек кирәкме яки гыйльме хикмәт кирәкме?», — тиб. Борһан әйде: «Бәңа гыйльме хикмәт (философия)

кирәкдер, пәйгамбәрлек эше агырдыр. Ул бәнем халемдән килмәз», — диде. Бәс (шулай итеп), Борһан гыйльме хикмәтне ихтыяр әйладе, «Локман» аталды. *Локман* мәгънәсе — күб фикерләүче димәк булыр. Углының исеме Кайдар ирде. Гаять салих (изге) кемсәнә ирде.

Әймешләр: Локман мең ел яшәде. Угылы ике йөз егерме ел яшәде. Фәләстыйн (Палестина) йирендә дәфен әйладеләр (күмделәр).

Әймешләр: Локман Сәрәндибдән (Цейлоннан) чыкты. Әймешләр: Остаздан сабак алмады. Аллаһу Тәгалә аңа укымаен (укымыйча) гыйлемлек бирде. Әймешләр: Локманның буе егерме аршын ирде. Кара чырайлыг, арык тәнлек (тәнле) ирде. Әймешләр ки, Локманның хатыны ике ирде: берсенең бер азакы (аягы) юк ирде вә берсенең бер күзе сукыр ирде. Әйделәр: «Йа хәзрәт, нә өчен бончалаен (болай) кәм (ким) әгъзалы хатынларны алдың?» — диделәр. Җаваб әйде ки: «Хатынлар ирәнләрдән (ир-атлардан) һәр нәрсәдә ким булсын: яшьдә һәм җәмалда (матурлыкта) вә малда, — диде. — Әгәр бу ике хатынымның әгъзасы ким улмаса ирде, мине сүмәзләр ирде», — диде. Локман хәкимнең гаҗаиб (искиткечле) ләтыйфәләре (гыйбрәтле сүзләре, мәгънәле хикәятләре, мәзәкләре) күбдер. Барыны язмак илә китаб озын булыр.

Җаваб әйгел аңа ширин (татлы) вә йомшак,
Мәгәр булгай җәһаләт хәмерендин саг.

Ягъни Локман Хәким әйде: «Әй, углым, анчалаен надан кемсәнә сүзгә килеб бәхәс әйласә, җавабыны сөчүк вә йомшак тел илә биргел; шайәд ки, ул надан кемсәнә наданлык хәмерендин сәламәт улыр, зирә ки (чөнки) надан ахмакга катигь сүз берлә җавап бирсәң, үбкәсе кабарыр, хакыйкать сүзне фәһемләмәеб (төшенмичә) калыр». Нәта ки боерды:

«Әгәр нәфгь (файда) тимәсә, кылма агадә (кабат).
Булыр әйгән сари җәһали зийадә.

Ягьни ул надан ахмакга сөчүк (татлы, йомшак) теллек илә җаваб бирдеке (биргән) сүзең файда кылмаса, сүзеңне әйламә, зирә ки сән тәкрар кылган саен, ул наданның үпкәсе кабарыб, наданлыкы артыр», — тиде.

Аңа сәүдә (файда) итмәсә әймаг савабы,
Сөкүт итмәкдер андин соң җавабы.

Ягьни ул надан кемсәнәгә синең тугры әйтмәкең фаңда бирмәсә, бәлки үпкәсе кабарыр булса, ул наданга җаваб бирмәен (бирмичә) тик тормак (сөкүт итмәк) — җавабдыр, — диде. Хасыйле кәлам (кыскасы, сүзнең асылы): наданның сордыкы сүзенә — йомшак җавабдыр, ул йомшак сүз илә аңламаса — тик тормакдыр», — диде» (1847 елгы басма, 255 — 266 б.).

Ике текстны чагыштыру шуны күрсәтә: оригинал әсәр дүрт бәеттән тора, ә шәрех күләм ягыннан берничә мәртәбәгә артык. «Сөбател-гаҗизин»дәге юллар тулысы белән «Рисаләи Газизә»дә бирелгән. Алар бәетләп алына да, жентекле шәрехләнә. Оригиналда Локман Хәкимнең улына биргән җавабы, ягъни бер сюжет кына бар. Шәрехтә исә алар берничә (Локманның хәкимлеккә ничек ирешүе; улы, хатыннары хакында мәгълүматлар...). Тажеддин Ялчыгол хикәяттәге төп каһарманны тагын да тулырак, күпкырлырак бирергә тырышкан. Аның асыл текстны аңлатуы һич тә бәхәс тудырмый. Оригинал белән шәрех арасындагы бу һәм башка төр мөнәсәбәтләрне күпләп китерергә мөмкин.

Таҗеддин Ялчыгол еш кына аерым сүзләр, этнографик детальләр ярдәмендә оригиналның артык үзгәртелмәгән эчтәлеген дә үз укучысына якынайта төшә. Мәсәлән, хатын-кыз һәм ир-ат мөнәсәбәтләре хакында сүз

www.darul-kutub.com

барганда, автор болай ди: «...Безнең Болгар йортында бер Сабан туе дидеке бәйрәме вардыр. Анда хатын вә кызларны таган асты дидеке уйный торган урынларына йибәрерләр вә яшь егетләр кызларның вә хатынларның кулындан тотыб уйнарлар, гауга, һай вә һуй илә урамлар тулуг улыр...» (190 б.).

Гомумән, «Рисаләи Газизә»дә халкыбызның тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, яшәгән табигате белән бәйләнешле мәгълүматлар шактый күп. Мәсәлән, суфыйчылыкта зикер әйтүчеләр, экстазга бирелүчеләр, — ди автор, — Болгарның кайбер урыннарында, җөмләдән «нәһре Сөндә (Сөн елгасы буенда) вә нәһре Керкәледә вардыр, әмма мәшһүр дәгелдер» (183 б.).

«Сөбател-гаҗизин» белән «Рисаләи Газизә»не үзара чагыштыру шуны күрсәтә: Таҗеддин Ялчыгол Суфый Аллаяр әсәренә механик рәвештә якын килмәгән, аны күңел казанында кайнаткан, зиһене аркылы уздырган, оригиналга бәйләп, үзенең күп кенә белем-мәгълүматын, фикер-күзәтүләрен, уйлануларын бәян иткән. Шуның нәтиҗәсе буларак, «Рисаләи Газизә»дә алынма һәм авторның үз материаллары, уй-кичерешләре кушылып, табигый бер эчтәлек, идея-эстетик бөтенлек тудырганнар. Шуңа күрә бу әсәрне гадәти шәрхи ядкәр дип кенә карарга ярамый. Ул — татар рухи тормышында, сүз сәнгатендә мөһим бер урынны били торган китап.

Ш. Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтенең икенче томында (К., 1900. — 250-251 б.) Таҗеддин Ялчыгол «Сөбател-гаҗизин»не «бер дә белмәгән, галәт (ялгыш. — Х.М.) бәян иткән», — дип яза, Күрәсез: тәнкыйть бик җитди.

Әйткәнебезчә, Суфый Аллаяр китабы — аңлау һәм аңлату өчен шактый кыен һәм катлаулы әсәр. Шуңа күрә аны шәрехләүдә аерым ялгышларның, төгәлсезлекләрнең китүе, бәхәсле урыннарга юл куелуы һич тә гайре

табигый хәл түгел. Китапта, мәсәлән, стиль кытыршылыклары, урынсыз кабатлаулар, хәрфи тәгәлсезлекләр күзгә ташлана. Боларның кайберләре, әлбәттә, күчерүчеләрнең, нәшер кылучыларның игътибарсызлыгы аркасында да киткән. Аерым аңлатмалар да бәхәс кузгата. Мәсәлән, «Сөбател-гаҗизин»дәге «лай» сүзен автор «балчык мәгънәсендә; төрекмән илә һинди лөгате» дип кенә аңлата (339 б). Бу исә татар теленә дә хас сүз. Әмма Таҗеддин Ялчыгол «Сөбател-гаҗизин»не «бер дә белмәгән» дию хакыйкатьтән ерак тора. Оригинал һәм шәрехне үзара янәшә кую «Рисаләи Газизә» авторының үз эшенә гаять җаваплы каравын, моңа күп көч түгүен, аның хәзерлекле әдип һәм галим булуын күрсәтеп тора. Шунысын да искә төшерик: Идел-йорттан тыш, Кече Азия, Кафказ якларында да яшәп алган, әтисеннән һәм төрле остазлардан гыйлем өйрәнгән Таҗеддин Ялчыгол гарәп, фарсы, төрки телләрен шактый белгән, Шәрыкның күп кенә әдәби һәм гыйльми китапларыннан хәбәрдар булган.

Ш. Мәрҗәни — гаять таләпчән, хәзерлекле галим. Ул хәтта Утыз Имәни шәрехләреннән дә хаталар таба. Үз мәслəгенә, рухына туры килмәгән авторларга (болар арасында, мөгаен, Таҗеддин Ялчыгол да булгандыр) аның бәя-хөкемнәре аеруча катгый. Шуңа күрә «Рисаләи Газизә» хакында «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтендә әйтелгән кискен тәнкыйди фикерне без бәхәсле, галимнең шәхси, субъектив карашы дип кенә саныйбыз. Аннан тыш бит әле шунысы да бар: бөтен әдип-галимнәр дә Мәрҗәни дәрәҗәсенә күтәрелә алмый һәм моны без мәҗбүри таләп тә итә алмыйбыз. Тормышның үзе кебек, фән һәм әдәбият та төрлелекне, заманча әйткәндә, плюрализмны ярата. Шәрех жанрының, дөресрәге — ысулының шәхси аңлау, кабул итү белән сыйфатлануын да онытырга ярамый.

Шунысы кызыклы: Ризаэддин Фәхреддин «Рисаләи Газизә» авторының эшчәнлегенә тел-теш тидерми, нинди дер

www.darul-kutub.com

чыганактан Ш. Мәрҗанинең Таҗеддин Ялчыголның язучылык хезмәтен хуплаган сүзләрен китерә. Анда «Таҗеддин хәзрәт гаять кятиб (язучы) вә сәйях (сәяхәтче)... бер зат иде... Язуы мәргуб (сыйфатлы; әйбәт) вә камил рәвешендәдер» дигән юллар да бар (Асарь, VI җөзэ, 357 б.).

«Сөбател-гаҗизин»нең идея-эстетик табигате хакында әйтелгән фикерләр «Рисаләи Газизә»гә дә тулаемы белән туры килә. Шуларга өстәп, биредә янә берничә үзенчәлекне искәртеп китәбез.

«Рисаләи Газизә» — Алла һәм пәйгамбәрләр, бу һәм теге дөнья, табигать, инсан, акың холкы һәм эш-гамәле, яшәеш хакында уйланoccупларның, мәгълүматларның, мифологик күзаллауларның мәҗмугаи, бергә тупланган бер гәүдәләнеше». Анда, кеше белән беррәттән, үрмәкүч, кырмыска, фил, елан һәм башка «мәхлукатлар», ягъни җан ияләре турында әкияти мәгълүматлар бирелү дә — нәкъ әнә шул барын да колачлауга, бөтенлеккә омтылышның бер галәмәте. Китаптан хәтта елан һәм ул чакканнан дәвалау ысуллары, «чынаяк ясамак», «алмас тимере», «чык суы кебек» темалар да читтә калмый.

Китапның эпик, лиро-эпик характерындагы сәхифәләрендә, хикәятләрендә, пәйгамбәрләрдән тыш, Хәсән Басрый, Вәйсел-Карани, Рабига, Сәүбан, Ясәви, Хуҗа Бәһаэддин Нәкышбәнди, Габдулла Әнсари, Шәех Хәбибулла, Суфый Аллаяр һәм башка мәгълүм затлар, аларның могҗизаи эш-гамәлләре турында сөйләнелә. Төрки һәм гомумән ислам дөньясының мәшһүр акыл иясе, шагыйре Әхмәд Ясәви — (1166 елда вафат була), автор фикеренчә, «шәригатьнең кояше» (кояш), «камиле мөкәммәл», «котбе галим» (ягъни галимнәрнең юлбашчысы, остазы) (187-188 б.). Һәм, гомумән, Таҗеддин Ялчыгол, Шәрык әдәбиятындагы дини-суфыйчылык традицияләренә тугрылыклы калып, үз каһарманнарын еш кына гайре табигый планда күрсәтергә, кәрамәт иясе, изге итеп тасвирларга омтыла. Бу яктан аеруча Хуҗа Бәһаэддин Нәкышбәнди хакындагы хикәят

(344-351 б.) гыйбрәтле. (Мәгълүм булганча, Урта Азиядә яшәп, 1390 елда дөньядан киткән бу зат Идел-йортта да бик хөрмәт ителә). Таҗеддин Ялчыгол аның ана ягыннан «Хозыр пәйгамбәр» белән бәйле икәнлеген күрсәтә. Нәкышбәндинең дөньяга киләсе Мәхәммәд пәйгамбәргә үк билгеле була. Хикәяттә анык зирәклеге, төрледән-төрле изгелекләре шактый үтемле итеп тасвирлана. Мәсәлән, ачлык елда Нәкышбәнди өч бөртек «богдай»дан «олуг таг кеби» икмәк көшеле хасыйл итә, кешеләрне үлемнән саклап кала. Ул вафат булгач, «ике кечерәк ак кош һәрвакытта кабер өстенә куныб, «хак-хак» дийү» кычкыра. Бу да аның хаклыгын белдертеп тора.

«Рисаләи Газизә» авторы алга сөргән идеаллар гомумкешелек кыйммәтләре, инсаният төшенчәләре белән табигый керешеп китә. Ул күрергә теләгән камил кеше — иманлы, укымышлы, күркәм холыклы, инсани эшгамәлле зат. Әдип «ачкүзлелек», «монафикъ»лык (икейөзлелек), «гафил»лек (ваемсызлык), көнчелек, нәфес колы булу һәм башка шундый сыйфатларның кешене тугры юлдан читкә сөйрәвен, әхлаксызлык, намуссызлык упкынына алып баруын үтемле итеп тасвирлый.

Әсәрдә суфыйчылык, аның асылы, төрләре, гамәлләре шактый җентекле тасвирлана. Мәүла Колый, Утыз Имәни шигырьләрендәге кебек, «Рисаләи Газизә»дә дә тыштан изге, эчтән комсыз булган руханилар, ялган суфыйлар кискен тәнкыйтьләнә. Безнең бу замандагы суфыйларның күпчелеге, — ди Таҗеддин Ялчыгол, — «мал өчен мөридләр бәсләрләр (тотарлар), кайусының малы улса, аны газиз тотарлар вә байлар ишекендә ишек саклаучы этләр кеби корырлар артык тәгамләрене бирерләр дийү... Кайу мөриднең малы улмаса, накабел (киресенчә) безләрдән сәңа тәрбият юк дийү алдаб кайтарырлар. Бончалаен җәмәгате суфыйлар (ның) дөнья вә ахирәт йөзләре карадыр... Аслан анларда яхшы ният юкдыр ки, күбләре надандыр...» (171 — 172 б.). «Рисаләи Газизә» авторы да, Ясәви, Гаттар, Хисам

Кятиб, Өмми Кәмал традицияләрен дәвам итеп, гомернең фанылыгына, үлемнең барлык инсаннар өчен котылгысыз булуына басым ясый («Әгәр сән йир йөзенең падишаһы булыб хөкем әйласәң дә, ахыр бер көнне үлем чәнгаленә, ягьни тырнагына тотылыб, кара йир астына керерсән, үлемдән капмазсән». — 151 б.). Кеше, ул кем булуына һәм нинди вазыйфа башкаруына да карамастан, тыйнак, итагатьле, сабыр булырга, мал-мөлкәт артыннан кумаска, күңелен, рухын пакь кылып яшәргә бурычлы. Әдип фикеренчә, кешеләрнең яшәү рәвешләре төрле-төрле: бае бар, ярлысы бар. Әмма аларның «һәр икесе дә әҗәл ширбәтене эчсәләр, ...бердән (бердәй) кара туфрак улырлар» (332 б.).

Таҗеддин Ялчыгол китабында тәрбияви, әхлакый яктан фикер-киңәшләр шактый күп: «Яманнарның яманы — кинә (ачу, үч) тотмак»; «Күңел милкенең падишаһы булсаң, сиңа хаҗәт дәгелдер йир йөзенең падишаһы улмак»; «...укыдыкы «Коръән» вә дәресдән үгет вә нәсыйхәт алмасаң, һаман бер кара чебен кебидер. Сән аның «Корьән» йөзенә куныб тордыкы кеби ула, ягъни әүвәл үзеңне тугры юлга күндер, андан соң адәмиләрне күндерерсән» (147 б.); «Сары май кеби мөселман кардәшләреңә мөлаем улгыл вә дәхи сөчүк (татлы) телеңне мөселманларга бал кеби даим әйлагел» (256 б.); «Үзенә рәва (дөрес, урынлы) күрмәгән нәрсәне, зинһар, мөселман карындашыңа рәва күрмәгел» (335 б.); «Нәсыйхәт сүзене ишетмәс каты күңелле кемсәнә, нә кадәр вәгазь китабларыны укысаң да, кабул әйламәс... Таш өстенә үлән бөтмәдеке (үсмәгән) кеби...»; «Пәйгамбәр г-м әйде ки: «Һәркем хатындан вә балачыкларындан качыб, нәфәка (туендырырлык ризык) бирмәен йөресә, ул кемсәнәнең аслан кылдыкы гыйбадәте кабул дәгелдер», — диде» (232 б.) һ.б.

«Рисаләи Газизә» — өйрәтү-аңлатуны, кабул итү-үзләштерүне, ягъни педагогик процессны күздә тотып язылган китап. Бу аның стилендә дә, төзелеш-структурасында да, поэтикасында да үзен нык сиздерә.

Текстта бәян итү, бәхәс, сорау-җавап формасы, кабатлау, төрле искәрмәләр бирү үзара үрелеп бара. Әсәр чагыштырмача мөстәкыйль структур берәмлекләрдән, төрле хикәятләрдән гыйбарәт. Бу ягы белән ул тартмалы композицион жанр төркеменә керә. Текстта мәгънәви эчтәлекне ачуга, эстетик тәэсир көчен арттыруга ярдәм итәрлек кызыклы сурәтләр, чагыштырулар бар: «Башың һәм күккә йитсә, кол сән, әй йар» (323 б.); «... агыр сабырлы улгыл дөньяда, йир кеби. Нитәк ки йирнең өстендә төрлек нәрсәләр вардыр: изгедән, явыздан, хәсисдән вә нәфисдән — барчасыны күтәреб торыр» (338 б.); «...сән ... хурлыкда калдым диб, «вай» димәгел, нитәк ки чынаякны күб тибкән вә баскан балчыкдан ясарлар» (3339 б.) ... Автор тау-ташларны «йир йөзенең кадаклары» дип атый (108 б.), күз яшен «кырау белән» (351 б.), «кызларның «сач толымын» «сөнбел» (351 б.) белән чагыштыра. Таҗеддин Ялчыгол фикеренчә, «йир илә күк — жефетләрдер. Яз фасылында йир җефетенә зәүкъ әйләр, күк аңа чык суыны йибәрер. Аның илә йир рахәтлек табыб, үләнләр илә хамилә (йөкле) улыр... Шуннан табигать, камиллеккә ирешер» (321 б.). Автор, үз укучысына дәшеп, китаптагы сүзләрне «колагыңа алка кеби... такгыл», — ди (366 б.).

Урта гасырның күп кенә әсәрләрендәге кебек, телдәге омонимия мөмкинлекләре «Рисаләи Газизә» дә дә иркен файдаланыла: «Бу төнне төш белән төш кылма» (137); «Кыямәтнең уен куйсаң, уен куй» (359 б.); «Булыбсән кер (керле), нәдәм (үкенмәклек) дәрьясына кер» (153 б.); «Кара димә, кара хуш фигълене...» (193 б.); «Тирем хиҗләт (оялу) белән акса тиремдин» (120 б.). Бер бәетнең тәүге мисрагында «сал» сүзе «гомереңнең елы», икенче юлында суны кичү әсбабы һәм гадәти фигыль рәвешендә кулланыла («...Тәвәккел салыны максат бәхренә сал...» (233 б.); «Вә гәр йөз табыса (йөз мәртәбә кыйнаса), кайтармас йөзене...» (192 б.). Шигъри юлларда, эстетик максатны күздә

www.darulkutub.com

тотып, бер үк сүзне кабатлау да күзгә ташлана: «Ушал пиригә (шәехка) пирнең пире булгай» (134 б.); «Мөселман алы («вәкиле») булсаң, алма алын, әгәр алсаң, кабул итмә вәбалын» (ярамаганын) (191 б.)...

Таҗеддин Ялчыгол сүз-гыйбарәләрне чагыштырма аңлатуның да күп кенә үрнәкләрен бирә: «...Рум халкының шаһыны «кайсар» дирләр; ...Чин халкы шаһыны «фәгъфур» дирләр; ...Татар халкының шаһыны «хан» дирләр; Русия халкының шаһыны «император»дирләр». «Яңгак ләфзы (сүзе) фарсы лөгатендә (телендә) «чар мәгыз» дирләр, болгар (татар) теленчә «әчтерхан чикләвеге» димәкдер, төрекмән лөгатенчә — «яңгактыр...» (218 б.).

Г. Рәхим һәм Г. Газиз, «Рисаләи Газизә»нең телен күздә тотып, болай язалар: «...аның теле җиңел вә һәрбер татар өчен ансат аңлашылырлык» (Татар әдәбияты тарихы..., 1925.— 159 б.). Чыннан да XVIII — XIX йөзләрнең күп кенә язма истәлекләре арасында бу китап тел-стиленең чагыштырмача аңлаешлы булуы белән аерылып тора. Әмма Октябрь инкыйлабыннан соң, без күп кенә элеккеге казанышларыбыздан, аеруча тел байлыгыннан шактый аерылдык. Шуның өчен Таҗеддин Ялчыгол әсәрендә бүгенге көн укучысы өчен бөтенләй яисә өлешчә таныш булмаган сүз-гыйбарәләр, грамматик шәкелләр дә очрый. Андыйларга аерым гарәп-фарсы, борынгы төрки-татар сүзләре һәм формалары керә. Кайбер сүз-атамалар, гәрчә алар татарча язылсалар да, катлаулы дини-суфыйчыл, фәлсәфи төшенчәләрне белдерү нәтиҗәсендә, бүгенге укучы тарафыннан авыр кабул ителәләр.

«Рисаләи Газизә» ядкәре тел ягыннан бай, кызыклы. Китапта без төрки-татар язма һәм сөйләмә тел хәзинәсенең шактый мул һәм тулы файдаланылуын күрәбез. Хәтта арада кылк (холык), ут (үлән), иркәк-теши (ир-ат һәм хатын-кыз), азак (аяк), үтмәк (икмәк) кебек борынгырак формалар да очрый. Татар теленең мишәр диалекты һәм Урта гасырның аерым ядкәрләре

(«Хөсрәү вә Ширин»...) өчен хас булган -мага/-мәгә (алмага, эшләмәгә...) кебек элементлар да «Рисаләи Газизә» өчен чит түгел. Автор, үз чорының сөйләм чынбарлыгына мөнәсәбәттә, әсәргә моңа кадәр язма әдәбиятта бик күзгә ташланмаган аерым сүзләрне дә кертеп җибәрә. Мәсәлән: «Шаль дидеке кәзә мамыкындан ясалмыш затдыр» (158 б.); кабак — мәйханә (238 б.); панар — фонарь (548 б.); шәберчек — йомыртка (269 б.); кыекча — яулык (250 б.); филтә — пилтә (290 « б.); «кисмәк вә чапчак» (242 б.); әзбиз — известь (340 б.)... Китап, иң беренче чиратта, педагогик ихтыяҗны, тәрбияви максатны күздә тотып язылган. Шуңа күрә анда үгет-нәсыйхәт, киңәш бирү интонациясе өстенлек итә. Моңа мөнәсәбәттә еш кына мәкаль-әйтемнәр, канатлы гыйбарәләр кулланыла: «Күз өстендә каш кеби газиз...» (171 б.); «Күб чишмә бер-беригә кушылса, олуг елга булыб акар» (177 б.); «Кадәм туфракы күзгә тутыядыр» (...аяк басдыкы туфракы күзгә сөрмәдер — 171 б.), «Үлмәздән борын үлеп куй» (275 б.); «Яманлык әйлагәнгә яхшылык кыл» (339 б.) һ.б.

«Рисаләи Газизә» — күпгасырлык төрки-татар әдәби казанышларына нигезләнеп туган ядкәр. Иң беренче чиратта, ул Рабгузый, Мәхмүл Болгари традицияләрен дәвам иттерә. Бу аларның һәм идея эчтәлегендә, һәм тел-стилендә, һәм төзелешендә күзгә ташлана. Бу өч ядкәр дә тартмалы композицион жанрда, дини-әхлакый, синкретик характерда.

XII йөз шагыйре Сөләйман Бакырганыйның «Сәна кол булгам — солтандин артык» шигыре бар. «Рисаләи Газизә»дә шуңа охшатып язылган юллар очрый («Сәнең юк булганың — барыңдан артык». — 303 б.). Мөхәммәдьяр (XVI йөз) болай ди: «Кем егылганда кулын тот бер моңлының, Ул тәкый тоткай кулың бер көн сәнең»[37]. Моңа аваздаш фикерне без «Рисаләи Газизә»дә күрәбез: «Әгәр мәртәбәң

www.darul-kutub.com

(дәрәҗәң) ирер, әгълаи афак («күкләргә тиярлек биек булса да»), Екылган хәстәләрнең халигә бак» (156 б.). Шунысы мөһим: Сәйф Сараилардан ук килә торган мондый мотив Мөхәммәдьяр, Таҗеддин Ялчыгол аша Тукай, Гафуриларга да ирешә. Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» әсәрендә (1069) тел, сөйләшү турында махсус бүлек бар. Шагыйрь фикеренчә, инсанны тел хөрмәтли дә, түбән дә итә. «Рисаләи Газизә» китабында да бу мәсьәлә читтә калмый. «Телеңне, — ди автор, — суык сүздән саклагыл... Яман тел сәбәбе берлә хур улырсән» (253 б.), ...«инә җәрахәте үңәлер (төзәлер), сүз җәрахәте үңәлмәз...» (252 б.). Котб, Сәйф Сараи тозлы (шурә) җиргә иген игүнең файдасыз шөгыль булуын кат-кат искәртәләр. «Рисаләи Газизә» китабында да бу мотив гәүдәләнеш таба: «Зирагать әйламә шуре зәминне» (ягъни тозлы, уңдырышсыз җирне.- 293 б.).

XVIII йөзнең ахыры — XIX гасыр башлары — татарларның, колониаль тукмаклардан бераз айнып, янә тернәкләнергә омтылган чоры. Пугач хәрәкәтеннән соң туган иҗтимагый-сәяси вәзгыятьтә халкыбыз, чукындыру, эзәрлекләү, кысу сәясәтенә калкан итеп, белем-мәгърифәтне, ислам динен, гореф-гадәтләрне торгызу, ныгытуны үзенә бурыч итеп куйды. Бу иҗтимагый зарурияттне гамәлгә ашыруга, Утыз Имәни, Курсави һәм кайбер башка зыялылар белән бергә, Таҗеддин Ялчыгол да үзеннән сизелерлек өлеш кертте. «Рисаләи Газизә» — шуның күркәм бер үрнәге. Ул халыкта бик популяр була, аны рухи яктан азыкландыруда мөһим роль уйный. «Рисаләи Газизә»дәге мотивлар, фикер-идеяләр, сурәтләр, шигъри чаралар Шәмседдин Зәки, Һибәтулла Салихов, Акмулла, Тукай һәм Гафури һәм башка авторлар тарафыннан тегe яки бу дәрәҗәдә файдаланылды. Гали Чокрыйның бу ядкәр тәэсирендә «Дибаҗәи Фаизә» әсәрен язуы да (Татар әдәбияты тарихы, 11-том, 430 б.) күп нәрсә хакында сөйли (Фаизә — автор кызының исеме).



www.darul-kutub.com

«Рисаләи Газизә» — әдәбиятны, динне, телне, мәгарифне, гореф-гадәтләрне, гыйлем тарихын тикшерүдә дә мөһим чыганак. Аны үзләштерү әхлаклылыкка, хәтер дәвамчанлыгына өйрәтә. Шагыйрь һәм галим Гали Чокрый (1826-1889), Таҗеддин Ялчыголны мактап, махсус мәдхия яза[38]. Ул шундый юллар белән тәгәлләнә: «Аның ханы нәвалендән ничә гам Алыр бәһрә ничә айда, ничә гам.» — Ягъни аның хәзинәсеннән никадәр халык ничә айлар, еллар алса да, өлешле булыр (сый-табыны кимемәс).

Таҗеддин Ялчыгол үз китабын кызы хөрмәтенә «Рисаләи Газизә» дип атаган. Әтисе «күзем нуры», «бәгърем пәрәсе» дип йөрткән Газизәнең кабере Мәлем зыяратында. Еллар узган, ничәмә-ничә буын туфрак булган, кабер өсләрендә агачлар үскән. Әмма «Рисаләи Газизә» ядкәре, вакытның агышына, җил-яңгырына да бирешмичә, яшәвен дәвам итә.

* * *

Алдарак әйтелгәнчә, Таҗеддин Ялчыгол әсәренең берничә дистә басмасы бар. Кулъязмалары да күп. Алар арасында теге яки бу дәрәҗәдә хосусый характердагы аермалар бар[39]. Күп кенә үзгәлекләр, мәсәлән, аерым сүзләрнең, грамматик шәкелләрнең, гыйбарәләрнең төрлелегенә карый. Техник кимчелекләр дә еш очрый.

«Рисаләи Газизә»нең автографы безгә мәгълүм түгел. Шуңа күрә без аның тәүге — 1847 елгы Санкт-Петербург басмасын алдык. Мәгълүм булганча, ул берничә нөсхә нигезендә нәшер ителгән. Кайбер өстәмә-төзәтмәләр 1912/1916 елгы[40] Казан басмасына таянып башкарылды.

«Рисаләи Газизә»нең билгеле кулъязма һәм басма нөсхәләрен туплап, үзара чагыштырып, җыйнама фәнни-тәнкыйди текст төзү — киләчәк эше[41]». Без исә үз алдыбызга, нигездә, фәнни-популяр максат куйдык. Эчтәлеккә, мәгънәгә зыян китермәслек итеп, өлешчә (әмма бик аз!) кыскартулар

да ясалды. Алар, кагыйдә буларак, аерым гарәпчә юлларга[42], искәрмә-өстәмәләргә, механик кабатланган яисә ялгыш сүз-гыйбарәләргә карый. Текстны кыскарткан урыннарда күп нокталар куелды. 1847 һәм 1912/1916 елгы басмалар арасындагы кайбер аермалар астөшермәдә күрсәтелде.

Без гарәп язуындагы текстларны гамәлдәге татар графикасы белән чагыштырмача тулы бирергә омтылдык. Әмма сирәк очракларда, бигрәк тә сузыкларның бирелешендә, урыны белән соңгырак дәвер әйтелешенә һәм язылышына өстенлек бирелде / җай-җәй, качан-кайчан, илдан-илдән һ.б./. Әмма мондыйлар бик аз. Текстта п,б авазларының икесе дә, нигездә, б хәрефе белән күрсәтелә, (п белән язылыш бик сирәк). Без аны сакларга тырыштык.

Мәгълүм булганча, әле бу чорда татар язма теленең орфографик кагыйдәләре тиешенчә эшкәртелмәгән. Шуңа күрә текстта бер үк сүзнең төрлечә язылу очраклары да тулып ята (әйләмеш-айламеш, сән-син...). Без дә мондый төрлелекне сакларга омтылдык.

Әүвәл без, киң катлам укучыларның ихтыяҗын күздә тотып, «Рисаләи Газизә» текстын хәзерге телдә генә бирергә уйлаган идек. Әмма бераздан бу ысулдан баш тарттык. Ни өчен? Чөнки тәрҗемәдә генә бирү әсәрнең шактый байлыгын, үзенчәлеген теге яки бу дәрәҗәдә югалтуга китерә. Китапның шәрех жанрында булуы да аңа сак килүне таләп итә. Аннан тыш хәзерге укучыларны да элеккеге тел-стильгә әкренләп өйрәтү, күнектерү мөһим бурыч булып тора. Моннан 100-150 ел элек кенә яшәгән әби-бабаларыбыз «Рисаләи Газизә»не шул килеш, бернинди тәрҗемә-аңлатмасыз укыганнар бит.

Без тексттагы аңлашылмаган сүз-гыйбарәләргә, җөмләләргә шунда ук җәяләр эчендә аңлатмалар бирү юлын сайладык. Ахырда яисә астөшермәдә бирү исә укучы өчен психологик кыенлык тудыра. Аңлатмалар, нигездә, контексттагы мәгънәгә карап бирелде.

Янә исегезгә төшерәбез: җәяләр эчендәге аңлатмалар,

искәрмәләр — безнеке. Аларның кайбер-ләре генә астөшермәдә бирелде. С.-П. 1847 елгы Санкт-Петербург, ә К. 1912/1916 елгы Казан басмасын күрсәтә.

«Рисаләи Газизә» кебек зур күләмле китапны уку, төшенү, хәзерге графикага күчерү, шәрех-аңлатмалар бирү, аерым нөсхәләрне үзара чагыштыру — гаять авыр, күп вакыт һәм хезмәт сорый торган эш[43]. Шуңа күрә мондый зур һәм катлаулы хезмәттә аерым кимчелекләрнең, төгәлсезлекләрнең җибәрелүе, бәхәсле урыннарның, аеруча техник хаталарның очравы һич тә гайре табигый хәл түгел. Андый җитешсезлекләр өчен без алдан ук гафу үтенәбез, мөхтәрәм укучыларның киң күңелле булуына өмет баглыйбыз.

## ИСКӘРМӘЛӘР

2. И. Г. Галяутдинов, «Тарих нама-и булгар» Таджетдина Ялсыгулова. — Уфа: Башкирское книжное изд-во, 1990. — С.169. Бу басманың 124-206 битләрендә гарәп, кирилл хәрефләрендә һәм урысчага тәрҗемәдә тәнкыйди текст урнаштырылган.

3. Иштәк-истәк — татар һәм башкорт составына кергән кабилә атамасы.

4. Троиски-Троицк — Көньяк Уралдагы шәһәр исеме. Шуңа мөнәсәбәттә Таҗеддин Ялчыголның туган җирен Троицк тирәләренә нисбәт итү дә бар.

5. Әдип әтисенең васыятенә тугры кала: нинди генә кыенлыклар булса да, гомере буе «дәрес әйтә», халыкны белемле, тәрбияле, сәламәт итү өчен тырыша, бу сыйфатларны үзенең балаларына һәм оныкларына да сеңдерә.

4а. Ш. Мәрҗани фикеренчә, Таҗеддиннең әтисе Кече Сөндә җирләнә (Асарь, VI җөзэ.- 337 б.).

5. Рәгаиб киче — рәҗәб аеның беренче җомгасында дини бәйрәм кичәсе, ягъни теләкләр теләү кичәсе.

6. Китабе Рисаләи Газизә. — Санкт-Петербург, 1847. — 367 — 368 б.

7. «Тәварихе Болгария»дә Таҗеддин Ялчыгол

әтисенең «65 яшендә», һиҗри белән 1200нче елда (миладиು белән — 1786да) вафат булуы хакында яза. Ә инде «Рисаләи Газизә»нең ахыргы битләрендәге шигырьдә атасының 53 яшендә үлүе искәртелә: «Ки илле өчдә ирде хәяты, Суйи шәгъбанда ирле мәмате» (Шәгъбан аенда иде үлеме.-Х.М.) (368 б.). Шушында ук әсәрнең «мең ике йөзнең унында» (ягъни 1796 елда. — Х.М.) язылуын, инде «унөч ел» аерылышу утында («наре фиракъ»да) януын телгә ала. Янәшәдә үк мондый юл да бар: «Уникe яшемдә калдым гарибдә, Тәвабигы вә Болгар вә Казанда» (Болгар вә Казан тирәләрендә. — Х.М.).

Күрәсез: «Тәварихе Болгария» белән «Рисаләи Газизә»дәге саннар арасында аермалар шактый. Моның сәбәбен әйтүе кыен. Төрлелек, әлбәттә, әдәби гомумиләштерү һәм яшьне һиҗри ел хисабында бирү белән дә булырга мөмкин. Кулъязманы күчерүчеләрнең дә төгәлсезлек җибәрүе ихтимал. Әмма авторның «12 яшемдә калдым гариб» дигәне «Тәварихе Болгария»дәге фактлар белән бөтенләй ярашмый. Ирексездән сорау туа: әллә Таҗеддин Ялчыгол, нинди дә булса сәбәп аркасында, даталарда төрлелекне махсус рәвештә җибәргәнме!?

8. Миңа 1995 елның 21 октябрендә Түбән Кама педагогия училищесы директоры, гаҗәеп тә милләтпәрвәр зат Рәфкать Муллин белән Зирекле авылында (аны Каенлы, Татар Җиреклесе дип тә йөртәләр) булырга туры килде. Биредә мин пенсионер укытучы (1907 елгы) Фәхри ага Шәрәфиев белән очраштым. Ул, төрле чыганакларга нигезләнеп, авыл тарихын язган. Фәхри ага раславынча, Каенлының шактый халкы Мамадыш ягындагы Кече Сөн һәм Усәли авылларыннан күчеп килгән. Ул «Таҗеддин Ялчыгол биредә 9 ел яшәгән», — дип яза».

9. И. Г. Галяутдинов. Күрсәтелгән хезмәт, 23-24, 28 б.

10. Мәлем (Югары Налим) — Зәй шәһәреннән 20 чакрымлап ераклыкта (Сарман ягына таба) урнашкан уртача зурлыктагы (200ләп өй) татар авылы. Элек Уфа губернасы Минзәлә өязенә кергән бу «карья»нең тирә-

юнендә урыс, татар, керәшен авыллары. Аннан 6 гына чакрым ераклыкта минем туган авылым Апач та (Сармаш по Ирне) бар. Шуңа күрә Мәлем, аның кешеләре миңа шактый таныш. Минем әтинең бертуганы Салихҗан абыйның (без аны «дүрәти» дип йөртә идек) хатыны Галимә түти («дүрәни»), әйтүләренә караганда, Мәлем килене, Таҗеддин Ялчыгол нәселенең бер вәкиле була. Әдипнең Апачта булуы хакында да мәгълүматлар бар.

11. Бу мәсьәлә безнең катнашта язылган «Тарихта эзле инсан» мәкаләсендә (Мирас. — 1998. — 11 сан. — 4 — 12 б.) шактый тулы яктыртылган.

12. И. Г. Галяутдинов. Күрсәтелгән хезмәт, 23-25 б.

13. Бу китапны «Фәваиде Баһавия» дип атау да очрый (Татар әдәбияты тарихы. 1-том.- К.: Таткитнәшр., 1984.- 444 б.).

14. Шиһабетдин Мәрҗани. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. 11 кыйсем.- К. — 1900,- 250-251 б.

15. Дамир Гарифуллин. Тарихта үз эзе бар// Казан утлары.- 1989. — 2нче сан.-182 б.

16. Марсель Әхмәтҗанов. «Тарихнамәи Болгар»ның яңа табылган бер кулъязмасы// Эхо веков.- Гасырлар авазы.-1996. — N 3 — 4- 25 -29 б.

17. Әмма бу җитди генә хезмәттә әдип атамасын «Ялсыгулов» рәвешендә бирү бәхәсле. Чөнки бу исем чыганакларда с хәрефе аша түгел, ә ч ярдәмендә бирелгән (Ялчыгол). Китапта телгә алынган Г. Чокрыйны да Г. Сокрый дип язу фәннилеккә хилафлык китерә.

18. Рәшит Хәмәдиев. Тарихта эзле инсан// Мирас. — 1998, — 11 сан — 10 -11 б.

19. Гамир әфәнденең әтисе Госман ага Таҗетдинов белән (ул 1910 елгы) минем очрашкалаган бар иде. Әмма, кызганычка каршы, мин Таҗеддин Ялчыгол, ягъни аның бабасы хакында махсус сораштырырга өлгерми калдым. Госман ага 1998 елның 7 июлендә вафат булды. Д. Гарифуллин исә бу могтәбәр заттан алган аерым мәгълүматларын «Тарихта үз эзе бар» мәкаләсендә (К.у. — 1989. — 2нче сан) файдалана.

19а. Әйткәнебезчә, «Тәварихе Болгария» 1806 елда

төгәлләнә. Ә әдипнең гаиләсе хакындагы бу мәгълүматлар соңрак, Таҗеддин Ялчыгол Мәлемдә яшәгәндә теркәлгән.

20. Имәнлебаш район үзәгеннән (ягъни Зәйдән) 15 чакрым ераклыкта урнашкан. Ул Зәй һәм Түбән Кама шәһәрләре арасында.

21. Таҗеддин Ялчыголның үлеме хакында Ш. Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар...» китабында (К., 1900. — 250-251 б.) болай яза: «Сәяхәтендә әхбабларындан берәүнең даренә дохул илә эчәргә сораб, сахибе бәйт шәрабе гасәл китереб биреб, шуны эчеб... Имәнле нам карьядә вафат улды». Ягъни әдип бер сәяхәте вакытында бер дустының өенә кергәч, эчәргә сорый, өй хуҗасы аңа ачы бал бирә, шуны эчеп... үлә. Бу хәлне кайвакыт заманча аңлату очраклары да бар. Имеш, Таҗеддин Ялчыгол эчеп үлгән. Ә бит бу факт бик гади аңлатыла. Җәйге эссе көндә кешенең сусавы, аңа, су урынына хуҗаның эчемлек бирүе, моның 70 яшьлек кешегә ярамавы табигый «Шәрабе гасәл» («Мөстәфадел-әхбар...»ның 1989 елгы басмасында аны «балдан ясалган аракы» дип тәрҗемә иткәннәр. — 293 б.) — гадәти ачы бал. Градусы түбән бу эчемлекне элеккеге татар гаиләләрендә сусауны басыр өчен дә кулланганнар.

Тынгысыз әдипнең күпләгән дуслары гына түгел, аерым дошманнары да булгандыр. «Ачы бал» вакыйгасын аларның гайбәт рәвешендә таратулары да мөмкин.

Таҗеддин Ялчыгол — әхлаклы, айнык акыллы, итагатьле зат.

Моны әдипнең тормыш юлы да, хезмәтләре дә, аның хакындагы якты истәлекләр дә раслап тора. Юкка гына бу инсанлы халык ул исән вакытта да, вафат булгач та «Таҗеддин хәзрәт», «изге зат» дип атамый.

22. Таҗеддин Ялчыгол яшәгән Каенлы, Кызыл Чапчак, Мәлем — элек тә, хәзер дә саф татар авыллары. Аларны, элеккеге Уфа губернасына керүләренә карап, башкортка, Башкортостанга бәйләргә омтылу бөтенләй нигезсез.

23. Әдипнең оныклары үзләренең нәсел-нәсәбе белән шактый кызыксына. Мәсәлән, Фәүзия һәм Госман Таҗетдиновларның бабалары — Таҗеддин хәзрәтнең

улы Җәләледдин (аның улы Мөхәммәдшакир, аның улы Сөнгатулла — 1873 — 1921...). Әле яңарак кына арабыздан киткән әдибә һәм журналист Диләрә Газый кызы Зөбәерова (1930 — 2000). Ул кайбер язмаларын Ялчыгулова имзасы белән да бастырды. Аның әнисе (Җәләледдин буынынннан) заманында Таҗеддин «бабасы хакында материаллар жыйган, өлкәннәрнең аның турында сөйләүләрен тыңлаган... Бабасының төп кебек нык, күзләренең зәңгәр, мыегының сары (бакыр) булганлыгын» искәрткән (Тарихта үз эзе бар// К.у.- 1989. — N 2. — 183 б.). Фәүзия апа фикеренчә, аның әбисенең әнисе Фәрхидоха (ул хәзерге Зәй районы Чыбыклы авылыннан килен булып төшкән) — Ризаэддин Фәхреддин шәҗәрәсе белән бәйле, Таҗеддин Ялчыголның, нәсел-нәсәбе, оныклары төрле төбәкләргә таралган. Алар арасында төрле шөгыль ияләре бар. Мәсәлән, Әнәс Габдулла углы Таҗетдинов (1927-1991/ 1971-1987 елларда Татарстанның Юстиция министры булып эшләде, Әсгать Сәфәров (1961) — генерал-лейтенант, Татарстаннын эчке эшләр министры. Гамир Таҗетдинов (1941) Зәй төбәгендә укытучы, мәктәп директоры, район мәгариф бүлеге мөдире һәм башка җаваплы урыннарда эшләде. Хәзер шул ук районның Аксар авылында күмәк хуҗалык рәисе.

24. Тарихта эзле инсан// Мирас.- 1998.-N 11.- 8 б.

25. Яңапар (Актүк) — Сергач төбәгенең мәшһүр авылы. Финляндиядәге күпчелек милләттәшләребезнең әби-бабалары шушы авылдан. Мөгаен, Ризван Маллай да Петербург, Суоми якларында сәүдә яисә башка эш белән шөгыльләнүче укымышлы бер зат булгандыр. Авыл тарихы, аның кешеләре хакында Хәсән Хәмидулланың «Яңапар тарихы»н карагыз/ Мирас.- 1998.- N 6. — 77-102 б.). Рәшит Ваhапов, Хәйдәр Бигичев, Рифат Фәттахов һәм кайбер бүтән билгеле затлар да — шушы авылдан.

26. Казан университетының басмаханәсендә 1850 елда дөнья күргән бу китапны матбугатка «Казан мешчаны (мещаны Шаһиәхмәд Хисамеддин углы вә Һәм Хәсән Бәһаэддин углы Саликовлар һәр икесенең хөраҗатлары илән» әзерлиләр. Алар фикеренчә, басма

текстның «асыл нөсхәсе» нигезендә башкарыла (437 б.)

27. Рухи пакьлеккә өндәгән китап // Мирас.- 1988.- N Ю. — 5 — 13 б.; Әдәбият; 9 нчы сыйныф өчен дәреслек... — К,: Мәгариф, 1994.- 178 — 179 б.

28. «Рисаләи Газизә»дә ул «Интекмәклекне исбат әйлагүче» дип тә тәрҗемә ителә (1847 елгы басма, 35 б.).

29. Фәнни әдәбиятта Суфый Аллаярның яшәү вакыты 1616 — 1713 еллар дип күрсәтелә. Шагыйрь 1616 елда туган дип алсак, аның үлеме 1706 — 1707 елларга туры килә. Чөнки Тажеддин Ялчыгол аның «туксан яшендә» үлгән искәртә. 1707 елда Суфый Аллаяр үзенең «Мәсләкел-мөттәкыйн» әсәрен төгәлли. Шунысы ачык: шагыйрь 1707 елдан да иртәрәк үлмәгән.

30. Фәрит Яхин. Урта Азиядә яшәгән татар шагыйре // «Мирас. -1997, — N 9. — 16 — 19 б. Шушы ук автор «Сөбател-гаҗизин» поэмасын, хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп, тиешле аңлатмалар белән әүвәл «Мирас» журналында (1997. — 9 — 12 саннар), аннан аерым китап рәвешендә бастырды /Суфи Аллаһияр. Собател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк). — К.: «Иман» нәшр., 2000. — 156 б./.

Фәрит Яхинның «Татар шигърияте ндә дини мистика һәм мифология» монографиясенең дә (К.: Татар дәүләт гуманитар институты нәшрияты. 2000. — 267 б.) бер бүлекчәсе (239 — 258 б.) Суфый Аллаяр иҗатын тикшерүгә багышланган.

31. «Сөбател-гаҗизин»нең язылу вакыты билгеле түгел. Мәгълүм булганча, Суфый Аллаяр иҗат эшенә шактый соң — 40 — 50 яшьләрендә генә керешә. Бу әсәр якынча XVII гасырның соңгы чирегендә язылган булырга мөмкин.

32. «Сөбател-гаҗизин»нец Утыз Иманигә нисбәт ителүче «шәрех»ендә (Казан университетының Фәнни китапханәсе. Сирәк китаплар һәм кулъязмалар фонды. — N 736 Т. — 128 кәгазь) төп урынны Суфый Аллаяр тексты алып тора. Биредә аңлатма-шәрехләр тик аерым сүзләргә, гыйбарәләргә генә бирелгән.

33. Сөбател-гаҗизин — К., 1841 — 108 б.

34. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты / Төзүчесе М. Гайнуллин. — К.: Таткитнәшр., 1979. — 12 б.

35. «Рисаләи Газизә»нең бу өлеше белән Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки»ендәге кереш типологик яктан охшаш, һәр икесендә дә башка авторның (берсендә — Сәгъдинең, икенчесендә — Суфый Аллаярның) әсәрен үз укучыларыбызга җиткерү үтенече белдерелә, һәм Сараи, һәм Ялчыгол үзләрен кимчелекле дип саныйлар. Ахыр чиктә һәр икесе дә үзгәләрнең теләген гамәлгә ашыруга керешә.

36. Локман. — Локман хәким — Шәрык дөньясының легендар акыл иясе.

37. Мөхәммәдьяр. Нуры содур. — К.: Таткитнәшр., 1997. — 66 б.

38. И. Г. Галяутдинов. Тарих нама-и булгар..., 25 — 26 б.

39. Мәсәлән, 1847 елгы басманың бер бүлегендә рәтенчиратын белмәгән юлдашның никадәр үгет-нәсыйхәт бирсәк дә, үзгәрешсез калуы искәртелә (313 б.). Ә инде Казан басмаларында (1850. — 373 б.; 1912/1916. — 215 б.) биредә «Ана сөте берлә күнелмәгән (күнмәгән) тана сөте берлә күнелмәс» мәкале өстәлгән. Мондый өстәмәләр янә дә очраштыргалый. Басма нөсхәләрдә һәм кулъязмаларда текстның бүлекләргә аерылуында, бүлекләрнең исем-атамаларында да кайбер үзгәрешләр бар.

40. Биредә ни өчен без ике дата куябыз? Чөнки бер үк китапның тышлыгында 1916, ә эчке ягында 1912 ел күрсәтелгән.

41. «Рисаләи Газизә»нең җыйнама текстын төзүгә Төркиядә яшәүче милләттәшебез, берничә телне (шул исәптән япун, гарәп, фарсы, инглиз һ.б.) белүче Фазыл әфәнде Агиш ниятләп йөри иде. Без дә аңа Таҗеддин Ялчыгол әсәренең берничә кулъязмасын (фотокүчермәсен) җибәргән идек. Бу эшнең торышы хәзерге вакытта безгә мәгълүм түгел.

42. Гарәпчә юллардан соң, гадәттә, аларга татарча

шәрех-аңлатмалар бирелә. Шул сәбәпле эчтәлек, мәгънә саклана.

43. «Рисаләи Газизә» текстын әзерләүгә инде без берничә еллар элек үк керешкән идек. Аның аерым өлешләре Казан университетында уку-укыту процессында безнең тарафтан кулланылып та килде. Әмма башланган эшне дәвам итәргә кул җитмичә йөрде. Таҗеддин Ялчыголның тууына 230 ел тулу уңае белән, ягъни 1998 елда «Рисаләи Газизә»не әзерләүгә ныклап керешелде. Моңа Зәй шәһәренең һәм районының ул вакыттагы хакиме Рәшит Хәмәдиев һәм аның урынбасары, чын милләтпәрвәр Рәис Нәҗиповның, күп кенә якташларымның (аеруча Мәлем, Аксар, Имәнлебаш зыялыларының) үтенечтеләкләре дә уңай йогынты ясады. «Мирас» журналының баш мөхәррире Әхмәт Сәхапов та «Рисаләи Газизә»не әзерләү белән даими кызыксынып торды, аның шактый өлешен үз укучыларына җиткереп тә барды. Кыскасы, бу хезмәт шәхси теләк белән генә түгел, ә күпләрнең ихтыяҗын, объектив зарурияtне тоеп башкарылды. Бу эштә миңа ярдәм итүчеләргә, аеруча бөтен язманы машинкада басучы хатыным Рәмзия Садрый кызына ихлас рәхмәтемне белдерәм.

*Хатыйп Миңлегулов*
*1998; март, 2001 ел*

www.darul-kutub.com

## Таҗеддин Ялчыгол (1768-1838)

# РИСАЛӘИ ГАЗИЗӘ[1]

## [Кереш]

(Китапның тәүге битендә чәчмә һәм шигъри шәкелдә Аллаһка, пәйгамбәргә мактау-мәдехләр укыла. Татарча юллар еш кына гарәпчә гыйбарәләр, текстлар белән аралашып бирелә).

...Бу китапны төзегән гөнаһ кырында гизгән, бөтен гомере бозыклык, начарлык белән узган, Аллаһның рәхмәтеннән өмет иткән, адәмнәр арасында дошман тотылган, барча эшне Ходага тапшырган, аз изгелек итүче, күп гөнаһлы көдөгый (көдай, көди[2]) халкы галиме Таҗеддин Ялчыгол углыннан үтенделәр ки, бу «Сөбател-гаҗизин»[3] китабын төрки теленә[4] тәрҗемә итсәң иде, — диделәр. — Синдә булган бераз фәннең хуш исе борыныбызга киләдер, — диделәр.

— Чөнки ул «Сөбател-гаҗизин» чуар, төрле тел белән төзелгән, — диделәр. — Аның серле телләрен

---

1 «Рисаләи Газизә»нең күп санлы басмалары бар. Биредә нигез итеп аның беренче — 1847 елгы Санкт-Петербург басмасы алынды (Китабе Рисаләи Газизә — 371 б.) (Алга таба — С.-П.). Аерым үзгәрешләр, өстәмә-төзәтмәләр 1916 (1912) елгы басмага таянып кертелде (Рисаләи Газизә: Шәрхе «Сөбател-гаҗизин». — Казан: Өмид, 1916. — 252 б.) (Алга таба — К.). Күп ноктalar кыскартуларны белдерә. Җәя эчендәге сүзләр, шәрехләр (аңлатмалар) — безнеке Х.М.).

2 1916 елгы басмада бу сүз көдәй (көди) рәвешендә язылган (3 б). Бу сүз «Тәварихе Болгария»дә дә очрый: «Бу Тынышдан ике угыл тугды: бере — Куди, бере — Кошчы. Бу ике угылдан күп хәлаеклар йәйелде» (Тәнкыйди текст: И. Г. Галяутдинов. «Тарих нама-и булгар» ... Уфа, 1990.— 161, 36 б.). Фәндә көдәй (көди, куди) атамасы тәмам ачыкланмаган. Г. Рәхим. Г. Газиз: «Көди» (гидай?), ихтимал, аның (Таҗеддин Ялчыголның) мулла булган авылының исемедер» (Татар әдәбияты тарихы, 1925. -156 б.); И. Галяутдинов: «Куди этимология неясная (назв. этнической группы башкир)» (с. 119).

3 Биредә Суфый Аллаярның (Аллаһыйарның — 1616—1713) әсәре истә тотыла.

4 Биредә татар язма теле күздә тотыла.

телебез белән аңлатсаң иде, — диделәр. Аларның бу сүзләренә игътибарыбыз булмады. Мәгәр үземнең күзем нуры, бәгърем парәсе бер кыз балам үтенде: «Әй ата, ни булыр, әгәр бу кавемнәрнең үтенечләрен хуш күрсәң вә ахыр чиктә без дә аннан файда алсак», — диде. Анда да игътибарыбыз булмады. Өченче тапкыр бу кызыбыз: «Әй ата, ни өчен үтенечебезне кабул итмәдең? Безне яратылыш дөньясында нәселегездә саклап, билгеле бер рәвештә тәрбия итеп шәфкать итәр идегез. Ни булыр ки, аталык мәрхәмәтегездән мәхрүм итмәсәң», — диде. Шулай итеп, зарурият белән ул күзем нурының үтенечен кабул итеп, «Сөбател-гаҗизин» китабын шәрех итүгә (аңлатырга) ният кылдым. Һиҗри ел хисабы белән 1221 нче[1] елкы (ат) елында тәмамладым. Бу шәрехкә (аңлатмага) «Рисаләи Газизә» дигән исем бирдем. Чөнки үтенүченең исеме дә Газизә иде. Шуның өчен «Рисаләи Газизә» булды.

## Шәех Хәбибулла кыйссасы

Килдек үзебезнең максатыбызга. Кыйссаларда шулай әйтелә ки, һиҗрәтнең мең дә йөзенче елында (ягъни 1689 елда) Бохара халкы, иман вә гыйбадәткә ялкау булып, бидгать (ярамаган) эшләргә чумдылар. Кыскасы, болар, тугыз ел начар вә бидгать эшләр артыннан йөреп, диннең асылларын югалтуга якынайганнар иде. Бохарада бер углан Ристан дигән базарда кавын, карбыз сатып йөри иде. Ул углан мондый бер фикердә икән: бу данлыклы Бохара шәһәре шулкадәр бозыклык һәм азгынлык белән тулган ки, әүлияләр әләме юкка чыкты. Йа Рабби, зинһар, бу бәндәңне газиз әйләп, боларга әмре-мәгъруф (үгет-нәсыйхәт, вәгазь) итәрлек кадәрле гыйлем бирсәң, — диде. Хак Тәгалә хәзрәтенә зар-зар елады.

Кыскасы, бер чәршәмбе көнне Хуҗа Бәһаведдин[2] әүлиянең каберен зиярәт итте. Анда да Хак Тәгалә хәзрәтенә күп догалар кылды. Моннан соң йокы басты. Йокыга китте. Төшендә бу сыйфатта Хуҗа Бәһаведдинне күрде: урта буйлы, күк (зәңгәр) күзле, кызыл

1 Һиҗринең 1221 елы миладиның 1806 елына туры килә. Фәнни әдәбиятта «Рисаләи Газизә»нең язылу вакытын 1796—1797 ел дип күрсәтү дә очрый.

2 Хуҗа Бәһаведдин — Мөхәммәд Нәкышбәнди (1314—1389) — Урта Азиядә яшәгән атаклы суфий.

www.darul-kutub.com

сакаллы. Диде ки: «Әй бәгърем, син Сәмәркандка бар, анда бер сыер көтүчесе булыр. Минем мөридләремнән. Син аннан белем ал. Соңыннан килеп, бу Бохараны яхшы эшкә дәгъвәт ит (өндә)», — диде.

Шулай итеп, бу углан, йокысыннан уяныл, шунда ук Сәмәркандка юнәлде. Бер көн Сәмәркандка барып җитте. Сыер көтүчесен күрде. Исеме Әндәрҗан Суфый иде. Мөридләре күп иде. Бу углан Хәбибулла һәм Әндәрҗан хәзрәтләренә чын ихластан мөрид булды. Күп вакыт анда аң-белем алды.

Кыскасы, Шәех Әндәрҗан көннәрдән бер көн әйтте: «Кайсыгыз Бохарага барып гыйлем өйрәтәсез? Ул Бохара халкы азгын булды. Әүлияләр әләме юкка чыкты». Мөридләр һичберсе җавап бирмәде, һәм шуннан соң шәех хәзрәтләре Хәбибуллага карап әйтте: «Бохарага син бар. Аларны мөрид әйлә. Мин сиңа рөхсәт бирдем», — диде.

Бу Хәбибулла ул вакытта егерме яшендә иде. Хәбибулла әйтте: «Йә шәех, әйе, синең сүзеңнән чыгу - көферлектер. Ләкин сез бер мәҗлестә шулай дигән идегез: «Шәйх булган кешегә дүрт нәрсә кирәк: беренчесе — зирәклек, икенчесе — сөйләм осталыгы, өченчесе — тиешле яшь, дүртенчесе — мал кирәк... Ләкин боларның һичберсе дә миндә юк», — диде. Зирәк булмыйча, мөридләр тәрбияләп булмас. Сөйли белмичә, гыйльме заһирга[1] җавап биреп булмас. Өлкән яшь шуның өчен кирәк: бик яшь булса, халык аны түбәнсетер. Мал халыктан сорамас өчен кирәк.

Һәм шәех, бу сүзне ишеткәч, уйга чумды. Бер сәгатьтән соң торып җавап бирде: «Әй углан, бар, юлда һәрберсе сиңа хасыйл булыр (табарсың)», — диде. Шуннан соң бу Хәбибулла, Аллаһу Тәгаләгә тапшырып, хәзрәте шәехне күңеленә алып китте. Бохарага җиткәндә, Аллаһу Тәгалә аны кырык яшьлек кеше кыяфәтенә әйләндерде, илаһият гыйлеме һәм гыйльме кимийа (могҗиза кылу, химия белеме) бирде. Халыкка һич ихтыяҗы калмады. Бохарага килеп керде, бер иске кибеткә кереп утырды. Кешеләрдә ярамаган эшләр күрсә, тиешле эшләрне эшләргә өндәү вә тыелган эшләрдән тыю белән шөгыльләнде һәм шул

---

1 Гыйльме заһир — тышкы, дөнья турындагы мәгълүмат. Батыйн — эчке; күренми торган. «Гыйльме заһир», «гыйльме батыйн» төшенчәләре, иң беренче чиратта, суфыйчылык белән бәйләнешле. Бу мәгълүмат нигезендә дөньяны, тирәюньне, кешене эчке тою, интуиция белән аңлап, таныл-белеп була.



www.darul-kutub.com

кибет янындагы балаларга сабак-дәрес бирде. Базардагы сәүдәгәрләрнең күбесе мөрид булды. Бу вакыйга һәм аның гыйлеме Бохарада мәшһүр була башлады.

Кыскасы, Бохараның ханы, үзенең галимнәрен ашка чакырып, пәйгамбәр хәдисләрен укыдылар, күп гыйбрәтләр алдылар. Галимнәр арасыннан берсе әйтте: «Йә падишаһ, гомерең озын булсын! Безнең Бохарага бер ялганчы, килеп, үзен олуг шәех санап, мөридләрне тәрбияли икән. Инде син, тагын бер мәҗлес җыйганда, аны да чакыр, безне дә чакыр. Без аннан дингә ышану мәсьәләләрен, Хак Тәгаләнең берлеге турында сорарбыз. Әгәр аның дини мәсьәләләрдән хәбәре булмаса, шәһәрдән куарбыз», — диделәр. Шулай итеп, болар, киңәшеп, бу фикергә килделәр, шаһ мәҗлесеннән чыгып киттеләр.

Кыскасы, көннәрдән бер көн шаһ мәҗлес җыйды. Галимнәрне чакырды һәм дамелла Хәбибулланы да шунда чакыртты. Бу Хәбибулланың бер һинди ишәге бар иде. Аңа менде, падишаһ мәҗлесенә барды. Кереп, галимнәр арасына утырды. Хәл-әхвал сораштылар. Аннан соң галимнәрдән берәү әйтте: «Йә дамелла Хәбибулла, Ходаны ничек танырсың? Һәм ничә сыйфат белән белерсең?» — диде. Шунда ук Хәбибулла җавап бирде: «Әгәр Ходаның сыйфатын вә берлеген белми торган булсагыз әйтегез. Әгәр имтихан өчен сорый икәнсез, монафикълык (икейөзлелек) уртасында сез», — дигәч, галимнәр тындылар, һичбересе каршы сүз әйтмәде. Аннан соң дамелла Хәбибулла әйтте: «Мин Коръәндә сурәи Йосыфны таба алмыйм», — диде. Шул чак, галимнәр арасыннан берсе әйтте: «Мин хәзер сурәи Йосыфтан сабак өйрәттем, мин табармын», — диде. Инша Аллаһ Тәгалә димичә, «Коръән Шәриф»не кулына алды, кәгазьләрне актарды, тапмады. Аннан соң тагын берсе алды. Ул да тапмады. Болар барысы да аптырап калдылар. Ахыр чиктә бу дамелла Хәбибулла Коръәнне кулына алды. «Бисмилләһир-рахманир-рахим» дип ачты, сурәи Йосыфны күрсәтте. Бу эштән таңгаҗәп калдылар. Шәех Хәбибулла, аннан чыгып, үз эшенә китте. Падишаһ калган галимнәргә әйтте: «Сез бу галимне дошман күрмәгез, чөнки сезгә кәрамәт (могҗиза) күрсәтте. Сез белдегезме?» — диде. Барчалары гаҗәпкә калдылар, аптырадылар. Мәҗлестән чыгып киттеләр.

Кыскасы, көннәрдән бер көн шаһ тагын мәҗлес

корды, галимнәрне чакырды. Барысы да килделәр. Шәех Хәбибулла да шунда иде. Баягы ишәгенә менеп килгән иде. Утырдылар. Тәгамне (ризыкны) галимнәр алдына китерделәр. Падишаһ әйтте: «Авыз итегез, ашагыз!» — диде. Һичберсе кул сузмады. «Син әүвәл кул суз, син беренче кул суз!» — дип, бер-берсенә әйтеп, бер сәгать чамасы тордылар. Әмма шаһ боларны күреп әйтте: «Йә галимнәр, ни өчен ризыкка кул сузмыйсыз, тәгам хәләлдер», — диде. Моннан соң араларыннан бер мелла — Нияз Чукмакый исемлесе «әфәнде, бисмиллаһ», диеп тәгамга кул сузды. Аның артыннан барча галимнәр кул суздылар. Бу шәех Хәбибулла кул сузмады, тик торды. Падишаһ әйтте: «Йә дамелла Хәбибулла, ни өчен кул сузмыйсың?» — диде. Хәбибулла әйтте: «Тәгамең хәрамдыр, галимнәрең фасикълардыр (бозыклардыр)», — диде. — Төн-көн хәрам ашап, күңелләреннән хикмәт нуры качкан», — диде. Галимнәр җавап биреп әйттеләр: «Безгә шәригать тыштан карарга кушты. Без бу шаһның ризыгында хәрам нәрсә күрмәдек. Син күрмичә, ничек хәрам дип фәтва бирәсең?» — дип галимнәр арасында гауга, җәнҗал күп булды.

Хәтта Шәех Хәбибулланы якалый башладылар. Шәех Хәбибулла әйтте: «Сабыр әйләгез, чөнки падишаһның, су алып, аш пешерә торган коесына бер кәнизәк (хезмәтче хатын) тавык үтереп ташлаган. Өч көн булды. Шаһның кырыслыгыннан куркып әйтми, — диде. — Тәҗрибә өчен шул коеның суын алып, минем ишәгемә китерсеннәр — эчмәс, — диде. — Әгәр гайре (башка) коедан алып китерсәгез эчеп туймас», — диде. Аннан соң шулай иттеләр. Шул коедан алып китерделәр, ишәк алдына куйдылар. Пошкырып эчмәс булды, аягы белән суны тибеп түкте. Башка коедан китереп, ишәк алдына куйдылар, туйганчы эчте. Шәех Хәбибулла әйтте: «Минем ишәгем бу галимнәрдән галимрәк икән», — диде. Падишаһ һәм галимнәр барчалары хәйран калдылар. Моннан соң шаһы хәзрәт хезмәтче кыздан сорады: «Коега тавык үтереп ташладыңмы?» — дигәч, «Әйе, бардыр», — диде. Шуннан соң коедан тавыкны чыгардылар һәм шәех Хәбибулла могҗизасын таныдылар, чын әүлия дип мөридлеккә керделәр. Әүвәл шаһ керде, аннан соң барча галимнәр керделәр.

Бохарада никадәр бидгать (бозык) эшләр булса,

www.darul-kutub.com

барчасы тыелды, бетерелде. Бохара халкының төн-көн тәүфыйклары артты, күп кеше аңа иярделәр, шөһрәте илдән-илгә таралды.

## Кыйссаи Суфый Аллайар

Назыйме рәхмәте Аллаһ галәйһинең сүзләре. Сәмәрканд шәһәрендә бер Миңлан исемле авыл бар иде. Ул авылның күпчелеге изгеләр иде. Ул авылда Тимерйар (1847 елгы басмада — Тимерир. — 8б.) дигән кеше бар иде. Гаять салих (изге), тәкъва (диндар) кеше иде. Асыл нәселе нугай халкы[1] иде. Аннан бер угыл туды, исемен Аллаһыйар (Аллайар) куйды. Унике яшендә, Бохарага китереп, мәдрәсәгә илтте. Гыйлемлек өйрәнде, күп фәннәр хасыйл әйләде (үзләштерде).

Егерме биш яшендә Бохараның шаһы аны баҗ мәхкәмәсенә (салым җыю оешмасына) түрә итеп куйды. Гаять кан түгүче, холыксыз иде. Һәрдаим бозыклыкта, азу-тузуда булды. Кешеләрне бик рәнҗетә иде. Көннәрдән бер көнне Ристан (С.-П. да — Рустак. — 8б.) базарында шәйх Хәбибулланың бер фикердәше сатучылардан әйбер алды, тик баҗ мәхкәмәсенә хәбәр итмәде. Алып барганда, Аллайар түрәгә очрады. «Йә, ни өчен баҗ мәхкәмәсенә тамга (пошлина) түләмичә алып барасың?» — дип тотты. Кылыч (К.да — камчы) белән сукты. Мөриднең башы ярылды, каннары акты. Шәех янына барды, Аллайар түрәнең эшләгәненнән зарланды. Шуннан шәйх Хәбибулла әйтте: «Сабыр итегез, мин аны сезнең кебек итәрмен», — дип, кулларын догага күтәрде.

Әйтте: «Йаребби, бу түрәне болар кебек гарип (мескен) күңелле әйләгел (ит), дөнья вә ахирәт морадыны биргел», — дип дога итте. Авызыннан чыкмастан борын, Аллаһ Тәгалә догасын кабул итте: шул сәгать Аллайарның күңеленә гауга төште, үзенең яман нәфесләрен исенә төшереп елады. Әүвәл телен ачып әйткән бәетләре будыр.

### БӘЕТ

Бәнем башымга хуш сәүда дөшебдер,
Күңел базарына гауга дөшебдер.
Дидем: «Әй тән, нә сәүдадер, нә эшдер, —
Сипаһыңа (гаскәреңә) кылыч берлә орышдыр (ор), —

1 Урта Азия халкы татарларны, гадәттә, нугай дип атый.

дип, шәех Хәбибулла хәзрәтенә елап килде. Ханәкәдә (гыйбадәт йортында, суфыйлар җыелган өйдә) тезне чүгеп утырды. Әйтте: «Йә шәех, рөхсәт булырмы мәдрәсәңә кереп, тәгълим (гыйлем) алсак?» — диде. Шәех, мөрәҗәгать итеп, шелтәләп әйтте: «Синдәй түрәләрнең урыны моның кебек урын түгелдер, бу — гарибләр мәкамыдыр (мескеннәр урыны)», — диде. Бу сүзне ишеткәч, Аллайар зар-зар елады. Аннан соң шәех әйтте: «Мин сине мөридлеккә кабул итәрмен, ике төрле шарт белән, — диде. Әүвәл — будыр: Бохарада никадәр өйләр булса, барчасына теләнчелек итеп йөрерсең, — диде. Икенче — итчегә барып, «Миңа бер куйның башын, дүрт аягын вә тизәкле карынын бер юлы алып килерсең», — диде. Аллайар кабул итте.

Әйтәләр ки, Аллайар түрәнең өч хатыны, ике кызы, бер улы бар иде. Кызының берсе Әминә исемле иде. Икенчесе Хәлимә иде. Улының исеме Мөхәммәдсадыйк иде. Болар Аллайар түрәнең теләнчелек кыйлганын күргәч әйттеләр: «Атабыз мәҗнүн булган (акылдан шашкандыр)», — диделәр.

Кыскасы, Аллайар итчегә барды, шәех әйткән нәрсәләрне алды. Бер кулына куйның башын тотты, бер кулга дүрт аягын тотты, тизәкле карынын башына чалма итеп чорнады. Тизәге сакалы буенча ага иде. Бохара халкы моны күреп таң калдылар: «Аллайар түрә тилергән», — диделәр. Кайберәүләр әйттеләр: «Зикер кылып, мәкамын тапты», — дип.

Кыскасы, шәех хезмәтендә унике ел калды. Кәшуфате мәкамат (суфыйчылыкта югары дәрәҗә; зирәклек) урыннарына иреште. Дүрт китап язды. Әүвәл «Мәсләкел-мөттәкыйн» (Бәхәссез караш), икенче — «Мөрадел-гарифин» (Акыл ияләренең морады), өченче — «Михрабел-мотыйгыйн» (Күндәмнәрнең михрабы), дүртенче — «Сөбател-гаҗизин» (Көчсезләрнең ныклыгы). Бу дүрт китапны язып, халыклар арасында кәрамәте (могъҗиза, дөреслеге) мәшһүр булды. Шәех Хәбибулланың могътәбәр (хөрмәткә лаек) фикердәшләреннән булды.

Әйтәләр: ошбу «Сөбател-гаҗизин» бу дүрт китап арасында гүзәлрәге вә мөшкелрәгедер (авыр, катлаулырагы). Чөнки төрле һәм чуар тел белән төзелгән. Шуның өчен бу Таҗеддин фәкыйрь, утенечләрне кабул итеп, әүвәл Аллаһ исеме белән шәрех кыла (аңлата) башлады.

Бисмилләһир-рахманир-рахим...

...Бу Таҗеддин, илаһым, бинәвадыр (мескендер, фәкыйрьдер),
Тәрәххем кыл (кызган), илаһым, бинәвадыр (моңлыдыр).

Хозур әйладе кальбә гяһгяһи (Күңелгә иминлек килде кайвакыт),
Гыйнаять әйлагел, фазлы иляһи (Ярдәм иткел, бөек иляһым).

«Сөбател-гаҗизин» — бер бәдигьдер (гүзәл нәрсәдер),
Миләл[1] әрбабына гайри хафидыр
(Милләт остазына тиң рухлыдыр).

Тарикатьдә улан һәрбер гакыйдә
(Суфыйчылык юнәлешендә булган һәр ышаныч),
Улыр назмыда бер миһре фәридә
(Тәртипкә китерүдә (иҗатта) булыр бер тиңдәшсез дус).
Хәлавәтдә биңзәр къанде Мисрә
(Татлылыкта Мисыр шикәредәй татлы),
Ки рухдыр йитәр та рузе хәшрә
(Рухы җитәр мәхшәр көненә кадәр).
Беләм дисәң бу фәндә гыйльме хали
Нәзардан кума бу назми, Аллали
(Игътибарыңнан ташлама бу Аллалы авторны...).

Бу назымдан Аллайарның морады (максаты):
Бәян әһле сөннәт игътикады
(Иман-ышануларны сөнниләргә бәян итү).

Бисмилләһир-рахманир-рахим. Сәна лил-халики (мактау бар итүче Аллаһка), (ул) гобрәи вә әфляк (җир һәм күкне) яратты. Катрәдән (тамчыдан) гәүһәре пакь, ягъни мактау һәм пакьләмәк шулкадәр Аллаһка булсын ки, күкләрне вә җирләрне яратты. Бу икесен әүвәл яратуга сәбәп ул иде: күкләрдә вә җирләрдә гыйбрәтләр күп. Күрмисеңме: күкләр өстебездә терәксез торадыр. Каулүһү тәгалә вә иләс-сәмаи кәйфә

1 С.-П.да бу сүз м.л.к. тартыклары белән бирелгән.



www.darul-kutub.com

руфигат вә каулүһү тәгалә собханәл-ләзи рәфәгас-сәмәвати бигайри гамәдә, — диде. Ягъни җир йөзендә төрле чәчәкләр яратты. Шуңа күрә адәм балалары, оешмаган хәлдән тиешле сурәткә килгәч тә, үзләрен белерлек булгач, күзләренә күрегән иң беренче нәрсә — җир-белән күк. Ул, аларны күреп, бүтән нәрсәләрдән дә гыйбрәт алу өчен.

*Гобра* монда җир йөзе мәгънәсендә, *әфляк* күкләр мәгънәсендәдер. Тамчы — мәни мәгънәсендә, ягъни аталар билендә үстереп, җитештереп, аналар карынында (аналыкта) урнаштырды, үстерде. Аннан гәүһәре пакь әйләде. Адәм угланнары тамчыда булган кисәкләрнең кушылуыдыр. Яки тамчы — Габдулла бине Габделмоталлабның шәһвәт (җенси дәрт) суыдыр. Гәүһәре пакь — Мөхәммәд галәйһиссәламдер. Ни төстә (рәвештә) булса да, галәмдә булган нәрсәләрне һәркемгә гыйбрәт өчен яратты. Халык сөйләменең «габраи» — җир өсте сүзенә катнашы «мин кабилин Зәйдун зарбун»[1] диерләр. Ныклап уйлау өчен әйтте.

Самавәт өвене (?) тотды мөгалләкъ,
Җиһанә хөкмене күрсәтде мотлак (чиксез).

Ягъни күк өен терәксез яратты. Бу терәксез итеп ратуы — халыкларга гыйбрәт өчендер. Вә шуннан гыйбрәтләр алып, Хак Тәгаләнең берлеген һәм барлыгын, куәтлелеген аннан карап белсеннәр өчен.

Кылыб габра мәдарин зәммәи (зәннәи?) хут,
Бәни Адәмгә андин кыйсем итәр кот.

Ягъни Аллаһ Тәгалә җирне балык өстендә яратты. Ул балык өстендә булган җирдән Аллаһ Тәгалә Адәм угланнарына ризыкны өләшеп бирер, кайберүләренә киң, кайберүләргә тар итеп...

...Әйтәләр ки: «Җирне күтәргән балык Нун исемледер». Ибне Габбас әйтте: «Хак Тәгалә бу җиде кат җирне

1 К.-да — «мин кабилин зарәба Зәйдун» (8 б.). Грамматик күренешләрне бу рәвештә аңлату, нигездә, гарәпләрнең атаклы филологы Зәмәхшәридән (1075—1144) килә. «Зарәба Зәйден Гомрән» (Зәйд Гомәргә сукты) җөмләсе Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәрендә дә (1391) бар (V баб).



www.darul-kutub.com

үгез өстендә кыйлды. Ул үгезнең исеме Яһүдә. Ул үгезне балык мыегына бастырып куйды. Ул балыкны дәрья эченә куйды. Ул дәрьяны караңгылык өстенә куйды. Ул караңгылыкны җил өстенә куйды». Кайберүләр әйттеләр: «Караңгылыкның астындадыр». Әмма югарыдагы риваять дөресрәктер ки, моннан гыйбрәт алып белегез: бу дөньяны җил тота икән. Җилнең кайчан бер җирдә туктап торуы булсын, шуның өчен газиз гомерләр җил кебек кичәр икән. Дөньяны ахырда җил хәрап итәр. Дөнья җил өстендә булса, аннан мәңгелек теләү дөрес түгелдер, уйла.

Пәдид (ачык) әйтде: Җиһан эчрә фәвасыйл (вакыт аралары),

Кылыр һәр фасла (фасылына) төрлек нәшаи (үсемлек) хасыйл.

Ягъни Аллаһ Тәгалә бу дөньяның үтүен җил кебек дүрт фасыл итеп яратты: әүвәл — кыш фасылы, икенче — яз фасылы, өченче — җәй фасылы, дүртенче — көз фасылы. Шулай итеп, яз көннәрендә үлгән җирдән үләннәр тергезеп чыгарыр. Бу дәлил адәм угланнарының каберләреннән кубып терелүләренә ишарәт. Җәй фасылында үләннәр, үсеп, камиллек белән торалар. Бу да ишарәттер адәм угланнарының фани дөньяда бераз гыйшгыйшрәт (кәеф-сафа) итүләренә. Вә көз фасылында баягы камил үләннәр чәчәкләреннән аерылып корый башларлар. Бу да ишарәттер адәм угланнарының, егетлеге тәмам булып, картлык дәверенә кереп, көзен корыган үләннәр кебек булуына. Кыш фасылында төзек дөнья бозылып, нәфис җимешләре түгелеп, кар явып, барлык хәйванат (хайваннар) өстенә мәшәкатьләр төшәр. Бу да — кыямәт көн бөтен мәхлукның (жан ияләренең) башына кайгы килеп, үз хәлләрендә булуларына ишарәттер. Әйттеләр: бу фани дөнья эчендәге нәрсәләр барчасы ахирәт («бетү») галәмәтенә ишарәтдер.

Гажәб сонг (тудырылган), күрең әһкяме тәкъдир (тәкъдир хөкеме).

Кылыр бер карасдин (? карашдин) галәм күзен сир (туйган).

Ягъни ул Аллаh Тәгаләнең гаҗәеп кодрәтләреннән безгә билгеле булучы будыр: үзенең хөкеме, тәкъдире белән барча дөнья халкын тук кылды, күзләрне — бер күмәч белән. Ул күмәч — кояш, ягъни ул кояш безнең күзебезгә күмәч кебек кечерәктер. Шулай булса да, барлык дөнья халкы, аның нурында тук булып, үзләренең хәрәкәт вә кәсепләренә йөриләр. Сату базарларына баралар һәм нурыннан Коръән вә дәрес укыйлар, биш вакыт намазның  вакытын беләләр... Шулай итеп, кояшның көнчыгыштан көнбатышка хәрәкәте барча адәм балаларының файдасы өчендер. «Кәшшаф»та (бирелдә Зәмәхшәринең «Коръән»гә тәфсире күздә тотыла булса кирәк) шулай дип әйтелеп килә. Ибне Габбас әйтә: «Бу кояшның олуглыгы бу дөнья кадәр. Кыш көннәрендә җиде кат күкнең өстендә йөрер. Җәй көннәрендә дүртенче кат күкнең өстендә йөрер». Сорау: «Кояш, бу дөнья микъдары булса, ничек безнең күзебезгә кечерәк күренер?» Җавап: «Ерак булганы өчен кечерәк күренер, чөнки күк белән җирнең арасы биш йөз еллык юл. Күкнең калынлыгы да биш йөз еллык юл, һәм күкләрнең арасы шулкадәрле үк юл. Чагыштыр: ничә йөз еллык юлдан кояш күзебезгә күренер. Бу — кодрәтләрнең иң гаҗәепләрдән саналыр. Әйтәләр ки: «Кояшның өч йөз алтмыш урыны бар. Һәр көндә бер урыннан чыгар, бер урынга керер. Вә айның егерме тугыз урыны бардыр, һәр көндә бер урыннан чыгар, бер урынга керер», — диярләр. Бу турыда кыйссалар күп. Тәфсир  китапларыннан да карый аласыз...

Ирадә кылса хәййа тәванә  
(Теләсә куркакны көчле итә),  
Кылыр бер ләхзадә белмәс(н)е дана  
(Бер мизгелдә наданны галим кылыр).

Ягъни Аллаhу Тәгалә, ни теләсә, шуңа Кодрәтледер... Аллаhу Тәгалә бер надан-белемсезне бер сулышта яки бер сәгатьтә галим, белем иясе итәр. Шуны ике юлда бәян итә.

Сафи туфрагын әйткәч җан илә җисем,  
Ничек әйладе данаи (укымышлы) һәр исем.

Ягъни күрмисеңме Аллаhу Тәгалә Адәмне туфрактан

www.darul-kutub.com

яратты, һичкемнән гыйлем алдыртмады. Шулай булса да, Хак Тәгалә аның күңеленә илһам бирде, һәрнәрсәнең исемен белдерде. Адәм галәйһиссәлам фәрештәләргә җитмеш ике төрле тел белән җавап бирде. Бу да аның гаҗәеп эшләреннән түгелме?! Наданны бер сулышта галим итте.

## Адәм галәйһиссәламнең яратылуы кыйссасы

«Кыйссаи Рабгузый»да[1] шулай килә:

Хәлас итсә (коткарса) берәүне раббел-әфляк (Аллаһ),
Калыр таг астыда — андан чыкар пакь.

Ягъни ул Аллаһ Тәгалә берәүне коткарырга теләсә, ул кеше бәла тавы астында калса да, Аллаһ Тәгалә ул колны һичбер зыян күрсәтмичә чыгарыр. Ул Кадыйр (кодрәтле) Аллаһ Тәгалә җирләр вә күкләрне яратучы, бәеттә аңлатканча.

Ничек кем тотды туфан дәшт, тагы (дала һәм тауны),
Вәләкин булмады һәүлә (юеш) Нух аягы.

Ягъни ничек күреп һәм ишетеп белмисең, хәзрәте Нух, туфан чыгып, һәрбер биек таулар өстендә кырык аршын су булды; Көнчыгыштан Көнбатышына кадәр җир йөзен су басты, барча кяферләр һәлак булды. Әмма Нух галәйһиссәлам сиксән кеше белән аякларына чык та тидермичә котылдылар. Шуның кебек Аллаһ Тәгалә, бер шәһәр халкына бәла китерсә, араларында бәрәүне коткарырга теләсә, шул Нух туфаныннан кебек бу бәндәне дә шул рәвешчә коткарыр. Вә туфан кыйссасы тәфсир китапларында бардыр. Аннан карагыз. Монда язсаң-озак булыр.

*Һәүлә* (һәүл?) чык суы мәгънәсендә. Кашкар халкы илә госман(лы) халкының арасында уртак лөгать.[2]

Хәлиулла (Ибраһим г.с.) өчен яндырдылар нар (ут),
Кадәм куймау (атламыйча) ушал ут булды гөлзар (чәчәклек).

---

1 «Кыйссаи Рабгузый» — «Кыйссасел-әнбия». Борһанеддин угылы Насреддин Рабгузыйның бу әсәре Алтын Урданың Харәзем төбәгендә 1310 елда төгәлләнгән. Бу китап татар дөньясында бик мәшһүр.

2 С.-П.да бу сүзгә аңлатма юк.

Ягъни әйтәләр: «Ибраһим галәйһиссәламне Нәмруд ләгыйнь утка атты. Шул Ибраһим галәйһиссәламне Нәмруд утка атканнан соң, Ибраһим галәйһиссәламнең аягы утка җитмәстән борын, ул ут эче барчасы гөл бакчасы булды. Ибраһим галәйһиссәлам уттан котылды».

Әйтәләр ки, ул ут кырык өч көн дүрт сәгать ярым янды. Җомга көн һәм гашурә көн (мөхәррәм аеның унынчы көне — бәйрәм көн) иде, Ибраһим галәйһиссәлам уттан чыкты...

## Ибраһим галәйһиссәламнең ни өчен утка атылуы кыйссасы

*(Кыйссаи кауме Гад).*

Якар Нәмруд үңенда нар-гөлхән (ут),
Хәлиленә идәр ул наре гөлшән[1].

Газаб йил гадиләрне кылды набуд,
Иде ул йил нәсиме табиге һуд.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең каһәре белән җил Гад каумен набуд әйләде (юкка чыгарды). Шул ук җил Һуд пәйгамбәр галәйһиссәлам кауменә йомшак хуш җил булды. Гад кауменә исә каһәр җиле булды.

Әйтәләр ки, Гад бер падишаһның исемедер. Кауме-кабиләсе күп иде. Буйлары өч йөз алтмыш карыш (текстта — карый) иде. Болар кебек җиһан йөзендә олуг кавем юк иде. Кайчан бу Гад кабиләсенең фисык-фөҗур (бозык) эшләре күбәйгәч, Аллаһ Тәгалә аларга Һуд пәйгамбәрне җибәрде. Алар Һудның сүзен кабул итмәделәр. Шуның өчен аларны җил белән һәлак иттеләр. Аның кыйссасы озындыр. «Кыйссасел-әнбия»дән кара. *Нәсим* монда йомшак мәгънәсендә.

Балык карынында бер сахибе кәрамәт (кәрамәт иясе),
Чәллә (кырык көн) утырды вә чыкты сәламәт.

Ягъни балык карынында бер кәрамәт иясе кырык көн торды, аннан сәламәт чыкты. Сәхибе кәрамәт монда

1 К.-да — гөлестан (10 б.) (чәчәклек).

Йуныс галәйһиссәламдер. Балык эчендә кырык көн торды, аннан Аллаһ Тәгалә балыкка әмер итте. Карыныннан чыгарып, Йуныс галәйһиссәламне дәрья якасына (диңгез ярына) ташлады, һичбер әгъзасына зыян тимәде.

## Йуныс галәйһиссәламнең ни өчен балык карынына керүе

«Кыйссасел-әнбия»дә шулай диелә: *Чәллә* мөхәффәф чәһл руздыр (Чәллә — кырык көн димәк; кичә һәм көндез). *Сахибе кәрамәт* мәгънәсе — өлешле кеше димәк.

Әгәр әмер итсә фарикыл-фәркъ (аеручы),
Килер бер ләхзадә герб өстендин шәркъ.

Ягъни Аллаһ Тәгалә берәүне китерергә боерса, таң атканчы китерерләр Көнчыгыштан Көнбатышка. Һичбер нигә ихтыяҗсыз китерерләр аны бер сулуда. Күрмисеңме: Бәлкыйс тәхетен Асаф бине Бәрхыя, күз йомып ачканчы, Сөләйман пәйгамбәр каршында куйды, һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламне, бер сәгатьтә җиде кат күкне гиздереп, гарше көрси (күк тәхете) өстеннән үтеп, Аллаһ Тәгалә белән туксан мең тугыз сүз сөйләп, кабат кайтканда, түшәгенең эсселеге һаман суынмаган иде әле. Аллаһ Тәгалә бәндәләренә бу кадәр куәт бирде, берәүне бер сулуда дөньяның бер почмагыннан икенче почмагына китетергә авыр түгелдер. *Фарикъ* — монда аеручы мәгънәсендә, ягъни кич белән көндезне аеручы Аллаһ Тәгалә. *Ләхза* — сулуда мәгънәсендә. *Гарб (гареб, мәгърив)* — көнбатыш мәгънәсендә. *Шәркъ (мәшрикъ)* — көнчыгыш мәгънәсендә. Югары бәетнең мисалына туры китереп:

Ничек кем дустыны солтане кәүнәйни
Йитерде сәгатидә каб каусәйни.

Ягъни гаҗәпләнерсеңме, күрмисеңме, дөнья вә ахирәт падишаһы Мөхәммәд галәйһиссәламне бер сәгатьтә, дүртенче кат күккә мендереп, сәдрәтелмөнтәһа (күктә үсүче мифик агач исеме) агачына ашырды. Җәбраил галәйһиссәлам ике ук атарлык микъдарга якынайтты. Болай якын итеп китерү Коръән белән ныгытылган

Аллаһ Тәгалә безне дә, бер сәгатьтә явызлыкларыбызны бетереп, яхшылыкка алыштырып, үзенә якын итсә — гаҗәп түгелдер. *Солтане кәүнәйн* — дөнья вә ахирәт, ике дөнья солтаны димәк. *Каб* — микъдар димәк. *Каусәйн* — ике җәя (ук) тоткасы димәк. Ике җәяне кереш урап, сыртларын бер берсенә үрсәң, каусәйни диләр.

Ягъни бик якын. Гарәпләр, берәүне күрсәләр, «дөнәүни каб каусәйни» диләр, ягъни «якын булдың миңа ике җәя тоткасы кадәр».

Әгәр һәркемгә бирсә гыйзз-у эмдад (хөрмәт һәм ярдәм),
Килер хезмәткә чын адәми зад.

Ягъни Аллаһ Тәгалә берәүне кадерле итәргә, җиңү бирергә теләсә, килер аңа хезмәт итәргә адәми вә пәриләр. Түбәндәге бәеттә әйтелгәнчә:

Сөләйман кем игүрде өнсү җендин,
Аның фәрманы ирде бәрнәкиндин.

Ягъни күрмисеңме: Сөләйман бине Дауд галәйһиссәлам хакында булганы кебек. Җыелдылар аңар хезмәт итәргә адәмиләр, пәриләр, кошлар, кортлар, җилләр вә болытлар, җир белән күк арасындагы вә дәрья төбендәге нәрсәләр — барчасы аңар хезмәт итәләр иде. Аның хезмәт иттерергә сәбәпче нәрсәсе — бер йөзек кашы иде. Боларны Сөләйман галәйһиссәламгә буйсындырыр өчен, йөзек кашында Хак Тәгаләнең олуг исеме язылган иде. Шул сәбәптән хайваннар барчасы аңа хезмәт итәләр иде...

## Сөләйман йөзеге кыйссасы

...Әйттеләр: ул йөзек алтыннан иде. Кайберәүләр әйттеләр: көмештән иде. Вә кайберәүләр әйттеләр: ләгыль (асыл; кыйммәтле) таштан иде. Кайберәүләр әйттеләр: ул йөзек балчыктан иде. Бу сүз дөрес саналыр. Балчыктан булуына сәбәп бу иде: гыйбрәт алып белсеннәр, бу җир белән күк арасындагы нәрсәләр барчасы Аллаһ өчен балчык бәясендә. Ул йөзекнең исеме «мәймүнә» иде. Әмма кайбер галимнәр әйттеләр: ул йөзектә язылган исем бу иде: «Күн фәякүн» (бул — бар да булыр!). Кайберәүләр әйттеләр: исем түгел, бер хикмәтле сүз язылган иде. Ул

сүз бу иде: «Әд-дөнйа сагатүн фәҗәгалһа тагатә» (Дөнья бер сәгатьлек, аны (Аллаһка) буйсынуда үткәрергә кирәк). Хәзер ул йөзек Сөләйман пәйгамбәрнең бармагында имеш, диләр. *Игүрде* (икүрде) — туплау мәгънәсендә.

«*Никин*» — «йөзек кашы» мәгънәсендә. Әйттеләр: ул Адәм пәйгамбәрнең йөзеге иде. Атадан-анадан угыл-кызга калып, Сөләйман пәйгамбәргә ирешә. Әйтерләр ки, кайчан кыямәт көне булса, ул йөзек Даббәтеләрз (бер коточкыч нәрсә; имеш ул мәхшәр көнендә җирдә күренәчәк) кулында булыр. Кыскасы, Сөләйман пәйгамбәргә дәүләтле вә кодрәтле булырга ул йөзек сәбәпче иде. Югыйсә, ул йөзек бер дирһәм (көмеш тәңкә) кадәр таш иде.

Гарзы кодрәт нәмалигъ әйладе фаш
Вә гәр нә ирде, — бер кадре дәрәм таш.

Ягъни Аллаһу Тәгалә үзенең кодрәтен белдерде. Сөләйманга дәүләт бирүе үзенең кодрәтен күрсәтү өчен иде.. Югыйсә, ул йөзек ни булыр иде?! Ул йөзек бит бер дирһәм кадәр генә таш иде. Дөньяның түбәнлеген һәм әһәмиятсезлеген белсеннәр өчен [шундый гына иде]. Аллаһу Тәгалә янында бу дөньяның кыйммәте бер дирһәм таш кадәр генә. Акыл иясенә бу сер түгелдер. Мәгълүм булды ки, җан ияләрен буйсындыруны йөзеккә бәйле итүе кучерелмә мәгънәдә, диләр... Чөнки эш-гамәлләрнең Аллаһ ризалыгыннан башка билгеләнмәве мәшһүрдер.

## Кыйссаи гасаи Муса

Кәлим[1] илкендәге котлуг гасаи (таяк),
Гяһ күфрүк иде, гяһ аждаһаи.

Ягъни күрмисеңме, Муса Кәлимулланың кулындагы изге таягы кайчак елгадан (яки диңгездән) кичү өчен күпер булды, ә кайчак дошманнар күзенә аждаһа елан булып күренә иде. Атадан, угылдан, кыздан калып, Шөгайиб ялавач (Шөгайб пәйгамбәр) кулына ирешә. Муса пәйгамбәр, Фиргавеннән качып, Мәдаин иленә барганда, анда Шөгайб ялавач кызы Сафураны Муса пәйгамбәргә никахландырды. Никахланган заманда Шөгайб бу таякны Муса пәйгамбәргә бүләк (итеп) бирде.

---

1 Калим, Кәлимулла — Муса пәйгамбәрнең атамаларыннан берсе.

Әйтәләр ки, ул таякта ун төрле гаҗәеп тансык эшләре бар иде. Әүвәлгесе бу: Муса галәйһиссәлламгә бер дошман очраса, адәм сурәтенә керен, ул дошман белән сугышыр иде. Икенчесе: караңгыда Муса галәйһиссәлам (алга таба — г-м) кырда калса, Мусага чыра (яктыртучы; шәм) булыр иде. Өченчесе: Муса г-м анда кое таnса, ул коеда чиләк, бау булмаса, ул таякны кое төбенә җибәрә иде. Ул таяк, озынаеп, кое төбенә җитә иде. Кое төбендәге башы, чиләк булып, су алып чыга иде. Аның белән тәһарәт ала иде. Дүртенче: Муса г-м, җимеш ашарга теләсә, ул таякны бер җиргә кадап куяр иде. Ул таяк бер олы җимешле агач була иде. Ул җимешләрдән туйганчы ашар иде. Бишенче: дәрьяда көймә була иде. Муса г-м, аңа утырып, дәрьядан чыгар иде. Алтынчы: ул таякның башы икегә аерылган иде. Бер башыннан сөт чыга иде, бер башыннан бал чыга иде. Муса г-м, теләсә, бал эчә иде, теләсә, сөт эчә иде. Җиденчесе: Муса г-м бер сәфәргә җәяү барып чыккан булса, бу таяк бер йөгерек ат була иде. Муса г-м аңар атланып йөри иде. Сигезенче: Муса г-мгә хуш ис (хушбуй) кирәк булса, аннан яхшы һәм тәмле хуш исләр чыгар иде. Тугызынчы: Муса г-м янына бер карак килсә, ул таяк, чакырып, Муса г-мгә әйтер вә сөйләшер иде: «Карак килде», — дип. Унынчы: дошманнар күзенә бер олы елан булып күренә иде. Әйтәләр ки, ул таякның озынлыгы ун аршын иде. Муса г-мнең буе да ун аршын иде. Муса г-м дөньядан киткәч, фәрештәләр, килеп, Бохара сахрасына күмеп куйдылар. Кыямәт көнендә Даббәтеләрз кулында булыр имеш. Әйттеләр: ул таяк әнбәгь[1] исемле иде вә кайберәүләр әйттеләр: гыйаса (гаса. 1847дә — габаса. — 19 б.) исемле иде. Кыскасы, ул таякта артык эш юк, бары тик Аллаһның кодрәте иде.

Гарзы кодрәт нәмалигъ ирде, әй дуст.
Вә гәр нә ирде кадде чуб (агач) пи пуст.

Ягъни, жыйнап әйткәндә, Аллаһның кодрәтен белдерү өчен генәдер. Югыйсә, ул таяк кабыгы купкан, адәм буе кадәр бер агач иде. Аннан артык эше юк иде ки, Аллаһ кодрәтен күрсәтеп, бәндәләр, күреп, гыйбрәт алсыннар өчен әйләде.

---

1 К.да — әнбига (12 б.).

Әгәр әмер әйләсә кәүнәен (ике дөнья) бер пай,
Кылыр бер пөстәнең (пәстәнең) почмагында җай.

Ягъни Аллаһ Тәгалә әмер әйләп теләсә, дөнья халкы белән ахирәт халкын барчасын туплап ,бер Әчтерхан чикләвегенең бер почмагында куяр, дөнья вә ахирәтне тар итмичә, чикләвек почмагын киң әйләп. «*Пөстә*» — фарсы «па»сының (фарсы телендәге п авазының) заммәсе (о, ө авазларын белдерүче билге) белән укыйлар. Гарәпчә «җәүз» дип әйтәләр. Фарсы телендә «чарымәгыз» (грек чикләвеге) диләр. Безнең төрки телебездә Әчтерхан чикләвеге, диләр. Аның дүрт төше була. Шуның өчен фарсыча чарымәгыз, диләр. Нәтиҗә: бу кадәрле олуг эш Аллаһ Тәгаләгә авыр түгелдер.

Диделәр: хәзрәте Рухеләминне,[1]
Канат йәйсә, тотар руйи зәминне (җир йөзен).

Ягъни риваятьтә шулай диелә: хәзрәте Җәбраил, канатын җәеп торса, барча җир йөзен каплар имеш, ягъни бу дөньяны каплап торыр иде.

Аның дик Җәбраил сәдрәи пәрваз,
Мөхәммәд йиңидә әйтер иде раз.

Ягъни шулкадәрле олуг булган Җәбраил, кайбер вакытта сәдрәтелмөнтәһа (мифик агач исеме. Имеш, ул күкнен җиденче катында үсә) агачыннан төшеп, пәйгамбәр г-мнең тун җиңеннән кереп, вәхи (изге.—1847 дә — дәхи.—20 б.) сүзләрене әйтә иде.

Әйтәләр ки, Җәбраил г-мнең биш йөз канаты бар. Бер-беренең арасы — биш йөз еллык юл, диләр. Җәбраил г-м вәхи китергән вакытта пәйгамбәребез Мөхәммәд г-мгә үз сурәтендә килми иде.

Күбрәк дәхиятелкәлби (?) сурәтендә килә иде. Гомерендә бер генә күрде үз сурәтендә, бүтән күрмәде. «Тәфсире Багави»дә әйтелә: көннәрдән бер көнне пәйгамбәр г-м әйтте: «Йа Җәбраил, безгә асыл сурәтеңне күрсәт», — диде. Җәбраил г-м әйтте: «Йа Мөхәммәд, такать тота

---

1 Рухеләмин — Җәбраил..

белмәссең», — диде. Пәйгамбәр г-м әйтте: «Күрмәк теләрмен», — диде. Җәбраил г-м әйтте: «Мәдинәдә Бакыйгы Гүрстанда (зиярәтында) син бер көн хазыйр бул, мин асыл Аллаһ Тәгалә яраткан сурәтемне күрсәтәм» — диде. Вәгъдә кылдылар. Пәйгамбәр Бакыйга Гүрстанга килде, Җәбраил г-мне асыл сурәтендә күрде; канаты белән күк-галәмгә тия иде. Пәйгамбәр г-м һушы китеп егылды. Бер заманнан һушы башына килеп торды. Җәбраил г-м, ул сурәттән күчеп, дәхиятелкәлби сурәтенә керде, диделәр.

Әгәр кыйлса берәүнең хаклыгын фаш,
Шәһадәт бирүче — гәһваридә яшь (бишектәге бала).

Ягъни Аллаһ Тәгалә бер бәндәсенең хаклыгын күрсәтергә теләсә, ул кешенең хаклыгы өчен гуаһлык (шаһитлык) бирер бишектәге яшь балалар да. Йосыф г-м хакында булганы кебек. Зөләйха хәзрәте Йосыфны зина белән яла ягуда өч җомгалык (бу очракта — «атналык») бала гуаһлык бирде. Моның хикәяте мәшһүрдер. Икенче тапкыр Гыйсә г-мне анасы Мәрьям тудырып кайтты. Кауме — кабиләсе Мәрьямгә әйттеләр: «...Йа Мәрьям, син гаҗәп эшне эшләдең, ягъни атасыз углан таптың», — диделәр. Мәрьям угланга ишарәт кылды (күрсәтте), ягъни: «Аннан сорагыз», — диде... Әйттеләр: «Ничек сөйләшик бишектәге углан белән?» Гыйса г-м бишектән башын күтәреп җавап бирде: «Мин сезгә илчемен, Аллаһ Тәгаләнең колымын. Аллаһ Тәгалә миңа бер китап бирмәкче», — дип, боларга җавап бирде. Бөтен халык таң калдылар. «*Гәһвар*» — «бишек» мәгънәсендә. Фарсы белән госмания халкының телләреннән...

Газиз итсә кайу колны ушал шаһ,
Әгәр чаһ астына төшсә, табар җаһ.

Ягъни Аллаһ Тәгалә бер бәндәсен, газизләп хөрмәтләсә, кое астында калса да, ул коеның астыннан юл табып чыгарыр. Йосыф г-м хакында булганы кебек.

Кардәшләре дошманлык белән тирән коега салсалар да, Аллаһ Тәгалә, аны хөрмәтләп, оҗмахтан (җәннәттән) хөллә-тун вә күлмәк китереп киерде, ялавач (пәйгамбәр)

www.darul-kutub.com

әйләде. Әйттеләр ки, Ибраһим г-мне Нәмруд[1] кяфер утка атканда, шул заман Аллаһ Тәгалә Ибраһим пәйгамбәргә, хөрмәтләп, бер күлмәк җибәрде, уттан саклау өчен. Ибраһим ялавач дөньядан киткәч, (ул) аның углы Исхак пәйгамбәргә калды. Аннан аның углы Ягъкуб пәйгамбәргә мирас булып калды. Аннан Йосыф пәйгамбәрне кардәшләре тар коега салганда, Җәбраил г-м, килеп, Йосыф иңенә куйды. Әйттеләр: ул күлмәкнең исеме ридаи газыймә (затлы өс киеме; кыйммәтле плащ) иде. Хәзер оҗмах эчендәдер. Вә... тагын бер вакыйга мәшһүрдер. Әбүлфәварисны бер һинди коега салды. Аллаһ Тәгалә аны да коедан юл биреп (күрсәтеп) чыгарды. Шуның өчен берәүгә бер бәла килсә, Аллаһ Тәгалә ул бәладән яки зәхмәттән шунын кебек коткарса, һич гаҗәп түгел. «*Чаһ*»— фарсы телендә «кое» мәгънәсендә. «*Җаһ*» — «дәүләт» вә «гыйззәт» мәгънәсендә.

Сөләйман хезмәтендә кылды пәрваз,
Әгәрчә саны юк шаһин вә шәһбаз.

Ягъни Сөләйман бине Давыдның хезмәтендә кошлар очар, ни әйтсә, аны кылырлар иде. Хәтта лачын вә карчыга аның хезмәтендә иде. Һәм аннан гайре (башка) хисапсыз кошлар аңар хезмәт итәләр иде. Әйттеләр: көн эсселегендә Сөләйман г-мнең башы өстендә канатлары белән күләгә итәләр иде. «*Шаһин*» дип «лачын» кошын әйтәләр. «*Шәһбаз*» исә «карчыга» мәгънәсенә туры килер.

Вәли бер моште поре һөдһөд иде пәйк,
Диде солтанга аре вә ләббәйк.

Ягъни андый олы кошлар хезмәт итәләр иде. Аларның арасында бер йодрык хәтле кечкенә кош — һөдһөд исемле — Сөләйман г-мгә илче иде. Күрмисеңме: олуглыгына карап, шаһларга якын булу кирәк түгел (шарт түгел), фәкать Аллаһның ярдәме кирәк. Әйттеләр: һөдһөд, Бәлкыйс[1] хатынның тәхетен күреп, Сөләйман г-мгә хәбәр бирде. Шуның өчен илче булды. Сөаль (сорау):

---

1 Нәмруд — Ибраһим г-мне утка ташлаган хөкемдар.

2 Балкыйс — Сөләйман никахында булган гүзәл хатын. Сәби шәһәренең мәликәсе (патшабикәсе).



www.darulkutub.com

«Сөләйман пәйгамбәр г-м кошлар арасыннан ни өчен һөдһөдне ихтыяр итте (сайлады)?» Җавап: барлык кошларның күркәмрәге вә гаделрәге иде вә суфыйрагы иде. Күзе гарше көрсине (күктәге тәхетне) күрер, оҗмах вә тәмугны күрер. Шулай итеп, боларны күргән — гаделрәк булып чыга. Шуның өчен башкалардан аны илчегә сайлады. Өченчесе шул: Аллаһ Тәгалә Сәмруг кошны яратты, (ул) олуг тәнле иде. Кошларда моның кебек олуг кошлар юктыр.

## Сәмруг кош бәяны

Әйттеләр ки, Аллаһ Тәгаләгә Сәмругны адәм кебек туфрактан яратты. Шул заман Сәмруг үзенең буй-сынын, килеш-килбәтен күреп әйтте: «Мин кошларның олуграгы. Кайчан Сөләйман пәйгамбәр дөньяга килсә, мин аңа илчегә лаекмын», — диеп тәкәбберлек кылды. Сөләйман пәйгамбәр, дөньяга килгәч, дәрәҗәсе булгач, мөнаҗәт әйләде (дога кылды): «Йарабби, кошлардан миңа кайсы илче булыр?» Җаваб килде ки, «кошлардан һөдһөд кошын ихтияр әйлә», — диде. Әйтәләр ки, Сәмруг кошларның падишаһы вә һөдһөд кошларның илчесе иде. Былбыл кошы Сәмругның хезмәтчесе иде. Әйтәләр ки, Сәмругның башы икедер: бер башы кош башы кебек вә бер башы адәм башы кебектер. Кош башы белән кошлар телендә сөйли вә адәм башы белән кешеләр белән кеше телендә сөйләшә иде. Әйтәләр ки, Сәмруг җефетсездер (парсыз; хатынсыз), кыямәт көнендә үлмәс, Каф тавында булыр. Әйттеләр: һөдһөд кошы Сәмругның тиреннән яратылды. «*Аре*» — кәлимәи иҗаб (зарури сүз); фарсы сүзе. «Әйе», «ләббәйк» (баш өсте) мәгънәсендә. «*Пәйк*» фарсы телендә «илче» мәгънәсендәдер.

Мәдәд кылса Ходай галәм арай,
Хәбиб итсә ишарәт — аерылыр ай.

Ягъни Аллаһ Тәгалә берәүне үзенә дуст булырга лаек әйләсә, үзенә якын вә сөекле итсә, ул дусты айга бармагы белән ишарәт итсә, — ярыр; һич тә аптырамагыз. Мөхәммәд г-м хакында булган кебек. Әйттеләр ки, Хәбиб бине Малик дигән бер кяфер падишаһы бар иде.

www.darul-kutub.com

Пәйгамбәргә килеп, могҗиза теләде. Әйтте: «Син хак пәйгамбәр булсаң, бу беткән айны ундүртенче көне булган кебек ит, тулып чыксын, күк уртасына җитсен. Аннан соң бармагың белән ишарәт кыл: ай икегә ярылсын; берсе итәгеңнән керен, куеныңнан чыксын, берсе куеныңнан керен, җиңнән чыксын». Һәм пәйгамбәр г-м алай итте ки, ул кяфер сораганча булды. Хәбиб бине Малик, бармак күтәреп, мөселман булды. Әйттеләр ки, Хәбиб Маликнең дуслары дүрт йөз кеше иде. Барчасы мөселман булдылар.

Кәлимин чәһрәсен кылмас өчен зәрд (сары),
Чыкарды ләхзадә Нил астыдин гәрд.

Ягъни Муса Кәлимулланың йөзен кауменә, сары кылып, оятка калдырмас өчен, фиргавеннән качып барганда, Нил тугаена килде. Муса кауме (кабиләсе) әйттеләр: «Йа рәсулуллаһ, артыбыздан дошман килә, алдыбызда Нил дәрьясы бар. Без бу дошманнан ничек котылабыз?» — диделәр. Муса г-м әйтте: «Курыкмагыз, Хода безнең белә(н) дер», — диде. Нил тугаена җиткәч, Муса г-м таягы белән Нил суына бәрде, Нил дәрьясы, икегә ярылып, юл бирде. Муса г-м кауме әйтте: «Йа рәсулуллаһ, бу диңгез юл булды. Әмма куркабыз ки, ничәмә еллар Нил моннан акты, баткак булыр, батып, дошман кулына дучар булырбыз», — диделәр. Хак Тәгалә кояшка әмер әйләде: «Бар, Нилгә кер, кызулыгың илә Нил төбен корыт», — диде. Әйттеләр ки, кояш, өч сәгатьтә Нил төбен корытып, кире урынына менде. Муса кауме сәламәт чыкты. Әйттеләр: күз йомып ачканчы, Нилне корытты. Шуның өчен назыйм (автор) ләхзадә (күз ачып йомганчы) диеп тә искә алды.

Кешенең рузисен (өлешен) гәр кылмаса кәм,
Йитәр һәр йирдә, михнәт булмаса[1] һәм.

Ягъни Аллаһ Тәгалә берәүнең ризыгын ким итмим дисә, ул бәндәсенә, ни җирдә булса да, ризыкны эшләмичә вә кәсеп итмичә бирер. ...Ягъни ни кадәр хәрәкәт һәм кәсеп әйләсәң дә, билгеләнгән ризыкны артык-ким итмәс, мал күп булса да. Әйттеләр ки, бәндәнең ризыгы, тәненә җан кермәстән борын, унбиш мең ел

1 С.-П.да — кылмаса (24 б.).

элек яратылды. Шулай булгач, кайда булсын ди, әзәл (мәңгелекнең башы) көнендә язылган ризыкны арттыру яки киметү?! Яратылышта китерелүгә пәйгамбәр г-м әйтте: «Әгәр сезнең тәвәккәллегез (тапшырылуыгыз; ышануыгыз) тәмам (тулы) булса, Аллаһ Тәгалә сезгә кошкортлар биргән кебек, ризыгыгызны михнәтсез бирер», — диде. Һәм мәгълүм булды ки, тәвәккәл кылу — бездән, ризык бирү — Аллаһтан...

Ничек кем хәзрәте Салих өчен фаш,
Балалыг төя (тивә-дөя) тугды хөкемдин таш.

Ягъни мәшһүр вә мәгърүф (билгеле): хәзрәте Салих ялавач (пәйгамбәр) таштан, дога кылып, балалы дөя чыгарды. Ул дөя, Салих пәйгамбәр дөньяга килгәнче, биш йөз ел элек яратылды. Шул биш йөз ел эчендә Аллаһ Тәгалә ул дөягә шул таш эчендә ризык биреп асрый иде. Белдегезме: Ходай Тәгалә михнәтсез ризыкны бирде!.. Галимнәр әйттеләр: ул дөянең озынлыгы илле аршын иде. Таудан ярылып чыккач балалады. Баласы үзе кадәр иде. Әйттеләр ки, сәмуд кауме[1] Салих пәйгамбәрне «ялганчы» диделәр һәм әйттеләр: «Син, раст (чыннан да) Тәңре ялавачы булсаң, безгә бу таштан дөя чыгар», — диделәр. Шул шарт белән таштан ун айдан соң дөя балалаган кебек балаласын», — диделәр. Салих г-м дога кылды, шулай булды да. Бу турыда күп кыйссалар бар. Тәфсир китапларына карагыз, анда язылган.

## Мәрьям һәм маидә кыйссалары

Йибәрде рузи (өлешен) Мәрьям мәләкдин,
Мәсихә (ягъни Гыйсә пәйгамбәргә) маидә төште фәләкдин.

Бу бәет ике хикаяткә ишарәттер. Берсе — маидә (тулы ризыклы табын, ашъяулык) кыйссасы, берсе — Мәрьям кыйссасы. Бәетнең мәгънәсе бу: җибәрде Аллаһ Тәгалә Мәрьямнең ризыгын фәрештәләр артыннан. Мәрьям аларны михнәтләнмичә ашый иде. Вә аның углы Гыйса пәйгамбәргә күктән маидә төште. Авырлыкларсыз кауме ашый иде. Әйттеләр ки, Мәрьямнең анасы Хинә исемле иде,

1 Сәмуд кауме — борынгы гарәп кабиләләреннән берсе.



www.darulkutub.com

тугрылыклы, салихә (изге) хатын иде. Хинә Гыймраннан йөкле булгач, алты ай узгач, Хинә нәзер әйтте: «Йарабби, әгәр бу корсагымдагы угланны сәламәт итсәң, юлыңда фида әйләрем», — диде. Әйттеләр ки, ул заманда гадәт шулай иде: угланнарны Бәйтелмөкаддәскә[1] илтеп бирәләр иде. Анда хезмәт итеп, галимнәрдән сабак өйрәнеп, гомерләрен анда кичерәләр иде.

Кыскасы, Хинә бала тудырды. Кыз иде. «Йарабби, бу кыз бала ич, Бәйтелмөкаддәстә ничек хезмәт итәр», — дип зар елады. Алай булса да, нәзерен үтәде (сүзенә тугры калды). Баланы Бәйтелмөкаддәскә илтте. Әйттеләр ки, Мәрьям Бәйтелмөкаддәс хезмәтенә барганда тугыз яшендә иде. Ул заманда Бәйтелмөкаддәс хезмәтендә торучы унтугыз галим иде. Алар һәрберсе тәүрият (китап) язып укый иделәр. Аларның иң галимрәге Зәкәрия пәйгамбәр иде. Аннан да олы галим юк иде. Әйттеләр ки, Зәкәрия пәйгамбәр Бәйтелмөкаддаскә илткәч, аңдагы игътикаф (ялгызлыкта; тынычлыкта) утыручылар Мәрьямне «мин тәрбия кылырмын» дип низагъ чыкты. Зәкәрия әйтте: «Мин лаекмын, чөнки Мәрьямнең анасы белән минем анам бертугандыр», — диде. Зәкәрия анасы Яһүдә исемле иде. Яһүдә белән Хинә икесе бертуган иделәр. Лявил (1916-да Равил.—176.) исемле кешенең кызлары иде. Башкалары әйтәләр иде: «Бу Мәрьямне без тәрбия кылырбыз, чөнки Мәрьям атасы Гыймран — безнең остазыбыз вә имамыбыз», — дип әйтәләр иде. Бу голямалар (галимнәр) арасында низагъ чыкканнан соң, шобага салмакчы булдылар. Шобагалары бу иде: «Тәүрият (турият?) яза торган каләмнәрне суга салаек, кайсыбызның каләме батмаса, аңа Мәрьямне тәрбия кылырга ирек бирик», — диделәр. Әйтәләр ки, каләмнәре тимердән иде. Бәгъзеләр әйтәләр камыштан иде дип. Болар, бу килешүгә килгәч, каләмнәрне алып килделәр. Бер агар елга бар иде. Каләмнәрне суга салгач, Зәкәрия каләме калыкты, батмады, башкаларның каләмнәре батты... Әйттеләр: «Йа Зәкәрия, бу Мәрьямне тәрбия кылырга син җаваплы бул», — дигәч, Зәкәрия кабул итте... Зәкәрия Мәрьям өчен Бәйтелмөкаддәс янында бер саумәга (хөҗрә; бүлмә) әзерләде, аны анда урнаштырды. Зәкәрия г-м Мәрьямгә азык китерә иде

1 Бәйтелмөкаддәс — Көдес (Иерусалим) шәһәрендәге гыйбадәт йорты.



www.darulkutub.com

вә сабак (дәрес) өйрәтә иде. Мәрьям янынннан чыкканда, саумәга ишеген баглап (бикләп) китә иде. Көннәрдән бер көн Зәкәрия сабак өйрәтергә кергәндә, Мәрьям янында төрле тәгамлар һәм җимешләр хазыйр (бар) иде. Зәкәрия әйтте: «Йа Мәрьям, бу җимешләрне кайдан хасыйл әйләдең (таптың)?..» Мәрьям әйтте: «Ходадан килә», — диде...

Әйтәләр ки, Мәрьям Бәйтелмөкаддәстә егерме өч ел торды. Аннан соң Гыйса г-м дөньяга килде. Бәйтелмөкаддәстән күчеп, Шам (Сүрия) җиренә килделәр. Анда Тәбийан[1] исемле тауда урнаштылар.

Әмма «*Маидә кыйссасы*» турында бәян итеlә: Харийун (Хәварийун) кауменә ачлык килде. Тугыз ел күктән яңгыр яумады, ашлык булмады. Көннәрдән бер көн Харийун җәмәгате (халкы) Гыйса г-м янына килделәр. Әйттеләр: «Йа Гыйса Рухуллаһ, безнең хәлебез үзеңә мәгълүмдер. Еллар авыр килде, ачлык булды. Синең Тәңреңнең куәте җитәр, безгә күктән маидә иңдергәй», — диделәр... Гыйса г-м әйтте: «Бәли (әйе), көче җитәр. Сез Аллаһны бер дип белеп, мине аның колы дип белегез, явызлыкларыгыздан кайтыгыз...». Болар кабул иттеләр. Соңра Гыйса г-м ике рәкәгать намаз кылды. Һәм бу доганы укыды: «...Аллаһуммә әнзил галәйна маидәтән минәс-сәмаи...»[2] (Раббыбыз, безгә күктән ризыклы ашъяулык иңдер)...

Шул чакта ике кара болыт күренде. Берсе — астан, берсе — өстән. Арасында бер олы кызыл сөфрә (ашъяулык) бар иде. Һәм бу Харийун кауме барчасы карап торалар иде. Ул сөфрә дә әкренлек белән иңде. Гыйса г-м янә дога укыды. ...Моннан соң Гыйса г-мгә әйттеләр: «Син бу ризыклардан беренче авыз ит», — диделәр. Гыйса г-м ике рәкәгать намаз кылды. Озак заманнан «бисмилләһи» дип, ашъяулыкны ачты. Ашъяулык эчендә бер каклаган балыкны күрделәр. Сөяге юк иде. Бер гаҗәеп яхшы пешкән балык иде. Ул балыкның башы очында тоз бар иде вә коерыгы янында серкә савыты бар иде. Серкәсе тулы иде. Һәм тагын биш күмәче бар иде. Бер күмәчнең өстендә сары май иде Дүртенчесенең өстендә ак май иде. Бишенчесенең өстендә каклаган ит бар ирде. Вә күмәчләр тирәсендә күп төрле җимешләр бар иде. Барча

1 К. да — Тибан (Тәйбан?) (17 б.).
2 Коръән, V сурә, 114 аять.



www.darul-kutub.com

Харийун кауме ашадылар. Аннан соң ул маидә күккә ашты (1847дә — агды,— 276.), гаиб (юк) булды.

Әйтәләр ки, Харийун кауменең бер галиме бар иде. Шәмгун Сафа[1] исемле иде. Гыйса г-мнән сорады: «Йа Гыйса Рухуллаһ, бу маидә эчендәге тәгам оҗмах тәгамымы йә гайре (башка) урыннанмы килде?» Гыйса г-м әйтте: «Оҗмах тәгаме түгел, Аллаһ Тәгалә үз кодрәте белән юктан пәйда кылды», — диде.

Кыскасы, бу Харийун кауме бераздан соң кяфер булдылар. Аллаһ Тәгалә сурәтләрен дуңгыз вә маймыл сурәтенә әвереләдерде...

Әзәлдә һәр кешене әйласә сәгыйд (бәхетле),
Хәлим углы дик итсә садыйкыл-вәгыйд (тугрылыклы хезмәтче).

Ягъни тәкъдирдә Аллаһ Тәгалә бер кешене изге, тугры һәм ышанычлы әйләсә, гаҗәп түгел ки, Ибраһим Хәлил угылы Исмәгыйль кебек изге, тугры, ышанычлы әйләр... Исмәгыйльнең садыйкыл-вәгыйд кыйссасы, вәгыйд бабында (өлешендә) зикер ителер.

Әгәр зәбех итсәләр (чалсалар), кайтармагай каш,
Күренмәс баш аның алдында бер маш (ясмык)...

Ягъни Исмәгыйль кеби, шул кадәр изге әйләп, Хода юлында корбан итеп бугазласалар да, һич каршылык күрсәтмичә, каш чытмас (җыермас), Хода хөкеменә риза булып, буен ияр. Гашыйк кешенең янында башның бәһасе бер ясмык орлыгы кадәр булган кебек. «*Маш*»*(ясмык)* — борчактан бераз кечерәк, каты бер орлыкның исеме. Харәзем вилаятендә күп була. Бохара фәкыйрьләренең күбесенең ашы — маш иде.

Кемә бирсә җәһаләт хамредин җам,
Биһишт (оҗмах) алдыга килсә, басмагай гам[2]

Ягъни Аллаһ Тәгалә бер бәндәсенә наданлык вә көферлек савытыннан бер җам (йотым; касә) эчерсә, ул бәндәсе, гәрчә оҗмахны күзе белән күрсә дә, игътибар итмәс, ягъни изге гамәл эшләмәс, бәлки аңар явыз эшләр

---

1 С.-П.да — Шәмгун Сәгар (27 б.)
2 С.-Пда — кам (28 б.). (аяк).

җиңел булып күренер. Аңа зәвык итәр (кызыгыр, өстен күрер). «*Җам*»— монда савыт мәгънәсендә[1]...

Йитәр рәхмәт суы күк кәвакибенә,
Йитешмәс катрәи гәмраһ ләбенә.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең рәхмәт суы күктәге йолдызларның вә җирдәге кошларның (1916 елгы басмада — кырмыскаларның — 19 б.) санынчадыр (1847 елгы басмада — сагышынчадыр.—28 б.). Алай булса да, Ходай Тәгалә берәүгә изгелек тәкъдирендә язмаса, аның иренenә бу кадәр рәхмәт суы җитми (ирешми) калыр.

Күрең: Әбү Талиб илә Әбу Ләһәбне[2],
Олуг дәрья ләбендә хөшек ләбне.

Ягъни күрмәссеңме Әбү Талиб белән Әбу Ләһәбне: пәйгамбәрләрнең кардәшләре иделәр. Ишекләре төбендә олуг дәрья акты, ягъни дәрья монда — пәйгамбәр г-мдер. Андый олуг дәрья янында да коры иренле калдылар, пәйгамбәрне пәйгамбәр димәделәр.

Аның шәфәгатеннән дөнья вә ахирәттә мәхрүм булдылар. Пәйгамбәр г-мне белмәделәр. «*Ләбендә*» — «дәрья якасы» димәк. «Ләбне» — «коры ирен» калмак, ягъни шәфәгатеннән мәхрүм булып калу.

Әгәрчә ут белә суда булыр фәркъ (аерма),
Чыкарды су мәканендин ничек бәркъ!?

Ягъни Ходай Тәгаләнең үзеннәндер һәр җан иясен, һәр кешене берләштерү, утны су итү, суны ут итү. Күрмәссеңме: хакыйкатьтә ут илә су икесе бер берсеннән бик аерылып торалар. Алай булса да, Аллаһ Тәгалә, һава йөзендәге кара болыттан яңгыр яуганда, арасыннан күк гөрләп, яшен яшьнәп, әйберләрне сугып яндырыр.

Әгәр чәндикә шәмгъ утдин булыр җәмгъ,
Кара судин кыйлыр күз нуры дик шәмгъ.

---

1 К.-да — «Җам», монда ихтыяҗ мәгънәсендә, «*Гам*» фарсыча «аяк атламак» мәгънәсендә...» (19 б.).

2 С.-Пда — «...бу Талиб илә бу Ләһәбне» (28 б.)



www.darulkutub.com

Ягъни гадәттә чыраг (лампа, фонар) шәм белән уттан була. Бу билгеле. Шуның кебек Аллаһ Тәгалә, теләсә, кара суны май кылып утка яндырыр.

Әйтәләр ки, Хак Тәгаләнең дүртенче кат күк өстендә бер фәрештәсе бар. Әрдаил[1] исемле. Аның ике канаты бар. Берсе — кардан, берсе — уттан. Ут карны эретмәс вә кар утны сүндермәс.

Кайу бер кодрәтен кыйлмак кирәк яд,
Ирер касыйре гокул (акылы зәгыйфь) адәми зад.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең ни кадәрле кодрәтен әйтеп торырга кирәк! Аның кадыйрлыгына (өстенлегенә, барысын да булдыру көченә) чик юк! Аңа гакылның аңлавы, төшенеп бетә алуы мөмкин түгел. Бәлки гакылың көчсез булып, хәйран булып юлда калырсың. Нәзым[2]:

Нә мохтаҗ, нә гаҗиз — бер ганидер (байдыр),
Җәһан фәрманы үзрә мөбтәнидер.

(Галәм кануннарына нигезләнгәндер).

Нәзар кыл, галәм кәүн-ү фәсадә
(Кара, галәм тууда һәм үлемдә),[3]
Мөнафигъ юкмы халкы хөнфәсадә...[4]
(Икейөзлелек юкмы коңгыздай (төрле-төрле) халыкта)
Габәс[5] халык әйламәз каййуму галәм[6]
(Ыгы-зыгылы (зиһенсез) халык белмәс мәңгелек галәмне (ягъни[7] Алланы),
Хәкиме кадийр[8] — мохтаре даим
(Зиһенле, акыл иясе — һәрчак ирекле).

---

1 С.-П.да — Рәдаил (Ридаил) (29 б.).

2 Алга таба килүче 8 бәет Таҗеддин Ялчыголның үзенеке булса кирәк. Бу шигырь юллары «Татар поэзиясе антологиясендә дә бирелгән /К.: Таткитнәшр., 1992 — Беренче китапта — оригинал (229 б.), икенчесендә — тәрҗемәсе (458 б.).

3 Антологиядә бу юл болай язылган һәм тәрҗемә ителгән: «Нәзар кыйл, галәм көн фәсадә» («Бозыклыкта көн күрүче галәмгә күз сал»). Гомумән, антологиядәге текст белән бирелгән текст арасында һәм укылышта, һәм тәрҗемәдә үзгәлекләр шактый.

4 С.-Пда — хөснифадә (29 б.).

5 Антологиядә (I китап) — гобүс (229 б.).

6 К.да — хәллакы галәм (20 б.).

7 Антологиядәге тәрҗемә: «чытык йөзле галәмне мәңгелек итмәс».

8 С.-Пда — хөкме кадир (29 б.).



www.darul-kutub.com

Деләрсәң фәһм хикмәтләр мөхалә[1]
(Хикмәтләрнең мәгънәсенә төшенергә теләсәң),
Мәһи табанә бак, гяһи һилалә[2]
(Мәһабәт «кояш»ка кара, кайчак — яңа туган айга).

Тәвакъкыйг вә һәм улынмаз бер кәмалә
(Өметтә ул һәм бер дә сорамый камиллекне),
Нәкаисдән[3] мөнәззәһ ләйәзалә
(Кимчелекләрдән арынган мәңгегә).[4]

Антологиядә бу юл болай язылган һәм тәрҗемә ителгән: «Нәзар кыйл, галәм көн фәсадә» («Бозыклыкта көн күрүче галәмгә күз сал»). Гомумән, антологиядәге текст белән биредәге текст арасында һәм укылышта, һәм тәрҗемәдә үзгәлекләр шактый.

Ки Таҗеддин сүзеңне әйла кыска,[5]
Ки кыскадан улыр мәтлубе хасла[6]
Мөвәххәде мостәдил-тәүхид эчендә
(Алланың бердәнберлеген дәлилләү-бер Аллага ышануда),
У(л), күрә (торып), калмасын тәкълид (иярү) эчендә.
Мокалләд улмакың гаять ирер бәд[7]
(Тәкълидче-иярүче булу — гаять начар эш),
Мөкалләдләр улыр — вәҗһе мөсәүвәд[8]
(Иярүчеләр булыр — кара йөзле! Ягъни ярдәмче эшне башкаручы).

* * *

Хәзрәте рәсүле Аллаһ г-м бәянында

...Доруд би гадәд һадийе дингә,
Рәсүле рәхмәт лил-галәмингә,

Ягъни сансыз салават (мактаулы догалар) пәйгамбәргә булсын; (ул) дөнья халкын тугры юлга күндерүче, үзе

1 К.да — «...фәһме хикмәт ля мөхалә» (29 б.).
2 Антологиядә — «Мөһами табанә бак ки, маһ-һилалә». С.-Пда — «...маһ-у һилалә».
3 Антологиядә — нәкаиздән.
4 Антологиядә — «Тел тидермәслек Ходадан, карышмый».
5 С.-П.да — «Ки, әй шәрех сүзеңне әйлә касыйр» (29 б.).
6 С.-П.да — мәтлубе хасыйл (29 б,).
7 Антологиядә — «Ки: тәкълид улмагын һәм фигальдер бәд».
8 Бу соңгы бәйт С.-Пда күзгә ташланмый (29 б.).

дә дөнья халкының пәйгамбәре, дөньяга рәхәт өчен яратылган пәйгамбәр...

Нә рәхмәтдер сәмавәт зәминә (күкләр хөкемдарына),
Нәзар кыл (кара), рәхмәте лил-галәминә.

Ходаның дусты мохтарел-корәйше,
Мөдам (һәрчак) өммәт өчен тәлх (ачы) ирде гыйше (тормышы).

Ягъни ул рәсүлнең сыйфаты: Ходаның дустыдыр, хәлаеклар (халык) арасыннан ихтыяр итеп (сайлап алып), ялгыз Мөхәммәдне дуст кыйлды. Ул Мөхәммәднең гомере(нең) күбрәге өммәте (милләте, диндәшләре) өчен булган.

Барча пәйгамбәрләр кыямәт көнендә «нәфси-нәфси» (үзем-үзем) диерләр. Тик Мөхәммәд ялгыз башы «өммәти» (өммәтем) дияр икән. Моннан беленә ки, кайгысының олугы — өммәт кайгысыдыр.

Әйттеләр ки, пәйгамбәргә бер көн хитаб (Аллаһтан мөрәҗәгать) килде: «Йа Мөхәммәд, ата-анаңны тергезеп мөселман итсәң иде; дөньяда алар гыйбадәт кылсыннар. Алар минем оҗмахыма керсеннәрме, яки өммәтләреңне кыямәт көнендә шәфәгать итүне (ярлыкауны) сайлыйсыңмы? Ягъни синең атаң-анаң терелеп мөселман булсыннар (дисәк), кыямәт көнендә өммәтләреңә шәфәгать итәргә рөхсәт булмас», — диде. Бу икенең берсен сайла», — дип вәхи (аваз) килде. Пәйгамбәр г-м ата-анасының терелүен сайламады. Өммәтләренә шәфәгать итүне сайлады. Бәет[1]:

Дин, шәригать рәваятен (карашларын) гали кылган Мостафа,
Көфер, золмәт ту(г)ларны (байракларын) йиргә салган Мостафа.

1 Биредә китерелгән дүрт бәетнең тәүге өчесе Рәбгузыйның «Кыйссасел-әнбия» китабының (1310) традицион багышлау өлешендә дә бар (Ташкент басмасы, беренче китап, 1990.—10 б.) Әмма ике әсәрдәге текстлар (берсендә — 6, икенчесендә — 4 бәет) арасында аерымлыклар да очрый. Мәсәлән, «Рисаләи Газизә»дәге икенче бәет Рабгузыйда болай башлана: «Кавмие арин күтәрмәдин».

«Кыйссасел-әнбия»дә өченче бәет бу рәвештә башлана: «Ул атасы-анасыны арттырыб өммәт өчен, Ялбарыб Хакдин шәфагать сатгун алган Мостафа». «Рисаләи Газизә» әсәрендәге бу мәдхия Рабгузый китабындагы юлларга өлешчә нәзыйрә рәвешендә дә язылган.



www.darul-kutub.com

Каумегә дин күтәрмәен[1] куккә акган Гыйса ул,
Өммәтенә булышубән (булышып) йирдә калган Мостафа.

Ул ата берлән анасындин кичеб өммәт өчен,
Ялварыб Хакдан шәфагать сатгун (сатып) алган Мостафа.

* * *

Имәс мәүҗүд аның дик гәүһәре пакь,
Дәлил улдыр ки, киде таҗе ләүләк.

Ягъни пәйгамбәребез кебек пакь гәүһәр юк барлык җаннар эчендә. Чөнки Хак Тәгалә хәзрәтенең бу галәмне яратуы, бар итүе аның гыйшкы өчендер.

Шул җәһәттән Аллаһ Тәгалә аңа бер мәдех (мактау) таҗын кидерде. Болай диде: «Ләүлакә лима хәләкъәтәл-әфлакә», ягъни «син булмасаң, мин күкләрне яратмас (бар итмәс) идем. Мәгәр синең гыйшкың өчен яраттым». Нәзым:

Рәхмәте Аллаһ Раббымыз, йаздане[2] пакь», —
Диер хәбибенә (яратканына), бу сүз(г)ә тот колак.
Улмаса иде гизлү (яшерен) гыйшкың дормагы[3] (булуы),
Күкләрә нитә (ничек) вирдем барлыгы.
Аның үзрә күкне дүшәдем биек,
Та беләсән (ничек беләсең) йәүчә (?йәүҗә) диб гыйшкы төзек.
Туфракы хар илтмешем, белгел, ки бән,
Та ки гыйшк дәүләтен фәһем әйлә (үзләштер) сән.
Ушал (шул) шаһиншаһы кем, шәмгы диндер,
Анын пәрванәсе (күбәләге) — Рухеләминдер (Җәбраилдер).

Ягъни ул Мөхәммәд г-м — падишаһлар падишаһыдыр, диннең чырагы (яктырткычы). Аны тәрбия итеп торучы — Җәбраил Әминдер. Адәмнең үзе генә бер вәсиләсез (бәйләнешсез, ярдәмсез) Хакка ирешүе, якынаюы мөмкин түгелдер, фәкать берсенең ярдәме булса гына. Вәсилә монда Хак җәнабенә (Аллаһка) илтүгә сәбәпче

1 С.-П.да — «каумега дин күтәрмәен...» (30 б.).
2 Йаздан — Ходай Тәгалә.
3 К.да — сормагы (20 б.)

булган вәсилә, диләр. Шулай итеп, әулияләрнең (изге затларның) вәсиләсе — әнбияләрдер (пәйгамбәрләр). Һәм гади кешеләрнең вәсиләсе — мөшаихлардыр (шәехләр). Иншаллаһ бабында зикер ителер. Нәзым:

Кабуле хезмәт фәхре Мәдинә,
Йитәр бу фазл (затлы) Җәбраил Әминә.
Диде мәгъбуд (Аллаһ) аның — атын «Мөхәммәд»,
Мәкаматигә (дәрәҗәсенә) һәргиз йитмәде хәд.

Ягъни пәрвәрдигәр (кодрәтле) Аллаһыбыз аны Мөхәммәд дип үгде. Мәгънәсе: үгелмеш — изге эшләре күп димәк, яки халык аны күп мактар димәк. Әйттеләр: пәйгамбәребезнең исеме «Коръән»дә — Мөхәммәд, «Инҗил»дә — Әхмәд, «Зәбур»да (яһүдиләрнең борынгы изге китабы) — Мадәх, «Тәурат»та — Әхи.

Әйттеләр ки, пәйгамбәрнең өч йөз алтмыш исеменең гүзәлрәге — Мөхәммәд. Шуның өчен Аллаһ Тәгалә ул исемнәрдән Мөхәммәд дигәнен сайлады. Кайберәүләр әйттеләр: пәйгамбәр г.-нең исеме туксан тугыздыр. Ничек булса да, шул исемнәр эченнән, үзенә якын итеп, Мөхәммәдне сайлады. Аның дәрәҗәсенә һичбер ялавачсәүче (пәйгамбәр) ирешмәде.

Әйтәләр ки, фазыйлә белән вәсилә дигән урын бар. Ул урында һичбер пәйгамбәр тормас, фәкать безнең пәйгамбәребез Мөхәммәднең урыныдыр. Шуның өчен азанда бу ике ләфз (гыйбарә, сүз) белән дога кылырлар...

Төшермәй йир йөзенә сәясене (күләгәсен),
Йитерде гарше өйүгә паясене.

Ягъни әйттеләр ки, пәйгамбәр г-мнең күләгәсе җир йөзенә һич төшмәде, аның эче-тышы нур иде. Нурның исә күләгәсе булмас. Аның мәртәбә-дәрәҗәсе вә могъҗиза булу гарше (күктәге) йортның иясе — Аллаһтандыр.

Әйтәләр ки, пәйгамбәр г-мнең заһир күренгән, күбрәк беленгән могъҗизасы ике иде. Берсе — күләгәсе һич җир йөзенә төшмәде. Икенче могъҗизасы бәеттәгечә бу иде:

Кадәм (аяк) баскан мәназил ирде пөр гатыр,
Сәхабел-әбйаз ирде башыга чадыр.

Ягъни ул пәйгамбәрнең мөбарәк кадәм-аяклары кайсы урынга басса, ул урыннан хуш ис килер иде. Һәм икенчесе — кая гына барса да, түбәсендә бер ак болыт бергә йөри иде. Мөбарәк әгъзаларының мөгъҗилары да күптер. Монда аларны искә алып тормыйбыз. Теләгән кешеләр тәфсиллән, озын итеп сөйләгән китаплардан карап укый алалар. Монда барчасын да искә алсаң, китап озын була, шуның өчен язып тормадык.

Җәмале нигъмәт мәтлубе кәвнәйн (ике дөнья),
Кәмалидә мөйәссәр кабе кавсәйн.

Ягъни пәйгамбәрнең матурлыгы вә күркәмлеге — нигъмәттер һәм бөтен халык аны теләр. Дөнья вә ахирәт халкы барчасы. Чөнки ул кәмал (җитешсезлеге) булмаган рәсүлдер. Бу хакта Аллаһ Тәгалә хәзрәте кабә кавсейн... диеп мактады вә аңар бу кадәр дәүләтне ихсан[1] (бүләк) итте.

## Даббәтеларз бәяны

Шәрафәт мондин үтмәс, сөннәт-ү фарз,
Йөрсә та хоруҗ Даббәтеләрз.

Ягъни пәйгамбәр г-м диненнән дөнья йөзендә артык дин булмас. Әгәр син моннан артык динне кыяматкә кадәр вә Даббәтеләрз чыкканчы эзләсәң дә, моннан артык (өстен) дин табылмас. Даббәтеләрз — бер мәхлук (җан иясе) исемедер. Ахырзаманда чыгар. Озынлыгы җиде кат күк өстендә һәм аягы җиде кат җирнең астында. Әйттеләр ки, Даббәтеләрз дигән хайванда дөньядагы хайваннарның һәммәсенең сурәте булыр. Әйтәләр ки, Гыйса г-м, күктән иңгәч, безнең пәйгамбәребезнең шәригате белән гамәл кылыр икән. Вә мәзһәбләрдән Имам Әгъзам Куфиның мәзһәбен сайлап алыр икән. Чөнки пәйгамбәребезнең шәригате - шәригатьләрнең ахырыдыр. Шуның өчен бу шәригать гамәлдән чыгарылмас.

Һәммә диндин булыбдыр дине балә (югары),
Гуаһы (дәлиле) хәзрәте важиб тәгалә.

---

1 С.-П.да — асан (32 б.).

Ягъни пәйгамбәребезнең дине барча пәйгамбәрләрнең диненнән югарырактыр. Бу сүземнең дөрес һәм раст булганына Аллаһ Тәгалә үзе дәлил вә шаһид булып тора.

Өммәтләрнең изге булуы — пәйгамбәрләр изге булуы беләндер.

Аның әүсафының (сыйфатларының) юк интиһасы,
Нәгу (мактау) йитмәс дисә васфын ходасы.

Ягъни пәйгамбәребезнең сыйфатларының интиһасы (чиге) юк вә аңа мәдех (мактау) җитмәс, мәгәр Аллаһ Тәгалә үзе җиткезер. «*Нәгү*» —- монда «мәдех» мәгънәсендә.

Ходаның рәхмәте булсын дәмадәм (һәрдаим)
Аның әүладига, әсхабигә һәм.

Ягъни сүзнең кыскасы будыр: Аллаһ рәхмәте ул рәсүл хәзрәтләренә сулаган сулу саен булсын, һәм дә аның Әүладларына (бала-чагаларына, нәсел-нәсәбенә) вә юлдашларына — барчасына рәхмәт әйләп һәм безгә дә шәфәгатьләрен насыйп әйләсен — «*Аллаһуммә әрзүкна шәфагатүһүм*».

«*Сәхабә*» дип юлдашны әйтәләр. Әмма шәригатьтә сәхабә ул: пәйгамбәрнең мәҗлесендә ...гакыйл вә балигъ, мөселман булу шартлары белән утырган зат. Әйтteләр ки, бу шартлар булган кеше пәйгамбәр янында өч ай торса, сәхабә дип әйтерләр. Әгәр аннан аз булса, гакыйл вә балигъ мөселман булса да, сәхабә дип аталмас...

## Сәбәбе тәэлифе китаб

*(Китапның язылу сәбәбе)*

Язылды фарсы теле берлә мәктүб[1]... Аллаяр Суфый бер фарсы китабы язган иде. Анда гыйлме гакаид (дингә ышану тәгълиматы) һәм форуг[2] (төп принциплар) бар иде, әмма ышану ысуллары турында түгел иде[3]. Алай булса да, ул фарсы китабы эчендә сүз мәгънәсен белгән кешеләрне Аллаһга тарту көче бар иде. Ул китапның исеме «Мәсләкелмөттәкыйн» (тугры юл; бәхәссез карашлар) иде.

1 Мәктүб — язма, хат. Биредә бу сүз «Сөбател-гаҗизин»нең язылуы хакында бара.

2 С.-П.да — форух (33 б.).

3 К.да — гакаиде осулдан чыкган иде (22 б.).

Аны кем күрделәр төрки йаранлар (дуслар),
Диделәр: гәр дога кылса ирәнләр (кешеләр, ирләр).

Ягъни ул фарсы телендә язылган китапның мәгънәсен белмәгәннәр, аңламаганнар булмасмы? «Олыларга дога кылдырып, ул фарсы китапны төрки телендә язсаң иде», — диделәр. Әйтәләр ки, галимнәр китап чыгарырга теләсәләр, яки бер изге урынга китәргә теләсәләр, изгеләрдән дога алып, остазларыннан рөхсәт алалар иде. Шуның өчен дә бәеттә әгәр дога кылсалар ирәнләр дип әйтелде.

Бөтелсә (язылса) төрки тел[1] берлә «Гакыйдә»[2] ,
Күңелләр булса андан арамидә (канәгать).

Ягъни ул фарсы телендә булган «Китабе гакаид»не төрки теленә күчереп, аннан файда алып, күңелләребез тыныч һәм рәхәт булса иде, диделәр.
Тәмәллек кылдылар чөн берничә йар:
Каләм тартай (тарт; яз), Ходай булсын мәдәдкяр (ярдәмче).

Ягъни берничә төрки мөридләре үтенде. Аларның үтенүе буенча каләмне алып язып карыйм дип яза башладым, Ходай Тәгалә миңа ярдәм бирүче булса иде.

Ирермән бәндәләрнең сәрнегуне,
Тулай (барлык) йар-у борадәрләр зәбуне.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең каршысында барча колларның гөнаһлырагы һәм түбәне, начар хәлдә булучы без фәкыйрь.

Вәләкин әйлайен (әйт) сүзләрне әҗмал,
Бәңа йукдыр мөфәссал (җентекле) кыйлгалы халь.

Ягъни, әмма ләкин кабул итсәм, бу китапта сүзләрне иң гүзәл рәвештә туплап язармын, чөнки язу ысулы — бәет вә шигырьдер.

---

1 С.-П.да — теле (34 б.).
2 «Гакыйдә» - иман, ышаныч китабы. Биредә Суфый Аллаяр язмасы күздә тотыла.



www.darul-kutub.com

Мәни (мин) бичарә, чөнки гаммидыр (надандыр) мән,
Грифтаре мәламәт дамидер мән.

Ягъни мин гади халыктан булган бер бичарамын, хасслардан (өстен катлам, аксөякләрдән) түгелмен. Адәмнәрнең шелтәләрендә калдым мин. Ягъни кайберәүләр мине салих (изге) дип изгелек хәлемне зикер итәләр, вә кайберәүләр явызлыгым (начарлыгым) турында әйтәләр. Әгәр мин хасслардан булсам, явызлыгым турында сөйләмәсләр иде. Назыйм (автор; шигырь язучы) үзен хур күреп әйтә.

Әгәр чәндикә булсам мәгъзе юк пуст,
Ишарәт кылдылар чөн берничә дуст.

Ягъни әгәр чәндикә (шулай; шундый) мин төше юк чикләвек булсам да, ягъни гыйлемдән коры булсам да, берничә үземә йар-юлдаш булган олуглар ишарәт иттеләр: «Йа Аллайар, ул төрки мөридләрнең үтенечләрен кабул әйлә вә алар теләгәнчә фарсы китабын төрки телендә яз», диделәр.

Аларның сүзләрен бозмый мәни зар,
Сәвад итдем (яздым) ничә мәнзумә начар (ирексездән).

Ягъни ул олугларның сүзләрен бозарга мин мескеннең хәлемнән килмәде. Шулай, заруриять белән аларның сүзләрен сылтау итеп алып, ак кәгазьне кара әйләдем, ягъни алар боеруы буенча шигъри әсәрне фарсы теленнән төрки теленә бәетләр илә (строфалап) яздым.

Гакыйдә сүзләрдин кыйлдым исбат,
Аңа куйдым «Сөбател-гаҗизин» ат.

Ул төрки телендә булган китапта Аллаһның берлеген һәм ышанылган мәсьәләләрне исбат иттем. Ул китапка «Сөбател-гаҗизин» дигән исем куйдым.

Үзем дик хәстәләр улгаймы диб шад,
Нәсаихдан һәм әндәк әйладем йад.

Ягъни ул китапны төрки телендә аның өчен яздым: үзем кеби хәстә күңелләләр аны укып шатлансыннар

өчен. Һәм дә нәсыйхәт сүзләреннән азрак яздым, укыганнар үгет-нәсыйхәт алсын өчен. Чөнки гакыл иясе аз нәсыйхәттән күп гыйбрәтләр алыр. Бер ахмакка ни кадәр олуг вәгазь китабын укысаң да, файда ала алмас.

Нәсыйхәт дыңламас деле сәхт мәхҗүб,
Күгәрмәс таш — ягъмур йагса һәм күб.

Ягъни бер нәсыйхәт сүзен ишетмәс, каты күңелле кешегә ни кадәр вәгазь китапларын укысаң да кабул итмәс. Таш өстенә яңгыр яуса да, ут-үлән үсмәгән кебек, бу ахмак та вәгазь-нәсыйхәттән файда ала алмас.

...Нәсыйхәт сүзләрен китапның кереш өлешендә куллану — сәнгатькәрнең (поэтиканың) мәшһүр бер кагыйдәсе.

## Асыл бәндәлек бәяны[1]

Нидер коллык — аның мөштакы булмак,
Үзедин фаный — Хакга бакый улмак.

Ягъни берәүдән сораса бәндәчелеген «ни, нәрсә?», җавап бу булыр: һәр кеше бәндәсе, үзен фани (вакытлы) белеп, Тәңре Тәгаләне бакый (мәңгелек) дип белү. Ягъни һәркем үзен фани дип белсә, Аллаһны ул таныды димәктер. Чөнки фани булганнар, дөнья матурлыгыннан, нәфес дәртеннән бизүчеләрдән булырлар. Чөнки, чыннан да, ул әйберләргә алдану — бакый нигъмәтләрдән коры калуга сәбәп булыр, дип әйтәләр.

Танымак Тәңрене — танмак һавадин,
Кәйн тормаг — фәгале нәрәвадин.

Ягъни бәндәчелек будыр: әүвәл Аллаһны тану һәм лаек булмаган сыйфатлардан Аллаһ Тәгаләне пакьләү, һәм дә нәфес теләкләреннән бизү (ваз кичү), шәригать боермаган эшләрдән ерак тору. *Танмак* — бизмәк мәгънәсендә, төрки сүзе. *Кәйн* — ерак булу, ераклашу мәгънәсендә, фарсы сүзе.

Буйсынмак — йөгермәк кол димешдә,
Казага разый улмак барча эшдә.

---

1 С.-П.да — «Фи бәяне мәгърифәте гобудият» (күндәмлек, бәндәчелек) (35 б.).

Ягъни бәндәчелек тагын будыр: Ходай Тәгаләнең әмеренә буйсыну. Аллаһ Тәгалә «эшен эшләгез!» дип боерса, аны йөгереп, иҗтиһад (тырышлык) итеп, аның теләгендә булу вә Ходай Тәгаләнең казаларына вә бәласенә разый булып сабыр иту. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Бер колым минем биргән бәлаләремә вә казаларыма сабыр әйләмәсә һәм бирелгән нигъмәтләремә шөкер итмәсә, шөбһәсез, минем бәндәм түгелдер. Җиремнән вә күгемнән чыгып, үзгә (башка) Тәңрене теләсен», — диде.

Өмед итмә ушал кодрәтле шаһдин,
Янардин хәүф итеб янмак гөнаһдин.

Һәм тагын бәндәчелек будыр — Аллаһның рәхмәтеннән өмет иту. Ни кадәр олуг гөнаһлы булсаң да, рәхмәтеннән өмет кисмә вә тәмуг утында янудан куркып, гөнаһлардан тыю, тыелу кирәк. Шулай итеп, бу бәет бәндәгә — хәүф белән риҗа (курку вә өметенеч, сорау) арасында булуга ишарәт итте.

Йакыйн белмәк җәмәгать игътикадын (ышанычын),
Кәйн салмак мохалиф иҗтиһадын
(«Каршы эш-гамәлләрне ташлау» мәгънәсендә).

Ягъни бәндәлек будыр: әһле сөннәт вә җәмәгать игътикадын (ышануын) кайгыртып игътибарда тоту. Алар (мөселманнар) нәрсәгә ышансалар, ул ышануда булырга кирәк. Безнең мәзһәбебезгә хилафлык (тискә-релек) күрсәтүчеләр, кире кагучылардан һәм шигый вә дәһриләрнең (динсезләр) ышануларыннан бизү кирәк. Әйттеләр ки, әһле сөннәт вә җәмәгать мәзһәбе дүрт мәшһүр мәзһәб. Аннан башкалары барчасы батыйл (дөрес булмаган) мәзһәбләрдер. Батыйл мәзһәбләр җитмеш икедер. Һәм назыйм... гакаидне белмәгән кешеләрне шелтәләп (тәнкыйтьләп) әйтте:

Гакаид белмәгән шайтан иләдер,
Әгәр мең ел гамәл диб кылса, — йилдер.

Ягъни гыйлме гакаид белмәгәннәр — шайтан халкыдыр. Ул гакаид белмәгән кешеләр күп еллар Хак Тәгаләгә коллык итсәләр дә, бөтен кылганнары җил кебек файдасыз һәм ахырлары — мәңге тәмуглы, кяферләр төркеменнән булырлар...

## Гыйлме гакаид бәяны

Оялмага мәгърифәтне үгрәнүрдин,
Тәнур җаең булыр — калсаң тәнурдин.

Ягъни гакыйл булган мөселман тәүхид (бер Аллаһка ышану) гыйлемен өйрәнүдән уфтанып, оялып тормас. Ни кадәр карый (Коръән укучы; карт) булса да, үзеннән кечкенә һәм олылардан өйрәнеп, гыйлемгә тартылыр. Чөнки оялып яки гарьләнеп, тәүхид гыйлемен белми калса, дөньядан кяфер булып китәр; соң чиктә урыны тәмуг пичләрендә булыр. Әүвәлге *«тәнур»* — пич мәгънәсендәге гарәп сүзе. Соңгы *«тәнур»* — төрки сүзе.

Оялмасдыр таләб әмрене алган,
Калыр яхшы уй алмакдин оялган.

Ягъни Тәңрене белергә теләгән кеше оялып һәм гарьләнеп торып өйрәнми калса, яхшы исемле булудан коры калыр. Яхшы исем будыр: дөньяда мөэмин мөселман дип аталу, ахирәттә исә хәбибе садыйк (сөекле дус). Болай итеп аталудан коры калса — дөньяда кяфер исемле, ахирәттә гаду (гадвийә) Аллаһның дошманы исеме белән аталыр...

Ходавандикә бердер, би шәк (бишик-шиксез) вәриб,
Рәва юкдыр аңа уртаг илә гайиб.

Ягъни Ходай бердер, шик вә шөбһәсез. Аның иптәше һәм уртагы юк. Аны гаепләүче дә юк. Мотлак (абсолют) заты белән бар булып торучы бер заттыр.

Шәрике юк Иляһи вахидемдер (бердер),
Бөтен дөнья бу хөкмә (хөкемгә) шаһидемдер.

Аның фәрманидин һич кем котылмас,
Тәванәдер (кодрәтледер) һәмишә, үзгә булмас.

Ягъни Аллаһ Тагалә фәрманласа (боерса), — ул булыр! Аллаһ Тәгалә Кадыйрдыр (көчледер), һич үзгәрмәс. Ягъни искерү, яңару вә картаю, көндез һәм кичә булмас — зате бакыясы (мәңгелек зат) вә сыйфаты бакыясы (мәңгелек сыйфатлары) белән бар һәм булыр.

Ирер ул барча галәмнең Ходасы,
Аның юк ибтидасы, интиһасы.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең әүвәле вә ахыры юк. Үзе барча галәм халкының Тәңресе һәм ризыкландыручы-туендыручысыдыр.

Ирер хазыйр, һәмишә юк мәкяны,
Аңа кылган имәс сәбәкат заманы.

Ягъни Аллаһ Тәгалә барлык халыкка хазыйр (катнашлыдыр) һәм аларның ни сөйләгәннәрен вә күңелдән кичергәннәрен белер. Ләкин хазыйр булса да, күзаллаган, күргән урын белән дә, заман белән дә түгелдер. Без берәүнең янында утырсак, алты тарафтан һәм өч заманның береннән тыш була алмыйбыз... Үзгәреп тору — кеше вә җан иясләренә хас нәрсә. Ходай Тәгалә исә андый түгел. Безнең кебек, барлыкка килеп, үзгәреп торган булса, Тәңрелеккә лаек түгелдер...

Замана җари дәгел, лямахал (шиксез),
Тәҗәддеддән мөнәззәһ, ляйәзал
(Үзгәрештән азат, мәңгелек).

Йимәк, эчмәк кеби анда нә мөмкин (юк),
Мәканә мөмтәнигъдер тәмәккен
(Урын биләү юктыр, — кодрәтле).

Үзе би шөбһәдер һәм би нәмүнә
(Үзе һич шиксез һәм өлгесез),
Рәва юкдыр аңа чөн вә чөнкә
(Чөнки аның тиңе юк).

Ягъни ул, шөбһәсез, Иляһыбыздыр. Аның кылган эшләренә һәм боерыкларына «Ни өчен моны эшләдең вә болай итеп эшлисең?» дип әйтүләргә лаек түгел. Чөнки һәр эшне бездән сорап, киңәшеп эшли торган түгел. *Нәмүнә* — охшашсыз мәгънәсендә.

Күңелгә кичсә, күзгә төшсә һәр шәй (әйбер),
Ирер андан мөнәззәһ халикы хәй.

Ягъни ул Аллаһ Тәгалә үзе хакимдер. Аның хөкемен үзгәртергә такать җитмәс һәм үзе дә хөкемен үзгәртмәс. Гакыл иясенең Аның затын белеп бетерергә гакылы җитмәс.

Фәрештәләр, нәбиләр йитмәделәр,
Буен сындылар вә фикер әйтмәделәр.

Ягъни Аллаһ Тәгаләгә фәрештәләр һәм пәйгамбәрләр фикерләрен җибәреп карадылар. Һәммәсенең дә фикерләре, хәйран булып, гаҗиз (көчсез) калдылар. Шуның өчен, бу фикерләреннән кире кайтып, Аллаһның әмеренә буйсындылар. Син дә Аллаһ Тәгаләнең затына фикер әйләмә, ул ни боерса, аны эшлә.

Вәли фикер Ходаның кодрәтигә,
Гаҗаиб эшләригә, сәнгатигә.

Ләкин шулай булса да, Аллаһ Тәгаләнең кодрәтләре турында фикер итү тыелмый.

Кодрәтләре вә гаҗаеп эшләре турында фикер йөртү — гыйбадәттер.

## Ходаның сыйфатлары бәяны[1]

Собутдер аның сигез сыйфаты,
Сыйфаты зати ирмәс нә гайре заты.

Ягъни Ходай Тәгаләнең затына сабит (хас; мөнәсәбәтле) булган сыйфатлар сигездер. Түбәндә искә алыначак. Ләкин ул сыйфатлары заты белән түгел һәм заттан башка да түгел. Бу вәгазьгә[2] күңелеңне бир. Монда бәхәсле нәрсәләр күп бар, күп җитезләрнең[3] аягы таеп хәрап булганнар иде.

Тәгалә шаэ нуһу голйа сыйфаты,
Нә гайн затидыр, нә гайре заты.

---

1 С.-П.да — «Ходаның собутия (асыл; дәлилле) сыйфатының баяны» (39 б.) К.да — «Аллаһ Тәгаләнең сигез сыйфатларының бәянында».

2 К.да — намаз (29 б.).

3 К.да — үткенләрнең (29 б.).

Хәйат, гыйлем, кодрәт һәм бәсар (күрү), сәмгь (ишетү).
Ирадә вә кәлам, тәквиндер, әй шәмгъ.

Ягъни сигез сыйфатының әүвәле — хәят, икенче — гыйлем, өченче — кодрәт, дүртенче — бәсар, бишенче — сәмгь, алтынчы — кәлам (сүз; сөйләм), җиденчесе — ирадә (теләк, омтылыш), сигезенчесе — тәквин (шәкелдер; юктан бар итү). Боларның барчасының мәгънәсе түбәндә искә алыныр.

Имам Әгъзам китабында риваяте.
Сигез нәкыл итде (бәян итте) затия сыйфаты:

Бәсар, сәмгь, хәйат, гыйлем, кодрәт,
Кәлам, фигыль, тәквин, ирадәт.

Шулай итеп, назыйм (язучы) сыйфатларын мәгънәләре белән бәян итә башлады:
Хәйат ул — кем терекдер, үзгә булмас,
Улыр һәр зи нәфәс (сулышта) һәргиз ул улмаз.

Ягъни хәятның мәгънәсе бу: Аллаһ Тәгалә һәрвакыт теректер (тере), һич тә аңа үлем булмас. Барча җан ияләре, үлеп, ахырда фани булырлар. Аллаһ исә тере калыр. Аллаһ Тәгаләнең хәй (яшәү) сыйфатын аңлатып әйтте:

Үзенең затыдин хәйдер ушал шаһ,
Вәләкин җисем илә җандин мөнәззәһ.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең тере булуы безнең күзаллауыбыз, уйлаганыбыз кебек җан белән түгел, тән белән дә түгел. Үзенчә тередер.

Кирәкмәсдер Ходага һич кай шәй (әйбер, нәрсә),
Ганидер (байдыр) барча галәмдин ушал хәй.

Ягъни Аллаһ Тәгаләгә җан, тән, ашау, эчү һәм моның кебек нәрсәләр кирәкми. Чөнки боларны Ул үзе бар итте. Шулай булгач, үзе бар иткән нәрсәгә ихтыяҗы юк! Һәм ул Аллаһ Тәгалә барча дөнья нәрсәләреннән пакь.

Имәс мохтаҗ һич эшкә Хак Тәгалә,
Йибәрмәгел күңлеңне, шәйб (ак чәчле, карт) — бала.

Ягъни Аллаһ Тәгалә һичбер нәрсәгә мохтаҗ түгел, чөнки бар әйберләрне үзе яратты (бар кылды). Шуның өчен күңлеңне югары һәм түбән җибәрмә, Аллаһ Тәгалә очраклы сыйфатларга мохтаҗ түгел. Аллаһ Тәгалә күктә вә (яки) җирдә дип әйтмә һәм күңлеңне җибәрмә. Болар бөтенесе көферлектер.

Әгәр монда йибәрерсең күңелене,
Салыр шайтан күңелгә үзгә юлны.

Әгәр күңелне югары һәм түбән җибәреп, явыз (начар) фикерләр уйласаң, шайтанләгыйн (каһәрле) сиңа биегрәк йар-юлдаш булып, ялган ышануларга ияртер. Пәйгамбәр юлыннан чыгарып, кяферләр төркеменнән итәр, газапларга дучар булырсын. Шуның өчен Аллаһның берлегенә ышанучыга, әһле сөннәт вә җәмәгать игътикадында (ышануында) булып, аны нык тотарга (үтәргә) кирәк.

Әмма сөнниләрнең ышану-тәгълиматы барчасы бу китапта бар.

Сыйфатының бередер — гыйлме йара,
Ирер дана (укымышлы) — гайб-әшкярә (ачык).

Ягъни Аллаһның сигез затия сыйфатының икенчесе — гыйлемлек. Әй юлдаш, белүе будыр: эчтәгесе һәм тыштагысы, күренә һәм күренми торганы — һәрбересе Аллаһ Тәгалә каршында бердер. Ягъни Аллаһ Тәгалә барлык яратылганны белер; ул нәрсә юктан бар булса да, бардан юк булса да. Һәм аларның күңелләрен вә сөякләрен белер. Үлеп, әгъзалары череп, таралып беткән тәннәрне һәм сөякләрне, адәмнәр күңелендә әйтелмәгән һәм әйтеләчәк сүзләрне белер.

Хәлаекдин кечекдер я олугдыр,
Булыбдыр һәр нә эш я булгулудыр.

Ягъни Аллаһ Тәгалә халыкның кечкенә һәм олугларын, һәр ни булганын үткән заманда белер, безнең кебек онытмас. Һәм дә киләчәк заманда ни булачагын белер. Һәм колларының башына нинди каза вә хөкемнәр

www.darul-kutub.com

булачагын белер. Хәтта ки чебеннең боты яки канаты сынса, аның сынганын белер. Аның канаты кайсы җиргә төшеп череде, кыямәт көн, аны онытмыйча, ул канатын чебенгә бирер тергезер. Моннан кыяс әйлә (чагыштыр) башка нәрсәләрне.

Күңелгә кичсә кайсы халь пишә,
Имәс пушидә (яшерен; сер) гыйлемдин һәмишә (һич тә).

Ягъни берәүнең күңеленә бер фикер төшсә, —изге яки явыз булсын — Ходай Тәгалә каршында ул фикер яшерен түгелдер. Аллаһ Тәгалә ул фикерне белер, ләкин карамел-катибәйнләр[1] белмәсләр. Әйттеләр ки, берәүнең күңеленнән көфер булган нәрсәләр (уйлар) үтсә, аның белән кяфер булмас, бәлки бу чын имандыр. «Фәтавийе Һиндия»дә шулай диелгән. һәм шулай итеп, йөз фикер килеп киткәндә, «Хәшәр» сурәсенең ахырын яки «Ихлас» сурәсен укыйлар.

Ул китап Көнчыгышта язылган һәм билгеле.
Торышдыр йә йөрешдер хәйр-шәрдин,
Нә кем тиксә аңа нәфгъ-зарардин.

Ягъни Аллаһ Тәгалә бәндәләренең кайсы җирдә торганнарын вә кайсы җиргә күчеп барганнарын белер. Бәндәләргә зарар һәм файда китергәнне белер... Язучы бу бәетләр белән фәлсәфәи мәзһәбләрне ялгыш һәм кимчелекле итте. Ягъни алар әйтерләр: Аллаһ Тәгалә галәме көллият (бөтен галәм, универсалдыр), аерым өлешләрне белмәс, диләр. Бу дөрес түгел һәм ялган мәзһәб.

Белер һәркемдә булса мәгърифәтдин,
Бере кодрәт ирер сигез сыйфатдин.

Ягъни һәр гакыйл, балигъ һәм камил кеше белер ки, Аллаһ Тәгаләне тануның берсе — кодрәттер. Ул кодрәт сигез сыйфатның өченче сыйфаты. Аллаһның кодрәт сыйфатының мәгънәсен тәфсилләп әйтте:

1 Кәрамел-катибәйн — кешенең изге һәм яман эш-гамәлләрен язучы ике фәрештә.

Нәфәслек[1] йа нәфәссез буд-на-буд (барлык вә юклык),
Нә кем ике җиһанда булса мәүҗүд (бар, яшәгән).

Ягъни җанлы вә җансыз, булган һәм булмаган нәрсәләр, ике җиһанда, ягъни дөнья вә ахирәттәге нәрсәләр — барчасы Аллаһ Тәгаләнең кодрәте һәм тәкъдирендәдер. Һәм бер мәхлуктта җан булуы һәм берсе җансыз булуы, берсенең бай һәм галим булуы, берсенең надан һәм фәкыйрь булуы, һәм ни нәрсә җиһанда күзгә күренсә — бөтенесе тәкъдирендә.

Зарардыр, нәфгъдер, хәйр-шәррдер,
Йокыйн белгел, каза берлә кадирдер.

Ягъни бәндәләрдә булган изгелек һәм явызлыктан, байлык һәм фәкыйрьлектән, саулык һәм сырхаулыктан, түбәнлек һәм зирәклектән, ирлектән һәм кызлыктан хәбәре бар. Болар барчасы Ходай Тәгаләнең казасы (билгеләве, әмере) һәм кодрәте белән ләүхел-мәхфуздә (язмыш, тәкъдир тактасында) язылган.

Халаекның җәмигы фигыль-кауле,
Имәс бер зәррә би тәкъдире мәүле.

Ягъни мәхлукларның эшләгән эшләре, сөйләгән сүзләре — ул сүзләр ялган булса да, дөрес булса да — барчасы Аллаһ Тәгаләнең тәкъдирендә. Алай да, ялганчылык — барча диннәрдә дә дошмандыр. Акыл һәм аң иясе ялган сүзне сөйләмәс. Тәкъдирдә «Бу кеше ялганчы булсын» дип язылган икән, бу кешене сайлап алу эшеннән мәхрүм итеп, Аллаһы Тәгалә тәкъдире белән теленә кирәкмәс сүзләр салыр, күңеленә төшерер. Аның ниятен Ходай әзәлдә (башлангычта, алдан) үк белгән иде. Әгәр ул кешенең нияте ялганчы булу, алдалау, яки урлау йә зина кылу булса, бу бәндә шулай булыр дип белеп, тәкъдирдә язды. Әгәр ул бәндәнең күңелендәге нияте Ходага гыйбадәт кылу, зикер-тәсбих әйтү, Коръән уку икән, Хак Тәгалә, аны да алдан белеп, Адәм пәйгамбәрне яратканчы, берничә мең ел элек тәкъдир итте.

1 Бу сүзне «нәфес» дип тә укырга мөмкин. Һәр икесенең дә җан, рух, сулыш мәгънәләре бар.

Ирадә әйлагәч (теләгәч) хәллагы галәм
Һәр эшне бул диде, булды ушал дәм (шул чакта ук).

Ягъни галәмне яратучы Аллаһ Тәгалә бер эшне бул дисә, шул заманда ук булыр. Корал һәм махсус җиһазларга мохтаҗ булмас. «Бул!» - диде - булды.

Нә итсә ирке бардыр, кодрәте бар,
Кулы берлә яратты димә, зинһар.

Ягъни Аллаһ Тәгалә бәндәләрне ни эшләтсә һәм ни хөкем әйләсә, ихтыярлыдыр (үзенең теләгендә), чөнки кодрәтле. Кодрәте дә безнең кебек кул һәм аяк белән түгелдер. Кул һәм аякка безнең кебек бәндәләр мохтаҗ, шуның өчен зинһар сак бул, Хак Тәгалә әйберләрне кулы белән яратты һәм эшләде дип әйтә күрмә. Ул мохтаҗ булмас.

Телеңне сакла мондаг кауле бәдтин (начар сүздән),
Мөнәzзәһдер Ходавәндәм җәсәддин.

Ягъни явыз сүзләрдән телеңне сакла. Явыз сүзләр күптер: Аллаһ Тәгаләнең кулы, аягы бар дип әйтү, Алла бабай дию, Аллаһның урыны күктә дип әйтү — болар барчасы кяферлек саналыр. Чөнки Аллаһ Тәгалә тәннән вә җаннан пакь. Әгәр Аллаһның кулы вә аягы булса, безнең кебек мохтаҗ булыр иде. Мохтаҗ булган нәрсә Тәңрелеккә лаек түгел.

Кәлам Хакъдә кем йәд әйладе йад,
Аның бер васфыдыр (сыйфаты), әй адәмизад.

Ягъни бер сорауга җавап. Берәү әйтсә, «Коръәндә «йәд» (гарәпчәдә «кул» мәгънәсендә) сүзе йад ителде (әйтелде) вә бер аятьтән Аллаһның кулы бар икәнлеге мәгълүм булды». Аңа җавап: «Әйе, Коръәндә «йәд» (кул) сүзе әйтелсә дә, чынлап, асылда ул «кодрәт» мәгънәсендәдер. Әгәр дисәләр «йәд» сүзен «кодрәт» мәгънәсендә йөргәнен кайдан белдегез? Җавабы бу: олы мөфәссирләр (шәрех-аңлатма бирүчеләр) мондый мәгънә бирделәр һәм шулай итеп аңлатканнар.

Әиммә (имамнар) белде Коръән мәгънәсен төз,
Күңелне куймагыл сән һәр кый йөз.

Ягъни үткән галимнәр Коръәннең мәгънәсен төзек беләләр иде һәм кыек вә ялган юлга китмәделәр. Алар «йәд» сүзен «кодрәт» мәгънәсендә дип аңлаттылар. Шулай булгач, син аларның юлыннан башка юлга күңел бирмә. Чөнки элек яшәгәннәрнең аңлатуы дөрестер...

Бәсар һәм сәмгъ аның васфы билә шәкк,
Бәсар мәгънәсе — күрмәк, сәмгъ — ишетмәк.

Ягъни Аллаһның ул сигез сыйфатының дүртенчесе-бәсар, бишенчесе - сәмгъ. Бәсарның мәгънәсе — күрү, сәмгъның мәгънәсе — ишетү. Ишетүе һәм күрүе безнең кебек колак вә күз белән түгел.

Ишетмәк, күрмәк бишәкк вәриб,
Ирер бәр дик һәмишә заһир гайб.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең ишетүе безнең кебек түгел, чөнки без ерактан ишетмибез, якын булса гына ишетербез, ул да бик акрын булмаса. Акрын сөйләгән сүзне дә ишетә алмыйбыз. Ходай Тәгалә андый түгел һәм күрүе безнең кебек тә түгел, чөнки без күзебез кайсы урынга җитә, шул кадәр генә күрә алабыз, аннан артык күрә алмыйбыз. Хәтта ерактагы нәрсәләрне күрсәк тә, тәгаен ни икәнен белә алмыйбыз. Ходай Тәгаләнең каршысында әшкарә вә гайб (күренә һәм күренми торган) нәрсәләр бар, ул аларның барысын да күрер вә ишетер, безнең кебек колак һәм күз белән түгел.

Колак күз бәндәгә хаҗәт ирер, бәс,
Хода һич кайсының мохтаҗы ирмәс.

Чөнки колак, күзгә бәндәләр мохтаҗ. Ходай Тәгалә аларга мохтаҗ түгел, чөнки аларны үзе бар итте. Шулай итеп, бар иткән — үзе барлыкка китергән нәрсәгә мохтаҗ булмас.



www.darul-kutub.com

## Ахирәттә Ходай Тәгаләнең дидарын (йөзен) күрү бәяны

Терелсәң ахирәтдә, әй хәридар,
Ходаем күрсәтер дустларга дидар.

Ягъни кыямәт көн, кабердән кубып, ожмахка кергәч, әй гакыл иясе, Ходаем үзенең дусларына йөзен күрсәтер. Ләкин күрсәтүе сурәт белән түгел һәм урын белән түгел, бәлки бер васыфсыз (сыйфатланмый торган) нурдыр. Әйтteләр ки, Аллаһ Тәгалә дидарын (йөзен) күрсәтү мөэминләрнең ихласына күрә. Кайберәүләргә тулган ай кебек күренер, кайберсенә ярты ай кебек күренер, вә бәгъзесенә яңа туган ай кебек, бәгъзесенә йолдыз нуры кебек күренер.

Бәка дарында җаиз ройате Аллаһ
(Мәңгелек йортта күрергә рөхсәт)
Улыр бәдре камәр (ай) кеби нәзар гяһ.
...Вәли күрмәкне би чөн вә ченан бел,
Җиһәтсез бел, мәсәлсез, бимәкян, бел.

Ягъни: ләкин күрүне бернигә дә охшамаган кебек бел. Күренүе бер нәрсәләргә дә охшаш булып күренмәс, шулай итеп ки, ничек күренмәк өчен сурәте кирәкмәс, бәлки күрүгә ышану кирәк.

Ушал кем белдерер бишәкклекне (шиксезлекне),
Белер ул яхшы күрсәтмәклекне.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең кыямәт көне үзен күрсәтүе моның өчен: үзе, шиксез, Тәңрелекне белдерер һәм бәндәләренә ни кадәр күрсәтүне үзе яхшы белер. Әйттеләр ки, Ходай Тәгалә дидары аерым кешеләргә күренеп торыр өч сәгать, кайберсенә өч көн күләмендә, кайберсенә өч җомга (атна) микъдары, кайберсенә өч ай кадәр, вә кайберсенә өч ел, кайберәүләргә өч йөз ел, кайберәүләргә өч мең ел микъдары. Һәм әйттеләр ки, Ходай Тәгаләнең дидар күрсәтүе үлем кучкарын бугазлаганнан соң. Һәм дә әйттеләр, Ходай Тәгаләнең дидарын күргәч, ожмах әһеле өч мең ел тәгам ашамаслар, ожмах шәрабларын эчмәсләр вә хур кызларын кочмаслар, Аллаһ Тәгаләнең гыйшкында булып ашамый-эчми торырлар. Өч мең ел

тәмам булганнан соң, хәзрәте пәйгамбәр г-мнең туе булыр, Мәрьям Ананы никахландырырлар һәм җирне күтәргән үгезне бугазларлар. Әйттеләр ки, ул туй биш йөз ел дәвам итәр. Аннан соң һәркем, оҗмахта үзенә хасланган (билгеләнгән) йортларында торып, оҗмах нигъмәтләрен ашый башлар. Бәет:

Күрер мөэмин бере чөн-ү чарадан (ирексездән),
Кичәр бу дәмдә (вакытта) зәүкы-мәсавадан.

Бу дәгъвада дәлилем — нассы аять (аять тексты),
Егерме бер сәхабидән[1] риваять.
Рәвафэз нәзар улмаз ул җәмалә
(Дәһри-диңсез карый алмас ул гүзәллеккә),
Гаҗәб хөсран (үкенеч) әһле игътизалә (диннән тайпылганнарга).

Бу турыда күп хәдисләр бар, барысын да язсак китап озын булыр.

Белер һәр адәминең булса исе (акылы),
Кәлам ирмеш сыйфатының бересе.

Ягъни һәр адәм белер ки, башында фәһеме (зиһене, акылы) булса, сигез затия сыйфатының алтынчы сыйфаты, — *кәлам.* Ягъни Аллаһ Тәгалә сөйләшүче, ләкин безнең кебек тел белән вә хәрф-ү аваз белән түгел.

Кәлам хадис ирмәсдер, кадим бел,
Аның әйган сүзе би кәм, би къил[2] (тавышсыз).

Ягъни Аллаһның кәламе (сөйләме; сүзе) хадис түгел, вакыт аралыгындагы түгел, ә аннан тышта, ягъни — мәңгелек. Ул Аллаһ Тәгалә сөйләсә, без сөйләгән кебек тел вә яңак белән түгел, бәлки сөйләме бер сыйфатланмый торган рәвештә. Бәндәләр аны сыйфатлый алмаслар. Затын сыйфатлый алмаулары кебек, моны да сыйфатлый алмаслар. Бер Аллаһка ышанучыга игътикад ышану бу

1 Сәхабә — Мөхәммәд пәйгамбәрне күргән, белгән кеше.
2 К.да — тел (30б.)

булыр: Аллаһ Тәгалә мөтәкәллимдер (сөйләшүче; әңгәмә алып баручыдыр) дип белү, артык әйттмичә.

Бөтелсә (язылса) йә укылса, алса ил йад, —
Болар хадис ирер, әй адәмизад...

Ягъни берәү Коръәнне язса йә укыса вә ятласа — болар барчасы мәхлукдыр, әй адәмиләр! Чөнки боларны мәхлук эшләр, шуның өчен мәхлук булды. Мәгълүм булды ки, гайре мәхлук (кеше тарафыннан бар ителмәгән) Коръән — күңелләрдә бер оешып килүче мәгънә, курку йә хәзз борчылу булса — болар гайре мәхлуктыр.

Ходаемның кәламен яхшы бел, баз,
Сүзең затига юк хәрфе аваз.

Ягъни Ходай Тәгаләнең кәламен яхшы бел ки, аның сүзенең авазы һәм хәрефе юк, ягъни безнең кебек аваз вә хәреф белән булмаган бер кәламдер. Бәндәләрнең аңлавы һәм төшенүе кимчелекле һәм тулы түгел. Аны сурәтләп безгә ни хаҗәт, бәлки көферлек булуы бик ихтимал.

Нә кем мәхлукыда бар исә, әй шаһ,
Ходавәндәм ирер андыйн мөнәззәһ.

Ягъни, мәхлукларның нинди сыйфаты булса, Ходай Тәгалә аннан пакь. Ошбу игътикадка (инануга) күңелне раст (дөрес) баглап тор.

...Сыйфатының берседер ирадә,
Моны белгән кеше йиткәй морадә.

Ягъни сигез сыйфатының җиденче сыйфаты ирадә. Моны белгән мөселманнар ахирәт морадларына (теләкләренә) җитәрләр. Ирадә мәгънәсе: ни теләсә, аны кылыр һич берәүдән курыкмыйча һәм киңәшмичә. Аллаһ Тәгалә гакылга вә сөйләмгә иядер. Гакылы бу: Ходай Тәгалә бөтен бар булган нәрсәләрне үзенең ихтыяры белән бар итәргә кадыйр (кодрәтле). Шулай итеп, үз ихтыяры белән бар иткән нәрсәләрен дә ни теләсә, аны эшли алуы көн кебек ачыктыр.

Кадалса бер тикән, йә төшсә бер кыл,
Ирадәсез имәс һич эш йакыйн бел.

Ягъни берәүнең аягына, кулына бер тигәнәк кадалса, йә башыннан, сакалыннан бер чәче төшсә — болар барчасы Ходай Тәгаләнең теләге буенча, шиксез. Ходай Тәгаләнең теләгеннән башка түгелдер.

Әгәр мури (кырмыска) куяр йир өстигә пай (аяк)
Вә гәр бер зәррәчә ком булса би җай (урынсыз).

Ягъни хәтта ки бер кырмыска җир йөзенә аягын куйса, яки бер бөртек чүлдәге комлар урыныннан кузгалса — болар барчасы Ходай Тәгаләнең теләге буенча. Ходай Тәгалә ул комлы урыныннан кузгалганын белеп торыр, кырмысканың кайсы җиргә басканын белеп торыр, аның эчендәге фикерне белер.

Болардин кечекдер йә зийадә (олы),
Имәсдер һич нәрсә би ирадә.

Ягъни болардан кечкенәрәк яки олы нәрсәләрнең хәлен белер, дөнья йөзендә нәрсә булса — барчасы Ходай Тәгаләнең ирадәте (теләге) буенча.

Сыйфатының берсен *тәквин,* диләр. Ягъни Аллаһ Тәгаләнең сигез сыйфатының берсе тәквиндер — халыкка ризык бирү һәм башка моның кебек эшләр — барчасы Аллаһтан. Тәквин мәгънәсе: нәрсәне юктан бар итү вә нәрсәләрне ярату — Аллаһтан. Әмма тәквин будыр: бар булган нәрсәләрне барчасын «яратылган», диләр.

Ки тәквин илә мөкәүвән улмады бер,
Бу сүзи (сүзне) күңелдә әйлә әзбәр (калдыр).

Ки тәквине мәфһүм кем әзщлидер, Мөкәүвән хадис улса, канда бердер...

Яратды ничек сезне вә безне,
Тәкый халкъ итде безнең фигълемезне.

Ягъни Ходай Тәгалә сезне һәм безне яратты һәм дә

безнең фигыльләребезне яратты. Әгәр ул фигылебез явыз булса, барчасы Аллаһ Тәгаләнең яратуыннан. Кыскасы, Аллаһ Тәгалә кяфернең көферлеген вә ихласлы бәндәнең ихласын үзе яратты. Бозыкның бозыклыгы вә мөнафикъның икейөзлелеге — барчасы Аллаһ Тәгаләнең әмере буенча вә башкаруында, аның карамагындадыр. Алай булса да, безгә ихтыяр (фигыль сайлау мөмкинлеген) бирде...

Әгәр чәндикә (шулай) куймаз иркемезгә,
Биребдер ихтыяри җөзимезгә[1].

Ләкин асылда Аллаһ Тәгалә безнең ихтыярыбызга карамас иде, чөнки ул — яратучы падишаһтыр. Ләкин алай булса да, безгә ихтыяры фигыль (эш-гамәлгә хәрәкәткә ихтыяр) бирде. Үзебез ниятләгән нәрсәләргә барырга һәм җитәргә безгә ике юл күрсәтте: берсе — оҗмах юлы, бере — тәмуг юлы. Җәбер һәм каһәрсез безнең ихтыярыбызда куйды.

Мөнасиб эш бирер йә на мөнасиб,
Аны кылмакга бәндә булды касиб.

Ягъни шәригатькә муафикъ эшләр булсын йә булмасын, аны бәндә үзе кәсеп итте, Хак Тәгалә фигыль ихтыяры бирүе буенча...

...Хода — кадыйр — өшенмәз кар эчендә,
Суыклык халкъ идәр (тудырыр) ул нар (ут) эчендә...
...Ушанча ихтыяры җөзиндин без,
Табар бәндә җәза күб кылса йә аз.

Аллаһ Тәгалә ихтыяр бирү сәбәпле, бәндәләр гамәлләр кылдылар. Изге вә явыз бәндәләргә ул гамәлләре буенча Аллаһ Тәгалә кыямәт көнендә җәза бирер. Күп гөнаһ булса, Аллаһ Тәгалә җәза әйләр, аз кылса, аз җәза булыр...

Ки Таҗеддин беләдер мәзһәбе хак,
Бөйлә (шулай) язмыш мәшарикъдә бу сабак.
Нә кем ризкы ки булса шәйб-у бала,
Яратыбдыр аны важиб Тәгалә.

---

1 Ихтияри җөзи — ихтыяр көче, хәрәкәт иреге..

Ягъни нинди ризык килер бәндәләргә югарыдан һәм түбәннән, кирәк хәләл булсын, кирәк хәрам булсын — барчасын Хак Тәгалә яратты. Ягъни берәү гомеренең барчасын хәрам ризык ашаса, һичшиксез, Аллаһның ризыгын ашады диn ышанырбыз. Ләкин Аллаһ Тәгалә хәрамдан ризыкны кәсеп итәргә боермаган иде. Алай булса да, Ходаның казасы вә хөкеме беләндер...

Хәрамдин вәли (ләкин) мәнгъ итде (тыйды) безне,
Биребдер ихтыяри җөзимезне.

Ләкин Аллаһ Тәгалә безне тыйды, хәрам нәрсәләрне алмагыз һәм ашамагыз, диде. Алай булса да, безгә ихтыяри фигыль бирде вә бу ихтыяр сәбәпле, хәрам нәрсәне кәсеп итеп, ризыгың хасыйл булса да, Аллаһ Тәгаләнең ризыгы, дибез. Шигырь:

Хәрам ризык диерләр әһле Хак, бәс,
Кире куймаз йийр (ашар) ризыкны һәр кәс (кеше).

Нә мөмкиндер йийсә ризыкны бер җан,
Йийар ризыкны йә бер гайре инсан.

Хода разый ирмәс гыйсйанымызга (гөнаһыбызга),
Ризасыдыр аның ихсанымызга.

Ягъни Аллаһ Тәгалә безнең гөнаһларыбызга разый түгел[1], аның ризасы безнең тагать вә гыйбадәтләребезгәдер...

...Килер гаятьдә (ахырда) бу мәгънә зоһурә (мәйданга),
Бу тасвир илә һәр шөгурә[2].
Таҗеддинның будыр белдеке кәлам,
Хакыйкатен белер Аллаһ Әгъләм.

Кеше разый дисә гыйсйан (фетнә; гөнаһ) кылырга,
Әиммә хөкмедер кяфер булырга.

Ягъни берәү: «Ходай Тәгалә безнең гөнаһларыбызга ризадыр» дисә, кяфер булыр. Имамнар диделәр: кеше

1 С-П.да — гөнаһымызга риза түгел (50 б.)
2 Шөгурә — аңга, зиһенгә. Бу очракта — шигырьгә.

www.darulkutub.com

иманын вә никахын яңартмыйча көфер булыр... Ходай Тәгалә безнең гөнаһларыбызга риза түгелдер. Алай булса да, аның тәкъдире вә хөкеме беләң. Аның өчен Ходай Тәгалә, безнең гөнаһларыбызга риза булса да, бәндәләренә золым итмәс...

Хода золым итмәде һич бәндәләргә,
Вәли төз юлны күрсәтте аларга.

Ягъни Аллаһ Тәгалә бәндәләргә золым итмәде. Һәм бер кяфернең көфердә булуы золымлык түгелдер. Аллаһ Тәгалә бәндәләргә тугры юлны күрсәтте, ихтыяри фигыльләр бирде вә пәйгамбәрләр, галимнәр җибәрде. Алар тугры юлны белмәгәнләргә күрсәттеләр. Шулай булгач, белмәү гозер булмады (акламый)...

Ушал халык ки, төз юлдан таярлар,
Алар үз җанларына золым итәрләр.

Ягъни бәндәләренә Аллаһ Тәгалә тугры юлны күрсәтте һәм алар, тугры юлдан чыгып, кире юлны ихтыяр иттеләр. Шулай итеп, үз җаннарына үзләре золымлык әйләделәр. Ходай Тәгалә золым итмәде. Инде үпкә калмады, бәлки үзләре, нәфесләренә ияреп, ялгыш юлны ихтыяр итеп, тугры юлны читкә куйдылар... Әйттеләр ки, бер адәмнең бозык юлда йөрү бәяны вә мисалы бу: бер мәҗнүн (тиле, акылдан язган) кебек. Ул, агач башына менеп, бер ботак очында утырып, ботакның төбен пычак (пычкы) беләң яки балта беләң кисүе кебек... Бу мәҗнүннең һәлак булуы үзеннәндер. Монда да шулайдыр...

...Газаб итсә бу галәм йә у(л) галәм,
Ирер ул гадел, әй фәрзәнде адәм (адәм углы).

Ягъни Аллаһ Тәгалә бу дөньяда бер бәндәсен газаплаcа — үзенең гаделлегеннән, адәм балаларына золымлыгыннан түгел. Чөнки үз милкенә үзенең ихтыяры бар.

Нәфәссез хәлкъ ирер йә зи нәфәсдер,
Аның үз мөлкедер (милкедер) һич золым имәсдер.

Ягъни дөньяда никадәр җансыз вә җанлы нәрсәләр бар, аларны бер хәлдән бер хәлгә әверелдерү, бозыкны суфый итү, яшь агачны коры итү, коры агачны яшь итү, динлене тәмугъ иясе итү — барчасы үзенең милке. Бәет:

Нә истихкакы вар габиднең (колның) нәгыймә,
Җәза важиб дәгел раббу кәримә.

Әгәр гафу әйләсә — үз фазлыдыр ул,
Будыр — сыйдкың вә ихласың, будыр — юл.
Аллаһның бер гөнаһкәр (гөнаһ иясе), бәндәнең гөнаһын гафу итеп, оҗмахка керүе үзенең рәхмәтендә. Һәм колның үтенечен кабул итмичә, тәмугка кертү — барысы да гаделлегеннән.

Бу сиңа дөрес юл һәм ихласыңны моңа багла. Бәет:

Ходадан фазлыдыр вирмәк сәвабы,
Ходадан гадлидер кылмак гыйкабы (җәзасы).
Бунын заддына (моңа каршы) вармы, әй диле нигарям («бәгырем»),
Булырсән шийгайи шом кауме бәдһәм.
Йитәрбез гамиләргә монча белсәк,
Тотыб мөхкәм (нык) буенсынсак, игелсәк (буйсынсак, иелсәк).

Ягъни безнең кебек наданнарга бу кадәр дин мәсьәләләреннән белсәк җитәрлек. Бу әйтелгән вә зикер ителгән хикмәтләрне нык тотсак һәм шул рәвешчә буйсынсак — җитәрдер. Кыскасы, гыйльме кәламдән ни кадәр олуг китаплар булса да, моннан артык мисаллар юктыр...

...Әйттеләр ки, иман өч төрле: берсенә имане тәхкыйк (нык иман), берсенә имане тәкълиди вә берсенә имане истидләли (дәлилле), диләр. <u>Имане тәхкыйк</u> бу: йөрәктә игътикад (ышану) тулы һәм бөтен, һич шик төшмәс. Бу иманны — пәйгамбәрләр вә фәрештәләр иманы, диләр. <u>Имане тәкълиди</u> бу: аталардан, аналардан, бабалардан ишетү юлы белән, дәлил теләмичә, Аллаһның берлеген һәм пәйгамбәрләрнең хаклыгын белер. <u>Имане истидләли</u>

бу: гыйлемле булып, яки артык зирәк һәм гакыллы булып, галәмнең төзелешеннән, тәртибеннән Ходаның барлыгын вә берлеген белер. Бу хакта бәхәсләр күп.

Җәмәгать, әһле сөннәт төзгән ирләр
Диделәр: торфә (гаҗәп) назекдер бу йирләр.

Ягъни ...әһле сөннәт вә җәмәгать юлын имамнар әйттеләр: бу юл бик нәзектер. Күп кенә белем ияләре, фәһем-аңлаулары киңәеп китеп, хак юлдан читләшеп, кяфер булдылар. Һәм дә артык тар фәһәмле булганнар, аңлаулары җитмичә, җәмәгать игътикадыннан мәхрүм булып динсез булдылар.

Һәм дә бу бәет гыйльме кәламне артык өйрәнү хәрам булганына ишарәт итә.

Бу галәмнең фарз гайн улмасы әзһар (күренә),
Көнәшдән һәр кешийә, маһә әнвәр
(Кояштан һәр кешегә, айга нурлар иңә).

Фәкыйрьнең фарзы гайн илә морады,
Бу фәндә әһле сөннәт игътикады...

Әгәр сән сакласаң рәхмәт юлыдин,
Гаду (дошман) килсә дә, нә килгәй кулыдин.

Ягъни, йарабби, әгәр син рәхмәтең белән шайтан вә дошманнан сакласаң, ул дошманның кулыннан һич эш килмәс.

Янә иманда айде әһле тәхкыйк,
Ходадандыр һидаять (туры юлга керү) берлә тәүфыйк.

Иманның бәхетендә булган чынын тикшерүче галимнәр әйттеләр: һидаять вә тәүфыйк бирү Ходаның үзеннәндер. Бу ике нәрсә уйлап чыгарылган түгел, Ходадан бирелә. Иман кәсби (табылган иман) будыр: тел белән әйтер вә күңел белән тәсдикъ итәр (раслар); аны бәндә кәсеп белән табар...

Олуг юлны куеб үлгүнчә, әй йар,
Кадәм (аяк) куйма, таяр йирләргә, әй йар.

Ягъни олуг юлны куйма. Олуг юл, кыскача тәүхидне, бер Аллаһка ышануны белү. Бу юлны куеп, аяк таяр урыннарга кермә, саклан вә ышануда күп бәхәс итмә. Әһле сөннәт вә җәмәгать шәехләре һәм дин галимнәре ни әйттеләр, ышанулары ни рәвешле булса, син дә аларның игътикадларында бул.

## Иманның бәяны

Ходадин һәр нә килсә, раст белдең,
Телең берлә янә икърар кылдың.

Ягъни иман ул — Ходай Тәгалә тарафыннан пәйгамбәрләргә нинди хөкем килде исә, аны дөрес санап, тел белән икърар кылу (әйтү). Иман асылы будыр.

Мөселманлыг юлыда, будыр иман,
Моны белмәс кеше, тыңла, пәшиман.

Мөселманнар будыр: иманны тел белән раслау вә күңел белән дөрескә санау. Моны белмәгән кешеләр, кыямәт көне үкенеп, кяферләр төркемендә тәмугда калырлар.

Якыйн белгел ки, иман булмагы кәм,
Ирер бер дик зиадә булмаган һәм.

Ягъни, шиксез бел, иман артмас һәм кимемәс, ягъни бер рәвешле торыр. Берәү иман артыр һәм кимер дип әйтсә, шул игътикад белән китсә дөньядан, бу кеше — кяфердер. Кыямәт көн кабереннән купканда, Ходай рәхмәтеннән нәүмиз булып, бик түбәндә, җәһәннәмдә булыр.

Бу сүздер әһле сөннәтнең тарикы,
Җәдал (бәхәс) итде бу сүздә һәр фәрикы (төркем).

Ягъни әһле сөннәт вә җәмәгатьнең игътикады вә юлы турында һәр гөруһ бәхәсләштеләр. Кайберәүләре әйттеләр: артыр һәм кимер дип. Кайберәүләре әйттеләр: артмас, әмма кими ала, диделәр. Һәм кайберәүләр: кимемәс тә, артмас та, диделәр. Бу сүз дөресрәк саналыр. Шигырь:

www.darul-kutub.com

Холус кальбилә (чын йөрәктән) иман инанмак,
Рәсүл мәнзилә икърар кылмак.
Бу әҗмалә инанмак — улды иман,
Кабул итмәз зиадә вә ноксан...

...Бу арада имамның вар җавабы,
Бу аятьдән морад анчак хиҗабы...
...Булыр әмма гамәл зиадә вә ноксан,
Табар яхшы гамәлдән әҗрү ихсан (игелекнең әҗерен).

Ягъни бары тик гамәлләр арта һәм кими ала. Изге гамәл кылган кешегә Аллаһ Тәгалә әҗер бирер, оҗмахта дәрәҗәсен арттырыр. Әмма гамәл кылмыйча, тик торган кешенең оҗмахта дәрәҗәсе кимер.

Гамәл әйлаң, вәләкин йимагайсыз,
Гамәлдин дахиле җәннәт (җәннәт эчендә) булырмыз.

Һәрвакыт гамәл кыл. Аның кабул ителүен Аллаһ Тәгаләгә тапшыр. Алай булса да, гамәл мине оҗмахка кертер, димә. Чөнки синең гыйбадәтең — Ходаның биргән нигъмәтенең шөкранәсе (рәхмәте) өчен, бәлки синең гыйбадәтең бирелгән нигъмәт бәрабәренә җитмәс. Ләкин Аллаһ Тәгалә сине оҗмахка кертсә, үз фазлы-рәхмәте беләндер, синең гыйбадәтең өчен генә түгел.

Аның әмерен дел (йөрәк) җаның белән ал,
Гамәл кыл, үзенең фазлына сал.

Ягъни Аллаһ Тәгалә боерган эшләрне җан вә күңел белән ал һәм гамәл кыл. Ихлас белән гамәлне кылганнан соң, кабул итүне үзенең рәхмәтенә тапшыр. Болай дип: «Йаребби мин зәгыйфь колың, боерылган гамәлне кылдым, рәхмәтең белән син кабул әйлә».

Насыйб итсә биһишт (оҗмах) үз фазлыдыр ул,
Бел, гамәл ки, аңа кылмай, гамәл кыл.

www.darul-kutub.com

Ягъни Хак Тәгалә, сиңа оҗмах дәүләтен бирсә, үзенең рәхмәтеннән бирә, синең гыйбадәтең өчен түгел. Шулай булгач, гамәлгә генә таянмыйча, гамәлдә һәрвакыт бул, чөнки  бәндә гамәлгә йөкләнелгәндер.

Гарыз (үтенеч) ул кем, гамәлгә булма мәгърур,
Гамәл кылгыл, гамәлгә бәндә мәэмур.

Кыскасы, син, гамәлгә алданып, «мин күп гыйбадәт кылдым» дип тәкәббер булма. Чөнки бәндә дөньяда бирелгән нигъмәт өчен гамәл кылыр.

## Гыйбадәтнең биш төрле булуы бәяны

Гыйбадәт биш төрле: берсе — гыйбадәте җәсәд (тән, гәүдә), икенчесе — гыйбадәте нәфәс, өченчесе — гыйбадәте рух, дүртенчесе — гыйбадәте кальб, бишенче — гыйбадәте сәр.

Гыйбадәте җәсәд — шәригать боерган нәрсәләрне әгъзалар белән кылу, намаз һәм рузә (ураза) кебек. Гыйбадәте нәфәс — кяфергә каршы булу, аңа охшамау. Гыйбадәте рух — дөнья мавыктыргычларын куеп, Аллаһтан башкалардан бизү. Гыйбадәте сәр — гыйбадәттән өлеш алып, хөрмәтләү нурыннан файда алу. Бер Аллаһка ышанучыларга, мөселманнарга бу биш төрле гыйбадәт хас булса да, чынлыкта аны вәлийе-Аллаһ (Аллага бирелгән; изге) дип әйтәбез.

Гамәл кылмакдин әһел истифадә
Диделәр: нуры имандыр зиадә.

Ягъни изгеләрнең, суфыйларның күпчелегенең, гамәл белән иман нуры артыр. Иман нуры артып, күңелгә ихлас урнашыр. Аннан соң шул ихласның нуры йөзенә чыгып, Рахман мәхәббәте урнашыр. Диделәр:

Вә гәр нә булмас иман зиадә вә кәм (күп һәм ким),
Гакыйдә будыр, әй фәрзәнде адәм[1] (адәм баласы).

Ягъни асыл иман артмас һәм кимемәс. Әһле сөннәт сүзләре: «Әй адәм балалары, иман нуры артуга, иманның файдасы гамәл белән булыр»

1 С.-П.да- гакыйдә булдырырмыз, фәрзанде адәм (56 б.)



www.darulkutub.com

Гамәлнең нәфгы (файдасы) иман беләдер,
Кайчан ялгыз гамәл кылган беләдер.

Ягъни гамәлнең файдасы Аллаһ Тәгаләгә иман китерү белән, бары тик гамәлдә генә түгел. Чөнки кяферләр дә гамәл кылыр, әмма бу иман булуга дәлил түгел, ә иман үзе гамәл булуга дәлил... Димәк, гамәлнең файдасы иман беләндер.

Нәгүзе биллаһи имансыз кешене,
Кабул итмәс, Ходаем, һич эшене.

Ягъни Аллаһ Тәгаләгә имансыз булудан сыенамын. Берәү имансыз булса, Ходаем һич эшен кабул итмәс, ни кадәр көч түксә дә — барчасы юкка чыгып, кяферләр төркемендә булыр.

Әгәрчә яхшылар Әгъмален (гамәлләрен) итсә,
Тәсаддык[1] йир йөзенең малын итсә.

Ягъни ул имансыз булган бәндә дөньяда изгеләр гамәлен эшләсә дә һәм мескеннәргә вә фәкыйрьләргә җир йөзенең малын сарыф итсә дә, кабул әйләмәс, бәлки юк булып, буш кала[2]. Әйттеләр ки, кяферләрнең дөньяда тәнне сыйхәтлеккә вә малын арттыруга файдасы бар, ахирәттә файдасы юк.

Риязәт[3] берлә булса иртә вә кич.
Ушал кем сыйдкъ юкдыр кылганы һич.

Ягъни иман дәүләтеннән мәхрүм булган кеше, кичә вә көндез мәшәкать чигеп, ураза тотып ач торса да, ахыры кабул булмыйча, кяферләр җөмләсеннән (рәтеннән; төркеменнән) булыр. Чөнки дөньяда сыйдкы вә ихласы юк иде, аның өчен гамәле кабул булмас. Риялык (күрсәтү өчен) белән гамәл кылучы да кяферләр җөмләсеннән, чөнки гыйбадәте Ходай өчен булмады.

Әйттеләр ки, фарыз гамәлләргә рия керсә, саваб булмас. Бу сүз дөрес түгел, аның өчен һәр гамәлгә керешкәнче, Хода өчен ниятләргә кирәк. Шулай итеп, Аллаһтан башканы Тәңре дип укыса[4] (гамәл кылса) сәвабы булмас.

---

1 С.-П.да — тәсаддәкъ (56 б.).
2 К.да — барчасы йилдер (37 б.).
3 Риязәт — теләкләрне тыеп тору, ашау-эчүдә чикләнү.
4 Бу сүзне үкде, ягъни мактады дип тә аңларга мөмкин.

www.darul-kutub.com

Булыр дүзәх (тәмуг) аның ахыр мәканы (урыны),
Котылмаз һәргиз (һич тә) андан җисем, җаны.

Ягъни иман дәүләтеннән мәхрүм булган кешеләр ни кадәр изге гамәлләр кылсалар да, ахыр аларның урыны — тәмугтыр. Котылмас ул тәмугтан тәне, җаны — барчасы газап эчендә калыр...

Әгәр иман гата кылса (бүләк итсә) кешегә,
Бирер әҗер аның хуб кылмышигә.

Ягъни Аллаһ Тәгалә бәндәсенә иман дәүләтен бирсә, аның изге гамәлләренә күп әҗерләр бирер һәм мөбарәк дидарын (карашын) юнәлтер.

Әгәр чәндикә кәбаир (гөнаһлар) кылса би хәдд,
Тәмугда калмас иманлы мөәббәд (мәңгегә).

Ягъни иман дәүләте булган кеше ни кадәр олуг гөнаһлар эшләсә дә, гөнаһы сәбәбле мәңге тәмугда калмас, тәмуг эчендә булса да, ахырда җәннәтле булыр.

## Мөнәҗәте Суфый Аллаяр

Иляһи, бәндәи бичарадыр мән,
Һәвайи нәфес илә әварәдер мән.

Ягъни, йарабби, мин бичара гөнаһ дәрьясына баттым, һәрчак гыйбадәтләрне калдырып, нәфес артыннан ияреп, җиһан мәсхәрәсенә калдым мин, димәк.

Кунамыз бер кич дөньяи һичә,
Нә эшләр кичәдер бездин бу кичә.

Ягъни безнең гомеребезнең барчасы бер кичә кебек. Бу бер кичә эчендә ни кадәр гөнаһ эшләр башыбыздан үтә. Әүвәлге кичә - үтә мәгънәсендә, икенчесе - көннең капма-каршысы, һәр икесе төрки сүзе.

Бу төндә тот бөтен иманымызны,
Сабах коткар (д)утындин җанымызны.

Ягъни бу кичәдә безнең иманыбызны камиллек белән саклап, кыямәт таңда тәмуг утларыннан, газапларыннан җаныбызны сакла, димәк. *Бу төндә* — бу кичә мәгънәсендә. *Бөтен* диюе- яртының каршысы, камил мәгънәсендә. *Сабах* — таң мәгънәсендәдер.

Күңел сандыкына[1] пөри бәһадур,
Үзең раст әйлагел, я кашифуз-зур.

Ягъни безнең күңел сандыгыбызны тулы итеп, кыйммәтле энҗене тутырып, үзең тугры юлга күндер.
Кыйммәтле энҗе ул - имандыр, ягъни үзең кальбебезгә иманны сеңдер, димәк. Раст мәгънәсе — сабит (нык) димәк.

Ушал дөр(р)е сандыкында шайтан бәдбәхт,
Тешебдер күб һәвахаһи (ярдәме) белән сәхт.

Ягъни бу энҗе (иман) саңдыгына шайтан явыз, нәфес теләкләрен кушып, хәйләләр корып, иман әһелен аздырырга теләр икән. Әйттеләр ки, шайтан ләгыйнь иман әһеле янында җиттмеш, кяфер әһеле янында икедер. Шайтан адәм балаларының кан тамырлары буенча йөрер. Шулай итеп, вакыт-вакыт мөэминнәргә ач булып тору киңәш итеlә. Чөнки ачлык шайтаннар юлын каплар.

Әгәр булсаң бәнем халемгә хами (яклаучы),
Тузар көл дик гадуларнын тәмами.

Ягъни, йарабби, әгәр син сакласаң минем хәлемне аларның явызлыгыннан, ул дошманнар барчасы, учак көле кебек тузып, минем канымнан качарлар. *Хами* монда саклау мәгънәсендәге гарәп сүзе.

Әгәр сән сакласаң рәхмәт юлыдин,
Гаду (дошман) кол кылса, ни килгәй кулыдин.

Ягъни, син рәхмәтең белән дошманнан сакласаң, ул дошман кулыннан һичбер эш килмәс.

Янә иманда әйтде әһле тәхкыйк,
Ходадиндыр һидаять берлә тәүфыйк.

---

1 К.да- ушалдыр касдына (38 б.).

Ягъни тикшерүчеләр иман бабында әйттеләр ки, һидаять (туры юлга керү) вә тәүфыйк бирү Ходай Тәгаләнең үзеннәндер. Бу икесен бәндәләр кәсеп итеп таба алмаслар. Болар Ходай Тәгаләнең — рәхмәтеннән. Болар иман кебек түгелдер, чөнки иман икърар ителер (әйтелер) вә күңел белән ныгытылып, бәндәләр аны кәсеп итәләр. Тәүфыйк исә кәсеп белән табылмый.

Ходаның фигъле ул мәхлук имәсдер,
Кеше мәхлук аны һәргиз димәсдер.

Ягъни Ходаның кылган эше мәхлук түгел һәм аңа мәхлук дип әйтелмәс. Тәүфыйк вә һидаять мәхлук була алмыйлар. Диделәр ки, күңел белән Аллаһ Тәгаләне тану вә тел белән икърар итү — бу икесе дә бәндә фигылеләдер.

Ничек кем бәндәне халкъ итде мәүле,
Тәкый мәхлук ирер фигъле вә кауле (сүзе).

Ягъни ничек Аллаһ Тәгалә бәндәләрне үзе яратты, ул бәндәләр эшләгән эшләр һәм сөйләгән сүзләр — барчасы мәхлуктыр. Шуңа итеп, икърар һәм тәсдыйк (раслау) һәм мәхлук булдылар.

...Ирер бер мәгънәдә иман вә ислам,
Моны белсә кирәк һәр хасс-у гам (аксөяк һәм гади халык).

Ягъни иман белән ислам икесе бер мәгънәдә. Әйттеләр ки, имансыз ислам булмас, исламсыз иман булмас. Шулай итеп, һәр икесе бер булды.

Дидем: иман вә ислам улды вахид (бер),
Бу хөкмә әһле сөннәт җөмлә шаһид[1]
(Бу карашка барлык мөселманнар да шаһит).

Булынмаз бере берсез тәсадикъ[2] (игелекле),
Бу мәгънә илә вәхдәт (берлек) улды садикъ (тугры).

1 С.-П.да — хәмаһид (59 б.).
2 С.-П.да — тәсалеф (59 б.).

Әиммә (имамнар) каулене бәрк ушлә, зинһар,
Җәдалнең (бәхәснең) нәфгы юк булса нәдер кяр.

Ягъни имамнар әйтүенчә,[1] аны нык тот, зинһар, һәм саклан, чөнки бәхәснең дөньяда вә ахирәттә файдасы булмас. Аның белән ни эшебез бар?! Бәхәсләшү гамәлләрне юар, бетерер. Әйтәләр бит, үткән өммәтләр (элек яшәгән кавемнәр) бәхәс күп булу сәбәпле һәлак булдылар. Кайберәүләр дуңгыз сурәтендә булдылар һәм кайберләрне җил һәлак итте. Әмма безнең Мөхәммәд өммәте ни кадәр бәхәсләшсәләр дә, сурәтләре үзгәрмәс, ләкин күңелләре үзгәреп, начарлыклар урнашыр, — диделәр. *Ушлә* — тот мәгънәседә, кыргыз халкының лөгате (теле). Вә кайберәүләр уста[2] дияръләр.

## Фәрештәләргә иман китерү бәяны

Мәлаик кем ирер галәму гайб,
Һәммә Хәкъ бәндәседер бишәкк вә рәйб.

Ягъни фәрештәләр галәме гайбдер, безнең күзебезгә күренмәсләр. Алар барысы да Ходай Тәгаләнең бәндәләре, шиксез вә шөбһәсез.

Алар фаригъ ирер эчмәк-йимәкдин,
Яман кылмак, кабәхәт сүз димәкдин.

Ягъни фәрештәләр пакь, ашау-эчүдән вә яман фигыльләр кылудан, яман, кирәкмәс сүзләр әйтүдән азат. Әйттеләр ки, фәрештәләрнең телләре гарәп теле, бер-берсе белән сөйләшмиләр, һәрвакыт Хак Тәгаләнең зикерен әйтәләр. Сурәтләре төрле-төрле. Кайберләре адәм сурәтендә, кайберләре ат һәм сыер сурәтендә, кайберләре исә бөркет вә арслан сурәтендә булалар. Кайберәүләрнең канатлары ике, кайберсенең өч, кайберсенең дүрт, кайберсенең йөз, вә кайберсенең мең. Һәм әйтәләр, фәрештәләр җәмәгатеннән күбрәк җәмәгать юктыр. Ибне Габбас әйтте: фәрештәләр адәмнәрдән вә пәриләрдән өч мең кат күбрәк. Фәрештәләргә иман китерү исә будыр: алар бар, барчасы Ходай Тәгаләнең колларыдыр, ир һәм хатын түгелләр...

---

1 С-П.да — нә сүзлә дисә (59 б.).
2 К.да — учта (40 б.).



www.darul-kutub.com

Теши ирмәс алар, ни васфы ир һәм,
Билә шәһвәт яратды шаһе галәм.

Ягъни фәрештәләргә иман китерү бу рәвешчә булыр: алар ир-хатын сурәтендә түгел һәм аларны Аллаһ Тәгалә шәһвәтсез (җенси дәртсез) яратты. Безнең кебек ашау-эчү һәм җенси мөнәсәбәтләргә керү аларда юк.

Алар барча Ходаның тагатендә,
Имәс гафил алар һич сәгатендә.

Ягъни ул фәрештәләр һәрдаим Аллаһның тагатендә вә гыйбадәтендә, һичбер вакыт гыйбадәтсез тормаслар...

Әгәрчә барчасы тагатьсез сәрәштә,
Мокаррәб (якын) бәгъзедин бәгъзе фәрештә.

Ягъни ул фәрештәләр һәрберсе тагать вә гыйбадәт даим кылсалар да, Хак Тәгалә хәзрәтенә араларыннан кайберәүләре якынрак, адәмнәр хәле кебек. Чөнки адәм балаларыннан пәйгамбәрләр Аллаһ Тәгаләгә якын, әүлияләр дә якындыр.

Халыкта әйтәләр ки, Аллаһ Тәгаләгә якын фәрештәләр җитмеш мең саф, яшәгән җире гарештә (күктә). Гареш аларның йөрү урыны, һәр сафта җитмешәр мең фәрештә бар. Сурәтләре адәм сурәте кебек. Әйтәләр ки, аларның башлыклары сигез фәрештәдер. Анларны баш фәрештә (херувим) диләр, ягъни ул сигез фәрештәгә гареш йөкләгәндер...

## Китапларга иман китерү бәяны

Мөселманлар укыр Коръән ки халә,
Ирер барча кәламе Хак Тәгалә.

Ягъни хәзер мөселманнар дәрес алып укыган Коръән Аллаһ Тәгаләнең сүзедер. Күктән Җәбраил аркылы җибәрелгән. Әйттеләр ки, Коръән егерме өч ел эчендә тәмам булды. Пәйгамбәр г-м хәзрәтенә кирәк булган саен, Җәбраил иңдерде.

Тәкый пәйгамбәремездин борын, бел,
Ходавәндәм көтүб ки кылды назил (иңдерде).

Ягьни пәйгамбәребездән элек тә Аллаһ Тәгалә пәйгамбәрләргә китап җибәрде һәм иңдерде. Адәм г-м, Шиш г-м, Идрис г-м, Ибраһим г-м, Муса г-м, Гыйса г-мгә һәм аннан башка пәйгамбәрләргә китаплар җибәрде. «Тәүрият» китабы Муса пәйгамбәргә иңде. Ул Адәм пәйгамбәр г-мнән алты мең ел узгач. «Зәбур»[1] Давыд пәйгамбәргә дүрт мең елдан соң иңде.

Инҗил биш мең елдан соң Гыйса г-мгә иңде. Аннан соң Коръән безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд г-мгә биш мең биш йөз егерме елдан соң иңде. Әйтteләр ки, Тәүрият борынгы сирия телендә, Инҗил нәбатия (борынгы тел исеме), Коръән гарәби телендә. Күктән иңгән китап барчасы йөз дә утыз өч, диләр. Бу йөз дә утыз өч китапның мәгънәләре барчасы Коръәндә әйтелеп килә. Һәм Аллаһ Тәгалә Коръәнне йөз дә ундүрт сурәдән гыйбарәт итте... Ул сурәләрне җиде кисәккә бүлде. Ул җиде кисәк Коръән сурәсенең җиде аятен фатиха кылды. Җиде аяте фатиха мәгънәсе җиде хәрефле (гарәпчә язганда төп хәрефләр саны) бисмиллада...

Алла үзе йитәр гашыйклара,
Коръән көллисе (төшенчәләре) йитәр галимләрә.

Галим мескен нә әйласен: кәлимәләре чукдыр,
Бу өч хәрфе илә гарифларның күңеле тукдыр.

Йибәрде һәр кае пәйгамбәригә,
Ки иман килтеребмез баригә.

Ягъни Аллаһ Тәгалә бөтен пәйгамбәрләргә китаплар җибәрде, барчасына иман китереп, хак дип әйтәбез.

Барчасы Хак Тәгаләнең кәлами,
Моны белсә кирәк һәр хасс-гами.

Ягъни күктән иңгән китаплар — барчасы Хак Тәгаләнең кәламе (сүзе). Бу сүз билгеле һәр олы дәрәҗәле һәм гади кешеләргә.

---

1 Зәбур — яңа эрага кадәр 1086 ел элек борынгы яһүди телендә язылган дини китап («Псалмы Давида»).

Кәламе васфыны (сыйфатыны), әй адәмизад,
Кылыб ирдем сыйфатын бабында[1] йад.

Ягъни әй адәм балалары! Аллаһ Тәгалә кәламенең сыйфатын бәян иттем.

## Пәйгамбәрләргә иман китерү бәяны

Сәна, хәмед, кадер телиг Ходага,
Ки иман килтерербез әнбийага.

Ягъни мактау һәм олылау шулкадәр Аллаһ Тәгаләгә булсын... Ходаның һидаяте (туры юлга кертүе) сәбәпле пәйгамбәрләргә иман китердек без.

Аларның әүвәле кем, Адәм ирде,
Мөхәммәд барчасыга хатем ирде.

Ягъни пәйгамбәрләрнең әүвәле Адәм вә ахыргысы Мөхәммәд г-м иде. Һәм ул Мөхәммәд барча пәйгамбәрләрнең соңгысы булып килүчеседер...

Барысы Тәңренең сүгән колыдыр,
Барысы җәннәте ризван гөледер.

Ягъни ул әнбияләр (пәйгамбәрләр) барчасы *Хак* Тәгаләнең сөйгән коллары һәм аларга Аллаһ Тәгаләнең ризалыгы булыр.

Ходаның хөкемене һәр фигыль, сүзгә,
Нәбиләр кылмады бер зәррә үзгә.

Ул пәйгамбәрләр Аллаһ Тәгаләнең хөкемен, әйткән сүзен зәррә кадәренчә дә (бик вак бөртек кадәр дә) үзгәртмәделәр. Ягъни Аллаһның боерыкларын җирдәге колларына китерепн җиткезделәр, арттырмыйча да, киметмичә дә. Үзләре дә ул боерыклардан һич чыкмадылар. Халыклардан җәбер-җафа күрсәләр дә, алардан йөз бормадылар, гөнаһ эшләмәделәр вә эшләргә ният тә итмәделәр.

---

1 К.да- сыйфаты бабында (41 б.).

Йитешмәс һич вәлиләр чаларига,
Йитешмәс, бәлки, хаке паларига.

Ягъни олуг әүлияләр мәртәбәсе (дәрәҗәсе) пәйгамбәрләр мәртәбәсе белән бәрабәр (тигез) булмас. Әүлияләр, пәйгамбәрләрнең аягы баскан туфракларына тиң түгел. Чөнки пәйгамбәрләр вәли[1] иясе, әүлияләр исә — кәрамәт ияләре. Кәрамәт иясе вәли иясе белән кайда тиң булганы бар? Әйттеләр ки, әүлияләр мәртәбәсе пәйгамбәрләр мәртәбәсе янында диңгезнең тамчысы кебек. Бәет:

Вәлиләр мәртәбәдә ирмәз нәбийә (пәйгамбәргә),
Бәдиһидер (ап-ачыктыр) бу сүз һәр зәкигә (зирәккә).

Әйттеләр ки, пәйгамбәрнең иманның бетүендә хәүфе-куркынычы бар.

Алардыр зөррийат (нәселләре) адәмизад,
Гөнаһдин әнбиянең барчасы пакь.

Ягъни ул пәйгамбәрләр туфрактан яратылган Адәм пәйгамбәр нәселедер. Ул әнбияләр гөнаһтан пакь һәм күрәзәче вә мәҗнүн түгел, хатыннардан яки коллардан да түгелләр....

Алардин бәгъзе эшкә кылдылар нәкыл,
Кылыр тәэвилене ногман, багкыл.

Ягъни пәйгамбәрләрнең кайбер эшләрен риваять итеп сөйләгәннәре бар... Адәм г-м оҗмахта бодай ашаганы, Давыд пәйгамбәр Урийа хатынны алуы, Йосыфның кардәшләре алдында «мин кол» дип әйтүе, тас яшереп кәрендәшенә угры (карак) дип яла ягуы кебек һәм моннан башка никадәр пәйгамбәрләрдә булганнарын... Һәм безнең пәйгамбәребез балны хәрам кылуы кебек — боларның барчасын имам Әгъзам рәхмәтуллаһигаләйһи (Аллаһның аңа рәхмәте булып, аны кичерсен) аңлаткандыр. Пәйгамбәрләр мондый эшне кылдылар диеп, безгә аны алга сөрү кирәкмәс. Хакыйкатьтә бу әйтелгән нәрсәләр гөнаһ булса да, кайберенең пәйгамбәрлектән элек,

2 К.да — вәхи (42 б.).

кайбере исә, аяклары таеп эшләнгән. Аларны Аллаһ Тәгалә гафу иткән. Шуның өчен гафу ителгән нәрсәләр юк дип саналыр...

Ул эш касд имәсдер әнбиядин,
Аларга ләгъзеше падыр хатадин.

Ягъни ул эшкә ниятләре юк иде. Эшләсәләр дә, гөнаһ кылды дип әйтелмәс, бәлки аяклары тайды вә хата кылды дип әйтелер. Һәм әйттеләр ки, аяк тайды дип, әйтү дә урынлы түгел. Ләгъзеш — аяк таю вә хәталану мәгънәсендәге фарсы сүзе.

Алар касд илә һәргиз кылмадылар,
Боерган әмридин аерылмадылар.

Ягъни ул пәйгамбәрләр ул эшне һич тә явыз ният белән кылмадылар, Аллаһ Тәгалә боерыкларыннан аерылмадылар.

Бары дәрья рәхмәтедә иде гаркъ,
Рәсүл илә нәбидә булды бер фәркъ.

Ул пәйгамбәрләр барчасы Ходай Тәгаләнең рәхмәт дәрьясына чумганнар һәм Ходай Тәгалә аларның иманнарын саклаган. Ләкин алай булса да, рәсүл белән пәйгамбәрләр арасында бер аерма бар, ягъни рәсүл белән нәби төрле нәрсәләрдер.

Нәбидер һәр рәсүл, аңлагучы бул,
Вәләкин һәр нәби ирмәс рәсүл ул.

Ягъни рәсүлне нәби дию урынлы һәм дөрес дип санала. Рәсүлнең Аллаһтан килгән китабы булыр. Нәбине исә рәсүл димәк дөрес булмас. Нәбинең Аллаһтан килгән китабы юк. Әйттеләр ки, Җәбраил г-м рәсүлләргә уяу вакытында килеп, хәбәрләр бирә иде, нәбиләргә йокыда хәбәр бирә иде. Рәсүлләр нәбиләрнең остазы дип саналыр. Нәбиләр исә рәсүлләрдән сабак алып (өйрәнеп), шәкертләре дәрәҗәсендә. Пәйгамбәр дип әйтү — рәсүлгә тиң. Идрис, Шиш, Муса вә Гайса — зур пәйгамбәрләр.

Боларны сәүче (илче) дип атыйлар. Зәкәрия, Шәмгун Урия кебекләрне ялавач дип атыйлар.

Диделәр: пареи мөэмин баласы,
Ирер бер мәгънәдә һәр икеләсе.

Әйттеләр: «Әй мөэминнең йөрәк парәсе, рәсүл белән нәби арасында аерма юк, һәр икесе бер мәгънәдәдер», — диделәр.

Сәләф кем әйладе лотфы гыйнаять,
Ирер әүвәлгесе мәшһүр риваять.

Ягъни үткән имамнар игелек итеп, әүвәлге риваятьне дөрес дип таптылар. Рәсүл илә нәби арасында аерма бар дип яздылар.

Бәшәр пәйгамбәр солтаны әгъдал,
Мәләк дайгамбәредин кылды әфзал.

Ягъни әһле сөннәт вә җәмәгатьнең күбесе әйтте: Адәми заттан булган пәйгамбәрләр фәрештәләр пәйгам-бәреннән артык (өстен), диделәр. Бу дәлилләрнең әүвәлгесе будыр: Аллаһ Тәгалә Адәм пәйгамбәргә фәрештәләрне сәҗдә кылдырды. Димәк, Адәм артык булды. Һәм икенчесе будыр: Адәм фәрештәләрдән галимрәк иде. Гыйлемлек белән дә пәйгамбәрләр фәрештәләрдән артык булды... Өченче будыр: адәм булган пәйгамбәрләр тагать һәм гыйбадәтне мәшәкъкать белән кылдылар, фәрештәләрдә исә мәшәкъкать юк. Дүртенче будыр: адәмиләр оҗмах-тәмугны күрмичә инанып торырлар, фәрештәләр күреп торырлар. Шуңа да күрмичә инанган кешенең өстенлеге бар. Бишенчесе: Аллаһ Тәгалә Коръәндә Адәм пәйгамбәрне, Нух ялавачны (пәйгамбәрне), Ибраһимны вә Ибраһимның җәмәгатен истифа (сайла) дип телгә ала. Бу дәлилләр белән адәмидән булан пәйгамбәрләр фәрештәләр пәйгамбәреннән артык булды. Фәлсәфәчеләр (философлар) һәм дәһриләр (дингә ышанмаучылар) әйттеләр ки, фәрештәләр пәйгамбәре артык (өстенрәк). Боларның бу сүзләре батыйлдыр (ялгандыр).

Бәшәрдән (адәмидән) һәр рәсүл әфзал мәләкдан,
Савабы әксәр (күбрәк) әкмәл мәләкдан.

Ягъни фәрештәләрдән рәсүл Җәбраил вә Исрафил, Микаил вә тагын гарше күктәге фәрештәләр, Ризван нәбидән башка болар дәрәҗәле китапларда телгә алыналар.

Бу сүздер мәзһәбе сөннәте җәмәгать,
Алар һәр нә диде — кыйлгыл итагать.

Ягъни адәми пәйгамбәрләр фәрештәләр пәйгамбәрләреннән өстенрәк. Бу сүзгә буйсын. Әһле сөннәт мәзһәбе мондый фикердә. Моны күңелеңдә тот...

Диделәр: гаммәи фәрзәнде адәм,
Мәләкнең гаммәседин фазлы күб һәм.

Ягъни имамнар әйттеләр: адәм балаларының галимнәре фәрештәләрнең галимнәреннән өстенрәк, диделәр.

Әйттеләр ки, сәхабә иярченнәре гомум фәрештәләреннән өстен саналыр. Гавамдан булган адәмиләр шундый булыр - тәкъва әһле...

Китабе Кяфи кем, пәр сафадыр,[1] —
Диде гамә бу йирдә иттикадыр (тәкъвадыр).

Ягъни Кяфи китабының авторы сафа әһеленең башчысы иде. Гамәдән морады (теләге) монда тәкъвадыр. Суфыйлар вә тәкъваларның кайберләре кан түгеп, хәмер эчеп вә зина кылып йөриләр, — болар фәрештәләрдән артык була аламени!? Фәрештәләр исә Аллаһ Тәгаләнең гыйбадәтендәдер.

Бәшәрдә вар нә чәндан бигамәлдер,
Бәһаимдик (хайваннар кебек) ирер, бел, һәм әзәлдер.

Ягъни күрмисеңмени, адәм баласында ни кадәр гамәлсезлек бар, төн-көн хайван кебек ашау-эчүгә бирелгәннәр. Хак Тәгаләнең гыйбадәтеннән гафилләр.

1 К.да — бесафадыр (44 б.).

Алар кайчан һәм ничек артык була ала тагать әһле булган фәрештәләрдән?..

Пәйгамбәрнең бары гаделе әгъдал,
Вәләкин бәгъзеседин бәгъзе әфзал.

Ягъни пәйгамбәрләрнең барчасы гаделләрнең гаделрәгедер, ләкин алай булса да, кайберләре Хак Тәгаләгә якынрак вә фазыйләтлерәк. Безнең пәйгамбәребез барлык пәйгамбәрләрдән дә өстен булганы кебек...

Савабе ротбәдә әфзал ирер халь,
Мосавидер (тиңдер) нөбүвәт (пәйгамбәрлек) берлә ирсаль.
Ягъни гыйбадәт савабында нәби белән рәсүл бертигез. Аллаһ Тәгаләгә якын булуы сават күплеге белән түгел, ә аның белән вәсиләгә (аралашу юлына) бәйле. Муса пәйгамбәр белән Ходай Тәгалә Тур (Синай) тавында җитмеш кат пәрдәләр аркылы сөйләште. Кайберләре белән Җәбраил аркылы сөйләште. Безнең пәйгамбәребез белән Мигъраҗ[1] төнендә пәрдәсез сөйләште. Шуңа күрә дә якын булуы бу тәртип белән хисапланыр. Уйлап кара.

Барының тиһтәре (өстене) ул Мостафадыр,
Хәбибе Хәкъ нәгин (йөзек кашы) әнбиядер.

Ягъни бу пәйгамбәрләрнең барчасының әфзалы (өстен булганы) вә әкмәле (камилрәге) Мөхәммәд Мостафадыр. Аллаһ Тәгаләнең дусты, пәйгамбәрләрнең йөзек кашыдыр. Ягъни пәйгамбәрләрнең иң өстенрәге.

## Пәйгамбәр г-мнең мигъраҗының бәяны

Мөхәммәд кем, ирер әфзал вә әсдак,
Ирер бишик Мигъраҗ бер Хәкъ.

Ягъни Мөхәммәд г-м аңа кадәр булган барлык пәйгамбәрләрдән дә артыграгы, өстенрәге булыр. Хак Тәгалә ул дустына Мигъраҗ төнен бүләк итте һәм Мигъраҗ казасы (бурычы, вазыйфасы) йөкләде. Монда зикер иту (сөйләп киту) белән китап озын булыр. Әйтәләр, Мигъраҗ рәбигыл-әүвәл аенда булды. Ә

1 Мигъраҗ төне — Мөхәммәд пәйгамбәрнең күккә ашу кичәсе.

кайберләре рәҗәб аенда булды дип әйттеләр. Тагын да әйтәләр, пәйгамбәр г-м Мәккәдән Мәдинәгә күчкәннән бер ел алдан (элек) булган иде. Һәм әйтәләр, пәйгамбәр г-м Мигъраҗ төнендә, җиде кат күккә менеб[1] (менеп), гарше көрсине (гарештәге Аллаһ урынын) үтеп, җитмеш пәрдә аша, Хак Тәгалә белән туксан мең сүз сөйләште. Һәм әйтәләр, бу кадәр җирне күреп, өенә кайтып кергәндә, түшәгенең эсселеге китмәгән (суынмаган) иде... Әйтәләр, мәсҗеде Хәрамдин (Мәсҗедел-хәрам — Мәккәдәге мәчеттән) мәсҗеде Аксага (Кодсул-Шәрифтәге — Иерусалимдәге мәчеткә) барса, иттифакый (очраклы рәвештә) кяфердер һәм аннан югарысына барса, кяфер булмас, диделәр.

Хәрамдин мәсҗеде Аксага нәгяһ
Алыб барганидыр аятьдә агяһ.

Пәйгамбәрнең Хәрам мәчетеннән Акса мәчетенә баруы «Коръән»нән аңлашыла. Аннан югары баруы аятьтән аңлашылмады, бәлки ожмах өммәтеннән (өметеннән) беленде. Акса мәчетеннән морад — Бәйтелмөкаддәс булыр. Хәрам мәчете белән Бәйтелмөкаддәснең арасы кырык көнлек җир булыр...

Шәбе Мигъраҗның улды маһы табы.
Нә фәршнем (җирнең), бәлки гаршнең афтабы (кояшы).

Борака[2] Мәккәдин менде ул сәрвәр (юлбашчы),
Рәкабендә (иярендә) йөрер намусы әкбәр[3]

Сәмадин юкары һәркайсы җага, Гыйнаять кыйлды ул басхага.

Ягъни Хак Тәгалә күкләрдә теләгән урыннарга ирештерде, Аллаһу Тәгалә ул бәндәсенә ярдәм биреп ашырды, ул үзенең дустына юмарт.

Дәхи әгълайа (югарыга) андан улды иршад (туры юл),
Ирешмәз ат мәкамә (урынга) гаклы нәкъкад[4].

---

1 С.П.да — бенеб (67 б.)

2 Борак — порак — Мөхәммәд пәйгамбәр, атланып, күккә ашкан хайван. С.П.да — Порак.

3 Намусы әкбәр — а) олы намус (иясе), б) серләрне белүче зат.

4 Нәкъкад — тәпченүче; тәнкыйди рухлы кеше.

Барыга сыйдкымыз, икърарымыз бар,
Имәс һич эш Тәңрегә дөшвар.

Ягъни шулай бип барысына да раслап телебез белән тәкърарлап әйтербез. Ягъни Мигъраҗ хак, Хак Тәгаләнең бер сәгатьтә җиде кат күкләрне гиздереп кайтаруы Тәңре Тәгаләгә берни түгел.

Нә манигъ (киртә) кодрәте Хәкъдан бу халә,
Бу дәгъвада мохалә йук хәвалә (мөмкин булмаган нәрсә бу хәлдә юк).

Мокам-у сәдрәи-ү нөҗүме мәләкне,
Биһиште гарше көрси нә фәләкне.

Ягъни сидрәтел-мөнтәһаны[1] һәм күкдәге йолдызларны, һәм оҗмахны, гарше көрсине һәм тугыз кат күкләрне

Әгәр бер кичә күрсәтсә ни кәм,
Вә гәр бер дәмдә күрсәтсә ни шәк һәм.

Ягъни ни булыр, бер кичәдә күрсәтү ничек авыр булыр, бәлки бер сулу эчендә күрсәтсә, ни итәрсең?! Хак Тәгалә хәзрәтенә бер дә читен түгел.

Ничек кем хөкем әйласә кадыйр Ходадыр,
Чәра (ни) өчен димәк колдин хатадыр.

Ягъни Аллаһу Тәгалә ничек хөкем кылса, ни дисә, шуны эшләр — бар нәрсәгә Кадыйр (көче җитә, аның ихтыярында). Ни өчен мондый кылды һәм ни өчен болай кылмас дию безгә лаек түгел, чөнки Аллаһу Тәгаләнең кодрәте җәмигъ (барлык) кодрәтләр мохиты (әйләнә-тирәне чорнап алган, билгеле).

Якыйн белгел анын Мигъраҗын, әй йар,
Тәне берлә иде һәм ирде пәйдар.

Ягъни бел, ул пәйгамбәрнең Мигъраҗы шиксез, үз тәне белән уяулыкта иде, төшендә булмады. Шийга халкы (шигыйлар): пәйгамбәр Мигъраҗга тәне белән

1 Сидрател-мөнтәһа — күкнең җиденче катында үсә торган мифик агач.

түгел, бәлки төшендә күккә менеп, Хак Тәгалә белән сөйләште, дип әйтәләр. Бу — батыйль мәзһәб (ялгыш юнәлеш, дөрес булмаган караш)...

Хәбиб һәр ничек кылса сәре әфраз.
Ходаның рәхмәте күбдер, имәс аз.

Ягъни Аллаһу Тәгаләнең дусты ничек кылса да кылыр, ул — олуглык иясе. Чөнки Хак Тәгаләнең рәхмәте күп, аз түгел. *Сәре әфраз* (сәрәфраз) дигәне васфы тәркибдер (кушма сүз), олуг-олы мәгънәсендә килә. Фарсы сүзе.

## Сәхабәи кәрам[1] бәяны

...Сәхабәи нәбидер барчасы хак,
Яман юлда имәс һич кайусы мотлак.

Ягъни пәйгамбәрләрнең сәхабәләре барчасы хак, берсе дә яман юлда йөрмәделәр, бәлки һәркайсы Хак юлында булдылар һәм хак юлга өндәделәр.

Ирер һәр кайсысы нәҗме һидаять,
Хода халкыга кылган гыйнаять.

Ягъни ул сәхабәләр һәркайсы хак юлга күндерүче йолдызлар иде. Хак Тәгалә ул сәхабәләрне халыкка, кешеләргә ярдәм өчен пәйгамбәр мәҗлесендә кылды, соңрак галим булып, аңардан хәдисләр ишетеп, гамәлләр кылдылар.

Биһиштдер[2] алардин катигъ ун йар,
Бәшарәт бирде ул солтаны әбрар.

Ягъни ул сәхабәләрдән ун кешегә изгеләрнең солтаны пәйгамбәребез оҗмах сөенчесе бирде, ягъни дөньяда булмасларыннан әүвәл пәйгамбәр г-м ун кеше оҗмахлык дип әйтә иде.

Әбүбәкер, Гомәрдер, соңра Госман,
Галидер, Талхәдер һәм Габдеррәхман.

---

1 Сәхабәи кәрам — сәхабәи кәрам, — хөрмәтле сәхабәләр (Мөхәммәд пәйгамбәр белән аралашкан, аны күргән кешеләр).

2 К.да — биһишликдер (46 б.)

Ягъни оҗмах сөенчесе бирелгән кешеләрнең әүвәле — Әбүбәкер, икенчесе — Гомәр, өченчесе — Госман, дүртенчесе — Гали, бишенчесе — Талхә, алтынчысы — Габдеррәхман бине Гаваф булды.

Зәбирә[1] бу Габидә булды әхбар,
Сәгыйд, Сәгьддер әйган бу ун йар.

Ягъни җиденчесе — Габидә, сигезенчесе — Сәгыйд бине Вәккас, тугызынчысы — Сәгъд бине Зәйд, унынчысы — Зәбир[2].

Мөхәммәд кем иде һадийе галәм,
Бәшарәт бирде өч фәрзәндигә һәм.

Ягъни Мөхәммәд г-м галәмне күндерүче, һәм дә ул өч баласына оҗмах белән сөенеч бирде. Аларның исемнәре:

Берсе — Фатыймадыр һәм — Хазыйрә,
Хәсән берлә Хөсәен — ике нәбирә.

Ягъни ул өч баласының берсе — Фатыйма. Ул Фатыйманың сыйфаты шундый, харамнан сакланучы. Һәм дә Хәсән белән Хөсәен — баласының балалары, ягъни Фатыйманың уллары. *Хазыйрә* ханың («ха» хәрефенең) фәтхәсе (сузыкны күрсәтүче билге) белән нокталы заның («за» хәрефенең) кәсре (ас сызык) белән гөнаһыдан тыючы, саклаучы мәгънәсендә килә... *Нәбирә* нунның (нун хәрефенең) фәтхәсе белән байи гарәбинең (гарәпчә ба хәрефенең) кәсре белән бемәгънә вәләдел-вәләддер (баласының баласы), фарсыча (фарсы сүзе)...

...Будыр бәнем ки белдеке каләмем.
Риваятьләр улдыкы мәрамем (теләгем).

Ки Таҗеддин һәмишә (һәрчак) бул теләкдә,
Ки максудлар табылмышдыр теләкдә[3].

---

1 К.да — Зәбир (46 б.).

2 К.да — «йиденчесе — Зәбир, сигезенчесе — Габидә, тукызынчысы — Сәгъд бине Зәйддер» (46 б.)

3 С.-П.да — беләкдә (70 б.)



www.darul-kutub.com

Нәбиләр соңында, белгел, бетәхкыйк.
Ки инсан әфзалы — Әбүбәкер Сыйддык[1].

Ягъни пәйгамбәрләрдән соң, бел, адәмнәрнең артыграгы һәм сыйддыкрагы (туры сүзлесе) — Әбүбәкер булыр. Чөнки Әбүбәкер хакында фәзаилләр (өстенлекләр) күп мәгълүм. Барысын язып китсәң, китап озын булыр. Безгә игътикад (ышану) шулай: пәйгамбәрләрдән соң Әбүбәкердән артык кеше юк дип игътикад (ышану) кылу.

Вәлиләр (изгеләр) әфзалы Әбүбәкер сыйддык,
Будыр әкмагы өммәт илә тәсдыйк
(Бу барлык халыкның фикере белән раслана).

Ки андин сонра — Гомәр, сонра — Госман һәм,
Андин соң — Гали, бишөбһә (һичшиксез), әй жан.

Ягъни Әбүбәкердән соң адәмнәрнең әфзалы Гомәр, аннан соң Госман, аннан соң Гали дип игътикад әйлә (ышан)...

...Бу түрт ирер өммәтнең нәгине (йөзек кашы; өстене),
Шәфагать хаһымызның канәшине (варисы).

Ягъни бу дүрт зикер булган (телгә алынган) ирләр — барча өммәтләрнең изгесе, гүя ки йөзек кашы кебек һәркемгә болар мәргубдер (якын, яратыла торганы); шәфәгать эстәүче (теләүче) пәйгамбәребезнең урынына утырып, хәлифәлек кылган кешеләр булыр. *Нәгни* фарсыя кяфе (фарсы телендәге кәф) белән йөзек кашы мәгънәсендә килә, ягъни өммәтнең изгесе һәм мәргубе (әйбәт сыйфатлысы) димәк... *Жандшин* хәлифә мәгънәсендә, ягъни берәү китеп, аның урынына утыру мәгънәсендә килә.

Рәсүл әйдер: үкәрсәм (? үтсәм) дөньядин йөз,
Хәлафәт булгай утыз елгача төз.

Ягъни пәйгамбәр г-м әйтте: «Әгәр мин дөньядан киткәч, утыз ел дәвамында бу дүрте хәлифә булыр, —

1 Сыйддык —тугрылыклы. Әбүбәкернең кушаматы

диде. — Аннан сон хәлифә дип әйтмәгез, ә түрәләр һәм солтаннар диегез», — диде.

Әйттеләр ки, Әбүбәкер белән Гомәрнең хәлифәлеге унөч ел булды, һәм Хәзрәте Госманның — унике, һәм Галинең биш ел булды. Барлыгы утыз ел үтте.

Ул утыз елда шаһ ирде ул түрт ир.
Алар вактыда бөстан ирде һәр йир.

Ягъни ул утыз ел эчендә ул дүрт кеше хәлифә иде. Алар заманында бөтен[1] җирдә гаделлек һәм бәрәкәт булды. Әйттеләр ки, аларның заманы кебек заман килмәс, мәгәр Хәзрәте Мәһди ахыр заманда килер. Фәкать алар изге һәм тугры булыр, диделәр.

Алардин соңра һич галиме гамил
Кыла алмас алар дик гадле кямил.

Ягъни дүрт сәхабәдән соң ни кадәр укымышлы хакимнәр булса, алар гаделлекне камил итеп башкара алмаслар; ни кадәр суфый һәм изге булсалар да, аларның аяк туфракларына җитмәсләр.

Ушал түрт ир ки Әхмәде йари ирде.
Биһиште мәгърифәт гөлзары ирде.

Ягъни шул искә алынган дүрт кеше пәйгамбәр г-мнең юлдашлары иде, Аллаһны тануда оҗмахның гөлбакчалары иде.

Рәсүл Алла тарикын (юлын) иртә һәм кич
Сәри муйи тәхәллеф кылмады һич.

Ягъни ул дүрт кеше пәйгамбәрнең юлында иртә һәм кич тордылар, һәм ташларга ниятләре юк иде, һәм пәйгамбәрнең һичбер әмеренә чәч кылы калынлыгы («сәри муйи») кадәр[2] дә каршы килмәделәр, ягъни күп булса да, әз булса да, димәк.

1 С.-П.да — канкый (71 б.).
2 С.-П.да — «кыл башы кадәре» (72 б.).

Ничек булсын хәлаф (хәлифә) ул чар сөгьдә[1],
Пәйгамбәр кылды утыз елга вәгъдә.

Ягъни ул дүрт кеше ничек утыз елдан артык хәлифә булсын?! Чөнки пәйгамбәр г-м аларга «миннән соң утыз ел сез хәлифә булырсыз», дип вәгъдә итте.

Утыз елда тәмам улды хәлафәт,
Утыз елдан соң диенер (?) имамәт[2].

Аларнын васфыныц һич саны булмас,
Тәмам әйтәй (әйтәм) дисәм, әмкяны (мөмкинлеге) булмас.

Ягъни ул дүрт кешенең изге сыйфатларының саны һәм хисабы юк. Ни кадәр әйтергә теләсәм дә, мөмкин булмас, чөнки аларны Аллаһ Тәгалә мактады. Аллаһ мактаган кешеләрне ничек мактамаска була?!

Һәр кемнен мадихе (мактаучысы) Алла ула, —
Күр, кыяс әйлә (чагыштыр) ки, ул нә шаһ ула!

Сәхабәнең бары һәм паке диндер,
Барысы раһнәмаи раһы диндер.

Ягъни бу дүрттән башка, үзгә сәхабәләр барысы да чиста диндәдер һәм аларның барысы да дөрес юлга өндәүчеләрдер.

Алардин соңра һичкем җаларига,
Йитешмәс бәлки хаке паларига.

Ягъни сәхабәләр заманыннан соң килгән изгеләр аларның дәрәҗәсенә ирешмәс, бәлки аларның аягы баскан туфракларына да ирешмәсләр. Чөнки алар пәйгамбәр г-м белән бергә булды.

Кеше булса нәбинең сохбәтендә,
Гөман юкдыр аларнын карибәтендә.

---

1 Чар сөгъдә — дүрт йолдыз. Бу очракта — дүрт сәхабә.
2 К.да — әмират (48 б.).

www.darul-kutub.com

Ягъни кем дә булса пәйгамбәребез кебек изгеләр белән булса, һәрвакыт аның артында намаз кылса, андый кешеләрнең Аллаһка якынлыгы юк, дип шикләнмә[1]. Ягъни якынлыклары нык, һичшиксез, Аллаһ Тәгаләнең гафу иткән[2] колларыдыр.

## Могавия[3] һәм Йәзид кыйссасы

Сәхабә бәгъзесе кем Мортазага[4]
Тәхәллеф әйләде (каршы килде) басәхага.

Ягъни сәхабәләрнең кайберсе Хәзрәте Галигә каршы килде. Ул каршы килүче Могавия иде. Ягъни Хәзрәте Гали дәверендә Могавия «мин хәлифәмен», дип каршы чыгып, күп сугышлар кылдылар, күп халыкның каннары түгелде. Алай булса да, Могавиянең Хәзрәте Галигә каршы килү иҗтиһадтан иде, ягъни «Пәйгамбәребез исән чагында миңа син хәлифә булырсың», — дип әйтте. Каршылыгы шуннан булды. Алай булса да, безгә әйтү кирәкми. Сәхабәләр бер-берсенең юлыннан бармадылар[5]. Без аларга ни өчен иярүебез ник кирәк, дип әйтмәгез. Чөнки Могавиянең каршы булуын безгә үрнәк итеп тоту кирәкми. Аның каршы килүе дөреслектә иде...

Саваб ирде ул ирләрнең морады.
Хата булды бинагяһ (көтмәгәндә) иҗтиһады.

Ягъни ул Могавия ниятләре дөреслектә иде. Ләкин аңлаулары дөрес булмыйча, хата ясадылар. Иҗтиһад итеп, берәү хата эшләсә, ахирәттә аңа газап юктыр. Шуның өчен боерды:

Хата кылган белән язды димәсмез.
Җәмәгать әһледин азды димәсмез[6].

---

1 С.-П.да — шөкер (73 б.).
2 С.-П.да — ярлыканмыш (73 б.).
3 Могавия (Мәгавия) — әмәвийләр (омейядләр) нәселеннән беренче хәлифә (661-668).
4 Йәзид — VII йөзнең беренче яртысында яшәгән гаскәр башлыгы. Могавиянең көрәштәше.
5 Мортаза — Мөхәммәд пәйгамбәрнең кияве, сәхабәсе Галинең кушаматы(«сайланган»).
6 Бу бәет С.-П.да күзгә ташланмый (73 б.).

Ә иммә, әһле сөннәт кем иделәр, —
Хатаи мөҗтәһид[1] мәгъкуд диделәр.

Ягъни әһле сөннәт һәм җәмәгать имамнары әйттеләр, иҗтиһад кешеләр хата эшләсә, хатасы гафу була, — диделәр.

Хатага бәлки табтылар савабы, —
Бу сүздер әһле сөннәтнең җавабы.

Ягъни бәлки иҗтиһад эшләүче хата эшләсә дә, аңа саваб булыр, — диделәр. Шулай дип җавап бирде әһле сөннәт имамнары:

Бөтебдер (язылгандыр) «Мәҗмәгыл-әшйа»да[2], әй шәмгъ,
Хатадин, бәлки, кайтыб ирде ул җәмгь.

Ягъни «Мәҗмәгыл-әшйа» дигән китапка күрә, Могавия тарафдарлары белән сүзләреннән кире кайттылар һәм Хәзрәте Галидән гафу үтенделәр[3] һәм эшләгән эшләренә үкенеп, тәүбә, гафу сорадылар, — диде(ләр). Фәтва бу сүзгәдер.

Мәгълүм ки, Йәзидкә[4] һәм ләгънәт укырга кирәкми, чөнки Йәзид мөселман иде. Имам Хөсәенне үзе үтермәде, тарафдарлары үтерде. Үтерүе ялгыш аңлавы нәтиҗәсендә иде, хата булды. Хәзрәте Әбүбәкер улы Габдулла Хәзрәте Госманны үтерде. Үтерүе ялгыш аңлавы белән иде. Хата булды. Һәм шулай ки, юкка кеше үтерү белән кеше кәфер булмас, олы гөнаһ эшләгән булыр.

Әйттеләр ки, Йәзид тәүбә итте һәм дөньядан иман белән китте. Әйттеләр ки, Йәзиднең өч төрле күркәм эше бар иде. Беренчесе — дөрес хөкем итә иде, һәм икенчесе — әүвабин намазын ихлас күңелдән Аллаһка бирелеп укый иде. Пәйгамбәр г-м әйтте: «Һәркем әүвабин намазын даими рәвештә укыса, ни кадәр олы гөнаһлы булса да, гафу булыр», — диде. Әгәр мәнем улларымны үтерүче булса да, гафу булыр, дигән иде. Шунын

---

1 Мөҗтәһид — дини мәсьәләләр буенча яңа хөкемнәр чыгаручы; тырышучы. Югары дәрәҗәле рухани.

2 «Мәҗмәгыл-әшйа» — китап атамасы. Ягъни «Әйберләр тупламы» мәгънәсендә.

3 С.-П.да — кулдылар (кылдылар) (73 б.).

4 Йәзид — VII йөзнең беренче яртысында яшәгән гаскәр башлыгы. Могавиянең кәрәштәше.



www.darulkutub.com

өчен Йәзид әүвабин намазын кылыр иде. Өченчесе — җир йөзенә тәһарәтсез басмады. Тәһарәте бозылса, тәһарәт алганчы тәйәммум кылыр[1] (ком яисә туфрак белән тәһарәт алыр) иде. Әйттеләр ки, Хак Тәгалә бу өч төрле изге гамәл өчен Йәзидне гафу итте һәм соңыннан бел моны: сәхабәләрдән соң табигыйннәр (ягъни сәхабәләрне күргән кешеләрнең өстене).

Бу өммәт әфзале бәгъдәс-сәхабә (сәхабәдән соң),
Мөхәкъкак (чын) табигыйндыр дәшмә табә...

...Мөҗәддәд улмагын (яңаруны) бу сүзе мөәббәд[2]
Килер һәр йөз башында бер мөҗәддәд (яңартучы; реформатор).

Әбү Йосыф Һарун Рәшидә[3]
Иреб китде йөз сиксән икедә (милади белән — 798 дә).
Мөхәммәд[4] китде йөз туксан тукызда
Зөфәр мәрхүм йөз илле сигездә...

Мәдинә галиме Малик замани,
Хәдиснең нуры дотмышди җиһани
(Җиһанны хәдиснең нуры тота).

Сөннәне[5] тәсхихе бәхәсендә ир ирде
(Сөннәне төзәтүдә оста иде),
Тәмам гомере сиксән түртдә вар иде.
Вафат улдыкы елда бу Хәнифә[6]

Җиһанда килде бер зат шәрифә (изге) —
Мөхәммәд Шафыйгый Ибне Идрис,[7]
Идеб Малик Мөхәммәд ана тәдрис (дәрес).

---

1 С.-П.да — сукар.
2 Мөәббәд — мәңгелек; алдагыны әйтүче. Текстта — «раслар» мәгънәсендә.
3 Һарун Рәшид — Багдад хәлифе.
4 Биредә Мөхәммәд пәйгамбәр күздә тотылмый.
5 Сөннә (ас-суннә) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең сүзләре, эш-гамәлләре турындагы хәдисләр җыелмасы.
6 Хәнифә — Әбү Хәнифә (767 елда үлә) — хәнәфиләр мәзһәбенә нигез салучы имам.
7 Мөхәммәд Шафигый (820 елда вафат була) — шафигый мәзһәбен нигезләүче имам.

Әлендән (кулыннан) әһле бидгать дөшде йирә (җиргә),
Тәмам гомре варды илле түртә (илле дүрткә).

Нә сахибе әфзал, остазы әкмал
(Затлылыкның хуҗасы, камиллекнең остазы),
Улыб шакерд Әхмәд ибне Хәнбал[1]...

## Шарты имамәтнең бәяны

Имамәт шарт булды һәр диарә (өлкәдә; төбәккә),
Ходуды шоруг татурдай карарә.

Ягъни мөселманнарга йортында имам теләү тиешле булды. Шәригать боерган эшләрене торгызып тору өчен. Әйттеләр ки, имам булган кешегә тугыз нәрсә шарт була. Беренчесе — һәрвакыт иҗтиһад итүче, барыннан да элек диннең нигезен белүче, ... диндәге кыен урыннарны ачып бирүче, ... хөкемләргә көче җитүче... Икенчесе — акыл иясе, кәферләр белән сукыш итергә хәйләкәр булучы. Өченчесе — батыр булучы, ... куркак булмыйча, шәригать боерган урыннарда каты торучы... Дүртенчесе — гадел, хыянәт итмәүче булучы. Бишенчесе — тиле булмау. Алтынчысы — ир кеше булучы. Җитенчесе — сабый булмыйча, балигъ булу[2]. Сигезенчесе — азат булу, кол булмау. Тугызынчысы — корәйши кабиләсеннән булу.

Төзәткәй[3] та шәригатьнең кыямын,
Тәкый кылтай йаманлар иһтимамын.

Ягъни ул имам булган кеше шәригать хөкемләрен дөрес итү, хак сүзне яшермичә һәм халыкның «һавасына» карамыйча, һәм яман юлда йөрүчеләрне кабул ителгән әмерләр белән тыеп, җәзага тарту.

Имам нәсб әйламәк (билгеләмәк) халыкда важиб (зарури; тиешле),
Будыр әҗмагы өммәт (барлык кешеләрнең), әй мосахиб (әңгәмәдәш).

---

1 Ибне Хәнбал — атаклы фәкыйһ һәм мөселман динендәге хәнбалитләр мәзһәбен нигезләүче.
2 Җиденчесе С.-П.да юк (76 б.).
3 К.да — йөреткәй (51 б.).

...Әгәр чәндики солтан булса бозык (бозык),
Боерса эш шәригатькә муафикъ.

Ягъни бер солтан я имам, я мөфти, я казый[1] фасыйкъ булсалар да, үзләре шәригатькә кушканча эшләргә боерсалар, имамлыктан төшерелмәсләр. Аларга буйсынып итагать итәрбез.

Имам улырса җәүрә-золыма мәшгуль
(Имам җәбер-золым белән мәшгуль булса да),
Имамәтдән улынмаз кәнд мәгъзул
(Үзе имамлыктан төшерелмәс).

Кыйлармыз җан-дел берлән итагать.
Үзе булса әгәрчә би канагать.

Ягъни бозык имам эшне шәригатьчә алып барса, җан һәм күңел белән боерган әмеренә буйсынырбыз. Әгәр ул имам канәгатьләндермәсә дә.

Имәсдер шарт: имам ула мәгъсум.
Кынлыбдыр шарт әмма шийгайи шом.

Ягъни шарт түгелдер: имам булган кеше тәкъва булмавы һәм гөнаһлардан чиста булмавы шарт түгел. Шигыйлар, ягъни кызылбашлар[2], имам булган кеше тәкъва һәм гөнаһтан чиста булырга тиеш булуны шарт итеп куйды.

Дәгелдер шарт имам нәсле Һашим[3],
Дәгел мәгъсум улмак шарты лязем (зарури шарт түгел).

Замана әфзалы улмак имамә (имамга),
Дәгел лязем низамы интизамә (тәртипкә китерүчегә).

Мөселман гакыйлы балигъ ир инсан, —
Имамәт шарты будыр, әй мөселман.

1 С.-П.да бу исемнәрдән «имам» гына атала (76 б.).
2 Кызылбаш дип, еш кына иранлыларны атап йөрткәннәр.
3 Һашим — Мөхәммәд пәйгамбәрнең бабаларыннан берсе.

Ягъни имам булган кешегә акыл кирәк һәм балигъ булу кирәк. Имам булу шарты болардыр, аңла, әй мөселман.

Рәвадыр икътида фаҗирга кылсаң, —
Хәдисе Мостафадыр, яхшы белсәң.

Ягъни дөрестер бозык имамның артында намаз кылу дөрес, чөнки Рәсүл г-м әйтте: «Һәр изге һәм явыз имам артында намазларыңны кыл!» — диде...

...Укысаң яхшыларның соңында, лик (ләкин)
Савабы би гадәддер (хисапсыз), хасләте (сыйфаты) ник (яхшы).

Ягъни изге имамнар укыган намазның савабы күп һәм барысы да өстен. Пәйгамбәр г-м әйтте: «Берәү изге имам артында намаз кылса, шиксез, минем артымда кылган намазымның савабы кебектер», — диде.

Белермез барча мәсех мүзәне (итекне)
Хәкь Ничек кем кылды тәгъйии шаһ әсдак.

Ягъни игътикадны Хактан (Аллага ышанудан) белербез, ике читек өстенә мәсех ясауны. Пәйгамбәр г-м боерды, ике читеккә мәсех кылыгыз», — диде. Әйттеләр, ике читеккә мәсех кылмакта анар эйдән (әйчкон) кемсәнәгә зәвале иманда (иманның бетүендә) хәүф вардыр. Нәгузе биллаһи (Ходай сакласын). Һәм әйттеләр, хәле җиткән кеше аягын юып укудан мәсех кылып уку яхшырак, — диделәр...

## Әүлияләрнең кәрамәте бәяны

Ирер бер Хәкъ кәрамәт әүлиядин,
Гыйнаятьдер вәлиләргә Ходадин.

Ягъни әүлияләрнең кәрамәте (изгелеге, могҗизага сәләте) чын. Ул кәрамәт әүлияләргә Аллаһ Тәгаләнең бер ярдәме. Мохтаҗ булган вакытларында бирелә.

Кәрамәт харак гадәт ирер исем,
Булыбдыр харак гадәт ничә кыйсем.



www.darul-kutub.com

Ягъни кәрамәт дигәннең мәгънәсе, гадәттә, юк эшне бар итүдер. Әмма гадәткә каршы килүче эшне башкаручылар берничә төрле. Аларны сөйләп бирдек.

Нәбидин харак гадәт тәгъйин, —
Диделәр могҗиза, и талибе дин (дин шәкерте).

Ягъни әгәр дә пәйгамбәрләр гадәткә каршы эшне күзгә күрсәтсәләр, аны могҗиза дип әйтерләр. Әй дин өйрәнүче кеше, гадәткә каршы килүче эшләр болар: бармаклардан су агызу, һәм һавада очу, һәм агачлар, кошлар белән сөйләшү. Бәс, бу эшләр пәйгамбәрләрдә күренсә, могҗиза дип әйтерләр. Мәгънәсе — гакыл аннан гаҗиз [мәхрүм] булу.

Нөбәүәтдин[1] борынны ди(е)рләр ирһас (әрһас?)
Моны белсә кирәкдер әййүһан-нас.

Ягъни пәйгамбәрләргә пәйгамбәрлек булганчы, моның кебек гадәткә каршы эшләр күренсә, аны ирһас дип атарлар. Әй адәмнәр, нитә ки безнең пәйгамбәребез яшүсмер чагында угланнар белән уйнап йөргәндә, бер йөзем агачы яшәреп, җимеш бирде. Угланнар, ашап, тамакларын туйдырдылар. Бәс, пәйгамбәрлек булганчы моның кебек эшләр күренсә, ирһас дип аталыр. *Ирһас* мәгънәсе — пәйгамбәр булуга дәлил димәктер.

Әгәр салих (изге) кешедин булса һәр гяһ,
Кәрамәт диб болар, бишик вә әшбаһ.

Ягъни әгәр суфый һәм тәкъва булганнарда моның кебек эшләр күренсә, аны кәрамәт дип әйтерләр. Һичшиксез һәм шөбһәсез, кәрамәтнең мәгънәсе хөрмәтләүдәдер, ягъни Ходай Тәгалә бу суфыйның камил ихласлыгы өчен бу гадәткә каршы сәләтне хөрмәтләп бирә, башкача түгелдер.

Күренсә бу гавам мөэмин кешедин,
Мәгунәтдер (ярдәмдер) ушал әйган (әйткәң) кешедин.

---

1 Нөбәүвәт — нәбилек. С.-П.да бу сүз «бәнәүвәт» дип язылган (78 б.)

Ягъни бу кәрамәт кебек нәрсә тәкъва булмаган кешеләрдә, ягъни үзе мөселман, ләкин тәкъва түгелләрдә күренсә. Аннан сулар агызу һәм су өстендә йөрүләр күренсә — аны мәгунәт дип әйтерләр, кәрамәт димәсләр. *Мәгунәт* сүзе мимнең (мим хәрефенең) фәтхәсе (өс билгесе) белән языла, ярдәм мәгънәсен белдерә. Ягъни Аллаһ Тәгалә аңа ярдәм итеп бирде, ничек икәне беленмәде, я тәкъвалыктан аңа ярдәм ителде, я бик тә фасикъылыгыннан (бозылганлыгыннан) ярдәм ителде, я бик тә һөнәрмәнд (һөнәр иясе) булуыннан бирелде. Бу хәйлә ителде: беленмәгәне өчен мәгунәт дип аталды[1]...

Әгәр күрсәтсә моңдаг кяфере инсан,
Ул истидраҗ манәндә шәйтан.

Ягъни кәрамәт кяфердән күренсә, аны истидраҗ дип атарлар. Шәйтанда да гадәттән тыш күрелмәгән гадәт юк: кояш та көнбатыштан көнчыгышка йөрмәгән кебек, ул да бер сурәттән икенче сурәткә керми. Боларны истидраҗ дип атарлар. *Истидраҗның* мәгънәсе — дөньяда теләгәнен биреп, ахирәттә тәмугта дәрәҗәсе артуда.

... Вәли ул гариф, билләһ, лса,
Яман эшдин кулы(н) кутаһ (кыска) кылса.

Ягъни әүлия шул: Аллаһы Тәгаләне аның сыйфаты сәлбия һәм затияләр (...асыл сыйфатлары) белән бергә танучы, шәригать кушмаган эшләрдән кулын ерак тотучы кеше шушы сыйфатлары белән әүлия була.

Ул әмерне һәмишә (һәрчак) кылса ул кол,
Тәкый кылма дигәнне кылмаса ул.

Яраткан Тәңренең куркынычыин низ (шулай ук),
Кай шөбһә дигәндин кылса пәрһиз (тыелса).

Ягъни Аллаһ Тәгалә ни боерган, шуны үтәсә һәм кушмаганнарыннан тыелса һәм нәфес һавалыгына буйсынмаса һәм зиннәтле дөньяга тугры булмаса.

---

1 С.-П. да — аталынды (79 б.)

Тәкый ләззәт белән шәһвәткә, әй йар[1],
Фәрүһәм (?) китмәсә, ул яхшы кәрдар.

Ягъни ул изге кеше ләззәтле нәрсәләргә алданмаса һәм нәфесенә иярмәсә, нәфес артыннан бөтенләй дә йөрмәсә, — ул яхшы эчле кеше.

Бу тәгърифләр кешегә булса садикъ (дус),
Вәли улдыр гакаидка муафикъ.

Ягъни бер кеше бу әйтелгән шартларга туры килсә, ул вәлид һәм хак иман әһеленә туры киләдер...

Һавада әһле тәкъваи итсә тайран
(Күктә изге затлар очып йөрсә),
Кәрамәт улмасында улма хәйран...

Болар әмсалы чукдан әүлия дә,
Зоһур харык гадәт эткыядә
(Изгеләрдә искитмәле гадәтләр булып тора).

Шәригатьсез кеше очса һавага,
Күңел куймак аның дик худнамәгә (үз-үзен бөек күрүчегә)

Ягъни берәү, шәригать кушканны буйсынмыйча һәм аныңча эшләмичә, могҗиза күрсәтеп, һавада кош кебек очып йөрсә, аңа өметләнеп, кәрамәт дип әйтмә; ул тәкәббернең эшенә хәйран калма, кошлар һәм чебеннәр дә бит һавада очарлар. Аларга игътибар ителмәгән кебек, моңа да игътибар ителмәс.

Һавада очса манәндә чебендер (чебен кебектер),
Аны һади (юл күрсәтүче) димә, - шәйтандыр.

Ягъни берәрсе һавада очса, үзе шәригатьне белүче булмаса, аның очуы чебеннеке кебек кенә, аңа игътибар юктыр. Син аны күндерүче вәли димә, шәйтан төркеменнән булган кеше дип әйт.

---

1 С.-П.да — һәр бар (79 б.)

Шәригатьсез кеше гәр йотса утны,
Һава уртасында менсә болытны.

Ягъни шәригатьне үтәмәгән бер кеше ут йотса һәм агулар эчсә дә, аны кәрамәт димә, һәм һавага менеп, болытларда йөрсә дә, ышанма — кәрамәт түгелдер.

Кайчан табкан ирер корбәт (якынлык) идне,
Вәли белмәң тәкый андаг кәдне.

Ягъни изге булмаган кеше кайчан Хак Тәгалә хәзрәтеннән ис табар, шундый коры агачны вәлигә санама. *Идине* дигәне ис мәгънәсендә, төрки сүз һәм болгар халкы аны ис һәм әйс дип әйтә. *Кәдне* дигәне хәрәкәсез дәл хәрефе белән языла, ул аршын зурлыгындагы бер агачның исеме. Ишәк коерыгыннан тартып, іяре төшмәсен өчен, ике як кабыргасыннан бәйлиләр. Ләкин бу урында буш, коры мәгънәсендә истигария (метафора) итеп алынган...

Булыбдыр мондаг эшләр кяфердин,
Ничек кем булды сихер Самиридин.

Ягъни мондый шәригатьсез могҗиза гадәтләре кяферләрдән булды. Аеруча мәшһүр: Самири (лунатик) сихерченең сихере. Ул, бозау рәсеме ясап, аны тәңре итеп, күп кешене кяфергә әйләндерде.

Сөйләүләр буенча, Муса г-м көннәрдән бер көнне халкына әйтте: «Сез мине[1] юксынмагыз, мин Тур (Синай) тавына барам, Хак Тәгалә белән сөйләшәм. Сез утыз көн буена көтегез. Утыз көн тулмыйча, мин кайтмам», - дип, кавеменнән китте. Муса г-м уразада иде. Өендә мисвакын (теш щеткасын) онытып калдырды. Озак вакыт ач тору сәбәпле, авызы сасыды. Фәрештәләр аңа әйттеләр: «Йә Муса, синең авызыңнан нинди сасы ис килә? Элегрәк авызыңдан хуш исләр генә килә иде», — диделәр. Муса г-м бу сүзләрне ишеткәч оялды һәм әйтте: «Йә Раббым, әгәр син минем авызымнан сасы исне алсаң, утыз көннән артык ун көн ураза тотырга нәзер әйтәм», — иде. Изи гыйззе үә җәлл (Аллаһ) догасын һәм нәзерен кабул итте һәм начар исне бетерде...

1 С.-П.да — бәне (81 б.)



www.garul-kutub.com

## Самири хикәяте

Муса г-мнең Самири (Самари) исемле бер шәкерте бар иде. Тыштан иман китерсә дә, эчендә кяфер иде. Бу Самири, Муса г-м Тур тавына киткәч, балчыктан бер бозау рәсеме ясады. Эчен тылсымлар белән ясап, бозаудан тавыш чыгартты. Һәм әйтте: «Йә халык, бу бозауны тәңре дип әйтегез», - диде. Халкы әйтте: «Муса пәйгамбәр безгә мондый нәрсәләргә табынырга кушмады[1]». Самири әйтте: «Мусаның тәңресе һәм сезләрнең тәңрегез шушыдыр», - диде. Мусаның кардәше һәм бәни Исраилның өлкәннәре әйттеләр: «Без Муса пәйгамбәр Тур тавыннан кайтмыйча табынмабыз», - диделәр... Сөйләүләр буенча, ләгыйнь Самири ул бозауның эченә тылсым ясамады. Җәбраилнең аяк баскан туфрагын салды. Җәбраил Фиргавен[2] кавемен һәлак иткән вакытта бер биягә атланып килгән иде. Фиргавен исә айгырга атланган иде. Фиргавеннең айгыры, Җәбраил атланган бияне куып, Нилгә керде. Аның артыннан куып кереп, бөтен кавеме һәлак булды. Шул вакытта Җәбраил баскан җир яшел төскә булып тора иде. Бу Самири ләгыйнь бер уч туфрак алып калган иде. Шул заманнан бирле шул туфракны саклый иде. Кайчан бозауны ясады, ул туфракны бер алды, бер кире салды. Әлкыйсса (шуның белән бетте).

Көннәрдән бер көнне Муса г-м Тур тавыннан кайтты һәм күрде: халкы, саф-саф булып, бер бозау алдында сәҗдә кыла. Үзе киткәч халыкның азуын, бозауның тәңре итеп тотылуын белде. Муса әйтте: «Йә халкым, явызлык эшләүче булдыгыз, бозауны тәңрегә тиңләдегез»... Ә кавеме әйтте: «Йә Муса, — Аллаһның рәсүле, бу тәңре түгелме?» — диделәр. Муса әйтте: «Тәүбә итегез»,- диде... Шуннан бу халык тәүбәгә килде. Изи гыйззә үә җәлл тәүбәләрен кабул итте. ... Аннары Муса г-м бозауны ут белән яндырып һәлак итте. Бозавы янында Самирины төрлечә мәсхәрәләде.

Әйтәләр ки, Муса г-м, Самири ләгыйньне үтерергә теләп, сакалыннан тотып алып килде. «Дар агачына асып үтерермен», — дигәндә, Җәбраил күктән төште һәм: «Йә Муса, Самирины үтермә, чөнки ул юмарт кеше», — диде.

---

1 С.П.да — куймады (81 б.)

2 Фиргавен — Вәлид бине Мусаб дигән хөкемдарның кушаматы. Ул Муса пәйгамбәр вакытында Мисыр белән идарә итә. Үзенең кансызлыгы, рәхимсезлеге белән дан тота.

Шуннан соң, Муса г-м аңа ләгънәт әйтте һәм аны: «Бәни Исраил арасында яшәмә, — дип чыгарып җибәрделәр һәм моннан соң ул һичкемнең янында утырмады.

Сахраларда йөреп, ачлыктан үлде, дип әйтәләр. Бу хикәя озын иде. Кыскарту сәбәпле тәмамланды. Гакыл ияләренә бик гыйбрәтледер.

## Фиргавен хикәяте

Ишеткел, бәлки, Фиргавен әмередин Нил
Коедин югарыга акды би кыйл (тавышсыз).

Ягъни, ишет, Фиргавен... Нил суын астан югарыга, ягъни үргә таба агырга мәҗбүр итте. Моның кебек изге булмаган кешеләр вәли дип саналмас. Әйтәләр ки, Фиргавен үзен тәңре дип игълан итте. Өч төрле гаҗәеп эше бар иде. Хак Тәгалә аларны аңа истидраҗ өчен биргән иде. Беренчесе шул: Нил елгасының бер кисәге үзе белән йөрде. Фиргавен кайда барса, елга да шунда бара иде. Фиргавен туктаса туктады; йөрсә йөрде. Икенчесе шул: Фиргавеннең Кәффах исемле аты — акбүз[1] айгыры бар иде. Бик тиз йөгерә һәм очып барган кошны куып тота иде. Фиргавен аңа атланып йөргәндә, тауга менгәндә, атының арт аяклары озын, ә таудан төшкәндә, алгы аяклары озын була иде. Тигез җирдә йөргәндә исә, дүрт аягы тип-тигез тора иде. Өченче гаҗәеп эш шул: буе җиде карыш һәм сакалы сигез карыш иде. Шулай көннәрдән бер көнне Нил елгасының суы корыды. Өч ел буена Нилдан су акмады, ашлык, таригъны сугара алмадылар. Мисыр халкы Фиргавеннең ишек төбенә җыелды. «Әй, безнең тәңребез, безгә Нилдан яңгыр яудыр һәм Нилдан су агыз! — диделәр. — Әгәр бу эшне үтәмәсәң, без сине тәңре дип әйтмәбез, Мусаның тәңресенә иман китерербез». Шуннан Фиргавен халкына вәгъдә бирде: «Сез, яраннарым, иртән торып, сәхәр вакытында фәлән урынга җыелыгыз», — диде. Барлык яраннар да хатын-кызлары һәм бала-чагалары белән бергә сәхәр вакытында җыелды һәм шуннан соң Фиргавен әйтте: «Сез монда торыгыз һәм, башыгызны ялангач[2] калдырып, ягъни баш киемнәрен салып, миңа сәҗдә кылыгыз». Барчасы шуннан сәҗдәгә китте.

1 К.да — бүз айгыр (55 б.).
2 С.-П.да — ялан (83 б.)

Фиргавен лəгыйнь ул урыннан күчеп, бер аулак урынга керде, башлыгын салды һəм сакалыннан тотып, үзен үзе бер ташка асып куйды да əйтте: «Йə Раббым, синең этлəреңнəн бер эт мин, мине төрле нигъмəтлəрең белəн бу көнгəчə тəрбиялəдең һəм мине юктар бар иттең һəм дөньяда телəгəн нəрсəлəремне бирдең. Инде, зинһар, мине халкым каршында рисвай (хур) иттə, дөньяда телəгəнемнең барчасын бир һəм ахирəттə булачак хөрмəтлəрең миңа кирəкмəс», — дип зар елады. Күктəн аваз килде: «Йə, мəлгунь, телəгеңне кабул иттем». Шул вакыт Нилга су килде һəм аның бер тармагы Фиргавен алдында[1] туктады. Фиргавен елга башына юнəлде, су артыннан барды. Ул халкына дəшеп: «Йə, кавем, белегез, мин сезгə өч ел буе суны бирмəдем, чөнки сез миңа бик күп гөнаһлы булдыгыз, ə инде хəзер тəүбəгə килдегез һəм мин тəүбəгезне кабул иттем», — диде. Өч елдан соң Фиргавен суга батып үлде, дип сөйлилəр. Шул рəвешле, мондый кяферлəрдəн күренгəн нəрсəлəрнең кəрамəт түгел, ə бəлки тиешле нəрсəлəрнең үтəлүе генəдер. *Кое* дигəне кайбер төрки теллəрдə түбəн мəгънəсен белдерүче сүз.

Моны, белгел ки, Һиндустанда хала,  
Очар гяһ кяфернең сəннасы бала.

Ягъни, моны белегез, Һиндстан илендə кайбер кяферлəр күктə очалар, бу хəзер дə билгеледер. Сөйлилəр ки, һинди кяферлəрнең кайберлəре, озак вакыт ач торып, кешелəрдəн читтə, тау тишеклəрендə яшилəр. Анда ачлык белəн яшəп, кешелəр белəн сөйлəшмилəр. Озак вакыт ач торганнан соң, бу кешедə рухи көч барлыкка килə, ə матди куəт (тəн куəте) бетə. Аннары алар күк йөзендə очалар. Бу гаҗəеп эш түгел. Хак Тəгалə аларга бу куəтне истидраҗ буларак бирəдер.

...*Синнасы* баштагы син хəрефенең кəсрəсе[2] белəн һəм нун хəрефенең тəшдиде белəн языла, Сəмəрканд халкы телендə тəн сүзен белдерə. Мəгънəсе — Һиндстан кяферлəре арасында кайчак кайберəүлəренең һавага очуы күнегүлəр нəтиҗəсе белəн.

www.darul-kutub.com

1 С.-П.да — үгендə (84 б.).
2 С.-П.да бу сүз шигырьдə фəтхə тамгасы белəн язылган (84 б.).

... Шәригать хөкмен әйтмәй истикамәт (нык итеп),
Тәгаҗҗеб эшләре булмас кәрамәт.

Ягъни ...шәригать хөкемнәренә тугры булмаган кешеләрдә гаҗәеп эшләр күренүе кәрамәт түгел. Нитә ки югарыда бәяннәре китерелде.

Шәригатьне кеше кем тотса хуб пас,
Кәрамәт мондиг үтмәс әййүһан-нас.

Ягъни берәү шәригатьне камил итеп тотса, кәрамәт ул кешедән ерак булмас[1], әй шундый кешеләр, ди. *Пас, паи* фарсыча камил мәгънәсендә яки хуб сүзенең гатыф аңлатмасы, синоним сүзләр. Рифма, шигырь өчен китерелде. Әмма барлык сүзләр фарсыда китерелгәндә пас камил мәгънәсендәдер дип.

Хилафе нәфес — истикмале тагать,
Булырмы мондин артык хәркы гадәт.

Ягъни берәрсе нәфес әмеренә каршы килсә һәм буйсынуын вә гыйбадәтен камил башкарса, ярамаган эшләрдән һәм хәрамнәрдән сакланса, моннан да олырак кәрамәт булмас. Әйтәләр ки, берәү нәфесен үтерсә һәм дөнья зиннәтләреннән бизсә, Аллаһ Тәгаләдән[2] башка һичнәрсәне теләмәсә вә Аллаһыга буйсынуны шәригать әдәпләре кушканча үтәсә, һичшиксез, моннан артык олы кәрамәт булмас, диделәр.

Кеше дисә вәли ни гайбдәндер,
Нәгүзе билләһ, ул сүз күб ямандыр.

Ягъни берәрсе: «Әүлияләр күренмәгән нәрсәләрне һәм кешеләрнең күңелендә булганны белә» дисә, Аллаһы Хәзрәткә сыенамын, чөнки бу сүз яманнарның яманрагыдыр.

Нәби һәм белмәгәй ошбу рәвешдин,
Мәгәр белдерсә Тәңрем бәгъзе эшдин.

---

1 К.да — үтмәсдер (56 б.)
2 С.-П.да ма сиваи Аллаһудан (Алладан башка) (85 б.)

Ягъни пәйгамбәрләр дә бу рәвешле яшерен булганны белмәделәр. Мәгәр белсәләр дә, кайбер эшләрне Җәбраил аша белделәр. Зирә ки яшерен булганны белү Изи гыйззе үә җәллнең үзенә генә хастыр...

Ходаның хассәседер гыйлме гайбе (серләрне белү),
Бу сүздә булмагай бер зәррә рибе (бер тамчы шик).

Ягъни яшерен булган әйберне белү Ходай Тәгаләнең үзенә хас сыйфат. Бу сүздә бер тамчы шик булмас...

Якыйн белгел ки, гайб эшдән фал беләнләр,
Хәбәр бирсә әгәр я әһле җеннәр.

Ягъни, шикләнмә, берәрсе фал ачып яшерен булганны хәбәр итсә, яки җеннәр, килеп, аңа хәбәр бирсәләр һәм аннан күргәнне һәм ишеткәнне кешеләргә хәбәр итсә.

Кеше чын дисә ул батыйль (ялган) сүзне,
Булыб кяфер кара кылгай[1] йөзене.

Ул биргән хәбәргә ышанып, ул ялган сүзне дөрес дип әйтсә, чыннан да, ул кяфер булды, кыямәт көнне йөзе кара булыр, кяфер гөруһындан үлеп, иманыннан мәхрүм калыр. Әйтүләр буенча, ул вакытта җеннәр һәм пәриләр, күкләргә менеп, фәрештәләрдән сүзләр урлап, җирдәге мөнәҗҗимнәргә (йолдызчыларга) һәм күрәзәчеләргә хәбәр итәләр иде. Безнең пәйгамбәребез дөньяга килгәч, фәрештәләр аларны күккә уздырмадылар, күктән ут алып аттылар... Ул заманда мөнәҗҗимнәр китаплар чыгарды, дип әйтәләр. Бу заманда берсе дә дөрес түгел. Әйтәләр ки, әгәр дә җеннәр яшерен хәлләрне белсәләр, Сөләйман пәйгамбәрнең дә үлгәнен аңларлар иде. Зирә ки Сөләйман пәйгамбәрнең үлгәнен белмәгәннәре аркасында, ул үлгәч тә өч ел Бәйтелмөкаддәсне (Кодес шәһәрендәге гыйбадәт йортын) төзеделәр һәм наданлыклары сәбәпле агач кортын... тотып, Сөләйманның таягын кистереп екканнан соң, үлгәнен белделәр. Бу чын ахмаклыклары аркасында иде. Бу турыда кыйссалар күп, тик барын да язырга вакытыбыз таррак.

---

1 С.-П.да — кяфра кылгай (86 б.)

Якыйн белгел ки, бәгъзе нә мөселман, —
Димеш вакты ки, корбәт (якынлык) табса инсан.

Ягъни бик тә сөекле бәндәсеннән Хак Тәгалә шәригать хөкемен алыр, ягъни биш вакыт намаз һәм ураза тоту аңа фарыз түгел, дип әйтерләр. Болай дигән кешенең йөзе кара, үзе кяфер булыр, димәк. Ягъни динсез дигән бер кавем әйтер: «Аллаһ Тәгалә бер бәндәсен бик нык сөйсә, аңа фарыз гыйбадәтләр фарыз түгел, аның гыйбадәте күңелендә, гыйбадәте заһира аннан алынган, һәм ул сөекле колы гайбәт вә яла һәм ялган сөйләсә, гөнаһ булмас дип әйтерләр һәм хатыннарына җимаг (интим мөнәсәбәтләр) кылдырырлар. Аларның карашлары ялган булганга, болай боерды:

Бу батыйль сүз ирер, колы мәлахид (динсез кол),
Шәригатькә ирер ул фирка җахид (каршы).

Ягъни бу югарыда әйтелгән сүзләр динсез диелгән җәмәгатьләребезнең шәригатьне инкарь итүчеләредер. Аңарга ышанслар, кяферләрдер.

Кеше булмас мокаррәб (якын, дус) әнбиядән,
Илля бизар ирер гаҗб, риадин.

Ягъни Аллаһ Тәгаләгә пәйгамбәрләрдән якынрак булмаслар. Мәгәр Аллаһ Тәгаләгә якын булсалар, масаюдан һәм риядан бизәр иделәр, ягъни аларда гомумән рия һәм гоҗб булмас. *Гоҗб* шул: гыйбадәтем бик күп дип мактану. *Рия* дигәне гыйлемне кешегә күрсәтү. Бәс, исеңдә тот: бу бәетнең рифмасы «мә йәкүн әл-инсану илля натика» төреннәндер. Бәетнең өске юлы фәгалә рисмасында. Соңгысы чыгармадыр. Кайберәүләр илля бизар дигәнне алар бизар дип укыдылар. Бу күренеп торган хата...

Күтәрелмәде үлгүнчә алардин,
Хода һәргиз күтәрмәс үзгәләрдин.

Ягъни пәйгамбәрләрдән дә, алар үлгәнче, Аллаһ Тәгалә шәригать хөкемен алмады. Бәс, бары тик әүлияләрдән

күтәрү каян?! Бәлки Аллаһ Тәгалә алардан күтәрмәстер. Аллаһ Тәгалә дуслары әүлияләрдән кайчан күтәрүе билгеле.

Мөхәммәд кем мәхәббәт кяне ирде,
Хәбибе Хәкъ рәсүле солтаны ирде.

Ягъни Мөхәммәд г-м - Аллаһ Тәгалә сөюенең хәзинәсе (кяне) һәм пәйгамбәрләрнең падишаһы иде.

Китәр вакытыда андаг булды хали,
Возуиларга (тәһарәт алырга) юк ирде мәҗали.

Ягъни Мөхәммәд г-м ахирәт йортына китәр вакытында, аның тәннәре агарып, тәһарәт алырга мөмкинлеге калмыйча, көчсез булды.

Ишетде чөн азан ба бәшарәт,
Диде: «Я Гайшә, кылдыргыл тәһарәт».

Ягъни пәйгамбәр г-м, азан тавышын ишеткәч, үзенең хатыны Гайшәгә: «Йә Гайшә, миңа тәһарәт алдыр, зирә ки минем тәһарәт алырга хәлем калмады. Аннары мәсҗедкә барам», — диде.

Тәһарәтдин ул шаһы олылгазм,
Җәмәгатькә барырга әйладе җәзм (катгый рәвештә).

Ягъни Гайшә тәһарәт алдырганнан соң, сабырлык шаһы — пәйгамбәребез җәмәгать намазына барырга теләде. Олылгазм дигәне матурлык өчен. Мәгънәсе — сабырлык падишаһы.

Кадәм басмай торыб китде үзедин,
Гаркын сәйәлан әйладе («тир акты») гөл тик йөзендин.

Ягъни пәйгамбәр г-м, җәмәгать намазына барырга дип, теләк белдергән иде. Аягүрә баскач егылып китте, ягъни авыруының көчлелегеннән үзен-үзен тота алмады. Гөл кебек йөзеннән тир акты һәм ул һушын югалтты.

Үзигә килде, баз (кабат) итде тәһарәт,
Янә кубды[1] ки та табкай җәмәгать.

Ягъни янә һушына килде һәм әйтте: «Йә Гайшә, тәһарәт алдыр». Гайшә тагын тәһарәт алдырды. Тәһарәт алганнан соң, пәйгамбәр г-м тагын җәмәгать намазына барырга теләк белдерде. Җәмәгать савабын табам, диде.

Кадәй басмай торыб ул сахибе раз,
Үзедин китде дәрман юкдин баз.

Ягъни янә җәмәгать намазына барырга теләгән чакта, тагын һушы китеп егылды. Ул сәр юлдашы пәйгамбәребез җәмәгать намазына барырга өч тапкыр тырышып карады, тик бара алмады. Ахыр чиктә өендә намаз укыды. Күрәсеңме: шундый олуг шаһтан да, үлемгә якын булган хәлендә дә, Аллаһ Тәгалә фарызларны киметмәде. Бәс, башкалардан киметсен, нитә ки ишарә ясап болай боерды:

Нәфес (сулыш; тын) чыкгунча (чыкканчы) та котлуг тәндин,
Хилаф итмәде бер кыл әйганедин.

Ягъни пәйгамбәр г-м, тәненнән мөбарәк җаны чыкканчы, әйткән сүзеннән баш тартмады һәм бер төк күләмендә дә хилафлык ясамады.

Аның дик Мостафа куркынычыдин ул
Возуә кылды (тәһарәт алды), үзедин китде өч юл (тапкыр).

Ягъни шулай галәмнең хуҗасы һәм яшәешнең мәшһүр кешесе Хәзрәте Мостафа Аллаһ Тәгаләнең боерган әмере булганга һәм куркуы аркасында өч мәртәбә җәмәгать намазына барырга теләде, өч тапкыр һушы китеп егылды. Күрәсезме: шундый олуг падишаһ Ходайдан куркуыннан ни эшләде. Син дә курык, Аллаһның боерганына каршы

---

1 С.-П.да — газм кылды (88 б.)

килмә. Күрәсеңме, шәригать галимнәре намазны басып укырга, хәле булмаса, утырып укысын, диләр. Алай да хәле булмаса, ятып укысын. Аңа да хәле җитмәсә, ишарәт белән укысын, үлгәнче, күңеле белән ничек тә булса, шәригать әмерен калдырмасын.

Сөеклек бәндәсе табылса мәхрәм (якын; дус),
Булыр куркынычы артык, гыйшрәте кәм.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең сөекле бәндәләренең куркулары безнекеннән[1] артык булыр һәм дөнья рәхәтлекләре [аларда] артмас. Аллаһ Тәгаләгә якынрак булган саен, куркынычлар артыр.

Әгәрчә әнбийа, бишик (шиксез), әмандыр,
Мөбарәк делләре хәүф илә кандыр.

Ягъни пәйгамбәрләр, һичшиксез, әманлы, ягъни аларның иманы бетү куркынычы юк һәм тәмуг аларга хәрам. Шундый булсалар да, мөбарәк күңелләре Аллаһ Тәгаләдән куркуга тулы.

Вәли өммәт әгәр гаусе замандыр,
Исән китмәке ахырдыр, гөмандыр.

Ләкин өммәтләренә рәхмәт яңгырлары яуса да[2], соңгы сулышта имансыз китүләре турында уйлыйлар һәм шикләнәләр. Күрәсеңме, кайбер суфыйлар дөньядан имансыз киттеләр. Хикәятләре билгеледер. *Гаус* дигәне яңгыр дигәнне аңлата. Рәхмәт яңгырын гаус, ә башка яңгырларны мәтар диләр. Рәхмәт яңгыры дип әйтергә теләгән нәрсә — пәйгамбәр дәвере. Аның дәвере кыямәт башланганчыга дәвам итә. Бәс, үлгән кеше хәвеф һәм өмет иту арасыда булып, үзеңне түбәннәрдән дип күрү кирәклеге беленде.

Әгәр галәм йаруса (яктырса) сән сәбәбдин,
Кояш дик тетрә даим хәүфе Раббыдин.

1 К.да — безнең куркуымыздан (59 б.).
2 С.-П.да — «өммәтләрдә рәхмәте пәйгамбәр бичукдыр; рәхмәте пәйгамбәрнең эчендә дорсалар да...» (89 б.).

www.darul-kutub.com

Ягъни синең дөнья халкы яктырып, нур алып торсалар да, син, кояш кебек, Аллаһ Тәгаләдән һәрдаим куркудан калтырап тор. Нитә ки кояш Аллаһ Тәгаләдән куркуы аркасында калтырап торадыр. Сорау: «Кояшның Аллаһ Тәгаләдән куркып калтыравын каян белдең?!» Җавап шушыдыр: «Бер савытка су салып, кояшка таба[1] куйсаң, кояшның нуры шул савытка төшәр. Аннан нур калкып, түбәгә төшәр. Ул түбәдә нур калтырап торыр. Кояшның калтыравы шуннан беленде». Һәм икенче җавап шушы: пәйгамбәр г-м әйтте: «Кояш Аллаһтан куркып калтырады. Бәс, мәртәбәсе зур булган кешенең хәвефе күбрәк икәне билгеле булды»...

Кирәк галийе кәрәмнең хәүфе күбраг (күбрәк),
Биек йирдән екылган калмагай саг.

Ягъни Хак Тәгалә хәзрәтенә якын булып, мәртәбәсе олуг кешенең (галийе кәрәмнең) күбрәк куркуы кирәк. Чөнки берәү түбәдән егылса сакланмас, сөяге уалып, һичнәрсәсе калмас. Шуның кебек берәрсе Аллаһ Тәгаләгә якын булып, аннары куылса, шулай булачак. Нитә ки иблис, аңа ләгънәт төшсен, шундый булды...

Олуг тотмас кечек дик[2] мәзһәбен киң,
Тәвә (дөя) таймагы ирмәс куй белән тиң.

Ягъни зур әйбер белән кече нәрсәнең таюы бер түгелдер. Кинәт, барганда, куй таеп егылса, аның таюы гаҗәеп түгел. Әмма дөя таеп егылса, кешеләр моңа гаҗәпкә калып көләрләр. Шуның кебек бер олуг изге кешенең кире кагылуы гади түгелдер, ягъни олуг булган кеше хата эш эшләсә, халык аннан гаҗәпләнеп калыр. Ә гади кешеләрнең эшләгән эшләре гаҗәп булмас, олуг кешене исә хәвефе күбрәк булыр.

Тәвәһһем ләк [куркуы йөз мең (күп)] булыр әфгале хубның,
Сәфәрдә хәүфе күбрәк малы күбнең.

---

1 С.-П.да — кояш таба (90 б.).
2 С.-П.да — кечекдәк (90 б.).



www.darul-kutub.com

Ягъни изге гадәтле кешенең куркуы күбрәк булыр, нитә ки мосафирларның берсендә малы күбрәк булса, ул кешенең каракларадан һәм юлбасарлардан хәвефе күбрәк булыр.

Тәвәффемдин ерак гафләти бәндә,
Китәр госса (кайгы) белән гамь уйухлаганда[1].

Ягъни Аллаһ Тәгаләдән куркуыннан гафил кеше, үлем йокысы килгәндә, кайгы-хәсрәт белән китәр. Яки мәгънәсе болай булыр: Аллаһ Тәгаләдән куркудан ерак булган кешенең мисалы шундый: йоклаган кеше кайгыдан ерак булып торса, ахыр чиктә кайгылы булыр димәк. Әмма беренче мәгънәсе җиңел[2]. Бу шигъри юллардан шунысы мәгълүм булды: әүлияләр шәригатькә каршы эшләр башкармас, нитә ки югарыда язылды һәм безнең заманда ишаннар шәехлеккә дәгъва кылалар. Тик күбрәге ялган шәехләр. Байлык туплаларга һәм хатыннар алырга телиләр һәм дөнья зиннәтләре белән бизәнгәннәр, кәсеп итмичә, халык кулына карап, халыктан тартып алырга гына ниятлиләр. Кайчан берәүнең Аллаһыга тапшырылып, соңрак күзенә дөнья малы күренүе булды?! Бәлки, ул сөйгәненең ризалыгын теләр. Вә әйтәләр: «Безнең шәехемез гайбәт сүз сөйләсә дә, гөнаһ юк, — диләр. — Чөнки шәех мөридләрен сынарга тели». Бу да ялган. Әгәр болай ышанылса, югарыда искә алынган динсезләр мәзһәбенә керә һәм алар төркеменнән була. Чөнки гайбәтнең хәрам булуына аять инде. Ул аять барлык кешеләргә дә карый. Шәехләргә гайбәт вә ялган сөйләү хәләл дип әйтелмәде. Һәм әйтәләр, дөнья зиннәтләре безнең дини җитәкчеләребезгә хәләл дип, чөнки Хәзрәте пәйгамбәр г-м кыйммәтле туннар киде, диләр. Әйе, җавап шул: ул Хәзрәт андый кыйммәтләр киде, чөнки үзенең шөгыле белән газиз башын, үлемгә куеп, үз-үзен аямыйча кяферләр белән сугышты һәм сәүбә итте. Сезнең кебек кул күтәреп тормады.

Шәех Җөнәйддән[3] сораганнар: «Суфыйның тәгърифе нәрсә?» Җавабында күрсәтте.. «Суфи — ул саф

1 К.да — ухлаганда (60 б.).
2 С.-П.да — әсһәл (җиңел) (91 б.)
3 Шәйх Җөнәйд, Әбелкасыйм... Әл-Багдади (910 елда вафат була) — атаклы суфый, дини мәзһәбкә нигез салучы. Ул аеруча үзенең «камил инсан» (бәгъдәл-фәна...) тәгълиматы белән мәшһүр.



www.darulkutub.com

калебле...» Шәех Шиблидән[1] сорадылар: «Суфи ул кем?» — дип. Җавабында исә әйтте: «Суфи дүрт хәреф мәгънәсенә туры килсә суфыйдыр. Алай булмаса, Куфа шәһәренең эте мең суфыйдан артыграктыр», — диде. «Сад» хәрефе сафа дигәннән гыйбарәт. «Вау» вафадан гыйбарәт. «Фи» фәнадан гыйбарәт. «Йә» якыйннан гыйбарәт. Сорау: «Суфый шәригатькә туры булмаган суфиларны ни өчен Куфа шәһәре этләренә тиңләмәде?» Җавап шул: Куфа этләре Хәзрәти Имам Әгъзам үтеп барганда тавышланмыйлар һәм аның юлына чыкмыйлар иде. Бер-беренә исә: «Әдәп белән торыгыз. Хак Тәгаләнең балкыш нуры төшкән бәндәсе алдында әдәп саклагыз, ул шәригать әдәбе кушканча Хак Тәгаләгә коллык итә», — диләр иде. Шул сәбәпле шәригатькә тугры булмаган суфиларның дәрәҗәсе[2] Куфа этләренә тигез булды, һәм бу охшату түбәнсетү өчен киная. Шәехләргә тиешле шартлар, Алла теләсә, түбәндә искә алыныр (Биредә Суфый Аллаһиярның суфилар турында берничә бәет шигыре шәрехсез генә китерелә).

## Әҗәл бердәмлеге бәяны

Әҗәл, әлбәттә, бердер, үзгә булмас,
Үләр һәр зинәфәс (җаны бар) һәргиз (һәрчак) ул улмас.

Ягъни сөннәткә иярүчеләр карашы буенча әҗәл бердер, бердән артык түгел, һәм барча җаннар үләчәк. Аллаһ Тәгалә үлмәс, ул үлемнән азаттыр. Берәүне берәү үтерсә, һичшиксез, ул үлгән кешенең әҗәле җитеп үлде диелә. Әгәр берәрсе: «Әҗәл җиттмичә үлде», - дисә, кяфер булыр, Аллаһ сакласын!

... Кай колга әҗәлнең вакты йитсә,
Котылмас һәрничә кем хәйлә итсә.

Ягъни бер колның әҗәл вакыты җитсә, ул бәндә күпме хәйлә эшләсә дә котыла алмас.

---

1 Шәйх Шибли, Әбубәкер... Җәгъфәр (861-946) — Әл-Җөнәйдинең шәкерте һәм мәсләктәше — Иляһи мәхәббәткә, рухи камиллеккә ирешү турындагы карашлары киң таралган. Кабере — Багдадта.

2 С.-П.да — ротбәсе (дәрәҗәсе) (92 б.)

Кин (үч итмичә) калмас әҗәл, әй ибне Адәм,
Йитешсә сәгате я элгәре һәм.

Ягъни, чыннан да, әҗәлдән кешеләр калмас, адәм баласы өчен әҗәл килсә, бер сәгать артык тормас һәм бер сәгать кичекмәс, шул вакытта ук җаны тәненнән аерылыр...

Кешенең илкендә (кулында) һәм булса бер җан,
Әҗәл илә үлебдер белсә инсан.

Ягъни бер җанны бер кеше үтерсә, ул җан үз әҗәле белән үлде дип саналсын. Кешеләр, ягъни ул кешенең әҗәле җитеп үлде диярбез.

Кай багыйс (сәбәп) белән һәр җан үлебдер,
Әҗәлдиндер, каза андаг килебдер.

Ягъни һәр җан төрле сәбәп белән үлсә дә, барысын да әҗәлдән булды диярбез, ләкин шундый каза килеп дип әйтербез. Мәсәлән, берәү берәрсен үтерсә, ул үлгән кешенең әҗәле җитте диярбез, ләкин ул үтерүче кеше Алланың казасы һәм хөкеме белән шулай үтереп, сәбәпче булды диярбез.

## Кабер газабы бәяны[1]

Газабы кабер кяферләргәдер чын,
Күрер гүренең газабын бәгъзе мөэмин.

Ягъни кабер газабы барлык кяферләр өчен дә чын. Әмма мөэминнәрнең кайберләре өчен генә булачак. Мөэминнәрнең күпчелеге кабер газабын күрмәс, диделәр. Һәм әйттеләр ки, кабер газабы сигез төрле кешегә булмас. Беренчеләре шул: шәһидләр. Икенчесе — садыклар, ягъни изгеләр. Өченчесе — сабыр кешеләр. Дүртенчесе — сугыш вакытында, сугышка кермичә, авырып үлүчеләр. Бишенчесе — җомга көнне я җомга кичәсендә үлгәннәр. Алтынчысы — һәр кичне «Тәбәрак» сүрәсен укыган кешеләр. Җиденчесе — гариплектә үлгәннәр. Сигезенче — мөәзиннәр. — Боларның барысы

1 К.да — «Газабе кабернең бәяны» (62 б.)

да кабер газабыннан имин. Вә кайберәүләр әйтәләр: үләт белән үлгән кешеләргә кабер газабы юк, — дип, — һәм бирән зәхмәте белән үлгәннәргә кабер газабы юктыр.

Һәм дә йөкле хатын үлеп, баласы корсакта китсә, кабер газабы аңа да юк. Шулай ук бирән зәхмәте белән үлгән кешегә кабер газабы юктыр, диләр. Шулай ук әйтәләр, пәйгамбәрләргә, чынлыкта, кабердә сорау алу һәм мәхшәр көнендә хисаб булмаячак, дип. Бары Сөләйман г-мгә кабердә сорау булыр һәм мәхшәр көнендә аннан хисап алыныр, диләр. Ә фәрештәләргә кабер соравы бар, кыямәт соравы юк.

Әйтүләр буенча, кабер газабының күп булуы телне[1] пычраклыктан сакламаганга була. Һәм дә бер өйдән бер өйгә сүз йөртеп, мөселманнар гайбәтен күп сөйләсә, - болар өчен кабер газабы булыр.

Газабе кабердер кяферлегенә,
Дәхи бәгъзе гасый (гөнаһлы) мөэминенә.

Кабер газабын җан күрерме яки тән күрерме дип әйткәннәр. Җавапта исә һәр икесенә дә булыр, дигәннәр.

Бетек күб нөсхән мәшһүр эчендә,
Килер ике фәрештә гүр эчендә.

Ягъни күп кенә атаклы китапларда ике фәрештәнең кабер эчендә керәчәге язылган. Алар кешедән хәлтен сорарлар, кайсы диндә, кайсы пәйгамбәргә иман китердең, дип әйтерләр. Кешене кабердә күмеп, кырык адым атлап киткәннән соң фәрештәләр керер. Кемнәрдер әйткәнчә, сорау фәрештәләре дүрт. Беренчесе — Мөнкир һәм икенчесе — Нәкир, өченчесе — Руман, дүртенче — Нагур (Нагурәд). Бу дүрт фәрештә килеп сорау алырлар. Ә кайберәүләр Мөнкир вә Нәкир һәр кеше саен, диләр. Ягъни һәр кешенең, кирамен кятибин (яхшы һәм яман гамәлләрне язып баручы ике фәрештә) кебек, үз Мөнкире һәм Нәкире бардыр. Һәм, әйтүләр буенча, кабердә Мөнкир һәм Нәкир кешеләрдән сирйани[2] телендә сорарлар, ә кеше сирйани телендә җавап бирер.

1 С.-П.да — төнене (94 б.), К.да — туныны (63 б.)
2 Сирйани — борынгы сирия теле.



www.darul-kutub.com

Ул ике фәрештәнең кабердә сораган нәрсәләрен бәян итеп...

Сорар: кемдер Хода берлә рәсүлнең?
Нәдер диерләр янә динең вә юлың?

Ягъни ул ике фәрештә кабердәге кешедән сорарлар: Раббың кем булыр, пәйгамбәрең кем булыр, нинди дин тоттың һәм нинди юлда йөрдең? Әгәр бәндә җавап бирсә — яхшылык һәм игелек, ә әгәр җавабын бирмәсә, газап булыр...

Әгәр керсә фәрештәләр[1] газабдин,
Чыкар ут борынидин, агыз-ләбдин (иреннән).

Ягъни ул кеше янына фәрештәләр ачу белән керсәләр, авызларыннан һәм борыннарыннан ут чыгарырлар, үзләре әшәке кыяфәткә керерләр. Кыяфәтләре маймыл кебек, маңгай уртасында торган күзләре зур табак кадәрле булыр һәм чәчләре җиргә кадәр сузылыр, һәм күзләреннән яшь кебек ялтырап ут чыгар, һәм авазлары күк күкрәгән тавыш кебек булыр.

Әгәр һәйбәт белән кылса нәзарә,
Булыр гамъгин күңелләр пәрә-пәрә.

Ягъни ул ике фәрештә кабердәге кешегә ачуланып[2] карасалар, аларның кырыслыгыннан күңелләр кисәк-кисәк булып, әгъзалар калтырар, һич җавап бирә алмаслар.

Дигәйләр: адәми будыр сиңа җай (урын),
Җавабын бирмәсәң вай өстенгә вай.

Ягъни ул ике фәрештә әйтер: «Әгәр син безгә җавап бирә алмасаң, сиңа хәсрәт вә үкенеч. Кыямәт көненә дигән урының шушы караңгы кабер. Сиңа чарак юк, без сине һәрчак монда газапларбыз». *Вай* сүзе хәсрәт вә үкенеч дигәнне аңлата. Пәйгамбәрне сыйфатлый торган метафоралар рәтеннән.

1 С.-П.да — фәрештәләрдин (95 б.).
2 С.-П.да — ачиг илә (95 б.).

www.darul-kutub.com

Орырлар гөрзи (чукмар) берлә ул ике йар,
Ишетер өнс-ү җендин (кешеләр һәм җеннәрдин) үзгә җанлар.

Ягъни ул җавап бирмичә торса, бу ике фәрештә бәндәгә чукмар белән сугарлар. Аларның чукмар тавышын кеше һәм җеннәрдән кала барлык тереклек ишетер.

Аларның зарбига (сугуына) таб итмәгәй таг,
Ничек такать кыйлыр бер мошт (уч) туфраг?!

Ягъни ул ике фәрештәнең сугуларына чыдый алмаган бер уч туфрактан яратылган кеше ничек чыдый алсын, ди. *Таб* — монда чыдамлык мәгънәсендә, фарсы теленнән. *Мошт* — йомрык һәм уч мәгънәсендә, фарсы сүзе.

Тулар дузәх саридин кабер эче дуд,
Пәшимән анда һәргиз, кылмагай суд (файда).

Ягъни ул ике фәрештә бу кешене чукмар белән сукканнан соң, кабер эче тәмуг утының төтене белән тула һәм анда инде үкенүнең файдасы булмаячак, ни кадәр үкенсәң дә, җиңел кылынмаячак. *Сари* — монда тараф, юнәлеш мәгънәсендә, фарсы сүзе.

Гыйнаять әйләсә данаи әсрар,
Керер гүргә мөлаем ул ике йар.

Ягъни ул колга барлык серләрне белүче Аллаһ Тәгалә ярдәм итсә, җавабын дөрес итеп бирсә, ул ике фәрештә аның каберенә йомшаклык белән һәм күркәм сурәттә керер.

Дигәйләр керсәләр: хәүф итмә мәндин,
Сорарлар миһербанлигъ берлә андин.

Ягъни ул изге кешенең каберенә бу ике фәрештә кергәч әйтерләр: «Зинһар, бездән курыкма, без сиңа оҗмах сөенече бирергә килдек». Һәм дә ул бәндәдән миһербан һәм шәфкать белән сорау алырлар.

Әгәр бирсәң җаваби[1] бесаваби,
Ачыр җәннәтдән ушал[2], мәнзилгә баби (капка).

Ягъни ул ике фәрештәгә дөреслек белән җавап бирсәң, кабереңнең почмагын ачарлар, аннан оҗмахны күрсәтерләр. Андагы урыннарны күреп, шатлык белән кабереңдә ятыр.

Караңгы гүр булыр андаг фәрәхнак (күңелле),
Җиһанның шәүкы (кызыктыруы) ядындан чыкар пакь.

Ягъни кабердә оҗмах ишеге ачылыр. Караңгы кабере якты булыр, бу яктылык дөнья яктылыгыннан да ныграк булып, җиһанда угылы-кызы һәм малы турында кайгысы күңеленнән китәр.

Күңелдә госса (кайгы) калмаз бер чикет дик,
Ятурсән яңа өйләнгән егет дик.

Ягъни шуннан соң күңелендә мамык орлыгы кадәр дә кайгысы калмас, ул кабердә яңа хатын алган егет кебек тик рәхәттә ятыр. *Чикет* — фарсыча «чим»[3] хәрефенең кәсре (ассызыгы) белән һәм «кяф» хәрефенең даммәсе (о, ө сузыкларын белдерүче тамга) белән языла, мамык орлыгы дигәнне аңлата.

Ки мондин соңрагы нигъмәтләрне,
Ходадин үзгә кем белгәй барыны.

Ягъни шулкадәр күптөрле нигъмәтләргә юлыгыр, һичкем хисабын белмәс, мәгәр Аллаһ Тәгалә үзе генә белер.

## Бәян урынында мөнәҗәт

Иляһи, бәндән бичарадыр мән,
Һәваи нәфес илә әварәдер мән.

Ягъни, Йә Рабби, мин бер бичара бәндә, нәфес-гайбәтем артыннан йөреп, дөнья мәсхәрәсе булдым.

1 К.да — җаваб (64 б.)
2 К.да — шул (64 б.)
3 С.-П.да — җимнең (96 б.).



www.darul-kutub.com

Ирермән барча ноксанымга (кимчелегемә) икърар,
Мөселман углы кылмас эшләрем бар.

Ягъни бар кимчелекләремне раслыйм, гөнаһым күп, мөселман кешесе кылмый торган эшне мин кылдым.

Мәнем дик гасый булгаймы җиһанда,
Гөнаһым зәһиримдин күб ниһанда.

Ягъни телим акыл, күзнемнең нуры юк, шуның өчен эшләгән гамәлем юк, эшләсәм дә рия эшлим, ди.

Әгәрчә мән яман кол пайе та фәркъ,
Булыб мән мәгъсыя дәрьясига гарык.

Ягъни гәрчә мин яман кол торам, башымнан аягымача гөнаһ диңгезендә батып калсам да.

Вәли садикъ ирермән берлекеңә,
Таяныб мән синең гафирлекеңә (кичерүеңә).

Ягъни бер Аллаһ Тәгалә дип раслап әйтәм һәм, синең Гафир исемеңә[1] таянып, гөнаһымны ярлыкар дип өмет итәм

Ләхедкә керсә бу ялгыз, гариб баш,
Үгерсә (?)[2] йөз һәммә кавем, карындаш.

Ягъни кайчан мин гарип бәндәне ялгыз башым ләхет эчендә калгач һәм барча туган-кардәшләрем мине куеп кайткач.

Тәхәййер булса җан гам сәрәштә,
Йитешсә соргали ике фәрештә.

Ягъни шул ләхет эчендә минем җаным кайгыдан хәсрәтле булса һәм шул вакытны миңа ике фәрештә сорау алырга керсә. *Сәрәштә* — кайгы мәгънәсендә килә. Махсус шигырь өчен гам сүзенә бәйләнешне ачыклаучы мәгънәдәш сүз буларак кулланылды.

1 К.да — гафирлекенә (64 б.).
2 С-П.да — үкерсә (97 б.).

www.darul-kutub.com

Дисә: мән рәбик, әй габде дәргяһ,
Телемгә җари кылгыя, Раббым Алла.

Ягъни ул ике фәрештә әйтсә: «Әй Аллаһ катына килгән кол. Тәңрең кем?» — дип. Шул вакытта телемә ярдәм ит, Тәңрем Алладыр, диен.

Сән әсан кылмасаң[1] анда сөали,
Ничек кичкәй гариб бәндәң хали.

Ягъни, Йә Раббым, син ул ике фәрештә сораган вакытта җиңеллек бирмәсәң, бу гарип бәндәңнең хәле ничек була, ул бәлки харап булып, йөзе кара булыр.

Әгәрчә гасыйдыр, Ярабби, бу бәндә,
Үзең бәндәм[2] дигел Раббым дигәндә.

Ягъни, Йә Раббым, гәрчә бу кол гөнаһлы булса да, син гөнаһына карамыйча, мин Тәңрем дип искә алганда, үзең дә минем кол диген.

Әгәр сән кыйлмасаң коллык атын җуд,
Мәнем «кол мән» дигәнемдә ничек сүд!?

Ягъни, Йә Раббым, әгәр син колым дигән сүзне юмарт (җуд) әйтмәсәң, минем үземне «мин кол» дип әйтүемдә файда (сүд) юк.

Иляһи, лотф итеб кыл монда вә анда,
Мәне бәндә итеб беркет бу бәндә.

Ягъни, Йә Раббым, рәхимле булып, син мине дөнья һәм ахирәт колы итеп, кол төркеменә беркет һәм алар төркеменә керт. Баштагы *бәндә* сүзе кол мәгънәсендә, ахырдагы *бәндә* сүзе баглау мәгънәсендә. Икесе дә фарсы сүзе.

Әгәр чәндикә күзсез булса инсан,
Сорылыр, әлбәттә, бишик вә ноксан.

1 К.да — итмәсәң (65 б.).
2 К.да — бәндә (65 б.).

Ягъни хәтта бу кеше дөньяда күзсез булса да, ул кеше кабергә куелса, аннан һичшиксез һәм һич ташламасыз соралыр, диделәр.

Әгәр дәрьяда улсын йә асылсын,
Газаб итсә бәне, адәм нә белсен.

Ягъни берәү диңгездә, су эчендә үлсә яки асылынган вакытта газап кичерсәләр, кешеләр белмәсләр, чөнки Ходай Тәгалә белдермәс. Әгәр кешеләр белсәләр иде, күрмичә иман китерерләр иде — хактыр дип.

Дәрендә (ишегендә; катында) адәм углын кыйлса харәк,
Гөман юкдыр сорар карында, әй пакь.

Ягъни ерткыч хайван, арыслан, юлбарыс кебек һәм аю, бүре кебек нәрсәләр бер кешене ашасалар һәм, ашап, ул кешене юк итсәләр, шикләр юк, Аллаһ Тәгалә Хәзрәте кабер соравын ул ерткыч хайван карынында алыр.

Әгәр бәндә могаззәб булса (газапланса) анда,
Калыр тоймый бу эшдин ул дәрендә.

Ягъни ашалган адәмне Аллаһ Тәгалә шул ерткыч хайван эчендә газапка дучар итсә, ул ерткыч хайван Ходай Тәгаләнең газаплавын тоймый калыр.

Ничек кылса ирер кадир-у насыйр,
Бу йирдә бәндәсенең гаклы касыйр (кыска).

Ягъни Аллаһ Тәгалә бәндәләрне ничек итсә дә кодрәтле һәм аларга ярдәм бирүче. Бу урында ничек булганын белергә бәндәнең гакылы җитмәс. Мондый эш ничек булыр дип таң калмагыз, чөнки боларның барчасын Аллаһ Тәгалә пәйгамбәренә хәбәр итте һәм бу әйтелгәннәр дә пәйгамбәрнең хәбәре беләндер.

Нә кем әйде Ходаем: йа пәйгамбәр,
Аны мөхкәм (нык) тотыб, фикер әйтмә дигәр (бүтән).

Ягъни Аллаһ Тәгалә үзенең пәйгамбәренә әйтте: «Аны

ның тот, аннан аерылма». Чөнки кабер газабы мәсьәләре пәйгамбәр г-м хәдисе аша билгеле булды.

## Кыямәтнең хаклыгы бәяны

Кыямәт хак ирер, әй адәмизад,
Хода «Коръән» эчендә кылды күб йад.

Ягъни Кыямәт чын булыр. Аллаһ Тәгалә аны Коръәндә искә алган. Коръәннең өч өлеше[1] Кыямәт хәлләре турында сөйли. Барын да искә төшерү хаҗәте юк.

Булыр кодрәт белән туфрагымыз тән,
Керер җан кайтадин бишөбһә вә занн.

Ягъни Ходай Тәгаләнең кодрәте белән үлеп, туфрак булырбыз. Туфракка әйләнгәннән соң, Хак Тәгаләнең вәгъдә иткән көне җиткәч, һичшиксез һәм шөбһәсез, шул туфракка җаннарыбыз керер.

...Тәнең һәр төрле булган булса бәрһәм,
Кылыр борнагыдык (? Борындагы тик) Хәллаке галәм.

Ягъни синең тәнең дөньяда нинди төрдә — акмы, карамы, озын яки кыска — булса да, Аллаһ Тәгалә барысын да элекке халәттә итәр. Галәмне яралтучы[2] (хәллаке галәм) Аллаһ Тәгалә һичберсен ким һәм артык итмәс, ди һәм барча таралган булган әгъзаларын, кирәк көнбатышта, кирәк көнчыгышта булсын — барысын да бер сәгатьтә туплап бетерепп тергезер. *Бәрһәм* — мәгънәсе мәгълүм, Харәзм сүзе, яки фарсы телендә бердәм кылыр мәгънәсендәге сүз. Икенче шигырь юлы беренчесенә бәйле.

Хода һич йирдә юкны әйладе бар,
Яратса кайтадин аермас (ирмәс?) бу дишвар.

Ягъни Аллаһ Тәгалә безне юктан бар итте, һич авырлык юк. Тагын бар итсә, бу сүз бер кешегә дә сер булмас.

1 К.да — «Коръән»нең өч өлешенең ике өлеше. (66 б.)
2 С.-П.да — ярадучы (99 б.).



www.darul-kutub.com

У(л)дыр хаким ничек кем хөкем кылды,
«Терел» дигәч, һәммә галәм терелде.

Ягъни Аллаһ Тәгалә, кыямәт көнне тергезеп, барлык җаннардан яхшы һәм яман хәлләрен сорар һәм байлыкны каян таптың һәм кайда сарыф иттең, дияр...

Һәр эшне күб кыйлыбдыр вә йә аз,
Хисабын һәм теләр ул бәндәдин баз (кабат).

Ягъни кешеләр дөньяда эшләгән аз һәм күп эшне, хәләл һәм хәрамне — барысыннан хисап алыр. Аллаһ Тәгаләнең соравы белмәгәннән түгел, ә бәлки колларның аңа үпкәсе калмасы өчен. Ул язуларны күзләренә күрсәтеп, үзләренә укытып, җәза бирер.

Ходa һәр бәндәсинә кылса асан,
Хисабын[1] биргүче бәндә ушал ан (чак, вакыт).

Ягъни Аллаһ Тәгалә хисап көнендә бер бәндәсенә хисабын җиңел итсә, аңа изге җәза үзенә кайтыр. Ан дигәне фарсы телендә билгесезлек алмашлыгы. Шигырь рифмасы өчен кабатлау булыр.

Әгәр катигъ тотар бәндә хисабын,
Үзе белгәй аңа кылган газабын.

Ягъни Аллаһ Тәгалә, бер бәндәсенә гөнаһлары аркасында каты, кырыс хисап оештырса, аны каты оештыруының хисабын үзе белер.

Белер гәрчә җәмигъ халемезне,
Тәразуга (үлчәүгә) салыр әгъмалемезне.

Ягъни Аллаһ Тәгалә барча хәлләребезне һәм гөнаһ-савапларыбызны белер. Шулай булса да, гамәлләребезне үлчәр.

Йибәрсә намәне рәхмәт юлыдин,
Килер намә у(л) колның уң кулыдин.

---

1 К.да — җавабын (67 б.)

Ягъни Аллаһ Тәгалә, бер бәндәсенең гамәл дәфтәрен рәхмәт белән җибәрсә, аны колның уң ягыннан бирер.

Кызыл йөзлек булыр[1] ул сәрафраз (горур),
Сиңа нәдин кыйлыр ул бәндә аваз.

Ягъни дәфтәре уңнан килгән кеше башын күтәреп, ул кеше, кычкырып, болай дип әйтер[2].

Укың нәмәне, әй торган хәлаек,
Кәлебдер нәмә ихласыма лаек.

Ягъни кычкырып әйтер: «Әй басып торган мәхшәр җәмәгате, карагыз минем дәфтәремне, ихласлыгымның дөрес булуы сәбәпле изге һәм гүзәл булып килде, күрегез минем ирлегемне һәм егетлегемне!» — дип, горурланып кычкырыр.

Биһиште галийә булгай мәкяны,
Гаркы рәхмәтдә булгай җисме, җаны.

Ягъни уң кулыннан дәфтәре килгән кешегә зур дәрәҗәле җәннәт булыр һәм Аллаһ Тәгаләнең рәхмәтендә аның тәне һәм җаны йөзәр.

Әгәр нәмә килер булса газабдин,
Килер аркасыдин йә дәсте гәбдин.

Ягъни бер кешенең дәфтәре Аллаһ Тәгаләнең каһәре белән булса, аны кешенең аркасын тишеп,[3] яки сул кулыннан бирерләр. Вә әйтәләр ки, Аллаһ Тәгалә бәндәләрне кабердән кубарганда, барчасын язу укый торган кылыр, язу танырлар, үзләренең дәфтәрләрен үз телләренә укырлар. Шулай ук әйтәләр ки, фәрештәләр дөньяда язылган гамәлләрне укырлар. Сөйләүләр буенча, кәрамел-кятибәйн, гамәлләрне язып баручы ике фәрештә кешеләрнең гамәлләрен гарәп телендә, гарәп язуында язырлар.

www.darul-kutub.com

---

1 С.-П.да — булыб (101 б.).
2 К.да — сөенгәндән ул бәндә чагырыр, әйдер белә дийү (67 б.).
3 С-П.да — төшеб (101 б.).

Кара йөзлек булыб шәрмәндә ул кол,
Торарлар һәм салырлар буеныга гол.

Ягъни дәфтәре сулдан бирелгән кемсәнең йөзе кара булыр, кешеләр арасында оятка калыр, һәм фәрештәләр ул кешене тотарлар, муенына уттан богау (гол) салырлар.

Тәкый зинҗир итәрләр гәрданига (муенына),
Тәрәххем булмагай йалбарганига.

Ягъни язуы сулдан бирелгән кешенең муенына чылбыр (богау) куерлар. Ул кол Аллаһ Тәгаләгә никадәрле ялварса да, ялваруларына игътибар ителмәс. Чөнки ялвару көннәре дөньяда иде. Дөньяда ваемсыз булып, нәфес кушканнарына бирелеп, боларны онытты.

Булыр төрлүк мәшәкатьләр хәвалә,
Кылырлар җанәбе дүзәх көшалә.

Ягъни дәфтәре сулдан килгән кешегә төрледән-төрле мәшәкатьләр йөкләрләр һәм зобанилар аны тәмугкә таба йөзтүбән өстерәп алып китәрләр. *Хәвалә* дигәне йөкләтү мәгънәсендәге гарәп сүзе. *Көшалә* кяф хәрефенең даммәсе (о, ө хәрефләрен белдерүче тамга) белән һәм шин хәрефенең хәрәкәсе белән языла, йөзтүбән өстерәү мәгънәсендә килүче фарсы сүзе.

... Иляһи, куркадырмыз хәзрәтеңдин,
Өмиде күб сәнең гаффар атыңдин.

Ягъни, Йә Раббым, синең олуг катыңнан куркабыз, ләкин синең Гаффар (Кичерүче) дигән исемеңә өметем бик зур.

Йийгылганда (җыелганда?) яман вә яхшы бәндә,
Колыңны кылмагыл шәрмәндә анда.

Ягъни гарасат мәйданында җыелган вакытта бу колыңны оятка калдырма, димәк

Әгәр әгъмалемә салсам күземне,
Сезавәре әләм (газапка лаеклы) диермән үземне.

Ягъни, Йә Раббым, әгәр кылган гамәлләремә күз салсам, газабыңа лаекмын дигән фикергә киләмен; гамәлләремнең барысы да кимчелек белән булган. *Сезавәре* лаек мәгънәсендә,фарсы сүзе; *әләм* газап мәгънәсен белдерүче гарәп сүзе...

Әгәр әлтафыңа баксам, Иляһым,
Өмидем күб багышлангай гөнаһым.

Ягъни, Йә Раббым, әгәр ярдәмеңә баксам, шәт, минем гөнаһым гафу ителер дип өмет итәбез.

Әгәр сән йабмасаң, әй галәме гайб,
Булыр таңда могаййән, саны юк гайб[1].

Ягъни әгәр син, рәхмәтең белән, минем гөнаһларыма гафу пәрдәсен капламасаң, һичшиксез, таң атканчы санап бетергесез гаепләрем һәм гөнаһларым булыр.

Иляһи, мәгъфирәт (ярлыкауга) мохтаҗидыр мән.
Синең киң рәхмәтеңдин раҗидыр (өмет итүчедер) мән.

Йә Раббым, синең ярлыкавыңа мохтаҗ торамын һәм дә киң рәхмәтеңә күп өметем бар, шаять, дәфтәрләребезне уң яктан җибәрерсең дип.

Дийү хиҗабе гафу йапмасаң гайбемезгә,
Дөрре рәхмәтене салсаң җибемезгә.

Ягъни гафу пәрдәсен (хиҗабын) безнең гөнаһларыбызга ябып, рәхмәт энҗесен якабызга багларсың дип.

Иляһи, куркадырмыз җанымыздин,
Йибәрмә намәне сул йанымыздин.

---

1 Бу бәеттә омонимик рифма күзәтелә: а) галәме гайб — серле дөнья (хуҗасы, ягъни Алла); б) гайб — кимчелек.



www.darul-kutub.com

Ягъни, Йә Раббым, синең газабыңнан җаныбыз белән куркабыз, көтмәгәндә, дәфтәребезне сул яктан җибәрерсең дип.

Өмидлек бәндәдермез һәм һирасан,
Хисабымызны ул көндә кыл асан.

Ягъни, Йә Раббым, сиңа өмет итәбез һәм куркабыз, Йә Раббым, рәхмәтең белән ул көндә хисапны җиңел итеп, синең бусагаңа лаек ит. *Һирасан* һа хәрефенең кәсре белән һәм ра хәрефенең фәтхәсе белән языла, куркү сүзен белдерүче фарсы сүзе.

Тәләттыф берлә соргыл кяремезне,
Кара кыйлма у(л) көн рөхсарымызны.

Ягъни, Йә Раббым, миһербанлыгың белән бездән сорау ал һәм, зинһар, кыямәт көнне безнең йөзебезне кара итмә. *Рөхсар* ра хәрефенең даммәсе һәм ханың сәкене белән (ягъни «ха»дан соң сузык килми) йөз мәгънәсен белдерәер.

Әгәрчә намөнасиб (килешсез) мән, яман мән,
Үзең әйдең: колымга миһербан мән.

Ягъни мин колың лаексыз, яман булсам да, син минем яманлыкларыма карамасаң иде, үзең колларыма миһербанлымын дип әйттең бит.

Әгәр чәндикә булсам зишт, бәдкяр,
Хәбибнең өммәте мән, кол атым бар.

Ягъни явыз эшләр кылган (бәдкяр) бәндәң булсам да, дустың Мөхәммәднең өммәтеннән дигән һәм Тәңренең колы дигән исемем бар. *Зишт* дигәне явыз эш эшләүче дигәнне белдерүче фарсы сүзе, бәдкяр сүзенә синоним буларак, шигырь өчен рифма итеп кулланылган.

www.darul-kutub.com

## Фи бәяни тәразу[1]

*(үлчәү бәяны...)*

Тәразу хак ирер рузийе кыямәт,
Аның сыйддыкыга (дөреслегенә) назил булды (иңдерелде) аять.

Ягъни кыямәт көнне мизан һәм үлчәү хак. Аның дөрес булуына дәлил итеп аять иңде. Тәфсир ясаучылар әйтүенчә, мизан (үлчәү) Микаил фәрештәнең уң кулында. Мизанның ике бүлеме бар; бер бүлеме нурдан һәм икенче бүлеме караңгылыктан тора. Һәм дикмә бүлемнең зурлыгы җир белән күк кадәр була. Һәм әйтәләр, һәр кешенең үзенә үз мизаны бар, дип. Шулай ук әйтәләр ки, пәйгамбәрләргә мизан булмас, бары Сөләйман пәйгамбәргә үлчәү булыр, чөнки дөньяда олуг падишаһ иде. Кайберәүләр әйтәләр, мизан дигәннәре күзгә күренә торган, җисми әйбер түгел, бу бары кинаядер дип. Безнең өчен дөресе шул: аның ничек булганын һәм нинди сурәттә булуын белүдә хаҗәт юк. Безгә мизан хактыр дип ышану гына кирәк.

Белер гәрчә җәмигъ халемезне,
Тәразуга салыр әгъмалемезне.

Ягъни Аллаһ Тәгалә безнең барыбызның да хәлен мизанга салмыйча да белер, ләкин шулай булса да, коллар үпкәләмәсен өчен, үлчәүгә куяр.

Кыйлар агяһ кылан кылмышларига,
Йитешмәс гакыл икәмнең (иямнең?) эшләригә.

Ягъни Аллаһ Тәгалә Хәзрәтләре, ул көнне кешеләрнең кылган гамәлләрен үзләренә белдерер һәм барысын да исләренә төшерер өчен, гамәлләрне үлчәүгә салыр. Ходай Тәгаләнең кодрәтен аңларга акыл җитмәс. Әй олуг кеше, *икәм* дигәне Аллаһ мәгънәсендә Сәмәрканд халкы сүзедер.

Тәразу барига (барга) икърарымыз бар,
Ничек иркәненә нә кяремез (эшебез) бар!?

---

1 К.да — «Тәразуи кыямәт бәяны» (69 б.)

Ягъни үлчәүнең хаклыгына раславыбыз бар, ә аның нинди икәненә ни эшебез бар, үлчәүнең кыяфәтен Ходай Тәгалә үзе белер, димәк.

Иляһи, кыл агыр мизанымызны,
Сәламәт тот безнең иманымызны.

Йә Раббым, син безнең үлчәүдә гамәлләребезне агыр ит һәм дөньядан үткәндә, иманыбызны сәламәт кыл. Агыр мизаныбызны дигән сүздә күчермәлелек бар; зикре халь вә ирадәи мәхәл кабиленнән[1].

## Сират күперенең бәяны

Җәһәннәм үзрә бер күфрүк ирер, аһ,
Ушал күфрүк сират атлигъ гизәр гяһ.

Ягъни җәһәннәмнең аркасында бер күпер бар, аһ, йә Раббым, ул сират күпереннән кешеләрнең үтә алуын телибез. Сөйләүләр буенча, сират күпереннән үтү гамәлләрне үлчәгәннән соң, биш йөз елдан ел үткәч була. Кешеләр хисап биргәнче, биш йөз ел үтәр. Хисап биргәннән соңра, сират күперенә саф-саф булып җибәрелерләр: тәмуг әһеле тәмугка кере өчен, оҗмах әһеле, оҗмахка керер, гыйбрәт алыр өчен. Пәйгамбәрләр дә шул сафлар эчендә булыр.

Җәһәннәм күпресе вар кылдан инчә (нечкә),
Кылычдан дәхи[2] кискендер йитенчә (үткенлектә).

Тәмам өч кәррә (тапкыр) бәң (мең) еллык юл улды,
Сәгадәт әһеленә асан юл улды.

Кылычдин тиз (үткен) ирер, кылдин инечкә,
Пәшиманлар ушал төшкәй эчкә.

Ягъни сират күпере кылдан нечкә һәм кылычтан үткен. Дөньяда гөнаһ эшләп үкенүгә калганнар эчкә, ягъни җәһәннәм эченә төшерләр.

---

1 Бу атамалар, нигездә, суфичылык тәгълиматенә бәйле.
2 С-П.да «сархи» дип басылган (104 б.).

Гаҗәб-хәйран булыр, фәрзәнде адәм (адәм баласы),
Кадәм (аяк) куйса (атласа) — аның асты җәһәннәм.

Ягъни сират күперен күреп, аның нечкәлегеннән һәм үткенлегеннән кешеләр хәйран калырлар. Басырга теләсәләр — сират күпереның асты җәһәннәм, аякларны пешерер.

Әгәр кайтай дисә куймас мөвәккәл,
Булыр фәрзәнде адәм хале мөшәккәл (мөшкел).

Ягъни гарасат халкы, кире борылырга теләсә, күзәтеп баручы фәрештәләр[1] кайтармас, чукмар белән сугарлар. Бу заманда адәм балаларының хәле мөшкел булса кирәк.

Могаййән күрсәләр ул халк тәф-таб (ут-ялкынны),
Булыр җан вә һәмми берлән зәһрәләр (агулар) аб(су).

Ягъни кешеләр, чыннан да, кызган сират күперен күрерләр. Ут белән кызганын күреп, җаннары курыкканнан йөрәкләре су булыр, ягъни кешеләрнең исәнлектән өмет кисәрләр.

Йөрәкләре кан булыр, күзләре түгәр яшь,
Котылгаймы у(л) мәнзиддин гариб баш.

Ягъни сират күперен күргән затларның йөрәкләре кан булыр, күзләрендә яшь булыр. Йә Рабби, ничек котылыр бу урыннан бу гариб башларыбыз? Йә Рабби, син ярдәм ит, диләктер.

Фөганлар (аһ-зарлар) купкай әүлад бәшәрдин,
Кем үткәй, кем якылгай ул гизәрдин.

Ягъни зарланулар башланыр, адәм балаларының сират җирендә кайберләре аннан үтер, кайберәүләр егылыр.

Гыйнаять (ярдәм) кылса бәгъзе адәмизад,
Үтәр андин яшендәк, бәгъзе чөн бад (җил).

Ягъни Аллаһ Тәгалә кайбер адәм балаларына ярдәм

итсә, алар сираттан яшен кебек һәм кайберләре җил кебек үтәр, ягъни һәркем ихласлыгының дәрәҗәсенә карап үтәр.

Үтәр бәгъзесе андин йөгрек ат дик,
Үтәр корбига (хөрмәтенә) лаек, ягъни һәр йөк.

Ягъни кайбер мөселманнар ул сиратны йөгерек ат кебек кичәрләр, ягъни, кыскасы, һәркем үзенең Аллаһ Тәгаләгә якынлыгы күләмендә үтәр.

Үтәр бәгъзе мөселман тая-тая,
Йитәр ахыр дигән гыйшрәтле җая (урынга).

Ягъни мөселманнар аяклары тая-тая кичеп чыгарлар, ахыры, бара торгач, мактаулы урынга, ягъни оҗмахка килеп җитәрләр. Вә әйтәләр, кайбер мөселманнар таеп егылганнан соң, өч сәгать вакыт күләмендә туктап торырлар, кайберәүләр бер көн, кайберәүләр бер ай, кайберләре бер ел, кайберләре мең ел...

Кадәм куйса, екылыр бәгъзе инсан,
Иляһи, әйлагел ул көнне асан.

Ягъни кайберәүләр аякларын беренче мәртәбә егылып куйгач, җәһәннәмгә китәрләр. Йә Раббым, рәхмәтең белән ул көнне безгә җиңел һәм асат ит.

Әгәр үткәрмәсәң андин сәламәт,
Колың рисва(й) булыр рузи кыямәт.

Ягъни ул сират күпереннән безне исән-сау чыгармасаң, колларың, чыннан да, кыямәт көнне рисвай булырлар.

Белеб, тәсдыйк итеб, бу көн хәтәрне,
Бу мескен куймады гыйсьян итәрне.

Ягъни бу мескен колың, чыннан да, сират, мизан һәм хисаб барлыгын белеп тә, гөнаһлардан тыелмады, һәрчак тәкатьсезлек эчендә булды.

---

1 С.-П.да — мөвәккәл зобани фәрештәләре (105 б.).

## Аллайар Суфый бәяны мөнәҗәте

Иляһи, бәндәне сахибе нәдәм (үкенеч иясе) кыл,
Сирате шәргъ үзрә сабите кадәм кыл.

Ягъни, Йә Раббым, бәндәләреңне дөньяда үкенүче ит һәм аякларны шәригать әмерләрен үтәргә беркет, димәк.

Һидаяте пиргә тапшыр колыңны[1],
Гыйнаять гүригә киң кыл юлымны.

Ягъни, Йә Раббым, без фәкыйрьләрне күндерүче шәехнең (пирнең) үзенә тапшыр, һәм ярдәм биреп, каберебездә юлыбызны киң ит, ягъни каберебезне киң итеп, рәхмәтеңә дучар ит.

Мәгаси (гөнаһ) утыйга тайдырма паем (аягым),
Биһиште мәгъфирәтне әйлә җаем (урыным).

Ягъни гөнаһ утына аягымны тайдырма, ягъни гөнаһларым сәбәпле яндырма, рәхмәтең белән гафу ит һәм урынымны ярлыкану бакчасында ит. Бәс, игътибарлы бул, бу ике бәеттә дүрт изафә бар...

... Әгәр чәндикә бихәддер гөнаһым,
Сәламәт кыл хәтәрләрдин, иляһым.

Ягъни әгәр шулкадәр минем гөнаһымның иге-чиге юктыр ки, Йә Раббым, рәхмәтең белән хәтәр урыннардан мине сәламәт кыл.

Әгәрчә саны юк гыйсъян кылыб мән,
Өмиде әүвәл кем, сәне вахид белеб мән.

Ягъни исәпсез-хисапсыз гөнаһлыр кылып торсам да, мин, ләкин сине бер дип белем, рәхмәтеңә өмет итәмен.

Иляһи, берлекнең хөрмәтедин
Сәламәт кыл у(л) куфрук михнәтедин.

Ягъни, Йә Раббым, берлегең һәм барлыгың хөрмәтенә без, гарипләрне, ул сираттан имин кыл.

---

1 К.да — кулымны (71 б.).

## Кәүсәр суы турында бүлек[1]

Кыямәтдә пәйгамбәр хоузыдыр хак,
Сыйфатын кыйлды тәгайен шаһе әсдак.

Ягъни кыямәт көнне булачак пәйгамбәр г-м күле чын, һәм аны хоузы кәүсәр — Кәүсәр суы, диләр. Нитә ки дөреслек падишаһы пәйгамбәр г-м бу аять белән сөйләде...: «Бу кәүсәр дигәне бер елгадыр».

Суы ул хоузның сөтдин ирер ак,
Исе мискдин ирде бәһрак (өстенрәк).

Ягъни ул елганың суы сөттән аграк һәм исе мисектән ислерәктер. Һәм *исе* дигәне кух (ис) мәгънәсендә, төрекчә кух диелә һәм татарлар ис дип атыйлар[2]. *Бәһрак...* яхшырак мәгънәсендә.

Аның олуглыгы бер айчылык юл,
Моны, әлбәттә, кыл зиһенеңә мәгъкул.

Ягъни Кәүсәр суының олылыгы бер айлык юл кадәр. Бу сүзне, әлбәттә, акылыңа муафикъ итеп, тугры күр. Әйткәннәр: бер айлык зур олылык дигәне аның яссылыгы, ә озынлыгы, биш вакыт намаз санынча, биш йөз еллык юлдыр. Кәүсәрнең башы оҗмах эчендәге таба агачының төбеннән чыга. Әмма аның урыны оҗмах ишеге төбендә. Әйткәннәр: ул күлдән Мөхәммәд өммәтеннән башкалар эчмәс. Аның өчен дәшү ныгыту өчендер[3].

Вә дәхи аб (су) эчсә андин һәр мөселман,
Якыйн бел, сусамас һәргиз (һич тә) ул инсан.

Ягъни бер мөселман, бер йотым микъдарында ул елгадан эчсә, беркайчан сусамас. Адәм балалары әйтүенчә, кәүсәр чишмәсеннән су эчәр өчен сайланган кешеләр биш төркем. Беренчесе — пәйгамбәрнең сөннәтен тотучылар. Икенчесе — Мәүлид бәйрәмен

---

1 «Кәүсәр суы (ягъни оҗмах чишмәсе) турындагы бүлек».
2 К.да — «ис дидеке кух вә ис мәгънәсенәдер. Төрекмән халкы ес вә ис диерләр» (71 б.).
3 «Аның олуглыгы...» дип башланган шигырь һәм аңа мөнәсәбәттә бирелгән шәрех-аңлатмалар С.-П.да күзгә ташланмый (107 б.).

үткәрүчеләр. Өченчесе — мөдәррисләр, хаҗилар һәм газилар. Дүртенчесе — ятимнәргә өлеш чыгаручылар. Бишенчесе — шәкертләргә, мосафирларга кунар урын бирүчеләр. Суфиларның фәтваларында шулайдыр.

Ходавәндә, насыйб иткәй сән андин,
Өмиде күб ирер бәндәңне сәйидин.

Ягъни, Йә Раббым, рәхмәтең белән безләргә ул елганың суын насыйп итсәң иде, чөнки бәндәләрнең өмете синнән күптер.

## Шәфагать бәяне

... Хода әзне (рөхсәте) белән хакдыр шәфагать,
Кылырлар әнбийа вә әһле тагать.

Ягъни Ходай Тәгаләнең әмере белән, шәфагать чындыр, һәм шәфагать китерүче[1] кешеләр — пәйгамбәрләр, буйсыну һәм гыйбадәт әһелләре.

Шәфәгать кем — мөселманларгадыр сүд (файда),
Вәләкин булмагай биәзн (рөхсәтсез) мәгъбүд[2].

Ягъни пәйгамбәрләрнең шәфагате мөселманнарга файдалы, ләкин Ходай әмереннән башка булмыйдыр... Әйткәннәр: шәфагать олуг гөнаһ ияләренә. Кем шәфагатьне инкарь итсә, ул кяфер. Кайберәүләр әйтә: кяфер түгелдер, бәлки, пәйгамбәр г-м шәфагатеннән мәхрүм булыр.

Хода әзне белән рузе кыямәт
Сүеклек (сөекле) бәндәсе әйлар шәфагать.

Ягъни Ходай Тәгалә әмере белән Кыямәт көнендә Аллаһ Тәгаләнең сөйгән бәндәләре гөнаһлыларга шәфагатьчелек итәрләр. Пәйгамбәрләр үз өммәтенә шәфагать итәрләр, һәм фәрештәләр, галимнәр, шәһидләр һәм изгеләр — барчасы шәфагать итәрләр, остазлар исә шәкертләренә шәфагать итәрләр, дип сөйлиләр. Һәм әйткәннәр ки,

,1 С.-П.да — шәфәгать идаче (107 б.).
2 Мәгъбүд — бу очракта Алла.

www.darulkutub.com

изгелек иясе изгелек иясенә шәфәгать итәр, дәрәҗәсе артсын өчен, изгеләр явызларга шәфәгать итәр, оҗмахка кертер өчен.

Кыямәт көн гаҗәб шиддәтле көндер,
Аның катигълыгы азхәдд фозундыр (гадәттән тыш зурдыр).

Ягъни кыямәт көне гаҗәеп кырыс көн, ул көннең кырыслыгы хәттин ашкан, исәпкә бирелмәслек кырыслык.

У(л) көннең һәйбәтедин, бишәкк, вәриб
Булыр күк парә-парә, йир булыр гайб.

Ягъни кыямәт көненең куркыныч булуы һичшиксез һәм шөбһәсез; ул кыямәт көнне күкләр кисәк-кисәк булып төшәр һәм таулар вә тигез җирләр барчасы җон[1] кебек һавада очарлар...

Зәмин утады барча куһе сәнгин,
Булыр Хәкъ хишмедин (ачуыннан) чөн пәшме рәнгин.

Ягъни җир йөзенең кадаклары — таулары һәм барча ташлары вә агачлары Аллаһ Тәгаләнең ачуыннан ул көнне, йон кебек тетелеп, һавада очарлар.

Ушал шиддәткә йир, күк кылмаса таб,
Ничек такать кылыр бер катрән аб (су).

Ягъни ул көнне җирләр һәм күкләр түзеп тора алмаса, бер катрәдән яратылган адәм балалары ничек түзәр соң...

Булыр һәм гамь белән хордан зипа[2],
Дәлилем: йәҗгалел-вилдан шиба.

Ягъни ул адәм балаларының кайгы һәм хәсрәттән чәчләре агарыр — өлкәннәрнең һәм кечкенәләрнең һәм нарасый балаларның — бу сүзнең дөреслегенә дәлилем...

1 С-П.да — йон (108 б.).
2 К.да — зиба (73 б.)

www.darul-kutub.com

Улыр бер-беригә дошман — дуст дигәнләр,
Мәгәр тәкъва юлыдин гамь йийганлар.

Ягъни ул кыямәт көнендә шундый рәхимсез булырлар, дөньяда вакытта бер-берсенә дус булганнар, монда дошман булырлар; барысы бер-береннән качар: атасы улыннан, улы атасыннан качар. Әмма бер-берсеннән шундый кешеләр качмас: дөньяда тәкъвалык кайгысын җыючылар һәм, бер мәҗлестә утырып, ахирәт турында сөйләшүчеләр һәм җәмәгать намазына баручылар — болары бер-берсенә шәфагать итәрләр.

Һава мәс дик кызарыр һәм тимер дик,
Газаб кылган кеше булгай күмер дик.

Ягъни ул кыямәт көнендә күк йөзе кызган бакыр кебек, ә җир йөзе кызган тимер кебек булыр, газапланган бәндәләрнең тәне күмер кебек булыр...

Килер нәйз буе хөршиде табан,
Хәҗаләте тиргә гарык ул бийабан[1].

Ягъни ул кыямәт көнендә Аллаһ Тәгалә кояшны сөңге (нәйзә) биеклегендә кеше башларының өстендә куяр. Бу вакытта кешеләр, эсселектән тирләп, мәхшәр сахрасы тулып чыгып, тирләреннән елгалар агыр.

Булыр үз хале берлә адәмизад,
Килер күңелгә кылган эшләре йад.

Ягъни ул көнне барлык кешеләр үз хәлләре белән мәшгуль булыр: угыл-кыз, ата-ана күзгә күренмәс, һәм дә дөньяда кылган гөнаһларының барчасы адәм балаларының исләренә төшәр...

Әгәр Хәкъ йапмаса җөрм әйлагән җан,
Гуаһлык бирүче, бел, дәст илә пан.

Ягъни Хак Тәгалә хәзрәте үзенең рәхмәте белән

1 С-П.да — пийапан (109 б.)



www.darul-kutub.com

безнең гөнаһ кылган урыннарыбызны әйтмәсә дә, кылган гөнаһларыбызга аяклар һәм куллар шаһитлык итәр...

Кабахәтлек гамәлләр төшсә күзгә,
Гыйлаҗын кем белер Хәзрәтдин үзгә.

Ягъни чиркаными һәм явыз гамәлләр күзгә төшсә, ягъни кешеләр дөньяда гөнаһ кылсалар, аның даруы шул: үлгәнче тәүбә итү, башкача түгелдер. Ягъни тәүбә итсәләр, язык гамәлләре юк дип саналыр, әгәр дә Аллаһ Тәгалә тәүбәсен кабул кылса.

Мөхәммәд кем ирер — Хәкъның хәбибе,
Мәгасый дәрденең — хазыйкы табибы.

Ягъни пәйгамбәребез Мөхәммәд г-м - Аллаһ Тәгаләнең дусты, гөнаһ авыруына даручы һәм гөнаһларга ышанычлы табиб.

Билен һиммән коригә баглаб ул ир
Һәммә «нәфсе» исә, ул «өммәте» ди(е)р.

Ягъни Мөхәммәд г-м, биленә һиммәт билбавын бәйләп, бу ирләрнең ире гарасат мәйданында барча халык нәфес-нәфес дигәндә[1], ул өммәтем дип аваз бирер һәм зар елар.

Һәммә үз нәфсигә булса грифтар,
Мөхәммәд өммәте мескен өчен зар.

Ягъни барча гарасат халкы үз хәлләрен уйлаганда, кирәк пәйгамбәрләр булсын һәм кирәк әүлияләр булсын, үз хәлләре белән мәшгуль булганда, Хак Тәгаләдән үзләре турында теләрләр, бүтәнне сорау кайгысы булмас. Ләкин араларында бары Мөхәммәд г-м генә, мескен гөнаһлы өммәте өчен зар елап, Хак Тәгалә хәзрәтеннән шәфәгать итәр[2], димәк.

Әйтәләр ки, гарасат көнендә барча кешеләр җыелып беткәч, атабыз Адәм пәйгамбәргә килерләр

---

1 К.да — дигәйләр (74 б.).
2 С-П.да — умар (көтәр — 110 б.).

һәм әйтерләр: «Йә атабызларга аталык мәрхәмәтен күрсәтеп, шәфәгать итсәң син!» — дип әйтерләр. Адәм г-м балаларына җавап бирер: «Әй балалар, безнең үз хәлебез мөшкел, сезләргә шәфәгать итү ничек булыр?» — дияр һәм: «Барыгыз, минем гүзәл углым бар, исемен Ибраһим Хәлиле Аллаһ диләр. Аннан шәфәгать үтенегез!» — дияр. Аннан Адәм балалары Ибраһимга килерләр, шәфәгать сорарлар. Ул әйтер: «Миңа төшкән хәл һәм хәсрәтләрем үз башымда да күп. Бездән шәфәгать итү булмас. Әмма сез Муса Кәлиме Аллаһ янына барыгыз, чөнки дөньяда вакытында ул Хак Тәгалә белән сөйләште. Аның Аңа якынлыгы безнекеннән ныграктыр». Адәм балалары, барчасы йөгерешеп, Кәлиме Аллаһ янына килеп әйтерләр: «Йә Кәлиме Аллаһ, безгә шәфәгать ит!» Ул исә: «Бездән булмас», — дип әйтер. Аннан Исмәгыйль г-м әйтер: «Минем күренекле һәм изге дәүләтле һәм гүзәл углым бар, исеме Мөхәммәттер. Аның янына барыгыз! Ул барлык дөнья һәм ахирәтне падишаһы һәм шәфәгать итүчесе». Шуннан соң Адәм угыллары пәйгамбәр г-м янына килерләр, шәфәгать эстәрләр. Пәйгамбәр г-м йөгереп гарешкә барыр, Аллаһ Тәгаләгә сәҗдә итәр һәм зарларын елар. Хак Тәгалә исә әйтер: «Йә Мөхәммәт, бу көн сәҗдә көне түгел, ник сәҗдә кыласың?» — диер. Пәйгамбәр г-м әйтер: «Аллабыз һәм Хуҗабыз, минем өммәтләрем гарасат мәйданында шәфәгать сорыйлар. Миңа алардан башка оҗмах нигъмәтләре хәрам», — дип әйтер. Бәс, Бөек һәм Кодрәтле Аллаһ җавап бирер: «Йә Мөхәммәт, бар, өммәтеңә шәфәгать ит һәм башка пәйгамбәрләргә дә әйт, өммәтләренә шәфәгать итсеннәр». Шуннан соң пәйгамбәр г-м өммәтенә шәфәгать итәр һәм башка пәйгамбәрләр дә өммәтләренә шәфәгатьче булырлар. Изгеләр һәм салихлар да шулай шәфәгать ясарлар. Суфиларның фәтваларында шулай диелә. Мәгълүм булганча, пәйгамбәр г-мнең анадан артык шәфкате бар. Өммәтен күргәч, аналарда кебек рәхимле күңеле белән якын итеп шәфәгать итәр...

Әгәр булса имә торган бала көм (гөм),
Табылганда ничек чәүлан[1] кылыр өм (ана).

---

1 К.да — җәүлан (75 б.).



www.darulkutub.com

Ягъни бер хатынның сөт имә торган баласы юк булып торса һәм соңыннан ул, баласы табылгач, анасы аның янында ничек әйләнеп һәм тулганып сөенеп йөрсә, баласына ничек рәхим-шәфкать күрсәтсә, шулай пәйгамбәр хәзрәте дә, кыяматтә өммәтен күргәч, һәр төрле рәхим һәм шәфкать итәр, ди. *Кәм* — фарсы язуындагы кяф хәрефе белән юк мәгънәсендә. *Чәүлан* фарсы чим хәрефе белән әйләнү-тулгану мәгънәсендә. Һәр икесе дә фарсы сүзе.

Мең андан анадин күбраг вә бәһраг,
Мөхәммәд кем гарибе өммәт өчен даг.

Ягъни пәйгамбәр хәзрәтнең өммәтенә шәфәгате аналарның шәфкатеннән мең кат артыграк, һәм ул һәрчак өммәте өчен кайгылы иде. *Бәһраг* дигәне күп мәгънәсендәге фарсы сүзе, күбраг сүзенә бәйле аңлатма. Шигырь рифмасы өчен.

Акар дәрья булыр ул мөхтәрәмдин,
Шәфагать шире бостане кәрәмдин.

Ягъни шәфәгать диңгезеннән шәфәгать сөте агыр дәрья булып өммәтләр авызына юмартлык имчәгеннән: ягъни пәйгамбәр г-мнең шәфәгатен сөт бирүче анага охшата...

Кылыр Хәкъ әзне берлә тарафе хуш,
Насыйб иткән ул дәрьядин кылыр нуш.

Ягъни пәйгамбәр г-мнең шәфагать дәрьясы һәр тарафка агар, Ходаның әмере белән насыйп булган бәндәләре шәфәгать елгасының сөтен эчәрләр.

Насыйб итмәгән фәрзәнде адәм
Калыр андаг олуг йимдин коруг фәм.

Ягъни насыйбы булмаган кешеләр шундый олы нигъмәттән, ягъни шәфәгать нигъмәтеннән коры авыз булып калыр, ягъни мәхрүм булыр. *Йимдән* дигәне нигъмәт мәгънәсендәге төрекмән телендәге сүз.

Кеше белмәс кыямәт дәштедә, аһ,
Бу колларны дигәйме[1] өммәт ул шаһ.

Ягъни кыямәт сахрасында (даласында) бу колларны пәйгамбәребез өммәт дип әйтерме икән? Йә Раббым, син рәхмәтең белән бу колларны өммәтеңнән итеп, шәфәгатен насыйп ит.

Әгәр өммәт дисә — хуш дәүләт-бәхет,
Юк ирсә — гасыйларга эш (иш) булыр сәхт.

Ягъни пәйгамбәребез г-м бу колларны өммәтем дип йөртсә, хуш дәүләт, бәлки, моннан зуррак бәхет булмас: әгәр өммәте дип теленә алмаса, гөнаһлы колларны башларына хәсрәт булыр...

Әгәр өммәт дисә нурун галя нур,
Йук ирсә — гасыйларга эш булыр зур.

Ягъни ул Хәзрәт бу колларны өммәтем дисә, нур өстенә нур булыр, әгәр дә өммәтем дип атамаса, гөнаһлы бәндәләргә зур эш булыр.

Ушал солтан дагыййа иля Аллаһ[2],
Гарибе өммәт өчен даг ирде Аллаһ.

Ягъни ул шаһыбыз, ягъни пәйгамбәребез һәрвакытта Аллаһтан сорап дога кыла иде, гарип өммәтләрене гөнаһлары турында сорап, өммәте өчен кайгыда була иде. Ант итәмен бу сүземне дөреслегенә, ди.

Бу өммәтләр гаҗәб зишт (зәшт) итде хален,
Йапар бидгать белән сөннәт җәмален.

Ягъни өммәтләр гаҗәп начар һәм кабих булдылар, үз хәлләрен үзләре боздылар, үзләрен кызганмадылар һәм пәйгамбәрне сөннәтенә бидгать эшләр өстәделәр һәм пәйгамбәрнең сөннәтен ташлап, бидгатьне арттырдылар. Шуның өчен начар гамәлләр эшләп, өммәтебез

1 К.да — «...коллар ни дигәйме» (75 б.).
2 С-П.да — «Ушал солтан ки дагыййан, әй Аллаһ» (112 б.).

диделәр. Өммәт булганнарга алай кирәкмәс иде — кирәк төне-көне сөннәтләрне үтәү...

Өммәт исәң, аның әхлакыны тот,
Таки өммәтлек ула сәндә собут (нык).

Мостафа эшләмәдеген эшләмә,
Эшләйүб соңра пәшиманлар (үкенечләр) йийма.

Бәһаим (терлекләр) эше эчмәк, йиймәкдер (ашаудыр),
Коруг тел берлә өммәтемез димәкдер.

Ягъни өммәтнең күбрәгене хәле шундыйдыр, һәрдаим ашау-эчүдер; моннан соң сөннәтләрне тотмыйча, коры тел белән «өммәтебез» дип әйтерләр, үзләре һәрдаим хайван кебек ашап-эчеп йөрерләр, пәйгамбәрнең сөннәтен тотмаслар.

Иляһи, лотф кыл хәсрәтле сәгать,
Хәбибеңдән насыйб иткел шәфагать.

Ягъни, Йә Раббым, рәхмәтең белән безгә кайгылы сәгатьне насыйп ит һәм бидгатьләрдән итмә.

Аерма яхшыларның арасыдин,
Ераг итмә хәбибне карасыдин.

Ягъни, Йә Раббым, яхшылар арасыннан рәхмәтең еблнә аерма һәм хәбибең (сөеклең) күләгәсеннән ерак итмә, аның сөннәтен тотарга ныклык бир.

## Җәннәт һәм тәмуг бәяны[1]

Ирер җәннәт вә дузәх хала мәүҗүд,
Яратыбдыр аны халкыга мәгъбуд.

Ягъни оҗмах белән тәмугның һәр икесе хәзерге вакытта, чыннан да, бардыр. Аларның икесен дә Аллаһ Тәгалә үзенең коллары өчен бар итте. Могтәзәлиләр[2]

---

1 С.-П.да — «Нар илә җәннәт бәяны» (113 б.).

2 Могтәзәлиләр (могтазалитлар) — «аерылып чыгучылар», «аерымланучылар». Алар ислам тәгълиматын аңлатуда VII-IX гасырда барлыкка киләләр. Могтәзәлиләр ислам диненең аерым өйрәтмәләрен үзләренчә аңлаталар. Аларның, мәсәлән, кешеләрнең ихтыяр иркен яклаулары мәгълүм.



www.darulkutub.com

әйтәләр: тәмуг белән оҗмах хәзер юк, Аллаһ Тәгалә аларны кыямәт көнендә барлыкка китерер, диләр. Боларның бу сүзләре ялган. Коръән аятеннән бу ике әйбернең барлыгы төшенелде. Боларга иң күркәм җавап урынына Адәм г-м кыйссасы да җитәр. Чөнки ул оҗмахта нигъмәтләр җыйды.

...Бу сәгать[1] вар вөҗүде нар-җәннәт
(Хәзер дә бар тәмуг-җәннәт),
Бәкасын (мәңгелек булуын) хөкем әйларләр әһле сөннәт.

Бәкасына дәлил, әй әһле һиммәт:
Китабе сөннәт вә әҗмагы өммәт (өммәтләрнең бердәм карашы, килешүе)

Күңелгә салма, әй гаклы пиадә,
Сыйгар[2] ул ике мәнзил кайсы җага[3].

Ягъни юк фикерне күңелгә алма, әй акылы белән белүче, Аллаһ Тәгалә хәзрәте ул ике нәрсәне кайсы урынга тели, шунда сыйдырыр; ягъни син күңелеңә бу җир белән күкләр фани булгач, кайда торарлар дигән фикер китермә. Бу ахмак фикердер. Аллаһ Тәгалә кодрәтле, ул нәрсәләрне теләсә кайда куеп саклар. Ул яктан Аллаһ Тәгалә мөшкел түгел.

Әгәр әмер әйласә, кәүнәйн[4] бер пай,
Кылыр бер пәстәнең почмагына җай.

Ягъни Аллаһ Тәгалә боерса, дөнья белән ахирәтне һәм аларда булган җан ияләрен бер әстерхан чикләвегенең бер почмагына куяр, тик ике дөньяны да кечерәйтмәс, чикләвекне дә киңәйтмәс, кодрәте белән сыйдырыр.

Керер дузәхка кяфер, кайта алмас,
Газабе сәхтдин һәргиз (һич тә) котылмас.

---

1 К.да — бәшарәт (78 б.).
2 С-П.да — сугар (114 б.).
3 С-П.да — җадә (114 б.).
4 Кәүнәйн — а) бу һәм теге дөнья; б) бөтен нәрсә.

Ягъни кяферләр төркеме тәмугка керер, кергәннән соң алар инде кире кайта алмас. Аллаһ Тәгаләнең каты газабыннан котыла алмаслар, мәңгегә тәмугта калырлар. Әйтәләр, тәмугка керүләре гөнаһлары өчен. Бу җәһәннәмгә Мөхәммәднең үз иманы белән киткән өммәтләре керер; ләкин гөнаһлары санынча яньрлар, аннары пәйгамбәрнең шәфәгате белән чыгарлар. Моннан астарак — ләза[1]. Анда яһүдиләр керер. Аннан түбән — хотамә дигән тәмуг. Анда нәсари кешеләре (христиан динен тотучылар). Моннан түбәнрәк — сәгыйрь. Анда диннән язган халык була. Аннан астарак — сәкарь. Анда мәҗүсиләр. Моннан түбәнрәк — җәһим. Анда мөшрикләр булыр. Тагын да түбән — һавийә. Монда монафикълар. Шушы алты тәмугта булган кешеләрнең барчасы мәңгегә калыр[2], дигәннәр.

Әйтәләр ки, никадәр гөнаһы кешеләр дә тәмугта җиде мең елдан артык тормас. Җиде мең ел булгач, пәйгамбәр г-м аларны тәмугтан алып чыгар. Оҗмах ишегендә Тереклек елгасы исемле елга булыр. Ул елгада бу гөнаһлыларны госел кылдырырлар: йөзләре күркәмләнеп, оҗмахка керерләр. Болар — Мөхәммәд г-мнең өммәтләре.

Һәмишә калмагай иманлы бәндә,
Тотар ахыр кулын иманы анда.

Ягъни ул җәһәннәмдә мәңгелеккә калмас, иманы ахырда кулыннан тотып чыгарыр һәм оҗмахка кертер.

Әгәр гафу итсә асаме кәбаир,
Дигел җаиз: улдыр гафир (кичерүче) вә сатир (ярлыкаучы)...

Ягъни берәү олуг гөнаһ эшләсә, Аллаһ Тәгалә аны гафу итсә, әйт: Аллаһ Тәгалә Кичерүче һәм Ярлыкаучыдыр.

Сагыйрәдин әгәр тотса Ходавәнд,
Дигәйсән: ирке аныңдыр хөрәдмәнд.

Ягъни Аллаһ Тәгалә берәүне кече гөнаһ аркасында

1 Ләза — а) ут-ялкын; б) тәмугның бер каты.
2 К.да — әбәдидер (мәңгедер) (77 б.).

газаплана, син әйт: Ул ирекле, бәндәләренә ни теләсә, шуны кылыр, диген, әй гакыл иясе булган кеше...

Үзе гафир, үзе кадир — Ходадыр,
Колыга һәр нә хөкем итсә, рәвадыр (урынлыдыр).

Ягъни Аллаһ Тәгалә үзе гөнаһларны гафу итүче, бәндәләренә кадир — кодрәтле, колларын нинди төрдә хөкем итсә, урынлы булыр дип әйт.

Нәгузе биллаһи, истихлал гыйсйан
(Алла сакласын, «гөнаһларны кичерсен»),
Алыр мөэмин кешедин шәмгы иман.

Ягъни сыгынамын Аллаһ Тәгалә тарафына. Берәрсе гөнаһларын хәләл дип санаса, ул кешедән Аллаһ Тәгалә иман яктысын алыр...

Биһишт (оҗмах) эчрә кеше кем булса дахил,
Булыр анда тәмам мәкъсуды хасыйл.

Ягъни берәрсе оҗмахка керсә, анда теләгән бөтен нәрсәсе хасил булыр: ашаудан да, эчүдән дә, кочудан да, ди.

Терекдер даимән, андин соң үлмәс,
Үлемдин хөзн (кайгы)-гамьдин зәррә булмас.

Ягъни оҗмахка кергән коллар һәрдаим тере, анда булгач үлмәсләр һәм рәнҗеш-кайгыдан бер тамчы да курыкмаслар; һәрчак уен-көлкедә булырлар.

Әгәр җәннәт белән дузәхне әүсаф
Кылырга, җәмгъ булса Каф та Каф[1].

Ягъни оҗмах белән тәмугның хәлләрен сөйләргә көнбатыштан көнчыгышка җан ияләре җыелса да, ул ике йортның хәлләрен сөйләп бетерергә хәлләре җитмәс.

1 Каф та Каф — Кафтан Кафка кадәр. Мифологик күзаллаулар нигезендә, имеш, бөтен җир йөзен Каф тавы чорнап алган.

Әда (мөмкин) булмас ике мәнзил сыйфаты,
Аны яхшы белер Тәңремнең заты.

Ягъни ул ике йортны хәлләрен сөйли[1] алмаслар һәм бәян итә алмаслар, мәгәр Аллаһ Тәгалә үзе яхшы сөйләр.

Ике мәнзил сыйфаты, саны булмас,
Алар әһле белә һәм фаный булмас.

Бу ике урынның сыйфатларын бәян итәргә саны-исәбе булмас һәм бу ике йортның җәмәгате фани булмас, ягъни җир белән күк фани булып, бозылган вакытында тәмугтагы зобанилар, оҗмахтагы хурлар һәм эчләрендәге әйберләр фани булмас, бетмәс.

Бөтебдер «Шарихел-әүрад»[2] аны,
Ки булмас гарше көрси ләүхе фаный[3].

Ягъни «Шарихел-әүрад» дигәне китапта язылган: күкләр беткән вакытта гарештәге язмыш тактасы бетмәс. Моның булачагына ышаныгыз, әй Адәм балалары, ди. Ягъни бу әйтелгән җиде нәрсә фани булмас, бетмәс. Җирләр һәм күкләр җимерелгән вакытта Ходай Тәгалә боларны үзе белгән урынга куеп саклар, ди.

## Фи бәяни мөнәҗәт[4]

...Иляһи игътикады паки берлә,
Мәне агаштә кылгыл хаки берлә.

Ягъни, Йә Раббым, миңа саф ышану бирүең белән һәм рәхмәтең белән мине туфраклык булган ышанычның үзенә катыштыр. Ягъни мине туфрак кебек түбәнчелекле итеп, мәртәбәмне зурайт, ди. *Агаштә* дигәне катыштыр мәгънәсендә килә.

Делем садикъ телемгә булды каил,
Бу сүздә кылмагыл бер зәррә заил[5].

1 К.да — сүзли (77 б.).
2 «Шарихел-әүрад» — «Изге сүзләрне шәрехләү» (ягъни Коръән тәфсире).
3 К.да — рухе фаный (78 б.).
4 К.да — «Мөнаҗәте бедәргяһе казый әл-хаҗәт» (78 б.).
5 К.да — маил (78 б.)

Ягъни минем күңелем, ышанычым сөннәт әһелләренә тиешлесенә тугры. Телем белән хак дип раслык китерәм. Ләкин, Йә Раббым, рәхмәтең белән бу ышанычтан бер тамчы кадәр дә өлешне бетермә, диләктер.

Ходавәндә, үзеңнең хөрмәтеңдән,
Кәриме гафире сатире атыңдан.

Ягъни, йә Раббым, үзеңнең хөрмәтле затың белән бу мескеннәрнең гөнаһларын ярлыкасаң иде, зирә ки син Кичерүчесең һәм бәндәләрнең гөнаһларын Ярлыкаучысың. Бу ике исемең хакына безне ярлыка син.

Бу мескенләргә мөэмин исме куйдың,
Җәмәгать әһле сөннәт кыйсме кыйлдын.

Ягъни бу мескен колларыңа мөэмин исемен куйдың, әһле сөннәт вә җәмәгать төркеменнән итеп, алар төркеменә керттең.

Ушал атдин аермагыл һәмишә,
Әгәр чәндикә булса җөрме пишә.

Ягъни, йә Раббым, безне мөэминнәр исеменнән аерма, гәрчә безләрдә гөнаһлар күп булса да; рәхмәтең белән шул исемне йөртүче ит.

Мәләк килсә җәсәден алгали җан,
Кылыр шәйтан мәлгунь касд иман.

Ягъни Газраил фәрештә безнең җаныбызны алырга килгән вакытта, шәйтан, аңа ләгънәт төшсен, безнең иманыбызны алдап алырга теләп килер, имеш.

Кылырда җан ширин җәсәддин-нәкыл,
Газиз җан ачыгыдин кем булыр гакыл.

Ягъни безнең татлы җаныбыз тәнебездән күчкән вакытта газиз җаныбызның ачысыннан башыбызда акыл кимер һәм кичелекле булыр, шәйтан ләгыйнь икәнен белмәсләр.

www.darul-kutub.com

Күңел шәһбазыны кылмак өчен сайд,
Кылыр һәр якда шәйтан хәйлә вә кайд.

Ягъни шәйтан... күңел карчыгасын ауларга, ягъни иманыбызны аулап алырга теләр һәм төрле хәйләләр корыр. Әйткәннәр ки, шәйтан ләгыйнь адәм балалары янына җан исерек булган хәлдә килер. Кулымда бер савыт тулы су булыр. Әйтер: «Әй адәм баласы, сиңа бу су кирәк буламы?» — дип. Бу кеше җавап бирер: «Әйе, кирәк!» — дип. Шәйтан әйтер: «Кирәк булса, бирермен, тик минем шартларымны үтәсәң». Адәм баласы сорар: «Шартларың нинди? Әйт», - дип. Шәйтан әйтер: «Тәңрем икедер һәм пәйгамбәрләр ялганчыдыр дип әйт!» Бәс, бу кеше изгеләрдән булса, җавап бирер: «Кит, син Аллаһ Тәгалә катыннан куылган шайтан», — дип әйтер. Әгәр дә ул кеше явызлардан булса, хосусан изге гамәлләр кылмаган[1], ягъни биш вакыт намаз укымаган, ураза тотмаган, сәдака бирмәгән[2] булса, — шайтан ни әйтә, шуны әйтер, дөньядан имансыз килеш китәр. Аллаһ сакласын! Бәс, монда булса, безнең хәтеребез олугтыр. *Кәйд* сүзе хәйләне аңлатучы гарәп сүзе.

Мәдәд сән кылмаса ул дәмдә, йа хәй,
Орар тырнагымызга ул ләгыйнь нәй.

Ягъни син, Хәй (Терек) булган Аллаһ Тәгалә, ул вакытта безгә яр булмасаң һәм ярдәм итмәсәң, ул ләгыйнь безнең тырнагыбызга, ягни иманыбызга камыш сугар. Камыштан мәгънә — хәйлә, димәк, иманыбызны алыр. *Нәй* нун хәрефенең фәтхәсе белән камыш мәгънәсеннән күчерелеп, хәйлә мәгънәсен хасил итте.

Ходавәндә терекдә җан чыкарда,
Ләхеддә, хәшәрдә, күфрүк үтәрдә,

Ягъни, йә Раббым, безне исән чагыбызда һәм җан чыккан вакытыбызда һәм ләхеткә кергән вакытыбызда, һәм кабердән кубып һәм сират күперен үткән вакытыбызда,

---

1 С.-П.да — кылгаламаган (118 б.).
2 С-П.да — бирә алмаган (118 б.).

Җәмигъ йирдә мөэмин атымыздин
Аерма сыйдкымызны (туры килүне, дөреслекне) затымыздин.

Ягъни барча җирләрдә безне мөэмин исемебезне затыбыздан аерма һәм шул исем белән нык ит, димәк.

Һәмишә нәфес илә шәйтан кәминдә (тозагында),
Мәне азгырмагыл дөнья вә диндә.

Ягъни һәрчак шайтан белән нәфеснең һәр икесе кешене аздырырга тели. Иляһым, рәхмәтең белән мине ахирәттә һәм дөньяда аздырма.

...Теләгем ул: әйа соббухе коддус,
Колыңны кылмагыл рисвай мәйүс.

Ягъни минем теләгем шул: әй пакь булган Аллаһ Тәгалә, бу колыңны җан ияләре арасында рисвай итеп өметсез итмә.

Ходавәндә, йаңылдым (ялгыштым) торфә (тарфә?) яздым,
Яман тел шомлыгындин юлдан аздым.

Ягъни, йә Раббым, мин, колың, хата эшләр эшләп, ялгыштым һәм юлдан яздым, вә яман телнең шомлыгы белән олуг юлдан аздым.

Пәшимән мән, пәришан үткән эшдин,
Бәһар тире маһ[1], йаз вә кышдин.

Ягъни мин үкенәмен үткән гөнаһларым һәм эшләрем өчен, пәйда ул гөнаһ миндә яз һәм кыш вакытында.

Йәнә шәрмәндә (оятлы) кылма кайта башдин,
Оятлыгъ мән, вәли дәстар фәшдин.

Ягъни тәүбә-истигъфар кылганымнан соң, тәүбәмне кире бозып, оятлы итмә, чөнки мин, игелек иясе һәм тәкъва

1 Тире мәһ — тир ае, ягъни Иран календаре белән — дүртенче ай. 21-22 июнь — 21-22 июльгә туры килә.

www.darul-kutub.com

булып, башыма чалма кидем. Зинһар, тәүбәмне боздырып, бу чалма белән җан ияләре арасында оятка калдырма, ди. *Фәшдин* дигәне фа хәрефенең өсте һәм шинны сәкене белән язылып, чалма коерыгы мәгънәсендә килә. Рифма шигырь өчен дәстар сүзенә бәйләнештә сөйләнеп искә алынды.

Монаҗат әйтде Аллайар мескин,
Кабул иткәйсәң, әй дарәндә дин (дин тотучы).

Ягъни Тимерйар улы мескен Аллайар дога кылды, ул доганы кабул ит, әй ислам динен тоткан падишай, ди.

Телем гозер әйгали, йа кашифер-раз,
Телемне мең телем кылсам, ирер аз.

Ягъни көн сорарга минем мөмкинлегемнән килмәс, чөнки мин гаепле бәндәмен. Хәтта телемне мең кисәк итеп, меңе белән гозер итсәм дә, минем гөнаһыма аз булыр, чөнки минем гөнаһым аннан мең артыктыр. *Телем* дигән сүз өч урында: беренчесе көн мәгънәсендә, икенчесе тел һәм зәбан (фарсыча — тел) мәгънәсендә, өченчесе язу мәгънәсендә...

Оятлигъ мән вәли, йа кашифес-сер!
Кани гозер әйгали йөз меңедән бер.

Ягъни, Йә Раббым, гөнаһымнан оялып торамын, әй серләрне ачучы Аллаһ Тәгалә! Кайда минем һиммәтем гөнаһымның йөз меңнән берсенә гозер әйтеп теләргә[1].

Имәс мән төз, кәрәм ханында йийб тоз,
Кирәк төзгә куйсам һәр кай йөз.

Ягъни мин колың, Йә Раббым, гадел коллардан түгелмен, чөнки Аллаһ Тәгаләне юмартлык табыныннан ипи-тоз ашап торам, ягъни көне-төне аның нигъмәтен җыям. Бәс, шундый нигъмәтләрне җыйгач, мин үз-үземне гадел тотып, кайда гына булса да, миңа Аллаһ Тәгаләнең боерган нәрсәләрен эшләргә кирәк[2]. Бәс, игътибарлы

1 С-П.да — куларга (119 б.).
2 К.а — «...боермаган нәрсәләрне эшләмәскә кирәк, димәкдер» (80 б.).

бул: тоз (төз) сүзе өч урында искә алынды. Баштагы төз — гадел булу мәгънәсендә. Икенчесе — тоз-икмәк мәгънәсендә. Өченчесе — төзләргә дигәне — гаделләргә мәгънәсендә. Өч сүз дә төркичә...

Телә әйдим (тел белән әйтим): телә — һәр матлабың бар,
Дидеке хакдыр үзе данаи әсрар.

Ягъни тел белән Аллаһ Тәгаләдән телә һәр төрле кирәк булган нәрсәләреңне, чөнки син бәндә һәм мохтаҗсың; мохтаҗ булган кеше кирәк нәрсәләрне байлардан сорар һәм син дә Аллаһ Тәгаләдән теләгәннәреңне сора. Чөнки дә Аллаһ Тәгалә синең серләреңне белүче һәм максатларыңны бирүче. *Телә* дигәннең беренчесе зәбан һәм лисан (тел) мәгънәсендә, икенчесе - хәзерге заман боерык фигыль, сора мәгънәсендә. Икесе дә төрки...

Ушал хәүф[1] итеб барыр йиремдин,
Тирем хиҗләт (оялу) белән акса тиремдин.

Ягъни шундый куркыныч җиргә барырга куркып, гөнаһым күплегенә үкенеп, оялып, тирләрем тәнемнән акса, ни гаҗәп эш булыр, ди. *Тирем* дигән сүзнең беренче гарәпчә гарык мәгънәсендә. Соңгысы тән тиресе мәгънәсендә. Икесе дә төрки сүз.

## Мөсаннифның (авторның) нәфесен битәрләве

Үтәр дөньяда Аллайар мәгъйүб,
Бонын дик йөргәнеңдин — үлгәне хуб.

Ягъни, Тимерйар улы Аллайар, дөньяда син гаеплесең, бу кадәр гаеп һәм гөнаһ эчендә йөрүеңнән үлүең хәерлерәктер. Тизрәк үлсәң, гөнаһың кимрәк булыр.

Йаман нәфсең синең ут дик тоташды,
Гөнаһың барә-барә хәддин ашды.

1 К.да — бе хәүф (80 б.).

Ягъни синең яман нәфесең, яна торган ут кебек, иман йортыңа төште. Гөнаһларны күпләп эшли торгач, хәттин ашып, хисаптан артты.

Белә алмам, әйа накабил әүкат,
Ничек тән сән, ничек җан сән, ничек зат?

Ягъни бу кадәр гөнаһ күплегеннән ничек оялмассың, вакытыңны тәүбә һәм истигъфарсыз үткәрерсең! Белмим, синең бу эшең таң калырлыктыр! Үзең өчен үзең кайгырмаган нинди җан һәм нинди тән син? Тәүбә итмәгән вакытыңны буш үткәрәсең, димәк.

Бәһаим сән, бәшәре диванә сән саг,
Гөнаһың алдында әрзәнчә (бөртек кадәрле дә) юк таг.

Ягъни син бу кадәр гафил торсаң, хайван син, үзең гөнаһтан тәүбә итмәсәң, чөнки синең гөнаһларың болындагы үләннәрдән күбрәк.

Мөхәннәсмү сән, ир, балигъму сән яшь, -
Йөзең катигъ, телең ачигъ, делең таш.

Ягъни бу кадәр гөнаһларыңнан куркып, тәүбә итмәскә хатыншамы син, тулысынча балигъ ирме син, я нарасый баламы син!? Әгәр үз акылыңдагы балигъ ир булсаң, тәүбә итәр идең. Шулкадәр күп гөнаһларың бар, һаман йөзең чытык һәм телең ачык, кешеләрне рәнҗетәсең, күңелең каты. Тәүбә итеп, күңелене йомшармасмы, ди.

## Һомай кошы бәянында

Фигалең намөбарәк, талгатең шум,
Һомай бәхтең үз кәгъбең белә бум.

Ягъни бу кадәр гөнаһ эчендә калсаң да, һаман да холыкфигылең яхшы түгел. Язмышның шум һомае бәхетнең үз явызлыгыннан ябалак кебек түбән булган. Әйтәләр, һомай дигәне бер билгеле кош: козгын зурлыгында, ак төстә, канат очлары кара, башы яшел. Шул һомайның торган җире күк йөзендә. Йомыркасын һәм баласын һавада басып чыгара. Әйтәләр: ул һомай кошы, кайбер вакытта очып,

www.darul-kutub.com

җиргә якынаер; тик кырык аршын биеклеккә җитмәс, кире һавага очып китәр. Шул вакыт берәрсе һомай кошының күләгәсенә туры килсә, җиһанда падишаһ була һәм тиңсез байлык иясенә әйләнә. Шуның кебек синең иманыңнан булган һомай кошы башыңа күләгә ясады, ә син аның күләгәсеннән качып, ябалак күләгәсен яхшы дип табасың, ягъни шәйтан күләгәсеннән хәер-бәрәкәт табарга телисең, ди. Уйлан! *Кәгъбең* бозыклыгың мәгънәсендәге һинди теле сүзе.

Нә кем кыйлдың җәһанда иртә вә кич,
Рия берлә ул эшне әйладең һич.

Ягъни җиһанда иртә һәм кич буйсындың һәм гыйбадәттә булдың, тик аларның барысын да рия белән юк итеп, савaптан мәхрүм калдың син.

Нә кем гаһдикә кылды, булды ялган,
Кани сәндик[1] гөнаһ астида калган.

Ягъни син Аллаһ Тәгалә белән үзеңнең арада килешүләр төзедең һәм гөнаһларыңнан тәүбә итем дип әйттең, — барчасы ялган булды. Тәүбәңне бозып, гөнаһлар эшләдең. Кайда синең кебек гөнаһ астында калып хәрап булган кеше?!

Ерак төшдең нәгу (ни өчен) корбәтле юлдин,
Йибәрде рәштән тагатьне кулдин...

Ягъни син, тәүбәңне бозып, ни өчен мондый якынлыкны калдырдың, гөнаһ кылдың, гөнаһың аркасында Аллаһтан ерагайдың, тәүбә һәм тагать җебен кулыңнан җибәрдең?! *Нәгу* — нокталы гайн һәм нунның даммәсе белән «ни өчен» дигән сүз. Төрекмән халкының сүзе.

Биленңне багла мөхкәм (нык итеп), булма мәфлүҗ,
Күзең күр[2], кәрвани кылдылар күч.

Ягъни, бәс, болай булса инде, Аллаһ Тәгаләгә тәүбә

1 С-П.да — сән дак (121 б.).
2 К.да — күзең ач (82 б.).

итеп, биленңне гыйбадәт путасы белән нык итеп бәйлә, гафил булма[1], күзеңне ач: кәрван халкы күчәр, сине көтмәс. Син дә алар кебек бер көнне күчәрсең. *Мәфлүҗ* чынлыкта отыш уены уйнап, җиңелгән кешене белдерүче гарәп сүзе.

Ятыб, гафләт карасын сөртмә йөзгә,
Йийдылар халык гамьне сәндин үзгә[2].

Ягъни алай булса, син йоклап ятма һәм гөнаһлардан тәүбә-истигъфар ит, тагать һәм гыйбадәт белән гафләттән уян. Җан ияләре кайгы җыялар, гөнаһтан тәүбә итеп, Хакка гыйбадәт кылдылар.

Мөсахибләргә һәм гаһед ирде монда,
Китәрләр бакый өйүгә көндә-көндә.

Ягъни бар юлдашларга бу дөньяда килешү бар, акыл ияләренә, чөнки көн саен бакыйлыкка адәм балалары китәләр, ягъни үлеп, кабергә керәләр. Ул үлеп киткән кеше килешү төзер: әй дуслар, мин кергән кабергә сез дә керерсез, ләкин минем кебек,[3] үкенеп, гамьсез китмәгез, дияр.

Күрерсән кафиләне үткәнен фаш,
Күтәрмәссән хәтарлек уйкудин баш.

Ягъни син гафил түгел, әгәр күрсәң: кәрван әһелләре үтә, ягъни кешеләрнең үлгәнен күрсәң; шулай булса да хәтарлекъ йокысыннан башыңны күтәрмәсәң, һаман да гөнаһ кылырсың, тәүбә итмәсәң.

Күзең алдындагы биганә вә хиш (чит вә үз),
Сәфәр рәхәтене багларлар пәс-ү пиш.

Ягъни үз күзең алдында, күрсәң: кардәшләрдән һәм чит-ятлардан барысы да сәфәр комачын бәйләп, дөяләрен арттыралар, ягъни изге гамәлләр кылып, гөнаһлардан тәүбә итәләр. Син исә һаман гафләттә ятасың.

---

1 К.да — тәрәддедә (шик-шөбһә) улмагыл (82 б.).
2 К.да — «Йийды халык үз гамене сәндин үзгә» (82 б.).
3 С-П.да — бән чалаен (122 б.).

Вәли сән хәмер гафләтендән булыб кәйф,
Ятыбсән монча[1] рисвалыг белә хәйф.

Ягъни вәләкин[2] син гафиллек хәмерен эчеп, исереп ятсаң, ахирәт эшләре өчен кайгырмасаң, һаман үзеңә оят гамәлләр кәсеп итәрсең, ди.

Олуглардин, кечекләрдин бийәкбар
Китәрләр ханәи максадга начар.

Ягъни күрерсең: олуглар һәм яшьләр берәм-берәм кабер өенә чарасыз китәләр. Алар кебек синең дә китүең хактыр.

Әгәр сәндин кечекләр тотсалар раһ,
Ятырсәнмү һәнүз, әй гаклы кутаһ (кыска).

Ягъни әгәр синнән кечерәкләр үлемгә юл тотсалар, син ничек ятырсың гафиллек белән, әй акылы кыска кеше; чөнки үлем адәмнең яшенә һәм картына карап килмәс. Бәс, тәүбә итеп, гөнаһларыңның ярлыкавын сора.

Бинагяһ кәрване солтан йитсә,
Сәңа аслы ватанның хөкмен әйтсә.

Ягъни аңсыздан сиңа кәрванны падишаһы җитеп, сиңа теге дөньяның хөкемен әйтсә, ягъни Газраил килеп, җаныңны алып, кабергә кертсә.

Олуг юлга керерсән хаһ нә хаһ
Нә кылгайсән вәли битушәи раһ (юлга азыксыз).

Ягъни син кай вакытта шәригать юлына керерсең; ягъни ахирәт юлына чарасыз керерсең. Ни кылырсың азыксыз, ягъни гамәлсез, димәк.

Гаҗәб юл гакабә (газаблы) һәрбер кадәмдә (адымда),
Җәмигы кәрвани бәхре гамьдә.

1 К.да — ничә (82 б.).
2 С-П.да — вәли сән (123 б.)

Ягъни ахирәт юлы — гаҗәеп мәшәкатьле юл: һәрбер адымыңа күп мәшәкатьләр бар һәм барча кәрван халкы кайгы диңгезенә гарык булырлар, ягъни батырлар.

Хосусан, юлда бер вәхшәтлек өв бар,
Кирәк ялгыз башың ул өвгә начар.

Ягъни, хосусан, мәшәкатьлерәк шул: юлда бер кирпеч өй бар, шул кирпеч өйдә ялгыз башың калыр чарасыз, ягъни кабердә якын карендәшләреңннән аерылып калырсың, ди.

Аерыб кәрвандин кундырырлар,
Кызыл гөл дик йөзеңне сулдырырлар.

Ягъни сине кәрван халкыннан аерып кундырырлар. Шул кабер өенең эчендә кызыл гөл кебек күркәм йөзеңне сулдырырлар.

Газиз җисмең ки, нигъмәте харә булгай,
Кара йир астида бичара булгай.

Ягъни дөньяда нигъмәтләр җыйган газиз тәнең хур булыр, шул кара җир астында чарасыз булып калыр.

Йөз әлван берлә сүз әйган[1] сөчүк тел,
Димәс фәрманидин артук бер генә кыл.

Ягъни дөньяда исән вакытта[2] йөз төрле сүзгә сәләтле телләр, кабергә кергәч, Аллаһ Тәгаләнең боерыгыннан башка бер сүз әйтә алмас.

Ләхед корты әгәр килсә йийгали (ашарга),
Кани ул дәмдә дәрман кеше дигәли.

Ягъни ләхет корты тәннәребезне ашарга килгән вакытта, кайда ул вакыт шул кортларны «көш!» дип куарга![3]

---

1 С.-П.да — берлә әйган (124 б.).
2 С-П.да — дөньяда икәндә (124 б.).
3 С-П.да — «...кани дәрман ул дәмдә кеше...» (124 б.).



www.darul-kutub.com

Йитешсә соргали ике фәрештә,
Нә кыйлгай бәндәи хәсрәте сәрештә.

Ягъни шул ләхеткә, сорау алыр өчен, ике фәрештә килер. Шул вакыт ни кылырсың һәм ни җавап бирерсең!?

Мәгәр Тәңре Тәгалә кылгай әмдад (ярдәм),
Вә гәр нә файда иткән[1] даде фөрйад.

Ягъни мәгәр Аллаһ Тәгалә ул урында үзе ярдәм итәр, югыйсә безнең аһ-зар итеп кычкыруыбыздан файда булмас.

Якыйн белдең моны, әй бәндәи зар,
Ходадин үзгә юкдыр һич хакимкяр.

Бәс, югарыдагы бәеттән мәгълүм булды ки, зар елаучы бәндәләргә Ходадан башка хөкем итүче юк.

Нәгу коллыкга багласаң билеңне,
Сәнасы берлә сәбз итсәң телеңне.

Ягъни тиз вакыт эчендә Ходай Тәгаләгә гыйбадәттә бил багласаң, ни булыр, һәм намаз-рузаны үтәп, садакалар биреп, зикерләр белән коллыкны яшьтән үтәсәң, һәрдаим зикердә булсаң, ни яхшыдыр! *Нәгу* монда «ни була» мәгънәсендә...

Ләхеддин барча адәм углы купса,
Булыб бер кәрван мәхшәргә йөресә.

Ягъни яңадан терелгән көндә барча кешеләр каберләреннән кубарылса, барча кешеләр, бергә җыелып, мәхшәргә барсалар, хисаб җирендә катнашсалар,

Вәләкин һәр кеше үз матәмендә
Булыр ахыргы сәүдасы гамендә.

Ягъни шул мәхшәр җиренә һәр кеше дөньяда кылган гамәлләренең кайгысында булыр. *Матәмдин* дигәне кайгы мәгънәсендә, Кашкар халкы теленең сүзе.

---

1 С.-П.да — тигәй (124 б.)

Ходa кылсa нәдаи (мөрәҗәгать итсә): әй бәндәи зар,
Нә килтердең, нә төрлүк кылмышың бар?

Ягъни шул гарасат халкы әзер булып торган вакытларында, Аллаһ Тәгалә үзенең кодрәте белән әйтер: «Әй бәндәләрем, минем яныма нинди гамәл китердегез һәм нинди эшләр кылдыгыз?» — дип.

Сәнең тәнеңдә татлигъ җан яратдым,
Бәһаим итмәдем, инсан яратдым.

Ягъни Аллаһ Тәгалә әйтер: «Әй бәндәләрем, сезнең тәнегезгә газиз җан яраттым, хайван итмәдем, кеше яраттым».

Һәмишә әйладем тәрбиятеңне,
Нәгу кылдың пәришан ниятеңне?

Ягъни сезне аталар һәм аналар рәхмәтендә тәрбияләп, зур дөньяга китердем һәм анда төрле нигъмәтләр белән тәрбияләдем. Шулай булгач, ни өчен минем әмеремне үтәмәдегез?

Сине салдым мөселманлигъ йиренә,
Кани шөкер әйткәнең мендән береңә.

Ягъни мин сезне мөселманнар җөмләсеннән яраттым һәм шундый гыйлемлекләр бирдем, йөз мең нигъмәт бирдем. Кая бу кадәр нигъмәтнең меңнән беренә шөкерегез?..

Тәмам әгъзаларыны салим (сәламәт) итдем,
Аригъ затым белергә галим итдем.

Ягъни барча әгъзаларыгызны дөрес ясап, үземнең пакь затымны белергә гыйлем бирдем.

Сугардым абе нигъмәтдин тешеңне,
Кани, әйгел бәңа кылган эшеңне!

Ягъни сезне агымсулар белән, төрле нигъмәтләр

белән сугардым һәм ашаттым. Бу кадәр нигъмәтләргә шөкерана итәргә ни төрле гамәлләр китердегез? — Әйтегез!...

Нә биргәй сән җавабын, әй тәне арай,
Бу хәсрәтдин фөган, әй руне сийаһ, вай.

Бәс, Аллаһ Тәгалә Хәзрәтенең бу кадәр сорауларына ни җавап бирерсең, әй тәнен кайгыртып, нәфес һавалыгы артыннан йөргән кол? Әгәр җавап бирәлмәсәң, йөзең кара булыр һәм үкенеч сиңа булыр, димәк.

Ирер башдин аягың — барчасы гайб,
Мәгәр гафу әйлагәй — данәндәи гаиб.

Ягъни син, колның, башыңнан аягыңача эшләреңнең һәрбарчасы гаептер.

Мәгәр гаепләрне белүче Аллаһ Тәгалә, үзенең рәхмәте белән гөнаһларны гафу итеп, оҗмахына туры китерер.

Янә нида килсә андин, белеңләр,
Яманлар яхшылардин аерылыңлар.

Ягъни Аллаһ Тәгалә җәнабеннән гарасат халкына: «Әй яхшы гамәлле кешеләр, явызлардан аерылыгыз», - дип әмер килсә,

Яманлыкны мәгәр данәндәи раз,
Ябыб кушкай сәгадәт әһлигә баз.

Ягъни без мескеннәрне Аллаһ Тәгалә, үзенең рәхмәте белән яманлыкларыбызны эретеп, изге әһелләргә өстәр. Юкса, безнең хәлләребез мөшкел булыр.

Мөселман углыда торфә яман сән,
Яманлык уртасында би гөман сән.

Ягъни, юкса, син мөселманнар арасында гаҗәеп яман эшләре булган кеше иң яманнар һәм явызлар арасында, шиксез, син. *Торфә* гаҗәп мәгънәсендәге төрекмән сүзе.

Вә гәр нә сән? — Җиһан рисвасыдырсән,
Хәлаек эчрә фетнә башыдыр сән.

Ягъни, юкса, Аллаһ Тәгалә үз рәхмәте белән коткармаса, дөньяда рисвайдыр син һәм җан ияләре арасында фетнә башыдыр син.

Телеңдә халык ара тәсбихе тәһлил,
Вәләкин батыйның тәзвир (алдау) илә хил (мәкер).

Ягъни син бер гаҗәеп риялык белән гамәл кылучы булырсың, халык арасында тәсбих һәм тәһлил күп әйтсәң. Аулакта явыз уйлар һәм төрле хәйлә корып торсаң. *Тәзвир* хәйлә мәгънәсендә. Хәйлә сүзе шигырь рифмасы өчен китерелде.

Телеңдә халык эчендә вәгазь илә дәрес,
Вәләкин батыйнында (эчеңдә) анча юк тәрс (курку).

Ягъни син бер гаҗәеп кешесең: телең белән халык арасында вәгазь һәм нәсыйхәт дәресләре бирәсең һәм кешеләргә «изге булыгыз!» дип әйтәсең. Ләкин эчеңдә болар юктыр, бәлки тәкәбберлек һәм хурлык белән йөрерсең һәм хәйлә вә алдау белән торырсың.

Киеб сән халык ара фокранәи мәлбүс[1],
Вәләкин батыйныңдан вә намус.

Ягъни кешеләр арасында башыңа чалма һәм сөлге урап һәм махсус өс киемнәре киеп йөрсәң дә, эчеңдә аның нәкъ киресе, һаман тәкәбберлек һәм исем чыгару[2] өчендер, ягъни кешеләр сине суфый һәм төзек әдәп иясе дип уйласыннар өчендер.

Күрер күзгә гаҗәб суфый нәмасән,
Нәһанда нәфигә[3] мөбтәлясән (дучар син).

Ягъни тышкы яктан гаҗәеп суфий кеше булып, башыңны түбән салып һәм башыңа чалма урап йөрсәң дә, эчеңдә нәфескә дучар булып, нәфес кушканнары белән әвәрә киләсең, ди.

1 Фокранәи мәлбүс — фәкыйрьләр (суфыйлар) киеме.
2 С-П.да — ат чыкармак (126 б.).
3 К.да — нәфсиятькә (85 б.).



www.darulkutub.com

Мәгәр рәхмәт белән данаи әсрар,
Гөнаһларың гафу иткәй бейекбар (шунда ук).

Ягъни мәгәр үз рәхмәте белән серләрне белүче (данаи әсрар) Аллаһ Тәгалә, гөнаһларыңның барысын да гафу итеп, үзеңне рәхмәтеңә лаек итсә иде.

Ушал гамьгин (кайгылы) күңелне әйлагәй шад,
Никүләр уртасында әйлагәй йад.

Ягъни Хак Тәгалә хәзрәте, безнең шушы кайгылы күңелләребезне шатландырып, изгеләр әһеленә кушса иде, үз рәхмәте белән, ди.

Кеше ташар кылыр, сәүдәсе ташыр,
Нәгүзе биллаһи, ул кем хәддин ашар.

Ягъни кеше һәрдаим явызлык кылса, кылган саен, күбрәк итәргә теләр, сыгынамын Аллаһ Тәгалә хәзрәтенә, ул гөнаһ эшләрне күп кылса, хәттин ашып көферлек дәрәҗәсенә төшер. Әйтәләр ки, кайчан адәм баласы бер кечерәк гөнаһ теләсә, шайтан әйтер: «Күбрәк эшлә, монда артык зыян юк», — дияр. Кайчан адәм баласы шул гөнаһны шәйтан сүзенә карап эшләсә, аннан гөнаһлырак эшләрне, бара[1] торгач, көферлек эшләрен эшләр. Моннан соң җитәсе урын ерак булып калыр. Баштагы *ташар* сүзе явыз дигәнне аңлата, фарсы сүзе. Соңгысы (ягъни ташыр) ташудан ясалган, күп булу дигән мәгънәдә.

Бәшәр булсаң, куй әфгале бәшәрне,
Габәс үткәрмәгел әснаи гашәрне.

Ягъни син, Ходайга якын диндар кеше булсаң, явыз гамәлләрне куй һәм аннан тәүбә ит, унике айны ярамаган эшләр белән үткәрмә. *Бәшәр* сүзенең беренчесе кеше мәгънәсендә, икенчесе явызлык дигәнне аңлата. *Габәс* дип ярамаган эшләрне әйтерләр, уйлап фикерләсәң.

Йә нәре хонсамисән сүзеңдән, йә нәр? —
Гаһдең нәһле (агачы) һәргиз бирмәде бәр (җимеш).

---

1 С.-П.да — бара-бара (127 б.).

Ягъни, хатыншамы син, йә иркәкме син? Сүзеңне тотмыйсың, яратылыш көнендә «әйе» дип җавап биргән вәгъдәң — хөрмә агачы — җимеш бирмәде. Бичара, бу дөньяга килдең, ул килешүне боздың, хатынша кеше кебек, сүзеңдә тормадың. *Нәр* дигән үсз иркәк (ир-ат) мәгънәсендә, фарсыча. *Хонса* дигәне хатынша мәгънәсендә... *Нәхел* хөрмәт агачы. *Бәр* җимеш дигәнне аңлата.

Яшен йиткән сарый, фигъле[1] синең яшь,
Күзең яше кани, әй мәгъзе (мие) юк баш?!

Ягъни сине яшең картайган саен, һаман егетләр кебек яшь чактагы нәрсәләрне телисең һәм нәфес һавалыгы артыннан картайган саен куасың, бу кадәр гомер яшәдең, кайда синең Аллаһтан куркып елаган күз яшең?! *Кани* ул мәгънәсез картайган баш дигәнне аңлата.

Канагать мәгъдәнигә ач күзең ач,
Тамәгъ буе күренмәй буйдан кач.

Ягъни канәгатьлек хәзинәсенә кара һәрчак ач булсаң да, канәгатьлек тарафына кара; күзеңне ач, дөнья әйберләреннән туймаган кеше, ягъни һәрдаим канәгать ул һәм комсызланма. Тамәг буй-сыны күренмәс борын, тамәг исеннән кач. *Ач* сүзенең беренчесе төркичә. *Чуг* (ачлык) гарәп сүзе, туклыкның капма-каршысы. Һәм соңгы *ач* (ач сүзе) «күзеңне ачып кара» дигәнне белдерә. *Буй* сүзенең беренчесе буй-сын мәгънәсендә, ә соңгысы мәшһүр мәгънәсендә, икесе дә төрки сүз.

Сачелмәсдин борын сачкъел үзеңне,
Соралмасдин борын соргыл үзеңне.

Ягъни үлеп, әгъзаларың черегәнче, үзеңне черегән хөкеменә куй һәм, гөнаһларга хисап кылынганчы, бу дөньяда үзеңә хисап яса, ягъни ахирәт хисабына кадәр үзеңне хисап ит. Һәм ни кадәр явызлыклар эшләдең, шуны исәпләп, кайсыннан бәхиллек теләп, кайсыннан тәүбә ит.

1 С-П.да — гаклың (127 б.).

www.darul-kutub.com

Казылмый йир сәңа, кайт азганыңдин,
Язылмый гакыдлар йан, язганыңдин.

Ягъни җир казылганчы, азгын эшләреңнән, тәүбә итеп, кире кайт һәм гөнаһ фәрештәләре язып куйганчы, гөнаһлардан кайт.

Әйтәләр ки, һәр кешенең ике фәрештәсе булыр: берсе — уңда, икенчесе — сулда. Кешеләрнең кылган эшләрен язырлар. Бер кеше гөнаһ кылса, сул тарафтагы фәрештә уң яктагысыннан сорар: «Бу адәм баласыны языгын (гөнаһын) языйкмы?» Уң яктагы фәрештә әйтер: «Сабыр ит, бәлки, тәүбә итәр, көтик», — дип. Хәтта җиде сәгать буена тәүбә иткәнен көтеп торырлар, ягъни син дә шул фәрештәләр язып куйганчы тәүбә итеп гөнаһларыңнан кайт, димәктер.

Бәкадыр димә гайш — би бәканы,
Бәканы тот әҗәл тотмый яканы.

Ягъни мәңгедер димә, мәңге түгел дөнья тереклеге; мәңгелек эшне әҗәл фәрештәсе сине тотканчы тот, ягъни, бу дөньяны мәңгелек дип санап, ваемсызлык белән яшәмә, зинһар; әҗәл килгәнче тәүбә итеп, гөнаһларыңнан кайт.

Мәкан иткән йирeңдер мохталат (төрле) лай,
Нәсыйхәт гүшә алсаң, гүшә кыл җай.

Ягъни синең урының булган җир — кабер, ягъни дөнья кабер кебектер, мәшәкатьләре бик күптер. Бәс, нәсыйхәт сүзләрен колагыңа алсаң, бер аулак урынга барып, анда тагать һәм гыйбадәт кыл. *Лай* балчыкны аңлатучы һинд халкы белән төрекмән халкының телендәге сүз[1]. Монда күчерелмә мәгънәдәге кабер сүзе. *Гүшә* дигән сүзнең беренчесе колак мәгънәсендә, соңгысы почмак мәгънәсендә. Икесе дә фарсыча. Почмактан ялгызлык мәгънәсенә метафора рәвешендә кулланылды.

Йаныб гайш тарәбдин эстә Рабдин,
Аермасын сәне яхшы таләбдин.

---

1 Лай сүзе татар телендә дә иркен кулланылышта йөри.

Ягъни дөнья ләззәтләреннән кайтып, Тәңре Тәгаләне эстә. Ходай Тәгалә сине үзен эстәүдән аермасын, көннән-көнгә эстәүне арттырсын. *Рабдин* дигән сүзне «ба»ның тәхфифе (кыскартылуы, бу урында «ба»ның төшерелүе) белән укы, гәрчә чынлыкта тәшдид белән укылса да; шигырь рифмасы өчен тәхфиф укылды.

## Аллайарның васыяте[1]

Мән үлсәм, әй җәмигы мәхрәмраз,
Мәне үзгә үлекдик кылмаң игъзаз.

Ягъни, әй минем сердәшләрем, мин дөньядан үткән чакта, минем васыятем сезгә шул: мине башка үлүчеләр кебек хөрмәтләп мәшәкать чикмәгез, бәлки, мине үлгән барлык мөселманнардан хуррак итегез...

Хәс-хар астына ташлаб тотың хар,
Бәһаим (хайван) исме дик бәндин кылың гар.

Ягъни мине чүп-чар (хәс-хар) астына ташлап, гәүдәмне хур итегез — дүрт аяклылар гәүдәсе кебек, минем гәүдәмне шулай хур һәм мәсхәрә итегез.

Бусага астыга ташлаб тәнемне,
Кяфен әйлаң пираһәнемне.

Ягъни бусага төбенә ташлап, минем тәнемне мәсхәрәләгез һәм, шул черек күлмәкләремне[2] кәфен итеп, мине мәсхәрәләгез.

Мәңа хәйф (әрәм) итмәңезләр тотмаган бүз,
Әгәр чәндикә мәрдем (кешеләр) кылсалар сүз.

Мин гарипкә яңа бүзләрне (бүз — кәфен тукымасы) кәфенлек итмәгез, хәтта кешеләр «Ни өчен яңа бүз белән кәфенләмәдегез?» дип тиргәсәләр дә. Аларның сүзләренә карамагыз, чөнки шәригать буенча, иске бүз (тукыма) чиста-пакь булса, кәфенлеккә ярыйдыр.

---

1 К.да — «Мөсанниф (автор) васыятенең бәяны» (87 б.).
2 С.-П.да — күләкләремне (129 б.).



www.darulkutub.com

Йибәрең тиз, бара торган йиремгә[1],
Мәбада калмагайсыз шомлыгымга.

Ягъни тизрәк әзерләп, бара торган җиремә җибәрегез, ягъни тизрәк каберемә илтегез; уйламыйча, тизрәк илтмичә, шомлыгымны (*начарлыгымны, җирәнгечлегемне*) күреп гаҗәпкә калып, мөселманнар кабереннән мәхрүм итеп, ялгыз җиргә күмәрсез. Шуның өчен җәһәтрәк булыгыз, димен.

Күзеңездән чыкармаң катрәи яшь,
Җәназам аркасыдин атыңыз таш.

Ягъни мине үлде дип елап, күзегездән хәсрәт белән бер тамчы яшь тә чыгармагыз, бәлки хурлап, җеназам артыннан таш белән атыгыз.

Аягымдан тотыб сөйрә ләхедкә,
Нә өчен кылмадың коллык Әхәдкә.

Ягъни мине кабергә илткән вакытта, аягымнан тотып өстерәп, мәсхәрә итеп, ләхеткә илтегез: «Ни өчен Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылмадың?» — дип.

Әгәр чәндикә булсам бән гөнаһкяр,
Дога вә зарыйга сезләр булың йар.

Ягъни мин гөнаһ дәрьясында батсам да, сез минем өчен Аллаһ Тәгаләдән дога кылып һәм зар елап, тәмугтан котылуны сорагыз.
Диеңез пәрвәрдикяр кәрдигярә,
Рәхимән мәгъфирәтлек бер вә барә.

Ягъни әйтегез галәмне Тәрбия кылучы Аллаһ Тәгаләгә Ул бәндәләргә Рәхимлек итүчедер[2] дип.

Алыб килдек сәнең качкан колыңны,
Хаталар бабыны ачкан колыңны.

1 К.да — юлымга (88 б.).
2 С-П.да — рәхим идачедер (130 б.).

Ягъни кабер янында әйтегез: йә Рабби, бу качкан бәндәңне синең катыңа алып килдек, бу колың күп хаталар кылгандыр.

Килебдер, хәйләсе юкдыр китәргә,
Теле юкдыр бу колның гозер итәргә.

Ягъни синең бу колың каршыңа килде, китәргә хәйләсе юк һәм гозерен әйтергә теле юк.

Гөнаһы күб, бәкар рөхсарәсе юк,
Буен сынмакдан үзгә чарасы юк.

Ягъни әйтегез: бу килгән бәндә гөнаһлары күплегеннән сезнең биек катыгызда югарыга уфтанып карап тора. Анда булырга теләсә, сезгә буйсынмый чарасы юктыр.

Әгәр бирсәң җәза — кадир Хода сән,
Әгәр гафу әйласән — сән падишаһ сән.

Ягъни әгәр бу мескен колыңны җәзаласаң яки гөнаһларын гафу итсәң, — син барысына да куәтле, син падишаһсың, син иреклесең.

Иляһи, барча атың хөрмәтедин,
Аригъ (саф) затың, сыйфатың хөрмәтедин.

Ягъни барча мөбарәк исемнәрең һәм пакь сыйфатларың[1] хөрмәтенә,

Бу качкан бәндәгә кылгыл тәрәххәм (мәрхәмәт),
Әгәрчә кылды коллык рәштәсен кәм.

Ягъни бу шәригать әмереннән качып йөргән колыңа рәхимле бул; хәтта бу мескен колың, гыйбадәт җебен[2] кителеп, сирәк вакыт коллык итсә дә, ярлыка.

Мөхәммәд атлигъ дустың хөрмәтедин,
Җәмигъ яхшы колларың хөрмәтедин.

---

1 К.да — «...пакъ сыйфатың вә затыңның хөрмәтенә» (88 б.).
2 К.да — кол булмак йебене (88 б.).

Ягъни үзеңнең дустың Мөхәммәт Мостафа һәм барча пәйгамбәрләр вә әүлияләр хакына безгә рәхим ит.

Әгәр чәндикә бәндәңдер бәдәфгаль,
Рөхе гыйсйанә сәүбе мәгъфирәт сал.

Ягъни хәтта бу колың явыз эшләр эшләгән булса да, аның гөнаһлы йөзенә ярлыкану киемен сал, гөнаһларын гафу ит. *Рөхе гыйсйанә* («Буйсынмаган җаны») дигәне күчерелмә мәгънәдә.

Мәхәббәт әһленең әсрары өчен,
Рөхе зәрд, деле хунбари өчен.

Ягъни Аллаһ Тәгаләне сөюче бәндәләр өчен һәм аларның, йөзләрен саргайтып, күңелләреннән кан агызганнары өчен, бу бәндәгә рәхимле бул, димәк.

Газа кылган ирәнләр җаны өчен,
Шәһидләрнең мөбарәк каны өчен.

Ягъни сугышып шәһид булган кешеләрнең җаны өчен һәм дә шәһидләрнең мөбарәк каннары өчен,

Гаҗузларның акарган башы өчен,
Ятимләрнең күзенең яше өчен.

Ягъни карчыкларның[1] чәч аклыгы өчен һәм ятим балаларның елаган яшьләре өчен, бу бәндәгә рәхимле бул, димәк.

Шикәстә бивәләрнең дәрде өчен,
Әсир халкының әһ-сәрде өчен.

Ягъни сынык күңелле тол хатыннарның сыныклыгы өчен һәм дә әсир төшкән халыкның кайгы һәм хәсрәт белән сулганнары өчен, бәндәгә рәхимле бул, ягъни назым ... бу унөч төрле төркем белән шәфәгать эстәве аның өчен. Боларның дәрәҗәләре һәм хөрмәте Аллаһ Тәгалә каршында ачык булу сәбәпле, боларны үзара бәйләде.

1 К.да — шәйхләрнең (89 б.).

www.darul-kutub.com

Әгәр чәндикә юк илкемдә һич шәйи,
Бу качкан колны рисвай кылма, йа хәйи (кеше).

Ягъни хәтта бу колыңның кулында гамәлдән башка берни булмаса да, рәхмәтең белән гөнаһларын гафу ит, кешеләр арасында хур калдырма.

## Суфилар бәяны[1] (Әһле сөлүк бәяны)

Кил, әй талиб, бу дөньядин йөз үгерсәң,
Тарикы Кәгъбәи максуда йөгерсәң.

Ягъни, әй Аллаһ Тәгаләне эзләүче бәндә, бу түбән дөньядан йөз чөерсәң, Изге Кәгъбәгә барырга теләсәң, ягъни суфи булып, Аллаһ Тәгаләне танырга теләсәң, шуны максат итсәң,

Кадәм куйсаң әгәр бу вадига,
Кулыңны тапшыр ул һадига.

Ягъни әгәр дә син суфи булып, тарикать чокырына аяк куерга теләсәң, ягъни Аллаһ Тәгаләгә якын булырга теләсәң, кулыңны бер өйрәтүче шәехкә тапшырырга кирәк. Аннан башка йөрү, аннан башка Аллаһ Тәгалә белән кавышу булмас. Чөнки пәйгамбәр г-м әйтте: «Кемнең шәехе юк, аның дине юк»... Чөнки суфи (Аллаһны танырга теләүче) булмаган кешенең ышанычларында һәм күңел гыйшкында ныклык булмас, бер камил мөршидне юл күрсәтүче итмичә... (*Бередә гарәпчә юл китерелә)*. Ягъни Пәйгамбәр хәзрәте үзе Аллаһ Тәгалә белән кавышты Җәбраил арадашлыгы белән. Бәс, шундый олуг падишаһ та мөршидкә мохтаҗ булса, без ничек юл күрсәтүчедән башка Аллаһ Тәгаләгә барыйк? Риваять: Хәзрәте Имам Әгъзам үлеменә кадәр ике ел алдан тәссаувыф гыйлеме (суфыйчылык) буенча Мөхәммәд-бакыйр исемле бер сыер көтүчесенең мөриде булды һәм аны шәех итте, ике ел аңа хезмәт итеп, суфыйчылык гыйлемен өйрәнде. Әлкыйсса, Хәзрәте Имам Әгъзәм дөньядан күчте. Кәрхи хәзрәтләре төшендә күрде ки, Имам алтын тәхет өстендә оҗмахның бер почмагында дәрес бирә. Сорады:

1 К.да — «Салике кәнҗене эстәмәк бәяны» (89 б.).

«Йә остаз, хәлең ничек булды һәм дөньядан үткәндә, Хак Тәгалә хәзрәтенә нинди гамәл белән лаек булдың?» — иде. Җавабында күрсәтте: «Бу суфый Ногман һәлак булыр иде», — диде. Кыскасы, бер юл күрсәтүче булмаса, бару кыен булганга күрә боерды:

Гаҗәб юлдыр — аның (очы) юкдыр,
Хәтарлек йирләренең саны юкдыр.

Ягъни Аллаһ Тәгаләгә сәяхәт итә торган юл гаҗәеп бер озак юл, аның һич тә чиге юк; аның чигенә барып җитеп булмас. Бу юлда куркыныч урыннар исәпсез-хисапсыз, чөнки ул юлда шәйтан ләгыйнь һәм нәфес һавалыгы сине Аллаһ Тәгалә тарафына сәяхәт итүдән аздырырга тели.

Таләб кылган ушал раһе гадәмдә,
Һәлакәт чаһыдыр һәрбер кадәмдә.

Ягъни Ходаны эзләү юлының һәрбер адымында һәлакәт коесы бар, ягъни һәрбер урында төрле фетнәләр бар. Әйтүләр буенча, вәкиләрнең тукталышы унике. Унике тукталышның һәрберсендә бер төрле фетнә булыр. Ул фетнәләрдән һичбер талиб үз-үзен коткара алмас, әгәр дә бер камил шәехе булмаса.

Гаҗәб юлдыр: тәмам михнәт-рәнҗ,
Вәләкин һәр карышда бер ниһане гәнҗ (яшерен хәзинә).

Ягъни Аллаһ Тәгаләне эзләү юлы гаҗәеп бер юлдыр: тукталышларның ахырына[1] кадәр михнәт чигүләр күп була. Ләкин шулай булса да, һәрбер карышында яшерен хәзинә бар, ягъни һәрбер тукталышта Аллаһ Тәгаләнең бер яшерен хикмәте һәм фазыйләте бар. Адәм баласы аны белмәс, әмма бу эшкә керешеп, аны татыганнан соң гына белер.

Чөнки бу тарикатьнең һәрбер тукталышы гүзәл, зәвыкълыдыр, аны бәян итү ничек мөмкин булыр, кеше үзе күреп татымыйча, аны бары белмәстер...

---

1 С.-П.да — ахирәткә (133 б.).

Ушал гәнҗе нәһан яткан зәминдә,
Каракчылар мөһәййаер (әзердер) кәминдә.

Ягъни бу яшерен яткан җирдә караклар, явызлар бар, һәрберсе бер посыкта («засадада») утырып, Аллаһ Тәгалә талибен аздырыр өчен торырлар. Бәс, камил шәех, шул каракларны куып, алар булган урыннан коткарып, мөриден кулыннан тотып, ... Ходай юлына туры илтер.

Әгәр булмаса юл башлагучы пир,
Салырлар буеныга нагяһ тәзвир (ялган).

Ягъни синең бер юл башлаучы шәехең булмаса, посыктагы угры-караклар, ягъни шәйтан, ... төрле хәйлә тозакларын салып, Хакны юлыннан аздырып, ялганга илтер.

Әгәр булмаса бер сахибе кәрамәт,
Имәс мөмкин кеше йиткәй сәламәт.

Ягъни Аллаһ Тәгалә тарафына сәяхәт иткәндә, синең бер кәрамәт иясе — шәехең булмаса, ул биек урынга исән-сау барып җиту мөмкин түгел. Күрмисеңме, фәлсәфәчеләр әйтә: «Безгә пәйгамбәрләр, әүлияләр кирәкмәс, барын да үз акылыбыз белән таныйрбыз, - диләр. — Пәйгамбәрләрне Аллаһ Тәгалә акылсызлар өчен җибәрде, һәм безгә мөршид кирәкмәс». Шулай үзләрен суфи итеп, акыллары белән дәлилләр китереп, ахыр чиктә үз дәлилләрендә шикләнә башлап, ул шикне хәл итә алмыйча, күпчелеге дөньядан кяфер булып үттеләр.

Кайчан һәр пир[1] белер котлуг юлыңны,
Табыб[2] ир яхшысын тапшыр кулыңны.

Ягъни Аллаһ Тәгаләне танучы булырга теләсәң, камил шәех булган кешегә ияр. Шундый шәех булсын ул, синең изге юлыңда хәлеңне белсен, диндар һәм тәкъва булсын. Әйткәннәр ки, мөршид булган кеше кырык яшьтән яшьрәк булмасын, хатынсыз һәм надан булмасын, һәм түбәндә искә алыначак ярамаган әмерләр бирү белән сыйфатланган булмасын.

---

1 Пир — карт; остаз. Гадәттә, суфыйчылык оешмасының (тарикатенең) җитәкчесен бу исем белән атаганнар. Мөршид, шәйх дип йөртү дә бар.
2 К.да — таныб (91 б.).

Ушал пиригә пирнең пире булгай,
Тарикать пишәсенең шире булгай.

Ягъни шәех булган кеше шәехләрнең камилрәге була һәм тарикатька иярүчеләрнең арысланы була. Моның мәгънәсе: батыйн гыйлемдә (эчке белемнәрдә) камил булып, мөридләренең лаексыз хәлләрен аңлаучы була, һәм аларның һәлакә килгән заманда игътибар һәм төшенү белән саклауга сәбәпле була, һәм аларда ярамас эшләрне бетерә һәм никадәр куркыныч урыннарда мөридләрне коткара һәм дә мөридләрнең табигатен белә һәм аларны аш-сусыз һәм кирәк-яраксыз юлга[1] күндерә. Әйтәләр ки, табигатьне танымаган кеше шәех булырга лаек түгел.

Тәхәллеф кылмаса шәргы эшедин,
Тамегълек булмаса һәргиз кешедин.

Ягъни бу шәех булган кешедә беркайчан да шәригатькә каршы килүче эш күренмәсен, йөрешендә һәм утыруында, ашавында һәм эчүендә һәм сөйләшүендә — барысы да шәригатькә ярашлы булсын. Һәм дә кешеләр кулындагы нәрсәгә комсызлык күрсәтмичә, бәлки, изгеләр кебек үзенең хәләл кәсебе белән яшәсен.

Алыб кулга чыраг гыйлме заһир,
Голуме батыйнында булса маһир.

Ягъни бу шәех булган кеше заһир гыйлемнән (ачык, тышкы белемнәрдән) дин зарурлыгы[2] күләменчә белә һәм гыйльме батыйнда (рухи, эчке гыйлемнәрдә) камил була. Кыскасы, шәригать мәсьәләләрен белеп, мөридләрен шик-шөбһәдән чыгарырлык дәрҗәдә була, вә батыйн белемнәрдә дәрәҗәле әүлиянең яртысы өлешеннән ким булмасын, аннан әзрәк булса, гыйльме батыйнда осталыгы юк дип саналыр.

Ул кеше әле үз-үзен дә саклый алмас, кайда монда мөридне коткару. Имам Казыйзадәдән җиткерелгән: шәех булган кеше уникe йөз хокук мәсьәләсен яттан белә һәм тәфсир буенча тугыз йөз аятьне мәгънәсе белән

1 К.да — йирле-йиренә (91 б.).
2 С-П.да — дин (135 б.).



www.darulkutub.com

аңлата һәм пәйгамбәрнең хәдисләреннән кырык хәдисне хәтерендә тота һәм моннан башка китапларга күз ташлап, авырлыкларны чишүче була, кире кагылган һәм гамәлдән чыкканны аерып, гамәлдә урнаштырылганны белә[1], синтаксистан играб[2] белер кадәр аңлар һәм дөрес уку гыйлеме — тәҗвидтән хәреф үтәү кадәр булыр, мәгънә гыйлеменнән хакыйкать белән кинаяне аңлар. Бәс, бу сыйфатлар белән белеп, дин белгече булса, — һаман да шәехтер, — диде.

Фәна булса тән вә җан тулайдин,
Котыла ма сивадин лотфе хәйдин.

Ягъни бу шәех булган кеше фәна әһеле булыр, ягъни үз-үзен оныта алыр. Тәннән һәм җаннан онытылып, Аллаһ Тәгалә тарафына тапшырылыр, җанына һәм тәненә бәла килгәндә сабыр булыр, Аллаһ Тәгаләдән башканы онытыр. Әйтәләр ки, Хәзрәте Шиблидән[3] сораганнар: «Фәна фи Аллаһи нә ула?» Җавабында әйткән: «Дөнья зиннәтләреннән бизү», - дигән. Һәм дә Әбүлмансур Матуриди[4] болай дигән: «Фәна фи Аллаһи шул була, ул бер тукталышның исемен, аны сөйләп бетерү мөмкин түгел, чөнки ул бик гүзәлдер. Бәс, ул тукталышка шундый кешеләр барып җитәр, нәфесенә каршы килеп һәм буйсынуын камил итеп, дөнья зиннәтләренән бизгән булса».

Кайу[5] ирмеш фәна булган нишани (билгесе),
Тәкәббер булмаса микъдар дани.

Ягъни шәехнең үз-үзен онытту дәрәҗәсе шулдыр ки, һичкайчан тәкәббер булмас, чөнки түбәнчелек пәйгамбәрләр холкыдыр...

Үзенең нәфсене ул әйласә пакь,
Булыб коллыкдта итсә ма габәдә накь.

1 К.да — «...мәүзугы хәдисләрне белә» (92 б.).
2 С-П.да — игъраз (135 б.).
3 Хәзрәте Шибли — Әбүбәкер Дулаф бине Җәгъфәр (861-946) — Багдадта гомер кичергән суфый. Әл-Җөнәйд һәм Хәллаҗның шәкерте.
4 Әбүлмансур Матуриди... әс-Сәмәрканди (870-944) — гыйльме калә тәгълиматендә махсус юнәлешкә нигез салучы.
5 С-П.да — кай (136 б.).

Ягъни ул шәехнең үз-үзен онытуы шулдыр ки, үзенең нәфесен хәрамнән һәм шикледән пакь итеп, Хак Тәгалә гыйбадәтендә булып... үзен хур итеп күрер[1].

Әгәрчә булмаса фаригъ эшедин,
Үзен ким тотса һәр мөэмин кешедин.

Ягъни ул шәех Хак Тәгаләгә гыйбадәтеннән бер сәгать тә азат булмас, үзен һәр мөэминнән ким итеп белер.

Ишетмәсә кеше һич мән дигәнен,
Үзе һәм белмәсә фаный икәнен.

Ягъни ул шәехтән кешеләр һичкайчан мин дигәнен һәм тәкәбберлек вә үз-үзен күрүне ишетмәсенннәр һәм дә үзе фәна фи Аллаһида (Аллаһ Тәгаләдә үз-үзен онытуын) белсен, ягъни үзен нинди тукталышта икәнен башкаларга әйтмәсен.

Үзе исә фәна булдым әймәсдер,
Фәна булган кеше һәргиз димәсдер.

Ягъни үз хәлен кешеләргә әйтмәс, үз-үзен онытучы үзен халыкка белдермәс.

Үзенең башыны сатса үзе кол,
Кайчан гакыйл кеше биргәй аңар пул.

Ягъни бер кеше үз-үзен сатканда, акыл иясе акча бирерме, чөнки колның үз-үзен сатуы дөрес түгел; шуның кебек шәехкә дә үз хәлен үзе әйтергә ярамас.

Әгәр ру бирсә бәгъзе мөкашиф,
Ышанмасдыр аңа һич мәрде гариф.

Ягъни әгәр йөз бирсә, кайчакта төшенкелек һәм танылу, гаҗәеп нәрсәләр күренсә дә, Аллаһ Тәгалә чынлап танучы моңа ышанмас, бәлки әйтер: «Минем гөнаһым гына күренде, башкасы түгел», — дип әйтер.

---

1 К.да — «..вә үзе дәхи тагать һә коллыкда улыб, ул шәйхенә... коллык вә гыйбадәт дийү үзене хур күрсә» (92 б.).

Әгәр күргән беләν үздин[1] китебдер,
Йитеб сән диб, аны шәйтан йитебдер.

Ягъни шундый ачылыш[2] күргәне белән үзеннән китсә, ягъни тәкәббер һәм үз-үзеннән горур булса, үзен олуг дип санаса, ул кеше шәйтан... кулыннан җиткән дип ышаныгыз. *Йитеб* сүзенең беренче булышмак мәгънәсендә, ә соңгысы җитү мәгънәсендә.

Бу төнне[3] төш белән төш кылма, әй хам (хыялый),
Бәян кылмак белән калмагай шам.

Ягъни бу әмердә истихарә төше белән яки камиллек табуыннан соң укуда гаҗәеп һәм гарәеп нәрсәләрне күрү белән аны төш вакытынча итеп коры калма, әй пошмаган кеше, ул төшдә күргән нәрсәләрне сөйли-сөйли, ахшам вакытына калырсың, таләп базарыннан кичкә калып, комачларың арзан булыр, ягъни теләгән нәрсәңнән коры булырсың. *Төш* сүзенең беренчесе риваять дигән сүз, соңгысы төш вакыты мәгънәсендә. Бәлки, төштә күргән нәрсәләрне сөйләмичә, һәрчак таләптә бул, чөнки ул төшнең кайберләре саташу гына, һәм онытылып уйга чумуның кайберсе ачылыш ярдәмендәдер. Мәгәр шул әмерне мөршидкә сөйләү урынлыдыр һәм аннан башканы бәян итү хәрамдыр.

Әгәр кем булмаса[4] күрмәкдин мәхафәт,
Йитәр ахшам, саба бу төшдин афәт.

Ягъни ул төш күргән кеше бу төшеннән курыкмаса, бу төшнең фетнәсе таң вакытында яки ахшам вакытында беленер. Ягъни әгәр изге төш була икән, аңа алданып, үз-үзен горурлыкка салыр, әгәр явыз төш булса, нәүмиз калыр...

Үзен айган кеше, әлбәттәдер, хам (ялганчы),
Вилаят тәхтигә баскан имәс кам (максат).

1 К.да — күздән (93 б.).
2 К.да — гаҗаиб вә гараиб (93 б.).
3 С-П.да — көнне (137 б.).
4 С-П.да — булса (137 б.)

Ягъни үз-үзен: «Мин кәрамәт әһеле һәм мөршид», — дип кешеләргә әйткән кеше, әлбәттә, ялганчы. Ул кеше вилаять дәрәҗәсенә җитеп, анда максатына ирешкән кеше түгел, бәлки, үз-үзен суфый итеп күрсәтеп, кешеләрдән мал алу һәвәсендә йөргән ялганчыдыр.

Әгәрчә һәр кичә күк булса тауфы,
Борынгыдин зиядә була[1] хәүфе.

Ягъни берәү, һәр кичтә җиде кат күкләрне гизеп, гарешкә барса да, ләкин Аллаһ Тәгаләдән куркуы барыннан да артык булса кирәк.

Мәбада горрә төшсә күңелгә,
У(л) горрә башласа афәт юлга.

Ягъни аңсыздан шундый кешенең күңеленә горурлык төшәр, ул горурлык аны фетнәле юлга юнәлтер. Ул кеше фетнәле юлга кереп һәлак булыр, тәкәбберләр төркеменнән булып үкенечкә калыр.

Булыр хаһәтлек ир, әлбәттә, хамуш,
Әгәр кылса[2] мәй, һич кылмагай хуш.

Ягъни берәүнең хәл (куәт) гыйлеменнән өлеше бар, ул кеше сөйләшмәс, хәленнән хәбәр бирмәс. Хәмер ачып җиткәч, һич күбеге һәм тавышы булмаган кебек, шулай хәл әһелләренең, камиллек торышына җиткәч, һич тә «мин-мин» дип әйткәннәре ишетелмәс.

Күтәрмәс өн вилаятлек херәдмәнд,
Сада чыкмас өнедин багласа канд.

Ягъни хәл гыйлеменнән булган акыл иясе авызын күтәрмәс, «мин шундый хәлифә, шундый ишан мин»... димәс. Шикәр камышының эченә, вакыты җитеп шикәр комы тулса, һичкайчан аннан тавыш чыкмас, никадәр генә кыймылдатсаң да. Шулай камиллек әһеленнән алай дигән сүз чыкмас, димәк.

1 С-П.да — булса (137 б.).
2 К.да — бетелсә (4 б.).

Димәс һәр кемгә әсраре хәкаек,
Әгәр табылса кәнҗ әхфасы лаек.

Ягъни хакыйкать серләрен белүче акыл иясе булган кешегә бер көтелмәгәндә хәзинә табылса, ул кешегә әйтмәс; чөнки әйтсә, бәлагә очрар, әйтмәве дөресрәктер. Шуның кебек берәү камиллеккә җитәр булса, әйтмәс.

Кеше очкан белән суйи сәмавәт (күккә),
Тәвәррыг (тәкъвалык) кылмаен ирмәс кәмаләт.

Ягъни берәү күктә очып йөрсә һәм аның очуы тәкъвалык белән булмаса, камиллек урынына җиткән димәгез — бәлки, бу истидраҗ (хәер), яки мәгунәттер (ярдәмдер).

Вәли улдыр: чыкарса масәваны,
Һавадиндыр таләб кылмак һәваны.

Ягъни вәли — изге кеше бу: күңеленнән Аллаһ Тәгаләдән башкага мәхәббәте чыксын һәм нәфес теләгәнне ташласын, чөнки Аллаһ Тәгаләгә мәхәббәт белән дөнья мәхәббәте бер җирдә бергә булмаслар.

Нәби[1] табигатедер рәштәи хәб[2]
Вәрәгъ (диндарлык) кылмак кәмаләте тәкаррәб.

Ягъни гыйбадәт җебе белән сыйфатлану пәйгамбәрләр табигате, гөнаһтан ерак булып, Ходага мәхәббәт итү камиллек әһелләренең якынлыгыдыр. Бу сәбәп белән Аллаһ Тәгаләгә якын булырлар.

Әгәр фил дәк ирер мөнһи вә гәр кыл,
Вәрәгы әсхаб әйтерләр: хәзәр кыл.

Ягъни әгәр шәригать боермаган эш фил кебек олы булса яки кыл һәм төк кебек кечкенә булса, тәкъвалылар

1 К.да — рәнби (94 б.).
2 С-П.да — чәю (138 б.).



www.darulkutub.com

әйтерләр: «Ул эштән[1] саклан!» Кыскасы, шәригать боермаган эш, кирәк кечкенә, кирәк зур булсын, - һәр икесе бер, аннан сакланырга кирәк.

Әгәрчә күб ирер җуде вә сөҗүде,
Күренмәс зәррәчә гариф вә җуде.

Ягъни хәрамнән, шикле эштән сакланмаган кешенең юмартлыгы һәм Аллаһ Тәгаләне төшенүе һәм сәҗдә кылу никадәр күп булса да, бөртек кадәренчә күренмәс, чөнки дә тыелган нәрсәләрдән сакланмаган кешенең барлык гыйбадәте юкка чыгар.

Әгәрчә заһир вә батыйн исә дөрес,
Сәкар алдында торган дик булыр[2] тәрс.

Ягъни хәтта тәкъвалы бу кешенең эче һәм тышы дөрес булса да, ягъни кешеләр аның тышыннан һәм эченнән дәрес[3] алсалар да, ягъни ул пакьлек белән сыйфатланган кешенең куркуы тәмуг алдында торган кебек булыр, Аллаһ Тәгаләдән һәрчак куркуда булыр, ничә кәрамәт иясе мөршид булса да, димәк.

Аның дик һадига кылсаң итагать,
Сәгадәтдер, сәгадәтдер, сәгадәт.

Ягъни бу сыйфат белән сыйфатланмыш кешеләргә иярсәң һәм аларның мөриде булсаң һәм һәрдаим аларга хезмәт итсәң, нинди зур бәхеттер!

Гидаи күчәи дәргяһ булсаң[4],
Өмиддер ки меңнең шаһы булсаң.

Ягъни шундый кешенең урамагы хәерче һәм теләнчеләр кебек һәрдаим шундый мөршиднең хезмәтендә булсаң, өмет бар, син күңелең падишаһы булырсың, ягъни күңел иркенлегенә хуҗа булып, төзәлүчеләрдән һәм әүлияләрдән булырсың. *Гидай* теләнче мәгънәсендәге төрек теле сүзе.

---

1 С-П.да — ул ашадан ашама (138 б.).
2 С-П.да — кылыр (139 б.).
3 К.да — файда (95 б.).
4 Бу юлны «гидаи күчәдер гиһ булсаң», дип тә укырга мөмкин.

Кеше кылса хилаф хөкме шәргы,
Аның җеңне дигел, я мәрде соргu.

Ягъни бер кеше мөршидлек дәвасын алса, ул кеше шәригатькә күп тапкыр каршы килсә, һәм аннан ярамаган эшләр күренсә, чыннан да, аны син җен диген, ягъни бу эшләрне җен ярдәме белән күрсәтер, яки соргы диген, ягъни соргы зәхмәте белән авырыйдыр. Шуның өчен бу хәлләр күренде, диген. *Соргы* дигәне бер авыру, җенлеләр белән сихерләгән кеше; ләкин үзе җеннәр белән мөгамәләдә булыр, алар белән күрешер һәм сөйләшер.

Әгәр су өстендә йөрссә ушал кәс (кеше),
Дигел җендән булыр су өстедә хәс.

Ягъни ул шәригатькә каршы булган кеше су өстендә батмыйча йөрсә дә таң калма, бәлки су өстендәге чүп-чар дип бел, алар да бит су өстендә батмас.

Һавага очса манәндә чебендер (чебен кебектер),
Аны һади (җитәкче) димә, шәйтанидиндер.

Ягъни ул диндар булмаган кеше һавадагы чебеннәр хөкемендә, аны тугры дип исәпләмә, шәех димә, бәлки, күренүче шәйтан гынадыр.

Күрән артык имәсдер, күрмәгән кәм (ким),
Кем иттика (диндар) булса, гыйндә Алла әкрәм.

Ягъни үз-үзен зур дәрәҗәдә күрүченең Аллаһ каршында мәртәбәсе артык булмас. Үзен ким күргән ким булмас, бәлки, Аллаһ Тәгалә каршында кем тәкъва, шул хөрмәткә иядер.

Кирәк табигъ ки, мәтбуг мөкәммәл,
Олуг тәндин булыр пәйда олуг зәл (күләгә).

Ягъни иярүче кешенең аны ияртән кешесе камил булырга тиеш, ягъни мөриднең мөршид булган кешесе камил камиллек иясе булырга тиеш, чөнки бернәрсәнең гәүдәсе зур булса, күләгәсе тагын да зуррак булыр, ягъни

Аллаһ Тәгалә каршында дәрәҗәсе күп булып, мөридләр тиз арада камиллек табар.

Кирәк күб талиб эчрә бер никү Ай,
Яруттмас[1] моңча йолдыз булмаса Ай.

Ягъни күп эзләүче яраннар арасында бер изге, акыллы мөршид кирәк, чөнки бит кичен йолдызлар да җиһанны яктырта алмас, араларында Ай булмаса, шулай мөридләр арасында камил мөршид булмаса, илаһи мәхәббәттән алган нурлар яктырмас.

Олуг һиммәт егетләргә кирәк пир,
Кәмансыз очмагай күб булса тир.

Ягъни олуг максатка омтылучы мөрид егетләргә пир булган мөршид кирәк, чөнки мөршидсез камиллек тапмаслар, чөнки ук савыты — садакта уклар күп булса да, җәясез алар очмас. Шуның кебек максатка баручы егетләр никадәр күп булса да, бер мөршид булмыйча, Аллаһ Тәгаләгә якынаюлары авыр, мөшкелдер һәм гыйшыклык капкасында ныклы була алмаслар.

Ушал чәндикә хәрбе алати асар,
Әгәр басәр йөресә, яуны басар.

Ягъни берәр гаскәр, сугышу ясау теләге белән йөргәндә, араларында җитәкче белән йөрсәләр, яуны басып, җиңүче булырлар, ягъни шулай мөридләр җәмәгате шәйтан гаскәрен үзләре генә җиңә алмаслар, мәгәр ки бер камил мөршид белән җиңәрләр. *Бәсәр* дигән сүзнең беренчесе башчылык һәм рәислек мәгънәсендәге фарсы сүзе. Соңгысы — заһир мәгънәсен белдерүче төрки сүз.

Сагылтыр (сау итәр) тәләбәне пире зәбәрдәст (оста куллы пир),
Коеның шурисен дәрья кылыр пәст.

Ягъни уйда булган борчылучы мөридне сәламәтләндерер күл өстенең иясе мөршид, бит коеның суы ачы булса,

1 С-П.да — яраттмас (140 б.).

дәрьяга салгач, әсәре дә калмас, һәммәсе ләззәтле булыр, шулай камил мөршид яхшылыгы белән мөридләрдә булган ярамас нәрсәләрне пакь итәр. *Тәләбә* дигәне борчылучы мәгънәсендә.

Төшеб шаһ илкенә бази качар баз,
Булыр загларга бази ул сәрафраз.

Ягъни бер карчыга хуҗасының кулыннан качса, ул карчыга, качканнан соң, каргаларга җитәкче булыр. Шулай бер мөршиднең мөриде аерылып китсә һәм аның тәрбиясеннән булып, халыкны аздырып, харап итәр. *Шаһ* дигәне хуҗа мәгънәсендәге сүз. *Баз* карчыга мәгънәсендә.

Бу тәгърифләргә садыйк булса пиреӊ,
Вәләкин булмаса раушан замиреӊ.

Ягъни югарыда искә алынган шартларга мөршидеӊ туры килгән чакта, шуннан соӊ мөрид булган кешенеӊ күӊеле яктырмаса,

Ирер ноксан үзендин күрмә, андин
Булыр сәгый (тырышлык), әлбәттә, пир мән дигәндин.

Ягъни бу әйтелгән камиллекләр шәехтә булса, мөрид дигәннеӊ мәхәббәте булмыйча, юнәлеше булмаса, ягъни шәригатькә тугъры килеп, шәехкә хезмәт итмәсә, кимчелеге үзеннән булыр, шәехтән күрмә, чөнки мөршид мин дигән кешенеӊ мәсләге бар булса кирәк.

Пирнеӊ фәрманыдин кылсаӊ тәхәллеф,
Тәәссефдер, тәәссефдер, тәәссеф (үкенеч).

Ягъни мөршидне боерган эшләрен куйсаӊ (үтәмәсәӊ), аныӊ хезмәтендә булмасаӊ, үкенечтер мөрид кешегә, чөнки өлеш тапмавы үзеннәндер. Әйткәннәр ки, шәех Шибли бер мөриде белән хаҗга китте. Гоман диӊгезе туры килде. Диӊгездә көймә булмады. Болар гаҗиз калдылар. Шәех Шибли хәзрәтләре намазлыгын су өстенә куйды. Утырды, мөридне дә утыртты һәм әйтте: «Әй мөрид, әйт син йә шәех

дип, - диде. — Мин әйтермен йә Аллаһ дип, башка сүз әйтмә», - диде. Шул рәвешле күпмедер вакыт барганнар иде, мөриднең күңеленә фикер килде: «Мин ни өчен Ходаемның зикерен ташладым, Ходаемны искә төшерим». Шәехне искә алудан туктады, «Йә Аллаһ», - дип бер тапкыр әйткән иде, намазлык суга төшеп, бата башлады. Шәех әйтте: «Тиз генә йә шәехем дип әйт, юкса һәлак буласың». Бу хикәяттән беленде: шәехнең әмеренә итәгатьле булса һәм аның әйткәнен үтәсә, Ходай Тәгалә тарафына якынаер, һәм әгәр аңарга кул бирмәсә, әмерләрен тотмаса, Ходайга таба якынлык табуы авыр икән.

## Юл кешесенең ризалык урынын теләү бәяны[1]

Кил, әй сакый, икәүлән әйлалик шөрб,
Ушал шөрбкә андин халык табар корб (якынлык).

Ягъни, әй сугаручы кеше, бу мәхәббәт шәрабен икебез бергәләп эчик. Ул шундый шәрабтер ки, барча кешеләр аның белән Ходай Тәгаләгә таба якынлык табарлар.

Шәраби бәргдер: андин булыр саху,
Кылыр бер мөддәгадин үзгәне мәхү.

Ягъни ул мәхәббәт шәрабе шундый шәрабтер ки, Аллаһ Тәгалә белән колның арасында мәхәббәт камил булып, Хак Тәгаләнең балкыган нуры белән исерер, моның соңында бу бәндәнең күңелендә Аллаһ Тәгаләдән башка нәрсәләр юк булыр. *Саху* сад хәрефе белән языла, исереклектән айну мәгънәсендә килә.

Әгәр фәгъфуре Чиндер, кайсаре Рум,
Мәхәббәт әһленең алдында мәгъдум (юкка чыга).

Ягъни Чин (Кытай) падишаһы, кайсар (Византия императоры) — боларның патшалыклары һәм дәүләтләре гыйшык әһелләре алдында барчасы юк кебек. Һәм аларның малларына һәм зиннәтләренә гашыйклар илтифат итмәс. *Фәгъфуне Чин* дигәне Чин падишаһы

1 Салик — юлчы, эзләүче. Биредә, суфыйчылыкка нисбәтән, юл кешесе мәгънәсендә килә. Булекчә исеменең мәгънәсе: «Юл кешесенең ризалык урынын теләү бәяны».

дигәнне аңлата. Рум халкының шаһына кайсар диләр. Иран һәм Туран халкының шаһларын хан дип әйтәләр. Ә Русия халкының шаһын император диләр[1].

Мәхәббәт җамыдин табса кеше бәһер (өлеш),
Нә кылсын мәлике Мавәраэннәһер.

Ягъни берәү мәхәббәт савытыннан эчсә, Аллаһ Тәгаләгә гашыйк булса, ни эшләсен ул малы вә милке белән, хәтта ки барча Мавәраэннәһернең (Урта Азиянең; Аму-Дәрья белән Сыр-Дәрья арасындагы җирләрнең) патшасы булсын, аңа игътибары булмас, чөнки Ибраһим бине Әдһәм Бәлх милкен куйган кебек. *Мавәраэннәһернең* телдәге мәгънәсе елга арты. Әмма, термин буларак, ул бер вилаятьнең[2] исеме. Бохара һәм Хәразем — боларны Мавәраэннәһер диләр.

Күңел мөле бер гали сыйфатдыр,
Мәхәббәт, гәнҗ, баг, мәгърифәтдер.

Ягъни күңел дәүләте һәм мөлке бер югары сыйфат, аны сыйфатлау мөмкин түгел. Ул — күңелдә мәхәббәт бакчасының һәм хәзинәсенең чыганагыдыр, Бәйтуллаһыдыр (Кәгъбәседер). Аны кайчан бәян итү мөмкин булыр!?

Ризаи Хәзрәте мәгъбуд ушанда,
Җәмигъ эстәгән мәкъсудлар анда.

Хәтта ул күңелдә Хак Тәгаләнең ризалыгы — андадыр. Барлык теләгән теләкләребез ул күңел өендәдер, Хак Тәгалә хәзрәтләре бит боерыр: тышкы рәвешкә карамас, бәлки ниятләргә һәм күңелләргә карар.

Аның дик мөлекнең солтаны булсаң,
Нә хаҗәтдер йир йөзе солтаны[3] булсаң.

---

1 С-п.да урыс хөкемдары телгә алынмый (142 б.).
2 С.-П.да — шәһәрнең (142 б.).
3 К.да — шаһы (98 б.).

Ягъни аның кебек күңел милеге падишаһы булсаң, сиңа ни хаҗәт булыр җир йөзендә падишаһ булу?! Чөнки дөнья падишаһы вакытлыдыр, ә ахирәтнең падишаһлыгы мәңгелектер.

Әгәр хәрдәлчә[1] булса миһре әгъйар,
Булыр батыйн күзе мәхҗубе әсрар.

Ягъни берәүнең күңелендә хәрдәл (горчица) орлыгы кадәр Аллаһ Тәгаләдән башкага мәхәббәте булса, Аллаһ Тәгаләнең серләреннән ул хәбәрсез булыр.

Ничек кем зәррән хәс төшсә күзгә,
Кылыр, әлбәттә, күрмәкне үзгә.

Ягъни күзгә бит бер бөртек кадәре генә тигәнәк керсә, ягъни чүп төшсә, әлбәттә, күзне күрүдән мәхрүм итәр, ягъни шуның кебек мәхәббәттә булучының күңелендә Аллаһ Тәгаләдән башка нәрсәнең мәхәббәте төшсә, ул гәрчә аз булса да, Аллаһ Тәгаләне сөюе үзгәрер; чөнки Аллаһ Тәгалә — көнчеләрнең көнчерәгедер. Кыскасы, Аллаһка бирелгәннең күңелендә бөртек кадәре башка мәхәббәт булмасын, иртә-кич Хак Тәгалә ризалыгын сорасын.

Адәми улдыр ки, Аңа гашыйк ула
Юлын ул дәргяһә итмә — гыйшык ула.

Гашыйк кылавыз (юл күрсәтүче) улмаенча, әй фәна,
Кемсә юлын дугры итмәс Хәзрәтә.

Гыйшкилә тотды каму галәме вөҗүд
(гыйшык белән тотты барлык галәм яшәешен),

Гыйшык иләдер бу кыям, бу сөҗүд (бу тору һәм иелү).
Һәркем ул гыйшка ирде мәнзилен (ул гыйшыкка тормышын корды),
Ул күрсәдер ирәнләр мәхфәлен (дәрвишләр яшәешен).

1 Хәрдәл — бик кечкенә үлчәү берәмлеге. Горчица бөртеге.

Багламасын юлыңны[1] бу аб, хакъ (су, туфрак),
Аслыңа бак, асылыңа, әй җане пакь.

Китмәенчә арадан бу маэман (киртә?),
Җан күзе күрмәз Хәкый, әй җане мән.

Дот колагың имди гыйшк әхваленә,
Сән дәхи кергел бу гыйшкның әхваленә.

## ...Сабыр булу бәяны[2]

Кил, әй сакый, мәхәббәт җамыдин мәй
Хәридар илкенә биргел пийапәй (пәр дәр пәй — бертуктаусыз).

Ягъни, кил, әй мәхәббәт шәрабы белән сугаручы, безне эчер. Сакый дигәннән мәгънә — Аллаһ Тәгалә үзе. Ягъни безне бер мөршиднең кулына тапшыр, димәк.

Хәридар — ул ирер җәз нияте фәрд,
Күңел күңләгенә йоктырмагай гәрд (тузан).

Ягъни хәридар дигәнебез Ходага рухи мәхәббәтнең үзендә булып, күңел күлмәгенә тузан йоктырмас, ягъни тәкәбберлек, хөсетлек һәм гөнаһтан күңеле бик тә саф булып, пакьлек белән сыйфатланган кешене хәридар диләр.

Кай[3] халәтдә булса иртә вә кич,
Хилаф хөкеме мәхбүб итмәгәй һич.

Ягъни ул суфый булган кеше кайсы хәлдә — кирәк авыру[4], кирәк сәламәт, шат, кирәк авыр хәлләрдә, иртә һәм кичләрдә гашыйк булган затының (мәгъшукының) хөкеменә каршы килмәс, бәлки көн-төн Аллаһ Тәгалә ризалыгын сорар.

---

1 С-П.да — булмасын юлыңа (143 б.).

2 Бүлекнең тулы исеме: Салик казага разый булмак вә бәлага сабыр кылмак бәяны.

3 К.да — кайи (99 б.)

4 С.-П.да — агырык (144 б.).

Бу йулның барчасын тай кылган (үткән) ирләр,
Риза бирмәк мәкам әгъласы дирләр.

Ягъни бу тарикать юлында йөргән кешеләр әйтер: «Хак Тәгалә хәзрәтенең бәла-казасына риза булу әүлиянең барлык мәкамнәренең югары дәрәҗәсе булыр, ягъни Хак Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкер итү һәм бәлаләренә сабыр булу — бу ике сыйфат олуг әүлияләрнең мәкамәдер (дәрәҗәсе, урыныдыр)».

Әгәр башында йөрсә асйайи сәнг,
Риза җүйәндә һәргиз булмагай тәнг.

Ягъни берәүнең башында тегермән ташы йөрсә, ягъни никадәр зур бәлаләр астында калса, Аллаһ Тәгаләнең ризалыгын теләгән кеше һәрчак ул кадәр бәлаләргә тар күңелле булып калмас, Аллаһ Тәгаләнең ризалыгын теләр, димәк.

Әгәр һәр көндә эчсә зәһәр айагын (савытын)
Сөекле бәндәсе чытмас кабагын.

Ягъни бер сабыр кеше һәр көнне савыттан агу эчсә, ягъни һәркөнне тәнендә төрле авыру булса да, Аллаһ Тәгаләне сөюче кол[1], рәнҗеп, йөзен чытмас, Аллаһ Тәгаләнең биргәнен разый булыр.

Кеше кем казыйлык намендә[2] булса,
Кылыр шөкер аждәһа кямендә[3] булса.

Ягъни бер кеше Аллаһ Тәгалә ризалыгын теләсә, ул кеше, хәтта аждаһа авызында булса да, Аллаһка шөкер итеп, һәрчак разыйлыгын теләр. *Намендә* сүзе монда зәвык мәгънәсендә, Сәмәрканд халкы телендә. *Кямендә* дигәне фарсы телендәге кяф хәрефе белән язылa, авыз мәгънәсендәге фарсы сүзе.

Риза әйванында табкан кеше җа,
Димәк ва, бабе афәт булса һәм ва.

1 К.да — кемсәнә (99 б.).
2 К.да — тамендә (99 б.).
3 К.да — гамендә (99 б.).



www.darul-kutub.com

Ягъни берәрсе ризалык сараенда урын тапса, бәла ишекләре ачылгач, «ва» дип тавыш күтәреп[1], аһ-зар итмичә, һаман ризалык үтенеп торыр. *Ва* дигән сүзнең беренчесе кайгы сүзе, хәсрәтле чакта кычкырыла; икенчесе ачу мәгънәсендәге кашгарый теле сүзе.

Әгәр мәгъзе делең аерылса я пуст,
Егны йыг, әгәр чын кол сән, әй дуст.

Ягъни синең әгәр дә бәла-каза куредән күңел маең аерып аерылса, яки тирең һәм тышың тәнеңнән аерылса, сабыр итеп елауны куй, әгәр дә син чыннан да[2] Аллаһ Тәгаләне сөйгән кол булсаң. *Егны* дигән сүз елау мәгънәсендә. *Йыг*[3] дигән сүз куй, калдыр мәгънәсендә. Икесе дә төрекмән теленнән.

Сүнәр гамь төшсә һәм азадә ирга,
Очар ут, төшсә хәсдин хали (азат) йиргә.

Ягъни бәла-каза азат кешегә төшсә, алар сүнәр, ягъни юк булырлар; яныл торган ут очып, бер җиргә төшсә, ул җирдә чүп-чар булмаса, ул ут сүнгән кебек. Шуның кебек ихлас бәндәгә авырлык килсә, ул сүнеп юк булыр, бәндә сабыр итәр, димәктер. *Азад ир* дигән сүз топ мәгънәсеннән күчерелеп, сабыр мәгънәсендә куелды. *Очар* дигәне сүнү мәгънәсендә. *Хәс* дигәне чүп-чар мәгънәсендә.

Ходa әмригә гакыйл гамь йиймасдыр,
Димәс: гәрдун кылыр гәрдун имәсдер.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең биргән бәла-казаларына акыл иясе булган кеше кайгырмас һәм әйтмәс: «Бу кадәр зур казалар мине ким-хур итте», — димәс. Һәрчак сабыр итәр. *Гәрдун* дигән сүзнең беренчесе күк йөзе мәгънәсендә. Бәла-казаны күкләр белән бәйләве күчерелмә мәгънәдән.

www.darulkutub.com

1 С.-П.да — әйлаб (145 б.).
2 С.-П.да — раст (145 б.).
3 К.да — йыг (100 б.).

Хода хөкемендә һәркем булса мәмнүн,
Күтәрмәс өн әгәр башын кылыр ун.

Ягъни берәрсе Аллаһ Тәгаләнең хөкемнәренә баш исә һәм буйсынса, ул кешегә бәла килеп, башын ярып, ун кисәккә бүлсә дә, ул авызын күтәреп, аһ-зар итмәс, һәрчак сабыр булыр. *Өн* сүзенең беренчесе аваз мәгънәсендә. Икенчесе (ун) бер сандыр.

Ботагга сөрсәләр ташлап ботагдин,
Сәнадин үзгә чыкмас гаклы сагдин.

Ягъни бер сабырлык иясен газаплап, агачның бер ботагыннан икенче ботагына ташлап газапласалар, сәламәт акыл иясе булган кеше Хак Тәгаләне зикер итүдән һәм мактаудан башка нәрсә эшләмәс.

Әгәр къиндыр, әгәр мең кылсалар къин,
Кайчан төшкәй чын ирнең күңленә чын.

Ягъни бер колны мең тапкыр кыйнасалар һәм суксалар, ул кол, әгәр Аллаһ Тәгаләнең чын колы һәм сабырлык ияләреннән булса, күңеленә авыр булып, йөзен чытмас, бәлки Аллаһ Тәгаләдән һәрчак сабырлык теләр дога белән. *Къин* сүзенең беренчесе тугры һәм ихлас мәгънәсендәге гарәп сүзе[1]. Икенчесе кыйнау һәм сугу мәгънәсенәге төрки сүзе. *Чын* сүзенең беренчесе тугры ир һәм туры, ихлас һәм сабыр мәгънәсен белдерүче төрки сүз. Икенчесе кыюлык һәм тәвәкәллек мәгънәсендәге фарсы сүзе.

Кай[2] халәт белән җан булса тәндә,
Булыр шөкер һәмишә, разый бәндә.

Ягъни сабырлык иясенең җаны-тәне нинди халәттә булса да, ул сабыр итәр, Аллаһ Тәгаләнең биргәненә шөкер итәр.

Олуг йулдин адашкан ничә бигакыл,
Кылыр ирләрдин ул йалганчылар нәкыл.
Ягъни бераз юлдан чыгып адашкан акылсызлар

1 С.-П.да — төркидер (146 б.).
2 С.-П.да — каиил (146 б.).

әүлияләрдән күргән һәм ишеткәнне үзләренә күчерерләр, ягъни әүлияләр мондый эшне кылды..., хәлбуки, ул эш шәригатькә каршы торыр. Бездә аңа кушылабыз, дип әйтерләр. Боларның барысы ялгандыр. Чөнки чын әүлия булган кеше шәригатькә каршы гамәл башкармас.

Кеше кем гашыйкы дидар хакдыр,
Мәхәббәт әһле берлә һәм сабакдыр.

Ягъни берәү Хак Тәгаләнең затына гашыйк булучылардан булса һәм дә Аллаһ Тәгаләне сөючеләр белән сабакташ булса,

Нә хаҗәт үзгәчә тагатьләр андин,
Булыр йөзе кара мондаг дигәндин.

Ягъни ул гашыйк булган кешегә ни файда булыр, әгәр буйсынуы һәм гыйбадәт кылуы шәригатьтән тыш булса, бәлки буйсынуның шәригатькә ярашлы булуы кирәктер. Әгәр берәү әйтсә: «Әүлияләрнең шәригатьтә эше юк», — дип, аның йөзе кара булыр, үзе кяфер булыр.

Боерганига һәркем булса мөнкер,
Гоман йукдыр булыр, әлбәттә, кяфер.

Ягъни берәү Аллаһ Тәгаләнең боерган әмерен инкарь итсә, һичшиксез, ул — кяфер; ягъни әүлияләр шәригатькә каршы эш эшләсә дә зыян юк, дигән кеше кяфердер.

Ушал халкы ки бигакыл имешләр,
Ходаның дошманын гашыйк димешләр.

Ягъни шундый кешеләр әйтерләр: «Әүлияләрнең һәм мәшаихләрнең шәригатькә каршы эшләүләре безнең күзгә күренсә дә, аларның күңелләре сафтыр. Теләкләре һәм әмер итүләре тәҗрибә өчендер». Мондый карашларның барысы да акылсызларныкы. Алар Ходайның дошманын Аңа гашыйк кеше, әүлия дип санарлар, ә бит биш вакыт намазны калдыру һәм гайбәт сүз йөртү — барчасы Аллаһ Тәгалә сөймәгән эшләр. Ходай сөймәгән эшне эшләп, Аллаһка ничек якынаеп булсын!?



www.darul-kutub.com

Дил, җан берлән булган гашыйкы зар,
Хилафе хөкем кылмыш зәррәи кяр.

Ягъни берәү күңеле, җаны белән Аллаһ Тәгалә хәзрәтенә гашыйк булса, ул кеше Аллаһның хөкемнәренә бөртек кадәр дә хилафлык итмәс, бәлки ризалык капкасына утырыр (ризалыгын өмет итәр)[1].

Боерган эшләренә шад вә[2] гамьдә
Кылыр бердәк (бердәй) фәрагатьдә, әләмдә.

Ягъни Аллаһка гашыйк бәндә боерылганнарны үтәр, аларны иркен вакытта да, тар вакытта да, кайгы һәм шатлык вакытында да һәм авыру чагында да калдырмас. Беркайчан да Ходай боерганга каршы булмас.

Әгәр тултырсалар йирнең йөзене,
Кызыл тала (теллә, алтын) белән салмас күзене.

Ягъни җир йөзен кызыл тәңкә белән тутырсалар, Аллаһыга гашыйк бәндә, күзен йомып, ул тәңкәгә мәхәббәт итмәс, бәлки һаман Хак Тәгалә хәзрәтенең ризалыгын теләп утырыр. *Тала* дигәне динар төшенчәсен белдерүче фарсы сүзе, аның авырлыгы җиде мыскал кадәр була.

Бәла укы кадалса, ормагай аһ,
Кылыч башига килсә, бозмагай раһ.

Ягъни Аллаһ Тәгаләгә гашыйк бәндәгә бәла угы кадалса да, аһ дип кычкырмас[3]. Хәтта берәрсе аның башына кылыч куеп мәҗбүр итсә дә, ул шәригатьне бозмас, бәлки шәригатькә тугры булыр.

Кеше кем кылса гашыйклык лафын,
Кылырмы һич мәгъшукыны хилафың.

Ягъни берәрсе Аллаһ Тәгаләгә гашыйкмын дип дәгъва кылса, Ходай әмерләренә каршы килмәс, бәлки Аллаһ ризалыгын теләп, Аның боерган эшләрен үтәр икән.

1 С.-П.да бу соңгы өч сүз юк (147 б.).
2 С.-П.да бу сүз язылмаган (147 б.).
3 С.-П.да — чагырыб хикаят әйләмәз (148 б.).

Мөселманига[1] йөз чуб орды бер дүн,
Ушал азадәдин һич чыкмады өн.

Ягъни бер мөселман кешенең йөзенә бер явыз дәүләтле бәдбәхет агач белән сукты, яки аны йөз мәртәбә сукты. *Йөз* сүзендә киная бар: бу мөселман кешедән һичбер тавыш чыкмады, ягъни ачу белән яман сүз әйтмәде, түзде. Сөйләүләр буенча, ул мөселман дип Ягъкуб Чәрхи аталган. Суккан кеше Лави Һинди дигән бер кара кол иде.

Диде бер назари куб: хаким вар,
Бу әйде: хакимем хазыйрдыр, әй йар.

Ягъни бу икәүнең маҗарасын карап торучы бер кеше бар иде. Ул әйтте: «Әй мөселман, сине ул явыз нахакка сукты, бар син казыйга, хөкем итеп, моннан үч ал». Бу мөселман исә җавап бирде: «Минем хакимем Аллаһ Тәгалә, һәр җирдә ул бәндәсенең хәлен күрә, белә, ахыргы көндә бәндәсен үзе хөкем итәр. Ни өчен дөнья хакимнәренә барыйм?»- диде.

Тән-ү җан җанан әмлаке Раббыдыр,
Мәкасыйд эстәмәк бездән гаҗәбдер.

Ягъни ул сугылган кеше әйтте: «Минем тәнем, җаным — барысы да Аллаһ Тәгаләнең милке. Бәс, шулай булгач, безгә үз максатларыбыз белән хакимнәргә бару гаҗәеп эштер, кодрәтле падишаһ — Аллаһы — үзе хөкем итәр үзенең милкен, диде. Әйткәннәр ки, Лави Һинди бу сүзне ишетеп, зар елап Ягъкуб Чәрхи янына килеп, разыйлыгын сорады. Ягъкуб, ул Һиндине кичереп, дөнья һәм ахирәт максуды белән дога кылды. Хак Тәгалә... кабул итеп, Хуҗа Бәһаэддин[2] әүлиянең хезмәтендә булып, камиллек тапты. Сөйләүләр буенча, Ягъкуб Чәрхи Хуҗа Бәһаэддиннең мөридендә тәрбияләнде. Өйлә вакытында катнашып, икенде вакытында ул җирләрнең олуглары арасында урын тапты, дин белгече исемен алды.

1 К.да — мөселманны (102 б.).

2 Хуҗа Бәһаэддин (Баһаведдин) Нәкышбәнди — XIV йөздә Урта Азиядә яшәгән атаклы суфый.

## Нәфес — теләкләрдән баш тартып һәм Аллаһтан нык курыккан юлчы бәяны[1]

Кил, әй күңел, җиһан сәүдәседин кич,
Кадәм гаме кишвәренә ормагыл һич.

Ягъни, әй күңел, бу җиһанның теләкләреннән һәм бәхетләреннән үт, дөнья өчен кайгы-хәсрәттә булуны ташла, ахирәт турында уйлан, тәүбә һәм истигъфар кыл...

Җәсәд калмасдин элгәре нәфәсдин,
Һәва күб кылмагыл, кичкел һәвасдин.

Ягъни тәнең җаныңнан аерылганчы, нәфес теләкләрен куеп, гөнаһлардан тәүбә ит.

Дәри тәүбә ачыкда эстә максуд,
Эш үткән соңында пәшиманда ничек суд!?

Ягъни тәүбә капкалары ачык вакытта гөнаһларыңнан тәүбә ит, чөнки үлгәннән соң терелеп, тәүбә кылу юк. Үкенечкә калдырсаң, файдасы булмас ул көндә үкенүдән. Әйткәннәр ки, үлгәнче өч ел элек кабул булыр. Кайберәүләр әйткән, өч җомга элек булса. Һәм кайберәүләр әйткәннәр - өч көн элек булса. Һәм кайберләре әйткәннәр, җан бугазга менгәнче өч сәгать элек булса[2]. Ләкин егетлек һәм куәтлек чорында тәүбә итү мең тапкыр яхшырак картлык заманыннан... Ходай ул бәндәнең дусты булыр икән.

Игел тизрәк Ходаның тагатигә,
Кин куйма бу дәмне сәгатигә.

Ягъни тиз арада тәүбә ит; бер сәгатьлек дөньяга алданып, тәүбә кылуны кичектермә. Аллага буйсына башла.

Егетлекдә гаҗәб хуш хәүф-зари,
Йагынлыг килсә, хуб елның бәһари.

1 Ягъни: Нәфес-теләкләрдән баш тартып, (Алладан) куркуы күп булган юлчының (суфыйның) бәяне.

2 Бу төр санап киту С.-П.да юк.

Ягъни яшьлектә тәүбә итү, Аллаһ Тәгаләдән куркып елау гаҗәеп яхшы гамәл. Чөнки Аллаһ Тәгаләдән куркып тәүбә кылучы егетләргә аптыраса кирәк. Чөнки яшьлектә булган тәүбә тәэсир ясарлык булыр. Аз кылган гамәле күп саналыр, аз гына гомере озын гомерле кешенекеннән файдалырак үтеп, күп өстенлекләр хасил булыр. Яз көннәрендә бит яңгыр күп яуса, ул елны ашлык күп булыр һәм бәрәкәт иңәр...

Күзедин яшь куркыб түгәр яшь,
Дөрре рәхмәт булыр һәр яшечә таш.

Ягъни әгәр яшь кеше Аллаһтан куркып, яшен түксә, һәрбер тамчысы рәхмәт энҗесенә әйләнеп, савабын күп алыр. *Яшь* сүзенең беренчесе егет кеше мәгънәсендә, ә икенчесе күз яше мәгънәсендә. Икесе дә төрки сүз. *Чаш* дигәне фарсыдагы җим хәрефе[1] белән языла, күп мәгънәсен белдерә.

Мәбада (Ходай күрсәтмәсен!), тәүбә кылмасдан борынраг,
Әҗәл килсә китәрсән тәүбәсез даг.

Ягъни уйламыйча, тәүбә кылмас борын әҗәл килсә, үкенеч белән китәрсең. *Даг* үкенеч мәгънәсендәге гарәп сүзе.

Үлемне даимән янында белгел,
Аның илкен гәрибанында белгел.

Ягъни үлемне һәрчак янында тора дип бел, үлемнең кулы якаңа ябышкан дип бел.

Үлем сакыйсын пишанәдә бел,
Ләбеңне даимән пәймандә бел.

Ягъни үлем шәрабен сузучы затны, ягъни Газраил г-мне, каршында[2] ширбәт суза дип, иренең белән үзең

---

1 Әмма бу сүз С.-П.да (149 б.) һәм К.да (104 б.) ч хәрефе белән язылган.
2 К.да — тугрысында (104 б.).

эчүче дип бел, ягъни көне-төне, гомерең үткән саен, үлем ширбәтен йотым-йотым эчәм, дип бел.

Күтәребдер кылыч безгә салырга,
Кеше белмәс, куярмы дәм (сулыш) алырга.

Ягъни әҗәл, бер җәллад кебек кылычын күтәреп, безнең муеныбызга салырга әзерләнеп тора. Кешеләр моны белмәс, ә әҗәл килеп җиткәч, сулыш алырга да ихтыяр калдырмас.

Әҗәл тартыб торыбдыр йәй (җәя) белән ук,
Йәш(ре)нер йир, качар дәрманымыз йук.

Ягъни әҗәл, бер аучы кебек, җәя белән укны тулысынча сузып, атарга теләп торыр. Безнең аннан качарга хәлебез юк.

Белерсән йук бу дөньяның бәкасы,
Кадәм (аяк) куйган йирендер йир йакасы.

Ягъни ни өчен тәүбә итмисең: һичшиксез беләсең, бу дөнья мәңгелек түгел; әйтерсең син бу дөньяда җир якасында торган кеше кебексең, ягъни бу дөньяны озак барыр дип санама, ул бит бер сәгатьлек дөньядыр...

Тәгаҗҗеб, мондин үтмәс җир ләбендә (читендә),
Бәни Адәм һәнүз (һаман) үз матләбендә.

Ягъни гаҗәбе шул: Адәм балалары үлемнән котылмаячакларын, аны һичшиксез булачагын беләләр, ә үзләре нәфес теләкләре артыннан йөриләр.

Кадәм дәрья йөзендә руйе хәсдә,
Һәнүз әүлад адәмнең һәвәсендә.

Ягъни кешеләр аякларын диңгез өстенә куйганнар, ягъни үлемгә әзер булып торалар, ә үзләре һаман түбәнлектә, һаман юк фикерләрен алып куеп, үлемгә яраклашмыйлар.

Сәхәр булса нида әйләр (чакырыр) фәрештә,
Ишетмәэ бәндә гафләте сәрештә (җан иясе).

Һәр төнне сәхәр вакытында дүртенче кат күк өстендә бер фәрештә кычкырыр. Ул фәрештәнең тавышын ваемсызлык каплавында булган кешеләр ишетмәсләр, ә башка хайваннар ишетер. Ул фәрештәнең кыяфәте әтәч сурәте кебек, диләр. Канатын канатына сугыб кычкырыр. Ул фәрештәнең исеме Тунийаил[1], диләр. Һәм җир йөзендә күпме әтәч булса, барысы аның тавышын ишетеп кычкырырлар.

Сәне хәлкъ әйлагән (тудырган) солтаны галиб,
Һәмишә бәндәседин тәүбә талиб.

Ягъни ул фәрештә әйтер: «Әй Адәм балалары, сезне яраткан, өстен булган гадел падишаһыбыз һәрвакыт сездән тәүбә сорый, тәүбә итегез».

Икәмнең (иямнең) мәгъфирәт (ярлыкау) дәрьясыдыр хуш,
Кил, әй бәндә, ул дәрьядин ит нуш.

Ягъни фәрештә әйтер: «Аллаһ Тәгаләнең рәхмәт елгасы һәрчак кайнап тора; әй кешеләр, шул елгадан эчегез, ягъни тәүбә итегез».

Икәмдин (иямдин) лотфе рәхмәт бабын ачмак,
Гаҗәбдер, бәндәседин монча качмак.

Ягъни аның рәхмәт ишеге ачык, тик бәндәләренең ул рәхмәттән качуы аның газабына дучар булу.

Ятырсән табка (? ваемсыз), имди уйангыл,
Дил-җаның белән хәзрәткә йангыл.

Ягъни никадәр гөнаһ кылдың, барысыннан тәүбә итегез, башыгызны югары тотмагыз, тәкәббер булмагыз[2].

---

1 К.да — Турнийаил (105 б.).
2 К.да — юкары кылма, игелгел (105 б.).

## Үгет-нәсыйхәт

Әгәр йир өстенең солтаны булдың,
Үлем чәнгалигә ахыр тотылдың.

Ягъни син җир йөзенең падишаһы булып хөкем итсәң дә, ахыр бер көнне үлем чәнгаленә, ягъни тырнагына эләгеп, кара җир астына керерсең, үлемнән калмассың, диде.

Әгәр табсаң хәяте Хәзрәте Нух,
Кылыр бер үлем җаныңны мәхрүм.

Ягъни син Хәзрәте Нух г-мнең гомере кебек озын гомерле булсаң да, ахыр бер көнне үлем килеп, җаныңны җәрәхәтләп китәр, һаман шул җир астында калырсың.

Әгәр табсаң хәяте Хозыр, Илйас,
Китәрсән бу җиһандин әййүһан-нас[1].

Ягъни син Хозыр белән Ильяс г-м гомерләрен кичерсәң дә, ахыр беркөнне китәрсең һәм үләрсең, әй адәм балалары, ничек гафил була аласыз?!

Нәдер тәүбә димәк? — Янмак гөнаһдин,
Төзек юлга йөрмәк үзгә раһдин (юлдин).

Ягъни ни ул дигән кешегә җавап шул: гөнаһларыннан кире кайту һәм төзек юл тарафына йөгерү һәм бозык юллардан баш тарту.

Хода дәргяһыда, чөн әйладең гаһед,
Аны сындырмагыл нәфес илә җәһед.

Ягъни син Ходай Тәгаләнең катында тәүбә итеп вәгъдә биргәч, ул тәүбәңне бозмаска тырыш һәм Аллаһ Тәгаләдән тәүбәңдә нык булуыңны телә.

Әгәр тәүбә димәк чыкды телеңдин, —
Нә сүд, булмаса җан вә делеңдин!?

---

1 С.-П.да — әййүһа-ннас (152 б.).

www.darul-kutub.com

Ягъни әгәр синең авызыңнан тәүбә дигән сүз чыкты исә, ни файда булыр ул тәүбә җан һәм күңел белән булмаса?!

Дел-җан берлән кылганның нишаны,
Йәнә кылмаса тәүбә кылган аны.

Ягъни тәүбәне җан һәм күңел белән дөрес итеп кылган тәүбәнең билгесе шул: ул тәүбә кылган нәрсәләрне тәүбә кылганнан соң эшләмәс.

Әгәр чын йанәсан тарымыш (?) бу йанә,
Тәһи[1] пайанәдер кайрылма[2] бу йанә.

Ягъни син чын күңелдән тәүбә кылып, гөнаһларыңнан кайтсаң, тәүбә тарафында тугры бул һәм кылган тәүбәңдә даими бул, йомшаклык җиренә аяк бас, тәүбә итүчеләрдән аерылма, һәрчак тәүбә итүчеләр белән бер мәҗлестә бул. *Бу йанә* дигән сүз тараф мәгънәсендә. *Тәһи* дигән сүз йомшак мәгънәсендә, аннан төп мәгънә - шәригать әмерләрендә булу...

Нәдам (үкенеч) нурын күңелдин кыйлма гайб,
Әгәр таиб ирерсән, китмә таеб.

Ягъни беркайчан да үкенү нурын күңеленнән югалтма. Тәүбә кылгансың икән, аны бозып, таеп егылган кеше шикелле харап булма.

Улар бер гаһд илә бер хәйли булса,
Әгәр чәндикә гыйшрәт мәйле булса.

Ягъни үзара килешү булыр бер хыяллы кешегә, ягъни хыялында Аллаһтан башкасы булмаса, хәтта дөнья рәхәтләренә теләге булса да, нәфесе гөнаһка тартса да, нәфесенә каршы килеп тәүбәсен сындырмасын.

Күңел тәсдыйкы — ришәдер, гамәл — шах,
Олугы — тәүбәдер, сындырма гөстах (дорфа).

---

1 С.-П.да — нә (106 б.).
2 К.да — тайрылма (106 б.).

Күңелнең дөреслеге иман агачының тамыры кебек, изге гамәл — ботагы кебек. Боларның зур булуы, ягъни үсүе — тәүбә. Зинһар, ул тәүбәне сындырма, гөнаһ кылу белән иман агачын корытма. *Ришә* дигәне агач тамыры мәгънәсендәге фарсы сүзе.

Сынык[1] шахә зарбе белән зәхм алыб асыл,
Мәбадә калмагай хөшк (коры) ахры фасыл.

Ягъни әйткәннәр ки, йөзем һәм тирәк агачларының ботакларын, көз көне алып, җиргә күмеп куялар. Икенче ел аннан йөзем җимеше була. Бәс, бәетнең мәгънәсе шул: сынык ботакны җиргә күмеп куйма, аның тамыры авыру булыр, агачы корыр. Шуның кебек, иманны сакламыйча, иман бәхетеннән мәхрүм калсаң, Аллаһ сакласын, башка изге гамәлләреңнең берсе дә дөрес булмас, юкка чыгып, харап булырсың. Саклан гөнаһтан, тәүбә ит, тәүбәңне бозма, нәфесеңә иярмә.

Җәримәи чәрки берлән заһирың сир (тук),
Булыбсән кер (керле), нәдәм дәрьясына кер.

Ягъни гөнаһ тузаны белән тышкы әгъзаларың тук булгандыр, ягъни гөнаһ белән тулгандыр, әгәр син гөнаһ кере һәм пычраклыгы белән булган булсаң, үкенү елгасына кер, ягъни һәрчак тәүбә итеп үкен. *Җәримә* дигәне гөнаһ мәгънәсендә. *Кер* дигән сүзнең беренчесе ‘кер, пычрак’ мәгънәсендә, гарәпчә — дәнс, икенчесе... керү мәгънәсендә. Икесе дә төрки сүз.

## Рабига хикәяте[2]

Ишеткел Рабиганың әшкен (күз яшен), әй шаһ,
Берәүнең чадырына тамды нәгяһ.

Ягъни, ишет, хикәятләрдән Рабига атлы бер әүлия хатынның күз яше хикәятен. Ул бер заманны хатыннар

---

1 С.-П.да — сонигъ (153 б.).

2 Рабига әл-Гадавийа (713-801) — гомеренең зур өлешен Басрада уздырган атаклы суфый һәм шагыйрә. Ул илаһи мәхәббәт, аскетик тормыш тарафдары. Катлаулы гомере, көчле таланты, оригиналь карашлары белән ул Шәрык рухи дөньясына көчле йогынты ясый. Татар әдәбиятында да билгеле. Мәсәлән, Әбелмәних Каргалый иҗатында Рабиганың изгелеге хакында шигъри хикәят бар.



www.darul-kutub.com

мәҗлесендә катнашты. Рабиганың күңеленә Аллаһтан курку төшеп елады, күзеннән яшь агып, игътибарсыздан, бер хатынның кыекчасына һәм бөркәнчәгенә тамды.

Диде: бу чадраңны (чадраңа), әй карындаш,
Кызыл кандыр күземдән чәчрәгән яшь.

Ягъни Рабига чадрасына күз яше тамган хатынга әйтте: «Әй кардәш, чадраңны ю, чөнки анда минем яшем кызыл кан, — диде. — Бәс, кан булгач, димәк, чадраң пычранды».

Ойатлигъ гасыйәдин, әй гөзидә.
Булыбдыр канә тәбдил абе дидә.

Ягъни Рабига әйтте: «Әй кардәшем, минем күз яшем гөнаһларым аркасында кара судан кызыл канга әйләнде; шуның өчен бөркәнчегең нәҗес белән пычранды». Гыйбрәтле нәтиҗә ясап, боерды:

Әгәрчә Рабигадер мәрәи биз-зат,
Ирәнләр куйдылар таҗер-риҗал ат.

Ягъни ирлек заһитлек (изгелек) белән, зикер һәм сакал белән түгел. Менә бит, Рабига, хәтта хатын-кыз булса да, аңа ирәннәр таҗы дип исем куйдылар...
...Ул Рабига җәяү, төрле мәшәкатьләр күреп, Кәгъбәтуллаһны зиярәт кылырга китте. Җиде елдан соң Кәгъбәтуллаһка барып җитте. Сөйләүләр буенча, Кәгъбәтуллаһ Рабига хатын каршына килде, үзен тәваф кылдырды (әйләндереп йөртте). Хәзергесе көндә дә Кәгъбәтуллаһның шәһәренә бер көн ярымлык җирдә бер чишмә бар. «Рабига чишмәсе» дип әйтәләр.

Аның шаинендә ки кәсбе кәмаләт,
Гадәдиндер бирун (хисаптан тыш), әхвак хәлавәт.

Ягъни Рабиганың затында булган гыйбадәт кәсебе һәм камиллек исәпкә һәм хисапка бирелми. Аның бәян итү мондый кыскалыкка сыешмас, димәк.

www.darul-kutub.com

Моның дик егласа[1] андаг никурай,
Безнең дик русийаһың (руи сийаһның) халигә вай.

Ягъни андый изге фикерле әүлиябез, болай итеп, күзләреннән каннар акканчы еласа, кара йөзлеләрнең хәле ни ояттыр, чөнки бездә ныклык аздыр.

Һәмишә зәүкымыз гыйш-көлешкә,
Йитешмәс иртә кылган тәүбә төшкә.

Чөнки безнең уебызы һәрчак яхшы тереклек һәм уен-көлке тирәсендә. Хәтта тәүбә итсәк тә, ул тәүбәдә ныклык юк: иртә белән тәүбә кылсак, көннең төш вакытында тәүбәбезне бозып, һәрчак элеккеге хаталы хәлебезгә китәбез. Кайда ул безгә Рабига кебек камиллек табу!?

## Үтенеч-теләкләрне үтәүчегә мөнәҗәт[2]

Иляһи, лотф кыл мән мөбтәлягә,
Төшебдермән бипайани[3] (чиксез) бәлагә.

Ягъни, Йә Раббым, рәхмәтең белән мин бәлале колыңа рәхим ит. Чөнки мин, бәла даласына төшеп, адашып юлдан язып калдым, димәк.

Йатыб мән йөз түбән эссигъда сусаб,
Кеше юкдыр тамызмагай катрәи аб.

Ягъни мин колың, гөнаһ даласында гөнаһ эсселегеннән сусап, рәхмәтең суына мохтаҗ булып, гаҗизлектән йөзтүбән ятып торамын. Һичбер кеше юк, һич юк шәфәгать итеп, рәхмәтең елгасыннан бер тамчы су тамызучы кеше.

Корыб каным, йитебдер ләбкә җаным,
Төшебдер йиргә агызымдин зәбаным (телем).

Ягъни шундый гаҗиз булып торамын; гаҗизлектән һәм сусаудан каным корып, җаным авызыма килде һәм телем авызымнан чыгып, гаҗизлектә каламын.

---

1 С.-П.да — багласа (154 б.).
2 «Бөтен (үтенеч-теләкләрне үтәүчегә (Аллага) мөнәҗәт».
3 С.-П.да — пипайани (155 б.).

Мәзийат әһле әтрафымыздадыр пөр,
Өмидлек мән һәнүз, әй кашифез-зыр.

Ягъни изге кешеләр тирәбездә күп. Аларның шәфәгатеннән һәрчак өмет итәмен, әй авырлыкларны бетерүче Аллаһ Тәгалә.

Кәрәм бәхридә, әй солтане ваһһаб[1],
Гата кылсаң мәңа катрәи аб.

Ягъни юмартлык диңгезеннән миңа бер тамчы су бир, әй ризалаучы шаһ.

Сәгадәт куәтен[2] кылсаң гыйнаять,
Рәфыйкым булса тәүфыйк, һидаят.

Ягъни, йә Раббым, рәхмәтең белән изгелек куәтен һәм изгелек азыгын ярдәм итеп биреп, юлдашымны тәүфыйк белән бүләклә.

Биреб сынмас гасан тәүбә кулга,
Таләб дәрде белән салсаң бу юлга.

Ягъни, йә Раббым, рәхмәтең белән ныклы тәүбә таягын кулыма биреп һәм тәүбәмдә тотрыклы итеп, Аллаһ Тәгаләне эзләү шөгылен күңелебезгә салып, тарикать юлына керергә гыйшыклык бирсәң иде!

Торуг зады (зады; запасы) булса куенымызда,
Гобудият (күндәмлек) тинабе (бавы) буенымызда.

Ягъни рәхмәтең белән безнең куеныбызда тәкъвалык азыгы булса һәм дә бәндәчелек бавы һәм теләге муеныбызда булса, ни гүзәл булыр иде. *Тинаб* дигән сүз та хәрефенең кәсрәсе белән языла, бау мәгънәсендәге төрекмән сүзе.

Йөретеб яхшылар гизгән сәбилне,
Риза милкегә куандырсаң бу колны.

---

1 Ваһһаб — Ваһаб — Алланың бер эпитеты.
2 Бу сүзне «котың» дип тә укырга мөмкин.

Ягъни, Йә Раббым, рәхмәтең белән бу гариб бәндәңне олуглар һәм яхшылар йөргән изге юллардан ... йөртсәң иде һәм дә үзеңнең ризалык милкеңә куандырып һәм шатландырсаң, ничек яхшы булыр иде! *Куандырмакың* каф хәрефенең даммәсе (у ны белдерүче тамга) белән уауның хәрәкәсе белән шатлык мәгънәсендәге төрки сүз.

Моның дик[1] эшләр, әй данаи әсрар,
Сәңа асан ирер, гәр безгә дишвар.

Ягъни мондый эшләрне эшләү сезгә җиңел булыр, әй серләрне белүче Аллаһ Тәгалә, безгә бик авыр булса да.

Күтәреб мән өмид берлән беләкне,
Ходавәндә, кабул иткел теләкне.

Йә Раббым, синең рәхмәтеңә сыгынып, беләкләребезне күтәреп, гозерләребезне үтенәбез. Үз рәхмәтең белән теләгән теләкләребезне кабул ит.

## Хәсәдтән ерак булу бәяны

Кил, әй нәфес, ачмагыл күз һәр кайанә,
Юк ирмеш игътимад ошбу җиһанә.

Ягъни, әй кеше, күзеңне ачып һәр якка карама, бу дөньяны мәңгелек дип ышанма, чөнки бу фани җиһанның мәңгелеге, тугрылыгы юк.

Мөйәссәр улса сәңа тәлладин тәхт,
Үзендин пәсткә, зинһар, әймәгел сәхт.

Ягъни Хак Тәгалә хәзрәте җиңел генә сиңа юктан таҗ бирсә һәм тәхетле падишаһ итсә, зинһар, үзеңнән түбән дәрәҗәле кешене каты сүз белән рәнҗетмә, димәк. *Тәлладин* дигән сүз юктан мәгънәсендәге төрки сүз.

Әгәр бирсә җиһан солтанлигъ дәст (кул),
Кеше үз халене белмәк кирәк пәст.

1 С.-П.да — даг (156 б.).

Ягъни дөньяның барча халкы сине падишаһ дип, сиңа бәйгать бирсәләр дә (ант итсәләр дә), кешегә үз хәлен түбән дәрәҗәдә дип белергә кирәк. Чөнки дәрәҗәсенә һәм шаһ булуына горурлану ахмаклык.

Әгәр мәртәбәң[1] ирер әгълаи афак[2],
Екылган хәстәләрнең халигә бак.

Әгәр синең дәрәҗәң зур булса да, мәртәбәгә алданма; гыйбрәтләнеп, җиһанда авыру кешеләр хәлен карап, гыйбрәт ал. Бәлки олы дәрәҗәң олырак булган саен, йөзеңне түбән итеп, барча кешеләрдән үзеңне ким күр.

Бу рәфәгать (бөеклек) берлә күкне күр һәмишә,
Йөзедер йир сарый (җиргә юнәлгән), әй яхшы пишә.

Ягъни күрмисеңме күкне: шулкадәр бөек дәрәҗәсе булуы белән барыбер йөзен аска, җир тарафына каратып, түбәнчелек белән тора, әй яхшы һөнәрле кеше, димәк. Бәс, болай булса, син дә түбәнчелекле бул.

Әгәр чәндикә урының булса әфляк (күктә),
Кояш дик уфтаныб рөхсарәгә хак.

Ягъни хәтта синең урының Идрис пәйгамбәр кебек күкләр өстендә булса да, тәкәбберле булма, бәлки һәрчак кояш кебек оялып, йөзеңне түбән кыл.

Әгәр дөньяда булса зур-у базу,
Вәли анда корылгандыр тәразу.

Ягъни син дөньяда көч-куәтле һәм ныклы беләкле булсаң, кешеләргә золым һәм көчләү кылучыларга үлчәү бар. Анда хисап итәрләр.

Тараф мури сәндә куәте фил,
Мөселманлыкда аңа мәрхәмәт кыл.

Ягъни бер мөселманның куәте кырмыска кебек булса,

---

1 К.да — рәтбән (109 б.).
2 Әгълаи афак — «күкләргә тиярдәй бөек булса да».

ә синең куәтең фил кебек булса да, мөселманлыкта аңа шәфәгать ит, «мин көчлемен», дип көчсезләргә тимә. *Тараф* мөселман мәгънәсен белдерүче төрек сүзе.

Әгәрчә ул аяк астындадыр хар,
Хода мәхлукыдыр, агыртма, зинһар.

Ягъни бер мескен һәм көче булмаган кеше аяк астында хур булып, тигәнәк кебек булса, син аны рәнҗетмә, чөнки ул — Аллаһ Тәгаләнең мәхлукы.

Тәкәббер кылмагыл, әй би мәгани,
Фәлән углыдыр мән димә, фәлани.

Ягъни тәкәббер булма, берәүне шундый-шундый дип хурлап, әй мәгънәсез, ул фәлән кешедән туды һәм фәләндер, атасы мондый һәм анасы шундый дип хурлама.

Әгәр алдыңдагы кол булса вали,
Күңлеңнең кинәседин әйлә хали.

Ягъни синең алдыңда бер кара кол, солтан һәм югары дәрәҗә иясе булса һәм дә бер имам яки шәех ... булса, син күңлеңнән ачу һәм хөсетне чыгар, аңа буйсынмаудан хурлан.

Борынгы халига[1] кылма нәзарә,
Аны Тәңрем газиз итсә нә чара!?

Ягъни хезмәт иясенең һәм тәкъва булган кешенең элеккеге хәленә карама, ягъни баштагы тормышында бозык иде, хәзер ничек тәкъва булды, мин аңа илтифат итмим, димә. Чөнки Тәңре Тәгалә аны сөекле итеп, әүлия итсә нишләрсең?!

Ышанма атаңа, калма таләбдин,
Кыяматдә соралмасдыр нәсәбдин.

Ягъни минем атам шундый олуг иде дип, аның белән алданып, Аллаһ Тәгаләне теләүдән коры калма, чөнки кыямәт көнендә синең нәселең ничек иде дип сорамаслар...

---

1 К.да — халина (110 б.).



www.darul-kutub.com

Хәсәб фәүкы нәсәбдер, әй нигү халь,
Епәк тундан үтәр хуб эшләгән шаль.

Ягъни изге гамәлләр кыямәт көнендә нәсел-нәсәптән өстен, әй изге хәлдәге кеше; чөнки нәселсез бер изге гамәлле кеше Аллаһ Тәгалә каршында нәсел-нәсәпле кешедән изге. Чөнки бит күрәсең: базарда яхшы шәлләр ефәк затыннан артыгraktыр. *Шәл* дигәне кәҗә мамыгыннан ясалган әйбер[1].

Әгәр сахибе нәсәб төздер эшигә,
Нә сүз ике хасийәтлек кешигә.

Ягъни бер изге нәсел-нәсәпле кеше шәригать эшендә төз торса һәм изге гамәлләр эшләсә, андый ике хасиятлы кешегә ни сүздер, ягъни, һичшиксез, изгеләрнең яхшырагыдыр.

Әгәр кылсаң сәфәр дарелхәйатә,
Хуб ата бар димә, тарымыш хуб ана.

Ягъни син ахирәт йортына сәфәр итәргә теләсәң, изге атам бар һәм аның нәселеннән мин дип алданма. Изге аталарың белән алдану ахмаклык.

Әгәрчә Нух иде һадийе инсан,
Тугыбдыр[2] андаг ирдин на мөселман.

Ягъни Нух кешеләрне туры юлга күндерүче пәйгамбәр иде. Шундый булса да, аның бер кяфер улы туды, Кәнган исемле. Атасының пәйгамбәрлегенә карамады, туфан суы киләчәгенә инанмады...

...Хак Тәгалә хәзрәте Нух пәйгамбәргә туфан вакытында көймәгә кергәндә вәгъдә кылды: «Туфан чыгып, көймәгә кергәндә, гаиләң белән бергә кер!», — диде. Туфан көне җиткәч, Нух г-мнең өч углы — Хам, Яфәс, Сам керделәр. Аннары сиксән кеше керде. Кәнган исемле улы кермәде. Нух г-м әйтте: «Йә Кәнган, безнең

2 К.да шәл сүзенә мондый аңлатма бирелә: «Шаль дидекләре(н) тун итәгенә тотарлар, кондыздан йә гайре нәрсәләрдән. Болгар халкының бәгъзеләре басталин диярләр» (110 б.).

С.-П.да — нугыбдыр (158 б.).



www.darul-kutub.com

белән көймәгә кер», — диде... Кәнган әйтте: «Мин биек тауларга менеп калырмын», — диде. Нух исә: «Йә Раббым, син вәгъдә кылдың, бу көймәгә гаиләң белән керерсең, дип. Ә бит минем улым Кәнган — гаиләмдер», — диде. Изи гыйзз-ү җәлл җавап бирде: «Ул Кәнган синең гаиләңнән түгел, чөнки ул — кяфер». Күрәсеңме, ата-анага игътибар булмады...

Әбү Талиб ки гамудыр Мостафага,
Ата ирде Гали әл-Мортазага.

Ягъни күрәсеңме Әбү Талибны: ул бит пәйгамбәрнең атасы Габдулла белән бертуган иде, һәм Хәзрәте Галинең атасы иде.

Кечекдин Мостафага ирде мөшфикъ,
Вәләкин булмады динә муафикъ,

Ягъни ул Әбү Талиб пәйгамбәребезгә, ул кечкенә чакта, шәфкатьле иде һәм аны тәрбияләде. Шулай булса да, дингә ярашлы булмады, кяфер булды.

Дийанәтсез ушал кем булды набуд,
Пәйгамбәр шәфкате һәм кылмады суд.

Ягъни ул Әбү Талиб динсез, кяфер булганы өчен, пәйгамбәргә кылган изгелекләренең барчасы юк булды һәм дә пәйгамбәр шәфкатенең файдасы булмады. Сөйләүләр буенча, Әбү Талиб вафат булган вакытта пәйгамбәр г-м килде, сәлам бирде, күрде: Әбү Талиб янында Әбү Җаһил ләгыйнь һәм Габдулла бине Өмийә һәм Вәлид кяферләр утыралар иде. Пәйгамбәр г-м әйтте: «Йә надан, сиңа әҗәл вакыты килде, әйт: «Лә иләһә илләлаһу Мөхәммәдүр рәсүле Алла». Шул арада бу кяферләр әйттеләр: «Йә Әбү Талиб, атабызның һәм бабабызның динен ничек калдыра аласың?». Пәйгамбәр г-м бу кәлимәи-шәһадәтне сорады. Әбү Талиб исә әйтте: «Әй Мөхәммәд, син бу сүзне куй, мин ата-бабам динен калдырмам». Пәйгамбәр г-м, бу сүзне ишеткәч, бик көенде, Әбү Талиб өчен Аллаһ Тәгаләдән ярлыкау сорады. Аллаһ Тәгалә аның догасын кабул итмәде... Ахыр чиктә, Әбү Талиб кяфер булып

www.darul-kutub.com

үтте.

Аның хөкемендәдер әдбару-у икъбал,
Тикәндин гөл чыкарды, зәһәрдин — бал.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең хөкемендә аркан булган нәрсәләрне ал итү, ягъни кяферне мөселман итү, һәм теләсә нәрсәдән гөл-чәчәк чыгарып һәм агуны балга әйләндерер. Моның яшерен мәгънәсе — кяфердән мөселман тудырыр...

Хәлилу Алла иделер Азәр углы,
Тәкый Лот нәбидер Һазәр углы.

Ягъни әйткәннәр ки, Ибраһим Хәлиле Аллаһ Азәр исемле кяфернең улы, һәм дә Лот пәйгамбәр Һазәр исемле кяфернең улы иде. Азәр белән Һазәр бертуганнар дип тә сөйлиләр. Алардан ике пәйгамбәр туды. Күрәсеңме: аталары һәм аналары кяфер иде, ә уллары мөселман булып, пәйгамбәр булдылар.

Хәсуд иткән кеше дүн дәгалдыр,
Бу сүз бер халкара иске мәсәлдер.

Ягъни болай Аллаһ Тәгаләнең эшләгәненә көнчелек кылган кеше азгын һәм түбән, дәрәҗәсез кешедер. Көнчеләрнең хәле шулай булыр, димәк. Бу ике пәйгамбәрнең аталары кяфер[1] иде, һәм моннан башка бер кешене Аллаһ Тәгалә сөекле итсә, аның атасы кяфер булса да, аннан көнләшмә, бәлки, хөрмәт ит. Чөнки көнче булсаң, син үзең халык арасында түбән һәм дәрәҗәң кимчелекле булыр. Чөнки явыздан изгене тудыру Ходаның хикмәте.

Чырагыны ки Хәкъ йандырды куйды,
Аны кем поф диде — сакаллы көйде.

Ягъни Ходай Тәгалә берәүнең кулына ислам чырагын яндырып бирсә, аны сөекле итеп, әүлия итсә, бу чырагны берәү, көнчелек белән, «поф» дип өреп, сүндерергә теләсә (моннан мәгънә — аны сүгеп, илтифат итмәсә), сакалы

1 К.да — имансыз (111 б.).

көеп, сакалсыз булып, халык арасында мәсхәрәгә калыр. Шулай бер сөекле булган кешегә каршы торсаң, дәрәҗәң төшеп, дәрәҗәсез булырсың, мәхшәр көнендә хур булырсың, яки дөньяда ук хур булып, халык табанының астында калырсың. Локман Хәким әйтте: «Берәү дәүләтле булса һәм мәртәбәсе арта торса, аңа каршы килмә», — диде.

Ходаның сонгыдин күрдең, көрәшмә,
Бер иске йирдин акты йаңа чишмә.

Ягъни Ходайның кодрәтеңнән күрдең, бераз акылың булса, күрерсең: борынгы заманнарда су һәм чишмә аккан урыннардан чишмә агызып, шундый борынгыдан кяфер булган нәселдән бер пәйгамбәр чыгарыр һәм бер сөеклене тудырыр. Бу гаҗәеп хәл түгелдер...

Аны бәнд иткәли алды бирү (?) пил,
Аны гарык әйладе нагяһ килеб сил.

Ягъни бер ахмак, ул яңа чишмәне буар өчен, филләр белән балчык ташыды, уйламаганда, тегe чишмә агып, күп булып, бу ахмакны филе белән бергә батырды. Шулай бер көнче ахмак дәрәҗәле кешенең мәртәбәсен төшерергә теләсә, ахырда ул көнче үзе хәрап булыр. *Сил* дигән сүз дип чынлыкта гөрләвекне әйтәләр, ләкин монда — ахмак мәгънәсендә.

Әгәр тарый кеше золым итсә, тартар,
Вәли мәзлум дигәннең әҗре артар.

Ягъни берәү пычак һәм кылыч белән берәүгә золым итәргә теләсә тартар. Ләкин шулай булса да, мескен һәм мәзлумның әҗере артыр. Әгәр ул залимнең золымына сабыр итсә, чөнки көнче бәдбәхет ул залимдер[1], юк урында кешеләргә дошманлык куар.

*Тарый* дигәне пычак мәгънәсендә, Сәмәркандлылар телендәге сүз.

1 С.-П.да — золымдыр (161 б.).

Мөселманига һич булма мәкабир,
Барыр җабир ирер, әй нәфсе җабир.

Ягъни син, кыскасы, мөселман булган кешегә тәкәбберлек кылма һәм, ул газиз кеше булса, итагать белән күңеленнән хөсетне чыгар, чөнки урын алучы мәртәбәле кешенең урын һәм мәртәбәсе, никадәр көнчелек һәм дошманлык итсәң дә, барыбер артыр, әй үзенә һәм нәфсенә золым кылучы кеше, димәк. *Җабир* сүзенең беренчесе кушма: урын алучы мәгънәсендә. Икенчесе залим мәгънәсендә.

Төшермә нәфгъ к рәнҗене мийанә,
Сәне илтәр зыйанә тазийанә.

Ягъни файдасы юк зыянны һәм рәнҗүне һәм золымлыкны мөселманнар арасына төшермә һәм фетнә куптарма, чөнки бу эшләрне эшләвең ахирәт зыянына илтер һәм дә камчыга төшерер, ягъни җан ияләрен күп рәнҗетсәң, берәү сине, казыйга чакырып, җәзага тартыр. *Зыйан* сүзе мәшһүр мәгънәсендәге төрки сүз. *Тазийанә* сүзе камчы мәгънәсендә.

Терек йөргүнчә залим — үлгәне хуб,
Гөнаһдин һәр ничә кем булгани хуб[1].

Чөнки халим кешенең дөньяда торуына караганда, үлеп, кабергә керүе яхшырак. Шуның өчен: тиз үлсә, ул залимның гөнаһы кимрәк булып, газабы аз булыр.

## Хәҗҗаҗ хикәяте

Мөселманга бер көн әйде Хәҗҗаҗ:
«Догаи хәйр өчен безгә кулың ач!»

Ягъни Хәҗҗаҗ бине Йосыф көннәрдән бер көнне изге, догасы кабул ителердәй кешегә гозер һәм үтенеч белән болай диде: «Газизләргә[2] бер изге дога кыл!». Әйтүләр буенча, ул изге кеше Багдад шәһәрендә иде, исеме Сөләйман бине Муса булган кеше иде. Бик тә тәкъва, укымышлы иде. Һәм бу Хәҗҗаҗ Мәккәнең шаһы һәм залим иде.

1 С.-П.да — җуб (162 б.).
2 К.да — әй газиз ир (113 б.).

һәм ул әйтә иде: «Дөньяда кан түгүдән ләззәтле нәрсә юк», — дип. Сөйләүләргә караганда, Хәҗҗаҗ үтерергә теләгән кешесен үтермичә калдырмады, мәгәр бер итчене генә үтерә алмады. Сөйләүләр буенча, көннәрдән бер көнне Хәҗҗаҗ[1] бер итчегә очрады. Хәҗаҗ базардан бер сугымлык мал алган иде. «Йә итче, моннан күп май булырмы?» — диде. Итче әйтте: «Фәлән кадәр май һәм ит булыр», — диде. Хәҗҗаҗ тиз арада куйны бугазлатты. Нәкъ итче әйткәнчә булды. Хәҗҗаҗ сорады: «Йә итче, син бу кадәр тәҗрибәң белән сугымнан чыккан майның күләмен белдең, Аллаһ Тәгаләне ничек таныйсың һәм ничә сыйфат белән беләсең?» Итче уфтанып: «Белмим», — диде. Хәҗҗаҗ, моны ишетү белән, җәлладларына боерды: «Тиз генә моны алып китегез һәм үтерегез!» — диде. Кыскасы, җәлладлар моны алып киткәндә, бу итченең мәдрәсәдә укыган улы бар иде. Ул әтисен җәлладлар алып баруын күрде. Мәдрәсәдән атасына йөгереп каршы чыкты, әйтте: «Әй ата, кайда барасың?» — диде. Итче әйтте: «Әй улым, мине җәлладлар асарга илтәләр». Улы сорады, итче баштан кичергән хәлләрен сөйләп бирде. Моны ишетеп, улы: «Сез монда бераз туктап торыгыз, мин Хәҗҗаҗ янына барам», — диде. Хәҗҗаҗ янына барды, әйтте: «Йә падишаһ, ни өчен безнең атабызны үтерәсең һәм мине ятим итәсең?» — диде. Хәҗҗаҗ җавап бирде: «Атаңның дингә игътибары юк, Ходайны танымый». Егет исә: «Минем атамның динендә игътибары булмаса, мине мәдрәсәгә кертеп, гыйлем капкасына күндермәс иде. Моның белән кан түгү хәләл түгел», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Ходаны һәм аның сыйфатларын белмәс», — диде. Егет: «Белмәгән нәрсә өчен кан түгү дөрес түгел, — диде. Белмәгән кешеләрне өйрәтергә кирәк». Хәҗҗаҗ хәйран булды, егеткә әйтте: «Атаңны багышладым».

Әйткәннәр: Хәҗҗаҗ табигыйннарның (сәхабәләргә иярүчеләрнең) олугы, чыгымнарны кызганмаучы юмарт кеше иде, ул Кәгъбәтуллаһка таштан бина корды һәм ике йөз мәсҗед төзеде, гарипләргә һәм ятимнәргә шәфкатьле иде. Сөйләүләргә караганда, сәедзадәләрне күп һәлак итте, хәтта ки дүрт йөз сәедзадәнең башын кисте. Кисүенең сәбәбе шул: Хәҗҗаҗның бер юртак аты бар иде, көннәрдән бер көнне аңа утырып

1 С.-П.да бу исем еш кына Хәҗҗаз дип язылган.



www.darulkutub.com

чыккан иде, Мәккә далаларында гизеп йөрде, сәедзадә дигән кешеләрне хөрмәт итеп, кадер-хөрмәт күрсәтте. Кыскасы, Хәҗҗаҗ бер көнне атына менеп, сәхрага чыкты. Бер кешенең бакчасы яныннан үтте. Ул бакча хуҗасы бакчасына су җибәргән иде. Су бакчадан артып, урамга чыкты, урамның кайбер җирләрен batкакка әйләндерде. Хәҗҗаның аты батып егылды, Хәҗҗаҗның аягы сынды. Вәзирләр Хәҗҗаҗны күтәреп алып кайттылар. Ул ант итте: «Билләһи-л-газыйм, ул бакча иясен үтерермен!» — диде. Бакча хуҗасын алып килделәр. Хәҗаҗ әйтте: «Ни өчен мөселманнар юлына су чыгардың?» — диде. Бу кеше җавап бирде: «Бакчадан артык су чыкты, — диде. — Югыйсә, мин үзем чыгармадым». Хәҗҗа әйтте: «Исәнлек бирмәгез, үтерегез!» — диде. Бакча иясе елады: «Өч кечкенә балам хакына гафу ит!» — диде. Хәҗҗаҗ исә: «Балаларыңны казна малы хисабына тәрбияләрбез», — диде. Бакча иясе янә әйтте: «Пәйгамбәр нәселеннән мин, пәйгамбәребезне яратуың өчен гафу ит» — диде. Хәҗҗаҗ моны ишеткәч: «Гафу итәм», — диде. Хәҗҗаҗның бер вәзире вафат булган иде, аның урынына бу бакча хуҗасын вәзире итте. Үзе янында тәрбияләде. Сөйләүләр буенча, ул бакча хуҗасының исеме Шәмгун иде. Кыскасы, көннәрдән бер көнне Хәҗҗаҗның ишеге янына бер теләнче килде. Хода өчен ризык теләде, «Ач мин,» - дип елады. Хәҗҗаҗ ул вакытта хәлвә ашап утыра иде. Теләнчене күреп кызганды, башыннан бер кыйммәтле ташны алып, хәлвә эченә салып, Шәмгунга бирде: «Бар, моны теләнчегә бир», — диде. Шәмгун аның янына барды, әйтте: «Әй теләнче, падишаһ сиңа бер кисәк хәлва бирде, син моның белән ни генә эшләрсең, мин бит сиңа бер көнлек ризык бирәм, — диде. — Бу хәлвәне бир миңа». Теләнче риза булды, көнлек ризыкны алды. Чыкты, китте. Бу Шәмгун хәлвә эчендәге ташны алды, хәлвәсен ашады. Кыскасы, теләнче икенче көн янә шаһның йортына килде. Ходa өчен ризык теләде. Хәҗҗаҗ тагын күрде, кызганды, баягы кебек хәлвә эченә таҗдан кыйммәтле ташны алып, Шәмгунга бирде. Әйтеп: «Бар, теләнчегә бир», — диде. Бу Шәмгун, тагын бер көнлек ризык биреп, кыйммәтле ташны алды. Кыскасы, өченче тапкыр теләнче килде, Ходa өчен берәр нәрсә теләде. Хәҗҗаҗ теләнчене күрде, әйтте: «Нәрсә инде телисең, мин сиңа бер падишаһ мөлке кадәр нәрсәләр бирдем», —

диде. Теләнче сорады: «Нинди нәрсә бирдең?» — диде. Хәҗҗаҗ: «Хәлвә эченә ике кыйммәтле таш салып бирдем», — диде. Теләнче Шәмгуннның хәйлә белән алганын әйтеп бирде. Хәҗҗаҗ ачуланып әйтте: «Бу сәедзадә түгелдер, чөнки сәедзадәләр гарип күңелле, канәгатьлек һәм дөреслек белән булалар иде, бу ялганчы һәм хыянәтче», — дип башын кистерде һәм аннан башка Мәккәдә никадәр сәедзадә булса, барысын да ялганчы дип башларын кисте, һәм әйткәннәр:

Күтәрде кул догага ул нику халь,
Диде: «ЙаРабби, бу залим жаныны ал!»

Ягъни газиз, Хәҗҗаҗның үтенечен кабул итеп, догага кул күтәрде һәм әйтте: «Йә Раббым, бу залимның җанын ал, гомерен аз кыл!» — дип дога кылды.

Диде Хәҗҗаҗ ушал мәрди Ходага:
Ничек барды телең мондаг догага.

Ягъни Хәҗҗаҗ, бу доганы ишеткәч, ул Аллаһ юлында йөрүче газизгә әйтте: «Ничек мондый явыз дога кылырга телең барды, миннән ни күрдең син, болай дога кылырга?» - диде.

Диде Хәҗҗаҗ ул мәрде нику сәйр:
Сәңа вә барча мөэминләргәдер хәйр.

Ягъни изге гадәтле әүлия Хәҗҗаҗга җавап биреп, әйтте: «Бу дога сезгә һәм барча мөэминнәргә изгедер», - диде.

Гөнаһың ким булыр, үлсәң әгәр тиз,
Китәр золмың аларның башыдин тиз.

Ягъни ул газиз әйтте: «Бу доганы аның өчен кылдым, әгәр минем догам сәбәпле тиз арада үлсәң һәм ахирәт йортына барсаң, гөнаһың азрак булыр; чөнки гомерең озын булса, гөнаһың күп булып, тәмугта озак торырсың, - диде. — һәм тиз үлүеңнән файда — мөэминнәрнең башыннан золымлыгың китәр, алар рәхәтләнеп калыр. Моннан артык сиңа булмас изгелек». Әйтүләргә караганда,

www.darul-kutub.com

Хәжҗаж, ул газизнең дога кылуыннан соң, егерме ел гомер кичерде. Соңрак мәңгелек урынга күчеп китте. Хәрам мәчетенең Габбас дигән капкасында күмелде, һиҗри йөз егерме алтынчы елда булды (милади 744 елда), рабигыл әүвәл аеның уникенче җомга кичәсендә иде.

## Комсызлыкны шелтәләү турында

Кил, әй азадә, бул һиммәт белән йар,
Тамегъ зинданига булма грифтар.

Ягъни, әй азат, һәрчак син һиммәтең белән юлдаш бул, зинһар, теләк-тамегъ зинданында тоткан булма, ягъни халыктан тамегъ итмә, чөнки тәмегъ кылу хурлык. Тамегъ дигәннең мәгънәсе шул: сәбәп булмаган җирдән өмет итү, ягъни бирәү иген иксә һәм сәүдә итсә, моннан файда өмет итү тамегъ түгел. Тамегъ шул: үзен халык арасында галим һәм суфый итеп күрсәтер, телендә вәгазь белән дөрес сүз булыр, ләкин ул суфый итеп кылану Аллаһ өчен булмыйча, бәлки халык яхшы итеп күрсен дип, моңа нәзер һәм үтенеч бирсеннәр дип тамегъ итер. Бу чын хәрамдыр.

Бирергә булмаса дөнья ашыдин,
Ул итсигъна тамегъ кылма кешедин.

Ягъни син, фәкыйрь булып, кешеләргә бирергә нигъмәтең һәм ашың булмаса да, моңсызлыкта телә, кешеләрдән тамегъ итмә, чөнки тамегъ начар эштер. Кыскасы, никадәр фәкыйрь һәм мескен булсаң да, хәлеңне кешеләргә белдермә һәм тамегъ итмә.

Ходаең һәр нә бирсә кыл канәгать,
Йөрәгеңне кылма миннәтдин җәрахәт.

Ягъни Ходай Тәгалә сиңа һәр ни бирсә — байлыктан һәм фәкыйрьлектән һәм гариплектән бирсә — барысына разый булып, канәгать булуың яхшы[1]. Йөзеңне яхшылык белән җәрәхәтләмә: фәлән кешегә шул кадәр изгелек һәм бу шул кадәр сәдака бирдем дип санама — боларның барысы хәрамдыр.

---

1 С.-П.да — ийүер (166 б.). Бу сүз төрекчә яхшы, әйбәт мәгънәсен белдерә.

Йөгерсәң бер кәдү өчен әгәр чәнд[1]
Бохара өлкәседин та Сәмәрканд.

Ягъни, мәсәлән, кәсеп итеп йөрсәң, бер кабак җимеше өчен Бохарадан Сәмәркандка барсаң, икесенең арасы алты көнлек җир торыр. *Кәдү* ... кабак җимешенең бер төре. Эчендәге нәрсәләрне ашыйлар һәм кабыгыннан савыт ясыйлар.

Бәдәхшандин күтәрсәң йөз сары таш,
Бәһасе Бәлх[2] эчендә булса бер маш.

Ягъни кәсеп итеп, Бәдәхшан шәһәреннән йөз баш лябур[3] ташын күтәреп, Бәлх шәһәренә илтеп сатып, бер ясмык кына алсаң, ягъни бу кадәр озак сәфәр кылып, аз нәрсә тапсаң, әйтерләр: Бәлх белән Бәдәхшан арасы егерме алты көнлек җир.

Әгәр башы белән чаһ казыса бәндә,
Күзенең яшечә су тапса анда.

Ягъни бер кол, башы белән кое казыса, ул коедан күз яше тамчысынча су тапса; кыскасы, күп мәшәкать белән аз нәрсә хасил булса.

Әгәр казса (казыса) аригъ кизлек белән мәрд,
Аңа бер хушәи җәү кылса пәрвәрд.

Ягъни бер кеше, кечкенә пычак белән арык казып, су агызып, бер башак кадәр арпа тәрбияләп үстерсә. *Кизлек* дигәннәре кечкенә пычак. Аның белән ук очын алырлар. Төрекмән сүзе. *Хушәи җәү* гыйбарәсе белән арпа һәм ашлык башагы мәгънәсендә, фарсы сүзе.

Бу михнәт берлә тапса парчаи нан,
Кешенең миннәтедән улдыр асан.

Ягъни бу югарыда әйтелгән мәшәкатьләр белән бер телем икмәк тапсаң, кешенең яхшылыгыннан, ягъни

---

1 К.да — «йөгерсәң көн дә бер кәдү өчен чәнд» (116 б.).
2 Бәдәхшан, Бәлх — Үзәк Азиядәге төбәк атамалары.
4 С.-П.да — лябуз (167 б.).

www.darul-kutub.com

халыктан сорап табудан изгерәктер, ягъни халыктан тамегъ итеп торудан әйбәтрәктер.

Кыдырган берлә ризыкың кадре ашмас,
Китәр кадрең кадәрдин һәргиз ашмас.

Ягъни кызуланып йөрү белән, Аллаһ Тәгалә тәкъдиреңә язган ризыгың арттмас, ләкин Аллаһ Тәгалә каршында сиңа карата хөрмәтең китәр, сабырсызлар, дөнья сөючеләр арасыннар дип саналырсың. Ә бит Аллаһ Тәгалә теләгәннән артык ризыгы булмас, мал артыннан никадәр ашыгып йөрсә дә. *Кыдырган* сүзе хезмәт мәгънәсендәге төрекмән сүзе. *Кадәри* дигәне каф хәрефенең фәтхәсе (а-ә) белән языла, тәкъдир һәм үлчәү мәгънәсендә. *Кадернең* дигән сүз хөрмәт мәгънәсендә кулланыла.

Тәвәккел кәнҗедин, әй йөз үгергән,
Боерганга моүалифдер бу йөргән (?).

Ягъни, әй син, комсыз, тәвәккел (Аллаһка бирелү, Аңа тапшырылу) хәзинәсеннән йөзеңне алып, тамегъ хәзинәсенә барасың, ә бит синең боерганың Аллаһ Тәгаләнең боерганына каршыдыр. Чөнки Аллаһ Тәгалә кәсеп итәргә боерды. Бу, кәсеп итмичә, халыктан тамегъ итүең Коръән аятенә каршы киләдер. *Кәнҗедин* гарәп һәм фарсы кяф хәрефе белән һәм гарәп кяфенең фәтхәсе белән хәзинә мәгънәсендә килә. *Боерган* сүзе әмер итү мәгънәсендәге төрки сүз...

Ала булган ала йөргәндин артык,
Күмелгән — тилмереб торгандин артык.

Ягъни иске кием белән торуың тамәгъ аша мал алып йөрүеңнән яхшырак һәм, тилмереп йөргәннән соң, туфрак астына күмелүең яхшырактыр кешеләрдән тамегъ итүдән. *Ала* дигә сүзнең беренчесе иске һәм тузган өс киеме мәгънәсендә, икенчесе алу мәгънәсендә.

Кешегә итмәгәй һимматле кат баш.

Ягъни бер кеше шәһәрдән чыгып таш эчсә һәм ашаса,

www.darulkutub.com

һиммәтле бәндә кешегә серне әйтмәс, диməктер. *Таш* дигәне сүзнең әүвәлгесе хәҗәр (таш) мәгънәсендә килә. *Эчсә* дигәне эчүдән ясалган, ашау мәгънәсендә алынды, мәҗазән (күчерелмә мәгънәдә) яки тәгъкиб (мәҗазән) бабында. Икенче *таш* хариҗ (тыш) мәгънәсендә була.

Тамегъ наныга ләб ачкунча ул ач,
Минән утындин очкын дик булыб кач.

Ягъни комсызның икмәгенә авызны (ләбне) ачканчы, ул карыны ач кеше адәмнәрнең миннәтләре (минән) утыннан һәм аларның табасыннан (кылган изгелекләре белән битәрләүләреннән) очкын кебек ерак качу кирәк, ягъни асылда комсызланмаска кирәк.

Әгәр карны бераз туймас карыны.
Кешегә әйтмәгәй ир бәндә серне.

Ягъни берәүнең карыны озак вакытлар туймый ач йөрсә, бәндә ул вакытта да серне кешегә әйтмәс: «Мин ач һәм ялангачмын», — дип сөйләмәс. *Карын* сүзенең элеккесе батн (эч) һәм корсак мәгънәсендә була, төрки сүз. Һәм икенчесе замана мәгънәсендә килә, гарәпчә.

Канагать мәгьдәнигә ач күзен ач,
Тамегъ буйы күренмәм буедин кач.

Ягъни канәгать хәзинәсенә (мәгьдәнигә), әй ач йөрүче кеше, күзеңне ач һәм дә комсызлыкның кад-каməте (буйсыны) күренгәнче, комсызлыкның исеннән дә ерак кач, диməктер. Ач сүзенең элеккесе җуг (ач күз, комсыз, туймас) мәгънәсендә һәм икенчесе ачу (күзеңне ач, йомма)дан гыйбарәт, мөштәкать (бер тамырдан ясалган), гарәпчә фәтех (ачу, җиңү) мәгънәсендә килә. *Буе* сүзе кад-каməте (сын, гәүдә) мәгънәсендә була. *Буедин* дигәне ис мәгънәсендә алынган.

Тамегълек силәдин бәһдер силәнгән,
Теләнгәндин ирер артык теләнгән.

Ягъни тамегъ белән бер куйның көтүен алганнан артыктыр (бәһдер) җилкәгә йодрык белән оруларыны,

ягъни сине берәү башыңа китереп сугудан яхшырактыр, тәмегъ белән куй вә дөяләр туплanудан.

Теләнче булып йөргүең тамегъ белән иске, ертылган киемнәр киюгә караганда артыктыр. *Силә* сүзе мөгезле терлек көтүе мәгънәсендә. *Силәнгән* сүзе кафайа йомрык белән сугу мәгънәсендә. Икесе дә төрекмән сүзләре. *Теләнгәндин* дигәне саил һәм теләнче мәгънәсендә...

Тамегъ кылма табарга зәрнигарен,
Бу зәр миһре бозар диннең хисарын.

Ягъни, кыскасы, беркайчан да тамегъ кылма син, хурлык табарсың күңел сөйгән нәрсә белән, чөнки алтынга мәхәббәт диннең кальгасын харап итә. *Бу зәр* дигән сүзнең беренчесе сүзтезмә: *бу* дигәне төрки күрсәтү алмашлыгы, *зәр* дигәне алтын мәгънәсендә. Соңгы *бозар* бер сүз, бетерү мәгънәсендә.

Кешенең матлабы (теләгәне) сим булса йә зәр[1],
Хәлилнең атасы һәм була Азәр,

Ягъни берәүнең теләгәне алтын яки көмеш булса, Аллаһ Тәгаләне теләмәсә, хәтта Ибраһим Хәлилнең атасы Азәр булса да. Бу шигырь юллары башлау өчен.

Мөсахиб (иптәш) белмәгел дөнья хәсыймен,
Нәсиме мәгърифәт эстә нәсимен.

Ягъни шулай Хакның ризалыгын калдырып, алтын теләгән кешене ахирәт юлдашы дип белмә, бәлки, Тәңренең бер дошманы дип бел. Бу шигырь юлы хәбәрдер. Уйла, бәс, шулай булса, син гакыл иясе булсаң, Аллаһ Тәгаләне тану җиһазын (?) телә, алтын-көмеш теләмә. Чөнки ике мәхәббәт бер урында бергә булма: берсен мәхрүм итмичә, икенчесе табылмас. *Нәсим* дигән сүзнең беренчесе җиһаз, әйбер мәгънәсендә. Икенчесе көмеш мәгънәсендә. Нун хәрефе кафия өчен языла...

Имекләб (? Имгәкләп) китсә, төшсә ит белә пуст,
Тамегъ кылма кешедин түшә, әй дуст.

---

1 С.-П.да — «Кешенең матлабы булса сим йә зәр» (169 б.).

Ягъни мәшәкатьләр белән фәкыйрьлек һәм ачлык белән итең яки тирең төшеп бетсә, ягъни никадәр авырлыклар эчендә булсаң да, кешеләрдән тамегъ итмә, әй дус, хәтта бераз гына булса да. *Имекләб* (? имгәкләп) дигәне мәшәкать мәгънәсендә. *Түшә* дигән сүз *лөкъмә* «бәләкәй кисәк» мәгънәсендә, киная итеп, аз дигәнне аңлата.

Гарзы дөнья булыб, әй адәмизад,
Газиз гомереңне һәргиз кылма бәр бад (җилгә).

Ягъни, кыскасы, дөньяда төрле хәлдә булсаң да, газиз гомереңне, буйсыну һәм гыйбадәт кылмыйча җибәрмә, әй адәм баласы, димәк.

Кешенең хезмәтендә багласаң кул,
Җәлавендә йөгерсәң бер кадәм йул.

Ягъни синең тамегъ артыннан йөрүеңә караганда, бер шәехкә хезмәттә кул баглавың яхшырак булыр. Аллаһ Тәгалә ризалыгы өчен бер адым йөгерүең әйбәтрәктер.

Бу йөрмәкдән фәна кичкәнең артык,
Бу нигъмәтдин зәкъкум (агу) эчкәнең артык.

Ягъни бу тамегъ белән йөрүеңнән үлүең артык, һәм дә бу тамегъ аркылы тапкан ризыкка караганда, агу эчүең артык.

Вәләкин тиксә хасс ирнең җәлавы,
Сәгадәтдер делең дәрдигә давы.

Ягъни бер камил шәехнең нуры сиңа төшсә, ни гаҗәп изге бәхеттер һәм күңел авыруларына дарудыр! Барлык теләгәнең шуннан чынга ашыр. *Җәлавы* нур мәгънәсендәге сүз. Моннан мәгънә — шәехнең тәрбиясе күренеше.

Аның дик ирнең хезмәтендә кыш, йаз,
Газиз гомреңне үткәрсәң ирер аз.

Ягъни шундый камил шәехнең хезмәтендә нык булып, кышларын һәм язларын торып, газиз гомереңне

хезмәтендә сарыф итсәң, аз булыр никадәр күп гомер үткәрсәң дә.

Ушал ирнең ире кем бириядыр,
Кадәм туфракы күзгә тутыядыр.

Ягъни бу хезмәт итүче ирнең мөршиде (юлбашчысы, өйрәтүчесе) андый риясыз һәм тамегьсез (комсыз түгел) була, бу сыйфатлары булса, ул мөршиднең аяк баскан туфрагы күзгә сөрмә, ягъни андый мөршид күз өстендә каш кебек газиз, хөрмәтле. *Тутыя* дигәне сөрмә мәгънәсендә.

Аның дик бәндәнең булсаң гәдасы,
Нә дәүләтдер Ходаемның ризасы!

Ягъни андый мөршиднең хезмәтендә хезмәтче (гәда) булуың, ни гаҗәп, күркәм дәүләт булыр! Ходай Тәгаләнең ризалыгы шул мөршидкә хезмәт итүчегә табылыр.

Аның бер данәседер хәрмәне зәр,
Дәме суддыр ул ирдин мөшек, шәкәр.

Ягъни андый камил мөршиднең бер данәсе, ягъни бераз янәшәсендә утыру, ындыр тулы алтын (хәрмәне зәр) белән тәңгәл. Алтыннан морад: бераз янәшәсендә утыру белән күп саваплар булыр һәм якынлык хасыйл булыр һәм дә аз гына игътибарына ирешү дә йофар (мөшкәт) һәм шикәргә тиңләшә, ягъни барча әгъзаларыңа курку төшеп, зикерләр хәрәкәт итәр, димәктер. *Хәрмән* ... ындыр мәгънәсендә, әмма ләкин монда кәсрәт (күп) мәгънәсенә истигарә (ишарә, метафора итеп) алынды.

Сәгадәтлек мөрид ул Хәкъ рәһендә,
Булыр юлбашчысының дәргяһендә,

Ягъни изге дәүләтле мөрид (шәкерт) шулдыр ки, ул Хак булучы камил мөршиднең юлында (рәһеңдә) һәм аның янәшәсендә булып, хезмәт итеп, даими (һәрчак) юлбашчысы мөршиде янәшәсендә һәм, бер сәгатькә дә аерылмыйча, аның хезмәтендә була.



www.darul-kutub.com

Нә рисвай пир ирер нәфес өчен хар,
Мөриде ишекендә йөрсә ул зар.

Ягъни дөньяда һәм ахирәттә ни рисвайлык, ни хурлык, мөршидлеккә дәгъва иткән кара йөзле бер кеше, нәфесен тыя алмыйча хур булып, алардан мал өмет итеп һәм комсызланып, һәм дөньяны сәбәп итеп, мөридләр ишегендә торып, аларны үзенә алыр. Бу — чыннан да, харам. Кыямәт көнендә йөзе кара булып, әүлияләр арасында хур булыр. Гомумән, бу бәет безнең бу замандагы суфыйларга ишарәт, чөнки күбрәге мөридләрне мал өчен тоталар; кайсының малы булса, аны хөрмәтләп тоталар һәм байлар ишеге төбендә артык тәгамнәрне (сынык икмәк) бирерләр, дип ишек саклаучы этләр кебек торалар. Үзләренең йөз суын сатып, тамакларын туйдыралар. Кайсыбер мөриднең малы булмаса, киресенчә, бездән сиңа тәрбия юк, дип алдап кайтаралар. Мондый суфыйларның җәмәгате дөньяда һәм ахирәттә йөзләре кара, заман шәехе болардыр. Асылда аларда яхшы ниятнең булганы юк, күпләре надан, дини фарызларны һәм тәүхиднең асылын (бер Аллаһлыкның асылын) белмиләр, үзләре мөрид тәрбия итәләр. Табигатьләренә буйсынган кешеләр һәм күркәм йөзле угланнар. Берәү фәкыйрь һәм кабәхәт йөзле булса, аннан качалар, бездән сезгә насыйп юк, диләр. Бу, дөрестән дә, көферлек, чөнки Хак Тәгалә бар кешене дә тигез күреп, ризыкларны тәмам итеп яралтты. Мәгъшукларының (сөйгән затның, ягъни Аллаһның) яралткан нәрсәләрен хур күрәләр, чөнки фәкыйрьлек һәм гарiплек Ходаның сөйгән нәрсәсе инде. Болар аны дошман күреп качалар, чып-чын көферлек. Мөршид булган кеше һәрберсен һәм һәр кешене тигез күрергә тиеш. Чөнки пәйгамбәр г-мнең холкы шундый иде: фәкыйрьләрне сөйде, байларны сөймәде. Әмма пәйгамбәрнең бу холыкка (гадәткә) күнүе Габбас сүрәсе иңгәч булды, юкса, ул да байларны сөя иде. Бу сүрә иңгәннән соң, ул (холыктан) тәүбә кылды: әй җане мән (минем җаным), агяһ булгыл (хәбәрдар бул, белеп тор), бу замана шәехләренең күбесе сурәт угрысы (карагы), хатын һәм мал һәвәсендә, шулай итеп тәҗрибә әһеленә беленер. Һәм алардагы сәләт, уй-ният барчасы



www.darul-kutub.com

төрле, чөнки гавамнар (гади халык), хасслар (сайланган, затлы) түгел. Күрмисеңме, шәех Шибли хәзрәтләре[1] гомеренең ахырында васыять итеп әйтте:

«Йә мөридләр, кайчан мин дарелфәнадан (бу дөньядан) дарелбәкая («мәңгелек йортка, ягъни теге дөньяга) барсам, минем әстанәм (чардуганым) капкасына бу хикмәтләрне языгыз: «Замана суфыйлары күп булыр. Әмма күбрәге фани дөньядагы теләкләре өчен суфыйлык кылыр. Кайчан бу хикмәтебезгә бер суфый тәңгәл килсә, аны хөрмәт ит һәм кадерлә, юкса, һаман бер кәлбе Куфидыр (Куфи этедер)» — дип, боерган.

Хәя (оят) юк, шәрм (оялу) юк һәргиз аларда,
Бетеклик һадилардин нөсхәләрдә.

Ягъни андый комсызлык белән йөрүче мөршидләрдә оят һәм уңайсызлану юктыр һәм изгеләрнең китапларында шулай дип язылган:

Кичә-көндезгә кемнең куәте йитсә,
Хәрам ирмеш үзене саил итсә.

Ягъни, берәүнең бер кич һәм көндезгә җитәр кадәрле азыгы булса, үзен теләнче итеп йөрүе — харам, — диделәр, чөнки теләнчелек — кәсепләрнең иң түбән дәрәҗәдәгесе. Шунысы мәгълүм булды, азрак ризыгың булса комсызланма һәм теләнчелек кылма. Безнең замана шәехләре, яхшы атларга менеп һәм яхшы арбаларда утырып, бай мөридләренә ризык җыярга барганнарын кайчан күрдегез, кайда күрдегез?! Бу, чыннан да, харам булып, үзләренең гадәтләрен тотып, җан ияләре булдылар.

Нәби әйде: «Кыямәт булса, әй дуст,
Тамегъ киннең йөзендә булмагай, пуст».

Ягъни пәйгамбәр г-м әйтте: «Кыямәт көне җиткәч, үтәгән амәнәтләре һәм садакалары белән адәмнәр каберләреннән купкан вакытта, комсызлык әһелләренең

1 Әбү бәкер Дулаф - Әш Шибли (861-946) — Багдадның атаклы суфые, Әл-Җөнәйд һәм Әл-Хәллаҗның укучысы һәм фикердәше. Иляһи гыйшык тарафдары. Аскетик яшәешне (зөһидлекне) яклаучы.

йөзендә тиресе суелып кубар, — диде. — Нәгузе биллаһи (Аллаһ сакласын), халык арасында йөзләре кара булып, оятлы булырлар», — диде.

Болай дисәң бу сүзне эстә «Мишкат»,
Тамегъ берлә кичергән хәйф әүкат.

Бу сүзне, ягъни пәйгамбәрнең хәдисен белергә теләсәң, ул «Мишкате мәсабих[1]» дигән китапта искә алынды. Шулай итеп, комсызлык белән гомер кичергән кешеләрнең вакытлары бушка, ягьни гамәлсез узган, ахирәттә хосран әһеленнән (үкенүчеләрдән) булырлар...

## Хикәяте Сәүбан...

Гаҗәб мәрд (кеше, ир) ирде Сәүбан әткыядә (диндарлыкта),
Ул атлигъ ирде бер көн, ил пиадә.

Ягъни хәбәр ителгәнчә, Сәүбан диндарлыкта гаҗәп тәкъва, суфый кеше иде. Әйткәннәр: Мәккәдән Бәтхигә барырга теләде. Атка менде, юлга керде, бераз җәмәгать (бер төркем кеше) җәяүләп (пиадә) баралар иде. Сәүбан артларыннан җитте, сәлам бирде. Сөйләшеп барган вакытларында

Кулыдин йиргә камчы төште нагяһ (кинәт),
Төшеб алды үзе ул мәрд агяһ.

Аңсыздан ваемсызлык белән камчысы кулыннан төште. Ул ир, тиз генә аңлап, сизеп алып, атыннан төште һәм камчысын алды.

Йаранлары әйделәр ул пакизә холка:
Нә булгай ирде әмер итсәң бу халыка?

Ягъни җәяү баручылар ул пакь холыклы Сәүбангә әйттеләр: «Йә хәзрәт, ни өчен камчыны үзең төшеп алдың, безгә боерган булсаң да ярамасмы иде? Алып бирер идек», — диделәр. *Холкы* дигән сүз элекке ханың

---

1 «Мишкате мәсабих» — үзенә төрле легенда һәм риваятьләрне туплаган атаклы җыентык исеме. «Шәм (фонарь) куя торган уентык» мәгънәсендә.



www.darulkutub.com

(ха хәрефенең) заммәсе (о хәрефен күрсәтүче тамга) белән укылыр һәм икенче юлда фәтхәсе белән (ягъни — «халык» рәвешендә) укылыр.

Диде Сәүбан: Тамегьдин булмагай, диб,
Алып биргел димәкне — күрмәдем ийеб.

Ягъни Сәүбан әйтте: «Комсызлардан булмыйм диеп, сезгә алып бирегез дип әйтүне лаек күрмәдем». *Ийеб* сүзе лаек мәгънәсендәдер, төрки сүзе. Әйтерләр: «Бу нәрсәнең җебе юктыр», — диерләр. Аннан морад — лаеклыгы юк, димәктер.

## Изгеләр белән сохбәт тоту (сөйләшү) бәяны

Кил, әй талиб, күзек гыйбрәт белән ач,
Мәхәббәтсез кешедин кош булыб кач.

Ягъни Аллаһ Тәгаләне эстәүче кеше, күзеңне җиһанга (дөньяга) гыйбрәт белән ач, галәмел-кәүн вә-л-фәсаддән («барлык яшәештән») гыйбрәтләр ал... һәм Аллаһ Тәгаләне сөймәгән кеше яныннан кошлар кебек кач...

Мәхәббәт әһленең җуйаны улгыл,
Ушал кем очрады — корбаны булгыл.

Ягъни син һәрвакытта Аллаһ Тәгалә сөючеләрне эстәүче (эзләүче, теләүче) бул. Көтмәгәндә тапсаң, юлларында фида булып, корбан бул. Хакыйкать әһеленең (ягъни — суфыйчылык юлындагыларның) корбанлыгы шулдыр: Аллаһны сөйгән әһелне табу, чөнки бу — Ходайның үзен табу ул.

Кешенең күңеле кем биганә булса,
Ирер дошман әгәр һәм ханы булса.

Ягъни бер кешенең күңеленнән ядлык тапсаң, Аллаһны эстәүче булмаса, фил-хакыйкать (чыннан да) ул бәндә синең дошманың. Гарчә ул синең белән өйдәш булса да, син аннан биз, яд-дошман күр һәм аның мәҗлесенә барма.



www.darulkutub.com

Мәхәббәтсез кеше булды һәр кай зат.
Әгәр фәрзәндә шириндер — ирер йат.

Ягъни берәү Аллаһ Тәгаләне сөймәс булса, аннан биз, чөнки ул ят торыр. Әгәр үзең сөт имезгән балаң булса да, ят бул. Шуңа күрә Нух г-мнең улы үзенә әһел булмады, Ходайдан «ләйсә мин әһлик» (синең әһелең түгел дигәнне) ишетте. Бу мәшһүрдер (билгеле, атаклы).

Мәхәббәт булмаса һәркемдә, әй хәйр,
Атаң булса, ирер биганә (чит), гайр.

Ягъни, һәркемдә (кемдә булса да) Аллаһ Тәгаләне сөю булмаса, әй изге кеше, атаң булса да, ят ул, әһел түгел. Аннан бизәр бул, чөнки ул дошман җан. Гарчә заһирында (тышында) дус булса да, батыйны (эче) кяфер.

Әгәр биганәең дагый булса,
Аңа сарыф ит, күзеңнең йагы булса.

Ягъни бер кардәш түгел кешенең күңелендә Аллаһка гыйшык булса, күзеңдә бераз гыйбрәт галәмәте булса, аның хезмәтенә сарыф әйлә (вакытыңны бир, хезмәт ит).

Җигәр бәндәң — йөрәгең күшәседер,
Аның миһре — кыямәт түшәседер.

Ягъни Аллаһ Тәгалә гыйшкында ул һәм таләбендә булган кеше — синең бәгърең пәрәсе һәм йөрәгеңнең ите (күшәседер). Аны сөю кыямәт көненең азыгы (түшәседер), ягъни Аллаһны сөюче әһел, хакыйкатьтә Ходайны сөя. Чөнки Аллаһ Тәгалә әһеленнән гайре (үзгә) түгел.

Аның дик йар илә чөн әйладең гаһед,
Эчерсә зәһәр, аны белмәк кирәк шәһид.

Ягъни андый гыйшык әһеле белән юлдаш булырга гаһед (вәгъдә) кылсаң һәм дуслык килешүендә булсаң, гарчә ул зәһәрләр (агу) бирсә дә, аны бал һәм шикәр кебек күрү кирәк, ягъни андый ярны, әгәр анда шәригатькә

каршылык булмаса, никадәр мәшәкатьләр очратса да, аны гафу итеп, кичереп, дуслыкта нык булу кирәк.

Теләсә бүркене — бирмәк кирәк баш,
Әгәр җан эстәсә, кайтармагай каш.

Ягъни андый дус синнән бүрек салдырып алырга теләсә, бирү кирәк, әгәр баш эстәсә һәм җан эстәсә, каш чытып хилафлык (каршылык) кылма, бәлки килешеп, Ходай өчен хезмәт ит.

Әгәр йиңел булсын дисәң агырлар,
Чыкыб бер йанә, таб бөрйан бәгырьләр.

Ягъни андый яр син гамәлдән җиңел булсаң һәм гамәлең аз булса, Аллаһ Тәгалә аның сәбәбе белән гамәлеңне авырлатып һәм үзеңне хөрмәт итәр ярны тап. Шулай итеп, андый син, илдән чыгып, бер тарафка барып, гыйшык әһелен тап, аңарга мөрид булып, Аллаһ гыйшкында бәгырьләреңне көйдер, димәктер. *Бөрйан* дигән баның (ба хәрефенең) заммәсе (о, ө хәрефләрен белдерүче тамга) белән көю мәгънәсендәдер. (Биредә исә) *бер йанә* йаның (хәрефенең) фәтхе (ә хәрефе) белән тараф мәгънәсендәдер, *Таб* — әмре хазыйрдер (боеруның хәзерге шәкеле) — табудан ясалган...

Кылыр сохбәт әсәре, ай талибе раһ,
Моның дик җарый улды гадәте Аллаһ.

Ягъни гыйшык әһелен эстәү шуның өчен (кирәк): аның мәҗлесендә утырып, күңелләрдә Аллаһка мәхәббәт булдыру, чөнки һәр мәҗлеснең тәэсире булуы гадәтидер, ягъни Аллаһ мондый гадәтне яраклы кылды.

Нә ки түзгәнигә төшсә, булыр түз (түземле; төз)[1],
Ки андин үтсә кичә-көндез.

Ягъни гыйшык әһеленең мәҗлесендә түзеп, сабыр бул, чөнки олылар әйтерләр: «Түзгән һәм сабыр иткән кеше түш җыяр (ашар)», диерләр. Шулай булгач, ул очракта,

1 С.-П.да — «Нә кем түзгәнигә уш булыр төз» (176 б.)

сабыр бул, аларның утырышларында мәшәкатьләр булса да, әгәр сабыр итүдән көн көндез һәм кичә үтсә дә, дәвамлы бул; димәктер. *Түзгәнгә* дигәне сабыр иткән мәгънәсендә. *Түш* сүзе хайванның түшен әйтерләр, мәгънәсе заһирдыр (ачык). *Түз* дигәне — боеру сүзе — түзүдән ясалган.

Әгәр чәндикә накабиллегең бар,
Никүләр җәмгыйдин аерылма, зинһар.

Ягъни әһле сәлаһ (күркәм холыклы кеше) булган кеше, кабулиятең (кабул булырдай изгелегең) булмаса да, изгеләр (никүләр) җәмәгатеннән аерылма, зинһар; изгеләр белән күңелеңне бәрк (нык) багла (беркет), димәктер.

Әгәр чыкса ефәкнең җәмгыйдин лас,
Булыр гарык сийаһы әййүһан-нас.

Ягъни ефәкнең төбеннән (түбеннән) чүбек (лас) чыкса, сатучы адәмнәр оялудан тиргә батарлар. Адәмнәр аны сүгәрләр: «Ни өчен монда чүбекне куеп, алдап сату итәсең?» — дип. Аннан морад: кыямәт көнендә Аллаһ Тәгалә шелтәләр: «Йә колым, ни өчен кадерле гомереңне явызлар утырышында катнаштырып уздырдың?» — диер. — Шул заман йөзең кара (сийаһ) булып, ефәк төбеннән чүбек чыккан кеше кебек булырсың. *Лас* дигәне чүбек мәгънәсендә...

Үзен кылса кайу мәс (бакыр) нокрага зәмм,
Куяр халык углы мәс атыны дәрһәм.

Ягъни күрмәссеңме, кайсы бакыр үзе көмешкә (нокрага) төшсә, ягъни бакырны көмешкә кушып (мәс нокрага зәмм), бергә эретеп, акча ясасалар, халык уллары ул кушылган бакырны көмеш акча (дәрһәм) дип исем куярлар. Кыскасы, син дә бер явыз әһеленнән изгеләр утырышына барсаң, изге исемле булырсың, димәктер. *Мәс* дигәне бакыр мәгънәсендә була, фарсыча. *Нокра* дигәне көмеш мәгънәсендә.

Алыр сохбәтдә кеше бер-бередин бәһр (өлеш),
Әгәр күб чәшмә булса, булыр нәһр (елга).

Ягъни бер мәҗлестә булып, зикер итүдә катнашсалар, бер-береннән файда алырлар. Чөнки күп чишмә бер-берсенә кушылса, олы елга булып ага. Андый күп изге әһелләр бергә җәмгъ улса (җыелса), олы савап табып, дәрәҗәләр хасыйл булыр. Сүзнең асылы: син җәмәгатьтән аерылма, димәктер. Шуңа күрә боерыр:

Җәмәгатьдин үзеңне кылма мөмтаз (аерым),
Чапар күб тубадин аерылганны кошбаз.

Ягъни, кыскасы, әһле сөннәттән үзеңне аерма, даими алар юлында йөр, бидгать (ярамаган) юллардан саклан; чөнки кошлардан берсе аерылып йөрсә, карчыга (кошбаз) аны алыр. Шулай син дә җәмәгать юлыннан аерылсаң, шайтан ләгыйнь алдап, харап кылып, иманнан җөда әйлаб (мәхрүм итеп), кяферләр гөруһыннан (төркеменнән) булырсың. *Тубадин* дигәне төрки сүздер, мәгънәсе тупланудан ясалган.

Киләгә бүре чапса, әй фәлани,
Кайу аерылса, ул һәм тешләр аны.

Ягъни, әй фәлән кеше, куй көтүенә (киләгә) бүре чапса, ул бүре көтүдән аерылган куйны тешләр һәм ашар. Андый, син дә җәмәгатьтән аерылсаң, шайтан сине алдар, димәктер. *Килә* кяфнең (кяф хәрефенең) кәсрә белән (и хәрефен билдерүче тамгасы белән) көтү мәгънәсендә. Сәмәрканд халкының сөйләме.

Йөрсәң йиккә[1] дийү башыңны янчер.
Каракчы тубадин аерылганны санчер.

Ягъни, җәмәгатьтән аерылып ялгыз йөрсәң, ничек угрылар һәм караклар кәрваннан аерылып йөргән кешене чәнчесәләр (санчер), малын алсалар, шайтан ләгыйнь дә башыңны яньчеп, ягъни акылыңны station аздырып, көферлек упкынына төшерер.

Ходаның рәхмәте булса җәмәгать,
Ирер рәхмәте дин аерылган шәнагать.

1 С.-П.да — нигә (179 б.)

Шулай булгач, кыскасы, җәмәгать Ходайның рәхмәтендә булса, ул рәхмәттән аерылу хурлык булыр (шәнагать), дөньяда һәм ахирәттә түбәнлеккә төшүне белдерер. *Шәнагать* шиннең (шин хәрефенең) кәсрә белән хурлык мәгънәсендә, гарәпчә. Шуннан чыгып, *җәмәгать* дигәне гадимдер (гомуми, масса). Җәмагатьтән морад: изге җәмәгать, сөннәт әһелләречә һәм изгелек юлында йөрүче.

Нә ул җәмгы ки гафләт әһле булгай,
Бәһаим дик зиадә җәһли булгай.

Ягъни безнең җәмәгать дигәнебездән морад: андый гафилләр (ваемсызлар) һәм фасикълар (бозыклар) җәмәгате түгел һәм хайван (бәһаим) кебек зиадә (нык, күп) наданнар җәмәгате түгел. Бәлки изге галимнәр һәм суфыйлар җәмәгате, зикер мәҗлесендә утырып, Аллаһны зикер итәрләр.

Аларның сохбәтен, бел, зәһре коттал,
Бозар күб сохбәтен, бел, бәд-әфгаль.

Ягъни ул явызлар һәм фасикълар утырышы үтерүче (коттал) зәһәр дип бел, чөнки изгеләрнең утырышында күп утыруыңны явызлар утырышында бер кәррә (тапкыр) утыруың бозар, саваптан мәхрүм кылыр.

Кирәк сохбәт илә бер тән вә бер рик,
Барс (?) руйи нахен булса һәм ник.

Ягъни бу мәҗлес әһеле барчасы бер тәнле һәм тамырлы (рик) булу, ягъни барчасы бер игътикадда (ышануда) булып тору кирәк. Фикерләре үзгәреп торган һәм мәзһәбләре пәрахәндә (таркау) булмау кирәк. Чөнки аклык тырнакта булса, яхшы, башка урыннарда аклык булса, мәзмүм (кушылган) һәм мәшмүм (хуш исле). Андый мәҗлес әһелләре барчасы изге гадәттә һәм изге фигыльдә булулары яхшыдыр. Араларында бер бәдәфгаль (бозык, начар фигыльле) булса, мәзмүм һәм мәшмүмдер. *Рик* дигәне тамыр мәгънәсендә. *Барс* аклык мәгънәсендә. *Нахен* тырнак мәгънәсендә.

Әгәр килсә мәгъз — нәфрәт кыл андин,
Еландин ни зарар булса, бел, андин.

Ягъни әгәр синең юлдашыңнан әҗнәбилек (чит, ят кеше) һәм йадлык (искә төшерү) килсә, ягъни Аллаһ мәхәббәте булмаса, ул юлдаштан кач, чөнки аннан явыз юлдаш еланнан зарарлырак диеп бел аны. *Мәгъз* дигән сүз әҗнәби (чит кеше) мәгънәсендә, төрекмән халкының сөйләме була.

## Хикәяте дию...

Диде бер дию хасдин беригә:
«Барыб кит, әйт, фәлан фахешле йиргә».

Ягъни бер шайтан икенче шайтанга әйтте: «Бар, фәлән җирдә суфыйлар мәҗлесе бардыр, анда барып хәйлә кыл, аларны юлдан чыгар һәм бозык урынга өндә», — диде.

Диде ул: «Фиркадин фаригъ бул, әй йар,
Алардыр бер-беригә дәһбәре нар».

Ягъни ул боерылган шайтан боерган шайтанга әйтте: «Әй юлдаш, ул суфыйлар җәмәгатеннән ерак һәм фаригъ (азат) бул. Аларга вәсвәсә кылып булмас, чөнки алар бер-беренә тәмугны ерак кылучылардыр, кешеләренең зикерләре безне ерак куучыдыр. Аслан (һич тә) аларга вәсвәсә кылырга мөмкинлек юк», — диде, *Дәһбәре* далның (дал хәрефенең) фәтхәсе белән ерак мәгънәсендә. Кашкарый халкының сөйләме була. Шуннан чыгып, мәгълүм булды: җәмәгате соләхада (изгеләр мәҗлесендә) файдалар күп, мөстәфид (файда эзләүчеләр) әһеленә хәфи (сер) түгел. Кыйссадан хиссая кайтып боерды:

Белебдер заһир дошманларын дуст,
Имәс хаҗәт ки, керсәң риг белә пуст.

Ягъни бу адәм уллары шундый гафилләрдер (ваемсызлар), ачык (заһир) дошман булучы нәрсәләрне дус дип белделәр, ягъни бозык, фөҗүр (уйнашчы) мәҗлесен дөньяда дус дип белделәр, аны сөйделәр, аларга иярделәр, әһеле сөннәт юлыннан ерак булдылар. Шулай итеп,

барчасын бәян итү сиңа хәҗәт түгел. Әмма изгеләр юлына тамырың һәм тирең белән керсәң, явыз мәҗлесләрнең дошман икәне мәгълүмдер һәм алар мәҗлесенең зарарлы икәнен белерсең, димәктер.

## Дөньядан тәҗәрред (бизү) хакында

Кил, әй салик (юлчы), үзеңне юлга салдың,
Олуг һиммәт гасасын (таягын) кулга алдың.

Ягъни, әй изге юлга керүче, үзеңне тарикать (дини юнәлеш) юлына салдың, олы һиммәт (тырышлык) таягын кулга алдың, ягъни әдәп, гакаиде тарикатьне[1] («дини-суфыйчыл ышануларны») кыскалык белән белдең[2].

Әгәр калмай дисәң кергән юлыңдин,
Тәҗәрред дәүләтен бирмә кулыңдин.

Ягъни әһле сөлүк (дәрвиш) булып, кергән юлыңнан калмыйм (калмай) дисәң, ялангач булмаслык кына дәүләтеңне кулыңнан чыгарма, ягъни аннан морад: дөньяга алданып, дөнья әһеле булудан саклан, ягъни бу дөнья ләззәтләренә алданып, Аллаһны эстәүдән мәхрүм булма.

Кәйнгә[3] бакма — гудик булса бәндә,
Йитәр мәкъсудига тиз эзләгәндә.

Ягъни Ходай Тәгаләнең ... сүзенә бер бәндәнең каравы булып, һәрчак ихласы белән Ходайның боерган әмеренә буйсынып, Аллаһ ризалыгын теләүдә булса, тиз заман бу бәндә мәкъсудына җитәр (теләгенә ирешер). Димәк, андый булса, гафил булмассың. *Кәйнгаһа* Аллаһ мәгънәсендәге сүз, әмма монда әмер мәгънәсендә...

Әгәр баксаң кәйн бу таг вә чүлдә,
Мәбадә калмагайсән урта юлда.

Ягъни син карасаң, Ходай Тәгаләнең ... әмерен тауларда һәм япаннардадыр (далалардадыр) дисәң, аңсыздан урта юлда калып, матлубыңдан (теләгеңнән) мәхрүм (мәбадә)

---

1 С.-П.да — адаб, гакаид вә тарикатьне (180 б.).
2 С.-П.да — мөхтәсар сәбәбле узә белдең (180 б.).
3 К.да — көтенгә (124 б.).

булырсың. Кыскасы шулдыр, Хак Тәгалә ризалыгы таularда һәм япаннарда гизеп табылмас, бәлки әмеренә буйсынып, дөнья ләззәтләреннән бизеп, күңелеңдә саф, чиста Ходай мәхәббәте белән генә ризалыкны табарсың.

Мәшәкъкать булмаса сунган буенда,
Бәһ (яхшырак) андин булганы[1] йирнең куенында.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең әмеренә буйсынган бәндәдә мәшәкать булмаса, ягъни күп мәшәкатьләр чигеп, Аллаһ Тәгаләне эстәмәсә һәм аның әмеренә итагать итмәсә (буйсынмаса), ул кешенең үлеп, җир куенында булганы — изгедер. Чөнки бәндә булган кеше, никадәр мәшәкатьләр күрсә дә, әлбәттә, Аллаһ Тәгаләне эстәве кирәк, димәктер.

Гыйбадәт бәндәнең мәнзуре булса,
Бәһ ул ирнең өйүендә хури булса.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең коллыгы бер бәндәнең зәүкы һәм гыйшкы булса, ягъни Аллаһның гыйбадәтенә рәгъбәт әйләсә (теләк булдырса), өендә хур кызы кебек күркәм кыз булса да, аңар мәйл (теләк) кылмас, бәлки Аллаһ ризалыгын табуны аннан артык дип белер, ягъни гыйбадәттән башка нәрсәне теләмәс. *Мәнзур* мәргуб (сөелгән, теләнгән) мәгънәсендә истигарә (күчерелмә мәгънәдә) алынды.

Вәләкин итмәсә шәһват (дәрт) җөдалигъ,
Күңелгә килсә[2] касд кәдходалигъ.

Ягъни хакыйкатьтә (чыннан да) Аллаһны эстәүче бәндә ул хур кызына кызыкмас, чөнки күңелендә Аллаһыга гыйшкы галиб (өстен) булыр[3].

Дийанәт эстәгүдекне таләб кыл
Вә гәр табылмаса, көнҗидә (почмакда) хәб кыл.

Ягъни тәҗәрреддән (башкалар белән бәйләнешне өзеп ялгыз яшәүдән) морад: бөтенләй үк (тәмам) хатын

---

1 С.-П.да — булганың (181 б.).
2 К.да — булса (125 б.).
3 К.да — Аллаху Тәгаләнең гыйшкыны төшереб, аңа (ягъни хур кызы кеби затка. — Х.М.) илтифат әйләмәз, димәкдер (125 б.).

алмаслык түгелдер, чөнки пәйгамбәр г-м хатынлы иде. Сүзнең асылы шулдыр: хатын алып, аның белән гыйш-гыйшрәт (кәйф-сафа) кылып, вакытыңны бушка уздырма, мәхәббәтеңне гыйбадәттән өстен чыгарма. Әгәр дә хатын алырга теләсәң, дин эстәүче суфыя (динле, изге) хатынны ал. Әгәр инде андый хатынны тапмасаң, почмакта[1] әбсәм булып (дәшмичә) тик тор *Кәнҗидә* почмак мәгънәсендә. *Хәб* дигәне — әбсәм; ул хамуш баш (дәшмә, дәшмәүче) мәгънәсендә, һәр икесе һинди сөйләме.

Әгәр зәнки бичәдер күзләре күр (сукыр)
Үкәм мәстүрә булса, аны хур.

Ягъни ул дин эстәүче хатын зәнгистан (төсләләр) вилаяте кешесе кебек кара хатын булып, күзләре сукыр булса да, ягъни йөзен намәхрәмнәрдән өретсә дә («күрсәтсә»), тәхкыйк (һичшиксез), аны хур кызы сана. *Бичә* дигәне бай сүзеннән, гарәпнең (гарәптәге ба хәрефенең) кәсрә (и хәрефе) белән хатын мәгънәсендә, төрки сүз.

Әгәр чәндикә булса бәндәзадә,
Аны сахибе нәсәбдин күр зиадә.

Ягъни ул мәстүрә (бөркәүле) хатын колдан туган булса да, аны син сәйдзадәдән (пәйгамбәр нәселеннән, аксөяк нәселеннән) артык (зиадә) күр; чөнки нәсел белән артыклык юк, бәлки тәкъвалык белән генә...

Теленең әүзүне — шәрем хәйасы,
Йөзенең акыдыр — ирнең ризасы.

Ягъни изге хатын шул була, үлчәп (әүзүн) сөйләшә, ягъни татлы телле, оятлы (шәрем) булып, ак йөзе белән ирнең ризалыгын ала. *Әүзүн* әлифнең фәтхә (ә, а авазларын белдерүче тамга) белән укылыр, заммәсе (у, у...) белән уку хатаи фахиштер. Мәгънәсе үлчәү.

1 С.-П.да — почыкда (181 б.).

Ушал хатын ки намәхрәм нәзардыр[1].
Әгәр шәмси-камәрдер, мачәи хәрдыр.

Ягъни алган хатының, мәсәлән, ят ир-атларга караучы (нәзар) булса, гарчә ул хатын ай һәм кояшка (шәмси-камәр) тиң күркәм йөзле булса да, ана ишәккә тиң булыр (мачәи хәрдыр). *Мачә* дигәне ана, хәр дигәне ишәк мәгънәсендә...

Әгәр чәндикә бозоргзадәдер ул,
Йакыйн бел: түрт айаклы мадәдер ул.

Ягъни ул намәхрәм сарый (читкә) караса, гарчә пәйгамбәрзадә булса да, шиксез бел: дүрт аяклы ана хайван, ягъни андый булса, аның сәидзадә икәненә игътибар булмас, аңа карап торылмас.

Ушал хатының яшермәз йөзене,
Ки намәхрәм сарый күрсәтер үзене.

Ягъни бер хатын йөзен пәрдә белән өретмәсә (капламаса), ят ирләргә йөзен күрсәтсә, алар белән сөйләшсә.

Аны мәнгь итмәс (тыймас) ирдер бихәмийәт,
Холасада (асылда) ирер мондаг сәввият (тигез).

Ягъни андый намәхрәмгә йөзне күрсәткән хатынны ире тыймыйча риза булса, ире көнчелек кылмаган өчен һәм хатын йөзен качырмаган өчен, һәр икесе гөнаһыда иптәш, иш булырлар (гөнаһлары уртак булыр)...

Багайрәт ир булыр разый кәзага,
Йибәрмәс әһлене туй газага.

Ягъни гайрәтле һәм көнче ир мәшәкатьләрдә һәм тарлыкларда торырга риза булыр, ләкин хатынын туйларга һәм башкача җиргә булышырга (газага) җибәрергә риза булмас, ягъни фәсад (бозык) урыннарга җибәрмәс. *Кәза* кяфе гарәбия (гарәб язуындагы кяф

1 К.да — нәгардыр (126 б.).

хәрефе) белән мәшәкать һәм хәйф мәгънәсендә, һинди сөйләме була. Кайбер нөсхәләрдә кәза каза язылган. Һәм ул дөрес, мәгънәсе ачык кала. *Газа* гайн белән бер җәмәгать хатыннар: төркем булып җыелып, кыз кияүгә киткәндә сорур (шатлык, музыка) белән такмак әйтерләр.

Булыр риза кара йиргә тыкарга,
Кайчан разый булыр өйүдин чыкарга.

Ягъни гайрәтле һәм көнче ир хатынын һәм җәмәгатен кара җирнең астына тыгарга риза булыр, ләкин, өйдән чыгарып, бозык урынга барырга риза булмас.

Гарз (үтенеч), әй бәндәләр, назыйр булыңлар,
Йаман йул-фиркага хазыйр булыңлар.

Ягъни, кыскасы, бәндәләр, бу сүзләргә караучылар яман юлда йөрүче адәмләрнең хәлләрен күрделәр, алардан Ходайга сыгынырлар, китапларда күргән кадәренчә яман юлга йөрүче гөруһларның (төркемләрнең) бәянына идалем (итәм), димәктер...

## Җәзбәи шайтан бәяны[1]

Бәни адәмдә бардыр бер фәрика.
Тоталар үзләрен әһле тарика.

Ягъни Адәм улларыннан бер төрле гөруһ (төркем) бардыр: үзләрен тарикать (дин) әһеле санап, «безләр әһле җәзбамыз» (экстазга бирелүчеләр) диерләр, җәзба дигән сүзнең мәгънәсен белмәсләр һәм аның ни төрле, ничек икәнен белмәсләр, «мөҗәррәд (ялгыз) тарикать әһленнән без һәм зикре җәһриданмыз (зикер әйтүчеләрдән без)» дип акырып, бакырып, дивана булып йөрерләр. Гомумән, моның кебек халык Кашгар җирендә күп. Бераз Бәлх, Бохарада бар иде. Бәхәмдуллаһу Тәгалә (Аллаһка шөкер), бу заманда мөнкатыйг булынды (туктатылды). Әмма Болгар җирендә бераз мәгълүм булган урыннарда бардыр: аерым әйткәндә, нәһре Сөндә (Сөн елгасы буенда) һәм

1 «Шайтан белән мавыгу бәяны».

www.darul-kutub.com

нәһре Керкәледә (Керкәле елгасы буенда) бар, әмма мәшһүр (атаклы, танылган) түгел. Әмма Дагыстан тарафында һәм әрзе Румда (ягъни Рум җирендә — Кече Азиядә) һәм гарәпләр җирендә асылда юк. Ә менә мәзһәбе батыйлны (ялган мәзһәбне) булдыручы Йаграб бине Сафуан иде. Элек Хак Тәгалә дини әмерләрен сөеп тота иде. Ахырда шайтан галәйһеллягьнәти (аңа ләгънәт төшсен!), аздырып, әһеле җеннән булды; барып Кашгар җирендәгеләрне аздырды, чөнки алар надан иделәр. Аннан галәм тарафына җәзбе зәхмәте (экстаз чире) кебек җәелде һәм тәэсир итте, хәтта ки Кашгар җирендә Хак әһелләренең күбесен һәлак иттеләр. Ахыры имам Гыйсмәтулла әл-Мәрвәзи,[1] Бәлхдаи барып, аларны туздырды. Инде азлыкта калып, көннән көн зәбун (түбән) булдылар. Бәһре вәҗһә («төскә әйбәт») булсалар да, алар Аллаһның дошманыдыр, Иблистән болар.

Алар шәргы нәбинең дошманыдыр,
Аларның аты, ягъни рушанидыр.

Ягъни ул сыйфатланган гөруһлар пәйгамбәр шәригатенең (шәргы нәбинең) дошманыдыр, ягъни шәригатьтә болардан артык дошман юктыр. Боларның хәлләре кяфере вәсәнидан[2] (поттан; сыннан) артыктыр. Әмма аларның мәзһәбләренең исеме «Мәзһәбе Йәгърәб бине Сафуаны Рушандыр» диерләр. *Рушани* бер авылның исемедер. Бәлхтән тугыз мил кадәредер.

Алар үзләригә гариф[3] куеб ат.
Укырлар яхшыларга яхшы әбйат (бәетләр).

Ягъни ул батыйль мәзһәбнең сыйфаты будыр: аклар бер-берсен гариф (белүче; югары дәрәҗәгә ирешкән дип) куеп: «Ул шундый олуг әүлия һәм мондый хәлле» диерләр; берәүгә җыелып, ахирәт хәлен сөйләгән бәетләрне һәм хикмәтләрне укырлар, гавамнарына әйтерләр; төрле дәф (шөлдер — музыка коралы) һәм най (нәй — флейта),

---

1 С.-П.да — әл-Мазрури (183 б.).
2 С.-П.да — кяфрел-вәсәндан (184 б.).
3 С.-П.да — гами (184 б.).
3 К.да — авазларлар (127 б.).



www.darulkutub.com

һәм кубыз, һәм гөслә чалырлар (уйнарлар), хатыннар һәм мәрдләр (ир-атлар) нәфис авазлар белән җырларлар[1]. Бер заманнан соң кайберләренең дәмагына (борынына, өстенә) шайтан усырып, акылларыннан язып, һушсыз булырлар. Әйтәләр ки, акыллары язуы әдвийа (тәм-том, «дәва»ның күплеге) беләндер. Нәбате софранийе голәсанә куеп (ягъни үләннәр яндырып, наркотик кулланып), аннан дуд[2] (төтен) чыгып, дәмагларына керер, һушсыз булдырыр. Әмма шәех булган бер кешеләре бар: ул һушсыз булмас, даими салкын балны авызына сала торыр, баягы төтеннең хәрарәтене (эсселеген, тәэсирен) бетерер. Ул мәлгуньнең гарзы (теләге) шул: кайсы күркәм хатын һәм күркәм ир һушсыз булса, аларга интим мөнәсәбәткә керү.

Вәләкин әйтер биһудә мәгънә,
Үзенең йулыга алмакга йәгънә.

Ягъни ул мәлгуньнәр ул мәҗлестә файдасыз (биһудә) мәгънәләрне әйтерләр, үткән изге әүлияләрнең хәлләрен сөйләрләр, аларда булган кәрамәтләрне (могҗизаларны) сөйләп, кешеләрне кызыктырып, үзләренең хәлләрен батыйль (бозык) юлга юнәлтү һәм кертү һәвәсендә булырлар; шулай булуга карамастан, үткән әүлияләрнең хәлләре боларда юк, шуның өчен файдасыз мәгънә булды.

Аларда булмагай һич яхшы ният,
Гайалу әһледә булмасдыр хәммият (саклау).

Ягъни ул мәҗлестә катнашучыларда һич яхшы ният булмас, бәлки бер-беренә гыйшык (гашыйк) булып йөрерләр һәм җәмәгатьләренә һәм хатынларына көнчелек кылмаслар, бәлки кайсының хатыны кулга очраса, аны җәмаг кылырлар (интим мөнәсәбәткә керерләр) һәм әйтерләр: «Мин Аллаһ гыйшкыннан исереп йөрдем, һич нәрсә белмәдем», диерләр һәм галимнәрне дошман күрерләр һәм намазны сөймәсләр һәм әйтерләр: «Һәркем бу кичә бу мәҗлесдә утырса, кырык ел гыйбадәт савабы булыр», — диерләр. Аһ, Йарабби (йә Аллаһым),

1 К.да — авазларлар (127 б.).
2 К.да — төтен (127 б.).

бу гарибең Таҗеддин үсмер чакта аларның мәҗлесенә өч мәртәбә (mankыр) дучар булды. Серләрне белүчесең син, тәҗрибә өчен керен йөрде, гафуны синнән үтенде, рәхмәтең белән гафу ит.

Җамигъ (һәммә) җанварлар төшсә күзгә,
Хәммийәтлек булыр дуңгыздан үзгә.

Ягъни җиһанда барча хайваннарның гайрәте һәм көнчелеге булыр, мәгәр дуңгызда юктыр. Шуның өчен аларның мөәннәсләре (ана дуңгызлары) өчен иркәкләре (ата дуңгызлары) ачуланмаслар, бәлки берсенең өстенә берсе менәр. Әйтәләр ки, ләввата («педерастия») һәм көнчесезлек дуңгызда бар, гайре (үзгә) хайванда юктыр, шуның өчен боларны дуңгызга тиңләде.

Аларның бу фигьледер дуңгызга охшаш,
Шәригать мәнкеридер агзыга таш.

Ягъни бу мәлгуньләрнең фигыле дуңгызга охшашдыр, чөнки дуңгыз кебек көнчелекләре булмас. Алар шәригатенә әйдәүчеләргәдер — авызга туфрактыр һәм таштыр. Аларның шәригатькә инкарь әйләмәкләре (кире килүләре) шулдыр: кайчан бер галим, аларны «Коръән» һәм китаплар белән үгет бирсә, кяфер диерләр, һәм аңа кире әйтерләр, һәм рамазан аенда, галимнәргә мөтабәгать әйләмәйүб (буйсынмыйча) уразага ике көн яки өч көн элек керен кенә, җәмәгатьтән алда ике көн элек гайд итәрләр (гает бәйрәмен уздырырлар)... Шәех булган кешеләре алардан, нинди яхшы нәрсәләрен күрсә, аны теләнчелек кылып алыр. Һәм дә әйтерләр ки: «Малыбызның нисбе (яртысы) шәехебезнекедер, бездән сорамый алса да, гарчә без риза булмасак та хәләлдер», — диерләр.

Аларның фигълене кем яхшы белде,
Булыб кяфер йанар утка екылды.

Ягъни ул мәлгуньләрнең хәлен яхшы белгән кеше аларга барса һәм, риза булып, хатыннарны һәм балаларын бирсә, кяфер булып, үзен-үзе утка атты, ягъни кяферләрдән

булып, җәһәннәмдә әбәд (мәңге) калды, чөнки хәләл түгел икәнен белеп барды, шуның өчен кяфер булды...

Булыбдыр йәнә бер фирка пәйда,
Аты мөэмин, вәли нәфсигә шәйда.

Ягъни бер Рушани мәзһәбе кебек бер гөруһ пәйда булып исеме мөэминдер, ләкин үзләренең нәфәсләрен[1] («кешеләрне») алдаучылар. «Мөэминбез» дип торырлар, чынлыкта алар батыйнда (эчтә; асылда) кяферләр. Әйтәләр: боларның мәзһәбе хоруфийун[2] диерләр, Бәркыйлда габбасия диярләр, чөнки бу явыз мәзһәбне пәйда кылучы Габбас бине Габиделхоруф диерләр. Әйтәләр: мондый мәзһәб Әдернә (Төркиядәге шәһәр, төбәк исеме) һәм Салиядә (Салидә) һәм Яна Кальгә шәһәрләрендәдер. Кайберләр әйтәләр: бу мәзһәбнең исеме әүбаш[3]...

Йагарлар пареи буены йәванны,
Салырлар уртага тага кыз вә җәванны.

Ягъни ул гөруһ (төркем) җыелырлар, мәҗлесләрендә бер парча буе яван дики әдвийане (җыелган тәм-томны) җәмгъ итәрләр[4] (ашарлар) яки утка ягарлар һәм дә яшь кызларны һәм егетләрне урталарына салырлар. Ул әдвийане салуларының максуды (нияте) шулдыр: мәзкүр (югарыды телгә алынган) әдвийанең дуды (исе; төтене) дәмагыга (борынга) керсә, адәмне һушсыз кылыр. Шәех булган кеше даими серкә һәм хомузат (кислоталы) нәрсәләрне эчәр, шуның өчен һушыннан язмас. Аннан соң теләгән кыз һәм яшь егетне (ир) җәмаг әйлар (интим мөнәсәбәткә керер). *Буены* юан бер үләннең исемедер, һинди дәүләтеннән килер, кара булыр, хатыннар толымы кебек булыр. Болар әүбашлылар, Рушани мәзһәбеннән явызраклар.

---

1 К.да — « үзләре нәфесләрене (нәфселәрене?) үзләре алдагучылардыр...» (128 б.).

2 Хоруфийүн — хоруфия — шигыйлар мәзһәбе. Аңа XIV гасырның урталарында нигез салына. Хоруф — хәрефнең күплеге. Бу мәзһәб тарафдарлары фикеренчә, иляһиятнең асылы сүздә гәүдәләнә. Сүз исә хәрефләрдән (авазлардан) тора. Аларның гомуми суммасы Алланың сыйфатларын белдерә. Хоруфия тарафдарлары аеруча Иранда һәм Госманлы мәмләкәтендә күп булалар.

3 Әүбаш — гыйсьян; сукбай; надан; азгын һ.б.

4 Биредә сүз исертә торган үләннәрне җыелешып иснәү, наркотиклар куллану турында бара.



www.darul-kutub.com

Әгәрчә Рушани ирмәк бу әүбаш,
Вәли бу эш шәригать хөкемедин таш.

Ягъни, гарчә бу мәзһәб Рушани мәзһәбе булса да, ләкин боларның исеме әүбаш була. Ләкин бәһре хәл (шул мәзһәб кисәге) булса да, һәр икесенең мәзһәб шәригате хөкемедин хариждыр (таш; ягъни тышта). Һәр ике мәзһәб кяферләр. *Әүбаш* һәр тарафтан килгән кешеләр исеме яки фасикълык (бозыклык) мәгънәсендә, истилахда (термин буларак) йайи нисбәт белән. Йайи нисбәт хәзф булынды (төшереп калдырылды). Зарурәт (ягъни төшерү) шигырь өчен. Асылда мәзһәбе Габбас бине Габиделхоруф әл-Әүбаши диерләр. Шулай булгач, бу тәкъдирчә Әүбаш бер шәһәрнең исеме булыр, Шираз карибендәдер (тирәсендә).

Бөтебдер Әбул-Хәсән ул йахшы бәндә,
Чыкар мондаг фарикъ ахры заманда.

Ягъни бу ике гөруһ замана ахырында чыгарлар[1], ул заманда күп булырлар, диде.

Бу айган фирка зал мазалдер,
Шәригать әһле бу иддин хәҗилдер.

Ягъни ул китапта (сүз «Адабе суфый» хакында бара) әйтте: бу әйтелгән ике гөруһ азгыннар (залдыр) һәм аздыручылар (мазалдер) инде. Бу җәмәгать шәригать әһелләре янында оятлылар. Мисраге саниядә (икенче юлда) тәкъдим һәм таэхирдер (кичектерү, соңга калдыру). Асылда бу юл шәригать әһелләре янында хәҗилләр (оятлылар, оялучылар), димәктер...

Инансын диб[2] моны берничә бигакыл,
Кылырлар Хуҗа Әхмәддин[3] моны нәкыл.

Ягъни инансыннар дип берничә акылсыз (бигакыл), ул ике мәзһәбнең табигълары (тарафдарлары) Хуҗа Әхмәдтән

1 Ягъни Әбүл-Хәсән Әл-Хоруфани хәзрәтләре «Адабе суфый» дигән китабында бу билгеле ике төркем заман ахырында чыгарлар, дип яза. (129б.)

2 С.-П.да — вәли (187 б.).

3 Биредә 1166 елда вафат булган Әхмәд Ясави күздә тотыла.

күчерерләр (нәкыл кылырлар), ягъни халыкларны алдау өчен әйтәләр: безнең силсиләмез (шәҗәрәбез; нәселебез) Әхмәд Ясәви, диерләр.

Ходаның дусты булса Хуҗа Әхмәд,
Кылырмы һәм моның тик бидгате бәд (начар гамәл).

Ягъни Хуҗа Әхмәд Ясәви хәзрәтләре Аллаһның дусты булса да, мондый бидгать һәм явыз эшләрне кылмас. Кыскасы, андый олы әүлия мондый кяферлек фигыльләрне кылмас.

Шәригатьдә әйде ул афтаби (кояш),
Төшебдер безгә ул ирнең китаби.

Ягъни назыйм (автор) әйтте: ул Хуҗа Әхмәд Ясәви хәзрәтләре шәригатьнең кояшы иде, ягъни камиллеге төгәл иде, ул ирнең безгә «Нәҗател-закирин»[1] дигән китаптан күчереп, «Тәнбиһел-залин»[2] дигән китабы эчендә язды. Бу ике китап та Хуҗа Әхмәд Ясәвинең тәхрирләредер (язмалары). Хәерле булсын дип күчереп куйды.

Анының дәк — фиркаи мәлгуне Ходадыр,
Аларның фигъле — сөннәтдин җөдадыр.

Ягъни андый гөруһ Аллаһ Тәгаләнең рәхмәтеннән ерак торыр һәм дә аларның эшләре сөннәт әһеле һәм җәмәгате эшләреннән аерылган булганга, шуның өчен кяферләр була. *Мәлгунь* дигәне Аллаһның рәхмәтеннән ерак мәгънәсендә.

Бу эшләрне, бишикк вә рәйб (һичшиксез), әй мөселман,
Ушал котбе замандин ирде ялган.

Ягъни бу әйтелгән ике гөруһның эшләре, шиксез һәм шөбһәсез, ул котбе галим (галимнәрнең үзәге, ягъни юлбашчысы) Шәех Хуҗа Әхмәд Ясәви хәзрәте заманыннан бирле ялган, ягъни бу ишарәттер, мондый кара гөруһлар анын заманында да булган, имеш.

---

1 «Догачыларның котылуы» мәгънәсендә.
2 «Юлдан язучыларны искәртү».

Кайу иргә нәкыл итсә бу эшне,
Инанмаң, зинһар, андаг димешне.

Ягъни кайда әүлиядән берәү мондый эшләрне күчерсә һәм нәкыл әйласә (кабатласа), зинһар, аның нәкылына инанмагыз (ышанмагыз), билхакыйкать (чынлыкта) ялган булыр.

Аның шаинында ялгандыр бәдәфгаль,
Әгәрчә чын булса, ирмәс сахибе халь.

Ягъни андый эшләр Хуҗа Әхмәд каршында (шаинында) ялган була. Әгәр мондый эш хакыйкать булса, ул һәм гыйльме хәл иясе (ягъни суфый) түгел, чөнки әһеле хәл мондый набекар (ярамаган; мәкерле эш) эшләмәс.

Вәли белмәсмез ул ялган кешене,
Кылыб үткән икән шәйтан эшене.

Ягъни андый фигыльләрне кылучы ялганчыларны әүлия дип белмәбез, бәлки аны шайтане ләгыйнь алдап, тугры юлдан чыгарды дип белербез.

Алыб барса кеше әһле гайалын,
Күтәрер бихәмийәтлек вәбалын.

Ягъни бу ике мәҗлескә бер кеше хатынын һәм баласын (гайалын) алып барса, ул кеше көнчелек кылмаганнарның гөнаһысын күтәрер, алар гөруһында булып, тәмугта калыр.

Хәрам эшне ки тагать белсә инсан,
Ирер бу игътикады (ышанычы) намөселман.

Ягъни берәү харам фигыльләрне буйсыну һәм табыну дип белсә кяфер булыр.

Борадәрләр, белеңләр раһы хакны,
Тотын дошман ушал әйган фәрикъны (төркемне).

Ягъни, әй кардәшләр, белегез тугры юлны (раһы

хакны), анын белән гамәл кыл, бу әйтелгән гөруһларны дошман тотыгыз һәм алар мәҗлесенә бармагыз. Әйтәләр: берәү алар мәҗлесенә бер керсә, кырык көнгә күңеленең мәхәббәте алардан бизмәс, шундый явыз әсәрледер (йогынтылы).

Кыямәт көн кушылса тән илә җан,
Кубар һәр ир үзенең дусты берлән.

Ягъни нәбина (пәйгамбәрләребез) г-м әйтте: «Кыямәт көнендә җан белән тән бер җиргә кушылса, кабердән купканда, һәркем үзенә дус күргән төркем белән кубар, — диде. — Шул әҗәлдән кандилдә китерелә ки», — диде.

## Хикәят

Пәйгамбәр дарида, бер күр гидаи,
Килеб ирде теләй чизи Ходай.

Ягъни риваятьтә килә ки, пәйгамбәр г-м йортына (дарина) бер сукыр (күр) теләнче (гидаи) килде, Аллаһ өчен (чизи Ходай) нәрсәдер теләде. Әйтәләр: бу сукыр теләнче Габдулла бине Өммемәктүб хәзрәте иде һәм пәйгамбәрнең мөәзине иде, гаять фәкыйрь кеше иде.

Торыб ирде карашыб бәгъзе әзваҗ,
Газаб берлә карады шаһе мигъраҗ (ягъни Мөхәммәд г.-м):

Ягъни ул сукыр теләнче(гә) пәйгамбәр г-мнең кайбер хатыннары карап торалар иде. Миграҗ шаһы пәйгамбәребез шундый ачу белән карады аларга һәм әйтте ки: «Йә, ни өчен намәхрәм йөзенә карыйсыз?» — диде.

Диделәр: «Әй шаһиншаһе кабаил,
Без андан качмадык күр (сукыр) диб бу саил (теләнче)».

Ягъни ул хатыннар әйттеләр: «Әй кабиләләр падишаһы, без ул теләнчедән сукыр булганы өчен йөзебезне качырмадык,», — диделәр.



www.darulkutub.com

Аларга әйде ул солтане әбрар:
Әгәр күр булса, сезләрдә күз бар.

Ягъни пәйгамбәр г-м җавабында әйтте: «Әгәр ул сукыр булса, сездә күз бар», — диде.

Алар «без белмәдек» диб зарый кылды,
Гөһәрләр күзләрендән җарый кылды.

Ягъни пәйгамбәр г-м хатыннары әйттеләр: «Йә рәсүле Аллаһ, без андый икәнен белмәдек, гафу кыл (кичер)», — дип зар-зар еладылар, күзләрдән гәүһәр кебек яшьләрен агыздылар.

Нә сүз пәйгамбәре әүзаҗига, әй хакъ,
Алар ирде җәмигы шәбедин (асылташлардан) пакь.

Ягъни акыл иясе, бу хикәяттән шул аңлашыла, бу - нинди олы сүз. Пәйгамбәр г-м хатыннарына шелтә белдерде. Әй туфрак затлы адәм, гарчә пәйгамбәр г-мнең хатыннары барчасы шәбедән (асылташлардан) пакьләр иде. Андый булсалар да, бу рәвешле шелтә белән каты дәште.

* * *

Тәгаҗәб фетнәлекдер бу замана,
Төшебдер ирләр әхвали йаманә.

Ягъни гаҗәп фетнәле безнең бу заманабыз: ирләрнең хәле яман, асылда аларда гайрәт һәм көнчелек юк, хатыннарын базарларда, туй һәм булышуларда («өмәләрдә») пәрдәсез риза булып җибәрәләр. Һәм ят ирләр белән сөйләшәләр. Аерым алганда, безнең Болгар йортында бер сабан туе дигән бәйрәм бар. Анда хатын һәм кызларны «Таган асты» дигән уйный торган урынга җибәрерләр, яшь егетләр кызларның һәм хатынларның кулыннан тотып уйнарлар, гауга, һай һәм һуй белән урамлар тулы булыр, һәм дә, шунда уйнап, шәһвәте тарикы (җенси дәрте) белән тоткан хатыннарны, кызларны никах белән алырлар, һәм кайда ул тыйнак хатынның кызын алу. Бу мәхзан (аерым алганда, чыннан

да) харам. Аллаһ Тәгаләнең ләгънәте ул бәйрәмне әүвәл кылучысына булсын, авызларына туфрак булсын хәләл дип игътикад әйдачеләргә (ышандыручыларга).

Хәрадмәнд, ишет мәндин берничә пәнд,
Бу сүзгә булмадым гамил әгәр чәнд.

Ягъни, әй акыл иясе кеше (хәрадмәнд), миннән берничә үгет һәм нәсыйхәт ишет, гарчә мин ул сүз белән гамәл кылучы булмасам да, син аны ишетеп үгет ал. Ул үгетләр түбәндә искә алынса кирәк.

Замана хатыныкы юлга салмак
Ирер асан ул эшдин чәнг кылмак (сугышмак).

Ягъни бу замананың хатыннарын юлга салу, ягъни изгелеккә күндерү бер кальгане (ныгытманы) сугыш белән алудан авыррак булыр.

Өзелмәс (озалмас?) салманы буеңга салма,
Әгәрчә алмадыр рохсаре алма.

Ягъни бәс, андый булса да, өзелмәс салманы, ягъни җепне муенга салма, гарчә ул хатынның йөзе алма кебек яхшы, матур булса да, аны алма һәм никах укытма, чөнки ул сиңа үлгәнче мәшәкать китерер. *Салма* сүзенең әүвәлгесе җеп мәгънәсендә, Сәмәрканд халкының сөйләме була. Һәм икенчесе төрки сүз, алмассызлык[1]. *Алма* сүзенең әүвәлгесе бер мәшһүр җимешнең исемедер. Икенчесе — фигыле нәһидер (инкарь фигыле), ягъни күркәм йөзле намәхрәмнәргә караучы булса, аны алма (өйләнмә), диләктер...

Дәми гайш ки булгай, ахры сәрд,
Аны хушлаб кабул итмә озын дәрд.

Ягъни бераз дөнья тереклегенең (гайш) әүвәле яхшы булса да, андый гафил (ваемсыз) йөрер булсаң; ахыры салкын булыр (сәрддер). Аннан морад: күркәм хатын һәм

---

1 К.да — « вә икене төркидер, салмактан мөштакдыр (ясалгандыр), кинаядер фаҗирә (бозык) хатынны алмассызлыкдан...» (131 б.).



www.darul-kutub.com

намәхрамнәрдән йөзне качырмас хатын алып, аны син яхшы күреп, озын кайгыны алма, чөнки яман хатынның кайгысы дөньяда да, ахирәттә дә күп булыр. Шуңа күрә пәйгамбәр г-м әйтте: «Хәйләкәр хатынның хәйләсе кырык ирнең хәйләсеннән артыктыр», — диде. Кенә (янә) әйтте пәйгамбәр г-м: «Фетнәләрнең олысы күркәм хатындыр, үзен намәхрәмнәрдән качырмас», — диде.

Бала диб салмагыл жаның бәлагә,
Бала берлә булырсән мөбтәлягә.

Ягъни балалар, уллар булсын дип, явыз хатын алып, жаныңны бәлаләргә һәм казаларга салма, чөнки уллар өчен явыз хатын шомлыгыннан күп жәфага очрарсың (дучар булырсың). *Бала* сүзе вәләд мәгънәсендә, гарәпчә. *Бәла* дигәне каза (жәза) мәгънәсендә...

Мөселман алы булсаң, алма алын.
Әгәр алсаң, кабул итмә вәбалын (ярамаганын).

Ягъни мөселман жәмәгатеннән булсаң, ал рәнгле (төсле тәнле) явыз хатын алма һәм аны никах кылма, чөнки *ал* нәрсәнең төсе тиз уңар, ягъни файда күрмәссең. Әгәр алсаң да, явыз хатынның гөнаһын кабул кылма, бозык фигыльләренә риза булып, гөнаһылы булма. *Ал* сүзе жәмәгать мәгънәсендә, гарәпчә. *Алма* — фигыле нәһүдер (инкарь фигыле). *Алын сүзе* уннардан бер ун, явыз фигыльле хатынга күркәм киная була. *Вәбал* гөнаһ мәгънәсендә.

Куеб Тәңре Тәгаләнең ризасын,
Ничек дилдүр кылыр тән мәдгасын («теләген»).

Ягъни мондый явыз хатын алып, Тәңренең ризалыгына ирешергә теләүне читкә куеп, хатынга буйсынып һәм аның явыз фигыльләренә риза булып, ни чук (никадәрле) адәмнәр диндә мөселманмән (мөселман мин) дип игътикад кылыр, гөнаһ кылганына риза булыр; бәлки аны талак кылу фарыздыр (тиеш була).

Әгәр бар алганың яхшы хале,
Димә хатын, дигел диннең кәмале.

Ягъни синең алган хатының изге булса, мәсәлән, намәхрәмнәрдән йөзен качырса, зинадан сакланса, биш вакыт намаз укыса һәм ураза тотса, җәнабәтдән (керләрдән) госел коенса (тәһарәт алса), хәйзе нәфис гыйлемен (гинекологияне) белеп, иренә халисә игътикад (саф ышану) белән хезмәт күрсәтсә, андый хатынны хатын дип зикер итмә, бәлки диннең җитешлеге дип зикер ит. Изге хатын сыйфатын бәян итеп, боерды:

Хуш ул зән, белмәсә биһудә (бүтән) ирне (йирне?),
Сөчүк ләфзы белән шад итсә ирне.

Ягъни ул изге хатын шул була: файдасыз ят йортларга баруны белми, бәлки татлы теле белән ирен шат итә, димәктер.

Әгәр ун ел өвендә булмаса он,
Өне чыкмас аны әйтергә бер көн.

Ягъни изге хатын шулдыр, ун ел буена да иренең өендә ашарга оны булмаса, «бер генә көн дә минем иремнең азыгы юк», дип аны кешеләргә әйтергә авазы чыкмас, бәлки ирнең барлыгына һәм юклыгына риза булыр, аны рәнҗетмәс. *Ун* сүзенең әүвәлгесе гадәддер (сандыр) һәм икенчесе (он) дәкыйк мәгънәсендә. Өченчесе (өн) аваз мәгънәсендә, һәр өчесе төрки сүз.

Белер ир алдыда дадик үзене
Вә гәр йөз табыса, кайтармас йөзене,

Ягъни изге хатын шул була: үзенең хәләл җефете алдында кәнизәк кебек хаҗәтсез итагать әйлар (буйсыныр), гарчә ире аны йөз кәррә (тапкыр) аяк астында типкәләсә дә, йөзен кайтарып ачуланмас, *Дадик* кәнизәк мәгънәсендә, Харәзем сөйләменнән була. *Табыса* сүзе табудан ясалган, төрки.

Әгәр уйса күзен көлфәт белән шуй,
Торыб өвдән чыкарга уйламас уй.

Һәм дә изге хатын шул була, әгәр ире (шуй) аның

күзен мәшәкать (көлфәт) белән уеп һәм тишеп алса да, иренең өеннән чыгып, ят өйләргә барырга фикер йөртмәс һәм ят ирләр мәхәббәте күңелендә булмас. *Шуй* дигәне ир мәгънәсендә. *Көлфәт* мәшәкать мәгънәсендә. *Уй* фикер мәгънәсендә.

Серен фаш әйләмәс ки гамидә булсын.
Әгәр тиң булса, әйтер булса булсын.

Һәм дә изге хатын шулдыр ки, иренең серен фаш итмәс, никадәр кайгыда (гамидә) булса да, һәм әгәр берәү әйтсә, син тарлыкта торасың дигән кешегә әйтер: «Булса булсын, — диер, — мин ризамын», — диер.

Әгәр зәннең моның дәк булса хәште,
Аны дигел бу дөньяның биһиште (оҗмахы).

Әгәр бер хатынның сыйфаты югарыда әйтелгән шартлар эчендә булса, андый хатынны бу дөньяның оҗмахы дип бел. *Хәште* дигәне хаи мөһмәләнең (ха хәрефенең) фәтхе белән сыйфат мәгънәсендәдер, госмания һәм фарсы халкының сөйләмедер.

Илкеңә төшсә мондаг назәнин кол,
Дигел: бу сәндәдер бусеңдә мән кол.

Ягъни Аллаһ Тәгалә насыйп итеп мондый назәнин (назлы, иркә) хатын кулыңа төшсә, әйт, ни серләрең бар, ул хатыннан кизләмәгел (яшермәгел), иншаи Аллаһ Тәгалә, ул хатыннан чыкмас, һәм дә үбеп-кочып «мин синең колың һәм бәндәң, һәм мин хезмәтчеңмен» дияр. *Бу сәндә* сүзенең әүвәлгесе төркидер, бу исеме ишарәт, сәңдәмен мәгънәсендә, төрки, һәм икенчесе *(бусеңдә)* үбү мәгънәсендә, фарсыча сүз.

Сарай ахирәтнең задыдыр ул,
Гыйнаяте гөлшанинен бадыдыр ул.

Ягъни ул сыйфатлар белән сыйфатланган хатын ахирәт йортының азыгы (задыдыр) һәм дә Аллаһның ярдәм җиле кебек (бадыдыр) рәхмәт гөле үзе. Кайбер

нөсхәләрдә гөлшәнинең ягыдыр... Ягъни изге хатын ахирәт дәрәҗәсенә васыйл булырга (ирешергә) сәбәп була.

Кара димә, кара хуш фигъле ху ни,
Никүдер ни кучә ни куни.

Ягъни кайчан да булса, хатын теләсәң, сурәтен күреп, кыздыр дип кызыкма, кара, бәлки аның күркәм холкына кара. Изге хатын шул була: олы һәм кече урамнарны күрмәгән булсын, ягъни өеннән яман фигыльләрне кылырга чыкмаган булсын, димәктер. *Никү* сүзе изге мәгънәсендә. *Ни кучә* нун (нун хәрефе) нафия (инкарь) өчен. *Кучә* дип кече урамга әйтерләр, куй сүзенең кечерәйтелгән варианты. *Ни куни* дигәне инкарь итү өчен. *Куй* дигәннәре олы урам була.

Ганимәт күр табылса холкы хуш күр,
Бәладер җанга маһе сохәне шүр.

Ягъни сиңа изге холыклы бер хатын табылса, байлык дип күр. Ләкин үзе сукыр (күр) булса да. Чөнки ачы сүзле (сохәне шүр) хатын, күркәм булса да, җанга бәла һәм каза китерер. *Күр* сүзенең әүвәлгесе боерык фигыль, төрки сүз. Икенчесе сукыр мәгънәсендә, фарсыча сүз. *Сохәне шүр* ачы телле мәгънәсендә була.

Акызыр аклыгын гәр килсә телгә,
Кызыл диб алмагыл бәдху кыз илгә.

Ягъни алган хатының синең белән сөйләшкән заманда даими аклыгын (күңел пакьлеген) күрсәтер булсын. Аннан морад: синең белән сөйләшкәндә күркәм һәм татлы сүзләрне күп кулланып сөйләшсен, димәктер. Һәм дә син кызыл йөзле, күркәм дип, явыз холыклы кызны алма. Шул сәбәпле югарыда бәяны килде. *Акызыр* сүзе ачыктыр (билгеле). *Кызыл* сүзенең әүвәлгесе төсләрдән бер төс була. Һәм икенчесе ачык мәгънәсендә...

Яман булса нәгузе биллаһи андан,
Зыяндан үзгә һич килмәс ямандан.

Ягъни алган хатының явыз булса, аның шомлыгыннан Аллаһ тарафына сыенырбыз. Андый хатыныннан явызлыктан башка нәрсә күрә алмассың.

Яман хатын шәйатыйн камчысыдыр,
Кулың баглагучы аргамчысыдыр.

Ягъни яман хатын шайтаннарның камчысы кебек, кулыңны Ходайга гыйбадәттә баглап, гөнаһыларга чумарсың. Әгәр, андый булса, андый яман хатынны талак кылу фарыз (тиеш була). *Аргамчы* сүзе чуму[1] мәгънәсендә, Кашгар сөйләме.

Ду (ике) галәм нары булса, нары китсен,
Күзең күрмәсен, шом дидары китсен.

Бу явыз хатын ике дөньяның тәмугъ уты (нары) булса, талак кыл, аның йөзен (дидарын) күзең күрмәсен, китсен, бетсен дип талак кыл. *Шом* явыз мәгънәсендә.

Әгәр ул китмәсә, сән кит алыб баш,
Күтәреб йөрмәгел тагдин агыр таш.

Ягъни ул явыз хатын үзе китмәсә, син үзең башыңны алып кит, чөнки үзеңә таудан авыр ташны йөкләмә, ягъни аның гөнаһын үзеңә йөкләмә.

Никү затига әйде бер никү ху... (яхшы холыклы),
Ирерсән бу әлгаҗәб монкад, әй шуй.

Ягъни берәү, бер изге холыклы кеше, бер изге (никү) дәүләтле хатынга әйтте: «Ни гаҗәпсең, иреңә буйсынучы син», — диде. Әйтәләр ки әйтүчесе Хәзрәте Фатыймага Хафиз бине Гомәр әйтте: «Син гаҗәп, иреңә буйсынучысың, һәрчак хезмәт кыласың. Асылда, бер сүзне хата әйтмәссең. Бәлки мин синең кебек ирләргә буйсынучыны күрмәдем», — диде. Фатыйма җавап биреп әйтте:

Диде касдем мең Тәңре ризасы,
Табар ул уртада ир мәддәгасы.

---

1 С.-П.да — чукмак (194 б.).

Ягъни Хәзрәте Фатыйма җавабында әйтте: «Минем хезмәт итүдән максатым: Тәңре ризалыгы өчен генә, шуның өчен иремә хезмәт кыламын, — диде. Ягъни иремә хезмәт итеп, аның ризалыгын тапсам, дөнья һәм ахирәт дәгъвасы (мәддәгасы) киселеп, бәндәм (ирем) хушнуд (риза) булса, Аллаһ Тәгалә шуның сәбәпле миннән риза булыр», — диде.

Ике тагать мөяссәрдер (җиңелдер) бер эшдә,
Ничек сынмай буен әмер әйләмешдә.

Ягъни Фатыйма әйтте: «Бу хезмәт итүдә бер эш белән ике буйсыну була. Берсе — Аллаһның ризалыгы табыладыр, икенче — иремнең шатлыгы буладыр, — диде. — Андый булса, ни өчен Аллаһ Тәгалә боерган урында буйсынмамын, чөнки хатыннарга ирләренә буйсынырга Хак Тәгалә боерып торыр».

## Шәехе камил эстәү һәм шәригатькә иярү хакында

Кил, әй суфый, өмид итсәң сафадин.
Карыш (каршы?) чыкма тарикы Мостафадин.

Ягъни кил, әй суфый булган кеше, Аллаһның рәхмәтеннән өмет итәр булсаң, пәйгамбәребезнең юлыннан чыкма. Пәйгамбәребезнең юлы бу бабда шул иде: мөршид әмереннән чыкмаслык. Син дә һәм мөршид (дини җитәкче, шәех) әмереннән чыкма, һәрвакыт камил мөршидне таләп итеп эзләнүдә бул.

Гамәл кыл, иттика кылма гамәлгә,
Тәвәккел әйлагел гыйзз-у җәллгә (Аллаһка).

Ягъни син пәйгамбәр юлында булсаң, гамәл кыл ихлас белән, гамәл кылганнан соң, гамәлгә таянма (иттика кылма) һәм аның күплегенә алданма. Гамәлеңне аз, үзеңне ким күреп, кылган гамәлнең кабуллыгын Аллаһ Тәгаләдән телә, тәвәккәл кыл (тапшырыл).

Гамәл кылмай сафа булмас күңелдә,
Аяксыз һич кеше йөрмәде юлда.

Ягъни мөҗәррәд (ялгыз) иман китерү белән Аллаһ ризалыгы табылмас, күңелләрдә сафалык булмас. Гамәл кыл, чөнки күңел сафланып, иманыңның нуры артыр, ахирәттә дәрәҗәң күп булыр, ничек аяксыз кеше юлда йөрергә көче җитмәгән кебек, гамәлсез Аллаһка якынлык табу мөмкин түгел.

Кайчан кулсыз кеше була шинавар (йөзүче),
Шинавәрмән дисә, һич кылма бавәр (ышанма).

Ягъни кайчан ки сиңа бер кулсыз кеше суда йөзәрмен дисә, аңа ышанма, чөнки кайчан кулы юк кеше суда йөзә алсын, ул ничек була?! Андый бер кеше гамәлсез Аллаһ Тәгаләгә якын вәсилә әйлармән (якынаермын) дисә, ялганчы булыр, игътикад әйламә (ышанма); шуның өчен Аллаһ Тәгалә гамәл кылырга боерды, боерганга хилаф әйламәк (каршы килү) лаек түгел. *Шинавәр* сүзе шиннең (шин хәрефенең) кәсре белән суда йөзү мәгънәсендә.

Салыбдыр раһе сөннәт раһе гамә,
Бу юлдан чыкмагыл үзгә мәкамә.

Ягъни тарикатькә (суфыйчылык юлына) сөеп бассаң, тарикате игътидалә (тарикатькә туры килешле) эшкә кереш. Тарики игътидал шул булыр: сөннәт юлында йөрү, гавамен-наска (кешеләргә) юл салу һәм күрсәтү, аны сәваде әгъзам (сөннәт әһеле) диерләр. Ул юлдан үзгә юлга (мәкамә) чыкма. Сөннәт әһеле һәм җәмәгать ни диделәр, һәм ни кылдылар, һәм ни игътикаддә (ышануда), һәм әгъмалдә (гамәлдә), һәм әфгалдә (фигыльдә) булдылар, — алар тарикынча бул, димәктер. Чөнки тәсауф әһеле (суфый) мин дигән гөруһлар (төркемнәр) унбиш, һәр ундүрте хаталы. Ләкин бер сәваде әгъзам башкача тора, аны тәсауфе сөннәт (сөнни дини юнәлеш) дип атыйлар. *Әүвәлгесе* —хоруфийун. Ул ике төрле: берсе — хоруфел-асла һәм икенчесе — хоруфе әнвагый. Хоруфел-асланы «мәзһәбе Рушани» диләр. Хоруфе әнвагыйны «мәзһәбе әүбаш» диләр. Боларның хәлләре югарыда бәян ителде. Бу ике мәзһәб заһирда (тышта) тәсауф әһеле булсалар да, кяферләр. Боларның каны һәм малы хәрби (сугыш) әһеле кебек иттифакы

голямаи (галимнәр киңәшүе) белән хәләл. *Икенчесе* — хәбибия. Алар бер кавеме тәсауф дәгъвасын кылырлар һәм әйтерләр, кайчан Аллаһ бер бәндәсен аеруча сөйсә, хитабате (сүзе) Аллаһ Тәгалә аннан канәгать, диерләр. Харам нәрсәләр аңа хәләл, диерләр. Болар да кяферләр һәм дә бу мәзһәби меллахед (динсезләр; икейөзлеләр), диерләр. Шул рәвешле назыйм (автор) рәһе кәрамәт (кәрамәт юлы) бабында зикер итте. *Өченчесе* — әүлия. Алар да тәсауф дәгъвасын кылырлар. Кайчан бер бәндә әүлия булса, ул кеше пәйгамбәрдән артыктыр, диерләр. Әмма зикерләрне җәһрия (кычкырып) әйтерләр һәм башка урыннарда шәригатькә муафикътыр. Болар да кяферләр. Бу ике мәзһәб Чин вә Мачин шәһәрләрендә (биредә, иң беренче чиратта, Шәркый Төркестан күздә тотыла) күп. *Дүртенчесе* — шәррахия. Алар да бер кавем. Мәҗлесләрендә барабан һәм дәф (шөлдер, бубен), гөслә белән кубыз чалырлар (уйнарлар), хатыннарын ул мәҗлестә башка кешегә җәмаг кылдырырлар (интим мөнәсәбәткә кертерләр). Һәм әйтерләр: оҗмах чәчәгедер, чәчәкне кунакка иснәтергә кирәк, дип. Болар да кяфер була, гарчә Коръән укысалар да. *Бишенчесе* — абахия. Алар да тәсауф дәгъвасын кылырлар һәм әйтерләр: без бер чылбырга бәйләнгән һәм бер шәҗәрәдә булсак, бер-беребезнең малы бер-беребезгә хәләл, сорау хәҗәт түгел, дип. Бәкяр (гыйффәтле) кызларны әүвәл кияүгә барганнан элек, шәехләренең куенына ябып, ул кызга кагылмаса, кияү алмас. Мондый мәзһәб Исфаһан һәм Караком шәһәрләрендә күп. Гарчә Аллаһны бер дип белеп, һәм пәйгамбәрне хак дисәләр дә, кяферләрдән санала. *Алтынчысы* — хәлалия. Алар тәсауф дәгъвасын кылалар һәм әйтерләр: зикер уку өчен, мөридләрен Ходага гашыйк кылыр өчен, танбур (тамбур — музыка коралы) хәләл, ягъни тамбурда уйнарга кирәк, дип. Аллаһ Тәгалә үзе дә уен авазын сөя. Һәм дә ул әмердә ни хәрәкәт һәм ни кәсеп итсә, өчтән берен шәехләренә фарыз, диерләр. Болар — әһеле бидгатьчеләр. Мондый мәзһәб Яркәндә, Әндиҗан һәм Кукан шәһәрләрендә күп. Һәм Болгарның тарафларында намәгълүм (билгеле булган) урыннарда бардыр. *Җиденчесе* — Холулийә. Алар да тәсауф (суфыйчылык) догасын кылырлар һәм әйтерләр: күркәм йөзле хатыннар һәм егетләр белән кочаклашып

күрешү хәләлдер, диерләр. Аңнан соң кулларын чабып, рәкъс әйләрләр (биерләр) һәм әйтерләр: болай кылу Аллаһ Тәгалә сыйфатларыннан бер сыйфат, диерләр. Заһирларында (тыштан) гарчә шәһадәтин (дингә ышанучан) булса да, болар да кяферләрдер. Мондый мәзһәб һинд шәһәрләрендә күп булыр. *Сигезенче* — хурийә. Алар холулийә мәзһәбе кебектер. Ләкин алар әйтерләр: безнең зикер мәҗлесебезгә хур кызлары килер, без һушсыз булырбыз, алар белән җәмаг әйлармезләр (интим мөнәсәбәткә керербез). Мәҗлесләреннән чыкканнан соң, госел коенырлар (юынырлар). Болар да әһле заләләт (азгыннардыр; ялгыш юлга керүчеләрдер), тәсауф дәгъвасын кылганлыкларына игътибар юк. *Тугызынчы* — вакфийә[1]. Алар да бер кавем: бер урынны билгеләп, мәчет кебек бина кылганнардыр, анда тәһарәт алып керерләр һәм биш вакыт намазны укырлар. Аннан соң, бер матур сурәтле кыз баланы күтәреп, михрабларына куярлар, дога кылырлар һәм барча кавемнәре, ул кыз бала йөзенә карап, «Ләә иләһа илләллаһу» дип кычкырырлар, һушсыз булырлар. Алар әһеле бидгать тә, заләләт тә (бозыклардыр). *Унынчы* — мөтәҗаһә. Алар да бер кавем: суфыйлары башларына чалма кимәс һәм безнең суфый булуыбызны һичкем белмәсен, дип әйтер. Кяферләр киемен киярләр. Болар да әһеле бидгать. Бу ике мәзһәб Дамган һәм Әстрәбад шәһәрләрендә. *Унберенче* — мөтәкасилә («ялкаулар»). Алар да тәсауф дәгъвасын кылырлар. Байларны тәсауфлары (суфыйлары) күрсә[2], теләнчелек кылыр һәм әйтерләр: фәкыйрь фәналык (онытылу; суфыйчылыкта камилләшү) юлы — шул, дип. Ул байның малын талап алырлар. Болар да әһеле бидгать. Мондый мәзһәб Бишбалигъ шәһәрендә[3] күп. *Уникенче* — илһамийә. Алар да бер кавем, тәсауф дәгъвасын кылырлар һәм әйтерләр: гыйлемлек өйрәнү вә «Коръән» уку кирәкми, дип, безгә мәгълүм бәетләр һәм хикмәтләр дә җитә, диерләр. Болар да заләләттер. *Унөченче* — софитан. Алар да тәсауф дәгъвасын кылырлар. Әмма хәкыйкыл-әшйаны (әйберләрнең хаклыгын) инкарь итәрләр. Болар да әһеле бидгатьтер... Болар мәзһәбе бу заманда

1 С.-П.да — вакшийәдер (198 б.).
2 К.да — байлары тәсауфларына керсә (137 б.).
3 С.-П.да — шәһәрләрендә(198 б.).

надирдер (сирәк күренеш). Әүвәл заманда Искәндәриядә күп иде. *Ундүртенче* — идгаййә (әдгаийә — «дога»ның күплек саны). Алар бер кавем: суфыйлык дәгъвасын кылырлар һәм әйтерләр: без бер нәсел чылбыры булып (ияреп, ялганып), камиллек таптык, диерләр.

Мал өчен шәехлек дәгъвасын кылырлар һәм дөнья зиннәтләренең әнваг (төрлесе) белән сыйфатланалар, сөйгәннәре байлар, калдыклары — фәкыйрьләр, телләрендә — ялган сүзләр һәм гайбәттән бизмәсләр һәм дә әйтерләр: мөршидләр бидгать эшне эшләсә һәм ялган сөйләсә дә, игътибар юк, чөнки ул мәеттер (исеректер), мөридләр хәлен тәҗрибә кылу өчен кыланырлар, диерләр. Болар да мәлахиде мәзһәбенә (динсезләр оешмасына) тугрыдыр, әһеле заляләтдер. Боларның кәшефенә (фикерләренә, серләренә) алданма. *Унбишенче* — сөнния, диерләр. Алар әһеле хактыр, ничек назыйм (автор), Аллаһ Тәгаләнең рәхмәте булсын (аны Аллаһ ярлыкасын), китабында язылган, башка китапларда да бар. Аны бәян иту хәҗәт түгел. Хәҗәт булса, китапларны кара. Әмма син тарикы игътидалә (түземлелек юлына) кереш һәм искә алынган мәзһәбләрдән саклан, димәктер. Әмма тәсауф сөннәтенең сыйфатлары бу бәетләрдә искә алынган.

Тәсауыф заилдән тәхәлли (Суфыйчылык бету белән татлы),
Сыйфаты мәрзыя берлә тәҗәлли (канәгатьлектә күренә).

Түгелдер[1] риза зөһде тәгаффеф (изгелек күрсәтү),
Хакыйкатьдә будыр гыйльме тәсауыф...

...Йазар татаре ханиядә мөфәссал (җентекләп),
Сәмагы вәгазь әхвала мөдәлләл (Вәгазь тыңлау хәлләрен дәлилләп).

Нәсыйхәт сүзә кыл бабе сәмагый,
Хилафе шәргы раһә улма сагый (Шәригатькә каршы юлда булма, тырыш)...

...Йаланчы мөриднек аһ-ваһы,
Утыз ел гайбәтдән чук гөнаһы...

---

1 С.-П.да — тәвәккәлдер (199 б.).

...Димеш «Йосыф-Зөләйха»сендә Җамый[1]:
Тарикать әһленең ул ник нами (изге исеме).

...Димеш мәрхүм Казыйзадә заһир,
Сәлах гыйльме галәмендә маһир (оста).

Сакын, санма йиймаз суфый суганны (Суфый суган ашамас дип уйлама),
Кабыгын куймаз һәм булса аны.

Димә тотдым фәлан бозорг (олы) эшне,
Куя күрмә нәбинең кылмышыны.

Ягъни кайчан син сөеп ияреп, тугры юлга аяк куйсаң, тәфахер әйләмәгел (кәперәймә, мактанма) һәм фәлән олы саваплы гамәлләрем бар дип әйтмә, бәлки эшләү теләгендә бул һәм пәйгамбәрнең һәр ни эшләгән фигыльләрен куйма.

Ушал пәйгамбәр ки сахибе һиммәтедер,
Рәсүле Аллаһның хасс (якын) өммәтедер.

Ягъни шундый олы кеше, аннан морад: шәех булган кеше тырышлык (һиммәт) иясе була һәм тамгъкяр (комсыз) булмый, андый кеше пәйгамбәрнең хасс өммәтеннән була. Кыскача әйткәндә, бидгать белән мәүсүф улмайан (сыйфатланмаган) шәех —Аллаһның олы рәсүленең өммәтедер, димәктер.

Пәйгамбәр кылгандин кылмагай таш,
Әгәр чәндикә булса күз белә каш.

Ягъни тырышлык куючы шәех шул була: гарчә ул эш күз белән каш арасы кебек (кыска, кечкенә) булса да, пәйгамбәребезнең кылган эшен башкаруны ташламас. Йомгаклап әйткәндә, сахибе һиммәт (һиммәт иясе) аз гөнаһлардан да сакланыр.

---

1 Биредә XV йөздә яшәгән һәм иҗат иткән фарсы шагыйре һәм фикер иясе Җами әсәре күздә тотыла.

Шәригать хөкмедин тышкы риязәт,
Имәс тагать, кабахәтдер, кабахәт.

Ягъни шәригать әмереннән тышка чыгып, мәшәкать чигеп, гыйбадәт кылуы, буйсынуы, ишануы түгел, бәлки кабәхәтлек, чөнки югарыда язылган мәзһәбләрне күрдең, аннан гыйбрәт ал.

## Гыйлемлек турында

Гамәл кылмак өчен керсәң бу юлда,
Кирәкдер шәмгы гыйлем, әлбәттә, кулда.

Ягъни син тарикать юлына кереп, гамәл кылырга теләсәң, әүвәл синә заруратә диния кадәре гыйлемлек (диннең зарурлыгын аңлар кадәрле белем) кирәк, ул фарыз (тиеш). Чөнки гыйлемлек чырагы (шәме) кулда булмаса, тарикать караңгылыгыннан котылу[1] мөмкин түгел...

Караңгуда кадәм куйсаң йазарсән,
Әгәр күз булмаса, юлдин азарсән.

Ягъни, чөнки берәү караңгы кич белән юл йөрсә, хата кидәр (ялгыш юлга китәр), күзе юк кеше юлга барса — азар. Андый наданлык белән тарикать сайласа, азар юлдан чыгып, әһеле җәһдан[2] булыр, ахырында зиндикъ (динсез) булып дөньядан үтәр. Нәгузе биллаһи (Аллаһ сакласын!), шулай булгач, бу гыйлемлек шикле урыннардан мөридне, мөршидне чыгарыр, шул әҗәлдән туры юлга васыйл булырга (кавышырга, керешергә) гыйлемлек сәбәп булыр.

## Хуҗа Бәһаэддиннең[3] ике мөриденең хикәяте

Хикәядә киләдер, ике кеше Бәһаэддин хәзрәтләренә кереп, күп вакыт хезмәт иттеләр, әдәбе тарикать (дин әдәбен) өйрәнделәр. Берсе гаять надан иде. Әлкыйсса, бу надан мөрид мәкаме әүлиянең (изгелекнең) алты дәрәҗәсен тапты. Берсе галим иде, гыйлеме әүвәлге дәрәҗәдән артмады. Көннәрдән бер көн Бәһаэддин

1 К.да — котылмак (139 б.).
2 С.-П.да — җәһдан (201 б.).
3 Хуҗа Бәһаэддин Нәкышбәнди (XIV йөз) — “Нәкышбәндия” тарикатенә (дини юнәлешенә) нигез салучы атаклы суфый.



www.darul-kutub.com

хәзрәтләре хатыны Бибихәлимә белән бер сүз турысында бәхәскә керделәр. Ул сүзләре бу иде. Хатыны әйтә иде: гыйлемле (белемле) кеше ике дөньяның хубы (яхшысы) һәм зирәге, ди, иде. Һәм дә Аллаһ Тәгалә янында якын кеше, ди, иде. Бәһаэддин хәзрәтләре әйтер иде: юк, андый түгел, ихласлы надан галидән артык диеп. Күрмисеңме бу ике мөриднең хәлен, ди, иде. Әлкыйсса, бу ике газиз бу сүз белән күп бәхәсләр кылдылар. Хатыны әйтте: «Әмер булырмы, бу ике мөридне тәҗрибә итәм», — диде. Хуҗа Бәһаэддин хәзрәтләре боерды. Бу хәл кич җиткәч булды. Төн уртасында бу хатын Хуҗа яныннан чыкты, ул мөридләрнең хәлвәте мәкаменә (торган җиренә; ял урынына) килде. Әүвәл надан мөриднең ханәкасенә (йортына; гыйбадәт өенә) барды, эчкә керде, сәлам бирде.

Надан мөрид әйтте: «Син кем соң?» Хатын әйтте: «Мин Җәбраил, сиңа вәхи (хәбәр) китердем, инде пәйгамбәр булдың», — диде. Ул надан ахмак алданып калды. Аннан чыгып, галим мөриднең ханәкасенә керде, сәлам бирде. Мөрид: «Син кем соң?» — диде. Хатын әйтте: «Мин Җәбраил, сиңа вәхи китердем», — диде. Шуннан соң, ул галим аятьне укыды... Кылыч алды. «Пәйгамбәрдән соң Җәбраил һичбер кешегә иңмәс, сөйләшмәс, син шайтансың», — дип, кылыч белән орырга теләде. Хатын качып тышка чыкты, мөрид аны куа чыкты. Анда мөридкә Хуҗа Бәһаэддин очрады: «Йә мөрид, ул минем хатынымдыр, кума, сезне тәҗрибә кылыр өчен җибәргән идек», — диде. Ахырда ул надан мөрид хәленнән язып һәлак булды, бу галим мөриднең мәртәбәсе артып камиллек тапты.

***

Ирер чөнки гаҗаиб нөр хәтаре раһ,
Кадәм куйсан, анын астыдадыр чаһ.

Ягъни бу тарикать юлы (раһ) гаҗәп тулы хәтәрле юл: аяк (кадәм) куйсаң, аяк астына коелары (чокырлары, чаһ) күп. Әмма ул хәтәрләрне бәян итү мөмкин булмас, кайберсе кальбидер (күңелдә) һәм кайберсе хисси, — барын зикер итү һәм китапта язу белән сүз озын булыр, чөнки белеме булмаган тарикатькә кергән кешеләр юлның бозыгын һәм төзеклеген аермаслар...

www.darul-kutub.com

Төзек юл диб каләм үтрү салырсән,
Козукга төшкәнең тоймай калырсән.

Ягъни син гыйлемлек (белемең) булмыйча, бер юлны күрерсең, бу юл төзек имеш диеп тырышып аяк куярсың, бинагяһ (кинәт) коега төшеп һәлак булганыңны тоймый калырсың, ягьни мәзкүр (югарыда телгә алынган) ундүрт юлның беренә кереп, җәһәннәм коесына төшкәнең белмәссең. Беленде шул: гыйлемлек олы корал булды.

Күзең күр булмаса, әй гаклы хуш йар,
Гаса кешесез кадәм һич куйма, зинһар.

Ягъни күзең булмаса, әй хуш (яхшы) акыллы карындаш булган яр, таяк (гаса) белән җитәкче булмаса, аягыңны юлга куйма, зинһар. Аннан морад; гыйлемлексез тарикать юлына әкъдам (тырышлык) кылма. Сорау: гыйлемлекнең ноугы (төрләре) бик күп, аның барысын өйрәнү бәндәләргә мөмкин түгел. Андый булса, гыйлемлек өйрәнү белән өйрәнә торгач, әҗәл җитсә, тарикатькә керүдән мәхрүм калыр. Шулай итеп, гыйлемлекнең чиге һәм күләме ни микъдар булыр, дигән кешегә җавап биреп боерды:

Әгәр галим сүзең хуб тотса гамил,
Аны гами димәде мәрде камил.

Ягъни тәмам, барлык булган гыйлемлек тупламын белү фарыз түгел, чөнки гамәл кылучы галимнәр сүзен теләп тотса, алар әйткән сүзне мең җан белән кабул итсә, рәсүле әкрам аны надан (гами) дип әйтмәде, бәлки камил ир дип мәдех кылды (мактады).

Диннең бихедер (тамырыдыр) — гыйльме гакаид,
Тамырсыз шахә су бирмәк нәфаид?!

Ягъни ислам диненең тамыры — гакаид гыйлеме, Аллаһның затийә вә сөбутия (заты һәм барлыгы) һәм сәлбийә (төкәнмәс) сыйфатлары белән аны **нәлаек** (лаек булмаган) сыйфатлардан мөнәззәһ әйлар (чистартыр). Чөнки назыйме китап (китап авторы) әүвәлендә

www.darulkutub.com

искә алды; шул назымча беләләр. Чөнки гакаид белми тарикатькә керүнең мисалы шундый була: тамыры юк ботакны, үссен дип, су белән сугаруга охшаган. Чөнки аңа су бирү заигь (файдасыз) иде. Андый гакаиде сөннияне белми тарикатькә омтылу файдасыздыр, гарчә мең ел гамәл кылса да — барчасы һәбадыр (бушка була). *Бил* тамыр мәгънәсендә. *Шах* ботак мәгънәсендә, һәр икесе фарсыча.

Улдыр җаһил: белеб мөршид үзене
Колакга алмагай галим сүзене.

Ягъни надан шул: үзен үзе мөршид дип белеп, галимнәр сүзен колакка алмас, галимнәрне дошман тотар, үзенең белгән нәрсәләре белән барыр, асылга игътибар итмәс.

Бу мөхкәм (нык) төб шәҗәрнең шахы әгъмал,
Либасы (киеме) тәкъва булды, мивәсе халь.

Ягъни аннан морад иман: бу нык (мөхкәм) төпле агачның, ботагы әгъмале салихтыр (изге гамәлләр) һәм киеме харамнардан һәм шөбһәләрдән саклану һәм җимеше — гыйльме хәлдер. Гыйльме хәлдән морад: гыйльме тәсауф булыр. Камил мөршиднең тәрбиясендә булып, хәл кылып һәм хәле әгъмал җәвар эчәдер (күрше, янәшә). Әмма камил мөршидне назыйм (автор), бәян итеп, югарыда искә алды. Әмма андый мөршиднең табылуы — бик зур дәрәҗә инде.

Гаҗаиб асыл ки, фәргу фис-сәмадыр,
Чыкарыр Һади галәме рәһнамадер.

Ягъни ул иман гаҗәп бер тамыр кебек: аның ботагы күктә, ягъни иман китерү — гамәлләр кылып, тарик әһеленә иярү белән Хак җанәбенә (тарафына) тартылуда. Ул тартылуны чыгаручы, юл күрсәтүче һәм күндерүче мөршид — галим була. Бәс (шулай итеп), мәгълүм булды: мөршидсез Аллаһны табу мөмкин түгел.

Бедүн гыйлем аңа куйсаң әгәр пай,
Таеб китсәң, сәнең әхвалеңә вай.

Ягъни гыйлемлектән башка (бедүн) ул тарикатькә аяк куйсаң, аякны куйганнан соң таеп егылсаң, синең хәлләрең хәсрәт, үкенеч. Нәтиҗәдә, гыйлемлек бу тарикадә аләтләрнең (тарикать коралларының) олысы.

Илеккә дамәне һадийе гыйлем ал,
Чыкыб шайад йигәйсән мивәи халь.

Ягъни кулыңа (илеккә) күндерүче мөршид галимнең (һадийе гыйлем) итәген (дамән) тот, күккә гыйльме хәл җимешен (мивәи халь) җый (аша)...

Гаҗәбдер йирдәке торган гамага,
Озатыр илкен әсмаре сәмага.

Ягъни җирдә торган сукыр кулын сузып, күктәге җимешне taлән итүе гаҗәп, ягъни надaнлык белән тарикатькә керeп, тәҗлийәт (хөрмәт) һәм көшүфать (ачышлар ясау) мәкамен (урынын) табып, Аллаһ Тәгалә якын булуны эстәр. Яхуд тәэвил (аңлату) шул булыр: гаҗәптер җирдәге сукыр. Аннан морад: берәү тәҗлийәт һәм көшүфать мәкаменә җиткән дә, күктәге җимешне алырга кул суза. Аннан морад: күктәге гаҗәпләрне белеп тора, гарчә, үзе ачык күзе белән күрмәгән булса да. Бәс, бу ике тәэвилгә (аңлатмага) гаҗәп мәдехдер (мактаудыр)...

Зәгыйфи исә би фәкыйһ зарури
Мөйәссәрдер аңа тагате сөрури (сәрвәри).

Ягъни бер зәгыйфь акыллы бәндә бәхәс кылып әйтсә, гыйльмел-фикъһене (хокук гыйлемен, шәригать кануннарын) белмәгән кешеләргә һәм ...дингә мохтаҗ булган гыйлемлекләр бар, аны белмәгән кешеләргә тәгать вә гыйбадәт белән, шаять, Хак Тәгалә хәзрәтен табу сәһелдер (җиңелдер) дигән кешегә җавап бирeп боерды.

Укый белмәсә заһир ләфзы «Коръән»,
Ничек мәгънәсене белгәй ул инсан!?

Ягъни бер надан «Коръән»нең сүзләрен (ләфызларын) һәм әдаи хоруфларыны (хәрефләренең әйтелешен)

www.darulkutub.com

белмәсә, чагыштыр ки: ул кеше «Коръән»нең мәгънәсен белеп, аның белән гамәл кылып, тарикатькә керешеп, һәлакәт вәртасыннан (упкынынннан, куркынычыннан) үзен үзе ничек коткарыр?! Бу заһирдыр (билгеледер). Андый надан мөршид кайчан халыкларны тугры юлга күндерер?! Бу бәет тәҗвид гыйлменең вәҗиблыгына (кирәклегенә) ишарәт итте.

Әгәр мәгъзен алыбдыр мәрде заһир.
Ничек калды күренмәй кашре заһир.

Ягъни берәү «Коръән»нең җелеген белсә, ничек аның ачык кабыгы (кашре) күренми калсын?! Әлбәттә, күренсә кирәк. Кыскасы, берәү «Коръән»нең мәгънәләрен белсә, хакыйкать белән мәҗазны (кинаяне) аңласа, андый галим кешегә ничек «Коръән»нең ачыклыгы беленми калсын, ягъни калмастыр. Бу бәет һәм гыйльме нәхү, һәм гыйльме бәян, һәм гыйльме мәганнең вәҗибенә ишарәттер, чөнки алар булмыйча, «Коръән»нең хакыйкатен аңлап булмас, чөнки болар аләтдер (корал).

Ирер дин гыйлеме чөн зәрдалу, әй дуст,
Мөләззәздер (татлыдыр) аның һәм мәгъзе һәм пуст.

Шулай булгач, дин гыйлемлекләре — фикъһе. Аны белгән кешенең мисалы шундый: өрек җимешен (зәрдалу) кулга алу кебек. Чөнки аның җелеге (мәгъзе) һәм кабыгы (пуст) ләззәтле. Андый камил мөршид фикъһе белән мәүсүф булып, «Коръән»нең хакыйкатен аңласа, андый мөршиднең заһиры һәм батыйны (тышы һәм эче) мөридләргә файдалы. *Зәрдалу* (зөрдалу) занын (за хәрефенең) заммәсе белән раның (ра хәрефенең) сөкүне белән бер җимеш. Кубан йортында күп булыр, йодрыктан кечерәк, Төрекмән халкы өрек диләр. Болгарда андый җимешләр юк. Әмма өрекнең кабыгын ашарлар, һәм эчендәге чикләвеген ярырлар, һәм анда төше бар, гаять ләззәтле...

Борадәрләр, будыр бу колның гарызы,
Вәли булгаймы кылган тәрк фарызы.

Ягъни әй мәҗлестә хазыйр булучы (катнашучы) карындашлар (борадәрләр), бу Аллайарның югарыда әйткән мәкальләрендә максуд (теләк) шул булыр: фарызлардан бер фарызны куйса, берәү мөршид булырмы? Чөнки андый надан мөршид булуы тәрке фарыздыр (фарызны туктату), чөнки гыйлемлек өйрәнү һәр мөселманга фарыз инде. Шуннан чыгып, андый фарызны куючы тәхкыйкан (чынлыкта) мөршид түгел, һаман һәрәзгуй (буш сүзле) мәрддер (кеше), үзен саклый алмаган ахмак. Кайда булды ди, мөридләрне һәлакәт хәленнән, (баскычыннан) чыгару?! Чынлыкта, һәр икесе һәлак була.

Бу тәрк үзрә булыр тәрке фәраиз,
Ничек булгай вәли тыңла (? таңла) гараиз.

Ягъни бу гыйльме фикъһене өйрәнми куюы (калдыруы) тәрке фәраиздыр (фарызны туктату). Шулай булгач, ничек ул әүлия һәм мөршид булып, халыкны туры юлга күндерер. Тыңла һәм ишет бу максудларны. Кыскасы, гыйльме фикъһене белмәсә, барча фарызларны куйганлыгына ишарәт була.

Әгәр ул белмәсә гыйльме гакаид,
Булыр ул әкбәре асамә гаид.

Ягъни ул мөршид булган кеше гыйльме гакаид (дини ышануларны) белмәсә, олуг гөнаһлы булып, көферлеккә кайтыр. Шуннан мәгълүм булды: Болгарның нәһре Сөн (Сөн елгасы) дигән тәвабигында (төбәгендә, тирәләрендә) бер җәмәгать бар, мөршидләре надан, зарурияте динияне белми, аның мөридләренә ни үкенеч.

Аның дик тәлбәи кәсдән, әй никү зат,
Вәли белмә, әгәр күрсәң көшүфать.

Ягъни андый мөршид дәгьвасын кылган ахмактан (тәлбәи кәсдән) кач, әй изге (никү) дәүләтле кеше, андый әүлияне мөршид итмә, әгәр аларда кәрамәт (могҗиза) һәм хәварык (гадәттән тыш) гадәтләр күренсә дә, әүлия түгел, бәлки мәлгунәттер (Аллаһтан куылган зат)...

...Йомыб күз уйкуда күргән белән кәс,
Вәли белмәс аны мәрде сөхән рәс.

Ягъни андый надан шәех мөракабийә варыб (экстазга бирелеп), күзен йомып йоклап, күргән нәрсәләрне һәм, анда күреп, хәбәрләр бирүе белән вәли мөршид дип белмәсләр; сүзнең хакыйкатенә ирешкән кешене мөршид дип белерләр. Ягъни, агяһ (сак, игътибарлы) бул, әүлияләрнең, бер кагыйдәсе (гадәттә, кагыйдә буларак), мәшһүрләре бардыр, кайчан аларга бер әмре газыйм (Аллаһ әмере) булса яки мөридләр хәлен аңларга теләсәләр, Хак Тәгалә хәзрәтенә тәүбә итәрләр, башны түбән салып, күзләрен йомып, бер хәйли (озак) заман торырлар. Анда Аллаһ Тәгалә хәзрәтләре аларга хәлләр мәгълүм кылыр, көшүфать вә тәҗәллийәт (балкыш, нур) хасыйл булыр. Аннан соң хәбәр бирерләр. Мондый хәлне бер надан мөршид сиңа хәбәр итеп бирсә, аны әүлия дип әйтмә. Әй Газизә, аңла, мондый эш вәҗибе моракабийә (тиешле экстазга) бару дигәннәре югарыда искә алынды. Үндүрт мәзһәбтә дә булса кирәк. Ләкин син андый эшләрдә алданма, бәлки сиңа назыйм (автор) боерды мөршидләр бәянында, аны аңлап, мөтәшәрригь (шәригатьне белүче) галим булган шәехкә әкъдам әйлә (ияр).

Бу күрмәкдән үзен белсә зиадә,
Дигел: аттин төшеб булды пиадә (җәяүле).

Ягъни ул моракабийә вардыкы мән (экстазга бирелгән кеше) анда күргән гаҗәп һәм гараибларны (искитмәле нәрсәләрне) артык күреп, тәкәбберлек кылса, андагы хәлләрне һәркемгә сөйләсә, тәхкыйк ит (дөреслектә), аттан төшеп җәяүле булды, ягъни мәртәбәсеннән төшеп мәрдүд булды (кире кагылды).

Борынгы халедин кылды тәнәззел (түбән төште),
Төшәр сәркәштә (буйсынмас) колның башига гол.

Ягъни ул моракабийә вардыкы кеше әүвәлге мәртәбәсеннән һәм хәленнән төште, шайтан һәм җенләр гөруһыннан (төркеменнән) булды һәм әһеле кибрдән (динсездән) булды. Андый сәркәш колның

муенына богау һәм чылбыр (гол) төшеп, тәмугта булыр диләктер.

Әгәрчә күб булса пәнһане сөҗүди (яшерен гыйбадәт),
Күренмәс зәррәчә гариф вөҗүди.

Ягъни ул мөракабәдә күргәне өчен, Аллаһ каршында кылган гамәле никадәр күп булса да, гариф (акыл иясе; югары дәрәҗәгә ирешкән зат) булуының әсәре һәм барлыгы (вөҗүде) зәррә (бөртек) кадәр дә күренмәс.

Ризаи Хәкъ аның максуды булса,
Хәйа вә гыйльме хилем, җуди булса.

Ягъни ул мөршид булганга, Аллаһ ризалыгы булса, оятлы (хәйа) һәм галим һәм юмарт (җуди) булса...

Аның ихласы коллык булса вә, бәс,
Риядан булмаса күңелендә бер хәс.

Ягъни ул мөршид булган кешенең даими гыйбадәт кылуы ихлас үзенә булса, башкача булмаса, һәм дә рия һәм гоҗбдән (тәкәбберлектән), бер чүп кадәре әхлакы зәммәләрдән (әхлаксызлыктан) булмаса, хакыйкатьтә мөршид шул булыр. Бу сәбил (юл) үзгә булыр. Мөбгәданең (иянең) хәбәре мәхзуфдер (төшерелгән). *Хәс* сүзенең (ха хәрефе) фәтхе белән килгәндә чүп-чар мәгънәсендә, фарсыча.

Җәмигъ эшләрен салса Ходага,
Кулын табшырса ул Һади ризага.

Ул мөршид булган кеше барча (җәмигъ) эшләрен һәм гамәлләрен Ходага салса, һәм дә күндерүче шәехнең үзенә кулын тапшырса, ягъни камил мөршид үзенә, кул бирер тәрбияләгән булса, аннан камиллек табып рөхсәт алган булса, һәм дә дүрт силсиләнең (биредә суфый мәзһәбләре күздә тотыла) берсенә муафыйк булса, диләктер.



www.darulkutub.com

## Хикәяте шәех Хәсән Басрый[1]

Имам әһле сөннәт шәех Басрый,—
Өмид улдыр ки, җәннәт булса касрый.

Ягъни сөннәт һәм җәмәгать имамы Хәсән Басрыйдан өмет шул була, оҗмахның сарае (касре) булу, һәм дә табигыйннарның (сәхабәләрне күрүчеләрнең) олысы иде, гыйльме тәсауфда әкътаб («котб»ның күплеге, ягъни югары дәрәҗәгә ирешкән зат) иде.

Аның бар ирде бер гами (надан) мөриде,
Вәләкин тәндә ирде кәшфе диде.

Ягъни хикәятләрдә килә: Хәсән Басрыйның бер надан мөриде бар иде. Надан булса да, бераз кәрамәт (могҗиза) әсәре бар иде. Әйтәләр: ул мөриднең исеме Габдулла атлы иде. Һәм кайберләр әйтәләр: Гали атлы иде. Ул мөрид даими Хәсән Басрыйда торып хезмәт итеп, әдәбе тарикать өйрәнер иде.

Мөриде килмәде берничә әййам (көн).
Үзе табды аны ул Шәехелислам.

Ягъни ул мөрид берничә көн шәех мәҗлесенә килмәде. Ахырда шәех Хәсән Басрый хәзрәтләре аны үзе эзләп тапты.

Диде, ул гамине кылмак өчен ал:
Мәңа әсрарын әйгыл (әйткел), әй никү халь.

Ягъни Хәсән Басрый хәзрәтләре ул наданны хәйлә белән юлга салу өчен әйтте: әй изге хәлле кеше, ни өчен мәҗлесебезгә килмәс булдыгыз, сәбәбегез, шаять, Аллаһка якынлык тапкансыз. Андый булса, без гарипләрне артка күрмичә, бераз көшүфать (могҗиза) серләреннән әйтсәң ни гаҗәп, хөсн (күркәм) булыр иде. Ләфзы *ал* хәйлә мәгънәсендә, төрки сүз.

Диде: һәргаһ ки Хәкътан килсә каршы,
Йитәрмен ләхзадә әйване гарше.

---

1 Хәсән Басрый (642-728) — күренекле рухани, дин белгече. Ул үз гомеренең зур өлешен Басрада уздыра, шунда ук вафат та була.



www.darul-kutub.com

Ягъни ул надан мөрид шәех Хәсән хәзрәтләренә җавап бирде: «Йә хәзрәт, минем башыма гаҗәп серләр очрады (килде, төште) чөнки ясыйга намазының вакыты килсә, бер сулуда (ләхзадә) гарше рәхмәнгә барырмын», — диде.

Мәлаикдән булыб гарше эчрә мөмтаз,
Хода берлән озын шәб (кич) идарәм раз.

Ягъни әйтте: «Гаршегә барып, фәрештәләр җөмләсеннән булып, Хак Тәгаләнең үзе белән кичәләрдә серләшеп чыгармын», — диде. Шәех Хәсән бу сүзне ишетеп җавап әйтте ки:

Диде: «Барсаң ушал мәнзилгә, чөн бад,
Бу мескен атыны һәм айлагел йад.

Ягъни әйтте: «Әй фәлән, әгәр син ул гаршегә дәхи җил кебек (чөн бад) барыр булсаң, бу мескен Хәсәнне дә искә ал, ягъни, йә Хәсән, дип минем исемемне ул урында искә төшер», — диде.

Йәнә кичкә ул мәнзилгә йитте,
Хәсән атын телигә җари итте.

Ягъни янә бер кичә ул мөрид гарше дигән урынга җитте, филхалъ (шунда ук; бик тиз) Хәсән Басрыйның исемен телендә йөртте.

Бозылган күрде гарше дилкешәсен,
Нэҗасәт ханәсендә күрде җасен.

Ягъни ул мөриднең күңелендә ачык булып күргән урында Хәсән дип искә төшергәч, үзен тәһарәтханәдә күрде.

Йакыйн белде моны: шәйтан кылыб кәйд,
Кылыр иркән аны һәр кичәсе сайд.

Ягъни ул мөрид бу хәлне күргәч, шиксез, белде ки, бу эшне шайтан эшли, аны хәйлә белән аулап, кулына төшерә. Бу мөридкә мондый хәлнең булуы гыйлемлеге юклыгыннан булды.

Инабәт кылды барыб, кайта башдин,
Мияссәр итде гыйлем атлигъ кояшдин.

Ягъни ул мөрид, кире кайтып, шәех Хәсән Басрый мәҗлесенә барды, зикерен әүвәлге тәлкыйннан башлап, гыйльме фикъһене эстәмәгә шоруг әйдаде (башлады). Бәгъдәзан (бераздан) Аллаһ Тәгалә аңа гыйлемлек кояшын сәһел әйладе (җиңел бирде), кире мәкамына (өйрәнгән урынына) җитеп, камиллек тапты.

Бозар батыйлны төз галимнең аты,
Фәкәйфә, ул йирдә булса заты.

Шулай итеп, бозык эшне изге галимнәрнең исеме бозар, харап итәр, чөнки Хәсән Басрый хәзрәтенең исеме бозды; чөнки була иде (фәкәйфә), әгәр ул җирдә заты булса һәм дә күрмисеңме, шәех Вәйсел-Карани[1] хәзрәтенең таягы шайтан ләгыйньне качырган кебек.

## Вәйсел-Карани таягы хикәяте

Әйтәләр: Фәхерразu хәзрәтләре Хак Тәгаләнең берлегенә, барлыгына, яшәешенә мең төрле акыллы дәлилләр (фикри дәлилләр) тәхриҗ әйладе (нәтиҗәләр китерде, ясады). Вакытлар үтү белән, аңа, әҗәл җамыны (савытын) бирү өчен, Газраил килде. Шул вакытта Иблис ләгыйнь килде: «Йә Фәхерразu, санигы галәмнең (галәмне барлыкка китерүченең, ягъни Аллаһның) вөҗүденә әдәлләли гаклия әйламешсән (барлыгына акыллы дәлилләреңне расла), һөнәреңне күрсәт», — диде. Шул чак бәхәс кылу ниятендә булдылар. Фәхерразu һәр төрле акыллы дәлилләрне китереп күрсәтте, мең дәлилләр тәмам булгач, Иблис ләгыйнь һәрбер дәлилгә мең төрле җавап бирде. Санигы галәмне[1] (галәмне барлыкка китерүчене) кире какты. Фәхерразu хәзрәтләре гаҗизлыкта (мескенлектә) калып, шул вакыт улына әйтте: «Тиз бар, Вәисне алып кил, аның Аллаһ катында абруе (дәрәҗәсе) бездән артыктыр». Бәс, улы Вәйс катына килде, кыйссаны баштан сөйләп бирде. Вәйс

1 Вәйсел-Карани — Мөхәммәд пәйгамбәрнең чордашы. Исеме легенда-риваятьләргә кергән шәхес. Аның Ямәндә көтү көтүе мәгълүм.
2 С.-П.да — нәфигъ (210 б.).



www.darulkutub.com

җаваб итеп: «Өемдә эшләрем бардыр. Әмма таягымны алып бар, иншаэ Аллаһ Тәгалә, шайтанны куып җибәрер», — диде. Бераздан, шуннан соң Фәхерразиның улы, таякны алып кайтып, өйнең ишеген ачты. Шайтан ләгыйнь көл булып, Фәхерразиның катыннан юк булды (юкка чыкты). Кыскасы, Фәхеррази күзен ачып, таякны кочып, Аллаһтан сөрелгәнне исбат итеп, дәлилләренең файдасын күреп дөньядан үтте, диләр.

Аригы гыйльме гамәлдер — рәһбәри халь,
Бу ике пал[1] илән очкан эчәр бал.

Ягъни изге гыйлемлек — аннан морад — гыйлемлек белән гамәл кылу һәм дә хәле гыйлемне хасыйл итү, бу ике канат белән очкан кеше, әлбәттә, Аллаһны табу ләззәтен татыса кирәк. *Пал* пай фарсы белән (фарсыдагы па хәрефе белән) канәгать мәгънәсендә. *Бал* баи гарәпчә белән гасәл (бал) мәгънәсендә, төрки сүз.

## Гакылны эшкә боеру, тәкәбберлек...бәяны

Кил, әй гакыйл, боерсаң гаклың эшкә,
Үзеңдән китмәгел дана димешкә.

Ягъни, әй акыл ияse кеше, акылыңны тәгать һәм гыйбадәт эшләренә боерсаң, үзеңне үзең «мин белемле һәм мин галим» дип тәкәбберлек кылма һәм югары күтәрмә.

Әгәр бала (югары) чыкыб китсәң узеңдән,
Екылгайсән таеб йиргә йөзеңдәй.

Ягъни үзен-үзе югары тотып, кибер (зур, тәкәббер) булудан күпмеләр тезләр-аякларыннан егылып, мәртәбәләреннән төштеләр, чөнки Иблис белән Һарут һәм Марут, һәм шәех Габдеррәзак, вә...Багури, вә шәех Бәрсыйса[2] кебекләр тәкәбберлек кылып, хәлләре ничек булды, хикәятләре мәшһүр бит.

---

1 К.да –үткенләр (146 б.).

2 Һарут, Марут, Бәрсыйса h.б. Мәхмүд Болгариның "Нәһҗел-фәрадис" әсәрендәге (1358) хикәятләрдә дә гәүдәләнеш тапканнар.

Әгәрчә һәр кичә диле мәхзәниенә (күңел хәзинәсенә),
Бакырсән күб торыб күбтермәсенә.

Ягъни син, камиллек табып, һәр кичәдә моталигъ (хәбәрдар) булсаң, мөракабәдә мөкашәфать (ачышлар) һәм мөшаһәдать (дәлилләр) күренеп, күңел хәзинәләре»ннән хәбәрдар булсаң да, үзеңне үзең олы күрмә, бәлки һәрчак үзеңне ким дип бел...

Әгәр чәндикә булсаң котбе әбрар
Дигел: ни данешем (белемем) бар, ни эшем бар.

Ягъни әгәр чынлыкта син изгеләрнең башчысы (котбе әбрар) булсаң да, әйт: "Ни белемем, ни эшем бар...» *Котб* монда башчы мәгънәсендә...

Ниһале михнәтең бирсен дисәң бәр (җимеш),
Ризаи Хәкъ өчем гыйлем ит мөяссәр.

Ягъни михнәт[1] (мәхәббәт) агачы сиңа җимеш бирсен дисәң, Аллаһ ризалыгы өчен гыйлемлекне эстә, аны халыкка сарыф итүне җиңеләйт. Кыскасы, әһле сөлүк (суфый) булып, күп мәшәкатьләргә очрап, Аллаһ Тәгаләгә якын булырга теләсәң, элек гыйльме фикхны өйрәнү кирәк. *Ниһал* дигәннәре бер кечкенә агач булыр, зур агачлар төбендә үсәр. Моннан соң аны тамыры белән суырып алып, базарларда сатарлар. Аны агачка ялгап үстереп, җимешен җыярлар. Болгар йортындагы алма агачы кебек. Монда мотлак агач тотылды (ягьни гомумән агач күздә тотылды), Ниһалны михнәткә изафә кылынуы истигарәдер (метафора булып килде).

Әгәр ягыңда булса кил риясы,
Кайчан булгай чырагның зыясы.

Ягъни синең гамәлләреңдә (ягыңда) рия туфрагыннан (кил) бераз булса, кайчан гамәл чырагың яктырып, Аллаһның нуры һәм иләһи серләр хасыйл булыр. Гамәл ягыннан морад: кылган гамәлләрең. *Кил* сүзе кәсрә кәф белән балчык мәгънәсендә килә.

---

1 К.да — мәхәббәт (146 б.).

Әгәр хали риядин хали ирмәс,
Хакыйкать ул кешенең хали ирмәс.

Ягъни бер гыйльме хәл белән мәүсуф булган (сыйфатланган) кеше риядан хали (саф, азат) була алмаса, хакыйкатьтә серләрне белү ул кешенең хәленнән килмәс. *Хали* сүзенең әүвәлгесе Кашгар сөйләменчә йөздә ике меңне әйтерләр. Әмма монда хәл әһеле тәсауфка истигарә (метафора) булды... Икенчесе хәлвәттән (ялгызлыктан) ясалган, гарәпчә сүз. Өченчесе — куәт мәгънәсендә килә...

Укыр булсаң укы нәфсең күзенә,
Кара чын күз белә мосхәф (Коръән) йөзенә.

Ягъни син Коръән дәресен укыр булсаң, элек үз нәфесеңне өшкер, аны гөнаһ зәхмәтеннән дарула. Андый булмасаң, ягъни укыган Коръән һәм дәрестән үгет-нәсыйхәт алмасаң, һаман бер кара чебен кебек булырсың. Син, чебен күк, Коръән йөзенә кунып торган кебек була, ягъни әүвәл үзеңне юлга күндер, аннан соң адәмнәрне күндерерсең.

Мөхәкъкыйк (чын) галим улдыр, галим[1] улса,
Нә күб җадәл йөкертеб җадәл улса.

Ягъни галиме мөхәкъкыйк (тикшерүче) шул, белгән гыйлеме белән гамәл кылучы бул, башкаларга өйрәтүче бул. Мөхәкъкыйк андый галим галим түгелдер: күп урыннарда бәхәс кылып, башкаларны әлзам вә молзам әйлия (мәҗбүр итеп) мәсхәрә итүче. Бу эшләр мәнһидер (тыелган), харам. Мәгәр ачыктан-ачык Хак өчен булса, маэҗүр («урынлы») диләр. *Җадәл* сүзенең элеккесе җай сүзеннән мәкъсурдыр (кыскарган). Икенчесе мөҗадәлә (бәхәс) мәгънәсендә, гарәпчә, бәхәс кылу була.

Җәдалдан кал ки, кыл өстендәдер каль,
Екытсаң йә екылсаңдыр зәбун халь. –

Ягъни син мөхәкъкыйк галим булсаң, бәхәстән

1 К.да — гадел (147 б.).

(җәдалдан) кал, асылда бәхәс кылма, чөнки вәгазь сөйлә, гыйльме кальдә үрнәкләре күп бирелә. Ул кыл сүзе белән бәхәс итә-итә үзең егылып, халыклар арасында мәсхәрәгә калырсың яки башкаларны егып мәсхәрә итәрсең. Бәһре хаљь булса да, бәхәснең хәле зәбунлыкдыр (түбәнлектер). *Кыл* сүзе зәгыйфәи мәраздер (зәгыйфь, авыру)... *Каль* дигәне гыйльме кальдер... *Екытсаң* дигәне башкаларны егу мәгънәсендә...

Вөҗүднең гакбасе ирмәс әл аша,
Тел аша килгән үлтермәс талаша.

Ягъни барлыгың тагы биек түгел, аннан морад: никадәр галим булсаң да, синең гыйлемлегең интиһасына (чигенә) ирешкән түгел. Шуның өчен сине берәү бәхәс кылып хур итәр. Бәс, андый булса, тау артыннан килгән кеше белән аннан морад; гадәмдән (юктан) барлыкка килгән кеше, кешеләр белән бәхәс кылып, орышып, талашып үтермәс. Андый булса, галим әрвахтан галим вөҗүдә (юктан бар булу) килүеңне хисап кылып, янә вөҗүддән (барлыктан) гадәмә барырсың (юкка чыгарсың) һәм истигъдадны (зирәклекне) күрсәтеп, бәхәсләрне куй, димәктер. *Вөҗүд* барлык мәгънәсендә, аннан гыйлемгә истигарә алынды. *Гакба* — әмре хазыйр (хәзерге заман боерык фигыле), төрки сүз. Ба гайн мөһмәленең (хәрефенең) фәтхе белән тау мәгънәсенә була, һинди сөйләменчә. Аннан галимел-әрвахка истигарә (киная) алынды. *Талаша* талашу һәм орышу мәгънәсендә.

Бу сүздин гарыз Тәңре ризасы,
Нә ул гыйльме ки, булгай халык азасы.

Ягъни бәхәс кылма дигән сүзеннән мәкъсуд Тәңре Тәгаләнең ризалыгы булыр, аның ризалыгын таләп иткән кешегә, әлбәттә, бәхәсне куярга кирәк. Андый гыйлемлек, бәхәс белән халыкларны рәнҗетер булса, Ходайның ризалыгына ирешә алмас, димәктер.

Йаныб килгәндә михнәте шәмгъ, әй йар,
Йаныб дотма һәва бадига, зинһар.

Ягъни гыйлемлек чырагын (белем тулпау) күп михнәтләр һәм иҗтиһадлар белән хасыйл итеп, камил булып, яктырып янып торса, андый гыйлемлектән кире кайтып, наданлыкка барып, нәфес теләкләренең юлында һәм ул теләгән нәрсәләр белән һәлак итмә. *Йаныб* сүзенең элеккесе гарәпчә, тәваккыд (яну) мәгънәсендәге сүз. Вә икенчесе кире кайту мәгънәсендәге төрки сүз.

Заманә әһле әксәре талиб кадер,
Болай диб садры мәҗлес кан(и) кылыр садер.

Ягъни бу заманның гыйлемлек эстәүчеләре галим булуыннан макъсудлары (максатлары) халыклар арасында кадер һәм хөрмәт казану булса, болай дип Аллаһны эстәүләре белән ахирәт мәҗлесенең түрендә утыруны каян (кайда) хасыйл итсен, ягъни бу ният белән ахирәт мәртәбәсен таба алмаслар, димәктер.

Укыбдыр сән әгәр халис мәгани,
Йөрәк каны белән асаре кани.

Ягъни син, дәрес укып, халис (чын) Аллаһ өчен укыган гыйлемлегем бар дип әйтерсең. Кани (кайда) синдә Аллаһдан куркып елауның галәмәте, — юк ул, һаман әйткән сүзең ялган... Син йөрәк каныңны Аллаһдан куркып агызмаган, димәктер. *Кани* сүзенең әүвәлгесе дәм (вакыт, сулыш) мәгънәсендә һәм икенчесе юк — ләйсә мәгънәсендәге сүз...

Белеб үз дошманыңа кылма хәрб,
Күреб утка үзен салмак ничек хәрб.

Ягъни, гыйлемлекне өйрәнеп, белеп, үз дошманыңа һөҗүм итмә, сукма. Чөнки гөнаһ эшләр барчасы сиңа ахырда дошман булыр. Дошманлыкны белеп торып, гыйлемлекне нәфес һәваларыңа сарыф итүнең мисалы: берәү ут барлыгын күреп, үзен үзе утка салуы кебек була. Шулай син дә үзеңне үзең белә торгач, гыйлемлекне нәфес-дошман һавасына буйсындырып харап итмә. *Хәрб* сүзенең элеккесе сарыф итү, һинди сөйләменчә. Һәм икенчесе - харап итү һәм юк итү, гарәп белән гаҗәм (фарсы) арасында уртак сөйләмнән алынган.

Муафикъ гыйльмигә кылса эшене,
Дигел: әрбабе гыйлем андаг кешене.

Ягъни берәү өйрәнгән гыйлеме белән тәгать кылса, андый галимне әрбаб дип ата, ягъни галиме раббани (изге галим, Аллаһ галиме)... дип ата.

Торуг шәһридә, әй мәрде кяри,
Кирәкдер, әлбәттә, карый вә карый.

Ягъни бер галим тәкъвалык шәһәрендә эш кылучы (мәрде кяри) булса, ягъни ул галим тәкъвалык белән торуны теләсә, әлбәттә, шулай кирәк. Галим кеше акрынлык һәм сабырлык, авырлык һәм тәхәммел үзрә (чыдамлыкта) булсын, димәктер. *Карый* сүзенең элеккесе укучы мәгънәсендә һәм икенчесе акрынлык мәгънәсендә, һәр икесе гарәпчә сүз.

Бөтебдер «Җамигыл-мишкать»[1] эчендә,
Нәбидин сорды бер соргучы бәндә.

Ягъни «Җамигыл-мишкать» дигән китап эчендә язылган (бөтебдер), пәйгамбәребездән сорады бер адәм. Исеме Габдулла бине Мәсгуд иде.

Йаманларның йаманы кайсы инсан? —
Җавабын бирмәде ана ушал ан.

Ягъни ул сораучы әйтте: «Йә рәсүле Аллаһ, ахирәттә яманнарның яманы һәм газапның күбрәге синең кайсы өммәтеңә булыр?» — диде. Сәйд г-м ул вакытта жавап бирмәде.

Өч айдан сон җавабын бирде аны:
Йаман галим — йаманларның йаманы.

Ягъни ул сораучы өч мәртәбә сораганнан соң гына җавап бирде: «Ахирәттә газапның күбрәге һәм яманрагы бозык галимнәргә булыр, чөнки гыйлеменнән файда

1 «Җамигел-мишкать» — Шәрыктагы атаклы җыентык исеме.

алмыйча, гамәл кылмыйча йөрделәр, халыкка өйрәтми һәм вәгазъ-нәсыйхәт кылмый, гөнаһыдан тыелмый һаваларына (нәфес-теләкләренә) табигъ (буйсынып) хөкем итеп, ришвәт җыеп (ашап) йөрүче галимнәр кебекләргә. Ахирәттә газапта болар шикелле каты[1] кеше юк», — диде... Пәйгамбәр г-м өч мәртәбә сораганнан соң җавап бирде. Хикмәте бу иде: галимнәрдән әдәп саклады, аларның гаепләрен тиз генә ачмады. Сораучының өченче мәртәбә соравы зарури булды. Шуннан беленде инде, андый олы падишаһ галимнәрдән әдәп сакласа, кайда калды безгә масаерга?!...

Йәнә диде ушал һәмразе мәхбүб (якын дус),
Диде; хубның хубы һәм галиме хуб.

Ягъни Пәйгабәребез г-м ул мәҗлестә җавап бирде: «Ахирәттә изгеләрнең изгерәге изге галимнәр булыр. Андый галим белгән гыйлеме белән[2] әмре мәгъруф һәм нәһийе мөнкәр әйлийә («ярамаган нәрсәләрдән эшләүдән тыш»), һәм юаш, һәм күндәм сүзле була, һәм фасикълардан ерак качучы була, солтаннар, байлар мәҗлесеннән ерак качучы була һәм байларга байлык өчен тәвазыйг (түбәнчелек) кылмый, һәм хөкемнәрдә ришвәт алмый, һәм мәчет юлын ташламый, һәм бәхәсләшүче булмый, һәм моннан башка ...әхлакы зәмимдән (ярамаган әхлаксызлыклардан) ерак була.

Диде пәйгамбәре галимгә: һади
Ирер дүзәхдә бер шиддэтле вади.

Ягъни дөнья халкын туры юлга күндерүче пәйгамбәребез әйтте: 'Тәмугта (дүзәхдә) бер каты газаплы чокыр (шиддәтле вади) бар», — диде. Бу хәдис һәм «Мишкать» эчендә Әбү Һөрәйрәдән риваять итеп (күчереп, алып) язылды.

Ушал вади Җөббел-хозн (кайгы чокыры) атанды (аталды),
Рийалек карыйларның җае диде.

---

1 К.да — ахирәтдә каты газаблы (149 б.).
2 К.да — бу сүздән соң «гамәл әйлаб» дип язылган (149 б.).

Ягъни: «Ул каты газаплы чокырга исемне Җөббел-хөзи дип Аллаһ Тәгалә (атады) бирде. Ул чокырда шундый кешеләр бардыр: риялык белән гыйлемлек алучыларның урыныдыр, диде һәм ниятләре гыйлемлек өйрәнгәндә, халык арасында хөрмәтле булсам иде дип ният кылып укучыларның урыны», — диде. Әйтәләр: ул чокыр җәһәннәмнең уртасында, анда өч төрле җәмәгатьләрне салырлар. Әүвәл берсе — галимнәр, чөнки назыйм... (автор) искә алды. Икенчесе — аталарына һәм аналарына гакъ булганнар (буйсынмаганнар), хатыннарына карап, аларны рәнҗеткәннәр. Бәс, шул әҗәлдән (исәптән) сәләфе салихинларның (изгеләргә мөнәсәбәтлеләрнең) күбрәге аталары һәм аналары үлмичә хатын алмадылар. Өченчесе — хатыннар; ирләренең алдында каты җавап биреп, аваз чыгарып (кычкырып) җавап биргәннәр. Бәс, бу өч төрле кешеләр шул чокырга керерләр, диде. Әйтәләр: ул чокыр төбе өч йөз егерме еллык юлдыр, эчендә төрле чаяннар булыр, диде. Һәм төрле сасы исләр анда булыр, диде. *Җөбб* җимнең (җим хәрефенең) заммәсе белән тирән мәгънәсендә...

Җәһәннәм көндә дүрт йөз катилә (мәртәбә) андин
Пәнаһ эстәр Ходай зилмәнәндин[1].

Ягъни ул чокырның һәйбәтеннән (куркынычыннан), андагы газаплар күплегеннән, һәр көндә дүрт йөз мәртәбә нигъмәт бирүче Аллаһдан мәдәд (ярдәм) теләп, җәһәннәм көн дә үзе Аллаһдан сыгыну эстәр.

Ходавәндә, ераг иткел рийадан,
Аерма сидкы ихласы зыядан.

Ягъни, йә Рабби, рәхмәтең берлә безне риялык белән дәрес укучылардан һәм риялык белән гамәл кылучылардан ерак кыл һәм дә безне ихлас нурыңнан аерма дип назыймның дога кылуы[2].

1 Зилмәнән — а) бөек, игелекле; б) Аллаһның эпитеты.
2 С.-П.да — мөнәҗәтедер (217 б.).

## Тәкәбберлек кылмый түбәнчелекне ихтыяр итү бәянында

Кил, әй заһид, кулыңдин бирмә тагать,
Зыйадә ит тагатең сәгать бесәгать.

Ягъни, әй дөньядан йөз чөереп һәм зиннәтен артка куеп, аңар алданмыйча, әһеле сөлүк булып, суфый булган кеше, зинһар, тәгать (буйсыну) һәм гыйбадәт кылмыйча, һич вакытларны буш үткәрмә, бәлки сәгать бесәгать (сәгатьтән сәгатькә) дәрәҗәсен арттыр.

Уйаглигъ пишә кыл, хәүф ит тамагъдин,
Рийазәт иләтәкъвәи вәрәгъдин.

Ягъни, син заһид, даими кичәләрдә уяу торуны хәзер ит («телә») һәм дә даими Аллаһ Тәгаләнең газабыннан курык, тамактан (комсызлыктан) ерак бул, көндез ураза тотып, гыйбадәтләр кылып, нәфесеңә мәшәкатьләр кыл.

Фәригать (ял итү) берлә һич гашыйк итәрме,
Кеше рахәт белән гашыйк итәрме!?

Ягъни Аллаһ Тәгаләгә гашыйк булучы кеше фаригь булып (тынычланып) йоклармы?! Асылда, гашыйкы хакыйкый (чын гашыйк) тынычлап йокламас, мәгъшугы таләбендә булыр, аңар лаеклы гамәл кылыр һәм дә гашыйклык дәгъвасын кылучы кеше ашап, эчеп рәхәт чикмәстер.

Әгәр кол хуҗасын җуенда булса,
Йатармы юлда гашыйк бәндә булса!

Ягъни мәүләсен эстим дип юлга чыкса, әгәр ул гашыйклыгы хакыйкый булса, фәрагать (эштән бушаганда), бихәбәр (хәбәрсез, ваемсыз) ятмас, һәрчак таләптә булыр.

Йийгел кәм кичә тормагдин йййсәң гамь,
Булыр эш кәм, әгәр күб туйса эшкәм.

Ягъни андый Хак Тәгаләгә гашыйкы хакыйкый булса, ким,

аз аша һәм ким, аз эч, чөнки күп ашау белән ашың ким булыр, ягъни тәгамең аз булыр, чөнки күп ашау табигатеңә кимчелек китерер, аннан соң Аллаһны эстәүдән мәхрүм булырсың. *Эшкәм* сүзенең элеккесе мөрәккәбдер (кушма сүз); *эш* фарсыча кяр мәгънәсендә, *кәм* аз мәгънәсендәдер; һәр икесе төрки сүз. Һәм икенчесе мөфрәдәддер (кушылмаган), корсак мәгънәсендә, фарсы сүзе...

Игә гаһд итсә фаталәбне, тәҗәдне,
Куярмы үзгәләр бу җәһд-ү җәдне.

Ягъни Хак Тәгалә (Игә) хәзрәте гаһд (вәгъдә) итеп, бу сүзне әйткән булса: әгәр хәкыйкать белән мине эстәүче – табарсыз дип, бәлки дөньяны арткы планга куймый, акыл иясе Аллаһны эстәүне ничек куяр? Ә бәлки Ходага гашыйк булып, җәдҗәһед (тырышлык) белән гамәл кылыр. *Игә* Аллаһ мәгънәсендә, һинд халкының сөйләме.

Аригъ жисмең әгәр булсын дисәң саг,
Сәнаҗ агзың сән ач, әлбәттә, кәмраг.

Ягъни синең пакь тәнең (җисмең) барча зәхмәтләрдән сәламәт булсын дисәң, күн көймәсенең авызын азрак ач, әй карыны ач кеше, димәктер. *Сәнаҗ* асылда күннән ясаган көймә. Эченә җил белән тутырып, ике башын мөхкәм (нык) җеп белән бәйләп, башка төрле көймә юк вакытта, өстенә утырып дәрьядан чыгарлар. Монда корсак мәгънәсенә истигарә (киная) алынды. Кыскасы, азрак аша, чөнки күн көймәсенең җебен күбрәк ачып җибәрсәң, эчендәге җил чыгып, дәрьяда һәлак булырсың; алай күбрәк ашасаң, нәфесең куәт табып, Аллаһны эстәүдән коры калырсың, гөнаһлар кылырга бәһатур (баһадир) булырсың.

Рийазат мивәседер мисле йәнгяһ,
Әгәрчә заһире — шәх, батыйны — йаг.

Ягъни, нәтиҗә, ачлыкта күп файдалар бар, чөнки ачлык белән мәшәкать чигүе сәмәрәсенең (мивәсенең, җимешенең) мисалы шундый. Әчтерхан чикләвеге кебек: чөнки аның тышы каты (шәх), эчке тарафы — төше — майлы (йаг). Андый ризалык сәмәрәсенең

әүвәле мәшәкать булса, ахыры рәхәт булыр... Дөньяда ачлыкка риза булып сабырлык кылсаң, ахирәттә күп рәхәт табарсың. *Йәнгяһ* сүзе фарсы сөйләменчә (фарсыча) чармәгыз (грек чикләвеге) диерләр, болгар сөйләменчә Әчтәрхан чикләвеге, димәктер. Төрекмән сөйләменчә йанкаһ диерләр. *Шәх* замме (?) шин (шин хәрефе) белән катылык мәгънәсендә, гарәпчә сүз була.

Мәгыйшәт әүвәле — нәрм, ахры — каһәр,
Еланның тышы — йомшак, эче — зәһәр.

Ягъни, кыскасы, карын туклыгында файда юк, чөнки хуп тереклекнең (яхшы яшәүнең, тормышның), күп ашауның башлангычы йомшак (нәрм), ягъни дөньяда вакытта файдасы бар, ләкин ахирәттә зарары күп, андый булса, елан кебек тиресе йомшак, эче тулы зәһәр (агу) булыр.

Рийазат хакыга һәр кичә ор баш,
Йөрәк кан әйләсә, ләгыль атаныр таш.

Инде андый булса, син мәшәкать чигү туфрагына һәр кич башыңны ор. Аннан морад: даимел-әүкат (һәрчак) ачлык белән бул һәм нәфесеңне даими мәшәкать белән тот. Мондый булу сәбәпле, йөрәк каның ләгыль ташына (асылташка) әйләнеп, Аллаһ каршында хөрмәтле булырсың. Чөнки ләгыль ташының адәмнәр арасында кыйммәте күп булыр, ризалык иясенең хөрмәте Аллаһ каршында шулай ук күп булыр, димәктер.

Билеңне баглагыл хезмәткә чөн нәй,
Шәкәр тулдырса, шайәд, күңлеңә хәй.

Шуннан андый булса, ачлык белән Аллаһ хәзрәтләренә хезмәткә билеңне багла, шикәр камышы (нәй) кебек, шаять ки, Аллаһ Тәгалә күңелеңә шикәр комын тутырыр, ягъни мәгърифәт һәм хикмәтләр белән тутырыр, *Нәй* камыш мәгънәсендә *Хәй* дигәне Аллаһ исемләреннән бер исем була.

Белер гакыйл бу дүнне сәҗне бәд буй,
Бәләнд уй эстәсәң, нәфсең күзен уй.

Ягъни син акыл әһеленнән булып торсаң, әлбәттә, акыл иясе бу зәбүн (дүн; түбән) дөньяны сасы исле зиндан (сәҗн) дип белер. Андый бу дөнья фани икәнен белгән акыллы кеше буйсынмыйча яшәүне һәм нәфесенә мәшәкать чиктерми торуы(ны) лаек күрмәс. Инде шундый булгач, бәләнд (мөһим; бөек) фикер иясе кеше, әлбәттә, нәфсе әммарәнең (нәфес кушуының) күзен мәшәкать белән һәм тәгать белән чыгарса кирәк, Аллаһ ризалыгын эстәсә кирәк. *Сәҗн* (сижн) дигәне зиндан мәгънәсендә. *Буй* ис мәгънәсендәге сүз. *Уй* сүзенең элеккесе фикер мәгънәсендә, икенчесе чыгару, я телү мәгънәсендәге сүз, уймактан (уеп алудан) ясалган.

Түшәб калын, йабыб тагать[1] җәмалын,
Куеб сән башыңга балын вә балын.

Ягъни нәфсе әммарәгә (кушып торган нәфесеңә) буйсынып, рәхәтлек өчен калын түшәк ябып, аның белән Аллаһ Тәгаләнең тәгать йөзен ябып, кяһил булып (ялкауланып), рәхәттә буласың. Шул сәбәпле башыңа гөнаһ ястыгын куеп, фирагатьтә (иреклектә; рәхәттә) ятасың, димәктер. *Балын* сүзенең элеккесе ястык мәгънәсендә, икенчесе гөнаһ мәгънәсендә.

Тиле нәфсең телә тагатькә кәм-кәм,
Мәгәр булгай игелмәс гәрдәң хәм[2].

Димәк, андый булса, ахмак нәфесеңне Аллаһ Тәгалә гыйбадәтләренә акрынлык белән кәм-кәм тел һәм бөк, аның өчен ул нәфесеңә мәшәкать салмый торуың, үзеңә буйсынмас итмәсен, чөнки нәфесең теләгән нәрсәләрне даими бирү белән куәт табып, сиңа өстен булмасын, димәктер... *Гәрдән* муен мәгънәсендәге сүз. *Хәм* дигән игелмәс һәм иелмәс мәгънәсендә, һәр икесе фарсыча сүз.

Күзеңдән әйлә гафләт ойкысын дур.
Вәләкин булмагыл тагатькә мәгърур.

Ягъни һәрвакыт күзеңнән гафләт йокысын ерак (дур) тотып, нәфесеңә төрле мәшәкатьләр яса һәм Аллаһ

---

1 К.да — бидгать (125 б.).
2 С.-П.да — хам (220 б.).

Тәгаләнең тәгатьләрен һәм гыйбадәтләрен даими кыл; андый булса да тәкәбберлек һәм гоҗеблек (һавалану) кылып, гыйбадәтең күплегенә алданма, димәктер.

Әгәрчә булсаң әһле гыйльме зөһһад,
Тәкәббер кылмагыл, аслыңны кыл йад.

Ягъни, гарчә син галиме зифөнүн (укымышлы) булсаң да, тәкәбберлек кылма, асылыңны истә тот, чөнки асылың туфрактан; шул асылыңны истә тотып, күңелеңнән тәкәбберлекне чыгар.

Тәкәббер әйламәк шәйтан фәгале (эше),
Егыйдыр, зарыйдыр адәмнең хале.

Чөнки тәкәббер булу шәйтан фигыле, шуның өчен тәкәббер булма, даими елауда бул, чөнки елау Адәм г-мнең хәле, ягъни ничек иблис тәкәбберлек белән Хак Тәгалә дәргяһендән (катыннан) сөрелде һәм дә Адәм г-мне, гөнаһысы сәбәпле, даими елаганы өчен, гөнаһысын гафу итеп, үзенә якын итте, һәр икесенең хикәятләре кыйссаларда мәзкүр (билгеле)[1].

Риазат берлә ачсаң күзеңне,
Газазил дик олуг тотма үзеңне.

Ягъни син, ризалык белән нәфесеңә күп мәшәкатьләр чиктереп, тәгать кылып, күзеңне ачсаң да, төрле тәҗәллийәт (балкыш, нур) һәм көшүфать (ачышлар) белән мәүсуф булсаң да (сыйфатлансаң да), Газазил кебек үзеңне олы тотып, тәкәбберлек кылма, ничек Газазил үзен, масаеп, олы куеп, гомерен заяга уздырып, дөнья һәм ахирәттә хурлыкка ирешә.

Әгәр йирнең йөзенә әйласәң дәрес,
Тәкәббер кылмагыл, булгыл Хода тәре.

Ягъни син, галим булып, дөнья халкының барчасына сабак һәм дәрес бирсәң дә, «оста мин» дип тәкәбберлек кылма, бәлки Аллаһтан куркучы (тәре) бул.

---

1 К.да — «Һәр икесенең хикаятләре вә кыйссалары мәшһүрдер» (153 б.).



www.darul-kutub.com

Сәнең кергән йулың торфә озакдыр,
Арада саны юк бәнд-тозакдыр.

Ягъни синең әһеле сөлүк (суфый) булып кергән юлың гаҗәп (торфә) озак булыр, араларында хисапсыз тозаклар бар. Шундый хәтәрле урыннары бар: һәрберсе әһеле сөлүкне тарикатьтән мәнгъ әйләдер (тыядыр). Боларның кайбере хисси һәм кайберсе кальби — барсын да бәян итү тәрке әдәбдер (әйбәт түгел), саликнең (суфыйның) үзенә беленер... *Торфә* дигәне гаҗәп мәгънәсендәге сүз, кашгар халкының сөйләме.

Гаҗәб юлдыр: арада күб хатәр бар,
Кеше белмәс, чебен йиткәйме, шоңкар!?

Ягъни тарикать юлы гаҗәп озак юл ул, күп хәтәрле урыннары бар: мондый хәтәрле[1] юлга һәркемнең барып җитүе нәмәгълүмдер (мәгълүм түгел); чебен җитәрме яки шонкар җитәрме, — мөгаен (ачык) түгел. Андый юлга күп гыйбадәт кылганнар җитәрме, бәлки аз гыйбадәт белән җитәрме?! Шәех Габдеррәзак вә Бәлгам вә Багур вә Иблис кебекләр җитмәделәр, тәкәбберлек кылып, харап булдылар һәм дә аз тәгать әйләгәннәр (буйсынганнар) җитәр-җитмәслеге мәгълүм түгел. Бәс, андый булса, бәндә хәвеф белән өмет арасында булсын, гыйбадәт кылсын, кабул булуын сорасын. Бәндә гыйбадәт кылырга мәэмурдер (тиешле). *Чебен* дигәне мәшһүр (билгеле). Морад: гыйбадәте бик аз. *Шонкар* бер мәшһүр кошның исеме, күбрәк торуы һавада. Лачын кебек. Аннан морад: гыйбадәт кылып, Хода юлында тиз һәм күп гамәлле булганнар.

Кеше белмәс бу Гомман астыда фаш.
Җәваһир парәи кыйммәт вармы йа таш.

Ягъни бу тәгать диңгезендә заһир (билгеле) түгел, ул диңгезнең астында кыйммәтле җәүһәр бармы йә кыйммәтсез таш бармы, аны кешеләр белмәсләр, чөнки— нәмәгълүмдер (билгесезлек). Андый буйсынуыбызда Аллаһның ризалыгы бармы, ягъни кабул буламы яки

1 К.да — мөшкел (153 б.).

юкмы, шулай булгач, гыйбадәт әһеле гамәленең кабул булуын сорасын. *Гомман* (Гоман) дигәне бер мәшһүр диңгез булыр, һинди тарафында. Әмма монда күп гыйбадәткә истигарә (метафора) кылынды.

Әгәр чәндикә гәүһәр парәдер сән,
Йакыйн бел, бәндәи бичарадыр сән

Ягъни син гарчә гәүһәр ташының барын алсаң да, аннан морад: сәйдзадә булсаң да, шиксез бел, чарасыз бәндә син. Андый булса да тәкәббер булма, бәлки һәрчак үзеңне бәндә дип бел.

Һәмишә бәндәдиндер зарый кылмак,
Нә хәддер башыны юкары кылмак.

Димәк, андый булса, бәндә булган кешенең хәле — даими гыйбадәт кылып, зарыйлык кылу. Бәндә булган кеше башын югары кылып, тәкәббер кылуда ни кяремез (эшебез) бар безнең?!

Тәвазыйглык булыб тоткыл үзен кәм!?
Шәҗәр кем мивәлек булса, булыр хәм.

Ягъни, бәндә булсаң, түбәнчелек кылып, үзеңне үзең ким тот, Аллаһ каршында хөрмәтле булырсың. Җимешле агачның (шәҗәрнең) ничек түбән (хәм) булганы кебек. *Хәм* ... түбән булу мәгънәсендә.

Тирәк кем ул күтәрде юкары баш,
Сәмәрәсез калды күрдеңме аны фаш.

Ягъни күрмисеңмени: тирәк дигән агачны, башын күтәреп торуы сәбәпле, җимешсез калуы билгеле. Андый Иблис кебек, тәкәбберлек белән торып, Аллаһ каршында дәрәҗәсез калуы мәшһүр.

Кеше кем хаке раһдыр бирийадыр,
Кадәм туфракы күзгә тутыйадыр.

Ягъни, бер кеше туфрак кебек түбәнчелек кылып,

һәм гамәлләренең риясы булмаса, андый кешенең аяк (кадәм) туфрагы күзгә сөрмә булыр. Аннан морад: андый кеше Аллаһ каршында кәраматледер, якындыр. *Тутыя* сөрмә мәгънәсендә, фарсы сүзе.

Китәр дәмдә тулайдин пәст (түбән) үтәр көн,
Саба чыкса, булыр галәмдә өстен.

Ягъни күрмисеңме: кояш баеган вакытта барча нәрсәләрдән түбән кала, кайчан таң ярып бетсә (таң аткач), барча дөнья халкыннан өстен булыр. Андый бер бәндә түбәнчелек белән гамәл кылса, Аллаһ Тәгалә каршында башка халыктан хөрмәтле һәм дәрәҗәсе артык була.

Нә булгай катрә дик (тик) тотсаң үзең кәм,
Гөһәр булсаң да кылсаң таҗе мәрдәм.

Ягъни ни була ди, нисан (язгы, апрель, ләйсән) яңгыры кебек үзеңне ким күрсәң, шаять, ирләрнең (мәрдәм) башындагы таҗларына куйган энҗегә (гөһәр) тиң булырсың. Әйтәләр ки, сәвер борҗының[1] (үгезбозау йолдызлыгының, ягъни апрель-майларга туры килүче айның) унбишендә нисан яңгыры явар. Ул яңгыр кайчан Фарсы белән Рум диңгезе кушылдыгы җиренә җитсә, диңгез төбеннән бер балык сурәтле хайван чыга, авызын ачып, Аллаһдан нисан яңгыры теләп, су өстеннән югары тота. Шул хайван нисан яңгыры авызына төшсә: бер тамчы, яки ике тамчы, яки өч тамчы эләксә, төшкәненә канәгать булып кына, дәрья төбенә китә, Хак Тәгаләгә, нигъмәт биргәне өчен, хәмде-сәналәр (мактаулар) әйтә. Моннан соң Аллаһ Тәгалә моның канәгать булганы өчен, аның эчендәге тамчыдан, кош йомыркасы кебек, бер садәф (энҗе кабыгы) яралта. Аның эчендә энҗе ярала.

Бу энҗеләр камиллеккә ирешкәч, мәзкүр (югарыда телгә алынган; бу) хайван аны дәрья төбенә коса, аннан соң, ярылып, садәф эченнән энҗе чыга. Әгәр нисан яңгыры бер тамчы булса, бер бөртек була. Ике

1 К.да — нур йолдызының (154 б.).



www.darulkutub.com

тамчы төшкән булса, ике була. Кыскасы, ничә микъдар тамчы авызына төшкән булса, шулкадәр бөртек садәф эчендә була. Вәләкин бер садәфтә бер яки берничә энҗе булса, беренчесе бәһале була, башкалары ике-өч булса, беренчесенең кыйммәтенә җитмәс була. Һәм дә әйтәләр: бу нисан яңгыры җиргә җиткәндә, диңгезне күргәч әйтер икән: «Бу диңгез минем каршымда ни олы дәрья торыр, мин бер тамчы торырмын», - диер. Хак Тәгалә шул сәбәпле, ягъни үзен ким күргәне сәбәпле һәм мәзкүр хайванның канәгате сәбәпле, моның эчендәге нисан яңгырыннан адәмнәр арасында кыйммәтле энҗене яралтыр. Ягъни, кыскасы, бер адәм канәгать әһеле булса, үзен ким дип белсә, нисан яңгыры кебек Аллаһ каршында дәрәҗәсе артык булыр. Һәм дә әйтәләр: ул нисан яңгыры яуган вакытта еланлар, өннәреннән чыгып, авызларын югары күтәреп торырлар, нисан яңгыры авызларына төшәр, күпме төшсә дә туймаслар, канәгать булмаслар. Шуның өчен Аллаһ Тәгалә аларның эчендәге тамчыны адәмне һәлак кылучы агу итеп яратыр. Шуңа күрә андый адәм Аллаһ Тәгалә биргән малга канәгате булмаса, аның малы да бәләле булыр, диләр.

Биредә фарсыча бер бәет китерелә. Ягъни нисан яңгыры, җиргә җиткән чакта, бу бәетне әйтер икән, үзен тәвазыйг кылып (түбәнсетеп), ким дип белүе өчен, падишаһларның таҗында урын табар булды, ягъни берәү үзен хур күрсә, Аллаһ Тәгалә аны газиз кылып, өстен итәр, димәктер...

Әгәр фәйз (игелек) эстәсәң, кылма тәкәббер,
Биеккә акмагай дәрьи улса һәм пөр.

Ягъни син, тарикы хакка (туры юлга) басып, төрле көшүфать (нурланыш, балкышлар) һәм тәҗлият (таҗ иясе) белән мәүсуф булып (сыйфатланып), Аллаһ Тәгалә күңеленә мәгънәләр салса, үзеңне олы күреп тәкәбберләнмә, диңгез никадәр яры белән тулы булса да, югары һавага акмас.

Әгәр тотсаң тарикы Мостафаны,
Йаман кәйдер тәкәббер, кәйдер аны,

www.darul-kutub.com

Ягъни пәйгамбәр г-м юлын ихлас белән тотсаң, тәвазыйглык (тыйнаклык, әдәплелек) белән тәкәббергә әйләнмә, чөнки тәкәбберлек урамы яман урам ул. Ул урамны шәригать уты белән көйдер һәм яндыр, димәктер. *Көндер* сүзенең әүвәлгесе урам һәм икенчесе яндыру һәм әхрак (яндыру) мәгънәсендә, төрки. Бу урында истигарә-киная була.

Агыр тотты үзене сәнгхарә,
Таләб базарида кермәз шомарә.

Ягъни күрмисеңме: караташ (сәнгхарә; гранит) үзен авыр тотып тәкәбберлек кылды: «Мин авыр», — дип тәфахер әйладе (мактанды). Шуның өчен сатучы базарында-хисапка (шомарә) кермәс. Ул караташның кадере булмас, берәү үзен-үзе авыр күреп, тәкәбберләнсә,...— базарына кермәс — хак каршында кадере булмас, (диләр).

Кечек белде үзене данәи дөрр,
Хәридар алдидә бәһасе пөр.

Ягъни күрмисеңме, энҗе данәсе (данәи дөрр) үзен кечек күрде. Ничек югарыда бәян булынды, шул үзен кече күргәне өчен, ул энҗенең бәһасе алучылар янында (хәридар алдидә) тулы кыйммәтле булыр.

Йигермеш җәзбе гыйшкы шәкәстә кәсне,
Егар гәрдаб әксәре харе хәшне.

Ягъни Аллаһ Тәгалә җанәбенә (тарафына) тартылган гашыйк кеше, әлбәттә, сыныклыгын һәм тәвазыйглыгын (тыйнаклыгын, әдәплелеген) тупларга кирәк, ягъни Аллаһка гашыйк булган кеше тыйнаклык белән сыйфатланган булса кирәк. Ничек упкын (гәрдаб) чүп-чарны җәмигъ әйлар (бергә туплар), андый әһеле гашыйк әхлагы тыйнаклыкның[1] барчасы белән сыйфатланган булыр. *Йигермеш* җәмигъ булу мәгънәсендә. *Гэрдяб* упкын мәгънәсендә була. *Хархәш*[2] чүп мәгънәсендәге сүз.

1 С.-П.да — хәмидәләрнең (225 б.).
2 К.да — хархәс (155 б.).

Әгәр нәфсең һәмишә тотмасаң кәм,
Дөрест ихлас илә булмаган һәм.

Ягъни берәү үзен-үзе тәвазыйг (түбәнчелек) кылып хур тотмаса, тәхкыйкан (чынлыкта) ул кешедә дөрес ихлас булмый.

Газизе кямилне җаһиле хам,
Кабихә ләфзы берлә бирде дәшнам (сүкте).

Ягъни бер кадерле камил әүлияне бер надан бәхетсез кеше чиркин (начар) сүзләр белән сүкте. Ул газиз тәхаммел әйладе (чыдады), асылда бер сүз әйтмәде. Әйтәләр ки, ул кадерле камил әүлия дигәне Хәзрәте Шибли[1] иде. Сүгүче Габдеррахман бине Мәсгуд Азани[2] иде. Ягъни бу икәү Багдад урамында бер сүз хакында бәйләнештеләр[3]. Хәзрәте Шибли хак тарафына тартыр иде, Габдеррахман бозык тарафка тартыр иде. Ахырда Хәзрәте Шибли(нең) сакалыннан тотып, начар сүз белән сүкте. Хәзрәте Шибли җавап бирмәде, буйсынып торды.

Тотыб сакалыны ул мәрде хушхуй,
Дийәр ирде үз тәнигә: әй, хәнәке руй.

Ягъни ул сүгүче киткәннән соң, Шибли хәзрәтләре сакалын кулына тотып, үзе-үзенә шелтә кылып, хитаб әйлар (дәшер) иде. Ягъни әйтте: «Әй чытык йөзле (хәнәке руй) набекир (явыз, мәкерле), хур булуың үз сәбәбеңнән, башкадан түгел, чөнки ул сүгүче юк нәрсәләрне әйтмәде, барчасы синдә бар.

Сәнең рисвалыгынны иргә вә кич
Үзем әйгангә бавәр кылмадың (ышанмадың) һич.

Ягъни Шибли хәзрәтләре үзенә шелтә кылып әйтте: «Йә тән, син шомның рисвайлыгын иртә дә

www.darul-kutub.com

1 Әш-Ширли Әбүбәкер Дулаф (861-946) — Багдадның мәшһүр суфые, Әл-Җөнәйд һәм Әл-Хәлләҗ шәкерте. Ул элек дәүләт системасында эшли, дәрәҗәле урыннарны били. Аннан суфый булып китә. Аның карашларында Аллага мәхәббәт, тормыш рәхәтләреннән үзеңне кискен чикләү (гайре аскетизм) өстенлек итә. Әш-Шиблинең исеме һәм хезмәтләре мөселман дөньясында билгеле.
2 К.да — Адани (156 б.).
3 К.да -сүзгә килделәр (156 б.).

кичтә күрәмен, йөземә оят синең сәбәбеңнән булыр, — диер иде. — Син шом үзем әйтеп биргән тәгать һәм гыйбадәтләргә бәһадурлык әйләмәдең», — дип үз нәфесенә үзе шелтәләр белдерде.

Бу мөһминдин ишетеб килтер инсаф,
«Никүләр әһле мән», — диб ормагыл лаф.

Һәм дә үзенә әйтер иде: «Йә Шибли, бу үзеңне сүгүче мөэминнән гаибеңне ишетеп, инсафга кил, моннан соң мин әһеле сәлахдан (изгедән) һәм суфыйдан дип коры исем белән юк лафны орма, бәлки бу мөселманнан ишеткән гаепләреңне, күңелеңә алып, истигъфар (тәүбә) ит», — диер иде. Шундый олы кеше, үзен-үзе шелтә кылып, хурлап һәм әдәпкә чакырганнан соң, кайда булды ди безгә тәкәбберлек кылу?! Кыйссадан хиссага кайтып боерды:

Ана инсаф, ана (әнә), холык, әй борадәр,
Үзеңнең гаибеңә сән йабма чадәр.

Ягъни акыл иясе, күр син, акыл әһеленә ни төрле инсаф һәм күркәм холык үзенә булды. Әй карындашлар, шундый инсаф әһеле булсаң, гаебеңне пәрдә белән ябып торма, тәүбә-истигъфар кыл, мөселманнар гаебеннән берсе бул. *Аш* (әнә) дигән сүз әлифнең мадде белән укылыр, исеме ишарәтләрнең (күрсәтү адмашлыкларының) төркеменнән, гарәпчә була.

Әгәр сән кылмасаң нәфсең шикәстә,
Йитәр сакалыңа һәр көндә дәстә (кул).

Ягъни син, үзеңне-үзең хур күреп, нәфесеңне сынык кылмасаң, бәлки теләгән эшләрен кылып, аны симертер булсаң, һәркөн дә сакалыңа кулын сузар һәм халыклар арасында сине хур итәр. Чөнки сүзгә килү белән гамәлләреңне юк итәрсең. Андый булсаң, тәкәбберлек кылма, тәвазыйглык (тыйнаклык, әдәплелек) белән башыңны күтәрмә, һәрчак күндәм һәм мескенлектә бул, хакыйкатьтә (чынлыкта) тәсауф шул була ул.

www.darul-kutub.com

## Тәвәккәл кылып (Аллаһка тапшырылып) юлга керү бәяны

Кил, әй гашыйк, күңелне әйлагел пөр,
Тарикы Кәгъбәи мәкъсудыңга кер.

Ягъни, әй гашыйк кеше, күңелне Аллаһ Тәгалә гыйшкы белән тутыр (пөр әйлагел), мәкъсудың Кәгъбәгә баруны ният ит, дөньяга илтифат итмә һәм күңеленә юк фикерләрне җыеп, матлубдан (теләктән) коры калма.

Ничек булгай диеб әндишә кылма,
Тәвәккел әйлә, үзгә пишә (гамәл) кылма.

Ягъни, ул Кәгъбәгә бару ният итсәң, малым һәм чыгымым һәм азыгым юк дип фикер йөртмә, Аллаһ Тәгаләгә тәвәккәл ит, чөнки Аллаһ Тәгалә разыйктыр (туендыручы), тәвәккәл итүчеләрне сөюче...

Тәвәккел бәндәнең юлдашы булса,
Гаҗәб ирмәс караташ ашы булса.

Ягъни, кайчан бер бәндә үзе тулаем тәвәккәл булып, тәвәккәл кеше аңа юлдаш булса, гаҗәп түгел, андый кешеләргә яландагы үләннәр һәм таудагы ташлар нигъмәт булыр. Чөнки бәни Исраил суфыйлары тауда ялгызлыкта тордылар, нигъмәтләре үлән булды һәм ком белән таш булды. Һәм безнең пәйгамбәребезнең өммәтеннән, ялгыз калып, тауда торучы хәзрәте Әбүзәр әл-Гаффари иде. Ул да тауда торды, күбрәк ашавы утүлән иде. Моның кебек әүлияләр дә күптер, кайсыдыр ки берсен бәян иттем. Кыскасы, Аллаһка тәвәккәл итү яхшы, гамәл ул.

Әгәр һиммәт кешенең йары (дусты) булса,
Гаҗәб юкдыр җәризәләр базары булса.

Ягъни берәүнең һиммәте (олы күңеллелек) юлдаш булып, тәвәккәле тулы булса, яланнарның (җәризәләр) базар булуы таң-гаҗәп түгел, ягъни тәвәккәллек юлдаш булган бәндәгә сәхраларда базар кебек нигъмәтләр булса кирәк. *Җәризэ* ялан мәгънәсендә, фарсы сүзе.

Йигәр ахыр тәвәккел әйлагәң кол,
Тәвәккел кыл, тәвәккел кыл, тәвәккел.

Ягъни, нәтиҗәдә, тәвәккәл иткән бәндә теләгенә ирешсә кирәк. Андый булса, тәвәккәл кыл, һәрчак аннан башка булма, һәрвакыт тәвәккәллектә бул. Өч мәртәбә (тапкыр) әйтүче моңа эшгарьдер (мисал).

Ирер бер ихтыяри җөзи (өлеш) сәндин,
Таләб кылганыңа тигермәк андин[1].

Ягъни Аллаһ Тәгалә хәзрәтләре сиңа бар ихтыяри фигыльне бирде. Ул фигылең белән һәрчак тәвәккәл кирәк. Чөнки Аллаһны эстәүгә ихтыярны бәндәләренә Үзе салды һәм морадларына җиткерү Аллаһ Тәгаләдән.

## Хозыр-Ильяс турында

Әгәр тотса Хода кол хатерен пас,
Чыкар һәр күшәдин Хозыр-Ильяс.

Ягъни Аллаһ Тәгалә бар кылган бәндәсенең хәтерен саклап (пас) тотса, аңар мәрхәмәт теләсә һәм тәвәккәле тулы булып, Аллаһны эстәмәк сәфәренә чыкса, әлбәттә, ул кешегә һәрбер почмактан (күшәдин) ярдәм бирергә Хозыр-Ильяс чыксалар кирәк, ул бәндәгә ярдәм-носрәт бирсәләр кирәк. Бу бәет Хозыр-Ильяс пәйгамбәрнең терек икәненә ишарәт. Кайберләр әйтәләр: Хозыр-Ильяс үлек дип, мәшәкать булган кешегә рухлары килеп ярдәм бирер, диләр. Бу гайре әсахдер (дөрес), чөнки ул икесе абел хәятны (тереклек суын) диаре золмәтдә (караңгылык илендә) эчтеләр һәм тәһарәт төзеделәр; мәгълүм көнгә тикле ул ике зат үлмәсләр һәм алган тәһарәтләрен бозмаслар. Бу сүз дөрес. Бу бәет дәхи тәвәккәл әһеленә гаеб ирәнләре ярдәм бирүләренә ишарәт кылыр, алар бу дөньяда мәшрикътан мәгърибкә кадәр кояш кебек сәяр итәрләр (гизәрләр).

Әйтәләр: алар кырык кеше һәм тагын кайберләре әйтәләр өч йөз алтмыш кеше һәм аларның олысына Будәлад диерләр, ике ягында ике нәүкәре (хезмәтчесе, сакчысы) бар һәм аларга рокаба диерләр. Ул ике нәүкәрнең дә ике нәүкәре (хезмәтчесе) бар. Ләкин аны ножәбә

---

1 К.да — йиткермәк (157 б.).

диерләр һәм аннан башкаларын әбдал диерләр. Әйтәләр: бу риҗалел-гайб (күренми торган зат) рәсул даирәсеннән хариҗдыр (тыштадыр), ягъни андый алар һичбер пәйгамбәрнең шәригатен тотмас диерләр, үзләренә истикъляллан (бәйсез) бер шәригать бар, диерләр. Моны әйткән мәзһәбе кяфер.

Әлбәттә, алар бер пәйгамбәрнең шәригатенә мотабәгать әйласәләр (кылсалар) кирәк. Һәм икенчесе шул: риҗалел-гайб (күренми торган зат) асылда юк диерләр, Имам Шафигъ һәм Хәзрәте Имам Малик мәзһәбе, бу сүз күңелгә мәгъкульдер (туры килешле). Өченче мәзһәб шундый: алар бар, адәмнәр, кыямәт дәверенә кадәр фани булмаслар. Болар да батыйл мәзһәб. Әмма мәзһәбе әсах (иң дөрес мәзһәб) шул, риҗалел-гайб булганы хак. Безнең күзебезгә күренми. Әмма алар әһеле җеннән. Пәйгамбәремез дәверендә, аңа килеп, җен кичәсендә иман китерделәр. Алар ул заманда пәйгамбәребездән үтенделәр: «Безнең халык, дөньядан аерылып, без һәм җенләр юлга гаҗиз булучыларга носрәт (ярдәм) бирер идек», — диделәр. Аннан ул Хәзрәте г-м сөбүтлек үзренә (раслап) дога кылды, җиһан йөзенә уздырды, та дәвре кыямәткә диген (кыямәткәчә) фани булмаслар, гаҗизләргә (ярдәмгә мохтаҗ булганнарга) дус булырлар, ярдәм бирерләр. Әмма вафат булырлар. Үлгәннән соң урыннарына җеннәрдән берсен алырлар, һәрчак шул мәзкүр (телгә алынган) гадәтләреннән зиадә (артык) һәм әксүк (ким) булмаслар. Фәтва булдылар; риҗалел-гайб — җеннән, чөнки адәмиләр булса, безнең күзебезгә күренерләр иде. Чөнки инсанның күзеннән мөхәффи (яшерен; күренмәс) булган, мәшрикътан мәгърибкә тай әйламәке (йөрүе) мөхальдер (мөмкин түгел), илля (әмма) әнбияләрдә (пәйгамбәрләрдә) бар. Ләкин аларның күбесендә бу хәл булмады. «Фәтавийе суфи»да Имам Газали хәзрәтләре (1058-1111. — Х.М.) шулай зикер итте.

Килдек Хозыр-Ильяс хакына. Аларның аналары бертуганнар иде, Чәка[1] исемле кешенең кызлары иде. Ул ике кыздан ике пәйгамбәр туды. Берсе — Бәшир исемле һәм берсе — Нәзир исемле. Бәшир дигән кешесе Хозыр пәйгамбәр торыр, Нәзир дигән кешесе Ильяс пәйгамбәр торыр. Үргәнеч шәһәреннән чыкканнар.

---

1 К.да — Җәка (158 б.).

Сорау: Бәширне ни өчен Хозыр дип атадылар? Җавап шулдыр: Хозырват дигәне өчендер. Хозырват мәгънәсе яшелчә үләннәрне ашау, димәктер. Әйтәләр: Хозыр тәгаме кәрәфәс, ягъни кузгалак. Шуның өчен Хозыр аталды. Икенче җавап шулдыр, Хозыр г-м баскан җир яшәрер, яшелләнер иде, шуның өчең Хозыр аталды. Өченче җавап шул була, һәр гаҗиз[1] (ярдәмгә мохтаҗ) булучы кешенең янында (ярдәмгә) әзер диде.

Сорау: Нәзиргә ни өчен Ильяс дип исем бирделәр? Җавап шул, һәр гаҗизе мөтәвәккелгә (ярдәмгә мохтаҗга) ярдәм биргәне өчен Ильяс аталды. Чөнки мәгънәсе гарәби[2]-яһуди теленчә ярдәм бирүче мәгънәсендә, яки Ильяс сирийани теленчә суда йөзү мәгънәсендә, чөнки Ильяс судагы гаҗизләргә ярдәм биргәне өчен Ильяс аталды. Әйтәләр: Хозыр Ильястан утыз ел алдан дөньяга килде. Әйтәләр: Ильяс белән Хозыр туксан яшьләренә җиткәч, кире кайтып утыз яшьлек егетләр булырлар, чөнки алар абел хәятны (тереклек суын) утыз яшьләрендә эчтеләр. Сорау: Хозыр белән Ильяс һәрбер кешегә ярдәм-носрәт бирер, дидегез. Әмма ләкин аларның мөшаһәдә булмаганлыгы (күзгә күренмәгәнлеге) җен булуга дәлил итмәс, бәлки аларны Аллаһ Тәгалә күзләргә күренмәс итте. Безнең пәйгамбәребезне дөньяга китерде, аннан соң пәйгамбәр дөньяга килүе мөмкин түгел. Өммәтләргә пәйгамбәрләр йөзен күрү җаиз (тиеш) булмады Гайсә дәверенә кадәр. Гайсә г-м күктән иңгәч, шул замандагылар пәйгамбәр йөзен күрсәләр кирәк. Аннан әүвәлге өммәтләр пәйгамбәрләр йөзен күрмәделәр. Аннан дөньядан үткәннәре өчен бу икене Аллаһ Тәгалә, үлгән кеше хөкеменә куеп, безгә күрсәтмәде, ягъни күренүче итмәде. Икенче җавап: риҗалел-гайбнең (күзгә күренмәсләрнең) җеннән булып, күзебезгә күренмәслеге һәм бу икенең адәмнең күренмәс булуы бөтенләй башка мәгънәдә. Бу урыннарда Аллаһ Тәгаләнең хикмәте бар, адәм балалары акыллары белән хисап кылу харам.

* * *

Әгәр тикерсә Мәүла кол эшене,
Кылыр мөшфикъ күренгән һәр кешене.

---

1 С.-П.да — гаҗил (229 б.).
2 К.да — гыйбрани (230 б.).



www.darul-kutub.com

Ягъни, Аллаһ Тәгалә бер колның эшен җитеш кылырга, теләк һәм ниятләренә ирештерергә, хасыйл итеп бирергә (тормышка ашырырга) теләсә, тәвәккәл итсә, Хода юлында баруы күренгән кешеләрнең барчасын мөшфикъ (сөйкемле, шәфкатьле) кылыр.

Әгәр лотф әйләсә бостан булыр чүл,
Алар уртасында пәйда булыр юл.

Ягъни Аллаһ рәхмәт итеп, зафәр әйләмәк («уңай хәл итү»; җиңү) теләсә, тәвәккәл булып, мәкъсудына җиткерергә теләсә, яланлар барчасы бакча булып, төрле нигъмәтләр пәйда булыр, юл булмаган яланлардан юл биреп, теләгенә җиткерер. Чөнки Муса г-м Тийә язысында (сәхрасында) ...дога сәбәпле кырык ел тәмам сәяр әйләделәр (гизделәр). Аллаһ Тәгалә Муса кавеменә сахраларда төрле җимешләрне үстереп, әзер итеп торыр иде. Андый тәвәккәл әһеленә яланнарда төрле нигъмәтләрне булдырыр, димәктер.

Үтәрдә аждәһа агзын сөрсә паең,
Зыян итмәс әман итсә Ходаең.

Ягъни Аллаһ Тәгаләне эстәүгә барган сәфәреңдә (үтәрдә), мәсәлән, аягың аждаһа авызына туры килсә, Аллаһ Тәгалә ул елан агуыннан аягыңа зыян тидермәс, әгәр сине Аллаһ Тәгалә имин кылса.

Игә: ком. — диде, — бу комдин булыб чөст (тиз),
Мәхәббәт комкомындан кыл үзең шөст.

Ягъни, Аллаһ Тәгалә (Игә — ия) сиңа тор (ком) һәм мине эстә, — диде. Бәс, андый булса, бу дөнья комыннан тизлек белән тор. Аллаһны эстә һәм аның әмеренә хилафлык китермә, Аллаһны эстәп, аның мәхәббәт комганыннан (комкомындан) гыйшыклык шәрабеңне эч һәм мәхәббәт шәрабе белән үзеңне гөнаһ кереннән ю, димәктер. *Ком* сүзенең әүвәлгесе әмре хазыйр, гарәбпчә һәм икенчесе рәмел (ком) мәгънәсендә, төрки сүз. Аннан арз (җир) мәгънәсенә истигарә алынды (метафора рәвешендә алынды). *Комком* дигәне әбрикъ (комган) һәм

комган мәгънәсендәге сүз, гарәпчә. Аннан мәхәббәт шәрабенә метафора итеп алынды...

...Бозык дөньяда, Аллаһны эстәмичә (теләмичә), тик яту яхшы булмас. Андый булса, аның ярдәме белән тәвәккәлеңне тулы итеп, пакь урынны эстә. Аннан морад: изге гамәл кыл, оҗмах сарай (тарафына) бару ниятендә бул, димәктер.

Әгәрчә сандә булса әһле фәрзәнд (бала-чага),
Йаратыбдыр аларны һәм Ходавәнд.

Ягъни син Аллаһ Тәгаләгә билхакыйкать (чынлап та) гашыйк булсаң тәвәккәл кыл, Аллаһны эстәүгә җәһт әйлагел (тиз тырыш), дөньяга алданма һәм балачыгым (бала-чагам) димә, аларны Аллаһ Тәгалә үзе яратыр.

Үзе кылды аларга җисем илә җан,
Бирер, әлбәттә, җан биргән Хода нан (ипи).

Ягъни ул бала-чагаларны тән белән җан риза итте. Әлбәттә, үзе җан биргәнгә икмәк бирер, алар өчен кайгыда булма.

Газиз җан чыкмаса калебләредин.
Төкәнмәс[1] нигъмәте Хәкъ ләбләрендин.

Димәк, андый булса, ул бала-чагаларның тәнләреннән газиз җанлары чыкмыйча, аларның үтмәкләре (икмәкләре) авызларыннан (ләбләредин) бетмәс. Өйлә булса, хатыным һәм бала-чагам бар дип, Аллаһны эстәүдән коры калма. Сорау: назыйм-шагыйрь бу ике бәет белән ишарәт кылды, хатыннарга һәм балаларга карамыйча, гозләт (ялгызлык) юлын тотуга ихтыяр бирде. Әмма ләкин аларның нәфәкалары (аларны туендыру) аталарына фарыздыр (тиеш), чөнки пәйгамбәр г-м әйтте: «Һәркем хатыннан һәм бала-чагаларыннан качып, нәфәка бирми йөрсә, ул кешенең асылда кылган гыйбадәте кабул түгел», — диде. Җавап шул, назыймның морады аларга карап, Аллаһның фарызларын ташламаса һәм харам нәрсәләрдән

1 К.да — кимемәс (160 б.).

тыелмаса[1], гаиләсенә нәфәка бирсә (тәэмин итеп торса) — Хак Тәгалә каршында болар гыйбадәт санала. Аллаһ сәфәрендә булу шул була да инде. *Калеб* тән мәгънәсендә, гарәпчә сүз. *Ләб* ирен мәгънәсендәге сүз.

Сәнаглигъ[2] (санаулы) гомердин та җан төкәнмәс,
Йакыйн белгел, агыздан нан төкәнмәс.

Ягъни син, хатыннарыңа һәм бала-чагаларыңа алданып, фарызларны (тиешле гамәл-бурычларыңны) үткәрмә, «алар нәфәкасы кәсебендә мин» дип дәлил эстәп, Аллаһ ризалыгын эстәүдән коры калма; бәлки аларның хисаплы гомерләреннән җаннары чыгып киткәнче, авызларыннан икмәкләре бетмәс. Өйлә (бу очракта — көн) булса, кәсеп итеп, Аллаһ Тәгаләнең боерган фәрманнарын әда итсәң (үтәсәң), ике төрле тәгать әйләмеш (буйсынуга лаек) булырсың: берсе — җәмәгатеңә нәфәка бирүдер, икенче — Аллаһ әмерләренә буйсынудыр.

Әгәр дәрья төбендә булса җаең (урының),
Бәһанә берлә йиткергәй Ходаең[3].

Гараз һәркайда, әй фәрзәнде адәм,
Сәнаглигъ рузи һәргиз булмагай кәм.

Ягъни сүзнең кыскасы шул: кайсы урында булсаң да, әй адәм улы, хисаплы ризыгың һәргиз (һич тә) ким булмас. Өйлә булса, алар өчен гөнаһлар эшләп, алар артыннан йөреп, гыйбадәттән коры калма, тәвәккәлең тулы, бөтен булса, фәрештәләр кебек тәсбих һәм тәһлил белән ризыкланып торырсың, чөнки кайбер заһидлар (изгеләр) ун көн микъдары тәгам җыймадылар һәм кайберләре егерме көн микъдары тордылар, ә кайберләре бер ай кадәре һәм кайберләре ике ай кадәре җыймадылар (ашамадылар). Күрмисеңме: Әбү Мәгавия ...хәзрәтләре балчык ашар иде, Ибраһим Әдһәм хәзрәтләре ком ашар иде.

Кешенең булса мондаг игътикади,
Аңа бостан ирер һәркайсы вади.

---

1 К.да — улынса (160 б.).
2 С.-П.да — сәналигъ (232 б.).
3 Бу бәет С.-П.да күзгә ташланмый (232 б.).



www.darul-kutub.com

Ягъни бер кешенең, югарыда әйтелгәнчә, игътикады (ышанычы) нык, тулы булса, ул кеше һәркайсы чокырда (вадида) булса да, аңа бакча (бостан) булыр Аллаһның кодрәте белән, анда төрле нигъмәтләр хазыйр әйлар (әзер кылыр) яки гадәтдә нигьмәт булмаган нәрсәләрне нигъмәт кылыр, чөнки Аллаһ Тәгалә кадирдер (кодрәтле, бар нәрсәне булдырырга көче җитә).

Вөҗүднең хар-хашигы калындыр,
Йалынсаң һәм һава очмас йалындыр.

Ягъни кяфер нәфеснең заты һәм теләгән нәрсәсе[1] (әйбере) калын чүп-чардыр (хар-хашик). Аннан морад: төрле бидгатьләр (бозыклыклар) ярамаган нәрсәләр мөзәййәндер (бизәлгәндер; тулгандыр). Андый булса, нәфесеңә ялынып, тәмәллекъ әйләмәгел (ялагайланма), чөнки аңа ялынып, ялагайлык очкыны һавага очмаган ялкын, бәлки яшеренлек белән сине аздыру ниятеңдә булыр. Андый булса, теләгән нәрсәләрдән берсе бул һәм аңа тәмәллекъ әйләмә. *Хар-хаш* чүп мәгънәсендәдер. *Йалын* сүзенең әүвәлгесе тәмәллекъ әйләмәк (ялагайланма, яраклашма) мәгънәсендә килә, икенчесе ут, очкын, ләһбе нар (ут ялкыны) мәгънәсендәге сүз.

Менеб һиммәт пәракын (атын), чык калындин,
Йалын мөхкәм (нык) тотыб, сәчрат йалындин.

Димәк, андый булса, тәвәккәл һиммәтенең (Аллаһка тапшырылуның көчле теләге) атына менеп, тәвәккәлсезлек урманыннан кач, даими тәвәккәллектә бул һәм дә, ул тәвәккәл атының ялын нык тотып, тәвәккәлсез ялкыныннан чәчрәп чык. Кыскасы, тизлек белән генә тәвәккәл кылып, теләгеңдә бул, димәктер... *Камын* дигәне урман мәгънәсендә... *Йалын* дигән сүзнең әүвәлгесе ат ялы.., икенчесе ут, ялкын... мәгънәсендә килә.

Йитеб[2] гомрең, әй тәбәһе хал,
Тәвәккел салыны максад бәхренә сал.

---

1 К.да — нәрсәләре (162 б.).
2 К.да — бетебдер (162 б.).

Ягъни синең гомерең елы (сале гомрең) җитеп, ахырына якын булган, әй бозык хәлле[1] (тәбәһе хал) кеше, андый булса тәвәккәллек салын ясап, максуд диңгезенә (бәхренә) сал. Андый морад: гомерең ахырына якын булган, калган гомереңне тәвәккәл бабында бәрг (игътибарлы) бул, димәктер. *Сал* дигәне ел мәгънәсендә килә. *Тәбәһ* дигәне бозык мәгънәсендә, һәр икесе фарсыча була. *Сал* дигән сүзнең әүвәлгесе күп агачлардан җыйнап, беркетеп бәйләнгән суда йөзү өчен яраклы җайланма. Көймә юк вакытта дәрьядан үтәрләр. Һәм икенчесе салудан ясалган, һәр икесен син (син хәрефе) белән уку тиешле булыр.

Тәвәккел бәхренә кереб, әй нәфсе залим,
Димә: салым минең йиткәйме салым?

Ягъни тәвәккәл диңгезенә кергәннән соң, әй залиме нәфес, тәрәддед һәм тәфәккердә булып (шикләнеп һәм икеләнеп), «минем тәвәккәл диңгезенә салынган салым сәламәт җитәрме?» дип шикләнүдә булма, һәрчак сөбүтдә (ышанычта) бул. *Салым* сүзенең мәгънәсе югарыда әйтелде...

Йитәр-йитмәелекеңдер хөкме Раббда (Аллаһ хөкемендә),
Ирәнләр шартыдыр — улмак таләбдә.

Ягъни җитәр-җитмәс кимчелегең белән булсаң да, Аллаһ хөкемендә бул, ни боергандыр — аннан аерылма һәм ни нәрсәләрдән нәһи әйлагәндер (тыйгандыр), аннан мәңгъ улгыл (тыел). Чөнки... андый булса, ирләр өчен төп шарт — Аллаһ Тәгаләне эстәү юлында вафат булу.

Тәвәккелне кылыб, әй адәми зад,
Йөгергел Кәгъбәи максудга чөн бад (җил кебек).

Ягъни тәвәккәллекне үз итеп, әй адәм уллары, максудың Кәгъбәдә җил кебек йөр. Аннан морад: тәвәккәл кылып, калган гомереңне тизлек белән тәвәккәллеккә сарыф кыл, тәрәддед вә тәфәккердә булма, димәктер.

---

1 С.-П.да — саллы (234 б.).

Кереб юлга, күреб әгъламе асар,
Озын бәр (җир) гөмәнбәр булма, зинһар.

Ягъни тарикать (зөһедлек, суфыйчылык) юлына кереп, һәм анда йокы белән уяу арасында төрле-төрле мөшаһәдать (күзаллаулар) һәм тәҗәллиятләр (чагылышлар) күреп, яки әнваг (төрле) мәхуфать (куркыныч нәрсәләр) күрсәң дә, бу тарлык һәм киңлек япаны дип гөман кылучы (гөманбәр-уйлаучы) булма, бәлки һәрчак кылган гамәл-фигыльләреңдә нык булып, тәвәккәллектә бул. Сүзнең нәтиҗәсе шул: хәбибе мөракабәдә (экстазда чакта) төрле мөшаһәдать вә тәҗәллиятләр (күзАллаһулар һәм шәүләләр) күреп, «мин моңдый мәкамә (дәрәҗәгә) ирештем», дип тәкәбберлек кылма һәм дә шул мөракабәдә төрле газап урыннары күреп, үзеңне Аллаһ рәхмәтеннән өмет кисеп, кылган гамәлеңне һәм кергән юлыңны ташлама, бәлки, һәрчак тәвәккәллектә булып, Аллаһны эстә... *Озын бәр* дип әйткәне госмания теленчә, озын япан мәгънәсендә.

Бу бармакда әгәр бармак салыр шир,
Качан кайтыр тәвәккел әйлагән ир.

Ягъни, бу Аллаһ сәфәренә барганда, арыслан (шир) тырнагын салса, аннан морад: төрле мәшәкатьләргә очраса да, тәвәккәл кылган ир, әлбәттә, юлыннан кире кайтмас, кергән юлында сабит (нык) булыр... *Бармак* сүзенең әүвәлгесе зәһаб (киту) мәгънәсендәге сүз, исеме масдар (фигыльдән ясалган исем), икенчесе исеме җәмиддер (тамыр исем). *Тырнак* исбәгун (бармак) мәгънәсендә килә.

Хатердин әһле һиммәт хирә булмас (аптырамас),
Әгәр ил тирә тотса, тирә булмас.

Ягъни, андый булса һиммәт әһеле һәм тәвәккәллеге, Аллаһка тапшырылуы тулы кеше Аллаһ Тәгаләгә баруда (очраган) мәшәкатьләргә һәм хәтәрләргә хәйран булмас һәм зәгыйфь, йомшак һәм булмас, гарчә барча халык аны эстәү сәфәренә барган юлында ут тотып атсалар да куркак булмас, һәрчак мәгьшугы таләбендә булыр,

аларның уклары арасында тәвәккәл кылып, Аллаһ Тәгалә җанәбенә китәр һәм юлында нык булыр. *Тирә* сүзенең әүвәлгесе ук, сәһм (ук) мәгънәсендә килә һәм икенчесе куркак мәгънәсендәге сүз була, Кашкар (Шәркый Төркестан) сөйләме.

Тәвәккелдән кеше кем алса бәһрэ (өлеш),
Кайчан зәһрә улыр[1] гарык улса зәһрә,

Ягъни, бер кеше тәвәккәллектән файда алса, андый кешенең кайчан күңеленә курку төшсә, гарчә ул бәндә зәһәр һәм агу диңгезендә гарык булса да, даими Аллаһ таләбендә булыр, гайре (үзгә, башка) нәрсәләргә илтифат итмәс (игътибар бирмәс). *Зәһрә* сүзенең әүвәлгесе курку мәгънәсендә, икенчесе агу мәгънәсендәге сүз.

Йиймә рузи гамен йирдә, әй йар,
Кем әсрарың белер ул йахшы асрар.

Ягъни, андый булса, ризык кайгысын һич җирдә җыйма (ашама), әй юлдаш, чөнки серләрне (әсрарың) белүче Аллаһ Тәгалә үзе белер сине яхшы тәрбия итүне, чөнки ризык сахибе (хуҗасы) Аллаһ, микъдарында кылганны зийадә (күп) һәм әксүк (ким) иттичә бирер, аның өчен син кайгы җыеп, сабырсызлык кылма... *Әсрар* сүзенең әүвәлгесе әлифнең фәтхе (ә хәрефе) белән укылыр, сердән мөштәкъ (сер сүзеннән ясалган). Икенчесе тәрбия кылу мәгънәсендәге сүз.

Ходага кылса һәркем хуб[2] тәвәккел,
Нә йирдә булса, заигъ улмас ул кол.

Ягъни һәркем Ходай Тәгаләгә хуб (әйбәт) тәвәккәл кылса, кайсы (теләсә нинди) урында булса да, заигъ (әрәм) булмас.

## Хикәяте Ибне Әл-Мөбарәк

Мөбарәк углы бер көн азгышыб раһ (юлдан адашып),
Гажаеб сусаганда күрде бер чаһ.

1 С.-П.да — орар (235 б.).
2 С.-П.да — хак (236 б.).

Ягъни хикәятләрдә килә: Мөбарәк улы Габдулла, бер көн Шамнан (Сүриядән) Мәдинә тарафына барганында, Мәдинә юлын тапмады: адашты. Барганда, каты (нык) сусап, бер көн аңсыздан алдында бер чаһ (чокыр; кое) күрде.

Кичерде: күңелдә табылды матлуб (теләгәне),
Әгәр делүрсән булса вде хуб.

Ягъни Габдулла бине Мөбарәк күңелендә бу сүз иде: «Ни күркәм була иде бу суның табылуы, әгәр бу коеның чиләге белән җебе дә булса», — диде. Шул фикер белән бераз заман уйланып калды.

Ушал дәмдә (шул чакта) бер аһу килде сусаб,
Ташыб чыкды козугның агзыга аб (су).

Ягъни Габдулла бине Мөбарәк бу фикердә булган вакытта, бер ак киек (аһу — газәл, «антилопа»), сусап, кое янына килде. Бу ак киек килгәч, тирән кое ташып, суын югары чыгарды. Ак киек суны эчеп канды (туйды), үз юлына китте.

Ул эчкән суның ушал шаһ барды чаһка,
Йитәр-йитмәсдә ул су төшде тәһкә (төбенә[1]).

Ягъни Габдулла бине Мөбарәк килеп җитәр-җитмәстә, кое суы әүвәлге урынына түбән төште, тирән булды. Габдулла бине Мөбарәк бу эштән хәйран калды; Аллаһ Тәгалә хәзрәтенә үпкә кушып әйтте:

Диде; Йарабби, бирерсән аһуыңга аб,
Мәңа бирмәссән, әй солтане ваһһаб (юмарт; ягъни Аллаһым).

Ягъни Габдулла бине Мөбарәк хәзрәтләре әйтте ки: «Йә Рабби, ак киегеңә чиләксез һәм җепсез су бирерсең, миңа бирмисең, әй рәхмәтләрне багышлаучы кәрим Аллаһ, әмма ләкин һәр икебез синең бәндәләреңбез, ни

1 С.-П.да — тәрга (236 б.).

өчен аны андый, мине мондый иттең?» — дип мөнәҗәт әйтте (аһ-зарын, үтенечен белдерде).

Нида (аваз) килде ки, ул һәҗһе хөсенгә:
Телең барды сәнең делүр сәнгә.

Ягъни һатифдан (хәбәр җиткерүче фәрештәдән) ул күркәм (вәҗһе хөсен) Габдулла бине Мөбарәк хәзрәтләренә нида (хәбәр) килде: «Сиңа аның өчен суны бирмәдем, чөнки синең әүвәл әмердә коены күргәнеңдә, телең чиләк белән җепкә барып, безне онытттың, алдан ук ярдәм эстәмәдең; инде бар, суны чиләк белән җептән сора, — дип гыйтаб (шелтәле) һатифдан нида (хәбәр) килде.

Ушал аһу ки, күрдең: чыкды йиргә,
Тәвәккел кылмады бездән дигәргә (башкага).

Ягъни ул һатиф (гаибтән килгән тавыш) бу җавапны әйтте: «Бу сусап килгән ак киекне күрдең, әүвәл әмердә безгә нәзар (ярдәм сорап) карады һәм әйтте: «Йә Рабби, бу суың белән кунак итче, — диде, — һәм чиләк, җепне күңеленә кертмәде. Инде син бар, суны чиләк белән җептән сора», — дип шелтә килде.

Ишетеб мондан булды хамуш[1],
Эчендән кулзум зәвык әйладе җуш.

Ягъни Габдулла бине Мөбарәк бу һатифның авазын ишетеп әбсәм (хамуш, сүзсез) булды, Аллаһ зәүкыннан һәм гыйшкыннан Кулзум диңгезе (Кызыл диңгез) кебек кайнау төште (җуш әйладе).

Мәхәббәт җамы кылды һәүл тамагын,
Тереклекдә оныттды сусамагын.

Ягъни Габдулла бине Мөбарәк Аллаһ мәхәббәтенең шәрабеннән тамагына курку (һәүл) төште, тере булган заманында сусавы онытылды, ягъни Аллаһ хәзрәтләренә

---

1 К.да — «Ишетеб бу ниданы булды биһуш» (164 б.).

гыйшык булып, сусавы исенә дә килмәде. *Җам* мәхәббәт шәрабе мәгънәсендә.

Зикре мәхәл һәм ирадәи халь каринәсе илә (ягъни «үз-үзеңне онытып, Аллаһка мөрәҗәгать итү халәтен аңлаткан контекста»). *Һәүл* (һәулә) чык суы мәгънәсендәге сүз була, чөнки югарыда бәяны килде.

Иде әувәлдә ул ир һәм әткыяда (диндарлыкта),
Йөз анча булды һиммәте зиядә (артык).

Ягъни Габдулла бине Мөбарәк хәзрәтләре әүвәлдә тәкъва ир иде, бу ниданы[1] (авазны, өнне) ишеткәч, йөз тапкыр һәм аннан артык тәкъва (изге) булды. Моннан соң кыйссадан хиссийага кайтып боерды:

Мәне мескин тәвәккел бабида даг,
Төшебдер һәмтәм кондин зәбунраг (түбәнрәк).

Ягъни мин мескен бәндәң тәвәккәллек капкасында хәсрәтлемен, ягъни тәвәккәллегемдә сөбүтлекем (ныклыгым) юк, көннән-көнгә тәвәккәллегем һәмтәм (һаман) зәбунрагдыр (түбәнрәктер)...

Һәмишә нәфес, зәштәм мөбтәлясы,
Мәнем дәк (тик) бармы һич мөэмин баласы!?

Ягъни даими мин зәште нәфсем (бозык нәфсем) артыннан йөреп бәлаләнәмен; минем кебек гөнаһлы һичбер мөэмин баласы юктыр.

Иляһи, бәхре рәхмәтедән[2] кылыб сир,
Мәни хонсага ирләр нишанәсен бир.

Ягъни «Йә Рабби, тәвәккәл һиммәте диңгезеңнән мине тук (сир) кыл һәм дә мин тәвәккәлсез куркакка («хонсага») бәһадур ирләрнең галәмәтен (нишанәсен) бир».

Ирермән гакыл юк, идракъ юк кол,
Нә тәмкин (көч; абруй) бар, нә һиммәт, нә тәвәккел.

1 С.-П.да — бондан (237 б.).
2 К.да — бәхре һиммәтедин (164 б.).

Ягъни, мин хәкаике әшйайә («камиллек дәрәҗәсенә») ирешмәгән колмын, сөбүт (ныклык) юк һәм тәвәккәллеге юк бәндә мин.

Килә батдым[1], килә кылмам кешедин,
Күрермен барча үз нәфсем эшедин.

Ягъни мин гөнаһ балчыгына (килә) батам, ул балчыкка батуны кешедән булды дип үпкә тотмыймын; бу гөнаһ балчыгына батуым үз нәфесем эшеннән һәм аның шомлыгыннан күрәмен. *Килә* сүзенең әүвәлгесе балчык мәгънәсендә һәм икенчесе үпкәләү мәгънәсендәге сүз, һәр икесенең әгърабы кәсре кяф белән, фарсы (фарсы сүзе)...

Бу мөэминләр эчендә бер баламән,
Бозык юлдан чыка алмый мөбтәлямән.

Ягъни бу мөселманнар эчендә гаҗәп бер гөнаһ дәрьясына баткан углан мин, һәрчак бозык юлдан чыга алмый, бәлаләре һәм казалары белән бәлаләнгән бичара мин.

Булыбмын гарык бәхре изтирабә,
Хараб улмыш төшеб нәфсе хәрабә.

Ягъни мин, мескен Аллаһйар, гөнаһ диңгезенә (бәхре изтирабә) гарык булып (батып), һәм дә шәриф вакытларымны хараблыкка очрап, нәфес мәйханәсендә исерек булып, шәриф (кадерле) вакытларымның кадерен белмәгәнмен. *Хәраб* сүзенең әүвәлгесе бозык мәгънәсендә һәм икенчесе мәйханә, кабак мәгънәсендә. Ләкин бу икенчесе... (күчерелмә мәгънәдә).

Ирер күклемдә күб раз-ниһани (серләр),
Йөзем юкдыр торыб әйтергә аны.

Ягъни мин мескен Аллайарның күңелендә яшерен серләр бар, аның барчасын Хак Тәгаләгә әйтергә йөзем уфтана һәм хәя итәрмән (оялырмын), чөнки олы гөнаһларым бар. Барын әйтергә телем оялып бармый яки әһеле хакаикның («суфыйларның») барча серләрен бу

1 К.да — йатдым (165 б.).


www.darulkutub.com

китапта әйтергә оялырмын, чөнки барын әйтү тәрке әдәбдер (әдәпсезлек).

Үзең сән галәме сер хәфийййәт,
Мөгайййәндер сәңа мәҗмугы нийййәт.

Ягъни чөнки күңелемдәге серләрне барчасын сиңа әйтү хәҗәт түгел, чөнки үзең яшерен серләребезне белерсең, барча ниятләребез (мәҗмугы нийййәт) билгеле, барын әйтү хаҗәт түгел. Гафуны синнән үтендек.

Әгәр кайтармасаң раем вәрадин,
Котылмасмын моның дик маҗарадин.

Ягъни, йә Рабби, мине мәхлукат фикереннән коткармасаң, мондый гауга, ыгы-зыгы маҗарасыннан котылмамын, һәрчак бозык серләрне әйтүдә булырмын, бәлки син мине, рәхмәтең белән мәхлукатлар фикереннән коткарып һәм нәфесне чыгарып, исбат бабында сөбүт (нык) кыл, димәктер.

Әгәрчә саны юк бу,кол гөнаһи,
Грифтаре газаб кылма, Иляһи.

Ягъни гарчә бу Тимерьяр улы Аллаһйар бәндәңнең хисапсыз гөнаһысы булса да, рәхмәтең белән гөнаһларым шомлыгыннан мине ачуыңа һәм газабыңа тоткын итмә. Бу әбйатлар (бәетләр) барчасы иктифаи (чикләү, канәгать булуны) кабул итүдән...

## Тәкъва кылып харам һәм шөбһәдән качу бәяны

Кил, әй дәрвиш, әгәр дәрвиш атандың,
Тарикать эһленең әндишә атандың.

Ягъни агяһ (хәбәрдар) булып кил, әй суфый, чөнки син, әһеле хәлдән булып, суфыйлык исеме белән аталдың һәм тарикать юлына кермәгәндәй, тарикать әһле каршында мин суфый дип фикер иттең[1], шул исемең һәм шул юл үзәгендә сабит (нык) булып тор.

1 К.да — зикер ителдең (166 б.).

Әгәр атың хилаф бәндәлекдәдер.
Кыямәт көн ничек шәрмәндәлекдәдер.

Ягъни синең исемең тарикать юлларына керен һәм хасс (якын) коллар җөмләсеннән (төркеменнән) булды. Ул исемең, нык булмыйча, нәфес-һаваларыңа китеп, югарыдагы исемеңә хилаф (каршы) булса, кыямәт көн аның ояты ничек булыр?! Бәлки сине кыямәт, көнендә суфый исеменнән годул әйлаб (аерып), йә залим, йә фасикъ, йә гами (надан; тупас) дип өндәрләр. Мондый исем белән өндәлүең олы хурлык булыр. Чөнки ишарәт кылып боерды ки:

Коруг ат берлә үткән хәйфе әүкат,
Уйангыл, булма мәгърур коруг ат.

Ягъни сүзнең асылы шул була: гамәлдән буш йөрмә, бәлки даими гамәлдә бул, чөнки мөҗәррәд (ялгыз, бер үзе генә) суфый исеме белән йөрүең әһле хәл булуга дәлил итмәс, бәлки кайчан син бу исем белән үзенне-үзең мәүсуф (сыйфатлаган) булдың, гафләт (ваемсызлык) йокысыннан уян, коры суфыйлык исеме белән алданучы булма.

Коруг йөрмә, корыг дәсте әҗәлдә,
Салыр нагяһ (кинәт) гөман итмәс мәхәлдә (урында).

Ягъни сүзнең асылы шул: гамәлдән буш йөрмә, бәлки даими гамәлдә бул, чөнки коры чапкы әҗәл кулында. Ул чапкыны гөман улмаган (искәрмәс) урында буеңа китерен салыр, ахирәт йортына үкенеч белән китәрсең, ягъни Газраил җаның алып, гамәлсез ахирәткә барырсың, андый булса, тиз заман гамәл кылуга җәһәд кереш (тырыш; кереш). *Коруг* сүзенең элеккесе буш мәгънәсендә һәм икенчесе (коры), асылда, бер чыбык, озын булыр, башына җеп тагып атны тотарлар. Ләкин монда Газраилның җан алуына истигарә (киная рәвешендә) алынды.

Үзеңдин китмә ихлас гавамә,
Сөенмә намә килмәй яхшы намә.

Ягъни кайчандыр кыямәт булып, изге намәләрең (яхшы изге эшләрең теркәлгән язмалар) кулыңа килмичә, әһле хәл мин («суфый») диеп һәм алар мәҗлесендә кабилиятем («катнашым») бар дип, үзеңнән китеп тәкәбберлек кылма һәм гавам халкының сине яхшы[1] дип ихласлы булганнарына алданма һәм дә халыкларның сине мөршид һәм ишаныбыз диюләренә алданма, димәктер. Кайчандыр кыямәт көнендә намәләрең уң кулыңа килсә, шул заманда сөен, чөнки егетлек һәм ирлек шул заманда мәгълум булыр, шул әҗәлдә.

## Хикәяте Хуҗа Бәһаэддин[2]

Хикәяттә сөйлиләр, Хуҗа Бәһаэддин хәзрәтләре Бохараның мәчет колләненә (манарасына) барганда, бер каравылчы Баһаэддин хәзрәтләрен тотып әйтте: «Син кем соң? — диде, — ирме син, хатынмы син?» — диде. Хуҗа әйтте: «Белмимен хатынмы, ирме икәнемне», — диде. Каравылчы Хуҗа икәнне белде, җибәрде. Үзеннән-үзе гыйбрәт алып әйтер иде: «Хуҗаның сүзе хактыр, чөнки дөньяда «егет мин, ир мин» диеп йөрербез, белмәбез, кинәт көтмәгәндә, явыз, зәгыйфь гөруһыннан (төркемендә) булып, тәмугка китәрсең; андый булса, ирлек һәм егетлек исеменә алданма».

Кеше кереб гәр йөрсә рудә,
Качан хасыйл булыр дөрр шөһүдә.

Ягъни, диңгезгә керен, энҗе (дөрр) алу теләгендә булган бер кеше дәрьяның кәнарында (читендә) йөрсә, кайчан, ничек энҗене эзләп табар?! Чөнки энҗеләр дәрьяның уртасында. Андый берәү, әһеле тарикатьтән булып, суфыйлык исеме белән мәүсуф булса (сыйфатланса), андый кеше исеменә һәм юлына муафыйк булмый (лаеклы булмыйча) йөрсә, ул кеше кайчан сәмәрәи тарикатене (суфыйчылык җимешләрен) хасыйл итеп, әнваг (төрле) мөшаһәдать вә тәҗәллият (күзаллаулар...) табар. *Рудә* сүзенең элеккесе дәрья мәгънәсендәге сүз, икенчесе кәнар (яр) мәгънәсендә, Кашгар халкының сөйләме.

---

1 К.да — мөршид (166 б.).

2 Хуҗа Бәһаэддин (1318-1389) Нәкышбәнди кушаматы белән куренекле суфый. Гомеренең төп өлешен Урта Азиядә Бохара төбәгендә уздыра. Нәкышбәндия дигән суфичылык тарикате, нигездә, Хуҗа Бәһаэддин исеме һәм эшчәнлеге белән бәйле. Бу зат һәм аның карашлары Идел-йортта да билгеле була.

Сивани нәфи икәнеңне әйлә исбат,
Тәвәккел бәхренә бат, әй күңел, бат.

Ягъни Аллаһтан башканы нәфи әйламәгеңне (танымаганлыгыңны) исбат ит, чөнки әһеле тәсауфның гадәте «..Ләә иләһа илләллаһу» сүзе белән, моңардан башкаларны нәфи әйларләр (инкарь итәрләр) һәм дә тәвәккәл диңгезенә гарык булып исбат итүеңдә ашыгучы бул, моңардан башкаларны тиз заман күңелдән чыгар. *Бат* дигәне элеккесе гарык бул, чум мәгънәсендәге сүз, төрки. Һәм икенчесе ашык мәгънәсендә, Бохара халкының сөйләменнән килә.

Күңел Хаке фәйзигә булсын дисәң чак[1],
Ки ул мәртәбә холкыңны кыл пакь.

Ягъни син күнелеңне Аллаһның илһамы (Хаке фәйз) керүгә ачык кылыйм дисәң, әүвәл шарты будыр: холкыңны җәмигъ (барлык) харамнан[2] пакь кылу өчен җиһәт кыл, ягъни пакь кыл — чистарт, арула...

Йиймә зәррә хәраме агуштә нандан,
Булыр чаһе нәҗес бер катрә кандан.

Ягъни холкыңны пакь кылу шул була: син әүвәл мәртәбәдә харам катышкан (хәраме агуштә) нигъмәттән һәм икмәктән ашама. Гарчә ул харам зәррә (бөртек) микъдары кечкенә булса да, чөнки боерды, күрмисеңме, коедагы суга бер тамчы кан яки хәмер төшсә, нәҗес кылыныр. Андый күп гыйбадәтең савабын кечкенә хәрам катышкан нигъмәттән җыйсаң (ашасаң), барчасы батыйл (ярамаган) булыр. *Агуштә* дигәне катышу мәгънәсендә була.

Әгәр аш мәнһи (тыелган) булса, күз йомыб аш
Вә әгәр, нә таңла, карыныңдин чыкар таш.

Ягъни бер нигъмәттә харам нәрсә булса, ул нигъмәттән күзеңне йомып уз һәм аңа карама һәм аны

---

1 С.-П.да — хак (241 б.).
1 С.-П.да — әшйадин (241 б.).

җыярга теләмә. Әгәр андый булмасаң, кыямәт көнендә карыныңнан таш чыгар. Аннан морад: төрле газапларга дучар булырсың. *Аш* сүзенең әүвәлгесе нигъмәт мәгънәсендә, һәр икесе төрки сүз.

Ирер хәрдәлчә мәнһи зәһре катил.
Кылыр бер катрәи мәй хөм суны батыйл.

Ягъни харам нәрсә, гарчә хәрдәл (ясмык) орлыгы кадәренчә булса да, үтерүче зәһәр һәм агу дип бел. Аннан морад: аз харам күп гыйбадәтләрнең савабын бозар, чөнки бер тамчы хәмер бер кисмәк (хөм, хом) суны бозар һәм нәҗес итәр. *Хәрдәлчә* хәр дәл сүзенең тәсгыйредер (кечерәйтелгәне), бер орлыкның исеме була. Шам Шәрифтә (Сүриядә) күп булыр. *Мән хәмер* мәгънәсендә. *Хөм* ханың (ха хәрефенең) заммәсе (ө се) белән укылыр, бер савытның исеме була. Олы чүлмәк. Болгар йортында кисмәк һәм чапчак дигән нәрсә була...

Хәрам аз булса һәм күбдер ямани,
Сәмане булса һәм, белгел, сәмани.

Ягъни, җыйнап әйткәндә, харам аз булса да, яманлыгы күп. Зинһар, харамнан саклан, аннан җыйма, гарчә ул бүдәнә ите булса да, агудан да артык зыяны бар. *Сәманн* сүзе әүвәлгесе бер кошның исеме була, үләннәр арасында йөрер. Уяу вакытта кайчак очар. Чыпчыктан олырак булыр. Төрки халкы сәмани диерләр һәм фарсы халкы вәрәнҗ, диерләр, һәм болгар халкы бүдәнә диерләр. Һәм икенчесе мөрәккәб (кушма сүз). *Сәм* агу мәгънәсендәге сүз. *Ани* хәмер, ачы була — «хәрам аз» сүзенә.

Бөтебдер шәргъда, әй дәлкъ (иске киемгә киенгән; дәрвиш),
Фәраиз әгъзамедер паки хөлкъ.

Ягъни шәригател-исламда (шәргъдә) язылган (бөтебдер), әй, иске кием киеп, суфыйлык дәгъвасен кылган кеше, фарызларның олысы (әгъзамедер) холыкны харамнан пакь итү һәм дә әйтте:

Кайу[1] тагать ки, ул мәрәзаи Раббыдыр, —
Йакыйн бел, куввәте лөкмә сәбәбедер.

Ягъни шәргьда (исламияттә) әйтте[2], кайсы тәгать һәм гыйбадәт кыла, аңа Аллаһның ризалыгы булса, ул ризалыкка сәбәп булучы нәрсәне ашау һәм эчү хәләлдән булсын, диде.

«Кифайәи-шөгъби»дә бу(л) һәм бөтелде (язылды),
Рәсүле Аллаһ сүзендән нәкыль ителде (күчерелде)[3].

Һәм дә «Кифайәиш-шөгъби» дигән китапта шәригател-исламның (ислам канунннарының) сүзе язылды. Пәйгамбәр г-м сүзе дип «Кифайәиш-шөгъби»нең сахибе (иясе, авторы) шул рәвештә күчерде.

Аригъсез локмә берлә кылса тагать,
Кабул ирмәс ушал кылган гыйбадәт.

Ягъни ул ике китапта әйтте ки: «Берәү (локмә) кечкенә генә харам ашаса, гарчә көндезләрдә ураза тотып, һәм кичләрдә уяу торса да кабул түгел», — диде. Сорау: ару (пакь) локмә фарызлардан (тиешле гамәлләрдән) бер фарыз булса, тәгать һәм гыйбадәтнең кабуллыгы аның белән булса, бәс, шартларыннан бер шарты булды, чөнки тәһарәт намазда шарт иде. Аннан булса, галимнәр ни өчен хәләл локмәне намазның һәм уразаның шартыннан итмәделәр? Җавап шул: назыймның («шагыйрьнең») монда шарт итүе тәгать һәм гыйбадәт сәбәбе белән Аллаһ Тәгалә хәзрәтенә якын булуда. Юкса, тәгате билкөллия (тамам; тулысынча) батыйль (начар; файдасыз) түгел, чөнки берәү харам нәрсәләрне җыеп (ашап), ураза, намаз кылса да, фарыз аннан төшәр, ләкин савабы булмас, димәктер. Икенче җавап шул: тәһарәтнең тәһарәт сүзеннән һәм саумның (уразаның) саум сүзеннән, локмәсе һәм кигән либасы (киеме) пакь булуына ишарәт һәм шуңа күрә ишарәт кылып боерды ки:

1 К.да — кани (168 б.).
2 С.-П.да — әйткәненә (243 б.).
3 С.-П..да — нәкыйль кылды (243 б.).

Ходаның мәнгыне (тыюы) нәфес эстәгәндә,
Вә гәр бер зәррәсен тәрк итсә бәндә.

Бу бәет мөбтәза (башлам, ия) хөкемендә. Мәгънәсе шул: бер кеше Аллаһ Тәгаләнең мәнгъ әйлагән (тыйган) нәрсәләрен хуш күреп тыелса, ул тыелган нәрсәсе бер зәррә (бөртек) кадәренчә булса,

Гыйбадәтләргә[1] булгай өнсе-җендин,
Бу әйгаи бәндәлек әфзальдер (өстендер) андин.

Ягъни ул кеше Аллаһның тыйган нәрсәләреннән тыелып торуы адәм белән пәриләрнең (өнсе-җендин) тәгатеннән һәм гыйбадәтеннән артык. Бу бәет хәбәре мөбтәдадер (хәбәр).

Әгәр тәрк итсә (ташласа) шөбһәне һәр йар, —
Диде, — йөз хаждин артык, әй никүкяр.

Ягъни әгәр бер кеше, Аллаһдан куркып, шөбһәле нәрсәләрдән сакланса, ул ике китапта әйтелде ки: бу кеше йөз тапкыр Кәгъбәгә барып хаҗ кылган савабын тапты, — диде. Шул рәвешле, бу бәеттән мәгълүм булды, шөбһәдән сакланган кешегә бу кадәр әҗер булса, чагыштыр, харамнардан бизгән кешеләргә никадәр савабы була, бәлки андый кеше оҗмахлык дип гуаһлык (таныклама, шаһидлек) бирсәң урынлыдыр, ләкин әһеле сөннәт һәм җәмәгать игътикады (ышануы; иманы) андый түгел; ничек булса да, әҗер (түләү; бүләк) газыймә мөстәхәкъ (лаеклы)...

Рисаләи Әбүл Ләйс эчрә мәзкүр,
Нәбидин кылды нәкыль ул мәгъдәне нур.

Ягъни «Тәнбиһел-гафилин» («Гафилләрне искәртү») дигән китапта хәзрәте Әбүл Ләйс Сәмәрканди пәйгамбәребездән бер хәдис китерә, гыйбрәт өчен дип:

Либасендә хораме агаштә булса,
Ушал агаштәсе (табы) бер риштә булса.

1 С.-П.да — гыйбадәтләр ки (243 б.).

Ягъни берәүнең кияр киемендә харам катышкан булса, ул катышкан нәрсәсе бер җеп (ришгә) микъдары булса да. *Агаштә* монда катышу мәгънәсендәге сүз. *Риштә* җеп мәгънәсендәге сүз. Бу бәет мөбтәда (ия була).

Ушал тун берлә үткәргән намази:
«Кабул ирмэс, — диде, — ул бәхре рази».

Ягъни ошбу харам җеп катышкан кием белән намазлар укыса, ул намазлары кабул булмас, — дип боерды серләр диңгезе (бәхре рази) пәйгамбәребез.

Сыйам (ураза) илә әгәрчә үтсә көнләр,
Кыйам илә кичерсә барча төнләр.

Ягъни ул либасында (киемендә) харам җеп катышкан кеше, гарчә көнләрнең барчасын ураза булып һәм кичләрендә уяу торса да кабул булмас, — диде. — Бәлки кылган гамәлләре барчасы буш җил, — диде. Бу ике бәет хәбәре мөбтәда (хәбәр).

Рийазәт берлә улсаң бәһре кәйф,
Аригъ булмаса локмәң — михнәтең хәйф.

Ягъни харам нәрсәләр белән Аллаһ юлында мәшәкать чигеп һәм ничәмә төрле гыйбадәтләр кылсаң да, локмәң пакь булмаса, кылган гыйбадәтләрең барчасы буш булыр, үкенечкә калыр. *Кәйф* сүзе ничә төрле мәгънәдә кулланыла, монда ул мокуламе[1] гыйшрә (әйтелгән кәеф-сафа, күңел күтәрү) һәм кеше халәтен белдергән кәефләреннән. *Хәйф* буш үкенеч мәгънәсендә килә, һәр икесе гарәпчә сүз.

Мәнаһи рәңгедин (гөнаһ төсеннән) эшең буйаглигъ,
Буйаглигъ эш илә хәйф уйаглигъ.

Ягъни син мескеннең ашы, кылган эше харам булган нәрсәләр белән буялган. Кыскасы, андый харам белән буялган туннар белән кичәләрне уяу торуың буш һәм әрәмгә китә.

1 С.-П.да — гокул (244 б.).

Фәраиз әгъзамын (олысын) кылган кеше тәрк,
Мәхәббәт буены кайдин кылыр дәрк (төшенер)!?

Ягъни бер фарызларның олысын куйган кеше, фарызларның олысы хәләл локмә булу иде, андый олы фарызларны куйган кеше Аллаһ Тәгаләнең мәхәббәт исен кайдан табып ирешер, ягъни ирешмәс, кылган гыйбадәтләре барчасы җилгә очар.

Атың чыкды гыйбадәт әһле халка,
Игерден халка, шөбһә салма халка.

Ягъни синең исемең халык арасында әһеле тәгать һәм гыйбадәт һәм суфый диеп мәшһүр булды һәм дә, тарикать әһеленә барып, ханәкъә яранларыннан (суфыйчылык тарафдарларыннан) булдың, андый булсаң, бугазыңа харам нигъмәте салма, бәлки харамнан, шөбһәдән кач. *Халка* сүзенең әүвәлгесе мәхлүк һәм халык мәгънәсендә. Һәм икенчесе ханәкъә һәм суфыйлар мәҗлесе була. Өченчесе ханың (ха хәрефенең) фәтхәсе белән бугаз мәгънәсендәге сүз.

Күнелсен тән дисәң зөһд илә пишә,
Ачылсын «эч» дисәң, пакь эч һәмишә.

Ягъни, гомумән, әгәр син теләгең белән тәнеңне Аллаһ юлында күндерү һәвәсеңдә булсаң, харамнардан һәм шөбһәләрдән күңелең эченә мәгърифәтләр ачылсын дисәң, хәләл һәм пакь нәрсәләр аша һәм эч. *Эч* сүзенең әүвәлгесе күңел һәм калеб (йөрәк) мәгънәсендә килә һәм икенчесе әмре хазыйр («хәзерге заман боерык фигыль»), һәр икесе төрки.

Әгәр агзыңдадыр бал вә бали,
Дигел: улдыр хәмим (эссе); әй мәрде хали.

Ягъни бу харам булган нәрсә бал кебек сөчек (татлы) булса да, гөнаһдыр, ахырда бер зарарны күрерсең һәм дә андый харам нәрсәләр төче булса да, җәһәннәмдә кызган су (хәмим) дип бел, әй әһеле хәлдән булган кеше. *Бал* сүзенең әүвәлгесе мәшһүр, гасал (бал) мәгънәсендә. Икенчесе гөнаһ мәгънәсендә.



www.darul-kutub.com

Әгәр мәнһи имәс (тыелмаган) булса бәгыйдең,
Булыр күб вәгъдәлек гайдең вә гайдең.

Ягъни синең ерак (бәгыйд) булган нәрсәң харам булмаса, Аллаһ Тәгаләнең күп саваплары булыр дигән вәгъдәсе синең хакыңда инде, ул шатлык һәм сөенеч иде. Әгәр син даими фасикъ (бозыклык), гыйсыйан юлында булып, ул сөенечләреңә зәвык кылып, гыйбадәтне ташласаң, сөенечләрең, шатлыкларың синең коры булыр, ягъни ахирәттә, газап булыр. *Гаид* сүзенең әүвәлгесе шатлык мәгънәсендә һәм икенчесе курку мәгънәсендә.

Әгәр кылса кеше лимә, вәлимә,
Грифтар улмагыл рәнҗү әлимә.

Ягъни бер кеше, туй җыеп, җәмәгатьләр чакырса, ул мәҗлестә бәдгакыйллар (начар затлар) булса, анда барып утырып, ахирәт газабы белән рәнҗү алучы булма. Әйтәләр, бидгате туй шул булыр: анда кубыз һәм танбур (музыка коралының бер төре) һәм хәмер эчү булса, һәм нигъмәтләрендә гошер һәм зәкят бирмәгән мал һәм ашлык кебекләр булса, боларның нигъмәте харам булыр, бармавыгыз фарыз (тиеш). Әмма туй мәҗлесенә керүдә, анда бидгатьләр булса да, анда катнашуга өч мәзһәб фикере бар. Әүвәлгесе шул: мөфтиләр һәм казыйлар кебек кешеләр каршы килү фарыз, керү багрик (патриарх) әүлягә харам. Һәм икенчесе: бер галим, бер мөдәррис һәм яки сахибе вилаят (хаким) булмаган кешегә дә анда керү харам булыр. Очраклы рәвештә гафиллек (ялгышлык, ваемсызлык) белән барып керсә яки ул бидгать әһелләре килеп, өстенә керсә, аларга әмре мәгъруф (боеру) теле белән тыйсын. Әгәр тыймасалар, ул мәҗлесдән чыгу фарыз. Өченчесе — гавамнар. Алар ул мәҗлескә душ булса (туры килсә), аларга чыгу фарыз түгел, бәлки алар ул мәҗлес халкын күңелләре белән дошман тоту фарыз булыр. Әй җанлы бәндә, агяһ бул (хәбәрдар бул), безнең бу замандагы суфыйларның догаларының мөстәҗаб (кабул) булмаганлыгы шуннан булыр.

Авылларда[1], байларның чакырган нигъмәтләренә барырлар. Әмма ләкин ул кеше гошерне (керемнең уннан

1 С.-П.да — көйләрдә (авылларда) (246 б.).

береннән бирелә торган садака) бирмәгән, шундый нигъмәтләрне ашап, камиллек тапмаслар һәм догалары кабул ителмәс, уллары аталарына-аналарына гак булганнары (буйсынмаганнары) шул явыз нигъмәттән булыр. *Лимә* дигән хаҗәт мәгънәсендә була. *Вәлимә* туй мәгънәсендә килә. *Әлимә* газап мәгънәсендәге сүз.

Тәгамы кәм әгәр — анда хәтардер,
Йакыйн бел, ләҗҗәи утдин бәдтәрдер.

Ягъни бер тәгам, әгәр анда бидгатьләр һәм харамнар булса, шиксез бел, ул тәгам ут парчасыннан (ләҗҗәи утдин) явыз. *Нәҗҗә* дигән ут парчасы мәгънәсендә. *Бәдтәр..* явыз мәгънәсендәге сүз була...

Әгәр булса хәрам ул локмәи шум,
Аны нигъмәт димәде зәһре зәкъкум.

Ягьни бер нигъмәт харам булса, аны нигъмәт димәде, бәлки аны зәһре зәкъкум (җәһәннәмдәге агулы агачның җимеше) дип боерды.

Нәдер зәгъкум: ирер тәгъзибе сәхти,
Җәһәннәм астында бөткән бер дәрәхти.

Ягъни зәкъкум нидер дигән (дип сораган) кешегә җавап шул була: каты газап (тәгъзибе сәхти). Һәм кайберләр әйтәләр, җәхиме тәмугның (тәмуг утының) астында үскән (бөткән) бер агач булыр. Әйтәләр, ул агач тигәнәк кебек, тәмуглык бәндәләр аны җыярлар (ашарлар), файда бирмәс.., барча зәһәрләрдән (агулардан) зәһәррәк булса кирәк...

Җәмигь (барлык) зәһәр[1] һәргиз булмас андаг,
Йийганның карны кайнармыш казандаг (казан кебек).

Ягъни дөньяда никадәр зәһәрле нәрсәләр булса да, бу зәкъкум кебек зәһәр юктыр һәм дә ул зәкъкумны ашаган кешенең карыны бакыр казан кебек кайнар...

1 С.-П.да — зәһәрләр (247 б.).

Эченең бары парә-парэ булгай,
Гыйлаҗын (дәвасын) белмәгәй бичарә булгай.

Ягъни ул зәкъкумны эчкән кешенең корсагы ярып пәрә-пәрә булыр, дару-дәрман итә белмәен (белмичә) чарасыз (бичара) булса кирәктер.

Иляһи, күңелемезне бигөман кыл,
Ушал шәрмәндәлекләрдин әман кыл.

Ягъни, йә Рабби, күңелебезне газабыңнан һәм аның тәсдыйкыннан шиксез ит һәм газабыңнан куркучы кыл, андый зәкъкум эчеп, рисвай булудан (шәрмәндәлекләрдин) әман кыл (сакла).

## Хикәяте Әхмәд бине Хәнбәл[1]

Ишеткел: Әхмәд Хәнбәлгә бер йәүм (көн),
Диде бер бивәзән[2] (тол) — һадийе кавем.

Хикәят китерәләр, ишет: Хәзрәте Әхмәд бине Хәнбәлгә көннәрдән бер көн бер карый (карт) тол хатын килде. Әйтәләр кем, ул хатын Разыя атлы иде, Багдад шәһәрендә иде. Гаять салиха (изге) һәм суфия хатын иде. *Бивә* (пивэ) дигән тол мәгънәсендә килә. Әхмәд Хәнбәл дигән сүзендә бине сүзенең төшерелүе шуның өчен булган: ике галәм исем (ялгызлык исем) арасында бине сүзенең хәреф булынуы (төшерелүе) кагыйдәи көллиядер (гомуми кагыйдә).

Чырагым, юкдыр аслан, әй олуг бәрх[3],
Үкүрүр (эрләр) ирдем айның баридә чәрх (орчык).

Ягъни ул тол хатын Әхмәд Хәнбәл хәзрәтләренә әйтте: «Минем өемдә шәм-чырагым юк, шуның өчен ай яктылыгында орчык эрлимен», — диде.

---

1 Әхмәд бине Хәнбәл (780-855) — хәнбәли хәрәкәтенә нигез салучы. Тумышы, яшәеше Багдад белән бәйле. Бу зат — үзенең дини карашларында традицияләр тарафдары. Аның фикеренчә, "Коръән"дә һәм пәйгамбәребез хәдисләрендә урын алмаган һәр нәрсә шикле, җидти түгел. Әхмәд бине Хәнбәл (Хәмбал) хөкемдарларга актив хәрәкәт белән йогынты ясауны да яклый.

2 С.-П.да — пивәзән (247 б.).

3 К.да — нәрх (171 б.).



www.darul-kutub.com

Фәррү (яктылык) китде — җәһан әйванындан маһ (ай),
Хәлифә шөгълә берлән үтде нагяһ.

Ягъни көннәрдә бер көн җиһан сараеннан (әйванындан) ай китте, ягъни ай батып торган заманда хәлифә хәзрәтләре минем өем яныннан панар (фонарь) яндырып үтте.

Аның рушанлыгында чөст чәлак
Үгердем бер-ике юл[1] чырагым, әй пакь.

Ягъни ул хәлифәнең чыра яктысыннан тизлек һәм җәһәдлек (чөст) белән орчыгымны бер-ике мәртәбә үреп алдым, ягьни бер-ике мәртәбә бөтереп алдым, бер-ике саплам эрләдем, — диде.

Мәңа ул риштәм (җебем), әй котбе заманә,
Җаваб әйгел, хәлал улгаймы йанә?

Ягъни хатын әйтте: «Йә Хәзрәте котбе заманә (заманның бөек заты), миңа ул эрләгән җебем хәләл булырмы, йә булмасмы? Бу мәсьәләгә җавап әйт», — диде.

Имам әйде: бу гафләт галәмендә.
Ничек зән сән моныңдәк дин гамендә?

Ягъни Хәзрәт Имам Әхмәд Хәнбәл әйтте: «Бу гафил дөньяда ничек, хатын башың белән син, мондый дин кайгысында йөрисең? Сүзнең асылы, син мондый аз нәрсә өчен фәтва эстәрсең (ачыклык кертүне сорыйсың), гаҗәп суфия хатын син», — диде.

Зәгыйфә әйде: әй мәкъбуле вафи,
Мәнем һәмзадәм (игезәгем) ирде Бәшәре Хафи.

Ягъни ул хатын әйтте: «Әй вафалар кабул булган[2] (мәкъбуле вафи), минем белән бер туган Бәшире Хафи хәзрәте иде». Сорау: Бәшир хәзрәтләренә ни өчен Хафи дип әйттеләр? Җавап шул: Хафи мәгънәсе ялангач аяк

1 К.да — дәм (171 б.).
2 С.-П.да — әй вафадар мәкъбул улынмыш (172 б.).

www.darulkutub.com

мәгънәсендә, чөнки Бәшир хәзрәтләре аягына башмак кимәс иде. Һәм дә аның бер күркәм гадәте бар иде: шәһәр эчендә бәвел һәм тизәк итмәс («йомышларын йомышламас») иде. Халыклар аягына минем нәҗасәтем (нәҗесләрем — пычракларым) тиеп, рәнҗемәсеннәр дип, шәһәр тышына барып, тизәк һәм бәвел кылыр иде. Әйтәләр: Бәшир хәзрәтләре гомерендә атка менмәде, Кәгъбәгә алты мәртәбә җәяү барып, тәваф кылды (әйләнеп чыкты; дини йоланы үтәде). Бер көн Бәшир хәзрәтне атка менеп, Багдад урамыннан узганын күрделәр. Халыклар аны күреп, таң-гаҗәп калдылар. Әйттеләр: “Без аның атка менгәнен күргәнебез юк иде, инде бу хәлдә күрдек, шаять, үләр, — диделәр. Шул чакта мөридләр, бу хәлне күреп, артыннан күзәтә бардылар. Чөнки Бәшир хәзрәте Багдад шәһәреннән чыгып киткәч, Багдад янында җан тәслим әйләде (үлде). Әйтәләр ки, Бәшир хәзрәти тәбәгы табигыйн (күндәм; буйсынучан) иде. Тарихе һиҗрәтенең ике йөз алтмышынчы елында (ягъни 874 иче елда) чәршәмбе көн дөнья куйды, Багдадта дәфен кылдылар (күмделәр), Хәзрәте Имаме Әгъзамнең кабере янына.

Ишетте Бәшир атын күздин түгеб аб (яшь),
Диде: сезгә рәва юк, әй дөрре наб (саф энҗе).

Ягъни Хәзрәте Әхмәд Хәнбәл бу хатыннан Бәшир Хафинең исемен ишетеп елады, күзеннән яшь түгеп әйтте: «Сезнең кебек олыларга андый шөбһәле җеп хәләл түгел», — дип җавап бирде. Асылда, Хәзрәте Әхмәднең Бәшир исемен ишетеп елавының хикмәте шул иде: чөнки Бәшир хәзрәтләре диндә күп иҗтиһад итүче (тырышлык куючы) иде. Андый булу бездә кайда инде дип, үзен ким күреп елады.

Аның дәк (тик) мәринең туфрагы, әй маh,
Безнең дәк йөз мең ирнең канидин бәh.

Ягъни, әй олы кеше, андый изге хатынның аягы баскан җир, без динсез ирләрдән торган йөз мең кешелек гаскәренең Хак юлында кяферләр белән сугыш[1] кылып каннарын түгүдән изге.

---

1 К.да — сугыш (172 б.).

Дəрига! Ир атын (исемен) болгаб йөрермез,
Гаммамə (чалма) бер габəс (юкка) чолгаб йөрермез.

Ягъни үкенечлəрнең олысы безгə, чөнки ирлек һəм суфыйлык исемен күтəреп йөрербез һəм дə батыйле дəстарны (сөлгене, чүпрəкне) башыбызга чолгап йөрибез. Кайдаબездə ирлек галамəте, димəктер. Андый булса:

Лəчəк (яулык) артык безнең дəстарымыздан,
Ирəнлəр гарь итəр гəрдарымыздан.

Ягъни андый булса, кыекчалы хатынның баш яулыгы безнең башыбызга дəстар ураудан артык. Күр: хикəят югарыда кичте, андый булса безгə ирлек исеме гарьлек. Кайда бездə ирлəрнең ирлек галамəте, димəктер. *Лəчəк* дигəнне хатыннар башларына ябарлар. Болгар халкы кыекча диерлəр һəм Бохара халкы лəчəк диерлəр.

Һəвəс базарында, əй мəйле күб нəфəс (кеше),
Йиймəк берлə кылыб сəн гəрдүң гафəс.

Ягъни, нəфес-арзуларың (телəклəрең) артыннан күп мəйл əйлагүче (телəүче) кеше, ашау һəм эчү белəн муеның юанайган, ирлек галамəте шул булырмы, димəк. *Гəрдəи* муен мəгънəсендə килə. *Гафəс* дигəн юан мəгънəсендəге сүз.

Сəңа суд (файда) əйламəс бу җисем вəрəмең,
Кылыб шəрмəң, бераз килмəйме шəрмең?

Ягъни андый булсаң, бу тəн симертүең файдалы түгел һəм ирлек галамəте дə түгел. Бу кадəр нəфес-арзуларыңнан гөнаһ юлына баруыңда оялмассыңмы (килмиме шəрмең), димəктер. *Җисем* тəн мəгънəсендə килə. *Вəрəм* асылда шешкəн нəрсəгə əйтерлəр. Биредə симерү мəгънəсендə сурəтлəнə. *Шар* дигəн явыз, гөнаһ мəгънəсендə була. *Мең* дигəн əлеф мəгънəсендə килə. *Шəрмең* васыф тəркибедер (сыйфатлау тезмəсе), тəрки белəн васыф булынган: оят, хəя мəгънəсендəге гыйбарə.

Булыб шəрмəндəлек дəрьясига гарык,
Йаман, йахшы фəркъ итмəгəн фəрык.

www.darul-kutub.com

Ягъни, хәя вә оят дәрьясында гарык булучы (батучы), кыямәт көнендә ни мөгамәлә күтәрсең, чөнки дөньяда вакытта яман эш белән яхшы эшне аермаган акылсыз башсыз, димәктер. *Фәркъ* сүзенең әүвәлгесе аеру һәм тәфрикъ (аеру) мәгънәсендә килә. Һәм икенчесе баш мәгънәсендә...

## Татлы телле булып яман сүздән кайту бәяны

Кил, әй габид, үзеңне әйлагел хакь,
Хәрам, шөбһәдин холкыңны кыл пакь.

Аллаһ Тәгаләгә коллык (габид) һәм бәндәчелек күрсәтеп, үзеңне туфрак (хакь) кыл, туфрак кебек алчак бул һәм дә харамнан һәм шөбһәдән (шикләнүдән) холкыңны пакь кыл, чөнки боерды:

Ачык куллык, көшадә (шат) йөзле улгыл,
Мөрәүвәтлек, мөлаем сүзле булгыл.

Ягъни хакыйкать (чын) суфый, габид (изге, тәкъва) булсаң, ачык дәст (кул), юмарт бул һәм ачык йөзле, сүздә торучы һәм йомшак сүзле бул, суфыйлыкның күркәме шул булыр...

Бу хасләтләр (сыйфатлар) муафикъ булса сәндә,
Өмид улдыр: «Ходаем!» дисә бәндә.

Ягъни бу югарыда әйтелгән шартларга муафикъьлык (туры килү) булса, Ходаеңнан өмет: шаять ки, Аллаһ Тәгалә сине хасс (якын) бәндәм дисә кирәк.

Мөселман углыда булса сөчүк тел,
Алыб килсә булыр бер кыйл белән кыл.

Ягъни бер мөселман улы татлы телле булса, ул төче теле белән күп буйсынмас җәмәгатьне дә дингә алып килүе мөмкин булыр. Кыскасы, төче телле булса, ул татлы теле белән никадәр күндәм булмаган кешеләрне тугры юлга күндерерләр... *Кыл* дигәннең элеккесе (кыйл) сүз мәгънәсендә һәм икенчесе күндәм булмау мәгънәсендә.

Сөчүк ләфзы белә мури хирәдмәнд
Салыр зур аждәрһаның агзына бәнд.

Ягъни сөчүк (төче, татлы) сүз белән акыллы кырмыска (мури хирәдмәнд) олы аждаһаның авызыга бәнд (бау) һәм богау салыр, ягъни аннан морад: бер зәгыйфь кешедә татлы тел булса, ул төче теле белән олы мәртәбә ияләрен үгетләп, тугры юлга күндерер, чөнки Шәмгун хәзрәтләре Антакия җәмәгатенең кайберсен тугры юлга татлы сүз белән күндерде. Шулай булгач, мәгълүм булды ки, олы мәртәбә иясенә йомшак сүз белән халыкны нәсыйхәтләү лаек була.

Мөлаем гел белә бихәрб, бизарб
Берәүне килтерерләр шәркъдин гарб.

Ягъни төче сүз белән орыш (бихәрб — би хәрби), талаш (бизарб — би зарби) кылмыйча, бер кешене мәшрикъдан мәгърибкәчә[1] китерерләр. Аннан морад: йомшак сүз белән Аллаһ Тәгаләдән ерак булган бәндәләрне тугры юлга күндереп якын итәрләр.

Бу ирләр алмаен бер игнә (инә) кулга,
Салырлар ничә гөмраһларны юлга.

Ягъни бер төче теле белән ирләр, начар халәтләр (әйберләр; корАллаһр) алып, сугыш кылмыйча, бары тик йомшак сүз белән ничәмә азгыннарны (гөмраһларны) тугры юлга күндерделәр. *Игнә* мәгънәсе мәшһүр. Аннан мотлак («гомумән») сугыш һаләтенә истигарә алынды (киная кылынды).

Сөчүк телдер гаҗәб кәнҗә мөгъзәм (олуг хәзинә),
Гата (бүләк) кылган белә һич булмагай кәм.

Ягъни, кыскасы, төче тел гаҗәп олы хәзинә булып: аны кешегә сарыф итү белән кимеми[2] (кәм булмая); андый булса, мөселманнардан татлы телеңне кызганма, димәктер.

1 С.-П.да — мәгърибә (251 б.).
2 К.да — һич кәм (174 б.).

Димə хəрфи ки, булса би мəгани,
Əгəр тел һəрзəлек (буш) булса, тел аны.

Ягъни син, чын кеше булсаң, кешелəргə мəгънəсез сүзлəрне сөйлəмə, əгəр синең телең батыйль (буш), мəгънəсез сүзлəрне əйтүче булса, яргалап[1] ташла, димəктер. *Тел* сүзенең элеккесе лисан һəм зəбан (тел) мəгънəсендə, һəм икенчесе яргалау мəгънəсендəге сүз, һəр икесе төрки, *һəрзə* дигəне лəгу (мəгънəсез) һəм батыйль мəгънəсендə килə.

Кəлиде кəнҗə мəгъна кем зəбандыр,
Аңа бер нокта төшсə, күп зыяндыр.

Ягъни мəгънə хəзинəсенең ачкычы (кəлиде) — телдер. Ул ачкыч эченə бер кисəк яки башка (үзгə) нəрсəлəр керсə, күп зыяны булыр...

Кылыр катигъ тəкəллем (сөйлəм) уң эшең чəб (сул),
Сүзең текләб, күңел бозгунча текләб.

Ягъни каты сөйлəү уңга баручы эшне сулга борыр. Аннан морад: булырга торган изге эшне булмас итəр; андый булса, очлы нəрсə белəн теккəн кебек, каты сөйлəү күңелне җəрəхəтлəр. Кыскасы, энə һəм очлы əйбер белəн җəрəхəт ясаган кебек, каты һəм яман сүзлəр күңелне җəрəхəт кылыр. Лəкин энə җəрəхəте төзəлер, сүз җəрəхəте төзəлмəс, димəктер. *Текпəб* сүзенең элеккесе хариҗ (чыгып торучы) мəгънəсендə килə һəм икенчесе текмəк (тегү) мəгънəсендə була.

Əгəр сүз җанə пəйда кылмаса, сүл
Аны сүз димəгел, əй мəҗлесе əфрүз (нурландыручы).

Ягъни бер сүз җанны рəхəтлəндерүче булмаса, андый сүзне яндыр һəм көйдер, чөнки андый сүзне сүз димилəр. Əй мəҗлеслəрне нурландыручы кеше, димəктер. *Сүз* сүзенең элеккесе төрки, кəлимə мəгънəсендə һəм икенчесе — көйдер, фарсыча.

---

1 С.-П.да — йаргалаб вə телеб (174 б.).



www.darul-kutub.com

Әгәр сүсәң олугларның эшене,
Нәбат (татлы) ит тел, нәбат агыр кешене[1].

Ягъни син әгәр әүлияләрнең һәм әсфияләрнең (саф затларның) юлын сөйсәң, телеңне төче кыл һәм тизлек белән бул. Кыскасы, аларның юлын сөйсәң, барча адәмиләргә йомшак сүзле бул, димәктер. *Нәбат* сүзенең элеккесе асылда бер шикәр була, Һиндстан вилаятеннән килер. Монда төче мәгънәсенә метафора итеп алынды. Икенчесе тизлек үзренә, һәр икесе Харәзем сөйләме.

Суык әйгүнчә, әй халкы заманә,
Зәбанә хәүфедин миһер ит (шәфкать кыл), зәбанә.

Ягъни адәмнәргә суык-салкын сүз әйткәнче, әй замана халыклары, зөбани фәрештәләре газабыннан куркып, телеңә миһер китер, адәмнәргә салкын сүз әйтүдән тыелып кал, димәктер. *Зәбанә* сүзенең элеккесе зобани фәрештәләре дип әйтерләр һәм икенчесе тел вә лисан мәгънәсендәге сүз.

Чу Ногман мөһредә бу ирде мәктүб
Кол әл-хәйрү вәлло фасөкүт хуб.

Ягъни Имам Әгъзәм хәзрәтенең мөһерендә (печәтендә) бу сүз язылган иде: «Кол әл-хәйру вәллә фасөкүт хуб». Мәгънәсе шул була: сүз әйтсәң, изге сүзне әйт, андый булмаса, сүз әйтмичә тик тор, димәк.

Суык сүздин булыр иман карангу,
Зарардин үзгә юктыр, нәфгъ (файда) барму?

Ягъни, кыскасы, адәмнәрдә салкын һәм суык сүз әйтүдән иман нуры караңгы булыр; андый булса, ул суык сүзнең бер төк кадәр дә файдасы юк. *Муй* дигәне төк һәм чәч мәгънәсендә килә.

Беһәр җаи телеңне сакла, зинһар,
Кеше телнең яманындин булыр хар.

---

1 С.-П.да — нәбат ит, нәбат аграет (агыр ит?) кешене (252 б.).

Ягъни кайсы урында булсаң да (беһәр җаи), телеңне салкын сүздән сакла, зинһар. Чөнки яман тел сәбәбе берлә хур булырсың.

Яман тел гяһи (бер; әле) саргайтыр йөзеңне,
Түбән башыңны тилмертер, күзеңне.

Ягъни яман тел сәбәпле, йөзең сары булыр, башыңны түбән иеп, күзеңне тилмертер. Шуннан соң, ни мәшәкатьләргә очрасаң да, сиңа рәхим-шәфкать кулын сузмаслар[1].

Яман тел шомлыгы гяһ җанга оргай,
Гяһи җаныңдин үтеб, иманга оргай.

Ягъни, кыскасы, яман сүзнең шомлыгы җанга ора. Аннан морад: яман сүз сәбәбеннән үтерерләр һәм дә шул яман тел сәбәбеннән көферлеккә төшәрсең. Нәтиҗәдә, яман телеңне куй, диләктер.

Мөселман углыга яхшы кылк кыл,
Телеңне хуш, чыраеңны елык (ачык) кыл.

Ягъни андый булса, мөселманнарга яхшы холык кылып, йомшак сүзле бул; телеңне яхшы кылып, йөзеңне ачык кыл.

Агыздин сач йирендә дөрре мәгъни,
Әгәр булмаса, хамуш илә йәгъни.

Ягъни мөселманнарга авызыңнан мәгънә энҗесен чәч, әгәр андый мәгънә энҗесен чәчә алмасаң, сөйләмә — тик тор, адәмнәрнең сүзен тыңла.

Әгәр булмаса сәндә сүзгә йитмәк,
Нә дәүләтдер сөкүт итмәк (эндәшмәү), ишетмәк.

Ягъни, әгәр синең яхшы сүзне әйтергә хәлеңнән килмәсә, ни дәүләттер: тик торып, башкаларның сөйләгән сүзләрен ишетү, аннан гыйбрәтләр алу. Әс-

1 С.-П.да — ...хәлаек аңа рәхим-шәфкать кулыны сузмаслар (253 б.).

сөкүтү — ганимәтү (дәшмәү — зур байлык) моңа әшгарьдер («мисалдыр»).

Ишет әмма: кайу суз булса бәһрак (яхшырак),
Коланына аны хилка (алка) кылыб так.

Ягъни сүзләрнең барчасын ишетү тиеш түгел, әмма сүзләр ишетергә теләсәң, кайсы сүздә үгет-нәсыйхәт булса, шундый сүзне колагыңа алка (хилка) итеп так, ахырдан ул яхшы сүзне оныттма, аның белән гамәл кылучы бул.

Колак салма вәли (ләкин) бимәгънә сүзгә,
Ишетсәң, куб йирдән үзгә йиргә.

Ягъни син камил гакыл иясе булсаң, мәгънәсе юк файдасыз сүзгә колак салма. Әгәр бинагяһ (кинәт) андый файдасыз сүзләрне ишетсәң, ул урыннан башка урынга күч, андый сүзләрне тыңлама.

Колак, күздин, кулыңдин, паларыңдан (аякларыңнан),
Сорар таңда тәмам әгъзаларыңдай.

Ягъни кыямәт көнендә аяк һәм кулларыңнан һәм барча әгъзаларыңнан сорау алырлар: «Күзең белән ни өчен намәхрәмләргә карадың? Мин аны «Корьән»гә карау өчен ялраттым, һәм телеңне тәсбих һәм тәһлил әйтер өчен ярлаттым. Ни өчен намәхрәмләргә карадың һәм гайбәт һәм ялган сөйләштең?» — диер дә барча әгъзаларыңнан сорау алыр, димәктер.

Ишетсәң нәфгъ (файда) юк сүз, әй никү зат,
Аны һәм күшә (колакка) алмай күшә чык, йат[1].

Ягъни файдасыз сүзне ишетсәң, әй изге дәүләтле адәм, аны колакка алмыйча, бер почмакка (күшә) чыгып ят, аны тыңлама. *Күшә* сүзенең элеккесе колак мәгънәсендә килә һәм икенчесе почмак мәгънәсендә була; башка нөсхәләрдә «ят» урынына «бат» язылган. Баи мөвәххәдә (бер нокта) белән ул тәкъдирдәгечә ашык мәгънәсендә, һәр икесе төрки сүз.

---

1 С.-П.да — бат (255 б.).

Кеше сәнчак сүз әйтсә, сән чык андин,
Ямандин кач, ямандин кач, ямандин.

Ягъни бер кеше начар сүз сөйләсә, аннан морад: гайбәт һәм ялганчылык сүзләр әйтсә, ул урыннан чык, ул урында сүз озайтып торма, бәлки куәтеңнән килсә, ул сүзне кире как, сөйләшмә диген. *Сәнчак* дигәне начар сүз мәгънәсендә, Харәзем сөйләме була.

## Хикәяте Локман

Нәсыйхәт кылды фәрзәндигә (улына) Локман:
Сәңа җаһил кеше бәхәс итсә, әй җан.

Ягъни, Локман хәзрәтләре улы Кайдарга болай дип нәсыйхәт итте: «Әй җан, һәркайчан ки, синең белән кеше сүзгә килеп, бәхәс кылса, аңа ачуланып җавап бирмә», — диде. Әйтәләр: Локманның хакыйкатьтә чын исеме Борһан иде. Аллаһ Тәгалә төшендә хәбәр бирде: «Йа, Борһан, сиңа пәйгамбәрлек кирәкме, йә гыйлем хикмәте кирәкме?» — дип. Борһан әйтте: «Миңа гыйлем хикмәте кирәк. Пәйгамбәрлек эше авыр. Ул минем хәлемнән килмәс», — диде. Гыйлем хикмәтен сайлады, Локман дипаталды. Локман мәгънәсе күп фикерләүче, димәктер[1]. Улының исеме Кайдар иде. Гаять салих (изге) кеше иде. Әйтәләр: Локман мең яшәде, кайсы ике йөз егерме ел яшәде, дидәр. Фәләстыйн җирендә - дәфен кылдылар (күмделәр). Әйтәләр: Локман Сәрәндиптән (Цейлоннан) чыкты. Әйтәләр: Локман остадан сабак алмады, Аллаһ Тәгалә укымыйча гыйлемлек бирде. Әйтәләр: Локманның буе егерме аршын иде, кара чырайлы, арык тәнле иде. Әйтәләр ки, Локманның хатыны ике иде: берсенең бер аягы юк иде, берсенең бер күзе юк иде. Әйттеләр: Йә хәзрәт, ни өчен мондый ким әгъзалы хатыннарны алдың?» — диделәр. Җавап итеп әйтте ки: «Хатыннар ирләрдән (ир-атлардан) һәр нәрсәдә ким булсын, яшьтә һәм матурлыкта», — диде.

Локман хәкимнең гаҗәп хәлләре бик күп. Барын да яза торсаң, китап озын булыр.

---

1 К.да — димәк булыр (179 б.).

Җаваб әйгел аңа ширин (татлы) вә йомшак,
Мәгәр булгай җәһаләт хәмредин саг.

Ягъни Локман Хәким әйтте: «Әй улым, андый надан, сүзгә килеп бәхәсләшсә, җавабын төче һәм йомшак тел белән үзенә бир, шаять ки, ул надан кеше наданлык хәмереннән айныр, сәламәт булыр, чөнки надан ахмакка каты сүз белән җавап бирсәң, үпкәсе кабарыр, хакыйкать сүзне аңламыйча, төшенмичә калыр...

Әгәр нәфгъ (файда) итмәсә, кылма агадә (кабат),
Булыр әйгъән сари җәһли зийадә.

Ягъни ул надан ахмакка татлы тел белән җавап бирсәң; сүзең файда кылмаса, кабатлама, чөнки син кат-кат әйткән саен, ул наданның үпкәсе кабарыр, наданлыгы артыр, — диде.

Аңа сәүдә (файда) итмәсә әймаг савабы,
Сөкүт итмәкдер андин соң җавабы.

Ягъни ул надан кешегә синең тугры әйтүең файда (сәүдә) бирмәсә, бәлки үпкәсе кабарып булса, ул наданга җавап бирмичә тик тору (сөкүт итмәк) җаваптыр, — диде. Кыскасы, наданның сораган сүзенә — йомшаклык җаваптыр, ул сүз белән аңламаса — тик торудыр.

## Ике мөэмин бер-беренә хәйр кылу бәянында[1]

Кил, әй мөэмин, һәмишә хуш гинан бул,
Мөселман булса, һәркем миһербан бул.

Ягъни Аллаһының берлегенә ышанучы андый мөэминнәргә, мөселманнарга һәрдаим син яхшы ярдәм бирүче бул һәм һәрбер «мөселман мин» дигән кешегә шәфкатьле бул.

Ачылгай сән аны күргәндә гөлидәк (чәчәк тик),
Тәвазыйг (түбәнчелек) илә хезмәткяр колдәк (кол кебек).

---

1 С.-П.да — бу бүлекчә «Әмре магъруф нәһи Мөнкир бәяны» дип исемләнгән (256 б.).

Ягъни, кайсы гына мөселманнарны күрсәң дә, гөлчәчәк кебек ачылып, елмай һәм дә аларга алчаклык («игътибарлылык») кылып, хуҗаларның коллары кебек хезмәт күрсәт.

Саригъ йагдай (сары майдай) аңа булгыл мөлаем,
Сөчүклекне гасәл (бал) дәк әйла даим.

Ягъни сары май кебек мөселман кардәшләреңә мөлаем бул һәм дә мөселманнарга бал кебек татлы телеңне даими куллан.

Тот ул дустыңны сөт өстендә каймак,
Газиз җаныңны күргел, бәлки бәһрак (өстенрәк).

Ягъни син Аллаһ өчен бер дусны тотсаң, ул дустыңны сөт өстендәге каймак кебек тот һәм дә ул дустыңны газиз җаның кебек күр, бәлки артыграк та күр.

Ходаның боерыгындан тайса нагяһ (кинәт),
Борадәрлек ушалдыр кыйлсаң агяһ.

Ягъни синең Аллаһ Тәгалә өчен тоткан дустың, аңсыздан Аллаһның боерыгын куеп, юлдан язып, явызлыкка барса, синең кардәшлегең шул булыр: аны начар юлдан тый, аңлат һәм әйт: «Әй дустым, ни өчен мондый бозык юлга барасың?» — дип тәмле сүз белән үгет-нәсыйхәт бир.

Борадәр, җисмеңә җандәк йөгерсәң,
Тәләттыф (йомшаклык) берлә ул юлдан үтерсәң.

Ягъни мөселман карындашның тәненә җан кебек йөгер һәм йомшак сүз белән ул явыз юлдан коткарып кал, димәктер.

Тәләттыф берлә ул кем булмаса төз,
Сөчүклек рәштәсене (җебен) илекдин (кулдан) өз.

Ягъни, ул мөселман карындашың изге сүзең белән төзеклеккә килмәсә, ягъни изге юлга кермәсә, төчелек җебен кулыңнан өз, аннан соң каты сүз белән өндә.



www.darul-kutub.com

Әгәр чәндикә (шулай) кылмасаң миһербанлык,
Сәнең әйгъән сүзең белсә яманлык.

Ягъни мөселман карындашың син әйткән сүзең белән тугры юлга кермәсә, синең әйткән төче сүзеңне яманлык дип белсә,

Телең зәхме белән кылгыл җәрахәт,
Ойалыб, шайәд, әйткәй әстәбгад[1].

Ягъни син ачуланып, әйтүеңне игътибарга алмаса, моннан соң кулың белән ор (зарб әйлә): «Ни өчен мондый начар; ярамаган эшне кыласың»,— дип искәрт; ору белән куркыт.

Боларның барчасыдыр миһербанлык,
Тәрәххемдер (кызганудыр) аңа ирмәс яманлыг.

Ягъни ул мөселман карындашыңа бу әйтелгән нәрсәләрне эшләү - кылган изгелекләр дә, яманлык та түгел, аны, рәхим кылып, тәмуг юлыннан чыгару була.

Бу сәгый иткән белә ул булмаса төз,
Күрәрдә ашналигъ рәштәсен өз.

Ягъни бу кадәр тырышуың (сәгый иткәнең) белән ул мөселман кардәшең төзәлмәсә, аның белән шул күрешкәндә үк белешлек (ашналигъ) җебен өз, аның белән мөгамәлә кылма, чөнки фасикъдыр (бозык кеше ул). Фасикъ белән бергә утыру изге гамәлләрне юар (югалта).

Вәли батыйнда шагыйл (мәшгуль) бул догага,
Аның эхвалене салгыл Ходага.

Ләкин андый булса да, ул дустыңа Аллаһдан телән, изге дога багышла, ул дустың хәлләрен Аллаһ Тәгаләгә тапшырып тор. Чөнки ахырын Аллаһ Тәгалә үзе белер. Үзеңне суфыйдан дип белеп, аны җәһәннәм әһеленнән дип белмә.

---

1 Бу бәет һәм аңа шәрех С.-П.да күзгә ташланмый (257 б.).

Кеше кем булса мөэминлекдә мәүсуф,
Ирер важиб ул колга әмре мәгъруф.

Ягъни бер кеше мөэминлек исеме белән сыйфатланган икән, икенче кешегә важиб (туры килешле; тиешле) төче тел белән мөселманлыкка, изге эшкә өндәр (әмре мәгъруф) һәм дә явызлыктан тыяр.

Күзе юк мөэмин барыр иде раһ (юлдан),
Нәзар кылдың (карадың); аның алдындадыр чаһ (чокыр).

Ягъни бер күзе юк мөселман юл белән бара. Карадың: ул күзе юк мөселманның алдында козугдыр (кое). Аннан морад: надан мөселман бозык гөнаһ юлына барганны күрдең, аны туктатмасаң,

Хәбәрдар итмәсәң, улдыр хыянәт,
Кайу инсаф ирер, кайу дианәт

Ягъни ул күзсез мөселманга алдында кое бар икәнен әйтмәсәң, олы хыянәт — шул булыр. Болай иту кайда дин, кайда инсаф бирер. Аннан морад: бер надан кешенең бозык юлга барганын син әйтмәсәң, аңа төзек юлны күрсәтмәсәң — хыянәтнең олысы шул булыр.

Фәган, дад (үкенеч) Ушал бина кулындин,
Әгәр кайтармасаң дүзәх юлындин.
Ягъни ул мөселман кардәшеңне, чакырып һәм төзеклек кылып, бозык юлдан һәм тәмуг (дүзәх) юлыннан тыймасаң — хыянәт шул булыр...

Кеше йабса (корса) козуг агзыга чадыр,
Ничек диерсән аның дикне, борадәр!?

Ягъни бер кеше мөселманнар юлына кое казып, өстен ябып куйса, андый кешене кардәш дип ничек әйтерсең?! Аннан морад: галим белгән гыйльме белән халыкларга үгет-нәсыйхәт бирмәсә, галим түгел инде, бәлки хыянәт әһеленең олысы була. Нәтиҗәдә (кыскасы), әмре мәгъруф (тиешле гамәлне) кылу фарыз, тиеш. Галимнәргә заманына карап бету булмас... Пәйгамбәр г-м әйтте

ки: «Сез шәригатькә мөнкир (каршы) килгән эшләрне күрсәгез, кулыгыз белән ул эштән тыегыз. Андый булмаса, телегез белән, алай да булмаса, күңелегез белән», — диде. Әйтәләр: кул белән тыю мөфтиләргә һәм казыйларга тиешле. Тел белән тыю галимнәргә кагыла. Күңел белән тыю башкаларга кала. Гомәр бине Габделгазиздән килгән риваять. Пәйгамбәр г-м әйтте: «Бер җәмәгать берәүнең гөнаһ кылганына риза булып, әмре мәгъруф әйләмәсә («туктатмаса»), ул кавемнең барчасы гөнаһлы була. Гөнаһлары да уртак булыр», — диде.

Хәзрәте Йушәгъ бине Нунга Аллаһ Тәгалә бер көн вәхи (хәбәр) җибәрде, әйтте: «Йә Йушәгъ бине Нун, син бу шәһәрдән чык, чөнки мин синең кавемләреңнән алтмыш мең явызларны һәлак итәрмен, — диде. — һәм дә кырык мең изгеләрне һәлак итәрмен», — диде. Йушәгъ бине Нун әйтте: «Йә Рабби, явызларны һәлак итүең хактыр, әмма изгеләрне ни өчен һәлак кылырсың?» - диде. Раббыдан җавап килде ки: «Изгеләрне шуның өчен һәлак кылырмын: явызларның гөнаһ кылганына риза булганнары өчен; алар белән бер мәҗлестә утырып ашадылар һәм эчтеләр, шуның өчен һәлак кылырмын[1]», — диде. Кыскасы, әмре мәгъруф (тиешле гамәлләр өйрәтеп) һәм яманлыктан, гөнаһыдан тыймый торган галим — монафикътыр, ике йөзле кеше була...

Вәләкин әмре мәгъруф әйлагән мәрд (кеше),
Үзе булгай гамәллегъ сахибе дәрд.

Ягъни әмре мәгъруф сахибе (тиешле гамәлләр иясе) әйткән сүзендә торучы була һәм дә ахирәт кайгысында була. Әгәр андый булмаса, кешеләргә үгетләп биргән сүзе тәэсир итмәс.

Әгәр әмер имәс расих эшигә,
Кайчан тәэсир итәр үзгә кешигә.

Ягъни изгелеккә боеручы кеше, боерган эшендә сабит (нык) булып, гамәл кылучы булмаса, андый кешенең боерган сүзе кешеләргә тәэсир итмәс...

---

1 С.-П..да — бу соңгы җөмлә юк (259 б.).

Безеңдик шәрм юк, инсаф юк җисем,
Башында мәгыз (ми), мәгънә юк, коруг исем.

Ягъни безнең кебек әйткән сүзендә тормаганның ояты (шәрм) юк, инсафы юк, башында акылы юк, андыйлар җиһанда күп шул. Кыскасы, назыйм (шагыйрь) әйтте: «Әмре мәгъруф — тиешле гамәлләр кылдык, ләкин без ул сүзебездә тормадык, безнең кебек булмагыз», — дип әйтүе инде.

Эшемездер рийа вә хәйлә, вә тәзвир (ялган),
Кыйлыр әйгъән сүземез кемгә тәэсир.

Ягъни безнең тиешле гамәлләр һәм тыеп кылган эшебез хәйлә һәм алдау өчен булды. Шулай булгач, безнең әйткән сүзебез һичберәүгә тәэсир итмәс.

## Күзне харамнан йомуның бәяны

Кил, әй мөэмин, әгәр тәрсәндә (куркучы) булсаң,
Күзеңне саклагыл һәр канда (кайда) булсаң.

Ягъни, әй мөселман, кил, боерган вәгазь-нәсыйхәтне ишет, ул нәсыйхәт шушы була: син һәркайсы урында булсаң да, Аллаһтан курыксаң, күзеңне кардәш түгел кызлардан һәм хатыннардан сакла, һәм аларга карама.

Кави (нык) булсын һәмишә (һәрчак) ноктаи чәшм,
Мәбадә булмагай бала төшеб чәшм.

Ягъни син мөэминнең күз алмасы (нокт[а]и чәшм) намәхрәмнәргә карамаска куәтле (кави, көчле) булсын, димәктер, чөнки аңсыздан (бала) намәхрәмләргә күз төшеп, Аллаһның ачуы булмасын (мәбадә булмагай)... *Чәшм* дигәне сүзнең чим (чим хәрефенең) нокт[а]сы төшеп, хәшм сүзенә әйләнмәсен. Әүвәлге мәгънәчә бу сүз күз алмасына истигарә (метафора) алынды. Һәм икенче мәгънәчә нокт[а]и хакыйкый мәгънәсендә аңлатылды (китерелде).

Нәзар кылгунча берай[1] нәфес мәгъйуб,
Төшеб күз нокт[а]сы күр булганы хуб.

---

1 С.-П.да бу өлеш болай бирелгән: « Андан тәҗавез әйлаб, нәмахрәмләргә карар улсаң, кыямәт көнендә үкенеч сәңадыр» (261 б.).

www.darulkutub.com

Ягъни бер кешенең харам булган (мәгъйуб) хатынларга изге күз алмасы (күз ноктасы) төшеп күргәнгә караганда, сукыр (күр) булуы, яхшыдыр яки... күзең андый гөнаһылы булганчы күрмәсен. *Күз* сүзенең мәхү булып (төшеп, бетеп), күр сүзе булуы, димәк.

Сәгадәтлек нәзар булса кадәмдә,
Тәҗавез әйлагәч (ярамаганны эшләгәч) булса нәдәмдә (үкенечтә).

Ягъни, синең каравың аяк астына (кадәмдә) юнәлгән булса, изге дәүләт шунда булыр. Һәм намәхрәмнәргә караганнан соң, үкенеп тәүбә итүче булсаң, изге дәүләттер[1].

Әгәр кане чәшмә булса, чәшмәи әйммәһ (иманлы),
Хәтарлек йиргә төшкәндән ирер бәһ.

Ягъни бер күз канлы булса, намәхрәмнәргә караган таза күздән ул күз мең дәрәҗә (мең тапкыр) артыктыр, ягъни синең күзең сәламәт булып, намәхрәмнәргә карап, ләззәт алыр булсаң, аның күрә торган күз булганыннан булмаганы яхшырак (ирер бәһ), аның күз булганында файда юк. Ахыры синең андый күзең кыямәт көнендә газап күреп кан алыр, димәктер.

Нә хушдыр дидәи тәрсәндә булса,
Вә гәр нә килсә сәндан кәндә (үзеңдә) булса.

Ягъни гаҗәп яхшы булыр андый күзгә (дидә): Аллаһ Тәгаләнең газабыннан куркып (тәрсәндә булып), нәмәхрәмнәргә карамаса. Әгәр андый булмаса, күз бәбәгеннән күзең алмасы чыгу изгерәк саналыр.

Хәтардин йом күзең, углан, хәйфә,
Ничек йомды куркыб бу Хәнифә.

Ягъни, андый булса, күзеңне намәхрәмнәрдән йом, аларга карама. Күрмисеңме, Аллаһ Тәгаләдән куркып, ничек Имам Әгъзам хәзрәтләре (Хәнифә) йомганны.

2 К.да — кани (168 б.).

Әйтәләр: Хәзрәте Әбү Йосыф яшь заманында күркәм егет иде. Имам Әгъзам хәзрәтенә сабак алырга барыр иде. Имам Әгъзам хәзрәтләре, Әбү Йосыфны артына куеп, сабак өйрәтер иде, гаять күркәм булганы өчен, аның йөзенә карамас иде. Әй газиз карындаш, аңла ки: Имам Әгъзам шундый тәкъвалык белән яшь егетләргә карамады, күзен саклады. Бездә кайда булды инде саклану, шул сәбәпле ишарәт кылып боерды:

Йөрәгем саф ирер диб ормагыл лаф,
Алар дәк булмагайсән, кил гер инсаф.

Ягъни әйтмә ки, мин намәхрәмнәргә карасам да, зыян юк дип, минем күңлемдә шәһвәт тарикы (җенси дәрт) юк, димә, чөнки Имам Әгзам кебек түгелсең. Шулай итеп, Имам Әгъзам хәзрәтләре шулкадәр суфыйлык белән күркәм йөзләргә караудан сакланды. Син никадәр сабыр һәм суфый булсаң да, алар кебек булмассың, инсафка кил, диләктер.

Карарың куймасаң илтеб карарың,
Алыр шәйгане зәманә ихтыярың.

Ягъни чөнки син намәхрәмнәр йөзенә каравыңны куймасаң, бәлки даими карауда булсаң, сабырыңны өзеп, шәйтане ләгыйнь сабырлык тезгенен алып, зинага этәргеч кылыр. Күп каравың белән зинага төшәрсең, диләктер. *Карар* сүзенең элеккесе нәзар һәм карау мәгънәсендә була һәм икенчесе сабыр мәгънәсендәге сүз.

Бакасыз мәгъсыйәтләргә бакасыз,
Ничек үз җапыпызга ут йакарсыз.

Димәк, андый булса, әй адәмнәр, фани булган гөнаһларга карарсыз, чөнки намәхрәмләрнең йөзе никадәр күркәм булса да, аннан никадәр ләззәтләр алсаң да, фани (вакытлы). Андый булса, намәхрәмнәр йөзенә каравыгызда ни файда, бәлки үз җаныгызга золым кылып, үзегезне үзегез җәһәннәм утына ягасыз, диләктер. *Бакасыз* сүзенең элеккесе фани мәгънәсендә килә һәм икенчесе карау мәгънәсендә була.

www.darulkutub.com

Бинагяһ төшсә намәхрәм күзгә[1]
Икенче бакмагыл, зинһар, у(л) йөзгә.

Ягъни аңсыздан (бинагяһ) бер намәхрәм хатынның йөзе күзеңә төшсә, зинһар, аның йөзенә кире карама, чөнки ул аңсыздан йөзенә каравың душ (туры) килгәнендә, гөнаһ юк иде, бәлки икенче кат (тапкыр) каравың гөнаһы булыр.

Икенче чөнки шәһвәтдән хәтардер,
«Нәһайә» кем китабе мөгътәбәрдер.

Ягъни намәхрәмгә икенче тапкыр каравында теләк булыр, әмма ул женси дәрт юлы. Һәм дә «Нәһайә» (бетем) дигән китапта китерелгән нәтиҗә яса дип:

Диде кем башка намәхрәм йөзигә,
Коярлар таңда кургашын күзигә.

Ягъни «Нәһайә»дә әйтте ки, берәү намәхрәм хатынның йөзенә женси дәрт белән караса, кыямәт көнендә ул караучының йөзенә эссе кургашын коярлар. Соббу Аллаһ Тәгалә собба дигәне моңа әшгарьдер («мисалдыр»).

Бөтебдер шәргыда ул сахибе бәзел (юмартлык иясе),
Кеше кем кылса намәхрәм белә һәзел («шаяру»).

Ягъни «Шәригател-ислам» дигән китапның сахибе язган (бөтебдер): берәү, ят хатын белән уйнап, сөйләшеп утырсалар,

Аның һәрбер сүзигә, әй херәдмәнд. (акыл иясе),
Булыр дүзәхдә та мең елгача бәнд.

Ягъни ул намәхрәм хатын берлә уйнап сөйләшүченең һәрбер сүзе өчен мең ел тәмугта калыр, диде.

Әгәр ул илтизам итсә хәрамә.
Йәнә ул нөсхәдә язылды хамә (каләм).

1 К.да — намәхрәмгә күзгә (181 б.).

Ягъни уйнап сөйләшүче харам кылуны үз өстенә (илтизам) йөкләсә, ягъни зина кылырга теләсә, алар хакында гына ул «Шәригател- ислам»да каләм тартылып болай дип язылды:

Кыямәт көн ки[1] дадгәр итәрләр,
Аны шәйтан илә зинҗир итәрләр.

Кыямәт көн андый зина кылучыларга гадел хөкем (дадгәр) итәрләр. Гадел хөкем шул: ул зина кылучыны шайтан белән бергә зинҗирлаб (чылбырлап) илтерләр.

Ләгыйнь шәйтан ки булгай дошмане шәх[2],
Аның берлә булыр мәдхул дүзәх.

Ягъни шайтан ләгыйнь каты дошман (дошмане шәх), ул зина кылучыны аның берлә бергә тәмугка кертерләр (мәдхул дүзәх), — диде.

«Хөласа» вә «Хәзанә» вә «Шәрхе әүрад»
Бөтебдер бәлки чәндин нөсхәдә йад.

Ягъни «Фәтавийе хөласа»да («Хөкемнәрнең нәтиҗәсе»ндә) һәм янә «Хәзанэтел-фәтавийә»дә («Фәтваләрнең туплямында) һәм «Шәрхел-әүрад» («Догаларның шәрхе») дигән китапларда болай дип язылган:

Җәван (яшь) хатынга намәхрәм имешдер,
Сәлам әйтмәк аңа манигъ димешдер.

Ягъни ул китапларда әйтелде: бер хатын яшь булса, үзе намәхрәм булса, андый хатынга сәлам бирү харам, диделәр.

Биреб булмас җаваб әйтсә сәлами,
Ирер гаурәт аның соут кәлами.

Ягъни ул намәхрәм сәлам бирсә, аңа сәлам җавабын кайтару харам, диделәр. Чөнки ул яшь хатынның авазы

---

1 С.-П.да — кыямәт көнең (263 б.).
2 С.-П..да — шах (263 б.).

(соуты) гаурәт, әйткән сүзе батрикы әүла (һава кебек өстен), сүзе харам.

Җәван хатын кабахәт (оятсыз) булса аваз,
Кабахәтдер кеше кем булса дәмсаз (якын).

Ягъни бер хатын яшь булып, авазы яшь булса, кайда булды ки ул гаурәт белән сөйләшү?! Әлбәттә, дөрес түгел. Равиләр (сөйләүчеләр) әйтә: карт хатынга сәлам бирү урынлы, диделәр. Әмма карт хатынга сәлам бирүдә ике фикердәге мәзһәб бар. Кайберләр әйттеләр: карт хатынның сәламен кайтарсаң ярый, диделәр. Һәм кайберләр кайтармаска, диделәр. Әмма фәтва шул булыр: заманасына карап кирәк. Әмма безнең бу заманада галимнәрнең бердәм килешүе белән кайтару урынлы түгел.

Кара, әй адәм, сакла үзеңне,
Ки намәхрәм сарый (тарафына) салма үзеңне.

Ягъни, әй адәм уллары, кыскасы, үзегезне үзегез саклагыз, Аллаһның газабыннан куркып, намәхрәм хатынларга күзегезне салмагыз.

Ки намәхрәм сарый бакгунча би къил,
Бәһ ул ки күзләренә тартсалар мил.

Ягъни андый намәхрәмләргә караучыга, шиксез, күзләрегезгә тимер калакны тарту изге эш булыр. *Мил* дигәннәре асылда бер калак (зур кашык). Җәзаланасы кешенең күзенә, күзне китәрү (күзгә сугу) өчен, капмакаршы тотарлар.

Бу дөнья миле үткәй бер зәманда,
Кыямәт миледин тоткай әманда.

Ягъни чөнки бу дөньяның суккан калагының газабы кайчан да булса бер үтәр һәм кыямәт калагының газабыннан имин булмассың.

Кыямәт көн гаҗәб шиддәтле көндер,
Аның алдында адәм углы сәрнегүндер.

Чөнки кыямәт көн гаҗәп каты (шиддәтле) көндер: адәм уллары баштүбәндер (сәрнегундер).

Кызар күк фәркъ сәрасигъда чүн тас,
Булыр сәркәштәләр пәрванә тик тас.

Ягъни ул кыямәт көнендә бар җирләр ут кебек кызар һәм дә адәмнәрнең башлары кыямәт эсселегендә бакыр тас кебек кайнар һәм дә ул көн гөнаһлы сәркәши (буйсынмаучы) коллар күбәләк (пәрванә) кебек очарлар. *Тас* сүзенең элеккесе - бакырдан ясалган бер савыт. Һәм икенчесе очу мәгънәсендә килә, госмания төрекләре сөйләме.

Тикәр утдик[1] астында туфрак,
Булыр йондик зәмин астындагы таг.

Ягъни кыямәт көнендә аяк астындагы туфрак ут кебек эссе булыр һәм дә җир (зәмин) йөзендәге таулар һавада йон кебек очарлар...

Булыр күб халык үзедин халедин еир,
Бу гамьдин та ки күрдекләр булыр пир.

Ягъни ул кыямәт көнендә халыклар барчасы үз хәленнән үзе тук булыр. Аннан морад: үзләрен үзләре сөймәсләр һәм дә кыямәт көненең мәшәкатьләре кайгысыннан нарасида[2] (сабый) балаларның чәчләре агарыр...

Яшермәк булса кайсы ру сийаһлык,
Элек сүзләб, аяк биргәй гуаһлык.

Ягъни кыямәт көнендә кара йөзле (русийаһлык) булучы адәмнәр гөнаһларын яшерергә теләсәләр, куллары һәм аяклары гөнаһларыннан хәбәр бирерләр, чөнки ул кыямәт көнендә аларның авызларына мөһер (печәт) орырлар, сөйләшә алмаслар, бәлки авызлары урынына куллары һәм аяклары гуаһлык (шаһидлек) бирерләр...

---

1 С.-П.да — утдак (264 б.).
2 К.да — барысы да (183 б.).

Тәмам әгъзаларын дәгъва кылырлар,
Хәлаек алдыда рисвай кылырлар.

Ягъни ул кыямәт көнендә барча әгъзаларың безне «ни өчен харам урыннарда сарыф кылдың» дип дәгъва кылыр. Халыклар алдында һәм бабаң алдында һәм атаң алдында, гөнаһларыңны әйтеп, рисвай (хур) итәрләр.

Ул көн дәгъваченең һич саны булмас,
Пәшиман булгай, әмма нәфгъ (файда) булмас.

Ягъни ул кыямәт көнендә дәгъвачеләрнең хисабы булмас һәм дә ул көндә үкенүнең файдасы булмас, чөнки үкенү, тәүбә өчен урын — дөнья.

Аның дик[1] вакыйгалардан борынраг,
Үзеңне әйлә гафләт хәмредин саг.

Ягъни кыямәт көне башка килмәстән элек, дөньяда вакытта гафиллек (ваемсызлык) хәмрендин (эчемлегеннән) сәламәт бул һәм нинди гөнаһларың бар, — дөньяда вакытта тәүбә һәм истигъфар кыл.

Пәшиман булсаң ул кылмышларыңдай,
Дел-җан берлә йансаң эшләреңдәй.

Ягъни дөньяда вакытта кылган гөнаһларыңнан үкен һәм дә күңел (дел-җан) белән ул кылган гөнаһ эшләреңнән кайт.

Ни булгай кем кабул итсәң, Ходаем,
Кыямәт шивдәтен (газабын) итсә мөлаем,

Ягъни дөньяда вакытта гөнаһларыңа тәүбә кылуыңны, шаять ки, Ходаем кабул итәр һәм дә кыямәт катылыгын хуш һәм җиңел кылыр.

Кайу колны Ходаем итсә мәмнүн (разый),
Булыр юлбашчы пәйгамбәр ул көн.

---

1 С.-П.да — аның дәк (265 б.).

Ягъни кыямәт көнендә Ходай Тәгалә, кайсы колын ярлыкап, оҗмах нигъмәте белән хөрмәтләргә теләсә, ул көн оҗмахка барырга юлбашчысы булыр.

Башында сайә булгай гарше[1] әгъзам (биек агач),
Фәрештәләр күңел биргәй дәмадәм (һәрчак).

Ягъни ул колның башында кыямәт көнне олы гареш күләгә (сайә) булыр һәм дә фәрештәләр ул колга, сулаган саен, рәхмәт сөенече бирерләр.

Әйтәләр: ул гареш күләгәсендә торучылар алты гөруһлардыр (төркем). Әүвәлгесе шаһидләр, икенчесе газыйлар, өченчесе хаҗилар, дүртенчесе мөдәррисләр, бишенчесе мөэзиннәр, алтынчысы намәхрәмнән күзен саклаучылар.

Гыйнәйәт намәсен кулга алырлар,
У(л) көннең үткәнен тоймай калырлар.

Ягъни кыямәт көнендә изгеләрнең, намәхрәмнән күзне саклаучыларның гамәл дәфтәрләре (намә) уң кулдан бирелеп ярдәм булыр. Аларга кыямәт мәшәкате сәһл (җиңел) булыр, ул көннең мәшәкатен күрмәс, тоймый калырлар.

Иляһи, барча мөхлисләр белән йад
Бу колны әйлагел ул көндин азад.

Ягъни, йә Рабби, рәхмәтең белән бу колыңны ихласлы бәндәләр (мөхлисләр) төркеменнән кабул итсәң иде һәм дә бу колыңны кыямәт көненең мәшәкатьләреннән азат кыл, дип назыймның (автор) дога кылуы булыр.

## Хикәяте шәех Бистами[2]

Кариган пәлләсендә шәех Бистам,
Үзедин сагать китде бер әхшам.

1 С.-П.да — шаһ (265 б.).

2 Шәйх Баязид Бистами (875 елда вафат була) — Шәрык дөньясының атаклы суфые. Чыгышы белән Ирандагы Бистам төбәгеннән. Үзенең фәна, ягъни Алла белән кушылу, үз-үзеңне оныту турындагы карашлары белән мәшһүр. Шәйх Бистаминың фарсыча әйтелгән фикерләре төрле хезмәтләрдә урын алган.

Ягъни хикәят әйтәләр: шәех Баязид Бистами картайган заманында бер ахшам вакытында һушы китеп егылды. Бер сәгать микъдар һушсыз булды. *Пәллә* дигәне асылда бер мыскал үлчәвенең бер табагы. Монда картлык заманына күчерелмә мәгънәдә алынды. Чөнки гомернең һәм мизан (үлчәү) кебек ике өлеше, ягы бар: берсе егетлек, берсе картлык. Бу метафораны күчерелмә мәгънә[1] диерләр, фән әһеленә хәфи (яшерен) түгел.

Үзигә (үзеңә) килде ирсә, әйде әсхаб,
Нәгу булдың моның дәк, әй дөрри наб.

Ягъни хәзрәт Баязид Бистами бер бераздан соң, акылына килгәч, мөридләр әйттеләр: «Йә хәзрәт, ни сәбәп белән моның кебек һушсыз булдың?» — диделәр. *Нәгу* (нәгъву) дигәне бу урында сәбәп мәгънәсендә килә. Харәзем сөйләменнән алынган. *Дөрр* энҗе мәгънәсендә алынган. *Наб* саф мәгънәсендәге сүз[2]. Рифма өчен назыйм бәеттә китерде.

Диде: «Балигъ булыр халәтдә бер раһ,
Күземә бер җәмилә төшде иагяһ».

Ягъни Баязид Бистами әйтте: «Минем һушсыз булуым шуның өчендер: яшь егет (балигъ) заманында юлда (раһ) барганда, күзем бер күркәм кызга (җәмилә) төште.

Йаныб бары дигәр (кабат) салдым нәгяһым (карашым),
Чыкыб ирде исемдән ул гөнаһым.

Ягъни ул күркәм кызга, аның күркәмлеген күреп ләззәт алыр өчен, икенче тапкыр әйләнеп карадым. Ул заманда караган гөнаһым бу замангача хәтеремнән чыккан иде, — диде.

Исемгә хала (шулчак) төшде ул нәзарә (караш),
Йөрәгем булды куркыб парә-парә.

Ягъни ул егет заманындагы гөнаһым инде хәзер хәтеремә

1 С.-П.да — мәккия (266 б.).
2 С.-П..да — дөрр наб сүзләренә аңлатмалар юк (266 б.).

төшеп, Аллаһ Тәгаләнең газабыннан куркып, йөрәгем пара-пара булды, һушсыз булуым шуннандыр, — диде.

Мөбарәк агзыдин күб тамды каны,
Ушал хәуфилә ахыр чыкты җаны.

Ягъни Баязид Бистами хәзрәтләре Аллаһ Тәгаләдән куркуыннан мөбарәк авызыннан каннары тамды һәм дә шул күркәм намәхрәм кызга карау гөнаһысының куркуыннан җаны чыгып шәһид булды. Әйтәләр ки, Баязид Бистами Бәлх шәһәренең янында Бистам атлы авылныкы иде. Мансур Хәллаҗның мөридләреннән иде. Гаять суфый кеше, нәселе муг (утка табынучы; зәрдәшт динен тотучы) иде[1]. Күбрәк торуы Багдад иде. Гомәр атлы кешенең улы иде. Җиде яшендә «Коръән» белде, егерме алты яшендә гыйльме ләдән (югары дәрәҗәдәге дин белгече атамасы; теолог) бирелде. Җәһрия тарикыны (юнәлешен) тотар иде.

Әйтәләр: Баязид Бистами, алтмыш яшендә вафат булып, күркәм Сәмәркандта дәфен кылынды (күмделәр).

* * *

Моның дәг егласа андаг никүрай,
Безнең дәк русияһнең (кара йөзнең) халенә вай.

Ягъни андый әүлия (никурай) бер каравы белән бу кадәр еласа, Аллаһдан курыкса, безнең кебек кара йөзлеләрнең хәле ничек булыр?! Чөнки ничә маккярә (мәкерле) намәхрәмнәргә карыйбыз. Хәлебез ничек булыр, димәктер.

Һәмишә зәукымыз гыйш-көлешкә,
Йитешмәс иртә кылган тәүбә төшкә.

Ягъни безнең дөньяда даими ләззәтләнүебез нәфес-һәваларыбызда һәм көлүдә, ахирәт фикере юк һәм дә тәүбә итсәк тә, тәүбәбезне сындырып, залалэт (түбәнлек) юлына барабыз.

---

1 Мансур Хәллаҗ чынлыкта Бистамидан соңрак яши (якынча 858 — 922 елларда). Бистаминың остазы — Әбү Гали әс-Синди дигән зат.

Үтәр дөнья эшен тотдым мөкаддәм (алдан),
Ганаһ әйнүкасы күб, куркынычымыз кәм.

Ягъни без дөнья эшләрен Аллаһ Тәгалә боерган әмерләргә итагать итмәдек, гаҗәп, бәлки, гөнаһларыбыз ким һәм аздыр? *Әйнүкасы* дигәне кәлимәи тәгаҗҗебдер (гаҗәпләнү сүзе). Бохара халкының сөйләменнән, күп нәрсәләрне әйнүкасы (инүкасы?) дип гәҗәпләнерләр.

Ходавәндә, үзең сән галәме гайб,
Мәни мескиидәдер һич саны юк гайб.

Ягъни, йә Рабби, үзең син гаебтәге (күренми торган) хәлләребезне белүчесең. Мескен Аллаһийар колыңда хисапсыз гаепләр бар. Рәхмәтеңне бир, димәктер.

Гөнаһы биңиһайәт (чиксез) бәндәдер ман,
Бүген шәрмәндә чөн шәрмәндәдер мән.

Ягъни мин колың Аллаһийарның гөнаһысы чиксез, бу дөньяда гөнаһыда булып ярен (иртәгә) — кыямәт көнендә оятлы мин. *Шәрмәндә* сүзенең элеккесе ике телдән ясалган: *шәр* сүзе гарәпчә, явыз мәгънәсендә килә һәм *мәндә* төрки; икенчесе фарсы: оят һәм хәйа мәгънәсендә кулланыла.

Габәс берлә (юкка) кулымдан китте вактым,
Гамәл мәһрен (кояшын) яшерде әбре мәкатем.

Ягъни мин — колың, батыйль (начар) гамәлләр белән кулымнан тәгать вакытын үткәрдем, гамәл кояшын ачы болыт (әбре мәкатем) белән капладым, асылда тәгать һәм гыйбадәт кылырга хәлемнән килмәде. *Мәһр* дигәне кояш мәгънәсендәге сүз, Харәзем сөйләменнән[1] була. *Әбр* болыт мәгънәсендә килә. Фән әһеленә мәхфи (билгесез) түгел.

Бәнем җөрмем (гөнаһым) бигадәд (чиксез) улса гәр чәнд[2],
Хәҗабе мәгъфәрәт (ярлыкау пәрдәсен) яб, әй Ходавәнд.

---

1 С.-П.да — гарәбидер (286 б.).
2 К.да — җөримем бигадәдә булса әгәр чәнд (185 б.).

Ягъни, йә Рабби, әгәр минем гөнаһым хисапсыз булса да, ярлыкау пәрдәңне ябып, гафу кыл, кыямәт көнендә гөнаһсыз коллар кебек ит.

Җуыб рәхмәт белән вәҗһем (йөзем) карасын,
Насыйб ит барча нигъмәтләр сәрасын[1].

Ягъни, йә Рабби, рәхмәтең белән йөземнең карасын гафуың суы белән юып, безгә нигъмәтең гәзидәсен (сый, хөрмәт) насыйп кылсаң иде. *Сәрасын* саф һәм гәзидә мәгънәсендә килә...

Кил, әй азадә, вакыйф бул күңелгә,
Күңел юлбашчысыдыр корбәтле (якын) юлга.

Ягъни, әй азат кеше, күңел серләренә хәбәрдар (вакыйг) бул, чөнки күңел булыр Аллаһ Тәгаләгә якын булу юлын башлатучы. Кыскасы, бу тарикать юлының олы башчысы күңел. Күңелең кошын Аллаһ Тәгалә сарый (тарафына) юнәл.

Тәфәккер кошыны һич кылма заил,
Пәләгъдә[2] булмагай та бәйзаи дил

Ягъни, әһеле сөлүк (суфыйлар) булучы, фикер кошын һичбер вакыт Аллаһ Тәгаләдән аерма (заил кылма), һәрчак фикерең Аллаһ Тәгаләдә булсын, көдүрәт (көенечле) тәкәбберлек (мин-минлек) һәм хөсед (көнчелек) белән булмасын, чөнки шәберчек йомыркада файда юк, андый бер күңелдә тәкәбберлек һәм хөседлек булса, файда юк. *Пәлэгь* дигәне шәберчек, чеби чыкмый калган йомырка була. Харәзем халкының сөйләменнән алынган. Монда хөсед (хәсәд-көнчелек) мәгънәсендә килә...

Тәфәккере морг даим булса дәмсаз (дус),
Өмнд улдыр ки, андан очса шәһбаз.

Кешенең күңеле һәм фикере даими Аллаһ гыйшкында булса, андый күңелдә әнваг (төрле) көшүфат вә

---

1 К.да — сәзасын (185 б.).
2 С.-П.да — бәләгъда (269 б.).



www.darul-kutub.com

тәҗлилать («ачышлар һәм нурлар») хасыйл булу өметле, димәктер.

Аның дәк базины чөн әйладең[1] кайд,
Күңел кошларыны кылса, булырмы сайд (аулау)!?

Ягъни, аның кебек карчыганы (базины) багласаң, аннан морад: зикерләр белән көшүфат мәкамын (ачышлар урынын) тапсаң, мөридләр тәрбия итү мөмкиндер, гайреләрнең күңел кошларын ауларга булыр (күңелләрен җәлеп итәргә кирәк мәгънәсендә). Әгәр ул булмаса, мөрид тәрбия итү кайда!?. Җиде зикер тәмам булмыйча, кайберләрнең хәлен белү мөхальдер (мөмкин түгел), суфыйларга болар мәгълүм.

Күңел һәргяһ (чак) салахиятдә булса,
Табар бәндә кайу ниятдә улса.

Ягъни, нәтиҗәдә, һәр нәрсәләрнең хасыйл булуы күңелдә бит, чөнки кайсы эштә булса, ягъни кайсы эшең касдендә (ниятендә) булса, әлбәттә, бәндә аны тапса кирәк. Мәсәлән, даими Аллаһны сөюдә булса, Аллаһ ризалыгын табар. Явыз гамәлләрне сөйсә, гарчә суфый сурәтендә булса да, явызлар гөруһыннан булыр, чөнки күңел падишаһ һәм калган әгъзалар гаскәр кебек.

Һәммә әгъза рәгыятьдер (буйсынган халыктыр), күңел — шаһ,
Әманлигъ булгучы шаһ гаделдән раһ.

Ягъни, синең барча әгъзаларың гаскәр кебек, кайчан падишаһ тугры юлга үзе барса, әлбәттә, гаскәре аның артыннан бара инде, андый күңел Аллаһ гыйшкында булса, башка әгъзалар да һәм гыйшык (гашыйк) булса кирәк.

Әгәр солтан үзе кылса йаманлигъ,
Кайчан булгай рәгыйятьдә әманлигъ!?

Ягъни, бер падишаһ элек үзе караклык һәм харамлык

---

1 К.да — әйләсәң (186 б.).



www.darulkutub.com

кылса, андый падишаһның гаскәренә иминлек (тынычлык) булмас. Анын кебек әүвәл күңел бозык юлга ниятләсә, әгъзадарда төзеклек булмас, каян килсен.

Күңел хуш итмәсә, күз булмагай нәм (яшьле),
Чыкармы кырга[1] су, ташмаса йәм (елга).

Ягъни, кайвакытта (кайчак) безнең күңелебез гыйшкы Хода белән кайнамаса, күзебездән яшь килмәс, чөнки дәрья ташымыйча, яланга су чыкмас. Андый хакыйкый гыйшык (чын, ягъни иляһи гыйшык) булучы кешедә, әлбәттә, Аллаһ Тәгаләнең куркуыннан күзеннән яшь чыкса кирәк. *Нәм* дигәне асылда чык мәгънәсендә килә. Монда күз яше мәгънәсенә метафора итеп алынды. *Йәм* (йәмм) дигәне дәрья мәгънәсендәге сүз.

Ишеткән сән аны булса[2] нәзаргяһ,
Нәзаргяһ күңел бер булса һәр гяһ (чак).

Ягъни син олылардан әсраре мәгърифәт[3] (мәгърифәт серләре) сүзен ишеткәнсең: ул ишеткән сүзеңне урынына куй. Урынына куюың шул булыр: ул сүзне күңел белән кабул ит, әгъзаларың да ишеткән сүзең белән гамәл кыл. *Нәзаргяһ* сүзенең элеккесе күңел мәгънәсендә була һәм икенчесе кабул итү мәгънәсендә килә.

Йөкерсә ул күңел һәр тарафка,
Качан лаек'булыр андаг шәрәфкә.

Ягъни синең күңелең теләсә кайсы тарафка йөгерсә, Аллаһ Тәгалә хәзрәтенә лаек булмас. Андый бердүнең күңеле дөнья мәхәббәтендә булса, чөнки ике мәхәббәт бер җиргә сыймас (җыела алмас).

Күңел дәрсене дирләр: хуш сабакдыр,
Тәмами мәгърифәт[4] — гыйшкы Хакдыр.

---

1 К.да — кыругга (186 б.).
2 К.да — делдер (186 б.).
3 Әсраре мәгърифәт — мәгърифәт серләре. Биредә суфыйчылык төшенчәләре хакында сүз бара.
4 К.да — мәгърифәтдер (187 б.).



www.darulkutub.com

Ягъни олылар әйттеләр, күңел дәресе яхшы сабак, диделәр. Ул күңел дәресенең һәм сабагының тәмамы шул була — Аллаһны тану һәм аңа гыйшык (гашыйк) булу. (Хикәят).

Күңел дәрсен сөаль итдем бер ирдән,
Тәләттыфдин[1], — диде, — сөрмә бу йирдән.

Ягъни, мин Аллайар, күңел сабагын һәм дәресен бер газиз ирдән сорадым. Ул газиз миңа кәламе лотыф белән («әдәп белән») әйтте: «Әй Аллайар, бу күңел җиреңнән сорама, чөнки күнел — бәйтел-Аллаһдыр, андагы хәлне мин каян белерем», — диде. Әйтәләр: сораган кешесе — Шәех Хәбибулладыр, Аллайарның остазыдыр. Һәм дә әйтте ул: «Күңел хәленең кайберсе — тәм табудыр, үзең аны татмаен (татымыйча) белмәссең», — диде...

Белә алмам бу ширбәт татмагунча,
Үзеңне яхшыларга катмагунча.

Ягъни ул газиз әйтте: «Әй Аллайар, бу күңел ширбәтенең ләззәтен татымыйча белмәссең һәм дә үзеңне яхшылар мәҗлесенә кушмыйча белмәссең, чөнки күңел хәле ләззәтләнүне теләр. Җиде зикернең[2] тәмамы булмаенча, күңел хәлләренең әшкальләреннән (кыенлыкларыннан) хәбәрдар булмассың», — диде. Гомумән, кыскача итеп әйткәндә, бу күнел хәлен белергә ике нәрсә шарт булыр: элек — улыңны мөршид галимгә (остазга, дини юнәлеш башлыгына) бирү кирәк һәм икенчесе — җиде зикерне тиешле дәрәҗәдә аңлау кирәк. Һәм моннан башка хәлне аңларга шартлар бар, барын да әйтү әдәпсезлек булыр һәм дә үзебез[3] әһеле хәлдән (ягъни «тарикатьчеләр төркеменнән») түгел. Монда бу шәрехне остазлардан ишетү белән тәхрир әйладек (яздык).

Эстәйәнә (теләгәнгә) бу кадәр булды taләб,
Йукарыдан йукарыдыр ул җәләб (кол).

---

1 С.-П.да — тәләттыф(и)лә (270 б.).
2 К.да — зикер (187 б.).
3 К.да — үземез (187 б.).

Әгәр аны (ани) онытса бәндә аны,
Терек ирмәс әгәрчә булса җаны.

Ягъни берәү бераз заман Аллаһ Тәгаләне онытып торса, күңеленнән чыгарып йөрсә, андый кешенең тәнендә җаны булса да, үлектер. Бу бәеттән беленде ки: әһеле хәл булган кеше, һичбер мизгел Аллаһны күңеленнән чыгармыйча, хакыйкатьтә зикер кылыр[1], диделәр. *Аны* сүзенең әүвәлгесе хин (вакыт) һәм заман мәгънәсендә килә. Һәм икенчесе замир (алмашлык сүз), мәфһуме (төшенчәсе) Аллаһ сүзенә туры килә, Аллаһка кайта мәгънәсендә кулланыла, гарәпчә бер мәгънәгә ия.

Күңел бөрҗендә гафләт гыйлләте (авыруы) пөр (тулы),
Дәвам улдыр — дәвам итсәм тәзәккер.

Ягъни күңелебез эчендә (бөрҗендә — почмагында) гафиллек (ваемсызлык) зәхмәте күп инде. Ул гафиллек зәхмәтенең даруы шул була — даими остазын хәтергә (бәйләнешкә; мөнәсәбәткә) алып, Аллаһны искә төшерү. Чөнки нәфийе исбат белән (дәлилне кире кагу белән), ма сиваи Аллаһ (Аллаһдан башканы), чире чыгар, димәктер. *Дәвам* сүзенең элеккесе дару мәгънәсендә килә. Һәм икенчесе даимчылык мәгънәсендә куланыла...

Ушал дәмне (мизгелне) нәдәм дир әһле мэгьнә,
Агыздин чыкса гафләт берлә йәгънә.

Ягъни мәгънә әһеленнән булган газизләр әйттеләр: берәү «Ләә иләһа илләлләһи» (Аллаһдан башка табыныр зат юк) дисә, аның мәгънәсен игътибарга алмаса, мөҗәррәд (ялгыз; бары) тел белән кылса, «Ләә иләһа илләлләһи» диюдә файда юк, бәлки аның мәгьнәсен аңлап әйтсә (якынаеп) һәм дәлилләп, ма сива Аллаһны (Аллаһдан башканы), нәфи әйләйә (кире кагып), ул чакта файда өмет итү урынлы, димәктер...

Күңел аңда һәмишә кыл, һәмишә,
Качан булгай моның дак (тик) йахшы пишә.

---

1 С.-П.да, К.да — кыылыб (187 б., 271б.).

Ягъни берәү Аллаһ зикерен күңеле аша әгъзалары белән дәвамлы кабатласа (дәвам итсә; кабатласа), моннан да яхшы һөнәрле (нишә) кеше булмас. Шуннан мәгълүм булды, зикер әйткән кеше элек зикеренең мәгънәсен күңел белән игътибарга ала, аннан соң теле белән кабатлый. *Кыл* сүзендә истихдам (шөгыль, хәрәкәт) бар һәм дә әһеле тариканең (дәрвишнең, суфыйның) әсраре зәүкыясы (эчке теләкләре, серле зәвыклары) бар, чөнки әсраре тариканең элек зәвыгы һәм ахыры ләззәт. Кайда булды әүвәлгене зикер итеп, ахырын тәфсир (аңлатмалы тәрҗемә) итү?!

## Хикәят. Талибның харисы гыйшык булуының бәяны

Кил, әй садыйк, харисы гыйшкы Хәкъ бул,
Күңел йараиы берлән һәм сабкъ бул.

Ягъни, әй Аллаһ Тәгаләгә растлык белән иман китерүче кеше, кил Аллаһ Тәгаләгә гашыйк булырга, харис бул һәм дә күңел хәлен аңлаучы яраннар (дуслар; якыннар) белән бер сабакташ бул, алар белән аерылмый, даими бер мәҗлестә бул; шәех булган кешең бардыр, аның сохбәтеннән аерылма.

Әгәр гизсәң[1] тарикы мәгърифәтенә,
Мөйәссәр әйласәң төрлек сыйфатыны.

Ягъни, сиңа Аллаһ Тәгалә насыйп итеп, Аллаһ Тәгаләне тану мәкамләрен (урыннарын) гизсәң һәм дә Аллаһ Тәгалә күңелгә төрле шатлык-сөенечләр һәм тәҗлийатләр (таҗлы булу, дәрәҗәгә ирешү) риза булса (бүләк итсә, өлеш чыгарса),

Мәкамәте хакыйкать әйласәң тай,
Күңелдә булмаса җөзе хөлләте хәй[2].

Һәм дә мәкамәт әһеле (суфый) Хакның бакчасында торсаң да һәм анда йөрсәң дә (әйласәң тай) һәм дә күңелдә Аллаһ дуслыгыннан башка нәрсә булмаса, бу ике бәйт[3] мөбтәда (ия) хөкемендә булыр..

1 К.да — керсәң (188 б.).
2 С.-П.да — хөббү вә хәй (272 б.).
3 С.-П.да бу сүз юк (273 б.).

www.darul-kutub.com

Борынгыдин зиадәдәр талиб бул,
Әгәр дәрьялар эчсәң, хөшке ләб (кипкән иренле) бул.

Ягъни син бу кадәр мәртәбәләргә җиттем дип тәкәбберлек кылма, бәлки Аллаһ Тәгаләне һәрчак эстәп, якын булу һәвәсендә бул, хәтта ки дәрья суларын эчеп бетерсәң дә, Аллаһ ризалыгын эстәп ач һәм сусаучы бул. Бу бәет — хәбәре мөбтәдадер.

Бу юлның чөнки һич пайаны (чиге) юкдыр,
Әгәр йитәм[1] дисәң, әмкане юкдыр.

Ягъни бу тарикать юлының һәм дәрәҗәсенең һич кырые һәм пайаны (чиге) юк, әгәр насыйп итеп, ахырына җитәм дип теләсәң дә, мөмкин түгел[2]. Андый булса да, һәрчак таләбендә бул...

Дигел һәр ләхзадә (мизгелдә) Аллаһым зидне,
Дңде Хәкъ чөнки фаталәбне тәҗидне (?).

Ягъни, никадәр олы мәртәбә тапсаң да, аңа алданып тәкәбберлек кылма: һәр сулуда Аллаһ Тәгаләгә ялварып: «Йә Рабби, арттыр, файдалы кыл һәм тәкәбберләр әһеленнән кылма!» — дип даими догада бул. Чөнки Аллаһ Тәгалә әмер итте: «Мине эстәгән, әлбәттә, табар», — диде.

Таләб әмрен ишетсә бәндә Раббыдин,
Үзен белгән качан калган таләбдин.

Ягъни, берәү Аллаһ Тәгаләне эстәү әмерен ишетсә, үзен-үзе белгән кеше Аллаһны эстәүдән калмас, бәлки нәфес-һаваларыннан бизеп, дөнья зиннәтен ташлап, гозләт (ялгызлык) юлын һәрчак ихтыяр итәр, һәрвакыт Аллаһны эстәр.

Нәбидин юк кем[3] карбе бала,
Аңа әйде «хәбибем» Хәкъ Тәгалә.

Ягъни пәйгамбәребез Мөхәммәд г-мнән Аллаһ Тәгаләгә

1 К.да — йитдем (188 б.).
2 С.-П.да — юкдыр (273 б.).
3 К.да — кеше кем (188 б.).



www.darulkutub.com

якын кеше юк. Ул пәйгамбәребезне Аллаһ Тәгалә «сөекле дустым» (хәбибем) дип әйтте.

Аңа һәм әйтде Хәкъ кол[1] рабби зидне,
Куярмы үзгәләр[2] җәһду җидне.

Ягъни ул Мөхәммәд г-мгә Хак Тәгалә хәзрәте аять иңдерде, кабатла дип: «Кол рабби зидни гыйлмән». Мәгънәсе шул булыр «Әй Мөхәммәд, әйт: «Йә Рабби, якынлыкыбызны арттыр!» - дип дога кыл», — диде. Андый булса, үзгә кешеләр таләбе җәһдене (эзләүдә тырышлыкны) кайчан куяр, димәктер.

Сөчүк җан ширбәте табылса ләбдә,
Кирәк кем бәндәсе булса таләбдә.

Ягъни андый булса, бәндәләрнең тәнендә җанлары булганда[3], әлбәттә, Аллаһны эстәү кирәк һәм якын булу истигъдадыны (тырышлыгын, сәләтен) хәзер тоту кирәк.

Билеңне кувәте бар да, алыб бил,
Күңел багын сугар үтмәй торыб сил.

Ягъни, иҗтиһад китмәнең куәте бар чакта, таләп чокырыңны казы, анда су чыгарып, күңел бакчаңны сугар, гомереңнең гөрләвеге үтмәстән элек, ягъни, кыскасы, гомерең үтмәстән борын, җәһәтрәк Аллаһны эстә, шаять ки, камиллек табып, әнваре[4] мөшаһәдәткә (татлы уйларга; экстазга) лаек булырсың, димәктер. *Бил* дигәне асылда бер корал булыр, аның белән җир казырлар, төрки сөйләменчә китмән диярләр. Монда иҗтиһад (тырышлык) мәгънәсенә метафора итеп алынды. Икенчесе (бел) әмре хазыйр (боерык фигыль), белүдән ясалган яки вәзен шигырь өчен истигарә алынды.

Йитәр йул йөргәли хала ки хәлең,
Йөри күр бер көн киткәй мәҗалең (көчең).

---

1 К.да бу сүз юк (189 б.).
2 К.да бирдә бул сүзе дә бар (189 б.).
3 С.-П.да — торгунча (273 б.).
4 К.да — әнваге (189 б.).

Ягъни фани хәзерге дөньяда тере чагында хәлең бардыр, зинһар, Аллаһ юлында тырышлык кыл, чөнки бер көн Газраил килеп, хәлеңнән яздырып алыр[1], ахирәт йортына гамәлсез китмә син, димәктер.

Йөрергә калмаса вактилә[2] дәрман,
Имәклә, калмасын та эчдә арман.

Ягъни кинәт дөньяда Аллаһ сәфәренә дәрманың калмаса, куәтең барынча имгәкләнеп; тырышып мәшәкать чик, хәтта тәкатең, Гали кадәр куәтең булсын, ахирәт йортына барганда, күңелеңдә үкенеч калмасын өчен. *Арман* төрекмән халкының сөйләме диерләр, үкенеч мәгънәсендәге сүз.

Имәкләб кувәте һәм китсә кулдин,
Үзеңне сөргел һәргиз, калма юлдин.

Ягъни Аллаһ юлына мәшәкать белән барырга кулыңнан куәтең китсә дә, үзеңне ул юлга хәлеңнән килгәнчә этәр[3], кайбер әгъзаларың белән тырышлыгыңны тулы, бөтен ит.

Йитешмәсә сөрергә һәм мәҗалең,
Күзең тек юлга тайгунча[4] халең.

Ягъни барча әгъзаларың белән Аллаһ Тәгалә юлын сөрергә хәлең булмаса, күзеңне текәп карап, ул юлда бул, хәлең җиткәнчә, чөнки мөмкинлегең булган[5] кадәре ул юлда йөр.

Күзең һәм булмаса, булсын күңелдә,
Бу матлаб (теләк) берлә җан чыксын бу юлда.

Ягъни Аллаһ Тәгалә юлында күз куәтең булмаса, күңел куәте белән Аллаһ юлында бул. Аллаһны эстәү белән җаның тәнеңнән чыксын, чөнки ахыргы гыйбадәт күңел

1 К.да — үлеб (189 б.).
2 С.-П.да — вакты (274 б.).
3 С.-П.да — «үзеңне Гали кадәр такатьул юлга соргел» (274 б.).
4 К.да — табтунча (189 б.).
5 С.-П.да биредә Гали сүзе дә бар (274 б.).

белән булыр[1]. Кыскасы, бу бәетләр шуңа ишарәт итте: кергән юлыңда нык бул, даими Аллаһны эстәүдә бул, никадәр чирле, авыру булсаң да, таләп куйма, димәктер.

Әгәр мондаг таләбдә чыкса жаның,
Улынса бакый өйүгә җисме жаның[2].

Ягъни Аллаһ Тәгаләне, югарыда әйтелгәнчә, эстәү белән җаның чыкса, мәңгелек йортына тәнең белән җаның васыйл булса ( бергә керсә),

Өмид улдыр: Ходаем дисә: «бәндә»,
Теләгән максудыңны бирсә анда.

Ягъни андый иҗтиһад булып (тырышлык куеп), торуыңнан өмет бар, шаять, Аллаһ хәзрәте сине «колым» дип зикер итсә кирәк һәм дә ни теләгән макъсудларың (теләкләрең) бар, аларны бирсә кирәк.

## Хикәят. Дөньяның мәкерлеге бәяныдыр (Дөньяның мәкерлеге турында)

Кил, әй хаиф, үлемнең йадын әйткел,
Китәр мәнзилнең истигъдадын әйткел.

Ягъни, әй Аллаһтан куркучы бәндә (хаиф), даими үлемне исеңдә тот, ахирәт йортына (мәнзиленә) китәчәкне истә тот һәм анда барырга яраганны кыл. Анда яраган нәрсә шулдыр, даими гыйбадәттә булу.

Ләбән тәрме торыб мәркад (кабер) ләбен халык,
Куярсәнме тәфффәккер бабыны галык.

Ягъни халык кабереңне кирпеч (ләбән) белән япканнан элек, дөнья фикерен чыгар һәм аның урынына ахирәт фикерен куй. Кыскасы, үлмәстән элек тәүбә-истигъфар әйт, димәктер. *Ләбән* сүзенең әүвәлгесе кирпеч мәгънәсендә килә. Икенчесе кабер якасы мәгънәсендәге сүз. Аннан морад: ләхет авызы була.

---

1 С.-П.да -ахирәт гыйбадәт кылыбдыр (274 б.).
2 С.-П.да — бакыйга бу җисмү-җаның (275 б.).

Йигыб һимә вә һимә кылмай анда,
Йатыб сән өстедә гафләтле бәндә.

Ягъни, син гөнаһ утыны туплап (җыеп), аннан аның тәмуг утыны булырын фикерләмичә, дөньяда гафиллек белән ятып, димәктер. *Һимә* сүзенең әүвәлгесе утын һәм хәтаб (ягулык; утын) мәгънәсендә була, һәм икенчесе фикер мәгънәсендә килә.

Үлемнең укы торгандыр сөйәнеб,
Уйаныб, үрмәй качгыл уйаныб[1].

Ягъни, үлем угы белән җәясен[2] сорап, безгә сөйәнеб (төзәп) атарга тора. Андый булса, гөнаһларыңнан тәүбә кылып ян һәм кайт, димәктер. *Уйаныб* сүзенең әүвәлгесе тараф мәгънәсендә килә һәм икенчесе иказ (уяну) мәгънәсендәге сүз.

Уйанмасдан борын үтенсәң, әй кол,
Мәбадә булмагай көлл эшләрең көл.

Ягъни, үлеп, җаның чыкмастан элек тәүбә ит һәм гафу үтен, гөнаһларың өчен оялсаң һәм тәүбә кылсаң, шаять ки, барча гамәлләрең көлгә әйләнмәс. Кыскасы, дөньяда вакытта гөнаһларыңнан тәүбә кылсаң, ахирәткә барганда, файдасыз булмас, бәлки гөнаһлар урынына савaплар язылса кирәк. *Көлл* сүзенең әүвәлгесе барча, барлык, барчасы, бөтенесе мәгънәсендә була, гарәпчә һәм фарсы белән уртак сүз, һәм икенчесе рәмадә (көл) мәгънәсендә. Аннан файдасыз мәгънәсенә метафора итеп алынды.

Борынгы баде гамь тигмәй борынраг,
Үзеңне кыл һәвәсе сөкраныдан (исереклегеннән) саг.

Ягъни синең борынга кайгы һәм хәсрәт баде (җиле) тимәстән элек, әүвәл гөнаһларыңнан тәүбә кыл, нәфес һәваларыңнан һәм аның исереклегеннән үзеңне сәламәт кыл. Кыскасы, ахирәт кайгысы килгәнче, элек дөньяда вакытта гөнаһларыңнан тәүбә ит, димәктер.

---

1 К.да бу бәет күзгә ташланмый (190 б.).
2 С.-П.да бу сүз юк (275 б.).

Йабышмасдан борын сүңәкенгә пуст,
Үлем берлә үзеңне әйлагел дуст.

Ягъни, үлем җәлладе Газраил сөягеңә ябышып, жаның алмастан элек, ул үлем белән дус бул, димәктер.

Йакын белгел ки, кемне күб әйласәң йад[1],
Булыр дустың сәнең, әй адәми зад.

Ягъни шиксез бел, берәүне искә төшереп күп уйласаң, хакыйкатьтә ул сиңа дус булыр. Андый үлемне көн исеңә төшерсәң[2] — дустыңдыр; жаның чыкканда жиңел булыр. Әйтәләр: тарифлар (суфыйлар) үлемне сулаган саен истә тотарлар, гамәл кылучы галимнәр һәр көндә бер мәртәбә искә төшерәләр, урта галимнәр җомгада бер тапкыр (мәртәбә) искә төшерәләр; азгын галимнәр айга бер кат искә төшерәләр. Әмма ахырда, бу өченче гөруһның (төркемнең) хәле шундый: иманнары бетүеннән хәвефләре бар. Нәгузе билләһи... (Ходай сакласын...), чөнки үлемне искә төшергән кеше, әлбәттә, нәфес-һәваларыннан һәм гайбәттән тыелып, сакланып, үлем белән үз дуслыгында үлсә кирәк...

Белер адәм углы булса уйаг,
Ватанның аслысыдыр безгә туфраг.

Ягъни, әгәр күңел гафләтеннән уяу булса, хакыйкатьтә безнең асыл йортыбыз туфрак дип, һәр адәм улы белер. Андый хәлне белгән кешеләр, әлбәттә, дөнья зиннәтеннән бизеп, үз ихласында булса кирәк.

Йакын бел гел: җиһан пөр (тулы) хәтаргә,
Килебмез берничә сәүда итәргә.

Ягъни шиксез бел, әй адәмиләр, без юктан бар булып, хәтәр тулы дөньяга килдек. Килүебез шуның өчен: без ахирәт сәүдәсе өчен килдек[3], нәфесләребез артыннан йөрү өчен килмәдек...

---

1 К.да — «йакын бел: кемне күбрәгъ әйласәң йад» (190 б.).
2 К.да — «...үлемнең зикрене күб кылсаң...» (190 б.).
3 С.-П.да — килмәдек (277 б.).

Йитешкәч ошбу шәһри моктәрәфкә,
Таралды кәрвани һәр тарафка.

Ягъни кайчан бу кәсеп сараена-дөньяга (шәһри моктәрәфкә) килгәч, кәрваннар һәр тарафка таралды: кайберләре ахирәт әһленнән булып, дөнья морадларыннан бизеп, Хак Тәгаләгә гыйбадәт кылдылар һәм кайберләре нәфсе морадларына ияреп, явызлар гөруһыннан китеп, ахирәт мәртәбәләреннән ерак төштеләр. Җыйнап кына әйткәндә, дөньяга килүләре ике гөруһтан имин, азат түгел. *Моктәрәф* исеме заман һәм исеме мәкандыр (мәкан — урын), мәгънәсе - кәсеп кылу җире була. Кайбер нөсхәләрдә моктәрәф урынына мөхтәрәф язылган, ягъни мәгънәсе шул ук була.

Үзен белгәнләре кем юлга салды,
Хәйасыз нәкъд гомрен кулга алды.

...Ягъни дөньяга килгән кешеләрнең кайберләре, үзләрен үзләре белеп, башларын тугры юлга салдылар, изгеләргә баш биреп, изгеләр мәҗлесендә утырдылар һәм дә, шиксез, гомерләренең файдасын табып, ахирәт йортына гамәлләре белән күчтеләр. *Хәйасыз* дигәне шиксез мәгънәсендә була, *Нәкъд* дигәне асылда акча мәгънәсендәге сүз. Монда исә файда мәгънәсендә килә.

Орыб йахшы дигәнләр үзрә башын,
Мийәссәр кылдылар тагать комашын.

Ягъни дөньяга килгән кешеләрнең кайберсе, изгеләргә буйсынып, аларның мөршид (җитәкче; остаз, шәех) булганнарына мөрид булдылар: ул камил, җитлеккән мөршиднең мәҗлесендә утырып, Аллаһ Тәгаләгә якынлык таптылар. Шул сәбәп белән буйсыну һәм гыйбадәт кома-чын табып, дидарына (карашына, игътибарына) лаеклы булдылар. Нәтиҗәдә, бу бәет бер мөршидкә мөрид булуга ишарә буларак язылды. Ләкин камил мөршиднең табылуы зур дәрәҗә әхмәрдер (комач кызыл, югары мәртәбә икәненә ишарә).

Кылыб сәүдаларын чабаке чөст,
Сәфәр рәхтене (яракларын) баглаб кылдылар җөст[1].

---

1 К.да — рәст (рөст) (191 б.).

Ягъни, андый яхшылар янында утырып, ахирәт сәүдәләренә тизлек белән керешеп, ахирәт йортына барулары өчен тырыштылар, Хак Тәгалә хәзрәтенә тизлек белән җавап бирер өчен тырышлык кылдылар...

Качан йөк куй дисә таййар ирер зад[1],
Керерләр юлларына хөррәм-у шад.

Ягъни кайчан Хак Тәгалә хәзрәте: «Әй колым, кайда, китергән йөгеңне куй,» - дип дәшсә, мондый кешеләр Аллаһ Тәгалә тарафына йөкне тоткарсыз әзерләрләр. Аннан соң оҗмах юлына атларлар, димәктер. *Таййар* тай мөһмәл (та хәрефе) йаның (й хәрефенең) тәшдиде (икеләтелүе) белән хәзер булу мәгънәсендә килә. Мавәрәэннәһер («Төркестан») сөйләменнән алынган.

Вәләкин кәрвандан бәгъзе инсан,
Күрер бу[2] фаный өйүне багы хәндан.

Ягъни, дөньяга килгәч, кайбер адәмнәр, бу сасы исле дөнья өен шатлык бакчасы күрерләр һәм нәфес һаваларына буйсынып, гыйбадәт вакытларын онытырлар, әмма ләкин бу дөньяның фани (вакытлы) икәнен барчасы белерләр.

Күреб йахшы аның нәкшы нигарен,
Оныткайлар ушал килгән дийарын.

Ягъни, ул түбән, кимчелекле дөньяның яхшы зиннәтләренә һәм хуп сурәтле йөзләренә (нәкшы нигаренә) карап, галәмел-әрвахдан (рухлар дөньясыннан) килгән йортларын онытканнар, дөнья йортын олы күреп, ахирәт йортын кече күрәләр.

Колак салгай тәганни вә нәвага (моңга һәм җырга).
Күңел биргәй. һәвәс берлә һәвага.

Ягъни ул кешеләрнең кайберсе, бу фани дөньяга килгәч, уен авазларына колак салалар, һавалы нәфесләренә

2 С.-П.да — зат (278 б.).
3 К.да — бул (192 б.).

www.darulkutub.com

күңел бирәләр, «Коръән» авазын ишетүдән читләшеп, мәгънәсез харам авазларны ишетеп ләззәтләнәләр.

Гаҗәб мәккярәдер дөньяи фаный,
Мең әлван җәлвә берлә алдар аный.

Ягъни, кыскасы, бу фани дөнья гаҗәп хәйләкәр нәрсә ул: мең төрле моң авазлары һәм күп төрле зиннәтләр белән адәм улларын алдар. *Җәлвә* җимнең (җим хәрефенең) фәтхәсе яки кәсрәсе белән моң-аваз мәгънәсендә була. Ләкин «Мәҗмугы лөгате фарси»да китергәнгә, җәлвә әнваг (күп төрле) зиннәт мәгънәсендә кулланыла.

Ушал мәккярә кем салса куенга,
Сөенгәндән керер шәйтан уенга.

Нәгүзе билләһи (Аллаһ сакласын), кайчан ки, ул хәйләкәр дөнья бер адәмне алдау кулын ул адәмнең куенына салса, шайтан сөенеп, ул адәмнең буйсыну белән гыйбадәтләре һәм Аллаһка гыйшык урынына кереп, юлдан чыгарыр, Аллаһдан ерак кылыр, димәктер.

Керер инсан аның ялган сүзигә,
Йөгертер сөрмәи гафләт күзигә.

Ягъни бу сыйфатлар белән булган андый адәм, акрынлап, ул ләгыйньнең ялган сүзенә инаныр; инанганнан соң, ул шайтан ләгыйнь ул адәмнең күзенә наданлык сөрмәсен тартып, нәфес тезгенен ул инсанның кулына җиткереп (нәфес колына әйләндереп), җәһәннәм чокырына төшерер, нәһүзе билләһи, ул шайтанның сүзе ялган булыр.

Гяһи уйганыб, уен[2] уйласа ул йад,
Тәләттыф (әдәп) берлә диер: «Әй адәми зад».

Ягъни бу адәм улы кайбер төннәрдә йокысыннан уянып фикер итәр, әйтер: «Ахирәттә барганымда, мин бу кадәр явызлыкларым һәм рисвайлыкларым белән

1 К.да — сөртеб (192 б.).
2 К.да — уйан (192 б.).

газап күрермен, — диер. — Инде тугры торырмын һәм тәүбәне итәмен», — дисә, шәйтан акрынлык белән ул кешенең күңеленә шулай дип әйтер:

Ашыкма, бер көни сәүдә кылырсән.
Бүген гәр булмаса, фәрдә (иртәгә) кылырсән.

Ягъни ул шайтан ләгыйнь ул фикерләүченең күңеленә дәшеп әйтер: «Әй адәм улы, ашыкма, чөнки Ходаның рәхмәте күп, хәзер яшь вакытыңдыр, уйна, аша һәм эч, — диер. — Чөнки Аллаһның көннәре күптер, бүген тәүбә итмәсәң, таңда итәрсең», — диер.

Бу ал (хәйлә) илә ушал мәккяри дүн (түбән, бозык),
Әда кылгай җәмигь нәкъде гомерен.

Ягъни ул адәм улы, бу кадәр бу ләгыйньнең алдавына инанып, барча гомеренең файдасыз буш үткәреп, ахирәт йортына үкенеч белән китә.

Әда кылгач бәсат гомерене пакь,
Бирер рөхсәт кашыдин чөсте чалак.

Ягъни адәм улы, аның ялган сүзенә карап, гомерен гыйбадәтсез, тәүбәсез буш үткәргәч, шайтан ләгыйнь тиз генә ул кешенең яныннан китәр.

Урар сине, диер: киткел бу йирдән,
Дигәй бизәр ирермән сәндик ирдән.

Ягъни шайтан, бу кешене тәмам алдагач, ул кешенең җилкәсенә йодрык белән орыр. Әйтер: «Син бу тәүфикъ һәм һидаять җиреннән кит, мин чын ялганга инанган кешеләрдән бизәрмән», — диер.

Нәзар кылмас фөган-ү наләсига,
Ирер рәштә аның дөнбаласига (артына).

Ягъни шайтан ләгыйн, ул ялган сүзгә инанган кешенең зарыйлык (фәган наләсига) аһына карамыйча, хәйлә (риштә, рәштә) чылбырын аягына орыр. Аннан соң

күңеле үлеп, тәүфикъ, һидайәт юлын тапмас бүтән. *Рәштә* шиннең (шин хәрефенең) фәтхәсе белән асылда аякка агач белән ору мәгънәсендә була. Монда хәйлә, чылбыр мәгънәсенә метафорик алынды.

Әмире кәрван ул дәмдә йиткәй,
Аңа асыл ватанның хөкмен әйткәй.

Ягъни шул чак кәрван башлыгы Газраил, шул сәгатьтә килеп, бу шайтане ләгыйнь сүзенә карап торган кешегә асыл йортның хөкемен әйтә. Аннан морад — җанны алып, кабергә кертә, ахирәткә үкенеч белән гамәлсез китә.

Куйалмай иркегә сораб йакадан,
Чыкарырлар җәһан би бәкадан.

Ягъни, ул кешенең ихтыярына куймыйча, якасыннан тотып, фани дөньядан чыгарыр. Хөсран әһленең (үкенечеләрнең) гөруһыннан булып, кабергә үкенеч белән керер.

Фөган (аһ-зар) әйләр китәрне белгәнем юк,
Китәргә түшә (азык) хазер кылганым юк.

Ягъни без, наданнар, ахирәт йортына зарилык белән барырыбызны белмибезме, даими нәфес артыннан йөрербез һәм дә ахирәткә баруны белсәк тә, анда барырга азык әзерләүдә гафиллектә торабыз.

Фөган сүд (файда) әйламәс әмма у(л) кәскә (кешегә),
Качан мөһләт (чик) куярлар бер нәфескә.

Ягъни зарилыктан андый кешегә файда булмас, чөнки әт нәфесләренә ияреп, гамәлләреннән гафилләр, ваемсызлар.

Әгәр кайтай дисә, булмас мәҗали,
Китәр асыл ватанга дәсте хали.

Ягъни, үлгәннән соң, кире дөнья йортына килеп,

гамәл кылырга мөмкинлеге булмас. Андый булса, шундый кеше асыл йортка гамәлсез, буш кул (дәсте хали) белән барырлар, ахирәттә йөзе кара булып, үкенүчеләр төркемендә булыр.

Будыр, әй адәми зад, хәсбе халең
Башыңдан үтмеш анча маһе-салың (айларың-елларың).

Ягъни, әй адәм уллары, сезнең дөньяда гафил торуыгызның хәле һәм хикмәте будыр: башыгыздан ничә айлар, елларның гафиллек белән үтүенең хикмәте шул: шайтан ләгыйнь сүзеннәндер, башка, үзгәдән түгел.

Колакга тотма[1] гафләт ләттәсене,
Йимэ шәйтане ләгыйнь шәтәсене.

Ягъни андый булса, син акыл әһеленнән булсаң, колакка гафиллек мамыгын тыкма, бәлки үгет һәм нәсыйхәт тыңлап, гафиллек мамыгын чыгар һәм үгет-нәсыйхәтне ишет. *Ләтгә* мамык мәгънәсендә метафора итеп алынды. *Шәгә* мәгънәсе югарыда үтте (әйтелде). Әмма монда үгет вә нәсыйхәт мәгънәсенә метафора итеп алынды.

Сүенмә (сөенмә) ки сәне дөнья сөебдер,
Сөеб мән диб күзеңә ком коебдыр.

Ягъни дөнья мине сөйде, теләгән мәкъсудларым табылды дип сөенеп шат булма. Ул мәкерле хыянәтченең сиңа мондый кылдым, — ди торгач, ахыр бер көн, үлгәннән соң, күзеңә ләхеттә туфрак кояр. Андый булса, ул хыянәтченең сүзенә карама.

Кемә күрсәтте бу фаний-у фаный,
Әзәлдин (мәңгедән) дошмани җан, белгел аны.

Ягъни андый булса, әй газиз, бел: бу фани дөнья кемләргә вафа (тугрылык; ышаныч) күрсәтте, ничәмә шаһлар һәм пәйгамбәрләр, сахибе «Коръән»нәр[2] («Коръән»

1 К.да — тыкма (194 б.).
2 К.да — киранлар (194 б.).

дуслары) дөньядан үттеләр! Кайда булды, ди, безгә вафалык (сүздә тору) күрсәтү?! Андый булса, бу фани дөньяның хыянәтләренә алданма, димәктер.

## Дөньяга хирыслыктан тыелу бәяны

Кил, әй мөэмин, йакыйн белдең китәрне,
Хисаб гомре би саман итәрне.

Ягъни, әй мөэмин, шиксез, бу фани дөньядан күчүеңне һәм дә хисаплы гомереңне карар кылмаслыкны (би саман итәрне) белдең. Ни өчен андый булса, дөньяның әнваг (төрле) зиннәте белән бизәнеп, ахирәт хезмәтендә булмадың, димәктер. *Би саман* би карар мәгънәсендә килә, Сәмәрканд халкының сөйләменнән. Ба (би) хәрефе адәте нәфидер (инкарь кисәкчәсе).

Үтәр дөнья өчен булма грифтар,
Үлемсә егмагыл манәндә кәфтар[1].

Ягъни андый булса, фани дөнья өчен тоткын (грифтар) булма, ахирәт юлыннан коры калма, бурсык кебек үләксә (үлемсә) җыюда булма. Чөнки бурсык дигән хайван оясына күргән үләксәләрен җыяр, аның кебек син дә мал җыюда Аллаһ ризалыгыннан үтмә, хәләл һәм харамны тикшер, димәктер. *Грифтар* тоткын вә хибес мәгънәсендәге сүз. *Үлемсә* дигәне үләксә мәгънәсендә килә. Бохарада үзбәк җәмәгатенең күбрәге үлемсә диерләр. *Кәфгар* кяфе гарәпчә (кяф хәрефенең) фәтхәсе белән забуг (сыртлан — гиена) һәм Рум (бу очракта — «госманлы») халкы бурсык дигән хайван була.

## Коңгыз корты бәянында һәм хикәяте Карун

Әгәр дөньяга хирсың булса, фәҗ сән,
Нәҗасәт йийгарга[2] калһәмиҗ (коңгыз) сән.

Ягъни, Аллаһ Тәгаләнең фарызларын үткәреп, дөнья хирыслыгында булсаң, түбән дәрәҗәле һәм беткән кеше, бозык син. Андый булса, коңгыз корты кебек, тизәк җыючы син. Чөнки коңгыз күп мәшәкатьләр белән җир

---

1 К.да — гөфтар (194 б.).
2 К.да — нәҗасәт йийгмагында (194 б.).

тишегенә тизәк һәм төрле нәҗасәтләрне җыя. Андый син, дөнья милкендә күп мәшәкатьләр чигеп, малны туплырсың, хәләлен һәм харамын тикшермәссең. Аллаһ боерган зәкят-гошереңне үтәмәссең, ялгыз, үзең генә җыеп, үз ислахында булырсың. Кайбер ахмаклар, мал җыеп, җир астына куярлар, ни үзе һәм ни башка кеше аннан файда алмас?! Мондый кешеләр коңгыз кебек булыр. *Фәҗ* Харәзем сөйләменнән алынды, зәбун, дәнаэт (түбән җанлы) мәгънәсендә, *һәмич* дигәне бер кечерәк хайван булыр, кара төсле[1] булыр, аягы белән җир йөзендә йөрер, аңлы вакытында канат белән очар. Болгар халкы коңгыз диерләр. Әйтәләр: коңгыз Муса пәйгамбәр заманында яратылды, аннан элек коңгыз булмаган.

Әйтәләр: кайчан Муса г-м Карунны тугры юлга өндәде, тегесе кабул итмәде. Бер көн Карун Муса пәйгамбәргә әйтте: «Йә карындашым Муса, минем малым күп булды: кырык амбар алтыным бар», — диде. Муса г-м әйтте: «Ул малны сиңа кем бирде?» — диде. Карун әйтте: «Гыйльме кимия («химия») белән үзем таптым», — диде. Муса әйтте: «Гыйльме кимияне сиңа кем өйрәтте?» Карун әйтте: «Син өйрәттең», — дигәненнән соң янә Карун әйтте: «Йә кардәшем Муса, гыйльме кимияне сиңа кем өйрәтте?». Муса әйтте: «Ходай Тәгалә өйрәтте» — диде. Карун әйтте: «Ходай кем торыр?» Муса г- м әйтте: «Сине һәм мине, җирләрне һәм күкләрне яраткан шул булыр», — диде. Карун әйтте: «Йә Муса, мин бу малны нишләтим?» — диде. Муса әйтте: «Зәкятен бир», — диде. Карун әйтте: «Зәкяте күп булырмы?» — диде Муса әйтте: «Өчдән бере», — диде. Карун Муса г-мнең сүзеннән көлде. Әйтте: «Әй карындашым Муса, син ярлы фәкыйрь булганга, сиңа шул кырык амбар алтыннан бер амбарын бирдем», — диде. Муса әйтте: «Мин фәкыйрьлегемнән өмет итеп сорамадым, бәлки Изи гыйзз-у җәллнең (Ходай Тәгаләнең) боерыгын-әмерен җиткердем», — диде. Күп вакыт узганнан соң, Изи гыйзз- у җәлл әмер бирде: Карунны җиргә йотарга, җир упды. Кырык көннән соң Карун тугрысыннан кан чыкты. Изи гыйзз-у җәлл коңгызны шул каннан яралтты, чөнки кондызда Карун охшашлыгы бар. Хирыслыкта һәм тәкәбберлектә.

www.darulkutub.com

1 С.-П.да — рәнгле (282 б.).

Әйтәләр: хәшәрәтләр арасында коңгыздан хирыс һәм тәкәббер һич нәрсә юк. Дүрт аяклы җанварлар арасында дуңгыздан һәм капланнан тәкәббер нәрсә юк, һәм очар кошлар арасында шоңкардан тәкәбберрәге, карга һәм саесканнан[1] хирысрагы юк.

Әйтәләр: коңгызның гомере озын. Яз көнендә Сәрәтан бөрҗенең (Иран календаренең дүртенче аеның) әүвәленнән ахырына кадәр канаты белән һава йөзендә очар. Аннан соң очмас. Очуына сәбәп шул имеш: күңеленнән әйтер имеш: «һинди вилаятенә барамын. Анда «Җәзирәи бак-бак» («Бак-бак утравы») дигән җир бар. Анда болынлыклар күп булса кирәк. Мохит диңгезендә су атлары чыгып, ул болынлыкларда утлар имеш. Аларның тизәге бер хуш исле азык булыр имеш. Шул чакта коңгыз аңа гашыйк булып очар имеш. Бераз заманнан соң күңеленә килер имеш: «Мин ул утрауга барсам, юлда азыгым юк һәм дә миңа ул атларның тизәге ни нәрсәгә ярар һәм дә исе начар имеш», — диеп кире кайтып, мондагы ат тизәгенә керер имеш. Андый кешеләр Аллаһ Тәгалә юлына бару ниятендә булсалар, бераз заман Аллаһ боерган зәкятне һәм гошерне[2] үтәрләр. Аннан соң кире кайтып, малларын һавалы нәфесләренә сарыф итәрләр һәм фәкыйрьләрне дошман күреп, зәкятләрен бирмәс булырлар. Пәйгамбәр г-м хәдисе бу кыйссага ишарә булыр. Әйтәләр: коңгызның күбрәк торуы ат тизәгенең астындадыр. Аннан башка тизәкләргә кермәс. Хикмәте шул булыр: козгында җен табигате бар, диләр. Җенләр дә ат тизәге ашаса кирәк... Югарыдагы хәлне кайтып боерды.

Әсир гомрең нәҗес егма рәһендә,
Калурсән бер көн ахыр йир тәһендә.

Ягъни үкенеч сиңадыр: гомерең коңгыз кебек нәҗес җыю хирыслыгында. Аннан морад: Аллаһның фарызларын үткәреп, мал җыю һәвәсендә син. Ахыр бер көн булып, җир астында калырсың, үкенеп берни дә үзгәртә алмассың. *Әсир* — әмма монда үкенеч мәгънәсендә килә. Кайбер нөсхәләрдә әсир урынына исәр язылган. Ул да дөрес. *Рәһендә* хибес, тоткын мәгънәсендә алынган. *Йир*

1 С.-П.да — сагышкандан (283 б.).
К.да — гөшрү зәкатны (196 б.).

www.darul-kutub.com

*тәһендә* тәхтел-мәгънәсендә, яки тәһи дәст (буш кул) мәгънәсендәге сүз.

Үрәмче[1] тик һәмишә тар идарсән,
Канагәтьсезлегең изһар идәрсән.

Ягъни син шундый хирыссың, үрмәкүч дигән хайван кебек һәрчак оя тукырсың[2]. Аннан морад: фани булырыңны белмичә, үлеп гүргә кермичә, һәрвакыт мал җыю, мал һәвәсендә син. Бу сыйфатлар белән булуың үзеңнең канәгатьсезлегеңне ачык кыла (белдерә), чөнки канәгать әһеле бар нәрсә белән канәгать булып, гыйбадәт кылса кирәк. *Урәмче* (урамчы) үрмәкүч вә ганкәбүт (үрмәкүч) мәгънәсендәге сүз, Хәразем халкы урамчы диерләр. *Тар* туку һәм нәсҗ мәгънәсендә килә. Үрмәкүчнең хәлен бәян итеп боерды.

Кылырсән рәштәи җаның белән каид,
Мәгәс (чебен) дик, мур дик кылмак өчен сайд.

Ягъни жанның җебе (рәштә) һәм тәкате белән халыкларны яндыру[3] өчен түгел, Ходай юлына сарыф итү өчен, мал кәсебен кылырсың. Чөнки үрмәкүч тозак (сайд) корган кебек, чебеннәр, кырмыскалар (мур) өчен *Могәс* чебен мәгънәсендә. *Рәштә* асылда җеп мәгънәсендә килә. Монда тәкать мәгънәсенә метафора итеп алынды.

Себерсә сахибе ханә бике бар (Рбийекбар),
Үрәмче һәм китәр, һәм ханә, һәм тар.

Ягъни үрмәкүчнең өен йорт иясе (сахибе ханә) себерсә, өен пакь итәргә теләсә, үрмәкүчнең тукыган нәрсәсе — анда бозылыр. Аннан морад: Изи гыйзз-ү җәлл мал җыючыларга әҗәл бирсә, үзе кабер эченә үкенеч белән китәр һәм җыйган малы[4] таралыр, хисабы муенында калыр, димәктер. *Хаиэ* сүзенең элеккесе өй мәгънәсендә килә. Анда башка шәкел юк, һәм икенчесе үрмәкүч өе мәгънәсендә була. *Тар* сүзе гатыф (бәйләүче) бәянында.

1 С.-П.да -урамчы (284 б.).
2 С.-П.да — тотарсән (284 б.).
3 С.-П.да — елындырмак (284 б.).
4 К.да — җыелган малы (196 б.).



www.darulkutub.com

Шигырь өчен китерелде. Әйтәләр: үрмәкүчнең торган өенә ханә димәсләр. Аның ханәсе ак булыр, мамык кебегрәк; тоткан нәрсәсе аннан нәзек. Әмма һәр икесе өй һәм ханә мәгънәсенә туры килә.

## Үрмәкүч һәм кырмыска бәянында

Әйтәләр: үрмәкүч белән кырмыска кардәшләр. Адәм г-м дөньяга килгәч, бәвел итте («кече йомышын» башкарды). Бәвеленнән соң зәкәреннән («...әгъзасыннан») ак су килде. Аны вәди диерләр. Адәм г-м кулы белән зәкәрен сыгып ташлады. Аллаһ Тәгалә ул вәдидән ике төрле хайван ялатты; берсе - үрмәкүч һәм берсе — кырмыска булды. Кайчандыр бу ике хайванның җир йөзендә йөргәннәрен Адәм г-м күреп таң-гаҗәп калды. Әйтте: «Йә Рабби, боларның файдасы минем улларыма булырмы? Боларны ни өчен яраттың?» — диде. Җавабы Раббани килде ки: «Йә Адәм, бу ике хайванны синең улларыңнан ике дустым өчен яраттым».- диде. Кырмысканың файдасы шул иде: «Сөләйман г-мгә үгет» бирде.

Аның кыйссасы «Сурәи нәмелдә... («Кырмыскалар сурәсендә») озак сөйләнгән, аннан кара.

Үрмәкүчнең файдасы: безнең пәйгамбәребез мәгарәгә, тау тишегенә, кергән вакытта, куыш авызына[1] ау тукыды. Кяферләр шиккә төште. Пәйгамбәр куышка керсә, бу үрмәкүч авы бозылыр иде, диделәр, һәм дә күгәрчен йомырка басмас иде, диделәр. Бу ике хайванның ике дусты булуының сәбәбе шул. Галимнәр әйтәләр: үрмәкүч (гарәпчә ганкәбүт) өч төрле булыр. Берсе ганкәбүте чагыравu[2] диләр. Икенчесе — ганкәбүте әһрәви. Өченчесе — ганкәбүте шәмакъи, диләр. Әмма ганкәбүте чагырави шул булыр: канатлы булыр, канатында кызыл һәм кара нокта кебек төсләре булыр. Кирәк урынына канаты белән очып барыр. Әмма ау кормас. Аның хасыяте шул, берәүнең бәвел һәм тизәге тотылса, ганкәбүт чагырәвинең өчесен тотып алып, суга салып, изеп эчсәләр, гаять шифасы була (дәвалы). Бу үрмәкүчнең торуы сахраларда үләннәр арасында булыр, аерым (башка) җирдә тормаслар. Әмма ганкәбүте әһрәви шул булыр: олы баш бармак кадәре

1 К.да — үзренә (197 б.).
2 С.-П.да — чыгырды (286 б.).



www.darulkutub.com

булыр, тәненең өсте яшел торыр, аяклары — кыска. Олы диңгезләр якасында булыр. Аның өе дә булмас. Аның хасыяте шул булыр: хамилә (йөкле) хатынларга изеп, туглап эчерсәләр, рәхәм (аналык) авызы ачылып, бала табарга гаять файдалы булыр. Һәм дә шәһвәте (женси дәрте; орлыгы) кара булып, ак булмаган[1] ир кешеләргә туглап эчерсәләр, табигате үзгәреп, шәһвәте ак булыр, бала булырга гаять файдалы. Әмма ганкәбүте шәмакъи мәшһүрдер: аяклары озын, ау корып чебен тотар, аны ашар. Хасыяте шул булыр: җен суккан кеше яки эссеттмә тоткан (бизгәк тоткан; паралич суккан) кешеләр бу үрмәкүчне ваклап, кара чебен белән төеп тугласа, аннан ашаса, җен һәм эссеттмә зәхмәтеннән имин булыр. Назыйме рәхмәте Аллаһ галәйһинең морады монда ганкәбүт шәмакъидыр. Бу төр ганкәбүтнең торуы өйләрдә һәм сахраларда булыр.

Кырмыска бәянына килик: ул да өч төрле булыр. Берсе нәмәле чәгъдәри, икенчесе нәмәле таййари, өченчесе нәмәле кабакъидыр диләр. Беренчесе нәмәле чәгъдәри шул булыр: гәүдәгә зур, тычкан кадәрле булыр. Мохитның Габилә[2] дигән утравында тулы булыр. Аллаһ Тәгалә хәзинәләре андый утрауларда күп булыр. Шәбчыраг (асылташ) һәм ләгыль (ал, кызыл төстәге кыйммәтле таш) һәм якут кебекләр анда күп булыр Хак Тәгалә ул кырмыскаларны әүвәл шул хәзинәне саклау өчен яралтты. Аерым (башка) хайваннар ул хәзинәдән алмасыннар өчен. Ул кырмысканың хасыяте күп: Таҗаибе мәхлукат» китабына карасаң, анда язылган. Икенчесе нәмәле таййари («оча торган кырмыска») ике төрле: берсе кара булыр, әсәд бөрҗендә (Иран календаренең бишенче аенда, ягъни июль-август айларында; әсәд-арслан) яңгырлы көндә канаты үсеп, һава йөзенә очар, башка бөреҗләрдә (айларда) очмас. Хасыяте шул булыр: җәзам зәхмәтле (махау авырулы; «проказа»лы) кеше кар белән[3] бу кырмысканы туглап ашаса, гаять шифалы (файдалы). Өченчесе кече тәнле булыр, бик тә зәһәр булыр, тешләгән җире авыртыр. Хасыяте шул булыр: дуңгыз зәхмәтле («свинка») кеше төеп, борынына

1 С.-П.да — углан улмаган (286 б.).
2 С.-П.да — гаилә (286 б.).
3 С.-П.да — кар әйлап (287 б.).

тартса, дуңгыз зәхмәте аннан китәр. Бу кырмыскалар шәһәрләрендә (ройларында; күчләрендә) күп санлы түгел. Нәмәле кабакъи шулдыр: кара булыр, нәмәле таййаридан олырак булыр, шәһәрләрендә (ояларында) ише күп булыр, бикләре һәм казыйлары булыр. Сату һәм базарлар итәрләр, бер-берсен хөкем итәрләр. Нәмәле таййарины дошман тотарлар. Сөләйман пәйгамбәр г-мгә үгет биргәнен нәмәле кабакъи диерләр. Аларның гаҗәпләреннән шул — шаһлары ак булыр, теши (ана) булыр. Чөнки «Корьән»дә сәгыйәи мөәннәс («тырыш хатын») диеп искә алына. Хөкәмалар (хәкимнәр) әйтәләр: ишләре шәһәрләрендә йөз меңнән ким булмас, бәлки аннан да артык булыр. Аннан ким булса, шәһәр (оя) кормаслар. Бу ике хайванның гаҗәпләре шунда: үзенчәлекләрендә һәм сыйфатларында, атамаларында. «Гаҗаибел-мәхлукат» китабында язылып, мәкаләи сәласундә (өченче «бүлектә») бирелгән (язылган).

Калыб сән тәнкә диб әхвалең тәнкә,
Мәшәкъкатьләр башыңда рәнкә-рәнкә (төрле-төрле).

Ягъни, әй мөселман, Аллаһ Тәгаләне эстәүдә, акча артыннан йөреп калырсың, төрле-төрле мәшәкатьләр алдыңда бар. Аллаһны хисап иттмичә йөреп, газиз вакытларын акча артыннан үткәрә, димәктер. *Тәнкә* сүзенең элеккесе акча мәгънәсендә килә, төркичә, һәм икенчесе мәшәкать мәгънәсендәге сүз, фарсыча.

Йөгермә жифа (үләксә) күб кылмакга ел, ай,
Болай диб бай бәсатың бирмәгел бай.

Ягъни андый булса, айлар, еллар «үләксә» (мал, байлык) җыйнап күбәйтергә дип йөрмә. Аннан морад: харам кәсептә мал күп кылыр өчен йөрмә һәм дә, байлыкны арттырып, тагын да бай булыр өчен, гомереңне отыш уенында үткәрмә. Аннан морад: бай булыр өчен, газиз гомереңне харам кәсепләргә сарыф итмә, димәктер. *Бай* сүзенең элеккесе тәвангәр һәм гани (бай) мәгънәсендә була. Икенчесе отыш уены мәгънәсендә була, госмания сүзе. Яки вәзен шигырь булынып, бер мәгънәдә булды.

## Хирыслыкның (комсызлыкның) бәяны

Назыйм (автор, шагыйрь) фани дөньяга хирыслыкның чиген, дәрәҗәсен билгеләп боерды:

Йакыйн белгел моны, әй сахибе халь,
Хирыс ирмәс зийад[1] иткән белән мал.

Ягъни, шиксез бел, әй гыйльме хәл әһеле (суфый), хирыслыкның чиге бар, ягъни үзеңә мал җыю һәм аның күп булуы хирыслык түгел, бәлки безнең морадыбыз шул:

Хирыс улдыр: әгәр дөньяи фаный,
Йигай дисә мәхәббәт берлә аный.

Ягъни бу фани дөньяның малын күңел гыйшкы һәм сөюе белән җыйнаса, фани дөнья артыннан йөреп, фарызларның (тиешле гамәлләрнең) вакытын уздырса һәм дә аз малы булса да, аңа карата күңел мәхәббәте белән торса, шул хирыс кеше була...

Әгәр булса кешедә малы сәһеле (азы),
Күңел бирсә ирер дөньяның әһле.

Ягъни бер кешенең аз гына малы булса, аңа күңел биреп арттыру һәвәсендә булып, Аллаһның фарызларын өстеннән төшермәсен, мал арттыру кайгысы булса, дөнья әһеле шул була.

Бәсатында («табынында») бер арпа корсы булса.
Аны дүн әһле[2] («түбән җанлы») бел, гәр хирыс улса.

Ягъни хирыс шул булыр: бер кешенең өендә бер арпа микъдары көмеш йә алтын булса, аны арттыру теләгендә булып, Аллаһның фарызларының вакытын үткәрсә, хакыйкатьтә (чыннан да) түбән; әһәмиятсез, дөньяга хирыс кеше булыр.

Кешенең күңлендә бу фаный булса,
Ирер дөнья аның бер дани булса.

---

1 С.-П.да — зийадә (288 б.).
2 К.да — ирер дүн әһле (199 б.).

Ягъни бер кешенең күңелендә бу фани дөньяның фанилыгын билгеләгән булса, фани икәненен ачык белеп торып, гыйбадәткә хирыс булса, андый кеше аз гына акчасы һәм ярлы булса да, дөнья малының барчасын тапкан кебек канәгать булыр. Сүзнең асылы шунда: канәгать әһеле аз мал белән канәгать булыр, димәктер. *Дани* сүзе асылда бер акча дигәнне аңлата. Аз бәһале нәрсә алганда бирерләр, Харәзем халкының сөйләменнән яки гарәпчә сүз...

Әгәр бер колда йөз хәрбар зәрдер,
Әгәр булмаса миһре — би зарардыр.

Ягъни бер бәндәдә йөз ишәк авырлыгы (хәрбар) алтын (зәр) булса, анда мәхәббәте булмаса, зарар юк. Кыскасы, берәүнең күп малы булса, аңа теләк белән яратып табынмаса, мәхәббәте бәйләнмәгәнлегенең билгесе шул булыр: ул малын Аллаһ юлына сарыф итәргә саранлык кылмаса, андый кеше дөнья әһеле һәм хирыслар җәмәгатеннән түгел, димәктер.

Әгәр мең телла күзә төшсә күзгә,
Качан дәүләт булыр әһле дел үзә.

Ягъни бер Аллаһны танучының кулына мең чүлмәк (күз) акча (теллә) төшсә дә, ул кеше, әлбәттә, аны дәүләт дип белмәс. Бәлки мал төшкәненә[1] кайгыда булыр, мин аның зәкятен үтәп, ахирәттә хисабын ничек бирермен дип кайгыда булыр. *Күзә* сүзенең элеккесе чүлмәк мәгънәсендәге сүз, икенчесенең мәгънәсе ачык (билгеле). Кул сүзе күчерелмә рәвештә алынды. *Теллә* мәгънәсе югарыда ачыкланды.

Кайудыр миһре юк ирнең нишаны,
Боерган йирегә[2] — урынга, сарыф итсә итсә аны.

Ягъни берәү әйтсә: «Малга мәхәббәте (миһре) юк кешенең галамәте ничек?» — дип, ул кешегә, җавап шул: «Малга мәхәббәте юк кеше шул булыр: малын, зәкятен

1 С.-П.да — дөшдекенә (289 б.).
2 С.-П.да — җайга (289 б.).

һәм гошерен (уннан бер өлеш сәдакасын) чыгарса, саранлык һәм бәхиллек кылмаса, малга мәхәббәте юк кеше булыр».

Дисә: «миһрем юк», әмма тотса мөхкәм (нык),
Ирер ялганчы ул фәрзәнде адәм (адәм баласы).

Ягъни берәү Аллаһны танучылыгына дәгъва кылса һәм әйтсә: «Минем малымда мәхәббәтем юк», — дип, әмма кулындагы малын нык тотса, саранлык кылып Аллаһ юлына һәм боерган әмеренә буйсынмыйча дәгъва кылса, хакыйкатьтә чын ялганчы адәм баласы шул булыр, дәгъвасендә кире булып, эше ялган булды. Чөнки бер Аллаһны танучы булган кеше, әлбәттә, малын гашыйкларча Аллаһ ризалыгына сарыф итәр.

Кеше малы ки би ихсан имәсдер,
Ходаның фазлыдыр, дөнья имәсдер.

Ягъни бер кеше малын изгелек кылу юлында сарыф кылса, ул мал Аллаһның рәхмәтедер, дөнья әһеленнән түгелдер, чөнки ул кеше дөнья әһеленнән булса, үкенер иде.

Димә: дөнья чырагы ахирәтдер,
Ходаемдай нишаны — мәгъфирәтдер (ярлыкаудыр).

Ягъни андый Аллаһ юлына сарыф кылган кешенең малын дөнья малы димә, бәлки ахирәт йортының чырагы дип әйт, һәм Аллаһның бу бәндәне, рәхмәтен чәчеп, үзенә якын кылуыдыр, дип әйт.

Безагать (байлык; мал) булса һәркем илә инфак,
Өземдер бәрге күб рәздин сөчүкрәк.

Ягъни андый булса, бар малыңны Аллаһ юлына сарыф кыл, азлыгына карама; йөзем агачының яфрагы үзенең[1] җимешеннән татлырак[2] булыр. Андый аз малны ихласың белән Аллаһ юлына сарыф итсәң, сәвабы күбрәк булыр, димәктер.

1 К.да — азынын (200 б.).
2 К.да — ләззәтледер (200 б.).

www.darul-kutub.com

Кирәк әһле кәрәм халык иткәли җәмгъ,
Үзене дәмбедәм (һәрчак) эш кылса чөн шәмгъ.

Ягъни, андый булса, юмарт кеше (әһеле кәрәм) бар малын фәкыйрьләр һәм мескеннәр җәмәгатенә сарыф итеп тапшыру, үзеңне ким күреп тору, кылган яхшылыгыңны искә төшереп битәрләүдән ерак булу кирәк. Чөнки шәм чырагының янында кешеләр үзләренә файда алыр өчен җыйналып торыр. сәгатьтән сәгатькә ул шәм чырагының филтәсе кимер. Андый файда-игелек эшләгән кеше бар малын сарыф итеп, үзен ким күреп, рәхмәттән ерак булыр, малының беткәненә пошынмыйча, ышаныч күрсәтеп, аннан башка кирәк-яракларыма ни кылырым дип фикерләмичә яшәр[1], чын, дөрес юмарт, киң күңелле туендыручы һәм игелекле кешенең хәле шундый...

Кешенең игътикады (ышанычы) улса салим (исән-сау),
Димәс: гүре кәфенлекдер — бу малым.

Ягъни бер кеше, фәкыйрьлектән сәламәт булып, игътикады (ышанычы) дөрес булса, малының беткәненә кайгырмас, бу минем кәфенлегем һәм әзерләп куюым кирәк булыр димәс, бәлки барын сарыф итәр.

Нә гамь иманлы колның үлгәнидә,
Тәнидә улмаса өч гәз тәнидә.

Ягъни иманлы туендыручы; игелекле бәндәнең үлгәненә кайгы-хәсрәт юк, ахирәт йортында ул һаман бер олуг шаһ, гарчә дөньяда өч микъдари[2] бүз тәненә кәфен булмаса да, кайгы юк.

Чөнки кәфенлек тәндә чолгану[3] Аллаһыга якынлыкка сәбәп түгел, бәлки Аллаһка якынлыкка сәбәп — иман булыр. *Тәнидә* сүзенең әүвәлгесе бәдән (тән) мәгънәсендәге сүз, фарсыча.

Сәламәт булса иман белә кәс (кеше),
Әгәр гари күмелсә, гари улмас.

1 С.-П.да — әйләмә (290 б.).
2 К.да — аршун (200 б.).
3 С.-П.да — тәнне кәфергә чолганмакда (290 б.).

Ягъни бер кеше, Аллаһ рәхмәтенә ирешеп, дөньядан иман белән китсә, гарчә кәфеннән ялангач булып күмелсә дә, аңа хурлык юк. *Гари* сүзенең әүвәлгесе гөрйан һәм ялангач мәгънәсендә була. Икенчесе истинкяф (тайпылучы; читкә кагылучы) һәм хурлык мәгънәсендә килә, яки һәр икесе бер мәгънәдә. Вәзен, шигырь өчен махсус алынды.

Кәрәмлек бәндәсе гәр булса чүлдә,
Эчрер булмаса бер зәррә күлдә.

Ягъни бер әһеле кәрәм (юмарт кеше), игелек иясе янында калып, каты сусап, чокырлардан су эзләп, зәррә кадәренчә («тамчы да») су тапмаса. Бу бәет мөбтәдадер (башлангыч өлеш). *Чүл* япан мәгънәсендә килә. *Күл* чокыр мәгънәсендә була, һәр икесе үзбәк сөйләменнән алынган.

Кубыб ултыргали калмый мәҗале,
һәлакәт пилләсигә (дәрәҗәсенә) йитә хале.

Ягъни ул әһеле кәрәм сусаганлыктан гаҗиз калып, утырырга, торырга хәле калмыйча, һәлакәт күперенә хәле җитсә, аннан морад гаҗизлек хәленә җитсә.

Әгәрчә күз йашечә су табса анда,
Кылыр йарымыны сарыф үзгә бәндә.

Ягъни шундый мәшәкать хәленә (чигенә) җитеп, чокырлардан күз яше кадәр микъдарда су тапса, әлбәттә, әһеле кәрәм фәкыйрьләргә[1] яртысын сарыф итәр, димәктер. Бу бәет — хәбәре мөбтәдадер...

Табылса локмәи җан вә җигәрдин[2],
Дәригъ итмәс (кызганмас) аны йар дигәрдин (үзгәдән).

Ягъни, бер әһеле кәрәм бер локма (токмач) кадәре нигъмәтне күпме мәшәкатьләр белән тапса да, әлбәттә, ул кеше ул локмәи нигъмәтнең яртысын икенче бер мөселман карындашыннан кызганмас.

1 К.да — үзгә кемсәнәгә (201 б.).
2 С.-П.да — чигәрдин (291 б.).

Кәрәмлек бәндәгә йалгыз йийган аш,
Булыр хәк (туфрак) агзыда бәлки белер таш.

Ягъни юмарт бәндәгә ялгыз җыйган (ашаган) аш күңеленә лаек килмәс, бәлки ул ашны бугазында дошман күреп, туфрак һәм таш җыйганы кебек, ләззәт белән бугазыннан үтмәс, димәктер.

Шәкәр нуш итсә табмагай бәһр,
Белер кан агзыда, бәлки белер зәһр.

Ягъни ул юмарт бәндә, әгәр шәкәр нуш итсә (шикәр эчсә дә), файдасын (бәһр) тапмас, бәлки кан вә зәһр (зәһәр — агу) эчкән кебек бугазында дошман күрер; аннан дошман күреп, ялгыз ашауны ихтыяр кылмас, бәлки артканын дәрвишләргә бирер. Мондый хәл — заһидлек тарифлар (дөньядан ваз кичкән монахлар) хәле. Әмма шәригатъ әһелләре кирәк кадәрге азыкны елдан елга җитәр кадәрен саклап торса, зыян юк, бәлки саваплы гына була, нәфел сәдакадан булыр.

Кара су эчсәләр ике берадәр (туган),
Күрәр ширбәтенчә бәлки абе кәүсәр.

Ягъни ике мөселман кардәш, мәҗлестә булып, кара су эчсәләр, гайре нигъмәтләр булмаса да, ул кара суны, бер-берсеннән файдаланып, рухи азык хасыйл итәрләр.

Ике һәмдия (фикердәш) йийса бер локмә нандан,
Сөчүк белгәй гасәлдән бәлки җандан.

Ягъни бер күңеллек (һәмдия) һәм бер иманлы кеше бер локмә ризык ашасалар, балдан (кесәлдән) яки җаннан артык күреп ашарлар, аның белән бер-берсенә куәтле рух хасыйл итәрләр.

Кеше нандик кылыр ихсанда хуйин,
Алыр тәнүр (мич) эчендә абе руйин.

Ягъни, бер кеше изгелекне вә юмартлыкны теләгәндә, йөзен ачык кылып, игелек иясе буларак ярдәм кылса,

www.darul-kutub.com

андый кеше мич эчендәге икмәк (нан) кебек йөз суы (абруй) алыр. Чөнки күрмисеңме: икмәкчеләр мичкә икмәкне салганда, икмәге гүзәл булсын өчен, икмәк йөзенә су сибәләр. Пешеп чыкканнан соң, икмәк гүзәл була, барча халыкка хөрмәтле була. Ул икмәкнең хөрмәтле булуының сәбәбе судан булган кебек, күп мәшәкатьләргә очрап, дучар булып нигъмәт табып игелек итәр. Шул икмәкнең йөзе кебек халык арасында газиз, хөрмәтле булыр...

Кызыл йөзлек булыб чыкган замани,
Төшәр халык агзыга ихсани ани.

Ягъни чөнки ул икмәк, мичтән кызыл йөзле булып, күңелләргә хуш булып чыгар. Шул чыккан заманында барча халыкның авызына изгелек белән төшәр. Әйтмәс: «Мин халыкка зәһәр (агу) булам, чөнки мичтә күп мәшәкатьләр чиктем», — димәс. Бәлки һәрчак хуш булып, бугазлардан үтәр. Андый бер әһеле кәрәм дә «мин күп мәшәкатьләр белән маллар таптым, адәмнәргә ни өчен игелек кылып ярдәм итим», — димәс. Болай дию ахмаклык булыр. Андый булса:

Көлеб миһман кашыйга (каршысына) чыкгыл, әй кол,
Шәҗәр (агач) мивәдин әүвәл күрсәтер, гөл.

Ягъни, сиңа көтмәгәндә кунак килсә, ул кунакның каршысына көлеп чык — кунакларга олуг хөрмәт шушы, чөнки бу нигъмәтнең башы. Чөнки җимешле агач әүвәл чәчәк ярыр, андан соң җимеш бирер. Ник дисәң, агачның башлангычы чәчәк инде. Андый әһеле кәрәмнең кунакларга башлангычы ачык йөзле һәм көләч булып торуы булыр. Андан соң бар нигъмәтен хәзер итәр, ул — хатимәсе (бетеме):

Әгәр ихсан идәр булсаң, ишет, хәриф,
Аны һәр җайга кылмак кирәк сарыф.

Ягъни ишет: изгелек эшләү төрле булыр, ләкин изгелек теләп, малны Аллаһ юлына сарыф итәргә теләсәң, аны урынына (җайга) сарыф итәргә кирәк.

Чөнки явызлык юлына мал сарыф итсәң, аны изгелек димәсләр, барча эшләгән изгелегең юкка чыгар...

Болаб бер җайга кәддиминне,
Зирагать әйләмә шуре заминне (тозлы җирне).

Ягъни син, ашлык-тары чәчәргә теләсәң, куәтеңне һәм көчеңне (кәддиминне) җирнең яхшысына сарыф кыл, лаек урынны сайла; лаек булмаган ачы һәм сазлык урынга орлыкны әрәм итмә. Андый изгелек кылсаң, галимнәргә һәм суфыйларга кыл, әҗере күп булыр. Явызларга изгелек эшләү сазлы җиргә орлык чәчү кебек.

Йаман йиргә аны сарыф итмә, йари,
Бүренең ертарига бирмә йари.

Ягъни, кыскасы, малыңны яман җирләргә сарыф итмә, мәйханәләргә һәм кухларга («түбән суыруларга») сарыф кылма, бәлки әһеле тәкъваларга сарыф кыл, мәчетләр һәм мәдрәсәләр бина кылдыр... Аяте тәфсиреңдә әйткән, надан мөселманнарга изгелек кылу — берсенә ун савап булыр, галимнәргә һәм шәкертләргә сарыф иту — берсенә йөз савап булыр, сәйдзадәләргә изгелек кылу — берсенә мең савап булыр, залимнәр һәм кяферләргә изгелек кылсаң юкка чыга, — диелгән. Бәлки гөнаһы да уртак булуы билгеле булыр, — диде. Имам Заххак (? Зоххак) әйтте ки: кяферләргә бер изгелек өчен бер савап булыр, — диде...

Кил, әй нәфес, булма әкнүн (хәзер) табигы нәфес,
Сулыр ахшам, саба бу гәрдәне гафес.

Ягъни, әй андый суфый, кил, һавалы нәфесләренә иярүче (табигы нәфес) булма, үткәннәреңә борчылып тәүбә кыл, калганнарына нәфесеңә ирек бирмә; чөнки нәфесеңне ирекә җибәрү белән муеның юан булыр, симерерсең. Әмма ләкин, тән симертүең мәңгелек түгелдер, бәлки көннәрдән беркөн арык булыр, кимер. Андый булса, нәфесеңне сугышып җиң. *Гәрдән* муен мәгънәсендәге сүз. *Гафес* (гафәс) юан һәм гализ (юан) мәгънәсендә килә. *Нәфәс* (нәфес) сүзенең әүвәлгесе зат

һәм шәхес мәгънәсендә була, икенчесе (нәфес) нәфес һәм хайвани нәфес диерләр. Әйтәләр: боеручы нәфес бер тун[1] кебек, барлык әгъзаны каплап ала, шуңа күрә хайвани нәфес диерләр. Әмма кеше нәфесе мәңгелек дөньядан фани дөньяга күчеп килгән. Аны нәфсе инсани (кеше нәфесе) диерләр...

Һәммә тагатьләрең хубы вә сафы,
Йакыйн белсәң — ирер нәфсең хилафы.

Ягъни барча тәгать вә гыйбадәтләрнең гүзәле һәм сафы, шиксез бел: нәфесеңә хилафлык китерү (нәфесеңә буйсынмау), чөнки нәфесеңә ихтыяр бирү кыекка; ялганга тартыр...

Куяр кечелеккә даим нәфсе бәд йөз,
Качан ут төз йанар йалбарсаң утыз.

Ягъни явыз сәркәш (кире; тискәре) нәфесеңә ихтыяр бирү, даими аның әмерендә булу сине кире юлга тартыр, чөнки янучы ут та төз янмас, бәлки һава агышына мөнәсәбәтле (сәбәбе беләН) йөрер. Андый нәфесе кяфирәгә яраклашу үзенең кяферлек арбасына тартыр, димәктер.

Ирер нәфсең дәмагы торфә (йомшак) йиллек,
Качан калыр йалбарсаң иллек (илле мәртәбә).

Ягъни чөнки синең нәфесең мәгъдәсе (тамагы; ашказаны) күзгә күренми торган җилдер, яшерен, сине аздыру ниятендә торыр. Чөнки коры һава дулкыннары йомшак рәвештә утның хәрәкәтен, януын кузгатыр, тәэмин итәр. Андый нәфсе кяфирәгә ия булма, гарчә илле мәртәбә ялварсаң да, синең беләН дус булмас, һәрвакыт явыз булыр, рийазәт (аскетлык) капкасына бикләнеп, аның беләН сугыш, көрәш алып бар. Ахыры, күп сугыша торгач, бәһадур рух башын кисеп, тәхетенә утырып, җирне алыр, аннан соң фани дөньяда Аллаһ беләН булырсың, димәктер.

---

1 С.-П.да — томан (294 б.).

Үзең пәст (түбән) әйласәң, нәфсең зәбәрдәст (югары).
Башың чәйнаб[1] салыр чән өштере мәет.

Ягъни үзеңне түбән, нәфсеңне югары кылсаң, аны югары кылу шул булыр: теләгән нәрсәләрне биреп кенә, аның өчен яраклашып торуыңдыр. Болай эшләүнең ахыры бер көн исерек тәва (өштере мәет) кебек башыңны чәйнәп хәрап итәр. Аннан морад: иманнан чыгарып, әбәди (мәңгелек) тәмуглык кылыр. Андый булса, ул кяфергә хилафлык кыл, диmәктер. Әйтәләр: иркәк тәва Хәмәл Көрдеңдәй Сәвер бөрҗенең ахырына дигән (Иран календаренең беренче һәм икенче айларында, ягъни якынча март-май айларында), исерек булыр. Исерек булуы шуның өчен: тешисенә (ана дөягә) зәвыкланганлык (гашыйкланганлык) җәһәтеннән.

## Тәвә белән филнең бәяны

Әйтәләр: тәвә оҗмахтан чыкты. Туби (туба — мифик агач исеме) агачының яфрагыннан яратылды, шуның өчен олы, куәтле булды. Фил белән кардәшләр имеш. Карындашлыгына сәбәп шул булыр: Изи гыйзз-у җәлл (бөек вә кодрәтле Аллаһ), тәвәне ялрaткач, оҗмахта йөртә икән, бер көн үлем кучкарын күргән. Ул кучкар, оҗмахның бер тарафыннан үтеп барганда, тәвә аны күреп куркып бәвел иткән («кече йомышын» башкарган). Изи гыйзз-у җәлл ул бәвел иткән туфракны алдырган, дөнья йөзенә иңдергән. Чөнки андый начар нәрсәләр оҗмахта булмасын өчен, ул туфракны Арадаил дигән фәрештә, китереп, Бәйтел-мөкаддәс (Изге йорт) җирендә куйды (кунды), хәтта ки ул туфрак Адәм г-м дәверенә кадәр торды. Аннан соң тәвә бер көн оҗмахта йөри иде, Газазилны (Иблисне) күрде. Газазил бу җир йөзе сыйфатын бәян итте. Ул ахмак бу ләгыйньнең әйткәненә кызыксынып теләк белдерде: «Әгәр Изи гыйзз-у җәлл миңа әмер кылса, дөнья йөзенә иңәр идем, — дип. Хакъ Тәгалә хәзрәтенә мөнәҗәт әйтте. — Йә Рабби, мине дөньяга иңдер[2], — диде. — Анда урнашырмын», — диде.

1 С.-П.да — чинар (295 б.).
2 С.-П.да — үзрәгел (296 б.).

Изи гыйзз-у җәлл кадим гыйльме белән моның адәмнәргә файда булырын белә иде. Мөнәҗәтен (үтенечен) кабул кылды. Дөнья йөзенә җефете белән җибәрде... Кайчан ки Изи гыйзз-у җәлл Адәмне яралтты, оҗмахка кертте. Аннан соң җир йөзенә иңдерде. Уллары күп булды. Бер көн Изи гыйзз-у җәлл Адәм пәйгамбәргә хитаб кылды (мөрәҗәгать итте): «Йа Адәм, диңгездәге бер утрауда бер җен каласы бардыр, аларны тугры дингә өндә», — диде. Адәм г-м Тәңренең әмерен җиренә җиткерер өчен, Сәрәндибдән (Цейлоннан) ул диңгезгә барырга ниятләде. Улы Шиш пәйгамбәр һәм башка[1] уллары белән кырык кеше булып киттеләр. Хакъ Тәгалә тәвәне боларга җибәрде.

Азыкларын һәм коралларын[2] йөкләделәр... Югарыда телгә алынган туфрактан филне яралтты: колаклары дуңгыз сурәтле, кабак яфракы кебек озын борынлы, кыска коерыклы. Хак Тәгалә Адәмгә әйтте: «Ул җен шәһәренә баргач, сиңа иман китермәсәләр, кальгаләрен бу хайван белән бездырырсың, — диде. — Мин аңа йөз мең куәт бирдем», — диде, Әлкыйсса, ул җен шәһәре иман китерделәр. Әйтәләр: фил йөкне уникe ел күтәрер. Хикмәте шул булыр: Адәм г-м алып барган фил ана иде. Адәм г-м, тәвә һәм фил аягы белән сугышырга, ул җен шәһәренә уникe ел барды. Адәм г-м дога кылды: «Йа Рабби, бу филнең ашавы, эчүе күп. Моны йөкле кылсаң, баласы уникe ел корсагында булсын, — диде. — Нәселе аз булсын, шаһларга лаек булсын», — диде. Изи гыйзз-у җәлл догасын кабул кылды.

Әйтәләр: фил йөз яшәр, илле яшенә кадәр олыгаер, куәтләнер. Аннан соң кырык ел шул куәте белән торыр. Аннан соң ун ел эчендә такате калмас: әҗәле җиткәндә, җәзам зәхмәте (махау авыруы, «проказа») белән үләр. Әҗәл[3] куркынычы кешенеке кебек.

Сорау: «Тәвәнең ите, сөте ни өчен адәм улларына хәләл булды, фил харам булды?» Җавап шул булыр: «Тәвә Туби агачыннан яратылды, шәрәф (затлы) нәрсәдән иде. Шуның өчен хәләл булды. Әмма фил морад (үләксә), чиркин (җирәнгеч) нәрсәләрдән яралтылды. Асылы

---

1 С.-П.да — әзин (296 б.).
2 С.-П.да — силахларыны (296 б.).
3 С.-П.да — хәл (297 б.).

нәҗес булганы өчен харам кылынды». Әйтәләр: тәвә танбур (кыллы музыка коралы), гөслә һәм орган авазын сөяр. Әйтәләр: тәвә ике төрле була. Берсе өркәчле, берсе өркәчсез. Оҗмахтан иңгәндә, тәва өркәчле иде. Өркәчсез булуы Дәкъянус (явызлыгы белән мәшһүр Рим хөкемдары) заманында булды. Әйтәләр: Дәкъянус тәңрелек дәгъвасын (үзен Аллаһ дип) кылды. Даладагы ни төрле киек бар иде — барчасын бергә туплады. Ул киекләр эчендә болан дигән киек тә бар иде, тәвәгә охшаш иде. Дәкъянус әгыйнь, бер ана боланны тотып, иркәк тәвәгә җилдерде. Аннан бер тәвә туды, өркәчсез булды. Хикмәте шул булыр. Боларның кыйссалары күп, кыскалык сәбәпле шулар гына бәян кылынды. Кирәк кеше «Гаҗаибел-мәхлукат» китабына карасын, анда тулысы белән бирелгән.

Борынга баде кибр исмәи борындан,
Борындык сал аңа куймай урындан.

Ягъни, хайвани нәфескә ихтыяр биреп, томшыгына тәкәбберлек җиле (баде кибр) искәнче һәм кергәнче, ул хайвани нәфеснең борынына тәвә борынныкы кебек борындык сал. Кыскасы, нәфесеңкуәт табып, синең рух шәрифеңә хуҗа, өстен булганыннан элек, теләгән нәрсәсен бирмә, димәктер. *Борындык* бер зинҗир (чылбыр), җәмаг (капланылган) тәвәләрнең борынына тагалар, башка җәмаг булганына (җәмаг булмаганнарга) алка тагалар. Әмма монда ашау-эчүдә чикләнүчәнлек мәгънәсендә алынды...

Риязәт бәндигә беркет аягын,
Күтәрмә башдин тәкъва таягын.

Ягъни андый булса, ул нәфсе кяфернең аягын мәшәкать һәм хилафлык җебе белән бәйлә, асылда аңа теләгән һаваларын бирмә. Ул явызның ашау-эчүдә чикләнүчәнлек таягын башыннан алма, һәрчак ашау-эчүдә чикләнүчәнлек таягы белән кыйна.

Екылыб калмагу дәк бир йимешне,
Зиадә кәм-кәм катигь эшне.

Ягъни, ул хайвани нәфескә ачлыктан гаҗиз булып, егылыр хәлендә нигьмәт бир, тук хәлендә бирмә, димәктер. Әмма ашау-эчүдә чикләнүчәнлектә (аскетлыкта) булсаң, бер юлы нәүмиз кылма, бәлки ашау-эчүдә чикләнүчәнлекне уртача кыл. Ашау-эчүдә кинәт чикләнүчәнлек харам. Чөнки зиадә кәм-кәм («күпчелек очракта аз-азлап») моңа ирешелә.

Куеб әнзадә халенчә йөкне,
Гыйбадәт юлига күндер бу лүкне.

Ягъни, ул нәфесеңә ашау-эчүдә чикләнүчәнлек теләсәң, чама, үлчәм белән кыл. Чамадан тыш ачлык һәм фәкыйрьлеккә дучар итмә, бәлки чамалап, хәленчә куеп, ул симез нәфесеңне тәгать вә гыйбадәт юлына күндерү өчен тырыш, чөнки тәдриҗ (әкренлек; эзлеклелек) белән ул симез нәфесең, мае эреп, рухи куәтең галиб (өстен) булыр. Бу — исем ишарә буларак килә. *Лүк* — гарәпчә, җәмгылеккә килгән, симез мәгънәсендәге сүз.

Бу михнәт берлә ул әммарәт дүн,
Нә булгай мотмәэннә ул бер көн.

Ягъни, ул хайвани нәфесне ашау-эчүдә чикләнүчәнлектә уртачалык белән михнәткә салып, гыйбадәткә күндерүең бер көн мөмкин булса кирәк... Аннан соң Шиш җәһәтендәй илһам килеп, һәр җанәбе (тарафка) карасаң, мәгъшуке кадими (элеккечә күркәм) күренсә кирәк, димәк. Нәтиҗәдә, ашау-эчүдә чикләнүчәнлекне уртача кылу безнең тиешле һөнәребездән.

Симез күб кылма бу тешләк этеңне,
Симереб йармагай нагяһ битеңне.

Ягъни, андый булса, бу тешләк этеңне симертмә. Аннан морад: теләгән нәрсәләрне бирмә, чөнки ул синең нәфесең симереп торып, бер көн битеңне ярмасын. Аннан морад: рух шәрифеңә хуҗа булып, ул шәрифне түбән; мәсхәрә кылып, тәмугта газапка дучар итмәсен. Эт симерсә, иясенә кабара дигәннәре моңа мисал.

Еланны асрадың монча ел ани,
Олуг булгай саен өстен зыяны.

Ягъни нәфес еланын өеңдә күп еллар асрадың. Ул елан олы булган саен, ул еланның зыяны күп. Аннан морад: нәфесеңә ихтыяр биреп, күп еллар йөрткәнең саен, сине һәлак итеп, үзеңне Ходаеңнан ерак кылыр.

Үтебдер кул белән буенын тотардин,
Хәтардер көч кылыб башың йотардин.

Ягъни ул хайвани нәфесең сиңа җиңел нәрсә белән үтеп кергән, хәтта шундый хәтәрнең хәленә ирешеп, рух шәрифеңне йотар дәрәҗәгә җитешкән. Аннан морад: күп ихтыяр бирүең белән көферлек чоңгылына ирешерсең, димәктер.

Йитебдер куйгали күксен йөзигә,
Кем диерсән үзең кылдың үзигә.

Ягъни ул явыз нәфесеңә күп ихтыяр бирүең белән олыгаеп, кабарып, күкрәген йөзгә капма-каршы китергән, хәтта, рух шәрифең җиңелгән, аны иман тәхетен урыныннан кубару хәленә җиткергән. Бәс, нәфсеңнең андый булуы үзеңнән, башкадан үзгәдән түгел, һичбер кешегә үпкәләмә, димәктер.

Дәла халән ки һәм тотма үзең пәст (түбән),
Билгә багла һиммәт футасын раст (рәст).

Ягъни андый күңел халән (хәзер) таләбе бабында үзеңне үзең ким тотма, бәлки олы дәрәҗәдә булып, билгә мәхәббәт путасын (билбавын) баглап, һәрчак хайвани нәфесне мәшәкать чиктерүдә бул.

Тәвәккел сәйфене сыйдкы илкеңә ал,
Кыл эчне халис, андан соң кылыч ал.

Ягъни үзеңне ким тотма, тәвәккәллек кылычын ныклык белән кулыңа алып, һәрчак ул кяфер белән сугышта бул. Тәвәккәллек кылычын ул заманда алу

лаеклы. Элек калебеңне (йөрәгеңне; күңелеңне) рия һәм тәкәбберлектән, хөседдән (көнчелектән) вә гожебдән (масаюдан), начар әхлак (әхлаксызлыктан) зәмимәләрдән (гамәлләр; ярамаган эшләрдән) чистарт, алардан берсе булса, моннан соң ул кяфер белән сугышта бул, димәктер.

Тәгаҗҗәб белмә фазл бибәһадин,
Хәлас итсә моның дик аҗдаһадин.

Ягъни, мондый аждаһа кебек нәфестән бер көн коткарса, Ходаның рәхмәтен гаҗәп дип белмә. Чөнки Аллаһның кодрәтенә гаҗәплек кылу кяферлек. Барлык гаҗәпләрнең иң өстене — Аллаһ үзе.

Гарыз (үтенеч): мондаг годуни (дошманны) кылма фәрбәһ,
Әгәр килсә кулыңдин катигъ сәрбәһ.

Ягъни, кыскасы, мондый дошманны симертмә. Аннан морад — нәфес. Аның теләгәнен бирмә. Әгәр ир егет булып, кулыңнан килсә, ул кяфергә нәфесенең башын кис.

Симерсә нәфес әгәр эчмәк, йимәкдин,
Йөз анча эт улыр артык димәкдин.

Ягъни, хайвани нәфес ашау-эчүдән симереп өстен булса, әүвәлгедән йөз тапкыр артык эт булыр, һәм симерер яки этлеген арттырганнан арттырыр, һәм халыклардан төрледән-төрле җай[1] алыр. Әһеле бидгать бу кешенең бидгать (ярамаган эш) юлында йөргәнен күреп, «фәлән яхшы, фәләнчә малны эчүгә һәм ашауга сарыф итте», — диерләр, үзләренең зур мәҗлесләрендә өстен куеп, аны «әй ага, яхшы килдең һәм сафа йөрдең», диерләр.

Йәнә юкары үтмәкдин бирер бәһр,
Бу[2] нәфсе җәһилә дөньяи бәде каһр.

Ягъни ул хайвани нәфес мәҗлесләрнең югары үтүеннән (мәҗлесләрнең югарысыннан) файда алыр

1 К.да — чаб (206 б.).
2 С.-П.да — вә (300 б.).

һәм куәт табар. Бидгать фигылен арттырыр, эчү һәм ашау һәвәсендә булыр, бидгать мәҗлесләрнең түрендә утырып, әһеле бидгать барчасы аны олылар, андый булса, бу нәфес надан, иләмсез, дөньяда морадларың бирмичә, бугазыңнан буып каһәр кылыр, димәктер...

Үтеб мән диб үтәрдә улмагыл шад,
Үтең, — диде, — үтен алгай бу җәллад.

Ягъни мәҗлесләр түрендә утырып: «Мин халыкларга рәис буламын», — дип шатлык кылма; чөнки сине халык олыламый; чөнки сине бу халык олылаулары, хөрмәте үзеңә генә зарар. Кинә, нәфес аннан югары мәртәбәдә булуны эстәр. Ахыры бер көн ул ләгыйнь югары мәҗлесләргә үтә торгач (үткәч), иман үтеңне алыр. *Үтен* сүзенең әүвәлге исеме масдар (исем фигыль), ягъни савахибләрнең[1] (хуҗаларның) «әй ага, югары утыр», диюе. Икенче исеме җам, хайван үте мәгънәсендә.

Кеше белсә риза шәһдине зәукын,
Белер бер дәк мәҗалис тәхт-ү фәукын[2].

Ягъни берәү, Аллаһның ризалыгы шөкереннән татучы булса, әлбәттә, андый кеше мәҗлесләрдә югары утыру белән түбән утыруны бәрабәр күрер. Асылда мәҗлесләрдә югары утыруны теләп итмәс һәм дә түбән утырамын дип хурланмас. Андый булса, даими Аллаһ әммарәсигә хилафлык итер һәм халыкларның «йа ишан һәм йа мөбарәгебез!» диюләренә алданмый, һәм зикре тиләвәте «Коръән»не («Коръән»не яхшы тавыш белән укып зекер кылуны) тиешеннән артык я ким итми башкарыр...

Торыр үз халидә бесийар (күп) димәкдә,
Йөрешен бозмагай һич шад-у гамьдә.

Ягъни хакыйкыйтә Аллаһ Тәгаләнең чын шәкерте үз хәлендә торыр, халыкларның күп тагать вә гыйбадәт итә (Аллаһка күндәм һәм табынучы) диюләренә һәм аларның мөбарәк исем бирүләренә алданмас, һәрчак үз

3 С.-П.да — мәвасибләрнең (300 б.).
4 С.-П.да — фәүте-фәхтен (300 б.).



www.darul-kutub.com

юлында булыр, рәхәт һәм мәшәкатьләргә очраса да, үз асылын бозмас, нәфсе әммарәсигә буйсынмас, димәктер...

Кеше күрсә Ходадин җәзеи көлне,
Белер хәйрият ул гыйззәте зөлне (күндәмлекне)

Ягъни, берәүнең башына ниндидер хөкем очраса, ул хөкемнәрнең изгесен һәм явызын, олыгын һәм кечесен — барчасын Аллаһдан дип белер, башкадан дип белмәс. Төгыйззә мән тәшаэә вә төзиллү мән тәшаэ аятенә иман китереп, халыкның изге һәм явыз итүләрендә игътибары булмас, һаман үз юлында торыр, димәктер.

Ирер халә ки тәүбә бабы мәфтух,
Йаман нәфсеңне кылгыл табигы рух.

Ягъни, андый булса, Аллаһ Тәгаләгә шөкер, тәүбә ишеге ачык (мәфтух), тизрәк гөнаһларыңнан тәүбә кыл һәм нәфсе әммарәгә хилафлык итеп, җанга иярүче бул, чөнки рух шәрифең югары Хак җәнабенә баруны эстәр[1], нәфсеңне аңа буйсынучы ит.

Әгәр нәфсең сәнең йиттмеш башыңдан,
Нә булгай файда йиттмеш яшеңдән.

Ягъни, синең нәфсе әммарең башыңа җитеп, үзе теләгән урыннарга илтсә, ул нәфсеңә ни теләсә шуны бирер булсаң, җиттмеш ел гомер сорап карый (карт) булуыңда файда юк.

Әгәр нәфсең морадин әзләмәк сән,
Әгәр сиксәнгә йитсәң һәмчү сәк сән.

Ягъни, син даими, нәфесең теләгәнне эзләп, аның артыннан йөрсәң, гарчә сиксән ел гомер сөреп карый булсаң да, һәрчак эт (һәмчу сәк) син, синең карыйлыгыңнан файда юк.

Әзәлдин кылса һәркем күңелне риш (яралы),
Дигәй унбиш яше күб, бәлки, ун биш (илле).

---

1 С.-П.да — тартар (301 б.).

Ягъни әзәл (мәңгелек; яратылу) көнендә һәркемнең күңелендә Аллаһдан курку җәрәхәте булса, андый кеше унбиш яшендә булып, гыйбадәт кылса — илле яшь гомер сөргән кеше кебек. *Унбиш* сүзенең ...икенчесе ун төштә биш мәгънәсендә була, барысы илле яшь була.

## Вәгъдәдә төз тору бәяны

Кил, әй садыйк, ки кылдың сыйдк лафын,
Үләнчә кылмагыл вәгъдә хилафын.

Ягъни, әй андый Аллаһ Тәгаләне һәм хак пәйгамбәрне рас дип белүче кеше, әгәр син раслык дәгъвасын кылсаң, үләр көнгәчә әйткән вәгъдәгә хилафлык итмә. Чөнки әйткән вәгъдәдә тору мактауга лаеклы әхлакның югары дәрәҗәсендә була. Моны һәм әхлакы ходавәнд (әдәпле хода бәндәсе) диерләр... Пәйгамбәр г-м әйтте: «Берәү әйткән вәгъдәсендә тормаса, әлбәттә, аның күңелендәге иманы нык, ышанычлы түгел», — диде.

Әйтәләр: бер көн пәйгамбәр г-мгә бер гарәп әйтеп бирде: «Йә рәсүлулла, мин сиңа килерем», — дип вәгъдә кылды. Пәйгамбәр г-м, вәгъдәчене көтеп, кырык көн өеннән чыкмады. Бер көн ул гарәп эчкә керде, сәлам бирде. Аннан пәйгамбәр хәзрәтләре сәламне алмады. Гарәп әйтте: «Йә рәсүлулла, ни өчен син аны алмадың?» Пәйгамбәр г-м әйтте: «Син икейөзлесең, мөнафикъ сәламен алу тиешле түгел». Шуннан, беленде ки, вәгъдәгә хилафлык итү (вәгъдәдә тормау) мөнафикълык (икейөзлелек).

Хилаф иткән зәбунләрдин зәбундер.
Бу дөнья вә у(л) дөнья сәрнәгундер.

Ягьни биргән вәгъдәсенә хилафлык кылган кеше зәбуннәрдән (түбәннәрдән) зәбуне. Бу дөньяда һәм ахирәттә баш түбән (сәрнәгун) килерләр, ягъни оятлы була...

Хәлаек алдыда кутаһ (кыска) зәбандыр,
Хода дәргяһидә андан йамандыр.

www.darulkutub.com

Ягъни биргән вәгъдәсенә хилафлык кылган кешенең дөньяда түбәнлеге шул булыр: халыклар арасында кыска[1] телле (зәбандыр) булыр (әйткән сүзе үтмәс), ахирәттә, мөнафикъләр чокырында булып, кабереннән кубар.

Хилаф итсәң әгәр әйган сүзеңдән,
Китәр иркәклек атыны үзеңдән.

Ягъни кылган вәгъдәңә һәм әйткән сүзеңә хилафлык итсәң, ир булган исемеңне үзеңнән алып, хатынша исемен ал. Чөнки ир мин дигән кешенең, әлбәттә, вәгъдәсендә төз торуы[2] кирәк.

Дадәк кыйгачы дәстарлекдән артык,
Сәнең юк булганың барыңдан артык.

Ягъни, синең башыңа олуг чалма киеп, Аллаһ хезмәтендә торуыңда файда юк, әгәр әйткән вәгъдәңә хилафлык кылсаң; андый хилафлык итүеңнән үлгәнең яхшырак булыр. *Дадәк* хезмәт мәгънәсендәге сүз.

Чыкармагыл агыздин кылмас эшне,
Кылырмән димә кулдин килмәс эшне.

Чөнки болай эшләү ирлек галамәте түгел. Ир булган кешегә, әлбәттә, авызыннан чыккан сүзендә торуы кирәк.

Агыздин чыкты сүз, кайтармагыл каш,
Әгәрчә китсә һәм ул сүз өчен баш.

Чөнки хакыйкать әһеле, әлбәттә, әйткән вәгъдәсендә торыр иде, андый булмаса, аннан күңелеңне өзеп, моннан соң сүзенә ышанма.

Йакыйн белгел ки төзлекдән гасаны,
Ирәнләр алдылар уң кулга аны.

---

1 С.-П.да — кыса (303 б.).
2 С.-П.да — истикамәт улса (303 б.).

Ягъни таяктан (гасадан) гыйбрәт ал: таякны гаять төз булганы өчен ирләр (аны) уң кулга алып йөриләр.

Хосусан төз кирәк ил игътимады (таянычы).
Булырмы игри (кәкре) һич мәсҗед гыймады.

Ягъни хосусан ил агаларына тугры вәгъдәле булу кирәк. Чөнки абруйлары бар. Чөнки мәчет терәге (гыймады) игри (кәкре) түгел. Чөнки мәчет барча халыкның шәриф (кадерле) урыннары. Шуның өчен аның терәге төз булды. Андый ир агаларының әйткән сүзе һәм кылган вәгъдәсе төз булу кирәк. Халыкның таянычы[1] — ил агалары.

Сүзен бозган кешене яхшы ирләр:
Косыб, кайтыб аны эчкүнчә дирләр.

Ягъни яхшы ирләр әйттеләр: сүзендә тормау, кеше өчен косыгын кире кайтып эчү кебек, чөнки ул табигый әһелләргә мәкруһдер (тыелган). Андый сүздә тормаганнар әһеле җитешкән затлар каршында мәкруһ (тыелган).

Кайу таййеб (чиста) кеше эчкәй кыйидин (косыкны),
Терек сән калмагыл гаһдең паедин.

Ягъни, берәү коскан косыгын эчсә, табигатьләргә яхшы буламы? Андый әйткән вәгъдәңдә тормасаң, яхшы түгел. Андый булса, үлгәнче, кылган вәгъдәнең артында һәм аның юлында бул, димәкдер.

Мәбадә (Ходай сакласын), өзсәң әкваләң гокудын,
Түгелеб калмагай йиган ногудың.

Ягъни аңсыздан әйткән сүзеңне һәм кылган вәгъдәңне бозсаң, барлык җыйган данәи ногудың (ногыт бөртекләрең) чәчелмәсен. Аннан морад: кылган вәгъдәңне бозып, гыйбадәтең һәбаи булмасын (юкка чыкмасын), димәктер.

---

1 С.-П.да — инамлык (имамлык?) (303 б.).

## Хикәят. Хәлил углы хәзрәте Исмагыйльнең бәяны

Хәлил углы ки Исмәгыйльдер, әй сәгыд,
Аны йад итде Тәңрем садыйкыл-вәгыд.

Ягъни, әй изге кеше, Ибраһим Хәлилнең улы Исмәгыйльдер! Ул Исмәгыйльне Аллаһ Тәгалә Коръәндә вәгъдәсендә торучы һәм күндәм (тугры) сүзле дип атады...

Аның садыйклыгын, әй адәми зад,
Кылыбдыр бер хикаят Рабгузый йад.

Ягъни ул Исмәгыйль йадавачның вәгъдәсендә торучы икәнен безгә Рабгузый җирлеге кешесе Борһан углы Насреддин (XIII гасырның икенче яртысында — XIV йөзнең беренче чирегендә яшәгән Алтын Урда әдибе) «Кыйссасел-әнбия» (1310) дигән китабында хикәят белән белдерде.

Барыр ирде ушал шаһ бер тарафка,
Йулыкты мөэмини ул ба шәрәфкә.

Ягьни хикәяттә әйтелер: көннәрдән бер көнне Исмәгыйль, Мәккәдән Фәләстыйн җиренә барырга чыкканда, Габдерахман атлы кешегә юлыкты. Әйтте: «Йа, Рәсүлулла, әгәр сез мине юлдашлыкка кабул итсәгез, мин сезнең белән барыр идем», — диде. Исмәгыйль г-м: «Яхшы булыр», — диде:

Диде: торсаң бу йирдә, әй никүкяр,
Өвемдэ ягъни бәгъзе эшләрем бар.

Ягъни ул Габдерахман әйтте: «Йа, рәсүлуллаһ, әгәр сез монда күп заман торсагыз, яхшы булыр иде. Минем өемдә кайбер эшләрем бар. Ул эшне җаен табып эшләп килсәм, аннан соң сезгә иптәш булсам, ни гаҗәп, изге, әйбәт булыр иде». Вәгъдәсендә торучы һәм гадел Исмәгыйль г-м әйтте: «Яхшы булыр, торырмын», — диде.

Килермен диб кашыдин киткән ул кәс (кеше),
Онытты вәгъдәсеме булды килмәс.

Ягъни Исмәгыйль г-м яныннан килермен дип киткән Габдерахман вәгъдәсен онытты, вәгъдәсендә тора алмады яки биргән вәгъдәсенә юри килмәде, яки «Инша Аллаһ» диеп әйткәннән соң, өендә сәбәпләрдән бер төрле бер сәбәп белән килмәде.

Кылыб мән, диб, вәгъдә ул сахибе раз,
У(л) йирдә алты ел торды кыш, йаз.

Ягъни ул вәгъдәсендә торучы Исмәгыйль г-м «вәгъдә кылдым мин» дип, вәгъдәсендә нык булып, ул вәгъдә кылган җирдә алты ел кышлады һәм язлады. Вәгъдә кылган Габдерахманны көтте — килмәде.

Ушал вәгъдә онытканның гөзари,
Йитешде йиде елдан соңра бари...

Ягъни ул, Габдерахман, онытканы исенә төшеп, җиде елдан соң Исмәгыйль г-м торган урынга килде. Белде ки, үткән заманда кылган вәгъдә өчен торганы хәтеренә килде.

Ушал вәгъдә өчен торганын белде,
Оят бады (җиле) белән тутдик екылды.

Ягъни Габдерахман Исмәгыйльнең шул биргән вәгъдә өчен торганын белде. Белгәннән соң, оят җиле белән тут агачы кебек егылды, һушсыз булды. *Тут* бер агачның исеме. Җимеше пешеп җиткәч, җил исүе белән җиргә коелыр. Җимеше сары булыр. Әмма безнең Болгар йортындагы карлыганның да бераз охшашы бар. Әмма ачырак булыр.

Агаздин дәфтәр агъзарын ачды,
Дөрре әшкен айаг астига сачде.

Ягъни ул Габдерахман Исмәгыйль пәйгамбәргә гозерләр (үтенечләр) дәфтәрен ачты. «Йа, Рәсүлуллаһ, бездә



www.darulkutub.com

хаталык булды, безне кичер», — дип елап, яшь энҗеләрен (дөрре әшкен) Исмәгыйльнең аяк астына чәчеп, бәхиллек (гафу итүен) үтенде.

Зәбихе Аллаһ аңа лотф итде чәндан
Әйде: чөн гончә гөлдәк багы хәндан.

Ягъни Исмәгыйль г-м шул кадәр ачык йөз белән Габдерахманга әйтте: «Хуш килдең, сафа йөрдең», - дип түбәнчелек күрсәтте.

Сөчүк телне аңа сарыф итде чөн бал,
Ана вәгъдә, ана гафу, ана халь.

Ягъни Исмәгыйль г-м ул Габдерахманга ,бал кебек төче телне кулланып, вәгазь-нәсыйхәт кылды. Әй газизем, аңла ки, шул булыр вәгъдәсендә торучы ирләрнең хәле, шул гафу кылучыларның хәле, шул әһеле хәл булучыларның хәле! *Ана* сүзе мәдд илә (а белән) укылыр, үзбәк җәмәгате бер хикәяттән, я бер гаҗәптән гыйбрәт алсалар, ана дип әйтерләр.

Кешенең вәгъдәсе кем булмаса раст,
Мәхәббәт гаһден анда кылма дәрхаст.

Ягъни, бер кеше кылган вәгъдәсендә дөреслек белән тормаса, Аллаһыны сөю килешүен, вәгъдәсен аннан көтмә, аннан биз.

Ышанма әйганигә, әй хәрдеманд.
Әгәр чәндикә ул йад итсә сәүгәнд (ант).

Ягъни вәгъдәсен бозган кешенең әйткән сүзенә инанма, гарчә ул ант эчсә дә, Аллаһ Тәгаләне зикер итсә дә, игътибар юк, чөнки мөнафикъның «биллаһ» диюендә игътибары юк.

Сүзен бозган кеше бозмасмы иман,
Ул кемсә берлә кылма гаһд-пәйман (килешү).

Ягъни әйткән сүзен бозган кеше, әлбәттә, иманны

бозып хараплыкка төшсә кирәк. Андый антны эчкән кеше белән вәгъдә кылма, чөнки ул игътибарсыз.

Әгәр төзлек белә бер («адымдаш») булырсәң,
Әлиф дәк җан эчендә җа булырсәң.

Ягъни әйткән сүзеңдә һәм кылган вәгъдәңдә торучы һәм сабит (нык) булсаң, җан сүзенең уртасындагы әлиф кебек. Чөнки ул җим хәрефенә якын. Андый кылган вәгъдәңдә сабит булсаң, Аллаһ Тәгаләгә якын булырсың, димәктер.

Әгәр кич булса әфгалең бу дөп дәк,
Калырсән бәлки каф астында нун дәк.

Ягъни кылган вәгъдәңдә аз гына кыеклык булса, кан сүзенең нүне кебек булырсың. Чөнки кан сүзенең нүне кан сүзеннән ерак булды. Андый кылган вәгъдәңдә нык булмасаң, халыктан читләшеп һәм алардан ерак булып, ике дөньяда нәҗеслек белән калырсың, димәк. Яки бу ике бәетнең хәрефләре капма-каршы хәрефләр белән хөкемләрен бәян кылуында акыл ияләренең, тикшерүчеләрнең фикерләре, билгеләмәсе бар. Алар җим хәрефен хоруфе җәзил диерләр һәм каф хәрефен хоруфе сал диерләр. Бу ике хәреф белән һавалы, нәфесле һәм тар табигатьлеләрне (холыклыларны) яд итәрләр («билгеләрләр», «нәтиҗә чыгарырлар»). Җим хәрефе тораби мәркәзенә ишарә булыр. Чөнки тораб нык. Мөстәкыйльлегенә, ныклыгына күрә, аны мисал итеп китерәбез, һава аның киресе була, һәрвакыт, фәлак (күк йөзе) белән мәҗзуб («бәйле»). Андый вәгъдәгә тугры булмаган кеше һаман нәфесе белән мавыгуда. Сабит (нык) булмавы айдан. Вәгъдәсенә тугры булган кеше җир шары кебек нык булуы җирдән. Яки гыйльме рәмелнең (ком белән күрәзәлек итүнең) кагыйдәсенә ишарәт. Җим хәрефе белән оятлылыкны чыгарырлар. Шуның өчен тугры вәгъдә иясе вәгъдәсендә нык. Һәм каф хәрефе белән замир төсен[1] чыгарырлар. Ул үз мәркәзендә аеруча нык. Хилаф кылган кеше аңа охшашлана яки мөнәҗҗим истилахенә (астролог атамаларына) ишарәт, чөнки алар

1 К.да — әнкәсене (210 б.).

www.darulkutub.com

җим хәрефе белән мөтасалли (кайгысы таратылган, юанган) чыгарырлар. Ул үз чиратында нык. Вәгъдә иясе шуның өчен вәгъдәсендә нык тора.

Каф хәрефе белән кәмитә (комета, яисә: кәммиййәтә — сан) аерымлыгын чыгарырлар. Ул рәсадүндә (күзәтү-тикшерүдә) аеруча сабит (бик нык; тотрыклы). Әүвәлгесе рәсад (рәсад — күзәтүче; астролог, астроном) — Боталимус (Птоламийус — Птоломей — антик Греция галиме), икенче рәсад — Форфириус (Порфирий — акыл иясе, Александр Македонскийның чордашы). Барча җәваһир (җәүһәрләр; җисемнәр) һәм әгъразлар («вакыйга-хәлләр») һәбадыр (бетә торганнар)[1]. Шуның кебек вәгъдәдә ышанычлы, нык булмаган кеше (шәхес) котыбсыздыр (үзәксез; юлбашчысыз), фәләк (күк) кебектер. Форфириус әйткән: күк һәм күк җисемнәре, йолдызлар әйләнеше юлбашчылы булуга мөнәсәбәтле, бәйле түгел. Чөнки аларның хәрәкәте, әйләнүе мәҗбүридер. Аларның хәрәкәте, әйләнеше, яшәеш зарурияте әмерендә булыр. Бу сүз мәзһәб («гыйльми яктан») хак булыр. Андый вәгъдә бирүче вәгъдәсендә ышанычлы, нык булмаса, яшәеш зарурияте әмеренә тискәрелек кылыр[2], ул чакта аңа һәлаклек ирешер. Чөнки күкләр һәм йолдызлар яшәеш зарурияте әмереннән башка бәйсез яшәсәләр, хәрәкәтләнсәләр, алар һәлакәткә дучар булыр иде, ягъни әһле гашыйкларның, суфыйларның исгыйлахенә (терминнарына, сүзләренә) ишарәт шул. Җим хәрефе белән морадлары җан булса, чөнки җан Аллаһдан кешегә (инсанга) иңде, ирешә.

Вәгъдәсендә торучылар тугры булса, шул рухтандыр. Чөнки минн гыйндә Аллаһ (Аллаһка якын) булган рух, әлбәттә, вәгъдәсендә торса кирәк. Кан сүзе мәкруһдән (яраксыз), әхлаке зәмимәдән (начар әхлактан) берсе. Андый булса, нәҗеслектә калды, минн гыйндә Аллаһ рухдан булмады, бәлки рухе дәвали (мәкерле) булды. Шуның өчен вәгъдәсендә нык булмады. Чөнки кирелек хайванда күптер яки гыйльме мөһәндәснең (хисаплау фәненең) истыйлахенә (атамаларына, төшенчәләренә) ишарәт була. Әбҗәд Җөмәле кәбир[3] хисабынча, җим өченче

1 К.да бу җөмлә Птолемей исеменнән әйтелә (211 б.).
2 К.да — хилаф әйләде (211 б.).
3 С.-П.да — җәмиле кыйб (308 б.). К.да — җөмәле кәбир (211 б.).



www.darul-kutub.com

дәрәҗәдән ишарәт[1]. Каф (хәрефе) йөзенче дәрәҗәдән ишарәт. Алар саннар таблицасында хисаплау фәне[2] — мөһәндәсне яшәеш зарурияте мәркәзендә тотарлар, җанибе мөмкинаттән (ихтималлык тарафыннан) тотмаслар. Андый булса, садыйкыл-вәгыд булган кеше өч дәрәҗә микъдары Аллаһ Тәгаләгә якын. Чөнки галәмел-әшбаһда («бу галәмдә») җаннар[3] важибел-вөҗүдә якын иделәр. Галәме сурдә («мәхшәр көнендә») өч дәрәҗә белән килде. Әүвәлгесе — һәйуладыр («орлыктыр»): аталар аслабында («тәнендә; әгъзасында») һәм аналар рөхемендәдер (карынындадыр). Икенчесе — һәйулаи тәүтыйәдер: аналар рөхемендә сурәт булып, җан булып торды. Өченчесе — вөҗүде таййарйдыр, ягъни бу дөньяга килеп, балигъ булып, иман китереп, кылган вәгъдәсендә нык, тугры булып, мәзкүр (югарыда телгә алынган) өч дәрәҗәдән артык һәм ким булмыйча, фани дөньядан бәкыйлыкка (вакытлы дөньядан мәңгелеккә) күчкәндә, элеккеге гыйшыкына васыйл булуыдыр (ирешү, очрашу, кавышу), һичбер хисап һәм мизан (үлчәү) вә тәмуг күрмәйен (күрмичә) торуы була. Әмма вәгъдәсендә тора алмаган ялганчы важибел-вөҗүд мәркәзеннән түбән төшеп, өч дәрәҗәдән үтеп, хисап һәм мизанда үлчәнеп, җавап биреп, тәмугта калып, ничәмә йөз кайгы-газаплар арасында калуына ишарәт булыр, яки әһле табигать истыйлахенә (атамаларына) ишарәт булыр.

Чөнки җан сүзеннән табигатьләргә мәкруһлык (зыян) ясалмас (килмәс). Андый нәрсә вәгъдәсенә тугры табигатьләргә (изгеләргә) хас. *Кан*[4] сүзе табигатьләргә зыянлы һәм иследер, яки нәхү (синтаксис) атамасына ишарә кыла, җим җәрдән (бер тамырдан) ясалган. Мәгънәсе: ас кылу һәм тартылу була. Андый вәгъдә биргән кеше түбәндер, бәндәчелектә кала. Шул сәбәптән Аллаһ Тәгалә җәнабенә тартылды, мәгънәви булды. *Кан*[5] сүзе мөһмәләгә (хәрәкәсез булуына) ишарәт кыла, башка мәгънәдә килә. Андый күп вәгъдәлелек мәгънәсез, игътибарсыз була, яки атама, термин

---

1 Әбҗәд хисабынча, җим, каф хәрефләре авазлардан тыш 3, 100 саннарын да белдерә.
2 Аркам — саннар, таблица.
3 С.-П.да — җафилар (308 б.).
4 К.да — каф (211 б.).
5 К.да — каф (212 б.).



www.darul-kutub.com

буларак мантыйкый морадка (логик максатка) туры кылә. Ялганчы кешенең сүзе әйтелештә хак булса да, асылы тулы ялган һәм моннан башка фәннәрнең термин, атамаларына ишарәт булыр, фән әһелләренә сер[1] булмас, билгесезлек түгел..

Кылыч башыңа килсә, әймә ялган,
Үлемдиндер бетәр чөнки уянган.

Ягъни андый булса, берәү кылыч башына куеп, әгәр аң булса, ялган сүзне әйтмә, чөнки ялган сөйләп, ахыры бер йөзеңә оят килсә, үлгәннән яман булыр.

Әгәр ялганчылыкда чыкса атын.
Кыямәт көн ничек булгай ойатың!?

Ягъни дөньяда ялганчы дигән исемең чыкса, кыямәт көнендә ояты аннан да олырак булыр, әбәди (мәңгелек) газапка грифтар дучар булырсың.

Нәҗес мордар имәс ялганчылыкдан,
Мөселманига шәрм ит (оял) бу коллыкдан.

Ягъни, андый булса да, дөньяда нәҗесләрнең нәҗесрәге ялганчылык булыр. Зинһар, мөселманнар. халыктан оялыгыз, болай ялган сүзне әйтмәгез, димәктер. Әйтәләр; ялганчылык өч урында рәвадыр (ярыйдыр): әүвәлгесе — кяферләрне сугышта[2] алдау. Икенчесе — ике кешенең арасын яраштыру өчен.

Өченчесе — ир хатынын алдаса, дөрестер. Аннан гайре урыннарда ялганчылык харам булыр. Әйтәләр: хәзрәте Мәгаз бине Җәбәлнең, разийаллаһуганһу (Аллаһ үзен ярлыкасын), бер баласы бар иде. Пәйгамбәр г-м Мәгаз өендә иде. Шул чакта Мәгазның баласы елады. Хәтерен күрү (юату) өчен баласына әйтте: «Әй күзем нуры, елама, сиңа йомырка[3] бирермен», — диде. Шунда улы елаудан туктады. Пәйгамбәр г-м әйтте: «Йа Мәгаз, йомыркаң бармы? Улыңа бир!» — диде. Мәгаз әйтте: «Йә Рәсүле Аллаһ (Аллаһның илчесе), әле хәзер юк», —

1 С.-П.да — хәфи (309 б.).
2 К.да — сугышында (212 б.).
3 С.-П.да — йомырда (309 б.).

диде Пәйгамбәр г-м әйтте: «Йә Мәгаз, ялганчы булдың, күрдеңме ялганчылыкның чиге сайланган кешеләргә мәхфи (яшерен) түгел».

Шәригать хөкме берлә, әй нигүрай,
Гяһи чын сүзне күңлеңдә кыл җай.

Ягъни шәригать хөкемен аңла, әй изге акыллы кеше[1] (нигүрай), фалчыларның сүзен күңелеңдә чит тот, ышанма (кыл җай). Чөнки ул ялган. Фалчы һәм мөнәҗҗимләр (йолдызчы; астролог) Аллаһның дошманы булыр. Алар сүзенә ышанма.

Намимэне (гайбәтне) яман әйде шаһы дин,
Сөхән (сүз) чын булса, һәм булса сөхәнчин.

Ягъни, ахыр чиктә аңла: өйдән өйгә сүз йөртү яман дип риваять кылынды пәйгамбәребездән. Андый булса, хак сүз булса да, өйдән өйгә йөртмә. Кауләһү Тәгалә: «Әл-фетнәтү әш-шәдду мин әлкатли». Чөнки өйдән өйгә сүз йөртүнең адәмнәрне үтерүдән дә гөнаһы артык. *Сөхән чын* (сөхәне чын) сүзенең әүвәлгесе ике телдән ясалган. *Сөхән* сүз мәгънәсендә бирелә, фарсыча. *Чын* төрки сүз, мәгънәсе ачык (билгеле). Икенчесе (ягъни сөхәнчин) мөфрәд (кушма сүз), сүз йөртү мәгънәсендә кулланыла, фарсыча.

## Сәфәрдә юлдашларның миһербанлык бәяны

Кил, әй газим, әгәр булсаң сәфәрдә,
Рәфикь таб тарыйкы нөр хәтардә.

Ягъни, андый сәфәр ниятендә булган кеше (газим), сәфәр кылырга теләсәң, әүвәл сиңа бер юлдаш кирәк. Олы хәтәрле юлларда (тарыйкы пөр хәтардә) юлдашсыз начар булыр. Нинди сәфәр булсын, кирәк дөньяви һәм кирәк ахирави (дини; теге дөнья), — әр-рафику сөммә әт-тарыйку, — әмма юлдаш булган кешенең юл әдәбен белгән кеше булуы кирәк. Шулай итеп боерды:

Ничек кем мәгъзне (төшне) җандан тотар пуст,
Мәхәббәт юлыда андаг кирәк дуст.

1 К.да — изге фикерле яр (212 б.).

Ягъни, ничек чикләвек төше[1] кабыгы белән якын, сәфәрдә хасс (якын) юлдаш булган сәфәр юлдашы мәхәббәттә бер-берсенә якын булу кирәк.

Үзене — кол, йарын — солтаны белә,
Үзене — тән, рәфыйкын — җаны белә[2].

Ягъни юлдаш булган кеше, үзен кара кол дип белеп, юлдашын падишаһ дип белә һәм дә үзен тән кебек күреп, ярын җан кебек күрә. Кыскасы, юлдаш бер-берсен хөрмәтләп, кадерләп йөриләр, димәктер.

Аякыга әгәр тиксә тикәне,
Кадалганча күзегә күрсә аны.

Ягъни изге юлдаш шул булыр: әгәр юлдашының аягына тигәнәк кадалса, ул тигәнәкне үзенә кадалган кебек күреп рәнҗер. Хакыйкать (чынлыкта) шундый булыр юлдаш.

Суык йил тиксә юлдаш йөзигә,
Әгәр кулдин килер, алса үзигә.

Ягъни хакыйкатьтә юлдаш шул булыр: әгәр кинәт ярың йөзенә суык җил тисә, хәлеңнән килсә, ул җилне үзеңә алырга риза булыр. Аннан морад[3]: юлдаш авыру булса, асылда ташлап китәргә риза булмас, бәлки үз тәне рәнҗегән кебек булып торыр.

Аңа килде тикән тере бәлагә,
Кылыб җанын сепер төшсә арага.

Ягъни ул юлдашына бәла угы (тире) килсә, хакыйкатьтә юлдаш шул булыр: ул килгән бәла угына җанын калкан кылып, бәлане юлдашка китертмәс өчен тырышыр[4], димәктер.

---

1 С.-П.да — чикләвек төше (310 б.).
2 К.да — бу бәеттән алда кирәкдер дип башланган янә бер строфа бар (213 б.).
3 К.да — сырхау (213 б.).
4 С.-П.да — бу бәеткә мондый гына аңлатма бирелгән: «Ул юлдашы арасына килтермәз өчен җәһед әйлар» (311 б.).



www.darulkutub.com

Яман юлдаш ирер өчен маре әфгый (агулы елан),
Зарардин үзгә юкдыр, зәррә нәфгый (һич файда).

Ягъни яман юлдашның зарары тугыз яшь яшәгән елан зарары кебек. Андый булса, зыяннан башка файдасы юк.

Әйтәләр: кайчан елан бер яшеннән сигез яшенә кадәр яшәсә, елан диләр. Аннан узып, туксан яшенә кадәр яшәсә, агулы елан диләр. Йөздән узып, мең яшенә кадәр яшәсә, аждаһа диләр. Ике мең тәмам булса, юха диләр. Аннан да үтсә, күркәм егет булыр яки кыз сурәтенә керер. Әмма яшәгән вакытында берәүне чакса, шулай да гыйлаж (дәва) булыр: ул чаккан еланны үтереп, башын кисеп ташлап, казанга салып, казанда кайнаталар. Шулпасын чагылган кешегә эчерәләр, гаять сыналган, «файдалы булыр». Яки ул тереклек иясен үтерү мөмкин булмаса, ат тирен шул чагылган кешенең әгъзасына сөртәләр һәм ат тирен эчерәләр. Аннан соң ачы әйрәнне тозлап эчерәләр, гаять файдалы. Әмма агулы елан чакса, аңа дәва юк.

Әйтәләр: еланның чагуы авыз ярыннандыр. Авызында зәһәре (агуы) бар, диерләр. Бу сүз дөрес. Әмма дөресе шул булыр: теленең эчендәге ике нәзек кара нәрсәсе бар, зәһәре шунда. Әһле мөтәгассабә («хәбәрдар булмаганнар») тәҗрибә өчен ак йомшак агачны еланның авызына тотсыннар. Елан, ачыгланып, ул агачны чагар. Баягы кара нәрсәсе ак агачта калыр. Аннан соң еланны кулың белән тот, асылда (һич тә) чагарга хәленнән («мөмкинлегеннән») килмәс. Бу — хөкәмалар (хәкимнәр) тәҗрибәсе.

Әйтәләр: аждаһа хәленә җитсә йөрмәс, бер җирдә урынлашып торыр. Адәмне яки гайре хайванны сулуы белән үзенә тартыр. Күбрәк ашаганы туфрак булыр. Әмма яшь еланның азыгы бака булыр. Кыш көннәрендә гомумән ашамас. Кайберәүләр әйтәләр: елан кыш һавасында йоклар, асылда уянмас. Чебенләр һәм күбәләкләр кебек, хакыйкатьтә рух гәүдәләрендә (тәнендә) калыр. Әмма мондый төр хайваннарга рух керүенә һава үзгәрүе сәбәп булыр. Яз һавасы белән җәй һавасында болар хайваннар кебек йокыларыннан уянырлар.

Әйтәләр: юха дигән елан Һиндия җирендә (Һиндстан якларында) күптер, гаять күркәм кыздыр, я егеттер.

Аның һич нәрсә белән адәмнән аермасы булмас. Мәгәр ки өч урында аерымлыгы бар. Әүвәлгесе шул булыр: кендеге булмас. Икенче: авызыннан үләксә исе килер. Никадәр юса да, хуш ис килмәс. Өченче: адәм сурәтенә кергәч, кырык тугыз көн генә яшәр, тиз заманда үләр. Үлгәннән соң, аждаһа сурәтенә кайтыр.

Әйтәләр: еланны Аллаһ Тәгалә оҗмахта фирдәвес (җәннәт бакчасы) туфрагыннан яралтты. Өч канаты бар иде. Фәрештәләрдән Газазил белән сердәш иде. Изи гыйзз-у җәллгә (Ходай Тәгаләгә) гөнаһ кылды. Оҗмахтан сөреп, дөнья йөзенә иңдерелде, сурәтен-кыяфәтен алыштырды, канатын алды, ачуланды. Ходаның каһәре еланның эчендә калды, шуның өчен зәһәр агулы булды.

Әйтәләр: елан өч төрле булыр. Берсе — кара башлы, ул еланның зәһәре артык юк. Икенче төрлесе — кара, әмма сары башлы. Ул елан зәһәр агулы. Өченчесе — бакыр төсле. Анда зәһәр юк. Аждаһа елан һәм юха кара башлылардан булыр, башка еланнан булмас. Ахыргы ике төрле елан озын гомерле булмас. Янә, ахыр килеп, бер төрле елан бар, аны шаһәмари (шаһ елан) диярләр, ак булыр, камчы сабыдай олы. Аны җәния (җонния?) диерләр. Ул — еланнар шаһы. Анда зәһәр булмас. Аның торуы күбрәк тау эчендә. Кайвакытта сахраларга чыгар. Аны үстерү шәригатьтә урынлы түгел.

Әйтәләр: ак елан өч төрле, еланнар нәселеннән түгел, бәлки хакыйкатьтә чын. Еланларга шаһ булу өчен, Изи гыйзз-у җәлл яралтты, диләр. Әйтәләр: оҗмахтан сөрелгән елан кара башлы иде. Дөньяга ингәннән соң, төрле-төрле булдылар. Төрле булуларының сәбәбе — кайберсе чаян белән кушылып төрлеләнделәр. Бу хакта кыйссалар күп[1].

Тотыб даим еланның коерыгыны,
Ничек дел җәмгъ идәрсән боерыгыны!?

Ягъни берәү еланның коерыгын кулы белән тотып, ничек туры китерерсең (яраклаштырырсың; килештерерсең), бәлки начар күреп, дошман күрерсең. Андый явыз юлдашның ничек боерганын яраган эш дип кабул итәрсең.

1 К.да — кубдер (314 б.).



www.darul-kutub.com

Яман булгай[1] вәләкин, булса намәрд,
Коруг сурәт ирер — кылгыл күңел сәрд.

Ягъни яман юлдаш шул булыр: егетлекле һәм кундәм (дөрес) сүзле булмаса, ялгыз буш, коры, мәгънәсез сурәт булса, аннан күңелеңне суындыр[2], аның белән аралашма, әңгәмә корма.

Үлекдер, булмаса һәркем дә гүрдә
Терелмәсдер күтәргән берлә мәрдә[3].

Ягъни андый юлдаш үлек, гарчә кабердә булмаса да. Үлекне син күтәрү белән җан иңеп терелмәс. Сүзнең кыскасы шул, рәтен-чиратын белмәгән мәгънәсез юлдаш синең үгет-нәсыйхәт бирүең һәм әдәпкә өйрәтүең[4] белән өйрәнмәс, тугрылыкка күнмәс, һаман үзенең бозыклыгына тартыр[5].

Имәс ирнең нишаны (билгесе) — риш, аләт (корал; әйбер),
Нишаны — һиммәт вә гайрәте, вә халят.

Ягъни ирләрнең ирлек галәмәте сакал түгел, бәлки ирлек галәмәте шул булыр: гайрәт иясе һәм хәл әһеленнән (суфый) була. Аннан морад: тәвәккәл (Аллаһка бирелгән) һәм хәлим (йомшак күңелле), гыйлемле һәм кундәм (дөрес) сүзле булып, тугры юлга өндәүче булып, бер-берсенә шәфкатьле булыр, бәлки изге юлдаш берсе өчен берсе җан бирергә риза булыр...

### Хикәят. Согыд вә Сәгыйтьнең бәяны

Сәгыйд, Согыд кылды гаһде йари,
Сәфәр булды аларның ихтыяри.

Ягъни хикәяттә әйтәләр ки, Сәгыйд белән Согыд дигән ике кеше юлдаш булырга килешкәннәр, гомерләренең күбрәге сәфәрдә булуын теләделәр.

1 К.да — булмай (214 б.).
2 К.да — сындыргыл (214 б.).
3 С.-П.да — мәздә (313 б.).
4 К.да — һөнәре (215 б.).
5 К.да — җәһле кадменә китәр (215 б.).



www.darul-kutub.com

Әйтәләр: ул ике кеше гомерләрендә хатын алмадылар, сәяхәтчелек кылып кеше яшәгән урынның (җирнең) дүрттән бер өлешен гизделәр. Әйтәләр: бу ике кеше пәйгамбәр г-мнең сахәбәсе иде, аларга оҗмах сөенчесе бирелгән иде. Әйтәләр: Согыйдның атасы Гомәр атлы кяфер иде, Мәккәдә иде. Ул үзе җиде яшендә пәйгамбәргә иман китергән иде. Сәгыйд дигәне Басрадан (Гыйрактагы шәһәр исеме) чыккан иде. Ләйс[1] атлы иде. Гаять күндәм, салих (изге) кеше иде. Бу ике кеше сәфәргә киттеләр. Ахыры Согыйд вә Сәгыйд Диарбәкер (Якын Көнчыгыштагы шәһәр исеме) сугышында шәһид булдылар, җомга вакытында тарихи һиҗрәтнең (һиҗри елның) кырык беренче елында иде (милади белән 662 елда).

Җан делдәк[2] (күңел кебек) иде ул ике, агяһ
Казадин акдылар дәрьяга нагяһ.

Ягъни ул Сәгыйд илә Согыйд дуслык килешүендә җан белән күңел кебек гаять бер-берсенә дус иделәр. Аңсыздан (агяһ) бу ике кешенең сәфәрләре Колзум диңгезенә (Кызыл диңгезгә) туры килде. Көймәгә керделәр[3].

Берсен тотды мәллахи (диңгезче) ушал халь,
Диде: «Куйгыл мине, ярым кулын ал!».

Ягъни һәр икесе көймәгә керделәр. Көймәне ишкәкче тотды. «Ни өчен тик утырасыз, көймәне ишегез!» — дип ачуланып ишкәкне Сәгыйд һәм Согыйд кулына тоттырды[4]. Шулчак, Согыйд торып әйтте: «Минем юлдашым Сәгыйд кулыннан ал, көймәне мин ишәрмен», — диде. Шуннан көймә хуҗасы, ишкәкне Сәгыйд кулыннан алып, Согыйд кулына бирде...

Моны куйды, аны чөн тотды мәзбут (нык),
Бу һәм әйде: «Мәне куйгыл, аны тот!».

Ягъни көймә хуҗасы Согыйд кулыннан ишкәкне алып,

1 К.да — Ләйп (215 б.).
2 К.да — дел җәндәк... (215 б.).
3 С.-П.да — аңсыздан бу ике кемсәнә Колзум диңгезенә акдылар (314 б.).
4 С.-П.да — бу өлеш бик кыска гына бирелгән (314 б.).

Сәгыйд кулына бирде. «Көймәне иш», — дип боерганда, Согыд әйтте: «Сәгыйдне куй, аның урынына көймә ишәргә мине тот», — диде. Көймә хуҗасы боларның дуслыгына гаҗәпкә калды. Яр булган кеше болар кебек булырга кирәк, бер-береннең җәфасын, авырлыгын тарту кирәк[1].

Тамаша кыл алардин, гаһдейари,
Анан («шулай») кауле дөрест ирләрнең кяри (эше; гамәле).

Ягъни, әй газиз кеше, тамаша ит, бу ике ирнең юлдашлык вәгъдәләрен күрмисеңме?! Дөрес адәмнәр бер-берсенә дус булып, бер-берсе өчен җанын фида кылырга риза булырлар, бер-берсенең мәшәкатен һәркайсы үзенә йөкләп алыр. Шуннан чыгып аңла: шушы күндәм сүзле ике ирнең эше, бер-беренә тән белән җан кебек, чөнки тән авырса, җан әрни[2]...

## Мөэминнең даими курку һәм ялваруда булуының бәяны

Кил, әй тән, бул һәмишә (һәрчак) илтиҗадә (үтенечтә),
Дәвамел-гомер бул хәүфе риҗадә.

Ягъни, әй адәм, Аллаһка хасс (якын) бәндәләреннән булсаң, Аллаһ Тәгалә хәзрәтенә сыенучы бул, тәгать вә гыйбадәткә алданып торма һәм барча гомереңне курку белән өмет арасында бул, димәктер. Ягъни, әй адәм, Аллаһка хас бәндә булыйм дисәң, газабыннан куркучы, рәхмәтен өмет итүче бул[3].

Күтәрмә һич риҗа вә хәүфдин раэәс (баш),
Якын бел: көфердер имин һәм йаэәс.

---

1 Әсәрнең бу өлешендә дә ике басма арасында аермалыклар бар. Биредә К.дагы текст алынды (215 б.).

2 К.да — бер-беренең мәшәкъкатенебере йөкләргә булдылар. Андаг булса андагыл: ошбудыр күни сүзлек ирәнләрнең эше, бер-беренә җан илә тән кебидер, нитәк ки җан агырса, тән һәм рәнҗү улыр (215 б.).

3 С.-П.да — Ягъни, әй адәм, Аллаһуга хасс бәндә булаем тисәң, газабындан куркутучы, рәхмәтендән өмид идәче бул (314 б.).

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең хасс (якын) бәндәсеннән булсаң, башыңны өмет белән куркудан күтәрмә, шиксез бел, Аллаһның газабыннан имин булып, рәхмәтеннән өмет кисү — көферлек...

Сәнең алдыңда пәйдадыр ике юл:
Бере уң ул сари (уң тарафка) баргай, бере — сул.

Ягъни син шуның өчен курку һәм ялвару арасында бул, алдыңда ике юл бардыр: берсе уң тарафка китәр, ул оҗмах юлы; берсе сул тарафка китәр, ул тәмуг юлы булыр.

Кеше белмәс кыямәт дәштедә, аһ,
Китәр бәндә ике юлдан кайу раһ (юл).

Ягъни кыямәт сахрасында (дәштедә) аһ, Йарабби (йа Аллаһым), ни эшләрбез, һичбер адәм белмәс, ул ике юлның кайсына барырбыз.

Әгәр сансыз гата (бүләк) кылса Ходаен,
Биһиште гадн (оҗмах бакчасы) эчрә булса җаен (урынын).

Ягъни Изи гыйзз-у җәлл (Аллаһ Тәгалә), хисапсыз кәрамәт (юмартлык) күрсәтеп, гаден оҗмахының урынына барырга хөкем чыгарса, ул хөкемне ахирәттә эчке тоем, сизгерлек белән ачык белсәң...

Карыш юл калса җәннәт йиткәли тауф.
Борынгыдан зиадә (күбрәк) әйлагел хәүф.

Ягъни, шулай булып, синең күзеңә күренеп, гаден җәннәтенә бер карыш микъдары калса, Аллаһ мәкреннән («кисәтүеннән», «каһәреннән») имин булма, чынлыкта алдагыдан артык курык димәктер.

Нәгузе биллаһи (Ходай сакласын), ул барган юлыңдан[1],
Әгәр кайтарса, нә килгәй кулыңдай!?

---

1 С.-П.да — йирендән (315 б.).

Ягъни Аллаһ Тәгалә хәзрәтенә сыгынырбыз, шуннан соң гаден оҗмахына (оҗмах бакчасына) бер карыш җитәр җитмәсендә кире кайтарып тәмугка җибәрсә, кулыңнан һичбер эш килмәс, и чарасыз бәндә, үкенү белән тәмугка китәрсең, димәктер.

Әгәр дузәх (тәмуг) ләбендә булса паен,
Өмид өзмә ки гафурдыр Ходаең.

Ягъни, шулай да, синең аягың тәмуг якасында (ләбендә) булса, Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзмә, чөнки Ходаең гөнаһларны гафу итеп, рәхмәт кылыр.

Гаҗәб ирмәс, әгәр кайтарса андан,
Насыйб итсә биһишт жавидәндән.

Ягъни Ходаның кадыйрлыгы (кодрәте) гаҗәп түгел, җәһәннәм ярында аягы булган кешене кире кайтарып, мәңгелек оҗмахны насыйп итсә дә...

Әгәр өстеңдәге йите табакны,
Гизеб әйләсәң йитмеш сабакны.

Ягъни син газиз булып, өстеңдәге җиде кат күкне гизеп, җитмеш төрле гыйлемлекне укысаң да, яки җиде кат күкне кичеп, җитмеш кат хиҗаб (пәрдә, капка) үтеп, Хак Тәгалә хозурында дәрескә утырсаң да...

Мәлаикдән әгәр пәрэндәдер сән,
Якын бел, бәндәи бичарәдер сән.

Ягъни фәрештәләр (мәлаикләр) җәмәгатеннән булып, очучы канатың (пәрәндә) булса да, шиксез бел, чарасыз бәндә син. Ни өчен тәкәбберлек кыласың...

Сәнең атың вә затың бәндә булса,
Ничек хәүф әйламәйсән җан тәндә булса.

Ягъни синең исемең һәм тәнең, җаның бәндә булса, ничек Аллаһ Тәгаләдән курыкмассың.

Ирер колның эше — куркыныч (курку) вә зари,
Кабул итмәк— икәмнең (иямнең Аллаһның) ихтыяри.

Ягъни андый булса, бәндә булган кешенең эше, Аллаһдан куркып һәм гөнаһлардан тәүбә итеп, зарыйлык кылу булыр. Ахыр чиктә, кабул итү Ходаның ихтыярында. Гафу итмәсә, безнең мөмкинлегебездән берни дә килмәс...

Әгәр гафу итмәсә, бичарадыр сән,
Кайу юл дисә, анда барадыр сән,

Ягъни бу кадәр зарыйлык кылып, гөнаһларыңны гафу кылмаса, ни чарадыр. Хөкем карарында кайсы юл дисә, анда китәрсең, аның боерыгына чарасыз син[1].

## Хикәят

Мөхәммәд кем — шаһи дөнья вә диндер,
Сыйфаты.рәхмәту лилгаләминдер.

Ягъни пәйгамбәремез г-м дөнья һәм ахирәт падишаһы...

Зәмине асманның халеки (җан ияләре), хили,
Яратылды, бәс, ул ирнең тофили.

Ахыры, ул Мөхәммәд г-мнең сыйфатлары: җир белән күктә һәм аларда торучы мәхлуклар ул Мөхәммәдкә ияреп яратылды. Әгәр ул булмаса, башкалар булмас иде.... *Хили* (хәйли) җәмәгать һәм мәхлук (җан ияләре) мәгънәсендәге сүз. Халкъ сүзенә (сүзнең — күплек саны) мөтәрадәфә (синоним) булды. Бу үлчәм шигырь өчен. *Тофили* таның (та хәрефенең) заммәсе (о. ө не белдерүче тамга) белән асылда бер олуг кеше исеме. Әмма монда мотлак (абсолют; тәмам) мөтәбагад (аерылучы) мәгънәсендә.

Укырда бер көни Тәңре китабын.
Укыды анда дузәхнең газабын.

1 К.да бу фикер түбәндәгечә бирелгән: “Хөкем кадимәсендә (“язмышта”) кайсы юл билгеләнгән булса, шунда барырсың. Аның гыйлемлеге чиксез һәм океан кебек тиңсездер. Бәндәләренә ни төрле хөкем карары тиеш - үзендә, бәндәләрнең төшенүе юктыр. Әлбәттә, каһәреннән куркып һәм рәхмәтләрен өмет итеп, боерганын эшлик һәм боермаганыннан тыелыйк, ахыры үзенә тапшырылган. Бу хикәят авторның карыш юл калса дигән сүзенә туры килешле. Аңа нәзыйрә хикәят китереп боерды.

www.darul-kutub.com

Ягъни Мөхәммәд г-м бер көн Изи гыйзз-у җәллнең (Аллаһның...) китабын укыр иде, Коръәндә тәмуг әһеленең газабын күрде...

Ул аяте вәһмидин китде үзедин,
Екылды, орды йиргә үзедин.

Ягъни пәйгамбәребез ул көндәге аятьнең мәгънәсеннән җиргә егылып һушсыз булды. Хәйли (күп) заман (шактый озак) ятты.

Сахабә һәр кайд бер халән булды,
Зәмин-у асман[1] дәр налә булды.

Ягъни пәйгамбәребез янындагы сахабәләр һәм йараннар аптыраш хәлендә булдылар һәм җир белән күк (зәмин-у асман) пәйгамбәребез һушсыз булуыннан үлде дип елауда булдылар.

Замандин күзене әйләде баз (кабат),
Сахабәләр әйделәр: әй мәхрәме раз.

Ягъни ул сәйд бер заманнан соң һушына (аңына) килде, күзен ачып торды. Йараннары әйттеләр: «Әй серләр карындашы сәедебез, ни өчен болай булдың, шаять, югары аятьнең эчтәлегеннән һушсыз булдың?» — диделәр.

Сәне халык әфзали кылды Ходаның,
Мөһәййә булса (әзерләнсә) җәннәт эчрә җаен (урының).

Ягъни сахабәләр әйттеләр: «Йа рәсүлуллаһ, ни өчен ул аять мәгънәсеннән еларсыз, барча халыкларның әфзалы (өстене) син һәм урының оҗмах эчендә хәзерләнгән. Ул аять сезнең кебек сәрвәрләр (юлбашчылар) хакында түгел, бәлки безнең кебек азгыннар хакында», — диделәр.

Сыйфатың рәхмәтел-лилгаләминдер,
Ходадин монча куркынычың нәдиндер?

---

1 С.-П.да — зәмин-асман (317 б.).

Ягъни, йа рәсүле Аллаһ (Аллаһның илчесе), синең сыйфатың Коръәндә «вә ма әфсәлнәка илля рәхмәтү лил-галәминә» булса, Изи гыйзз-у җәлләдән куркуың ни өчен? — диделәр.

Диде: гәрчә рәсүл җөзи көлл мән.
Ничек хәүф әйләмәй, — зирә ки кол мән.

Ягъни сәедебез сахабәләргә җавап бирде: «Әй йараннар, гарчә барча халыкка пәйгамбәр мин, шик юк, ничек курыкмыймын, чөнки кол мин»

Әгәр йөз мең бәшарәт булса, бары
Кирәк колдан ушанча хәүф, зарый.

Ягъни әйтте: «Әгәр бер бәндәсенә Аллаһ Тәгалә йөз мең бәшарәт[1] (сөенеч) бирсә дә, хакыйкатьтә бәндәгә элек артык курку һәм зарый кылу (кычкырып елау) кирәк», — диде.

Кешенең исме, заты булса бәндә,
Булырмы фаригыять кол дигәндә.

Ягъни бер кешенең исеме һәм заты бәндә булса, андый кеше Аллаһның хезмәтеннән фаригъ (азат) булмас, чөнки бәндәнең эше даими ялвару һәм тәүбә булыр.

## Ходай Тәгаләнең рәхмәтенә өмет бар булуы бәяны

Кил, әй тән («кеше»; ваемсыз), бирмәгел вакытыңны кулдин,
Йөре дәрьяи рәхмәткә бу чүлдин.

Ягъни андый бәндә кил, калган гомереңне бәндәчелектә үткәрмә, үткән гомереңә борчылып, калган гомердә тәүбә һәм күндәмлек белән бул; чөнки Аллаһның рәхмәт диңгезе дөнья яланында агыр, һәрчак андый булса, кылган гомереңне бәндәчәлеккә сарыф итмә, ягъни тәүбә ит.

Гөнаһым күб ирер диб булма мәэюс (өметсез),
Гаҗәб ирмәс, әгәр гафу итсә коддус («Аллаһ»)

1 К.да — йөз мең оҗмах илә сөенеч бирсә дә (218 б.).

Ягъни гөнаһым күп дип Аллаһының рәхмәтеннән өметсез булма. Гаҗәп түгелдер: Изи гыйзз-у җәлл (Аллаһ Тәгалә) гөнаһларыңны гафу итеп һәм тәүбәңне кабул итсә.

Дел-ү җан тәүбә кылсаң, әй йар,
Мәгәр гафу әйлагәй данаи әсрар.

Ягъни гөнаһларыңда күңел һәм җаның белән тәүбә итсәң, шаять, серләрне белүче изгебез (данаи әсрар, ягъни Аллаһ) ярлыкый, диләр.

Әгәр лотф әйласә сәттаре (кичерүче; Аллаһның эпитеты) галәм,
Табар ләхзада (мизгелдә) кяр ду (ике) галәм.

Ягъни гөнаһларны уручы[1] Иземез рәхимен бирсә, бер сулуда ике дөнья халкының гөнаһларын гафу итәр; чөнки кодрәтендә гаҗизлек (мескенлек) юк.

Габәсдии имди еглыб, тетрә еглаб.
Телә жан вә делеңдән рәхмәте рабб.

Ягъни андый булса, калган гомереңне батыйл (ярамаган) гамәлләрдән тыелып, Аллаһның газабыннан куркып елауда уздыр, күп файдалар бар диләр...

Һәваи пәст (түбән) идәр әшкең (күз яшең) нөҗүме,
Кәвакибдер — шәятыйнның рәҗүме.

Ягъни күз яшенең нөҗүме, ягъни йолдызы (бөртеге) һавалы нәфесләрне түбән итәр, чөнки күктәге йолдызлар (кәвакиб), шайтанларны атып, җир йөзенә иңдерер. Андый Аллаһтан куркып елаучының күз яше нәфес шәйтанны харап итәр...

Йөрәк йагың китәр булсаң, дисәң баз,
Кылыр күз йагыны, эч йагыны аз.

Ягыш сән йөрәк маен китермәк теләсәң, әүвәл күз ягьмырыны йагдыргыл. Аннан морад: Аллаһтан

1 К.да — уртачы (218 б.).

куркып ела, андан соң йөрәк маең аз булыр; нәфес хафаларың киселеп, бозык әхлаклы урынына күркәм[1], әдәпле, мактаулы булырсың, күңелең саф булып, фәна фи Аллаһ («Аллаһка бирелгән») булырсың. *Йагы* сүзенең әүвәлгесе янгыр мәгънәсендәдер һәм икенчесе май мәгънәсендәдер. Аннан морад: бозык әхлаклыга истигарә алынды (метафора рәвешендә алынды).

Ни дәүләтдер килеб гайбеңә шәрмең,
Вәли гәрмең сәнең аерылса гәр мең.

Ягъни гаҗәп изге дәүләттер: бер көн оятың (шәрмең) килеп, гаепләреңнән оялып, тәүбә һәм истигъфар итсәң (гафу, ярлыкау сорасаң), күңелне хәрарәтле (эссе, кайнарлык) итсәң, күңел хәрарәтең белән коеныр, гөнаһлардан кайтсаң — дәүләтләрнең олысы шулдыр. *Гәрмең* сүзенең әүвәлгесе хәрарәтлек (эсселек; җылылык) мәгънәсендә килә. Икенчесе ике телдән (сүздән) ясалгандыр: *гәр* фарсыча, бер мәгънә әгәр (әгәр мәгънәсендә); *мең* сүзе төрки була.

Ходаның хәүфедин бер катрәи шәк,
Газазил алдига чәндан (шулкадәр)[2] булыр рәшк.

Ягъни гөнаһларыңнан оялып[3], Ходаның газабыннан куркып, бер тамчы яшь күзеңнән чыгарсаң, шайтан ләгыйнь («Газазил») күзенә күп җирдә пәрдә булыр, җан иркендә ул ләгыйнь сине күрмәс, диməктер. *Рәшк* сүзе пәрдә мәгънәсендә килә, гади халык сүзе кулланылган.

Сәгадәтлек кеше йийб даимән гамь,
Күзен Хәкъ хәүфе берлә кылса шәбе нәм.

Ягъни изге дәүләтле кеше шул булыр: даими Аллаһ өчен кайгы җыеп, гөнаһларыннан үкенеп, Аллаһтан куркып елап, күзеннән чык суы (шәбе нәм) кадәре яшь чыгаручы. Кыскасы, күздән яшь чыгару куркучыларның галәмәте. *Шәбе нәм* васфы тәркибе (сүзтезмәсе) чык суы мәгънәсендә килә.

1 С.-П.да — пакъ (319 б.).
2 К.да — чәндай (219 б.).
3 К.да — үтенеб (219 б.).

## Чык суы бәянында

Чык суы өч төрледер: бер төрлесе кайбер икълимдә хәмәл (Иран календаре буенча ай исеме) бөрҗеннән сәрәтан (кысла; ай исеме) бөрҗенең ахырына тикле (ягъни 22 марттан июньгә кадәр) булыр. Ул чык суы бары тик үләннәргә файда өчен генә, хайваннар өчен түгелдер. Әмма әсәд (арслан; ай исеме; безнеңчә июльгә туры килә) бөрҗеннән сөнбелә бөрҗенең (августның) ахырына кадәр төшкән чык үләннәр файдасы өчен һәм анасунә (?) дигән хайван өчен булыр. Ул хайван чык суына нигъмәтләнеп торыр. Кайчан көз фасылы җитсә, ул хайван йоклар, хәтта икенче яз җиткәч, йокыдан уяныр, язгы чык суы белән бала чыгарыр, җәй фасылында булучы чык суы белән баласы, тәмам үсеп, үзе кебек булыр. Әйтәләр, анасунә дигән бер коштыр, үрдәк микъдары булыр, канатлары чуар[1], башы кара булыр. Үләнләр арасында торыр. Кайвакытта бүдәнә кебек очар, озак тормый үләннәр арасына төшәр. Очканда канатыннан төрле-төрле авазлар чыгар, авызы белән чыгармас. Һәм иркәк (ир-ат; «мужской род») булмас, чык суы белән хамилә (йөкле) булыр. Йомыркасы[2] өч булыр: ике йомыркасы йәпләгъ (?) булыр, ягъни шәберчек булыр, берсеннән баласы чыгар. Гарәб җәзирәләрендә (утрауларында) күп булыр һәм безнең Болгарның чигендәге Бохарада булыр.

Әйтәләр: чык суы яз фасылы белән җәй фасылында булган болыттан ирешәдер, бәлки дәүре фәләкнең (күк йөзенең) дәүреннән (әйләнүеннән) һава үзенә тартып торыр, чөнки дөнья күгеннән түбән бер дәрья бар, аны мәсҗүр диңгезе диерләр; каты җәядән чыккан ук кебек агар. Бу ике вакытта (яз һәм җәй) чык суын ике вакыт һавасы җәзеб итәр, ягъни тартыр. Кайчан кояш «Каф-тау артыннан» баш күтәрсә, баягы чык суын көрәй фәләк (күк гөмбәзе) үзенә тартып торыр, үләннәрдән алыр; вакытлыча биреп торган нәрсә кебек булыр...

Әйтәләр: сәрәтан бөрҗендә (аенда) төшкән чык суын анасунә дигән кошның йомыркасының кабыгына салып, авызын балавыз белән беркетеп, эченә чык суын тутырып, кояш чыкканга тикле (кадәр) тик кенә тоталар. Кояш иртәнге ашка кадәрге вакыт урынына

1 С.-П.да — чобар (320 б.).
2 С.-П.да — йомырдасы (320 б.).

ирешкәч, баягы йомырканы көрәй фәләк (күк) үзенә тартыр, эчендәге суын тарта алмас, шуңа күрә су тулы йомырка кабыгы белән һава йөзенә очар... Тәзруһ дигән аятьнең тәҗрибәсе шул булыр. Әмма күз төшкән чык суы хасыятле түгел, ул яңгыр. Гарчә сурәттә чык суы булса да, хасыяте юк, бәлки һава үзгәрүдән генә барлыкка килә. Кыш фасылына бәйле, хас булып, сәхабә гализ (тыгызланган болыт) булганыннан, башкадан түгелдер. Кыш булуына сәбәбче булыр. Әмма югары ике фасылда булган чык суының файдасы шул булыр: җир белән күк — җефетләрдер. Яз фасылында җир җефетенә ләззәтләнү җибәрер, күк ана чык суын җибәрер. Аның белән җир рәхәтлек табып, үләннәр белән хамилә (йөкле) булыр. Кайчан никах белән ул угланнарны тудырыр, шулчак камиллеккә ирешер. Җәй фасылында чык суын җибәрер, аларга ул кием кебектер. Үлән угланнарына аның белән зиннәтләнеп, ...төрле-төрле рәйгләри (төсләре) чык суыннан булыр... Шуннан чыгып, беленде инде, фаслы бәһардә (яз фасылында) күк җиргә чык суы җибәрүе җәмаг («интим мөнәсәбәт») кебектер. Асылда җәй фасылында бирүе аталар улларына либас (кием) биргәне кебек булыр. Әмма бу әшйадарны (әйберләрне) фәләккә (күккә) кайтарып калдырулары, мөнәсәбәтле бәйләүләре иснаде мәҗази (аллегория; метафора) диелә. Боларда (бу хакта) күп-күп кыйссалар бар, «фәне нәбат»ның (нәбат — үсемлекләр, үсемлекләр турындагы фәндә) әүвәлге фасылында бирелгәндер, анда кара.

Гарыз өзмә өмид талибе раһ,
Диде: «Ля тәккәту мин[1] рәхмәтуллаһ.

Сүзнең кыскасы шул булыр: әй Аллаһны теләгән кеше, Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзмә, чөнки Изи гыйзз-у җәлл (Аллаһ Тәгалә) боерды: «Әй минем бәндәләрем, рәхмәттән өмет өзмәгез, андый булса, никадәр гөнаһларда булсагыз да, рәхмәттән өметегезне кисмәгез».

Үтелмәс[2] җәрме шәрек, әй мәрде салик,
Үтәр лотыф әйләсә мадуне залик.

1 С.-П.да — имин (321 б.).
2 С.-П.да — үртүлмәс (321 б.).

Ягъни, әй туры юлга кертүчеләр (мәрде салик), тәүбә һәм истигъфар белән барча гөнаһлар кичерелер[1], мәгәр Аллаһ Тәгаләгә ширкәт каткан (тиңдәше бар дигән) кешеләрнең гөнаһлары кичерелмәс. Әгәр дә кем ширкаттән кайтып тәүбә итсә, Хак Тәгалә кабул итсә, аны да кичерер. Чөнки мөртәднең (диннән язучының) мөселман булмавы дөрес.

## Хикәят. Фасикъларның (бозыкларның) гөнаһтан янганы

Әгәр дузәх (тәмуг) ләбендә (кырыенда) булса паең (аягың),
Өмид өзмә ки, гафардыр (кичерүчедер) Ходаен.

Дигән сүзенә нәзыйр әйлаб (җавап биреп; охшатып) боерды ки:

Ишеткел фасикъи (бозык) янды гөнаһдин,
Пәшиман булды әхвале тәбаһдин (бозыклыкдан).

Ягъни, Аллаһ Тәгаләнең рәхмәтен өмет итүче бәндә, ишет, хикәяттә әйтәләр: фасикъ кеше гөнаһларыннан тәүбәгә килде, үткән гомерендә бозык хәлләреннән үкенеп тәүбә итте. Әйтәләр ки, тәүбә итүче назыйм (шагыйрь; автор), рәхмәтуллаһу (Аллаһның рәхмәте төшсен), үзе иде. Әүҗәле әмердә (тәүге «вакытта», элек) фасикълардан иде. Тәүбә итеп шәех Хәбибулла мәҗлесенә керде. Көннәрдән бер көн бер гөнаһ эшләп тәүбәсен бозды.

Кылыр ирде яман нәфсен[2] мәламәт (шелтә),
Гөнаһдин мөддәте ирде сәламәт.

Ягъни, ул тәүбә итүче фасикъ тәүбә итте һәм һәр көн нәфесен тыеп шелтәләп тора иде. Бераз мөддәт (вакыт) гөнаһ эшләмичә, пакь булып, гөнаһ юлына басмый торды. Әйтәләр: ул фасикъның гадәте даими хәмер эчү иде.

1 К.да — барчаның гөнаһлары кичелгәй (220 б.).
2 С.-П.да — нәфе (322 б.).

Яман нәфсе тәказа (таләп) итде янә,
Яманлык аркасына китде янә.

Ягъни тәүбә итүче кешенең яман нәфесе генә хәмер эчәргә теләде; шайтан вәсвәсәсе өстенлек алып, ахыр чиктә хәмер эчә башлады, тәүбәсен бозды, мәйханәдә хәмер эчеп өенә кайтты, йоклады.

Сәхәргяһ уянды ул гөнаһсыз,
Пәшиман булды кылган фигъледин баз (кабат).

Ягъни, ул гөнаһ төзүче кеше сәхәр вакытында уянды, исереклектән айныды, тәүбәсен бозганы хәтеренә төште, үкенде, Аллаһтан гаять курыкты, хәтта йөрәге пәрәләнергә җитте.

Булыб ирде дел-җаны белән нәрем (йомшак),
Вәләкин кылды бозгам гаһдиден шәрм.

Ягъни ул фасикъ гөнаһтан куркып, күңеле һәм жаны белән йомшады, кылган тәүбәсен бозганына, Аллаһтан оялды (шәрм кылды).

Юк ирде зәһрәсе тәүбә кылырга,
Якын йитде йөрәке ярылырга.

Ягъни ул тәүбәсен бозган фасикъның икенче кәррә (тапкыр) тәүбә итәргә тәкате калмады. Аллаһтан курыкмавы барча тәненә таралды, Аллаһтан курыкмавыннан йөрәкләре ярылырга җитешде. Аваз күтәреп утырган заманда

Нида килде һатифдан ушал халь:
Киен бакма, үзеңне элгәре ал[1].

Ягъни елап торган заманында аңсыздан галәме гаибдән (күренми торган галәмнән) колагына аваз (нида) килә (бу рәвештә): «Бәндәм, кирегә калма, үзеңне алга ал», — дип. Аннан морад: «нәүмиз булма, бәлки өметтә бул» дигән аваз килде.

---

1 С.-П.да — сал (323 б.).

Һәрчак мәгъфирәт дәрьясыдыр хуш,
Дәми аби ушал дәрьядан ит нуш.

Ягъни галәме гаебтән (күренми торган галәмнән) ул кешенең җан колагына әйтте: «Безнең ярлыкау (мәгъфирәт) диңгезебез синең аһыңнан кайнауга килде. Андый булса, кил бире, бер сулу микъдары безнең шул диңгезебездән эч (ит нуш)», — диде.

Әгәр чәндикә өзде гаһде пәстә (килешүне),
Ничә тәүбә итеб кылдың шикәстә (үкенеч; җиңелү).

Ягъни һатиф әйтте: «Гарчә, син бәндә, безнең белән кылган гәһдеңне өздең (иткән тәүбәңне боздың), хакыйкатьтә (чын; чынлыкта), тәүбәңне бозып, гөнаһ эшләдең һәм ничәмә тапкыр (мәртәбә) ул гөнаһларны эшләп һәм ничә мәртәбә тәүбә иттең, андый булса да:

Дел вә җан берлә чөн әйладең аһ,
Ирер тәүбәң сәнең мәкъбул дәргяһ.

Ягъни андый булса да, ничәмә төрле гөнаһлар эшләп, тәүбәләреңне бозсаң да, безгә җан һәм күңел (дел вә җан) белән аһ иттең. Шуның өчен безнең дәргяһымызга (катыбызда) тәүбәгез кабул булды. Чөнки без һәр гаҗизнең булышучысы (ярдәмчесе), бездән гайре сезгә падишаһ юк», — диде.

Ишетде бондай мәрхәмәте нак,
Орыб нәгъръә, якасын әйладе чак.

Ягъни Аллаһның рәхмәте хуш булган бәндә, бу авазы шәрифне (мөбарәк авазны) ишеткәннән соң, аваз күтәреп (орып нәгъръә) аһ итеп, якасын ертып, эченә Колзум диңгезе (Кызыл диңгез) кебек кайнау төште[1]. Һатифнең (Аллаһның) аваз шәрифен ишетеп гашыйк булды.

Үзедин кичде гаҗәб вә риядин,
Ходаем кылды ахыр әүлиядин...

1 Биредә бу җөмлә гарәпчә дә бирелгән (323 б.).



www.darul-kutub.com

Ягъни ул фасикъ бәндә һатифдан авазны ишеткәннән соң, рия һәм тәкәбберлеген ташлады. Ахыр чиктә, Ходай Тәгаләнең дусларыннан булып, вилаят мәкамен (җирдә үз урынын) тапты.

Тәрәххем (рәхимлек) күбдер бәндәгә Ходайдин,
Өмид өзмәк рәва ирмәс гидадин (фәкыйрьдән).

Ягъни, андый булса, Ходаның рәхмәте бәндәләргә күптер; без чынлап хәерче (фәкыйрь) бәндәләренә рәхмәтеннән өмет өзү ярамас.

Якын бел, гәрчә гафирдер (кичерүчедер) Ходавәнд,
Аңа һәм мәгърур улмагыл хәрдеменд.

Ягъни, шиксез бел, гәрчә Изи гыйзз-у җәлл гөнаһларны ярлыкаучы (гафирдер), андый булса да, аңа алданып гөнаһлар эшләмә, ягъни Аллаһ ярлыкар дип фискъ-фәсад (бозыклык) белән гомереңне уздырма, бәлки буйсынып гыйбадәт итеп, тәүбә, истигъфар (гафу үтенү) кыл.

Үтәр диб ятмагыл канга буялыб,
Уяныб лотфига ултыр сөянеб.

Ягъни Аллаһ Тәгалә минем гөнаһларымны ярлыклар дип гөнаһ канына буялып ятма, бәлки гафләтдән (ваемсызлыктан) уянып, рәхмәтеннән өмет итеп, изге гамәл кыл. Чөнки Аллаһның рәхмәте гамәл кылучыларга якынрактыр[1].

Әгәрчә лотф күбдер, каһре һәм бар,
Башың һәм күккә йитсә, кол сән, әй йар.

Ягъни Изи гыйзз-у җәллнең рәхмәте күптер, каһре (ачуы, җәзасы) да бар, ләкин рәхмәте каһәреннән күп, өстен. Әгәр башың күкләргә җитсә дә, ахыры кол син. Колның азат булуы хуҗа ихтыярында булыр. Андый булса, ничек Ходаның каһәреннән имин булырсың!?

Сәнен алдыңдадыр чәндан («күп») хәтардин,
Ничек гафил йөрерсән — хәуф итәрдин

1 Биредә бу җөмлә гарәпчә дә бирелгән (324 б.).

Ягъни син мескен бәндәнең алдында күп хәтәрләр бар. Шундый күп хәтәрләрдән курыкмый ничек гафил йөрерсең?

Гыйнаят кылса Хәкъ үлгән заманын,
Өзелсә нуре иман берлә җанын.

Ягъни Аллаһ Тәгалә сиңа кайгыртучанлык күрсәтеп (гыйнаят) ярдәм кылса, үлгән вакытта иман нуры белән җаның тәнеңнән чыкса.

Җавабе кабренә бирсәң чу бәһрак.
Кыямәт көндә купса йөзләрең ак.

Ягъни Аллаһ Тәгалә ярдәме белән гүр соравына тугрылык белән Мөнкир вә Нәнкиргә (кабердә сорау алучы ике фәрештәгә) җавап бирсәң, һәм ахырда кыямәт көнендә кабереңнән купканда, йөзләрең ак купса.

Тәразүгә (үлчәүгә) агыр килсә сәвабың,
Әгәр уң илкеңдә килсә китабың.

Ягъни хисап җирендә мизанда (үлчәүдә) гамәлләрең авыр килсә һәм дә гамәл дәфтәрең уң ягыңнан бирелсә.

Җәһәннәм өстендәй үтсәң сәламәт,
Биһиште җавидан кылса кәрамәт.

Ягъни сират күпереннән егылмый сәламәт үтсәң, мәңгелек оҗмах йортын (биһиште җавидан) Аллаһ Тәгалә риза кылса.

Болардин үтмәен, әй адәмизад,
Ничек фаригъ йөрерсән хөррәм-ү шад!?

Ягъни бу әйткән мәзкүр хәтәрләрдән котылмый, әй адәм, дөньяга алданып, ни өчен шат йөрисең!? Бәлки болардан сәламәт аерылсаң, аннан соң шатлыкка ирешерсең. Шулай итеп боерды:

Җиһан көлкү[1] йире имәсдер, әй кол,
Әгәр билкөлли (бөтен) хәтардин атласан, — көл.

1 С.-П.да — көлек (325 б.).



www.darul-kutub.com

Ягъни андый булса, бу дөнья уйнау, көлү җире түгел. Алда әйтелгән мәзкүр (телгә алынган) хәтәрләрдән атлап, узып син оҗмахка кергәч, уйна, көл гел, димәктер.

## Казага риза булып бәлагә сабыр итү бәяны

Кил, әй бәндә, үзеңне сал Ходага,
Казага разый бул, сабыр ит бәлагә.

Ягъни, андый бәндә, үзеңнең ихтыяри йөзеңне (өлешең; омтылуыңны) Ходага сал. Салуың шул булыр: ул сөйгән кешесе хөкеменә биргән бәлаләренә сабыр кыл, кайгырма һәм иңгерәмә, чөнки мәшарикъдә китерелгән, Аллаһ Тәгалә пәйгамбәренә мөрәҗәгать итеп болай ди: «Әгәр безнең биргән нигъмәтебезгә шөкер итмәсә һәм килгән бәлаләребезгә сабыр итмәсә, әйт: «Андый кол безнең җиребез белән күгебездән чыгып, башка тәңрене эзләсен», — диде». Әй газиз кеше, аңла, каза белән бәланең мәгънәсе, билгеләмәсе шул булыр: каза дигәннәрен Аллаһ Тәгалә, мәңгелек көнендә бәндәләренә үлчәп кенә, ләүхе мәхфуздә (язмыш тактасында) язгандыр, аны каза диерләр. Кайчанда булса, ул бәндә галәме һәйуладин (хаостан) галәме сурәгә килсә, баягы үлчәнгән каза бу бәндәнең башына уралса, аны бәла диерләр. Әйтәләр: Аллаһ Тәгалә ләүхене (тактаны) кызыл якутдан яратты. Анда өч юл язылгандыр. Әүвәлгесен — гыйльме Аллаһ диерләр. Икенчесен — гыйльме кәрүбиййун (кәррубиййун) диерләр. Өченчесен — гыйльме мәлаик (мәләкләр — фәрештәләр) диерләр. Әүвәлге юлның һәрбер хәрефе Каф тавының кыялары кебектер. Андагы мәгънәне һич кәрүбийун вә саире (башка; үзгә) фәрештәләр, кешеләр укый алмаслар, белмәсләр. Изи гыйзз-у җәлл бәндәләренә тиешле, билгеләнгән ризыкны һәм бәлаләрне гыйльме кәрүбиййуннан төшереп, кәрибиййун аны күреп, фәһемләп (аңлап, уйлап) гыйльме мәлаиккә төшерер. Аннан соң барча фәрештә җәмәгате бәндәләргә ни киләсен аннан соң белерләр. Шуның өчен элекке заманда шайтаннар җәмәгате күк йөзенә чыгып, фәрештәләрнең сөйләшкән сүзен ишетеп, җир йөзендәге фалчы һәм мөнәҗҗимләргә (астрологларга, юраучыларга) хәбәр бирәләр иде. Инде безнең сәедебез яшәргә килде. Аларны, ул ләгыйньләрне, фәрештәләр йолдызлардан ут алып атып куалар...

www.darul-kutub.com

Якын бел, бәндә булса асыл исмең,
Ходаның милке (мөлке) булса җан вә җисмең

Ягъни, шиксез бел, асылда исемең бәндә булыр һәм дә тәнең белән җаның Изи гыйзз-у җәллнең мөлке (Аллаһның әйбере, байлыгы). Андый булса:

Аныңдыр мал вә милке — һәр нә бары,
Ничек кылса үзенең ихтыяры.

Ягъни[1] синең малың һәм дә милекләрең бар — барчасы Ходайныкы. Андый булса, үз милкендә Аның ихтыяры бар. Синең бәйсез милкең юк. Андый булса, сабыр ит, чөнки бәндә үз милке белән үзе эш итә алмый.

Буен сынгыл, ничек кем кылса фәрман,
Булырмы бәндә дә хөҗҗәтү дәрман!?

Ягъни, андый булса, Ходай Тәгалә ни төрле хөкем итсә дә, хөкеменә буйсын, чөнки бәндә дигән нәрсәдә хөҗҗәт (дәлил) иту булмас. Андый булса, аның хөкеменә риза бул.

Кеше кем булмаса разый казага,
Әгәр сабыр итмәсә килгән бәлага.

Ягъни бер кеше килгән бәлаләргә сабыр итмәсә һәм Ходаның үлчәү, чама кылганына риза булмаса, бу бәд мөбтәдадер (начар кеше, явызлык иясе).

Янә шөкер итмәсә Хәкъ нигъмәтигә,
Качан лаек булыр бәндә атига!?

Ягъни Ходаның биргән нигъмәтләренә шөкер итмәсә, андый кеше бәндәлек исеменә лаек түгел. Чөнки бәндә булган кеше, әлбәттә, мәүләсенең («хуҗасының», Аллаһның) хөкеменә риза булыр. Шигырь ахыры хәбәре мөбтәдадер (ия, хуҗа).

---

1 С.-П.да — вә дәхи (326 б.).

Ходага һәр эшең кылсаң хәвалә,
Булыр җәннәт бу утырган кавалә.

Ягъни бер бәндә барча эшен Ходага тапшырса, килгән бәлаләренә аһ-зар кылмаса һәм дә биргән нигъмәтләренә шөкер кылып торган бәндәгә барча җир йөзе бакча булыр. Гарчә коры юлханәсендә утырса да. *Хәвалә* — тапшыру мәгънәсендәге сүз... *Кавалә* бер кечерәк өйнең исеме була. Мәсакин җәмәгате («авырулар») дәрья якасында бина кылырлар, һәм кемне күрсәләр, шуны хөсбәтанлиллаһ өчен («Аллаһ хакы өчен», бушка) дәрьядан су алып сугарырлар. Әмма монда мотлак җир мәгънәсендә килә, төрекмән сөйләменнән алынган.

Күңелдә калмагай[1] дөнья гамендәй.
Алырсән бәһрә (өлеш) үткән дәмендән.

Ягъни андый кешенең күңелендә дөнья кайгысы юк. Андый сабыр иткән кеше гомерләреннән файдалар алыр.

Кайу колга мияссәр булса бу халь,
Әгәр агу эчәр булса, белгәй аны бал.

Ягъни мондый хәл бер бәндәдә булса, бәлаләренә сабыр итсә, нигъмәтләренә шөкер кылса, андый бәндә, әгәрчә зәһәр (агу) җамыны (савытын) эчсә дә, бал кебек дип белер, ягъни Хода биргән нәрсәләргә риза булыр.

Ходаның кәнҗедин (хәзинәсеннән) булса бу яхшы,
Рәҗа (өметләнгән) чү(н) кол аны күрмәсме яхшы!?

Ягъни бу килгән бәлаләр һәм казалар Ходаның яныннан сиңа яхшылык өчен килгән. Шулай булса да, аның хикмәтеннән гафил син. Әмма Аллаһ ризалыгын теләгән кеше, әлбәттә, ул килгән бәлаләрне яхшы күрү кирәк, чөнки Аллаһ Тәгалә бәндәләренә җибәрүе тәҗрибә өчен. Шуның өчен безнең өммәткә дә, хитабы тәхис (махсус мөрәҗәгать) белән боерды... Гомумән алганда, бәлаләргә сабыр итү — ул безнең җәмәгатьнең эше.

---

1 С.-П.да — булмагай (327 б.).

www.darul-kutub.com

## Хикәят. Габдулла Әнсари

Голами алды Габдулла Әнсар,
Диде: «Әй кол, атыңны әйлә изһар».

Ягъни хикәятләрдән килә: Габдулла (Габдуллаһ) Әнсари хәзрәтләре бер кол сатып алды. Ул колга әйтте: «Әй егет, исемеңне әйт, ни исемле торырсың?» — диде. Әйтәләр: Габдулла Әнсари Мәдинә шәһәренеке иде. Атасы әнсарилардән иде. Гаять күндәм, тугрылыклы мөселман иде. Һәм үзе сәхабәләрнең олысыннан иде. Гаять бай иде. Әйтәләр: Мәдинә җәмәгатендә ул дәвердә Габдрахман бине Гауфдән бай кеше юк[1] иде. Аннан кала Габдулла Әнсари иде. Өхед сугышында шәһид булды. Алтмыш өч яшендә вафат булды, диләр.

Диде: Әй хуҗа, сән куйсаң кайу ат,
Бәнем атым ушалдыр, әй никү (изге) зат.

Ягъни ул кол җавап бирен әйтте: «Әй хуҗа, син кайсы исемне куйсаң, минем атым шул булыр», — диде.

Диде: Әй кол, сүвәрсән — кайсы хубрак (әйбәтрәк),
Диде: Синдин нә тиксә — бәһдер (яхшыдыр), әй пакь.

Ягъни Габдулла әйтте: «Мин сиңа исем биререм, ләкин кайсы исемне сөясең?» — диде. Кол әйтте: «Син кайсы исемне сөеп куйсаң, исем миңа лаек булыр», — диде.

Диде: Кайсы ирер күңлеңдә мәргуб?
Диде: Сән кайсыны бирсәң, ушал хуб.

Ягъни Габдулла әйтте: «Кайсы исем күңелеңә сөекле соң, мин аны куярым», — диде. Кол әйтте: «Син кайсы исемне сөеп куйсаң, миңа шул исем яхшы», — диде.

Диде: «Әй кол, нәдер кәсбең вә кярең (шөгылең)?
Диде, һәр кайусы — булса ихтыярың.

Ягъни Габдулла әйтте: «Әй кол, ни төрле кәсеп һәм ни төрле һөнәр кыласың?» — диде. Кол әйтте: «Сезнең

1 С.-П.да — тәвангәр (бай) (327 б.).

ихтыярыгызда: нинди кәсепкә кушсаң, аны эшләмичә чарабыз юк», — диде.

Диде: Бари (ярый), кылырсән кайу һөнәрдин?
Акызды әшкен (яшен) ул кол чәшмийе тәрдин (күзеннән).

Ягъни Габдулла әйтте: «Әй кол, төгәл генә әйт, ни төрле һөнәр беләсең?» — диде. Колның бу җавабын ишетте, яшьләр агызып елап җибәрде:

Диде: Әй яхшыларның шәһрияры,
Булырмы кол дигәннең ихтыяры.

Ягъни кол әйтте: «Әй изгеләрнең падишаһы, кол дигән кешенең ихтыяры булмас. Ни эшкә кушсаң, буенсынмый чарасы юк».

Әгәр әмер әйласәң, һәр кайсы йөзгә,
Нәдер чарам буен сынмакдин үзгә.

Ягъни син безгә һәр кайсы кәсеп һәм хәрәкәт эшләргә боерсаң, кол бәндәнең чарасы юк, син кушкан эшне эшли.

Ишетде хуҗа ул колның сүзене,
Екылды йиргә, орды үз-үзене.

Ягъни Габдулла сүзне ишетте, сүзнең кайсы тарафтан әйтелгәнен белде. Моннан соң үзен-үзе җиргә атып һушсыз булды.

Якасын чак итеб, диер ирде анда:
Әй Габдулла ки, күрдең фигьле бәндә.

Ягъни Габдулла, һушсыз булып, якасын ертып (чак итеп) егылды. Шул заман үзенә-үзе әйтер иде: «Әй Габдулла мескен, күрдеңме бәндәчелек фигылен? Хакыйкатьтә (чынлыкта) Ходага бәндә булырга бу кара колдан өйрән», — диде. Әйтәләр: Габдулла Әнсари бу колны азат итте, үзе ялгызлык, дәрвишлек юлын сайлады һәм барча малын мескеннәргә сарыф кылды, таратты.

## Фәкыйрьләрне хур күрү бәяны

**К**ил, әй назыйр, мөселман булса һәр йар,
Нәзар кылма (карама) хәкарәт берлә, зинһар.

Ягъни, әй андый туры күз белән карап гыйбрәт[1] алучы кеше, зинһар, мөселман булган кешегә мәсхәрәлек күзе белән карама.

Фәкыйрьне белмә ким дөнья илидин,
Хәдиси килде пәйгамбәр телидән.

Ягъни син фәкыйрьләрне дөнья түбәннәре, кимнәре дип мәсхәрә кылма һәм алардан көлмә, чөнки фәкыйрьләр хакында пәйгамбәребез теленнән шундый хәдис килде:

Диде: «Әл-фәкйр — фәхри», ягъни ул шаһ,
Ничек артык күрерсән хишмәте җаһ?

Ягъни пәйгамбәребез фәкыйрьләр хакында әйтте: «Фәкыйрьлек минем мактаначак һөнәрем», — диде. Андый булса, әй андый гаскәр һәм мәртәбә иясе кеше, фәкыйрьләрне ни өчен читкә[2] куеп игътибар итмисең, димәк. *Хишмәт* дигәне гаскәр сахибе (иясе) мәгънәсендәге сүз. Һәм *җаһ* дигәне мәртәбә иясе дигәнне аңлата...

Гамәлдер — яхшы колларның кәмали,
Вәрәгъдер — хәшмәте ж,аһ җәлали.

Ягъни яхшы колларның камиллеге гамәл белән һәм дә үз-үзен чикли белүе Аллаһның ачуын сүндерер. Андый булса, фәкыйрьләргә тәкәбберлек кылма.

Имәс дөньясы булган берлә мәхбуб,
Хисабе ахирәт ким булганы хуб.

Ягъни дөньялыкта артык мал һәм мөлкәт күплеге Аллаһ Тәгалә каршында сөелгән булуына дәлил түгел, бәлки тәкъвалеккә ирешү, чөнки фәкыйрь булган кешенең ахирәт йортында хисабы шул.

---

1 С.-П.да — гар (329 б.).
2 С.-П.да — артык (329 б.).

Әгәр бәһ (күп) булса булган берлә малы,
Ки Карун булгай ирде әһле хали.

Ягъни мал-мөлкәте күп булган кеше изгеләрдән булса иде, Карун ләгыйнь әһеле суфый, тәкъва булып, Ходага якын булыр иде.

Куанды ничә көн дөнья өйуга,
Йибәрде малы берлә йир коега.

Ягъни ул Карун ләгыйнь бераз вакыт дөньялыкта сараенда куанды. Ахырда бер көн Изи гыйзз-у җәлл ул ләгыйньне малы белән җир куенына җибәрде, «якыныннан» ерак төшеп, кяферләрдән булды.

Әгәр дөньясы юкдан булса ир хар (түбән),
Пәйгамбәргә[1] билал («хәбәрче») булмас иде йар.

Ягъни, дөньяда мал булганыннан кеше хур булса иде, пәйгамбәргә Билал хабаши юлдаш булмас иде. Шуннан беленде, Үзенә якынлык мал-мөлкәт белән түгел. Күпме мал-мөлкәт ияләре нәфесләренә буйсынып, ияреп, һаваланып, Ходайдан ерак булдылар һәм күпме фәкыйрь булып, Ходай биргәненә канәгать итеп, гомерләрен Хода юлына сарыф итеп, изһаре («чын») мәхәббәт сәбәпле Аллаһка якын булдылар.

Мөхәммәд кем нәбиләргә иде таж,
Гата (бүләк) кылды Ходай ул кичә мигъраҗ.

Ягъни пәйгамбәребез г-м барча пәйгамбәрләрдән өстен иде. Көннәрдән бер көнне Изи гыйзз-у җәлл (Аллаһ Тәгалә), ул сәедкә мигъраҗ төнен бүләк итеп, дүртенче кат күк йөзенә ашырды.

Мәкаме сидрәгә тиде[2] ул бәндә,
Билале нәгълин сауте килде анда.

Ягъни пәйгамбәребез мигъраҗ төнендә күкнең

1 К.да — Мөхәммәдкә (225 б.).
2 К.да — йитде (226 б.).



www.darulkutub.com

җиденче катындагы урынга — мәкамга ирешкәндә, төннең яртысы иде. Билал, разыйаллаһуәнһу (Аллаһ аны ярлыкасын!), мәчеткә барырга тәһарәт төзеп, мөнтәһа агачы төбендә иде. Аңсыздан аваз колагына ишетелде, җир йөзе селкенә иде. Әйтте ки: «Йә карындашым Җәбраил, ни хәл булды: күк йөзе һәм җир йөзе селкенә?» Җәбраил г-м әйтте: «Йә Мөхәммәд, Билал мәчеткә барырга чыкты, аның башмагының авазы; җирләр аның тәкъвалек һәйбәтеннән («тәэсиреннән») калтырый һәм күк аның гыйшкыннан хәрәкәткә килә», — диде. Пәйгамбәр г-м әйтте: «Билалны күрер идем»,— диде. Шул заман Хак Тәгалә күкләр капкасын ачты. Пәйгамбәребез үз күзе белән Билалның мәчеткә барганын карап торды. Барып җиткәнче, күк йөзе һәм җир калтырап торды. Әмма ләкин Билал дөньяда фәкыйрь кеше иде, бик изге иде, сәхабәләр арасында серләрне ачучы зирәк иде.

Әйтәләр: көннәрдән бер көнне Гомәр, разыйаллаһуәнһу (Аллаһ аны ярлыкасын!), әвендә йомырка[1] алды. Ул йомырканың агын үз алдына пешерде һәм сарысын үз алдына пешереп ашады. Мәчеткә барды. Төннең яртысы иде. Күрде: мәчет эчендә Билал утыра. Сәлам бирде. Билал сәламне алмады... Гомәр әйтте: «Йә Билал, ни өчен галәйкә («сиңа булган сәламне») алмыйсың?» — диде. Билал әйтте: «Күңелеңдә көферлек галәмәте күренә», — диде. Гомәр әйтте: «Хашилиллаһ (Аллаһ сакласын), бу ни хәл?» — диде. Ике тезен чүгеп, Билал каршысына утырды. Әйтте: «Йә вәлийе нигъмәти (нигъмәт иясе), бездә көферлек галәмәте булса, аны кылавыз (юлбашчы; остаз) булып, бездән чыгар», — диде. Билал әйтте: «Йә Гомәр, пәйгамбәребез гомерендә ике төрле нигъмәтне бергә ашамады һәм аны эшләргә дә кушмады. Үзегезгә мәгълүм, сез бу төндә йомырканы ике төрле ясадыгыз: берсе артыннан берсен ашадыгыз, кяфи (кяфа) түгелме (шулай түгелме)? Бер төрлене ашап канәгать итсәк? — диде. — Шул сәбәпле күңелең даирәсендә начар уй-явыз көч гизде. Күңелеңнән әйттең: «Иртә белән һәм мондый нигъмәтне ашыйм», — дидең. Гомәр: «Садәкать (дөрес)», — диде, мәчеттән чыгып, ашаганын косты һәм ,тәһарәтен кайтарып алып, мәчеткә кереп сәлам бирде һәм Билал сәламне алды.

---

1 С.-П.да — йоырда (330 б.).

Бәла вә факага (ачлыкка) сабыр иткән инсан,
Дианәт мөлкедер ул мәрде мәйдан[1].

Ягъни бәлаләргә һәм ачлыкларга сабыр итү — дин мөлкенең камиллеге булыр, әй белекле адәм.

Әгәр чәндикә булсаң, би безагать,
Сөләйман сән, әгәр кылсаң канәгать.

Ягъни әгәр никадәр генә дөнья йөзендә һич нәрсәң булмаса да канәгать булсаң, Сөләйман пәйгамбәр кебек бай булырсың, чөнки байлык канәгатьлектә була.

Канәгатьдер — күңелләрнең сәфасы,
Канәгатьдер — барча гыйлләтнең (чирнең) дәвасы.

Ягъни канәгать итү — күңелләрнең сафлыгы һәм дә канәгать итү — барча күңел зәхмәтенең даруы.

Канәгать кем табиб һәр кәсәлдер («авыруга»),
Канәгать әһлигә агу — гасәлдер.

Ягъни, канәгать кешегә зәһәрле нәрсәләр бал кебек.
Берәүнең хөкме йитсә гаребдии шәрк,
Берәүнең башига мури (кырмыска) кылыр хәрб.

Ягъни бер кеше, шаһ булып, мәшрикътан мәгърибкәчә (көнчыгыштан көнбатышкача) хөкем йөртсә һәм берсе зәбун (зәгыйфь) булып, кырмыска аның белән сугышса, аңа галип булмаса (аны җиңмәсә),

Әҗәл җәллады куксен (күкрәген) әйлагәч чак,
Булыр һәр икеләсе (икесе) күрмәгән дәк.

Бу ике кешенең күкрәкләрен әҗәл җәллады (палач) ярса, ягъни Газраил җаннарын алса, һәр икесе дә яшәмәгән дә, күрмәгән дә кебек булырлар, шаһ булганын күрмәгән кебек була, ягъни һәр икесе бер шәкелдә туфрак астында калырлар, (асылда) бернинди аерма булмас.

1 К.да — минан (226 б.).



www.darul-kutub.com

Берәүнең нокрә телләсе[1] мул-мул,
Берәүнең күргәне юк гомерендә бер пул (акча).

Ягъни бер бәндәнең көмеше һәм тәңкәсе тул-тулы булса һәм дә икенче бәндә гомерендә бер акча күрмәсә, ягъни асылда һич нәрсәсе булмаса,

Моны мөфлис (фәкыйрь) димә, тыңла[2] (уйла) аны бай,
Булыр һәр кайсыга ләхеде җай.

Ягъни бу гомерендә бер акча күрмәгән кешене кыямәт көнендә ярлы димә һәм дә көмеш тәңкәсе күп кешене бай булыр димә, чөнки аның өчен ахирәт хәлләре мәгълүм түгел, һәр икесе ләхед астында калырлар.

Берәү үткәрде гомрене гыйш илә фаш,
Берәү таткңны юк агзы тулы аш.

Ягъни бер бәндә гомерен рәхәтлек һәм киңлек белән үткәрде һәм бер бәндә гомерендә авызы туйганчы аш җыймады (ашамады), фәкыйрь өммәт булды.

Әҗәл җан ачыгын күргәч ан дәк,
Кылыр һәр икелесе (икесе) күрмәгән дәк.

Ягъни, ул икесе әҗәл ширбәтен эчсәләр, һәр икесе бердәй кара туфрак булырлар.

Берәүнең булса даим михнәте гәрд (тузан...),
Берәүнең көлфәте булмаса бер корд.

Ягъни бер бәндәдә даими михнәт тузаны булса, зәхмәт белән гомерен үткәрсә һәм дә бер бәндәдә тузан кадәренчә мәшәкать булмаса, асылда гомерендә рәнҗү күрмәсә,

Алар булса үлемнең мөбталясе,
Булыр һич күрмәгәндәк икеләсе.

---

1 С.-П.да — атласы (332 б.).
2 К.да — танда (226 б.).

Ягъни бу ике кеше үлем зәхмәтенә дучар булса, ләхедкә керсәләр, бу ике кеше башларына төшкән нәрсәләрне күрмәгән кебек булырлар.

Гарз һәр канда (кайда), әй фәрзәнде Адәм,
Йиймә һәр гиз (вакыт) үтәр дөнья өчен гамь.

Ягъни сүзнең кыскасы, әй Адәм улы, һәр кайсы хәлдә булсаң да, дөнья өчен кайгырма, бәлки дин кайгысын кайгырт, ахыр чиктә ихласың белән изге гамәлләр кыл, Аллаһ Тәгалә ризалыгына ирешергә тырыш.

## Хыянәттән ерак булып, диянәтле булу бәяны

Кил, әй мөэмин, кәмал итсәң дианәт,
Кешегә кылмагыл һәргиз (һич тә) хыянәт.

Ягъни хыянәт төрле әгъзаларыңнан пәйда булыр: кайвакыт кулыннан килер, мәсәлән, берәүнең бер нәрсәсен урлау кебек, яки харам әгъзаларын тоту кебек. Һәм дә күзеннән килер, намәхрәмләр (чит хатын-кызлар) йөзенә карау кебек. Һәм дә аяктан килер, гөнаһ эшләргә бару кебек. Күңелдән дә килер, мөселманнарга явыз уй, ният кылу кебек. Сүздән дә килер, гайбәт һәм ялган сүз кебек. Моннан башка хыянәтләр бар, барын да искә алып китү хаҗәт түгел. Ничек итеп боерды:

Моны белгәй җәмигъе адәми зад,
Имәс хаҗәт бер-бер әйласәм йад.

Ягъни хыянәтнең төрле-төрле әгъзадан булганын барча адәм уллары беләләр, аларның барчасын бәян итү хаҗәт түгел, һәр кешегә билгеле.

Хыянәт кем ирер пәйда күңелдән,
Моны аңла, дианәт бирмә кулдан.

Ягъни хыянәтнең олысы күңелдә, моны аңла, зинһар, Аллаһ хакы өчен дип әйтәмен. Бу күңел хыянәтен кылма — динсез кала күрмә.

Нә кем төшсә күңелгә яки күзгә,
Рәва (урымлы) күрмәсән ул эшне үзенгә.

Ягъни күнел хыянәте шул булыр: бер нәрсә күзеңә күренүе яки күңелеңә төшерден исә, бу күргән яки фикерләгән нәрсәләрне уйлап кара, үзеңә килсә, үзең яраклы күрмәсәң,

Рәва күрсәң мөселманга аны,
Боны диерләр: хыянәтнең яманы.

Ягъни үзеңә яраклы күрмәгән нәрсәне бер мөселманга яраклы күрсәң яки инкяр булуы өчен шатлансаң, бу — хыянәтнең яманы булыр.

Кайу эшкә риза булсаң күңелдә,
Әгәрчә кылмасаң — булдың у(л) юлда.

Ягъни кайсы эшкә күңелең белән риза булсаң, аны сөйсәң, әгәр кылмасаң да, шул юлда булырсың. Шуның өчен күп мөселманнар, дөньялыкта кяфер әһелен сөйгәне өчен, кяфер булып дөньядан үттеләр һәм дә кяферләр мөселманнарны сөйгәне өчен мөселман булдылар. Сорау: эш андый булса, ни өчен Муса г-м Бәлгам Байгурәгә көферлек белән дога кылды? Әмма ләкин Муса г-м көферлеккә риза булды, — диделәр. Җавап шул булыр: Муса г-м шәригатендә зарар тидергән кешегә кяферлек белән дога кылу рөхсәт ителгән иде, шуңа күрә Бәлгам Байгурә ул Муса г-мгә дога кылды. Муса г-мнең зарары юк иде, әмма моның соңында, Муса г-м аның догасы сәбәпле, кырык ел Тиһ сәхрасында йөрде. Муса г-мгә зарары килде. Шуның өчен, шәригатендә рөхсәт ителгән булганы өчен дога кылды. Шулай ук Ягъкуб шәригатендә азат кеше «кол мин» дип әйтеп белдерсә, сатулары дөрес иде. Шулай ук Адәме Сафиуллаһ шәригатендә карындашны алу кебек һәм Идрис г-м шәригатендә зәкяттән арткан малны утка ягу кебекләр кабул ителгән иде. Сорау: Муса г-м Бәлгам Байгурә догасыннан булганын кайдан белде? Җабап: Җәбраил белдерде. Сорау: Бәлгам Байгурә дога кылганны Җәбраил Мусага әйтеп сүз[1] йөртүче әһеленнән

1 С.-П.да — нәммимә (334 б.).



www.darulkutub.com

булдымы, чөнки сүз йөртү хәрам булса, Җәбраил бозык булдымы? Аллаһ сакласын, Җәбраил бозык булыр? Җавап шул булыр; Җәбраил г-мнең Мусага әйтүе сүз йөртү түгел, бәлки Изи гыйзз-у җәллгә дога кылды: «Йарабби, миңа нинди хәл очрады, бу хөкем үзеңнәнме яки гаварызлардан («гарыз»ның күплек саны) бер гарыз беләнме?» Изи гыйзз-у җәлл догасын кабул итте, чөнки пәйгамбәрләр догасының кире кагылуы харам. Аллаһ Тәгалә Җәбраилгә шуны белдерде, ул Мусага әйтте. Сорау: Изи гыйзз-у җәллнең үзенең әйтүе сүз йөртү түгелме? Җавап: Ходай Тәгаләнең бәндәләренә кылган фигыленнән һәм сүзләренә сорау юк, аның хикмәтен тикшерү бәндәләргә харам. Сорау: Муса г-мне ни өчен Кәлимуллаһ диде, әмма ләкин Изи гыйзз-у җәлл үзенең кодрәтле теле белән әйтмәде, Җәбраил артыннан әйттерде. Андый булса, Мусаны Кәлимуллаһ диюләре ялган булдымы? Җавап шул булыр: Аллаһ Тәгаләнең сөйләшүе бик күп, даими түгелдер: кайсы вакытта сөйләшер иде һәм кайсы вакытта Җәбраил артыннан әйттерер иде һәм җавап дигәннәре шул була. Аллаһ Тәгаләнең сөйләшүе Тур тавында (ул Синай төбәгендә) булыр иде. Башка урыннарда сөйләшү харам булды.

Мөселман углыны күрең күзеңдәк,
Зарарда, нәфегъдә (файдада) белсәң үзең дәк.

Ягъни барча мөселман улларын күзең нуры кебек күрсәң, файданы да, зарарны да үзеңә килгән кебек күрсәң, мөселманнарга бәла-каза килгәндә кайгырсаң, рәхәтлек килгәндә сөенсәң.

Кайу колның моның дәк булса хале,
Будыр, бишәкк, мөселманлык кәмале.

Ягъни кайсы бәндәнең югарыда әйтелгән хәле кебек хәле булса, ягъни мөселманнарга бәла килгәндә кайгырса һәм рәхәтлек килгән вакытта сөенсә, мөселманлыкның асылы шул булыр. Әйтәләр: берәү бер мөселман кардәшенә бәла һәм каза килгәндә шатланса, әлгаязубиллаһ (Аллаһ сакласын!), кяфер булыр, чөнки мөселман карындаштан булса, әлбәттә, мөселман өчен кайгырыр иде. Андый

булса, һаман да кяфер булыр... Мөселман карындашка килешү, дуслашу шул булыр: бер-беренә күңел бәйләү һәм мәшәкать хәлендә көенү һәм рәхәтлек хәлендә сөенү һәм кыек юлга барса, туры юлга күндерү...

Әгәр чәндикә булса шөбһәи кәм,
Рәва күрмәсәң аны уз нәфсеңә һәм.

Ягъни бер кечерәк зыян килсә, ул зыянны, үзеңә килгәндә, яраклы, тиешле күрмәсәң, ул эшне сөймәсәң,

Рәва күрмә мөселманига, зинһар,
Әгәр белсәң бинагяһ (көтмәгәндә) әйлә изһар.

Ягъни үзенә яраклы күрмәгән нәрсәне, зинһар, мөселман карындашыңа ярашлы күрмә, әгәр үз акылында булса, аңлат, төшендер.

Хосусан бирмәгел тәкъвалек иргә,
Могыйлан сачмәгел рәйханлы йиргә.

Әмма ләкин ул эшне тәкъвалык һәм суфыйлык кылучыга яраклы күрмә, ягъни шөбһәле нәрсәләрне җыеп йөрүдән саклан, чөнки тиешле күрсәң, рәйханлы, чәчәкле җиргә тигәнәк орлыгы чәчкән кебек булырсың.

Тәкыйның (изгенең) күкеседер — дарес-сийанәт,
Сийанәтханәйә кылма хыянәт.

Ягъни аңлашылганча, тәкъвалек әһеленең күкрәге харамнардан саклану урыны (дарес-сийанәт). Андый булса, харамнардан сакланучы йортка (сийанәтханәгә) хыянәт итмә һәм әһеле тәкъвага явыз уйдырмалар якма, башына бәла һәм каза килгәндә сөенмә, һәрчак аның өчен гамьдә бул...

Әгәр табылса нигъмәт, алдыга сач,
Әгәр булмаса, агзың гозер өчен ач.

Ягъни, мөселман карындашыңа нигъмәтең булса, алдына куй. Әгәр хәләл нигъмәтең булмаса, яхшы телең

һәм ачык йөзең белән гозерләр өчен авызыңны ач, ягъни үтенечләреңне әйт.

Әгәр мең халта (хәлитә) бирсәң хилт күб зәр,
Сәңа андин ничек соуд (файда), әй борадәр.

Ягъни, бер мөселман карындашыңа мең калита (янчык) алтын бирсәң, чынлыкта ул алтын харамнар белән катыштырылган булса, сиңа аннан файда да, савап та юк. *Халта* сүзенең әүвәлгесе бер нәрсә: киек аулаучыларның урманда йөрүчеләре бил бауларына күннән тегеп тагарлар, эчендә үзләренә мохтаҗ булган нәрсәләрне — ут ташы, күкерт һәм чакма тимере кебекне салырлар. Болгар йортында калитә диярләр. Әмма Сәмәрканд җәмилдә (гүзәл Сәмәркандта) ха (ха хәрефе) белән укыйлар. Һәм икенчесе *хәлгә* (катнаш) мәгънәсендә сүз, гарәпчә.

Әгәр бирсәң аригъдин катрәи аб (бер тамчы су),
Ирер чәндан саваб, әй гәүһәре наб (саф гәүһәрдәй зат).

Ягъни бер мөселман карындашка кечкенә елгадан (арыктан) бер тамчы микъдары су алып эчерсәң, синең йөз калитә харам алтынны биргәнеңнән изге булыр.

Кешегә бирсә кем малы хәрами,
Өмид итсә, саваб ул мәрде гали (олуг ир).

Ягъни берәүгә харам малны[1] садака итеп биреп, ул биргән садакасыннан савап өмет итсә, ул — залим була.

Булыр кяфер өмид иткән ул инсан,
Белеб алыб дога кылган һәм ул ан (чак).

Ягъни ул, хәрам малны садакага биреп, савап өмет иткән кеше дә, белеп алып дога кылган кеше дә — һәр икесе кяфер булырлар.

Хыянәтнең бере кем, булды мәүсуф,
Белеб кылмаса, һәр кем әмре мәгъруф.

1 К.да — алтынны (230 б.).

Ягъни хыянәтнең бер төрлесе шул булыр: берәү, галим булып, изге юлга бәндәләрне боермаса,

Вә гәр нәһи итмәсә (тыймаса) мөнкәр (ярамаган) эшне,
Хыянәтлек дигел андаг кешене.

Ягъни ул галим булган кеше шул явыз эшләрдән бәндәләрне тыймаса (туктатмаса), мондый галимне хыянәт әһеле дип бел. Моннан олуг хыянәт булмас.

Берәгү юл белмәен йөзләнсә чүлгә,
Белеб гәр салмасаң сән яхшы юлга.

Ягъни бер кеше юл белмичә ялгышларга барса, син, аның анда барганын белеп, юл өйрәтми торсаң, аннан теләк: берәү, галим булып, надан кешенең бозык юлга киткәнен белеп, яхшы эшләр кылырга әмер итеп һәм тыелган нәрсәләрдән туктатмаса,

Кайу инсаф ирер, кайсы дианәт
Ирер анда улуг бөхил-ү хыянәт?!

Ягъни андый юл белгән кеше юл күрсәтмәсә, бу нәрсә булыр?! Чөнки, әлбәттә, дин карындашы булса, ул гаҗизне тугры юлга өйрәтер иде. Киресенчә булса, олуг саранлык һәм хыянәтлек була.

Әгәр алдындагы тәгаме булса нагяһ,
Йанар утка төшәрен белсән агяһ.

Ягъни берәүнең күз алдында бер нарасый углан яна торган утка кергәнне күрде.

Озайтмас булса аңа дәсте әлтаф (игелек кулын),
Ничек булгай бөрадәрлекдә инсаф!?

Ягъни утка кергән нарасый угланга рәхим һәм шәфкать кулыңны сузып, ут яныннан алмасаң, моный кеше дин кардәше түгел. Шундый бер надан, белмичә, хәрам эшләргә керешсә, син, галим булып, ул наданны бозык юлыннан хәбәр бирмәсәң, моңнан олы хыянәт юк.

Җәмигъ бәндәи мөэмин сәрасәр (баштан ахырга),
Иредмез бер-беремезгә борадәр.

Ягъни чөнки барча мөселман җәмәгате бер-берсенә карындашлар. Карындаш булса, бер-берсенә шәфкать итү кирәк. Шәфкать шул булыр: галимнәргә гыйлемлегендә юмарт булып, белмәгәннәргә өйрәтү һәм байлар фәкыйрьләргә садака бирү.

Берәү чыкса, тарикы ахирәтдән,
Үгерсә (укыса?) йөз мәкам мәгърифәтдән.

Ягъни бер надан кеше, белмичә ахирәт юлыннан чыгып, бозык юлда йөрсә, төрле сәбәп белән Аллаһ Тәгаләдән гөнаһларыннан ярлыкану әдәбен белмәсә,

Әгәр күрсәтмәсә юл белгән инсан,
Бәхиллек мондан үтмәс, әй мөселман.

Ягъни ул наданга үзе белгән галим туры юлны күрсәтмәсә, саранлык һәм хыянәт була.

Сән әйган соңра төз булмаса хале,
Үзенең буенга калгай вәбале (гөнаһы).

Ягъни син, галим, ул наданга туры юлны күрсәткәннән соң, ул надан туры юлга кермәсә, гөнаһысы синдә калмады, бәлки үз муенында калды...

Ачыбдыр сән борадәрлекнең бабын (капкасын),
Табыбсән әмре мәгъруфнен савабын.

Ягъни син мөселман карындашларыңа кардәшлек ишеген ачсаң һәм бар кешегә дә билгеле итүнең савабын белсәң,

Әгәр килмәсә кулыңдин йә телеңдин,
Яман бел ул эшне җан-делеңдин.

Ягъни бозык эшне эшләгән кешене тыю кулыңнан, я телеңнән килмәсә, чөнки кул белән туктату мөфтиләргә



www.darul-kutub.com

һәм казыйларга тиеш. Андый булмасаң, телең белән тый. Бу мәртәбә галимнәргә бирелгән. Галим дә булмасаң, зинһар, ул бозык эшне күңел һәм җан белән дошман күр, аның мәҗлесендә утырма.

## Халыктан (кешеләрдән) рәнҗү һәм авырлыкка түзү бәяны

Кил, әй инсан, әгәр булсан чын ир дәк.
Агырлык, пишә кыл, дөньяда йир дәк,

Ягъни, әй адәм баласы, хакыйкатьтә Аллаһ юлында булучы бәндә булсаң, бу дөньяда җир кебек авыр сабырлы бул. Ник дисәң, җирнең өстендә төрле нәрсәләр бар: изгедән, явыздан, хәсистән һәм нәфистән — барчасын күтәреп тора. Шуның кебек син дә күтәр, адәмнәргә яхшы, күркәм бул.

Әгәр табса сәне һәр кайсы мәүҗид.
Зыян итмә, тәкый тикер соуд (файда).

Ягъни сине, мәсәлән, һәр җан иясе аяклары астына салып типкәләсәләр дә, һич нәрсәсенә зыян тидермә, бәлки кулыңнан килсә файда китер. Ник дисәң, җирнең өстендә барча халыклар тизәк һәм бәвел итәләр. Аларның кем нәрсә салганнарына хурланмыйча, җир аларга, төрле игеннәр һәм үләнләр үстереп, төрле нигъмәтләр бирә. Мин-минлек кылганга — яхшылык кыл.

Йөрәгең кылсалар аһән белән чак,
Чыкар алдыга төрлүк нигъмәте пакь.

Ягъни адәмнәр синең йөрәгеңне тимер белән ярсалар да, төрле җәфа кылсалар да, аларның каршыларына төрле нигъмәтләреңне бир, җәфалары өчен кинә тотма (үчләшмә).

Әгәрчә галәмә сәндин тигәр нәфгъ,
Үзеңдин кылгыл туфрак атын рәфгъ.

Ягъни син, мәсәлән, барча дөнья халкына файда китерсәң дә, үзеңнән туфрак исемен бетермә, тәкәбберлек кылма.

Атаң ирер сәнең[1] йир дәк кылк кыл,
Яманлык әйлагәнгә яхшылык кыл.

Ягъни синең исемең яки атаң Адәм туфрак торыр. Андый булса, җир кебек сабыр холык кыл, башка адәмнәр сиңа яманлык итсәләр, аларга изгелек ит, димәкдер.

Кеше таш орса башә (башыңа), әй хөҗәстә (бәхет иясе),
Көлеб бакгыл йөзигә мисле пәстә.

Ягъни берәү сиңа ачу белән башыңа таш орса, әй андый мөбарәк кеше, орган кешенең йөзенә әйләнеп көлеп кара. Чөнки чикләвекнең башына таш белән орырлар; ярылып көлгән кебек торыр, эчендәге төшен бирер. Син дә һәр җәфага ачык йөзең белән төрле нигъмәтләреңне бир, димәктер. *Хөҗәстә* хаи хәрефенең (хәрәкәле ха хәрефенең) заммәсе (о, ө не белдерүче тамга) белән мөбарәк мәгънәсендә була. *Пәстә* мәгънәсе чикләвекне белдерә...

Буйсындырмакга дел-тәнең булма, зинһар,
Өмид улдыр ки — хуш күргәй хәридар.

Ягъни адәмнәр синең башыңа таш органнарына күңелеңне суытма, зинһар, чөнки мондый сабырлык иясеннән булсаң, бәндәләрне сатып алучы Изи гыйзз-у җәлл хуш күреп, үзенә якын кылыр...

Аяк астига калдым диб димә вай,
Булыр чын касә күб тәбкү исә лай.

Ягъни, син бу кадәр хурлыкта калдым дип «вай» димә, чөнки чынаякны күп типкән һәм баскан балчыктан ясыйлар, шуңа да аның халык алдында бәһасе күп булды. Андый халыклардан күп җәфалар күрсәң дә, сабыр итсәң, халык алдында газиз булырсың. *Лай* балчык мәгънәсендә килә, төрекмән белән һинд халкының сөйләменнән (бу сүз татар телендә дә шул ук мәгънәдә иркен кулланыла).

---

1 К.да — атаң йирдер сәнең (231 б.).

## Хикәят. Чынаяк ясау бәяны

Әйтәләр: чынаяк ясаучылар чынаякны ак балчыктан ясыйлар, кырык көн чират белән ул балчыкны, үзбиз (известь) белән бергә кушып, аяк астына салып басалар, һич туктамаслар. Аннан соң корби (?) дигән даруның[1] суына салалар. Анда егерме көн микъдары ачып ята. Аннан чыгарып, ун көн дәвамында аяк астына салып басалар. Аннан чыгарып, үзбиз белән катнаштырып, корби суына гына салалар. Анда егерме көн кадәре тора. Аннан чыгарып, төрле савытлар ясыйлар, аннан соң ул савытларны ут эченә куялар. Ун көн буена ут эчендә яндыралар; яхшысы ут эчендә төзек була, яманы бозыла. Утның тәэсире, дәрәҗәсе баягы савытларны туфрак табигатеннән чыгарып, корби дигән дару табигатенә әвереллерә, саф була, эчендәге нәрсә тышыннан күренә.

Әгәр дошманга дуслык кылсаң изһар,
Башың ярган кешеләрне дисәң йар.

Ягъни дошманлык теләүчеләргә дуслык күрсәт, башыңны сугып яручыларны яр юлдаш дип бел, шулай, ачу тотучы булма.

Риза милкен тәмгин әйлагән нас,
Җәфа алмасы тиксә, катигъ алмас.

Ягъни Аллаһ Тәгаләнең ризалык милкендә урын алучы адәм күпме бәла һәм казалар алмас, тимер белән чапсалар да, адәмнәргә каты булмас. Кыскасы, ризалыкка ирешергә теләүчеләргә никадәр бәлаләр килсә дә, адәмнәргә каты сүз әйтмәс, бәлки ачык йөзе белән төрле нигъмәтләрне китерер. *Алмас* сүзенең әүвәлгесе бер мәшһүр тимернең исеме (хәзергечә алмаз), каты нәрсәләрне кисәр. Икенчесе фигъле нәфидер (инкарь фигыль) кагылмас мәгънәсендә кулланыла...

## Алмас тимеренең бәяны

Әйтәләр: алмас (алмаз) тимерен адәмнәр сәнәгать ясамаслар, бәлки Изи гыйззә вә җәлл (Аллаһ Тәгалә) үз кодрәте белән яралтты, гайре тимерләрне

1 С.-П.да — давәрнең (340 б.).

адәм уллары балчыктан кайнатып тимер итерләр. Кайберләре, балчыктан булган тимердән җиттеш мәртәбә кайнатып алмас итәрләр, дип тә әйтәләр. Бу сүз иң дөресе булыр, бәлки кайбер тауларда күптер. Гомумән алганда, Кытай һәм һиндекытай тауларында бар, Диарбәкер[1] йортында бар, Мәккә вә Мәдинә тауларында бар... Әйтәләр: бу тимернең һәм башка эри торган мәгъдәннәрнең, ягъни металларның пәйда булуы шуннан булыр: җир астында булучы юллар һәм газлар, төтеннәр томаланып, җирдән кузгатучылар[2] (тәэсир итүче көчләр) тапмасалар, үзләре күп булмыйча, җиргә кушылсалар, үз сыйфатларында төрле булсалар, җисемнең күплеге; төз һәм күк фараз[3] һәм нишатыр[4] кебек җирдәге матдәләр аннан булыр. Кайчан да кайчан газ, төтен белән пар бер-беренә катышып һәм ачы нәрсәнең берсенең табигате икенчесенә катышыр булса, алтын, көмеш һәм тимер кебек нәрсәләр аннан булыр. Әгәр дә ул ачы нәрсәнең икесе йә өчесе газ, төтен белән пар катышса, алмас тимере аннан булыр, боларда аңа хас сыйфат, үзенчәлек булыр. Әмма хәрәкәт үзенчәлеге, үсеш-үзгәреше кеше теләге белән була алмый. Бу хакта күп гаҗәпләр тасвирлана, акыл ияләре китапларында күп, тулып ята.

Әйтәләр: алмас тимере кара кургашны кисмәс, башка каты нәрсәләрне кисәр. Кисмәгәнлеге тәкәббер булуыннан диерләр, чөнки алмас «дөньяда мин үткенмен» дип мактанды, шуның өчен Аллаһ Тәгалә моны кисмәслек хәлгә дучар итте. Бу сүз нәфесе әмердә («тыштан») хак булса да, асылда ялган. Һәм кисмәгәнлегенең хикмәте шул булыр: чөнки кара кургашында пар, су күп, алмас табигатендә кислота күп. Кислота пардан гыйбарәттер, шуңа күрә кара кургашында су күп була, алмасда ут күп була, су утны басар.

Димәс асиб, аны халык орса асиб (асыб)
Вә йә михнәте җәбали (тавы) йитсә басыб.

---

1 Диарбәкер — хәзерге көньяк-көнчыгыш Төркиядәге шәһәр исеме. Мәгълүм булганча, анда Таҗеддин Ялчыгол берничә ел яшәп ала.
2 С.-П.да — мөхарекъла (341 б.) -кузгатучылар, тәэсир итүчеләр.
3 С.-П.да — парз (341 б.).
4 С.-П.да — нәүшадыр (341 б.).

Ягъни сабыр бәндәне халыклар таганга асып кыйнасалар да, орсалар да, ул бәла һәм каза килде, димәс. Ул бәндәне бәла-каза тагын-тагын басып ятса да, бәла һәм каза килде, димәс, Аллаһ биргәненә һәрчак риза булып, җәфа китерүчеләргә игелек, рәхмәт әйтер, кинә тотмас. *Асыб* сүзенең әүвәлгесе бәла һәм фетнә мәгънәсендә килә, фарсыча, икенчесе салып һәм асу мәгънәсендә була, төрки сүз...

Җәһаләт әһле кылмыш кинә дәркин,
Качан дәркин булыр кем булса дәркин.

Ягъни бу үч алучанлык тәхетендә утыручы кеше, әлбәттә, җәһиллек иясе булса кирәк, чөнки Аллаһтан максудына ирешүне теләгән кеше, әлбәттә, үч тотмас. *Дәркин* сүзенең әүвәлгесе тәхет мәгънәсендә килә, Сәмәрканд халкы белән Госмания халкының сөйләме. Икенчесе ике телдән ясалган, дәрек мәгънәсендә, гарәпчә; идракъ төшенү, аңлау мәгънәсендә була... Өченчесе кяфе гарәпчәнең (гарәп язуындагы кяф хәрефенең) кәсрә белән язылу очрагы, гарәп белән фарсы арасындагы уртак сөйләмнән алынган...

Әгәр разый исә мең зарбәи йәд,
Доганы һәргиз (һәрчак) аңа кылмагай бәд (начар).

Ягъни кешеләр Аллаһы ризалыгына ирешергә теләгән кешене мең тапкыр явызлык белән орсалар да, аларның органыннан зәхмәтләр җыйса да, әлбәттә, ул кыйналган кеше җәфаларга, кыйналуларга явыз дога кылмас, бәлки изгелектә тугрылык нияте белән дога кылыр.

Зрарга һәргиз разый булмас әкмәл,
Һидайәт берлә тәүфыйкын теләр, бел.

Ягъни җәфа күргән кешенең зарарына риза булмастыр камил адәм, бәлки аның тәүфигын теләп дога багышлар.

Сүнер кин гәрдендән халәте җәмалы,
Китәр гәрдии күк гәр диннең кәмалы.

Ягъни, әй газиз кеше, аңла, гыйльме[1] хәлдән булган мәртәбә иясе кинә тузаныннан beредер. Андый булса кинә тузанын күңелеңнән җибәр, кинә тотучы булма, әгәр син дә диндә камил булуны теләсәң. *Гәрд* сүзенең әүвәлгесе тузан мәгънәсендә килә һәм икенчесе ике телдән ясалган, гәр-әгәр мәгънәсендә кулланыла, дин мәгънәсе ачык...

## Хикәят. Пәйгәмбәр г-м төшенең бәяны

Ухуд тагында пәйгамбәр дешене,
Шәһид итде янә йитмеш кешене.

Ягъни Өхед сугышында пәйгамбәребезнең тешен кяферләр таш белән атып төшерделәр, ахырда ул сугышта җитмеш олуг сахабә шәһид китте. Хәмзә (Мөхәммәднең агасы) белән Габбас хәзрәтләре дә анда шәһит булдылар. Өхед сугышының кыйссасы данлыклы. Әмма Өхед бер тауның исеме. Хиҗаз җиренең Искәндәрия тарафында Мәккәдән дөя аягы белән туксан көнлек юл озынлыгы булыр.

Гаҗәб көн төшде мөэминләр башына,
Гомәр килде пәйгамбәрнең кашына.

Ягъни ул Өхед сугышында мөэминнәргә гаҗәп авырлык килде, чөнки ул сугышта кяферләр күп иде, мөэминләрне җиңделәр. Шул заманда хәзрәте Гомәр сәргаскәр (гаскәр башлыгы) иде. Гали хәзрәтләре өйдә юк иде. Гомәр, кяферләрне җиңә алмаганы сәбәпле, пәйгамбәремезнең янына килде. Болай дип әйтте:

Диде, еглаб: әйа солтане әбрар,
Дога кылгыл кырылсын ошбу көффар.

Ягъни Гомәр пәйгамбәребез янына килеп, елап: «Йа рәсүле Аллаһ, бу кяферләргә дога кыл, бер юлы кырылсыннар», — диде.

Вәләкин кыйлмады ул дәгъвәте бәд,
һидайәткә дога кылды Мөхәммәд.

Ягъни Мөхәммәд г-м явыз дога кылмады, бәлки һидаят

1 К.да — гыйльме (234 б.).

белән дога кылды: «Иләәһи бу кяферләргә ислам юлын риза кыл», — диде.

Ушал рузи ки, әнбуһ (күп) ирде көффар,  
Әбу Суфиян вә Халид ирде саләр.

Ягъни ул Өхед сугышында кяферләр күп иде. Әбү Суфиян белән Халид кяферләрнең башлыгы иде. Чөнки ул ике ир әле ул вакытта кяферләр иде. *Әнбуһ* күплек мәгънәсендә килә.

Иҗабәт булдылар пәйгамбәр догасы,  
Мөселман булдылар һәр икеләсе (икесе).

Ягъни шунда ук пәйгамбәрнең догасы кабул булды. Ул Халид белән Әбү Суфиян мөселман булдылар.

Ул ике ир белән күб әһле тогйан (бозыклык ияләре).  
Ухуд кяферләре булды мөселман.

Ягъни Халид белән Әбү Суфиян, Өхед кяферләре, буйсынып, берәм-берәм килеп мөселман булды барчасы.

Чу (кайчан) Халид алды диннең шәһден бәһр (балыннан өлеш),  
Мөселман булдылар илкендә мең шәһр.

Ягъни Халид хәзрәтләре исламның шөкереннән файда алды, ул ирнең кулында (илкендә) мең шәһәр халкы мөселман булдылар, дияре мәгърибнең (көнбатыш илләренең) шәһәрләре барчасы Халид җитәкчелегендә ислам таптылар.

Гыйрак илә Дәмәшкь вә Хәтаи Шам  
Әбү Суфиян илкендә табты ислам.

Ягъни Гыйрак шәһәрләре һәм Дәмәшкъ белән Хәтай шәһәрләре, Шам Әбу Суфиян кулында мөселман булдылар.

Мөхәммәд кем алды гыйльме хушдин,  
Мөйәссәр итмәде алтын-көмешдин.

Ягъни пәйгамбәр г-мнән гыйлемлекне телән алды, Өхед сугышында төшкән алтын-көмешне алмады, чөнки



www.darul-kutub.com

малга теләге булса иде, кяферләргә бәддога кылып һәлак итеп, алтынларын алыр иде. Нияте аның малда булмады, бәлки ислам нурын арттыру иде. Шул сәбәпле һидаят белән дога кылды.

Әгәр сән мәрде сахиб һиммәте сән,
Рәсүле Аллаһның хасс (якын) өммәте сән.

Ягъни син күп һиммәт иясе булсаң һәм дә пәйгамбәрнең хас өммәтләредәй булыйм дисәң,

Тотарсән җан илә фигъле нәбине,
Кылырсэн һәр мәхәлдә (урында) бируены.

Ягъни син, җан белән пәйгамбәр фигылен тотуны теләсәң, һәр урында пәйгамбәрнең барган юлын югалтма, аның юлы шул иде: явызлык кылганнарга изгелек кенә кылды. Син дә шул фигыльне тот, димәкдер.

## Хикәят. Хуҗа Бәһаэддин хәзрәтләренең[1] гавани (сакчыларга) юлыкканы

Бәһаилхак валидин таб мисбаһ,
Юлыкдылар гаванига бинагяһ (көтмәгәндә).

Ягъни Хуҗа Бәһаэддин хәзрәтләренең Аллаһ Тәгалә, каберен күркәм кылып, кыямәткә кадәр файда алырга ризалык биргән иде. Көннәрдән бер көн бер залимга юлыгып, аның берлә сүзгә килделәр. *Гаван* дип асылда шаһлар һәм бәкләр янында йөрүчеләрне әйтәләр. Безнең Болгар йортында куштан, диләр. Монда мотлак залим мәгънәсендә килә. Әйтәләр: Бәһаэддиннең хакыйкать (чын) исеме Мәһди иде, сәйдзадәләрдән (Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән) иде. Бохарада иде. Кәгъбәтуллаһка ике тапкыр җәяү барып тауваф кылды (әйләнеп йөрде; «гыйбадәт кылды»). Күп кәрамәтләре (могҗизалары) ачык билгеле булганы өчен Бәһаэддин дип куйдылар. Әйтәләр: Баһаэддиннең ана ягыннан нәселе Хозыр пәйгамбәр тәрбиячеләреннән[2] иде. Хәзрәте г-мгә ыруг (туган) иде.

---

1 Хуҗа Бәһаэддин Нәкышбәнди (Мөхәммәд бине Мөхәммәд әл-Бохари) (1389-1390 елда вафат булган) — Урта Азиядә яшәгән атаклы суфый. Ул Идел йортта бик билгеле була.

2 К.да — мамәләрендән (тәрбиячеләреннән) (235 б.).



www.darulkutub.com

Көннәрдән бер көнне безнең пәйгамбәребез Мигъраҗ төнендә гарешкә тикле күтәрелде. Анда күрде: җаннардан бер җан, җитмеш хөҗҗаби (пәрдә аша) үтеп, Аллаһ Тәгалә белән сердәш булып, тәмам гарш тирәсенә кунар иде. Пәйгамбәр г-м әйтте: «Йә Рабби, бу ни хәл? Син әйттең: синнән соң пәйгамбәр булмас, дидең. Бу ни гаҗәп җандыр, сезнең белән пәйгамбәрләр кебек сердәшлек итә?»

Раббының җавабы килде: «Йә Мөхәммәд, хәбәрдар бул, синнән соң биш йөз ел үткәч, бер вәли килер, аның исеме синең исемең кебек булыр, ләкаб (кушаматы) исеме Бәһаэддин булыр, — диде. — Синең өммәтләреңнән җитмеш кешегә оҗмах сөенчесе бирер, — диде. — Әмма аның исеме безнең бусагабызга ирешәдер». Пәйгамбәр г-м моны ишетеп, минем өммәтемнән мондый олылар бар икән дип сөенде. Ахырда Тәңре Тәгалә белән сердәш булганы өчен Бәһаэддинне имаме Раббани дияләр иде. Соңрак Раббының җавабы килде: «Йә Мөхәммәд, гарешнең икенче тирәсенә кара, — диде. — Күрдеңме, дүрт җан китаплар укып торалар, хәтта күзләрен китаплардан алмаслар, бер-бере белән бәхәсләшерләр»[1]. Пәйгамбәр г-м сорады: «Болар кемнәр?» Раббының җавабы килде: «Бу дүрт ир синең олуг галимнәреңнәндер. Берсе — Сабит углы Ногмандыр, Куфәдән (шәһәр исеме) чыгар, — диде. — Икенчесе — Имам Малик, Мәдинәдән чыгар, — диде. — Өченчесе — Имам Әхмәд Хәнбәл, Басрадан чыгар. — диде. — Дүртенчесе — Имам Шәфигъ Идрис улы булыр, хакыйкатьтә исеме Мөхәммәд, җәзирәи Шафигидан чыгар, — диде. — Бу дүрт кеше — өммәтеңнең чырагы булыр. Синнән соң бу дүрт кемшенең сүзенә карап, бәндәләрем миңа буйсынырлар», — диде. Пәйгамбәр г-м моны ишетеп сөенде.

Бәһаэддинне Мөхәммәд Нәкышбәнди диеп тә әйтәләр. Мәгънәсе: бизәк ясаучы һәм һөнәр күрсәтүче диелә. Көннәрдән бер көн Бәһаэддин хәзрәте бер бүрек текте. Теккән вакытта һәр энә санынча мәртәбәләп «Ләә иләһа иллалләһу Мөхәммәдүн — рәсүле Аллаһ»ны (Аллаһдан башка Иляһы юк, Мөхәммәд — аның илчесе дип) җитмеш тапкыр әйтә иде, шуннан соң бу бүрекне җиде елда тәмам кылды. Сүз бирде, кем дә кем бу бүрекне миннән сатып алыр булса, бәһасе шул булыр: җиде тәмугның

1 К.да — идәрләр (235 б.).

www.darul-kutub.com

иясе булса, шул алсын, диде. Үтенеч һәм ният шушы иде: бу бүрек белән җиде тәмугны сатып алырмын, мөэминнәрнең һичберсен бу тәмугка кертмәм, чөнки үз мөлкемдә үзем ихтыярлы булырым, дип мөэминләргә шәфкать күрсәтү өчен бу сүзне әйтте. Серләрне белүче падишаһ (Аллаһ) бер фәрештәне зәнки (негр) сурәтенә кертеп җибәрде: «Бар, Бәһаэддиннең бүреген сатып ал. Ул фәрештә килгәч эчкә керде, сәлам бирде, әйтте: «Йә Мөхәммәд, мин зәнгестан вилаятеннән килдем, бүрегем юк. Синдә сатлык бүрек юкмы?» — диде. Бәһаэддин: «Әйе, бар, ләкин бәһасы авыр», — диде. Зәнки әйтте: «Бәһасе нәрсә була?» — диде. Хуҗа әйтте: «Җиде тәмуг, синең милкеңдә булса, ал», — диде. Фәрештә әйтте: «Ул минем кулымда түгел», — диде. Чыгып китте. Хак җанәбенә мөнәҗәт әйтте. Хуҗаның әйткәнне сөйләде. Изи гыйззә вә җәлл (Аллаһ Тәгалә) әйтте: «Бар, алты тәмугны биреп алдым, диген, аннан артыкны бирмә, чөнки мин Бәһаэддиннең теләгән нәрсәсен беләм: мөэминнәргә шәфкать итү өчен җиде тәмугны сорый», — диде. Шуннан соң фәрештә хуҗа янына килде: «Бүрекне алты тәмугка алырмын», — диде. Хуҗа әйтте: «Арзан була», — диде. Фәрештә артык бирмәде. Ахыр Хуҗа бүрекне бирде, алты тәмугка хуҗа булды. Кыямәт көне җиткәч, Хуҗа алты тәмугка Мөхәммәд өммәтен кертмәс инде, чөнки үз милкендә үзенең көч-куәте бар. Ул хөрмәт иясенең киң бүрек тегүенең максаты шул булды: җиде тәмугка хуҗа булып, мөселманнарны саклап калу иде. Сүзен һәм кылган фигылен дөрес күреп, Мөхәммәд өммәтен кертмәс өчен, Аллаһ Тәгалә алты тәмугны аңа бирде. Каһәреннән имин булмасыннар өчен җиденче тәмугны бирмәде. Шуның өчен Нәкышбәнди дип аталды.

Әйтәләр: Хозыр пәйгамбәр бер көн Аллаһ Тәгаләгә мөнаҗәт әйтте: «Йә Рабби, Мөхәммәд өммәтеннән бер олы хөрмәтле кеше Бохарада бар. Әмер булырмы аңа барып күрешсәм?» — диде. Раббының җавабы килде: «Бар, Бохарада фәлән мунчада хәзер госел кылыр (юыныр)», — диде. Хозыр г-м шунда ук бер кара кол сурәтенә керде, кулына комган[1] алып, Бәһаэддин янына керде. Әйтте: «Әй Хуҗа, әмер булырмы сезләргә су салсам?» — диде. Бәһаэддин: «Яхшы булыр!» — диде. Чөнки Хуҗа Бәһаэддин

1 С.-П.да — әбрикъ (346 б.).

хәзрәтләренең Хозырны күргәне юк иде. Хуҗа әйтте: «Син кем соң?». Хозыр әйтте: «Мин бер кара колмын». Ахырда Хозыр г-м әйтте: «Йә Хуҗа, дөньяда Хозыр дигән кеше бармы?» — диде. Хужа әйтте: «Бардыр». Хозыр әйтте: «Йә Хуҗа, ул пәйгамбәрме йә вәлиме?» — диде. Хуҗа әйтте: «Әүвәл замандагы өммәтнең пәйгамбәре иде. Безнең өммәтнең олуг галимнәре кебектер, ләкин алардан мәртәбәсе аздыр». Хозыр г-м әйтте: «Йә Хуҗа, ничек безнең өммәтебезнең галимнәре кебек дисең? Ул Җәбраил г-м белән сөйләште, ә безнең галимнәребез андый түгел», — диде. Хуҗа әйтте: «Ул заманда, пәйгамбәребез заманында, Җәбраил күкдән җиргә иңәр иде. Чөнки пәйгамбәребез ахры заман рәсүле иде, инде дөньядан үтте, Җәбраилгә дә җир йөзенә иңү харам булды. Хозырга Җәбраил иңмәс, чөнки ул Хозыр г-м үлгән пәйгамбәрләр хөкемендә булды, гәрчә сурәттә терек булсалар да. Безнең галимнәребез Хозырдан артык булды, чөнки безнең галимнәребез көн дә Аллаһ Тәгаләнең каләменә (сүзенә, китабына) карап, Ходай Тәгаләнең үзе белән арадашчысыз сөйләшә», — диде. Хозыр әйтте: «Син Хозырдан да артык булдың», — диде. Хуҗа әйтте: «ИншАллаһ (Аллаһ боерса), хәзерге вакытта Хозырдан артык торырмын, әгәр Хозыр пәйгамбәр булса, без халыктан булсак, Хозыр пәйгамбәрлеге белән безнең башыбызга су салып хезмәт итмәс иде», — диде. Хозыр г-м, уфтанып, күзеннән юк булды. Аннан соң башка Хуҗага күренмәс булды, диләр.

Әйтәләр: бер көн Хуҗа Бәһаэддин хәзрәтләре мөридләреннән җитмеш кешегә оҗмах сөенчесен бирде. Бу мөридләр арасында бер галим бар иде, Хәзрәте Әхмәд бине Хәнбәлнең шәкертләреннән иде. Ул уйлана калды: «Пәйгамбәребездән соң һичбер кеше оҗмах сөенчесе бирергә лаек түгел», — диде. Ахырда Хуҗа әйтте: «Әй йаранлар, хәбәрдар булыгыз, сезнең арагызда җитмеш кеше оҗмахлык», — диде. Ихласлы йаранлар: «Хак», — диделәр. Аннан соң Хуҗа кул күтәреп дога кылды... Баягы галимнең күңеленә бу шик салды. Күңеленнән әйтте: «Хуҗа шәйтания булды, үзен пәйгамбәр дип үк мактады дип, ул галим мөрид бу мәҗлестән чыкты. Бер мөрид белән китаплар тикшерә башладылар. Ничә йөз хәдис китапларын

тикшерделәр. Имам Мөслим[1] һәм имам Бохариның[2] хезмәтләреннән бер сүзне, бер хәдисне күрделәр.

Мөрид әйтте: «Йә галим, хәбәрдар булыгыз, Хуҗабыз дога кылганын аңладыңмы?» — диде». «...Васыйл дигән ир шушы Бәһаэддин булса кирәктер», — диде. Галим, тәүбә итеп, Бәһаэддин хәзрәтләренә уникe ел хезмәтен багышлады, диләр[3].

Әйтәләр: Бәһаэддин әүлияны һичкем исә әүлия дип белмәде. Мәгәр өч төрле могҗизасы ачык билгеле булды. Аннан соң Хуҗахак дип исем куйдылар. Берсе шул булыр: бер заман гүзәл Сәмәркандтан өч кеше сәүдәгәр булып килделәр. Берсе ипи пешерүчелек кылды, берсе кибеттә утыра иде, берсе тукыма сату белән шөгыльләнә иде. Бер көн Хуҗа, экстазга чумган чакта, икмәкчегә каза килгәнен күрде. Икмәкче янына барды, әйтте: «Йә икмәкче, миңа Аллаһ өчен бер икмәк бир», — диде. Икмәкче бирмәде. Ахырда игътибар итте: каза икмәкчегә якын килде. Кабат барды, сорады, бирмәде. Өченче мәртәбә Хуҗа күп үтенечләр юллады. Соңра ярты икмәк бирде. Хуҗа икмәкне кулына алып һава йөзенә ташлады. Әйтте: «Йә залим икмәкче, бу икмәкне теләнеп алуым үзем өчен түгел, бәлки синең үзең өчен, һава йөзенә кара», — диде. Икмәкче карады, күрде, бер кара болыт кебек нәрсә белән икмәк сугышып тора. Кара болыт җир йөзенә иңәргә тели, икмәк иңдермәс өчен тырыша. Хуҗа пәйгамбәр г-м хәдисен укыды..., икмәкче яныннан китте. Икмәкче якасын ертып үкереп елады, барып, Хуҗага мөрид булды.

Икенче могҗизасы шул булды: әйтәләр, бу өч кеше бертуган иделәр. Икмәкчесе — кечерәкләре — Хуҗаның могҗизасын, барып, агаларына әйтте. Тукыма сатучы белән кибеттә утыручы киңәш итештеләр. Тукыма сатучы әйтте: «Мин үлек булыйм. Мине җеназага салып, Хуҗа янына илтегез. Әгәр миңа җеназа укыса, якасына ябышырсың, тере кешегә нәрсә кыласың, дип». Болар, берләшеп, тукыма сатучыны җеназага салып, Хуҗаның өе турысына китерделәр. Чакырдылар. Әйттеләр: «Йа Хуҗа, җеназага хәзер бул», — диделәр. Хуҗа чыкты, җеназаны үтәп бирде.

---

1 Имам Мөслим бине әл-Хәҗҗәҗ әл-Кушайри әл-Нәйсәбури (817-875) — атаклы хәдисче.

2 Мөхәммәд әл-Бохари (810-870) - ислам белгече, мәшһүр шәрехче. Аның "Әс-сәхих" җыентыгын (ул хәдисләр тупламыннан гыйбарәт) кайвакыт сөнниләр "Коръән"нән кала икенче китап дип тә йөртәләр. Әл-Бохариның кабере — Сәмәрканд янында. Бу изге урында 1997 елның маенда безгә дә булырга туры килде.

3 Ул галим белән булган бу эпизод 1847 елгы басмада 350 биттә бирелгән.

Кибетче килде, Хуҗаның якасына ябышты: «Тере кешегә нәрсә кыласың? Үзең газизлек дәгъвасын кылырсың», — диде. Хуҗа әйтте: «Әй күзем нуры, сабыр бул, җеназаны кара». Соңыннан җеназаны ачтылар: үлгән, сөякләре каткан. Кибетче Хуҗаның аягы астына төште, ялварды: «Йә Хуҗа, моның үлеме сезләрнең мөбарәк сулышыгыздан; зинһар, әфсүн укы, терелсен», — диде. Хуҗа дога кылды: үлек терелде. Барча Бохара халкы, күреп, Хуҗаның хак әүлия икәнен белделәр. «Хуҗаи-хак вәлидин», — диделәр.

Өченче мәшһүр могҗизасы шул иде. Бервакыт Бохарада дәрьяның суы аз булды. Ашлык, үсемлекләрне сугара алмадылар. Кыскасы, Бохарада ачлык җиде ел булды, хәтта бер уч бодай бер теллә (акча берәмлеге) булды. Гашыйклар гыйшыкны оныттылар. Бер көн Хуҗа бер бодай сатучысына килде. Әйтте: «Йә фәлән, миңа бер уч бодайны сат», — диде. Кибетче әйтте: «Акчаң бармы?» Хуҗа әйтте: «Акчам юк, әмма ашъяулык белән җиләнемне бирермен», — диде. Кибетче ашъяулык белән җиләнне алды, Хуҗа бер уч бодай алып өенә килде. Хуҗаның бер Әхмәр исемле диванасы бар иде. Әйтте: «Бар, Ристан урамында казык как», — диде. Дивана барды, казык какты. Хуҗа да барды. Аркан белән җебен муенымда бәйләп, икенче очын казыкка бәйлә», — диде. Дивана шулай кылды. Хуҗа өч бодайны аяк астына салды, диванага әйтте: «Син мине камчы белән ор!» — диде. Дивана камчы белән Хуҗаны ора башлады. Хуҗа йөгерә башлады. Ат белән ашлык бастырган кебек Хуҗа «Ләә иләһа иллаләһү» дип кычкырып әйтә иде. Хуҗаның мөбарәк аягы баскан урынга бодай түбә кебек булып, бодайны ишәйтеп чыгара, хәтта олы тау кебек булды. Дивана чакырып әйтте: «Йә Бохара халкы, килегез бодайдан җитәрлек кадәре алыгыз», — диде. Шуннан соң, барча Бохара халкы, килеп, бодайны алдылар, савытлары тулды. Ул көн шимбә көн иде. Чәршәмбе көн Бәһаэддин хәзрәтләре дөньядан үтте, җитмеш өч яшендә, тарихи һиҗринең җиде йөз туксан беренче елында иде.[1]

Бохарадан алты мил кадәре Тазтүбә дигән җирдә

---

1 Нәкышбәндинең үлгән елы (781) милади белән 1389/1390 га туры килә. "Рисаләи Газизә"нең 1847 елгы басмасында бу урында болай язылган: "Бәһаэддин хәзрәтләре дөньядан үтте. Алтмыш тугыз яшендә иде. Тарихы һиҗринең биш йөз алтмыш тугызынчы едында иде." (349 б.) Бу милади белән 1174 елга туры килә. Техник хата булса кирәк.

җирләделәр. Һәр чәршәмбе көн, кыямәт җиткәнгә кадәр, каберен зиярәт итәләр. Кылчыксыз бодай аннан калды, дип сөйлиләр. Әйтәләр: Хуҗаның олы могҗизасының берсе шул булыр, кыяматкә кадәр күренер: ике кечерәк ак кош, һәрвакытта кабере өстенә куныр, «хак-хак» дип чакырырлар, аның хак икәне шуннан беленер. Бу фасылның күп могҗизалары бар, барын язу мөмкин булмады. Кыскалык сәбәпле бәян булды. Хасс әһеленә күп файдалар бар.

Гаван[1] — бер сүз диде, бу мәрд — бер сүз,
Гаван куйды яманлигъ күбигә йөз.

Ягъни ул залим бер сүз, диде, ахырда Хуҗа бер сүз диде, ягъни икесе бер сүз хакында каршылык кылдылар. Кеше үз сүзен әйтте, Хуҗа үз сүзен әйтә иде. Әмма кеше Хуҗаның хак сүзен яманлы урамына куйды. Аннан морад: Хуҗаның сүзен «батыйл (ялган)», диде.

Йөзигә салды камчы мәрде гали,
Кызыл кан булды сөнбел дик сакали.

Ягъни ул кеше, ачуланып, Бәһаэддин хәзрәтләренең йөзенә камчы белән орды. Хуҗа хәзрәтләренең йөзен ярып, кан чыгып, сакаллары буенча агып, сөнбелдәй сакалы кызыл кан булды. *Сөнбел* бер үләннең исеме, һинди вилаятеннән килер, һәр төрле әдвияләргә (дәваларга; даруларга) салырлар. Сыйфаты кызларның чәч толымы кебек. Гашыйклар сөйгәннәренең толымын аңа охшатырлар.

Ушал канлы сакалын алды кулга,
Диде: Йарабби, моны сал яхшы юлга.

Ягъни, шул канлы сакалны кулга алып, Хуҗа хәзрәтләре әйтте: «Ул кешене, йә Рабби, изге юлга сал,» — дип хәерле дога кылды.
Газаб кылма аңа, кыйлгыл гыйнайәт,
Мөһим охрависен кыл кифайәт.

1 Гаван турында башланган бу хикәят алдарак өзелеп калган иде. Биредә шул дәвам ителә.

Ягъни Хуҗа хәзрәтләре елап әйтте: «Йә Рабби, бу бәндәгә ярдәм кыл, газап бирмә, дөнья һәм ахирәт теләкләрен бир», — диде.

Бу сүзне аңлады ул мәрде би пакь,
Орыб нәгъръә, якасын әйладе чак.

Ягъни ул гөнаһ иясе кеше Хуҗа хәзрәтләренең изге дога кылганын аңлады. Бер заманнан соң, чакырып елап[1], якасын ертып һушсыз булды.

Йөзене йиргә сөртеб, налә (аһ-зар) кылды,
Гөһәрләр (гәүһәрләр) күзләрендин җалә кылды[2] (агызды).

Ягъни ул гаван һушыннан акылын туплап: «Күрче безнең яман фигылебезне», — дип, калды эшенә уфтанып, Хуҗа хәзрәтләренең аягына йөзен сөртеп, үтенечләр яудырып, елап, күзләреннән гәүһәр кебек яшен кырау кебек агызды. *Җалә* дигәне җаи фарсыяның (фарсыдагы җ хәрефенең) фәтхә (а, ә не белдерүче тамга) белән; таң алдыннан төшкән кырау мәгънәсендә. Гарәпчә сакигъ (чык), диләр. Фарсыча җалә, төркичә кырау, диләр.

Алыб һиммәт гасасын керде юлга.
Кулын тапшырды ул һиммәте колга.

Ягъни, ул кеше затлылык таягын кулына алып, тугры юлга керде; кулын һиммәт иясе Бәһаэддин хәзрәтләренә тапшырды, ягъни аны юлбашчы, җитәкчесенә әйләндерде.

Хода ул бәндәгә кылды гыйнайәт,
Ничә көн үтмәен табды вилайәт.

Ягъни Ходай Тәгалә ул гаван бәндәгә ярдәм бирде: күп заман үтмичә әүлиялык дәрәҗәсен тапты, ягъни Аллаһдан[3] әүлия булды. Әйтәләр: ул кешенең исеме Сибгатулла иде. Хуҗа хәзрәтләренең олуг хәлифәләреннән булды. Кыйссадан өлешчә кайтып боерды ки:

---

1 С.-П.да — екылыб (351 б.).
2 К.да — Күзенең яшене чөн җалә кылды (239 б.).
3 К.да — вәлийеаллаһ (Аллаһның дусты) (239 б.).

Әна — холык вә әна — хилем, вә әна — халь,
Әна — дәүләт, әна — носрәт-у икъбаль.

Ягъни, әй газиз кеше, аңла ки, шул булыр — камил холыкларның холкы, шул —ярдәм, будыр —йомшаклык карусызлык, будыр — гыйльме халь әһленең хәле, будыр — дәүләт, будыр — яманлык эшләгәнгә яхшылык — шушы шәкелдә.

Әна — һиммәт, әна — холык, әна — вар[1] (лаеклы),
Әна — тәбәгъыйәт (буйсыну), солтане әбрар.

Ягъни шушы һиммәт әһеленең хәле, будыр — изгеләр падишаһы (солтане әбрар), пәйгамбәребезнең юлына ияручеләрнең хәле — шулдыр.

Яманларның эшедер — кинә тотмак,
Мөселманлык — яманлыкны онытмак.

Ягъни яман колларның эше — кинә (үч) саклау, мөселманлык исә — яманлыкны онытып, даими изгелек кылу.

Үзенең нәфсене ким әйладе кол,
Кылыр ничә җәфа күрсә тәхәммел (түзәр).

Ягъни үзен-үзе ким күручеләр, әлбәттә, нәфесен түбән һәм ким күреп, никадәр халыктан җәфа күрсәләр дә түзәрләр, Аллаһ ризалыгын эстәрләр, җир кебек сабыр холыклы булырлар.

Вәләкин бу тәхәммел әйлагән нас (кешеләр)
Хәмиятдә (саклануда) кирәкдер тигъе алмас.

Ягъни халыкларның җәфасына түзүче кеше[2], кирәксә, Аллаһ Тәгаләгә якын булу өчен, көнчелек белән халык җәфасын чыдам күтәрер.

Хәмият бабыны үткәрмәгәй мәрд,
Әгәр чәндикә ул эш булса бәргәрд.

---

1 К.да — кяр (240 б.).
2 К.да — кемсәнәләр (240 б.).

Ягъни, көнчелек бабын үткәрмичә, ул ир кеше һәрчак көнчелегендә булса; ә көнчелек исә шул булыр: Аллаһ ризалыгы өчен, халык җәфасын чыдам күтәреп, изге гамәлдә көнче булыр, ягъни минем ахирәт гамәлем кешеләрдән артык булсын дип, ул гамәлләрне эшләргә теләр, диелгән.

Хәмият кайсыдыр белсәң тәгыйан (ачык),
Нәзар әйлә китабе мөҗтәһиддан.

Ягъни көнчелек ни нәрсә икәнен белергә теләсәң, дини китаплар буенча билгеләмәләр чыгаручы китаплардан кара. Сорау: Әгәр Аллаһ Тәгаләне көнче, дидегез. Аның көнче булуы ничектер? Җавап шул булыр: гайрәтеннән теләк — әсәр (эз, билге, тамга, йогынты, тәэсир) булдыру. Әйтерләр: берәүгә караса — аннан морад күзенең әсәредер.

## Авторның мөридләренә (шәкертләренә) ялвару бәяны

Әйтәләр: Аллаһ рәхмәте белән автор, ул заманда мөридләрне тәрбия кыла иде. Аларга тәүбә аятен аңлата иде. Өчәр тапкыр аңлата иде. Моннан соң ул мөридләр үзләренә ныклык белән дога кылалар иде. Моннан соң зикерне аңлата иде. Моннан соң дини дөреслекне әйтә иде. Аннан соң җиде зикерне өйрәтә иде. Күп заман бу намаз нигезендә мөридләрне тәрбия итә иде. Бер көн мөридләр әйттеләр: «Шәехебез Аллайарның безне тәрбия кылуы авыр булды, безнең хәлебез көннән-көн түбән булды», — диделәр. Кыскасы, бу хәбәр авторга ишетелде. Бер көн Аллайар мөридләрен чакырып әйтте: «Әй дуслар, сездә тәвәккәллек бармы?» — диде. Мөридләр әйттеләр: «Бар», - дип. Аннан соң Аллаһйар өеннән бер кызган тимерне алып чыкты. «Әгәр сездә тәвәккәллек (Аллаһка тапшырылу) бөтен булса, бу кызган тимергә басыгыз», — диде. Мөридләр әйттеләр: «Йә вәлие вәли, дүрт элемент, (ягъни су, һава, җир, ут) аерым-аерым, бер-берсе белән дус түгелдер». Аннан соң Аллайар мөбарәк аягы белән тимер өстенә басты. «Әй йаранлар, хакыйкатьтә тәвәккәллек шушы була. Токымның хуҗасы, ягъни Аллаһ күңелендә ни булса, ул

нәрсә кылса, шул булыр!» — диде. Аннан соң мөридләренә бу шигырьләрне әйтеп мәҗлесеннән куды.

Борадәрләр, ки безгә кылдыгыз гаһед,
Алырмыз диб мәхәббәт җамыдин шәһед.

Ягъни, әй кардәшләр, элек безгә вәгъдә биреп, бездән бераз мәхәббәт шәрабеннән бер касә алырбыз дип, мөрид булган идегез.

Табылмас бәндә дә сез эстәгән халь,
Ачылмас гасыйдин сез әйган ишкял.

Ягъни, әй мөридләр, сез теләгән хәлләр без фәкыйрь Аллаһйардан табылмас; сез сораган мөшкел мәсьәләләр без гөнаһкярдән ачылмас.

Таләб кыйлмаң бу нәкысдан кәрамәт,
Көшүфат-ү мәкамәт-у галамәт.

Ягъни, әй мөридләр җәмәгате, аңлагыз, бу кимчелекле Аллайардан хөрмәт көтмәгез һәм кәшфү мәкамләрә (биредә суфыйчылык дәрәҗәләре күздә тотыла) һәм галамәтләр ирешүне бездән өмет итмәгез.

Беләә алмам нәһаи тәрбийәтдин,
Алыб ирдем элек нәфсә ниятдин.

Ягъни, әй йаранлар, аның хәтлене көтмәгез, чөнки мин тәрбия чиген һәм асылның нәрсә икәнен белмимен. Ул[1] тәрбия итүемә карагыз, ник дисәң, элек нәфесем өчен алып бардым.

Пәшиман мән элек алганларыма,
Тамгы наныйга кул салганларыма.

Ягъни мин, элек мөридләр алганыма һәм дә комсызлык итеп, кул салуыма үкенәмен, чөнки сезнең гомерегезне бушка уздырып торырмын димен.

1 С.-П.да — әүвәл (354 б.).

Барың имди, йаранлар, һәр кайәнә,
Йөргенләр бер мөкәммәл ир табанә[1].

Ягъни инде андый булса, әй йаранлар[2], барыгыз һәр тарафка, бездән сезгә рөхсәт, ләкин бер камил мөкәммәл иргә инанып, аны мөршид (юлбашчы) итеп, бер шәехнең[3] хезмәтенә йөрегез.

Коруг кул алганымдин дәразамән,
Газизен эстәгәнеңездин ризамән.

Ягъни моннан ул коры кул белән мөридләр кулын алганыма рәнҗермен һәм дә сезнең газизлек камиллек эзләгәнегез өчен ризамын.

Мәне диб калмаңыз үз караңыздин,
Ойатлигъ мән сезнең рөхсәреңездин.

Ягъни, мин фәкыйрьнең хезмәтендә булып, хәтеремне саклап, үз эшегездән калмагыз. Мин сезләргә рөхсәт бирдем: барыгыз, камил шәехне эзләгез, аңа кул бирегез, аннан файда таләп итегез. Бу көн сезгә тәрбия юк, бәлки элек укытып, тәрбиялим дип кулыгызны алганым өчен оятлымын. Назыйм (автор) әйтте, ягъни үзен кимләп, башкаларны олылап, нәфесен кимсетү өчен бу сүзләрне әйтте: «Ник дисәң, барча олыларның хәле шушындыйрак, Хак Тәгалә каршында дәрәҗәләре артсын өчен, шулай үзләрен кимсетеп күрсәтәләр, чөнки шулай боерылган. Бер кеше үзен ким дип белсә, Аллаһ каршында дәрәҗәсе олы булыр», — диде.

Бәхил әйлаң килеб киткәнеңезгә,
Йилеб[4] йөгереб өмид иткәнеңезгә.

Ягъни, әй иптәшләр, бездән сезгә рөхсәт, әмма үткән заманда безне газиз дип йөгереп, бездән изге рух өмет итеп, хезмәтебездә йөгергәнегез өчен бәхил-риза булыгыз, үзегезнең безгә төшкән йомышыгыз булмады, шуның өчен без оятлы булдык.

1 С.-П.да — тәйанә (354 б.).
2 К.да — мөридләр (241 б.).
3 С.-П.да — һәр шәех (354 б.).
4 К.да — белеб (241 б.).

Кичермәс булсаңыз мәндин, әй каум,
Минем халем ки мөшкилдер сабаи йәүм (таң җиле).

Ягъни, сез шәкертләр җәмәгате, бу йөгереп-килеп йөргәнегезне кичермәсәгез, минем хәлем начар булыр, һәр кичләрдә һәм көндезләрдә кайгыда, хәсрәттә мин дип әйтү була бу.

Табиб мәндин табиб[1] олуг кешене,
Тотың мөхкәм (нык) аның котлуг әшене.

Ягъни, әй мөридләр җәмәгате, минем каршымнан киткәннән соң табыгыз бер кыйммәтле бөек, олуг кешене һәм аның боерган әмерләренә ихлас тырышып тотыныгыз.

Кирәк мөршид дигән манәндә Гомман,
Мөбарәк батыйне пөр дөрр-мәрҗан.

Ягъни юлбашчы булган һәркем Гомман диңгезе (ул Гарәбстан янында) кебек кирәкле: аның мөбарәк күңеле энҗе-мәрҗән белән тулы була. Ник дисәң, Гомман диңгезенең эче тулы энҗе. Шуңа күрә мөршид булган һәркем сөйләм гыйлемендә һәм гыйльме хальдә камил булып, әхлагы мактаулы сыйфатка ия була, гомумән юмарт була, бәхил (саран) булмый.

Җәһаләт дәштедин кем килсә сусаб,
Аңа заһир суыдин булса сираб...

Ягъни юлбашчы дигән шул булыр; кайчан булса да берәү, наданлык сәхрасыннан сусап, белем алырга килсә, ул сусап килгән наданны, юлбашчы галим изгелек суы белән тукландыра. Кыскасы, камил юлбашчы шул: надан мөридләрне шиктән чыгару кадәре генә булса да, изгелек гыйлеменнән дә хәбәрле була...

Әгәр булса кеше кем талибдер,
Чумыб батыйнга чиббен илә әйлагәй пөр (гулы).

---

1 К.да — таныб (242 б.).

Ягъни бер кеше, энҗе эзләргә булса, эчкә үк чумып савытын тотырсын. Шуңа күрә юлбашчы булган кеше, күңеленә игътибар итеп, күңел савытын нур белән тотырсын, димәкдер. *Чиббин* (җиббин) зәнбил күңел савыты мәгънәсендә килә.

Димәк: табылмагай бу нйшаилек кәс,
Җәһан әйване киңдер, хали ирмәс.

Ягъни, әй мөридләр, мондый кеше җиһан сараенда юк дип әйтмәгез; чөнки җиһан сарае киң ул, анда бушлык булмас. Шул сәбәпле житәкчесез заман мәгънәсез буш булыр.

Табылмаганда моның, дик ләҗҗәи хасс,
Кани (кайда) ихласлы, һиммәтле[1] гаувас (водолаз).

Ягъни мондый сайланган шәех табылып торганда, кайда кыйммәтле дәрьяларга чумучы мөрид?!

Чумыб алгай илеккә (кулга) дөрр мәкъсуд
Вә гәр нә кул салыб качмак ничек суд.

Ягъни, ихласлы мөрид чумып, элек кулына теләгән энҗесен алыр, аннан соң гына үзен күрер[2], чөнки аерым бер шәехкә кул биреп, мәҗлесендә тормыйча качып китүендә файда юк. Андый булса, аның мәҗлесендә дәвамлы бул, аннан соң өлгереп камиллек табарсың.

Әгәр сез табсаңыз бер йахшы шаһны,
Хәбәрдар әйлаңез бу руйе сийаһны (кара йөзне).

Ягъни, әй мөридләр җәмәгате, бер яхшы падишаһны табып, аннан морад — бер камил житешкән галим юлбашчыны тапсагыз, зинһар, без Аллайар мескенне хәбәрдар итеп, ул кешенең мәҗлесендә булыгыз.

Кылаймән йөзен күңлем зыясы,
Кадәм (табаң асты) туфракны күзгә тутыясы (дәвасы).

---

1 К.да — Кани ихласы күб һиммәтле гаувас (242 б.).
2 С.-П.да — Андан соңра кәнду-үзене ким күреб (356 б.).



www.darul-kutub.com

Ягъни, мин фәкыйрь, ул газизнең йөзен күңелемнең нуры дип һәм аның мөбарәк аягы кайсы җиргә тисә, туфрагын күземә тидерермен.

Ни булгай сез борадәрләр пәйидин
Мәңа һәм бирсәләр вәхдәте мәйидин!?

Ягъни нинди гаҗәп була, сез карындашлар артыннан миңа ялгызлык, онытылу шәрабеннән бирсәләр, барча гөнаһ-гыйлләтләремә дару булыр иде.

## Авторның улына әйткән нәсыйхәтләре

Әйтәләр: Аллайарның улы Мөхәммәдсадыйк исемле, Бохарада туган иде. Егерме җиде яшендә асыл йорты — Сәмәркандка китте. Аллайар үзе Бохарада калды. Ун елдан Бәйтуллага («Аллаһ йортына»), хаҗ кылыр өчен ниятләп, безнең Болгар йортына[1] килеп, бераз Казан каласында да туктап ала. Ул заманда Болгарның бер камил суфыйсы бар иде, исемен Идрис Хафиз диерләр иде.

Аның белән туганлык җепләре (буыннары) бер имеш. Аннан соң Аллайар Суфый Болгар йортыннан Рум җиренә, Кече Азиягә барган, анда күп кәраматләре ачыклана (беленә). Аннан Искәндәрия шәһәренә килгән, анда дарелфәнадән дарелбәкайә (вакытлы йорттан мәңгелек йортка) китеп барган. Рәҗәб аеның егерме тугызынчы көне иде. Аллаһйарның ул заманда яше туксанга җиткән иде. Озын буйлы, куе (куй) күзле, җирән сакаллы, диялар. Сәмәркандка улы киткән заманда улына үгет-нәсыйхәт итеп биргән сүзләрен бәян итеп боерды ки:

Тәваллам улдыр, әй фәрзанәи фәрзәнд,
Нәгяһдарең сәнең улсын Ходавәнд.

Ягъни догам һәм нәсыйхәтләрем шул булыр: әй мөбарәк балам, сине һәр ике дөньяда саклаучы Ходаең булсын. *Тәваллам* бефәтхел- вау һәм тәшдидел-лям (вау хәрефенең фәтхесе һәм лям хәрефенең тәшдиде, ягъни икеләтелгәнлеге) бемәгъни-д-догаи вә-л-васыяти (..дога вә васыять мәгънәсендә...)

---

1 С.-П.да — душ (356 б.).

Күземнең рәушаны Садыйкмөхәммәд,
Ерак булсын күзеңдән дидәи бәд.

Ягъни, әй күземнең нуры Мөхәммәдсадыйк улым, Ходай Тәгалә сине явыз күзләр фетнәсеннән ерак кылсын.

Ишет мән хәстәдин берничә кауля (сүз),
Егетлеккә сәне тикерсә мәүля.

Ягъни, әй мөбарәк балам, мин авыру атаңнан бераз мондый үгет сүзләрен ишет. Ул үгет будыр: кайчан сине Аллаһ Тәгалә егет дәверенә җиткерсә,

Йаман йөрмә, йаман әндишә кылма,
Атаң дик русийаһлек пишә кылма.

Ягъни, әй балам Мөхәммәдсадыйк, чөнки син егетлеккә җитәсең, яман юлда йөрмә һәм яман фикерне уйлама, атаң Аллайар кеби кара йөзле (русийаһлек) булма, һөнәр өйрән.

Йаратkан Гәнригә кыйлгыл тәвәккел,
Тәмгъ кылма кешедин бер генә пул

Ягъни, әй улым, яраткан Ходайга тәвәккәл кыл, бер пул (акча) микъдары булса да, адәмнәрдән комсызланып; теләнеп йөрмә, кешедән өмет итмә.

Тәмгъ пәр парча булса, бирмәгел вай,
Булыр бер пәрдәдин йөз пәрр би җай[1].

Ягъни кешедән өмет итмә, чөнки бер кош канаты микъдары нәрсә өмет итсәң, йөз пәрдәңне күтәрер, оятсыз булырсың, димәктер. *Пәр* сүзенең әүвәлгесе кош канаты мәгънәсендә килә. Икенчесе — канат[2] (канәгать) мәгънәсендә. Өченчесе сәтрел-хәя (оят пәрдәсе) мәгънәсендә алынган.

Йөзеңдән пәрдә кем төшмәсен тәс,
Хәйадин гари йөзең гари булмас[3].

---

1 С.-П.да — Булыр пәрдә йөздин пәрдә би җай (357 б.).
2 К.да — кәнәгать (234 б.).
3 Бу бәйт һәм аңлатма С.-П.да күзгә ташланмый (358 б.).

Ягъни йөзеңнән оят пәрдәсе төшмәсен, чөнки оялып торудан синең намуслы йөзеңә хурлык килмәс. *Гари* сүзенең элеккесе ялангач һәм шәрә мәгънәсендә була. Икенчесе кабул итмәү һәм намус мәгънәсендә килә.

Гәмгъ (тамәгъ) берлә симергән нәфсе гаммаз (гайбәтче),
Әгәр агзын теләр булсаң, теләр баз (кабат).

Ягъни комсызлыктан хасыйл булган нигъмәт белән симергән гаепле нәфесең, әгәр ашаганнан артканын ярып һәм телеп эченә куйсаң да, барыбер сорар. Кыскасы, әмир нәфес («буйсындыручы нәфес») асылда бу дөнья нәрсәсеннән туймас... *Теләр* сүзенең элеккесе ярмак һәм шәкъ (яру) мәгънәсендә кулланыла. Икенчесе, сорау һәм мәсьәлә мәгънәсендә, һәр икесе төрки сүз.

Никабе шәрм ачылмаздин борынраг,
Аны бәрк әйлә һәр йакдин тыкыб йаг[1].

Ягъни оят пәрдәң (никабе шәрм) ачылмастан элегрәк, аны ныгыт, май (ягып) белән тыгып, һәр тарафтан, монда майның комсызлыктан камил саклаучы булуына киная итеп бирелә.

Канәгать кыл, мәламәт милке булма,
Атаң дик халык-илгә көлке булма.

Ягъни, әй балачыгым, канәгатьлек кыл, халык өстендә, аның милкен өмет итүче булма, бәлки үзең мөселманнарга файда китерүче бул, атаң Аллайар кебек халык арасында көлке булма.

Пәйгамбәрләр фигыледер — канәгать,
Аңа вабәстәдер (бәйледер) мәҗмугы тагать.

Ягъни ни дисәң дә канәгать булу — пәйгамбәрләр фигыле. Андый булсаң, Ходаең нәрсә бирсә, аңа канәгатьлек күрсәт, кыскасы, барча (мәҗмуг) буйсынулар (тәгатьләр) һәм гыйбадәтләреңне канәгатьлеккә багышла.

1 К.да — такыб бак (244 б.).



www.darul-kutub.com

Билеңне багла мөхкәм (нык), булма мәфлуҗ (паралич суккандай).
Күзең ач, кәрвани кылдылар күч.

Ягъни Ходайның хезмәтенә билеңне багла, гомереңне бозык урынларга сарыф итмә, гыйбадәтеңне шайтан уенына оттырма; чөнки күзең ачып кара: барча кәрван халкы күчтеләр (үлделәр). Сиңа да ул көн җитәр, андый булса, ул көнгә изге гамәлләрне хәзерлә. Гөнаһлар эшләп, шайтанны сөендермә...

Шәрарәт әһленең (явыз кешенең) пәйвәнде (иярчене) булма.
Һава берлә һәвәснең бәнди булма.

Ягъни, әй улым Мөхәммәдсадыйк, аңла, беркайчан да явызлар белән дуслашма, ягъни алар белән бергә утырма һәм ахыр чиктә нәфес-һәваларына ияреп, аларның карамагында булма.

Кечеклекдән гыйбадәткә буең куй,
Кыямәтнең уен кылсан, уен куй.

Ягъни, әй улым, кечкенә һәм яшьлек чагында гыйбадәткә буеңны куй, олыгайгач кылырым, димә. Чөнки бу ялган һәм буталу — шайтаннан, кыямәт турында фикер йөрткән кеше, әлбәттә, дөнья уенын куйса кирәк. *Уен* сүзенең әүвәлгесе фикерләү мәгънәсендә кулланыла. Икенчесе уйнау вә логбә! (уен) мәгънәсендә, һәр икесе төрки сүз.

Гаҗәб хушдыр егетлекдә булыб саг,
Бөгелмәкне куеб гамьдин бөгелмәк.

Ягъни моны аңла ки: әй улым Мөхәммәдсадыйк, бу егетлек чагында сау-сәламәт булып, дөнья хәсрәтен куеп, Аллаһдан куркып, ахирәт куркуыннан һәм аның кайгысыннан билеңне гыйбадәткә бөгү гаҗәп яхшы эш... *Бөгелмәк* бөгү сүзенең әүвәлгесе сәгыб (кирелек; тыңлаусызлык) мәгънәсендә килә...

Шәбабидә (яшьлектә) түксә һәр көн күздин аби[1],
Аны гайн дигел рәхмәт сәхаби.

Ягъни бер егет һәр көн, Аллаһдан куркып, күзеннән яшь чыгарса, андый егетнең күзе Аллаһның рәхмәт болыты дип бел, чөнки егетнең елавы бары тик Аллаһ өчен, кариларның (картларның) елавы гомерләре үткәннән; үлемнән куркып еларлар, тормыш дәвамыннан мәһрүм булырлар.

Рийә гәрдене йоктырма итәккә,
Атаң дик булма табигъ нәфсе сәккә (этқә).

Ягъни гамәл итәгенә рия тузанын (гәрдене) йоктырма, ягъни гамәлне рия белән кеше күрсен өчен эшләмә һәм дә атаң Аллаһйар кебек эт нәфескә иярүче булма.

Тәвазегъдин күтәрмә югары баш,
Тәкәббер кылмагыл чөн тохме хәшхәш (мәк орлыгы кебек).

Ягъни, мәк орлыгы кебек әлчаклыктан һәм түбәнчелектән башыңны күтәреп тәкәбберлек кылма.

## Мәк белән чикләвекнең бәяны

Әйтәләр: мәк белән чикләвек һәр икесе карындашлар дип. Борынгы заманда чикләвек белән мәк бер агачта үскән. Мәкнең кабыгы кара, ә чикләвек нәкъ хәзерге замандагы кебек булган, ләкин бер агачта булсалар да, мәк татлы икән. Көннәрдән бер көнне Гайсә г-м чикләвек агачлары төбендә утыра иде. Күңеленнән әйтте: «Йә Рабби, ярдәм бирсәңче, бу агачның җимешен җыяр идем», — дип кулын сузды, янә кире алды. Бу агач адәмнәр хакы булмасын дип, Җәбраилне көтте. Ул арада чикләвек белән мәк сүзгә килделәр. Мәк әйтте: «Рухе Аллаһ (ягъни Гайсә пәйгамбәр) мине җыяр, — диде, — чөнки мин синнән ләззәтле, татлыракмын», — дип, үзен артык дип белеп, тәкәбберлек күрсәтте, агачтан коелды.

1 К.да — Шәбаби түксә күздин һәр шәб аны (244 б.).

Әлкыйсса, бераздан соң Җәбраил килде, әйтте: «Йә Гайсә — Рухе Аллаһ, бу агачлар адәмнәр хакы түгел, сиңа рөхсәт, җый», — диде. Моннан соң Гайсә г-м элек кулын җиргә коелган мәк җимешенә сузды. Раббысы: «Син элек чикләвек агачына сузыл, — диде. — Чөнки ул үзен ким күрде, мәк тәкәбберләнде. Шуның өчен мәкнең сурәтен үзгәрттем, асылда аны сабан астында яткырып, аннан үстереп, урак белән урырлар, ничәмә төрле мәшәкатьләргә дучар иттем», — дип җавап килде. Җавап килде, мәкнең сурәте шул заманда үзгәрде. Әйтәләр: тәкәбберлеге өчен. Бу хикәят Бохараның әфзальләреннән (фазыйлларыннан, ягъни белемлеләреннән) ишетелгән иде...

* * *

Тәкәббер хатыйреңә килсә, филхаль (шунда ук)
Газазил кыйссасын ядыңа ал.

Ягъни син күрерсең: Иблис тәкәбберлек белән Газазил исеменнән аерылып, мәлгунь исеменә лаек булды (алды); кайбер хикәятләрдә мәшһүр (халыкка билгеле, атаклы). Андый булса, аны фикерләп, тәкәбберлектән саклан.

Күземнең мәнзилен кыл гүшәи фәкыйрь,
Кыямәт зады кылгыл түшәи фәкыйрь.

Ягъни күңел урынын (мәнзилен) фәкыйрьлек почмагына (түшәи фәкыйрь) әйләндер. Кыскасы, фәкыйрьлек белән сыйфатланган бул. Асыл кыямәт азыгын фәкыйрьлек белән таләп ит.

Җәһанның хирсыдин кылгыл үзең дур (ерак),
Атаң дик булмагыл дөньяга мәгърур.

Ягъни, әй улым Мөхәммәдсадыйк, дөньяга хирыс булма, комсызлыктан ерак бул, атаң кебек дөньяга алдатучы булма.

Өмид иткән күземнең нуры балам,
Атаң дик булмагыл рисваи галәм.

www.darul-kutub.com

Ягъни, әй күземнең нуры балачыгым, атаң кебек дөньяда рисвай булма.

Әгәр чәндикә (шулай) булсаң кул канагликъ,
Хода дәргяһида бул мескен аглигъ[1].

Ягъни, әй улым син, кул һәм канатларың күп булса да, аларга алданма, бәлки Ходай катында түбәнчелек һәм мескенлектә бул.

Ыруглык мән димә, танда ыруг («җәза») бар,
Хисабнамә вә вәзен, соруг бар.

Ягъни, әй улым, минем нәсел-нәсәбемдә күп баһадирлар һәм яхшылар дип, син масайма, чөнки болар Хакъ Тәгалә каршында синең өчен җавап бирмәсләр, бәлки үзеңнең Аллаһ хозурына барып хисап бирен, гамәлләрең үлчәнүе турында фикер йөрт, ягъни ул көннәрне хисап итеп, изге гамәл кылырга тырыш, димәктер. *Ыруг* сүзенең элеккесе кабилә мәгънәсендәге сүз...

Үзеңне әйлә хуб булган сари күб[2],
Ничә мән күб дигәнләр булды мәнкүб.

Ягъни, әй улым, изге булган саен түбәнчелектә бул. Күрмисеңме: дөньяда ничә адәмнәр, эреләнеп, тәкәбберлек белән йөзтүбән киттеләр. *Күб* сүзенең элеккесе түбәнчелек мәгънәсендә килә, икенчесе кәсир (күп) мәгънәсендә була. *Мәнкүб* йөзтүбән булу мәгънәсендә кулланыла.

Булыб хуш[3] тәбарең (чыгышың) берлә мәгърур,
Димә мән «зур», әгәр дин булса мәнзур (игътибарда).

Ягъни, әй улым, әгәр синдә дин игътибары булса, кардәшләрнең күплегенә алданып, «мин — олымын» димә. *Мәнзур* сүзенең элеккесе олуглык мәгънәсендә килә, икенчесе карау һәм игътибар итү мәгънәсендә була.

1 К.да — мәскәнәтлик (урнашкан) (245 б.).
2 К.да — Үзеңне әйлә күб булгай сари хуб (245 б.).
3 К.да — хиш (үзең) (246 б.).

Бу дөньяда әгәр үтсәң коруг ләб (авыз, ирен),
Күңелгә салма һаргиз йаде мәнсаб.

Ягъни, әй улым, бу дөньядан гамәлсез коры үтсәң, ахирәттә дәрәҗәле булырмын дип, күңелеңә китермә, чөнки ахирәт дәрәҗәсе адәмнәрнең гамәлләре кадәренчә булыр.

Утәр дөньяда һәркем булса диилик.
Белер мәнсабдин артык хушә (башак) чинлик.

Ягъни, әй улым, аңла ки, дин тотучы кеше иман белән китсә, андый адәм ахирәт йортына баргач, андагы дәрәҗәнең дөнья мәртәбәсеннән артык икәнен белер, чөнки дөнья мәртәбәсенең мисалы башак җыйнау кебек. Кыскасы, дөнья мәртәбәсе ахирәт мәртәбәсе янында түбән.

Гаҗәб афәт ирер җаһ-шәрафәт[1],
Шәрафәтне белә күрмә шәрафәт.

Ягъни фетнә йөзеннән дөньяда гомер кичергән заманда мәртәбәгә менү һәм Зирәк исемен күтәрү гаҗәп булыр. Аңа алдану изге теләгеңнән коры калдырыр. Һәм андый булса, бу нәрсәләр белән «мин артык булам» димә, бәлки фетнә дип бел. *Шәрафәт* сүзенең элеккесе кушма сүз, *шәр* — явыз, *афәт* фетнә мәгънәсендә килә. Икенчесе бер генә сүз — артыклык мәгънәсендә була.

Белеб дөнья мәкамен гайре мәгъмур,
Булыр Зирәк вә зирәк атыдиндур.

Ягъни дөнья урыны (мәкаме) төзек түгел (гайре мәгъмур) дип белгән кеше, әлбәттә, дөнья зирәклегеннән һәм Зирәк исеменнән ерак булыр.

Күтәрсәң башка артык булма артук,
Булыр мәгълүм, саба өрсә, өрсә.мәлик туг.

---

1 С.-П.да — зарафәт (362 б.).

Ягъни, әй улым, башыңа олуг мәртәбәле исемнәрне күтәрсәң дә, «мән олуг» дип дәгъва кылма һәм тәкәбберлек күрсәтмә, чөнки кыямәт таңында барча мәликлегеңнән (патшалыгыңнан) тук булырсың, аларны күзең белән күрәсең килмәс, барчасыннан качарсың.

Ходадан һәр нә килсә әйлагел сабыр,
Атаң дик кылмагыл үз нәфсеңә җәбер[1].

Ягъни, әй улым, Ходадан нәрсә генә килсә дә, барчасына сабырлык кыл һәм риза бул. Атаң кебек үз нәфесенә үзе көч китерүче булма.

Ходаның әмригә кыйлгыл итагать,
Зийадә ит тагатең сәгать бесәгать.

Ягъни, әй улым, Аллаһ әмерләренә буйсын һәм дә сәгатьтән сәгатькә гыйбадәтеңне арттыр.

Мәхәббәт футасын багла билгә,
Атаң дик гомереңне үткәрмә йилгә.

Ягъни, әй улым, теләккә омтылу путасын (билбавын) билгә бәйлә, атаң кебек газиз гомереңне бушка үткәрмә.

Һәвәсе дөньяга кылма мөхтәрәмлек,
Вәли бул халеңә лаек кермәлек.

Ягъни, әй хөрмәтле улым, дөнья зәвыкларына кызыкма, алданма, даими юмартлык кыл, ләкин хәлеңчә генә, хәлеңнән тыш булмасын.

Әгәр көч табсаң бер парчәи нан,
Йийма ялгыз, йарымын кылгыл ихсан (бүләк).

Ягъни, әй улым, әгәр син ач көндә бер кисәк икмәк тапсаң да, аны ялгыз ашама, бәлки яртысыннан мескеннәргә өлеш чыгар.

1 С.-П.да — Атаң дәк булмагыл нәфсеңә җәбер (362 б.).

Китәр булса һәркем җан тәнгә[1],
Йиймәс тәнгә гамен бу нәфсе ләнгә.

Ягъни һәркем тарлыкка китүен белсә, аннан морад — кабергә барасын белсә, бу аксак һәм зәгыйфь нәфесе өчен бу дөнья фәкыйрьлеге аның кайгысы булмас, бәлки ахирәт тарлыгының кайгысы аны борчыр, ягъни изге гамәл кылыр, юмартлык кылыр. *Тәнгә* (тәңгә) сүзенең беренчесе кысынкылык һәм мәшәкать мәгънәсендә килә. Икенчесе фәкыйрьлек мәгънәсендә була, яки акча (тәңкә) мәгънәсендәге сүз.

Җәһан миһрен күңелдин әйлә заил,
Атаң дик булмагыл дөньяга маил.

Ягъни, әй улым, күңелеңнән дөньяга мәхәббәт тотма, атаң кебек дөньяга кызыгучы булма.

Эшеңне әйлагел көн көндин әкъваи (көчле),
Ходаның сүгәнедер әһле тәкъваи (изге).

Ягъни, әй улым, гамәл эшеңне көннән көн куәтле кыл, арттыр, чөнки Аллаһның сөйгән бәндәләре тәкъвалар, ягъни гөнаһыдан сакланган кешеләр булыр.

Әгәр тәкъва эшен кылсаң ба ихлас
Дигәй, шайәд, сәне Хәкъ бәндәи хасс.

Ягъни әгәр син тәкъвалык эшен ихласың белән тотсаң, шаять, Аллаһ Тәгалә сине хасс (якын) бәндәм дияр.

Әгәр булсын дисәң җан вә делең җәмгъ,
Вәрәгъ (тыелу) аен бүлеб, гыйлем аен ит шәмгъ.

Ягъни, әй улым, начарлыктан сакланучы холкың белән син чын күңелеңнән җаныңны бер итәргә теләсәң, гыйлемлелек өйрәнүгә ябыш...

Әгәр гыйлем, гамәл бер булса рәнги,
Бу аинәи (көзге) китәр аинә зәнги[2].

---

1 К.да — Китәрне белсә һәркем җан тәнгә (247 б.).
2 К.да — Бу аинә(м)лә китәр аинәи зәнги (247 б.).



www.darul-kutub.com

Ягъни гыйлемлек белән гамәл икесе бер төстә булсалар, бу гыйлемлелек көзгесе булыр. Кыскасы, гыйлемлелек белән гамәл булган кешедән катылык китәр.

Әгәр табсаң Хода дәргяһидә карб,
Мәхәббәт касәсендән бирсәләр шәрб (шәрап).

Ягъни, улым Мөхәммәдсадыйк, әгәр син Аллаһ бусагасында якынлык тапсаң һәм ахырда мәхәббәт ширбәтен бирсәләр...

Сәхәрләр куб, күтәр дәст (кул) доганы,
Теләә моңлуг ата берлә ананы.

Ягъни, әй улым, андый мәртәбәгә ирешсәң, сәхәрләрдә (иртәләрдә) кубып торып, дога кылып, моңлы атаң белән анаңа да Аллаһдан телә...

## Сүзне кыска кылып, китапны тәмамлау бәяны

Кил Аллайар, сүзеңне кутаһ (кыска) кылгыл,
Билеңне багла газмераһ кылгыл.

Ягъни кил, Аллайар, сүзеңне кыска кыл, тәвәккәллек путасын биленә багла, Аллаһ юлыннан баруны ниятлә.

Карасаңдыр сәнең аслың кара сәнг,
Биребсән рия каны белән рәнг (төс; буялу).

Ягъни, әй Аллайар, синең асылың кара таш, әгәр гыйбрәт күзең белән карасаң; асылда гамәлләреңә карасаң, рия каны белән буялган. Кыскасы, риялык белән гамәлләр кылынган, димәктер. *Карасаң* сүзенең әүвәлгесе ялгыз, карау һәм нәзар (караш) мәгънәсендә килә. Икенчесе (кара сәнг) мөрәккәб (кушма сүз), кара, бемәгъни-с-сәвад (кара мәгънәсендә), төрки сүз; *сәнг* бемәгънк-л-хәҗәр (таш мәгънәсендә). Ләкин монда тәшбиhе бәлигь (образлы, охшату) бар...

Үлем туфаны бу серне кылыб фаш,
Әгәрчә эч булмаса, суд әйламәс таш (тыш).

Ягъни әҗәл туфаны бу сүзне билгеле итте. Әгәр синең калбең пакь булмаса, күренеп торган әгъзаңны төзәтүдән файда юк.

Кариб җисмең, кариб булсаң һәвәскә
Ничек шәрмәндәлек төсле кәскә (кешегә).

Ягъни тәнең карт булып, карт чагыңда нәфес-һәваларыңа ачыклык кылсаң, синең кебек кешегә оят түгелме?! Кыскасы, ак сакаллы вакытыңда, Ходадан курыкмыйча, нәфес артыннан йөрсәң, оялы булырсың, димәктер. *Кариб* сүзенең әүвәлгесе картаю һәм шәех булу мәгънәсендә була. Һәм икенчесе якыйн (ачык) булу мәгънәсендә килә.

Акарды сач, нәдамәт (үкенү) әшкене сач,
Йакаң ушлаб, дәһан (авыз) мәгъзур өчен ач.

Ягъни, әй Аллайар, чәчең һәм сакалың агарды, хәзер, үкенеп, күз яшеңне чәч, ягъни ела, якаңны тотып, гөнаһлардан үкенеп, авызыңны гозерлек (үтенеч) өчен ач. *Сач* сүзенең әүвәлгесе түк һәм шәгър (чәч) мәгънәсендә килә.Һәм икенчесе коймак һәм саббун (түгү; сибү) мәгънәсендә була.

Йалың акы әсәр кылмады халә,
Бакыб һәр дәм ояла күр, у(л) йалә.

Ягъни, әй Аллайар, чәчеңнең аклыгы Алладан куркудан булмады. Хәл аңдый булса, аклыгыңнан оялып йөр. Ягъни Аллаһдан оялып, гөнаһыдан саклан, димәктер. *Йал* сүзенең әүвәлгесе асылда ат ялына исем бирде. Әмма монда мотлак чәч һәм сакал мәгънәсендә була. Икенчесе хәйа (оялу) мәгънәсендә килә. Өченчесе — ат ялының исеме, монда — сакал мәгънәсендә килә.

Һәва берлә төзек эш кылмадың һич,
Булыбдыр кич һәвәс базарындин кич.

Ягъни, әй Аллайар, нәфесең һавалы, масаючан, төзек гамәлләр кылмадың. Андый булса, гомереңнең көне кич булды, ягъни карт булдың, нәфесе-һаваларыңнан кич, димәктер.

*Кич* сүзенең әүвәлгесе ләйлә (төн) мәгънәсендә килә. Һәм икенчесе куй һәм тәрк (ташлау) мәгънәсендә була.

Сәңа әйде ушал мәрди көһие сал,
Әгәр каль әһлидә (сөйләүчедә) табылмаса халь.

Ягъни, әй Аллайар, сиңа өлкән яшьтәге карт Шәех Хәбибулла болай дип теләк теләгән һәм әйткән: әгәр гыйльме каль әһлендән гыйльме халь булмаса,

Гамәл кем әйләгәй үзенең кале (сүзе) берлән[1].
Калыр гыйззәт вә хөрмәт илә берлән.

Ягъни ачык гыйлем әһеле үзенең күңеле белән уйлап гамәл кылган, халыкларның (кешеләрнең) гыйззәтенә вә хөрмәтенә алданып, тәләп базарыннан коры калган.

Булыр артык һәвәс берлә һәвасы,
Ирер халь ошбу гыйлләтнең (чирнең) дәвасы.

Ягъни, ул каль гыйлеме белүче халыкларның хөрмәтенә алданып, күңеленә тәкәбберлекләр тутырып, һәвәсләнеп нәфесе һавасын арттырыр. Шулай булгач, әй газиз кеше, аңла, гыйльме хәл дигәннәре шушы әйткән зәхмәтләрнең даруы булыр. Җыйнап әйткәндә, гыйльме хәл булмаган галим шайтан коткысыннан азат булмас, никадәр аскетлыкта булса да.

Каләм кыйлдың, кара күңлеңне кыл ак,
Ушал ирнең сүзен хилка (алка) кылыб так.

Ягьни, әй Аллайар, каләм кулыңа алдың, ялгызың бер каләм тоту ахирәт өчен тырышлык түгел, бәлки язган каләмең белән гамәл кылып, каралган күңелеңне акка әйлән һәм нәрсә сиңа югарыда картайган шәех әйтеп бирде, аның сүзен колагыңа алка кебек так, чөнки нәсыйхәт итү ансат, кабул итү авыр булыр.

Үзең кылмай күңелне ихтыяри,
Нә булгай, — калса мәндин ядкяри.

---

1 С.-П.да — Гамәл кылмай үзенең кале берлән (365 б.).

Ягъни, әй Аллайар, син олылар һәм яшьләр күңеленә ихтыяр бирмичә үтен. Боларны «Мәсләкел-мөттәкыйн» («Изгеләрнең мәсләге») дигән китапта яза башла дип әйттеләр: «Йә Аллайар, үтенечебезне кабул ит һәм дә синнән кыямәт көненә дигән (кадәр) ядкяр һәм мирас калыр», — диделәр[1].

Бөтебдер (язып) сән фарсы теледин китаби,
Тәмам анда мәсаилнең бәяни.

Ягъни, әй Аллайар, ул олыларның сүзләре таләбенчә, бер фарсы китабы язып, шушы «Сөбател-гаҗизин» кебек һәм аны «Мәсләкел-мөттәкыйн» дип исем куеп, син ул китапта барча дини мәсьәләләрнең җавабын яздың.

Һәммә фәтва вә тәкъваның җавабы,
Ун мәндин артык бәйте аны(ң).

Ягъни ул «Мәсләкел-мөттәкыйн» китабында барча динне аңлатучыларның һәм изгеләрнең җавабын язгансың. Ул китап гыйльмел-фикъһе (юриспруденция) мәсьәләләренә багышланган. Кирәгенчә бу «Сөбател-гаҗизин»дә аннан артык озын сүзләргә урын бирдең, чөнки «Мәсләкел-мөттәкыйн» эчендә уникe мең мәсаиле фикъһене (юриспруденция мәсьәләләрен) яздың, диннең кирәкле мәсьәләләрен аннан карап белерләр.

Диден: шәйи кәлиле төрки теледин,
Кич имди, әлбәттә, бу кал-у кыйлдин.

Ягъни, әй Аллайар, элек бераз мондый мәсаиле тәсаувыф (суфыйчылык мәсьәләләре) һәм тәүхидне (иман китерү турында) әйтеп бирдең. «Мәсләкел-мөтгәкыйн»китабы эченә һәм башка күп мәсьәләләрне бу «Сөбател-гаҗизин» эченә яздың, вәгъдәндә сабит (нык) булып калдың. Чөнки барча риваятьләрне язу сиңа мөмкин түгел.

---

1 Үзең кылмай...” дип башланган бу бәеттән һәм аңа шәрехтән алда Казан басмасында мондый юллар бар:

Үзең кылмай, күңел базарыны тый,
Кешегә сүзләмәк тә чәнд таки.

Ягъни сән үзең гыйбадәткә һәвәсне чолгамаенча, кешегә боның фискы (зарары) нә микъдарда дийү сүзләмә (248б.).

Әгәрчә яхшы сүз — каңду-шәкәрдер,
Хатасыдин вәли хәүф хәтардер.

Ягъни, әй Аллайар, әгәр яхшы сүзләрең шикәр кебек ләззәтле булса да, хаталы булуыннан курык.

Хатасы булмагай әйган (әйткән) сүзеңне,
Тәзаррегъ хакига сөртел йөзеңне.

Ягъни, әй Аллайар, язганың «Сөбәтел-гаҗизин» китабының хатасы булса, Аллаһтан гафу теләп, туфракка йөзеңне терәп зарыйлык кыл. Чөнки бәндәләрнең эше зарлану...

Ходага зарый кылгыл иртә вә шам (кич),
Эшеңне пөхтә кылгыл калмагай хам.

Ягъни андый булса, әй Аллайар, Ходага иртә һәм кичен зарыйлык әйт һәм дә гамәл-эшеңне пешер, чи калмасын. Рия, көнчелек һәм дә бозык әхлаклар бар, алардан биз, котылып, алар урынына яхшы әхлакый сыйфатларны үстер.

Хиҗабе мәгъфирәт йа бәкаи хатага,
Сәзавар (лаеклы) әйлагәй төрлүк гатага (бүләккә).

Ягъни, Аллаһ Тәгаләгә зарлану сәбәпле, хаталар урынына ярлыкану пәрдәсен (хиҗабе мәгъфирәт) ябып, рәхмәте белән төрле-төрле ярлыкауларына лаек итәр. Автор ... хиҗабе мәгъфирәт диеп китабын тәмамлады. Анда суфыйчылык серләре бар. Шуның өчен бу язмам матур сүз белән бетерүне теләп итте[1].

1 К.да текст шушы урында тәгәлләнә (249б.) 250-252 битләрдә "Эчтәлек" яки бүлек һәм бүлекчәләр исеме бирелгән. Ахырда, ягъни 252 битнең соңында мондый юллар бар: "Шарих (шәрехче - бу очракта Таҗеддин Ялчыгол) 173 нче сәхифәдә ялгыш җибәргән. Әхмәд бине Хәнбәл белән Разия кыйссасында. Чөнки Разияның соравы Бәшир Хафиянең вафатыннан соң булуы бәеттән аңлашыладыр. Имам Әхмәд 241 нче елда вафат, Бәшир хәзрәт 260 елда вафат. Шулай булгач, имам Әхмәд Бәширдән 21 ел элек вафат булса кирәк. Шарихнең тәрҗемәсе (тормыш юлы) Таҗеддин бине Ялчыгол әл-Башгари 1253 ел (1836, 95, ягъни 1837 ел ахырларында. Әмма аның үлгән елы фәндә 1838 елга нисбәт ителә) чикләрендә шәгъбан аенда вафат булып, Имәнле дигән авылда күмелгән.

Бәнем «Газизә» атлы (бу) рисаләм
Тәмам улмышдыр бу төхфәи гъиҗаләм (ашыгычлык белән әзерләнгән бүләгем).

Кем укыса бу шәрхе дилкешаи (мавыктыргыч шәрехне),
Идә гофран илә һәр дәм догаи (ярлыкауны үтенеп һәр мизгелдә дога кыла).

Мөһәйә әйламешдем бер гиҗалә (әзерләгән идем бер җимеш),
Тәракиб газиб үзрә рисалә (бер рисалә төзергә).

Морәссәгъ, ләгьл, якут, дөрридән (кыйммәтле ташлардан, якут энҗедән)
Әхадис (хәдисләрдән), китабе мөгътәбәрдән.

Кәлүрде хатире гамъгинә гяһи (Кайгылы хәтеремә кайчан килә иде):
Бу ләә-ләәи («энҗедәй әсәрне») шәрех итсәм, Иляһи.

Мияссәр әйладе (теләгемә ирештерде) ул Раббым Аллаһ.
Хыялымда хитаб итдем (дәштем) сәхәргяһ (таңда):

«Кил, әй баде саба, сахибе фәзаил
(Кил, әй таң җиле — фазыйлларның хуҗасы),
Сәламем әйлә Газизәмә васыйл (җиткер).

Пәришанлыкда хали иштигалем (таркаулыкда буш эш-гамәлем),
Һавада зөлфә-ганбәр — бу мисалым (һавада чәчтән аңкыган ганбәр кебек).

Унөч елдыр — наре фиракъи (аерылу утында),
Дәрунемдә — әкариб иштиякъи (эчемдә — якыннарымны юксыну хисе).

www.darul-kutub.com

---

Имам Әхмәд Бәширдән 21 ел элек вафат булган.

Шарихнең тормыш юлы: Таҗеддин бине Ялчыгол әл-Башгори 1253 ел (1856, 95 ягъни 1837ел ахырларында. Әмма аның үлгән елы фәндә 1838 елга нисбәт ителә) чикләрендә шәгъбан аенда вафат булып, Имәнле исемле авылда күмелгән.

Вагылды нагяһан һиҗрәт сәхабе (таралды кинәт аерылышу болыты),

Тулу итде висалең афитабе (балкытты кавышуың кояшы).

Бөрадәрзадийә килдем кәдидә (туганымның улына килдем (?уран)),

Ирешдем Хозыриш абе хәятә (Хизыр кебек мәңгелек суына ирештем).

Бу мең ике йөзнең унында (ягъни 1795, 24,— 1796 елда),

Рахәтлекем тәмам улды уңында.

Кечеклекдә җөда улдым (аерылдым) атадан,

Калыб бән гариблекдә казадан.

Унике яшемдә калдым гарибдә,

Тәвабигы вә Болгар вә Казанда (Болгар һәм Казан тирәләрендә).

Ки илле өчдә ирде хәяты,

Суйи шәгъбанда ирде мәмате (Шәгъбан аенда иде үлеме).

Вөҗүһе (билгеле булуы) илә шәһадәт улды хасыйл,

Гариблекдә улдыгычөн мәрде кямил (камил ир).

Ки Сөннең тагына мәдфун кылдым (җирләдем),

Ки андин соң гаять хэзәндә (кайгыда) калдым.

Күңел сабры илә итдем аһ-зари,

Кәламе Хәкъ (Аллаһ сүзе) илә даим игътибари.

Бу сүзләрдән дәгел шәква (шикаять) морадым,

Ходадан мәрхәмәтдер — игьтикадым (ышанычым).

Каләмемдә булырсә гайбе нисйан (онытылу, буталу),

Кәрам-ү әман илә (әйлә) пәнһан (киң күңеллек һәм әман белән капла).

Нә хуш газа (сый) әйламеш бәгъзе әфазыйл (кайбер затлылар),

Пәсәндидә мәгъкуле кабил (мактауга лаеклы, урынлы)...

...Ки бонда улды минем каләмем,

Ки хөснел-әхтәтам — әһтәмамем (матур итеп йомгаклау — булды тырышлыгым).

(1847 елгы басманың 348-350 битләрендә китапта җибәрелгән хаталар һәм аларның төзәтмәләре бирелгән).

Иң соңгы 351 нче биттә мондый юллар бар: «Олуг император галиҗәнапның хөкемдар бөек цензура комитетының рөхсәте белән шушы «Рисаләи Газизә» китабын Петербургта Нижнай губернасының Сергач өязенең Яндувишә волостеның Яңалар (Актүк) авылының Ризванмалай углының чыгымы белән мөселманнарның мәнфәгате өчен, укыганнардан хәерле дога өмет итеп, беренче тапкыр Петербург басмаханәсендә тарихе һиҗри 1263 елда һәм милади Гайсә г-м 1847 елда басылды.

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

## Эчтәлек

Шәех Хәбибулла кыйссасы ........ 38
Кыйссаи Суфый Аллайар ........ 42
Адәм галәйһиссәламнең яратылуы кыйссасы ........ 48
Ибраһим галәйһиссәламнең ни өчен утка
атылуы кыйссасы ........ 49
Йуныс галәйһиссәламнең ни өчен балык
карынына керүе ........ 50
Сөләйман йөзеге кыйссасы ........ 51
Кыйссаи гасаи Муса ........ 52
Сәмруг кош бәяны ........ 57
Мәрьям һәм маидә кыйссалары ........ 59
Даббәтеларз бәяны ........ 69
Сәбәбе тәэлифе китаб (Китапның язылу сәбәбе) ........ 70
Асыл бәндәлек бәяны ........ 73
Гыйлме гакаид бәяны ........ 75
Ходаның сыйфатлары бәяны ........ 77
Ахирәттә Ходай Тәгаләнең дидарын (йөзен)
күрү бәяны ........ 84
Иманның бәяны ........ 93



www.darul-kutub.com

Гыйбадәтнең биш төрле булуы бәяны .......... 95
Мөнәҗәте Суфый Аллаяр .......... 97
Фәрештәләргә иман китерү бәяны .......... 100
Китапларга иман китерү бәяны .......... 101
Пәйгамбәрләргә иман китерү бәяны .......... 103
Пәйгамбәр г-мнең мигъраҗының бәяны .......... 108
Сәхабәи кәрам бәяны .......... 111
Могавия3 һәм Йәзид кыйссасы .......... 116
Шарты имамәтнең бәяны .......... 119
Әүлияләрнең кәрамәте бәяны .......... 121
Самири хикәяте .......... 126
Фиргавен хикәяте .......... 127
Әҗәл бердәмлеге бәяны .......... 137
Кабер газабы бәяны .......... 138
Бәян урынында мөнәҗәт .......... 142
Кыямәтнең хаклыгы бәяны .......... 146
Фи бәяни тәразу .......... 152
Сират күперенең бәяны .......... 153
Аллайар Суфый бәяны мөнәҗәте .......... 156
Кәүсәр суы турында бүлек .......... 157
Шәфагать бәяне .......... 158
Җәннәт һәм тәмуг бәяны .......... 165
Фи бәяни мөнәҗәт .......... 169
Мөсаннифның (авторның) нәфесен битәрләве .......... 174
Һомай кошы бәянында .......... 175

www.darul-kutub.com

Аллайарның васыяте ........ 187
Суфилар бәяны (Әһле сөлүк бәяны) ........ 191
Юл кешесенең ризалык урынын теләү бәяны ........ 204
Сабыр булу бәяны ........ 207
Нәфес — теләкләрдән баш тартып һәм Аллаһтан нык курыккан юлчы бәяны ........ 214
Үгет-нәсыйхәт ........ 218
Рабига хикәяте ........ 220
Үтенеч-теләкләрне үтәүчегә мөнәҗәт ........ 222
Хәсәдтән ерак булу бәяны ........ 224
Хәҗҗаҗ хикәяте ........ 231
Комсызлыкны шелтәләү турында ........ 235
Хикәяте Сәүбан... ........ 244
Изгеләр белән сохбәт тоту (сөйләшү) бәяны ........ 245
Хикәяте дию... ........ 251
Дөньядан тәҗәрред (бизү) хакында ........ 252
Җәзбәи шайтан бәяны ........ 256
Хикәят ........ 264
Шәехе камил эстәү һәм шәригатькә иярү хакында ........ 272
Гыйлемлек турында ........ 278
Хуҗа Бәһаэддиннең ике мөриденең хикәяте ........ 278
Хикәяте шәех Хәсән Басрый ........ 287
Вәйсел-Карани таягы хикәяте ........ 289
Гакылны эшкә боеру, тәкәбберлек бәяны ........ 290
Тәкәбберлек кылмый түбәнчелекне

www.darul-kutub.com

ихтыяр иту бәянында ........................................................ 298
Тәвәккәл кылып (Аллаһка тапшырылып)
юлга керү бәяны .............................................................. 310
Хозыр-Ильяс турында ...................................................... 311
Хикәяте Ибне Әл-Мөбарәк................................................. 320
Тәкъва кылып харам һәм шөбһәдән качу бәяны ........... 325
Хикәяте Хуҗа Бәһаэддин .................................................. 327
Хикәяте Әхмәд бине Хәнбәл ............................................ 336
Татлы телле булып яман сүздән кайту бәяны............. 340
Хикәяте Локман ............................................................... 346
Ике мөэмин бер-беренә хәйр кылу бәянында................ 347
Күзне харамнан йомуның бәяны...................................... 352
Хикәяте шәех Бистами ..................................................... 360
Хикәят. Талибның харисы гыйшык булуының бәяны.. 369
Хикәят. Дөньяның мәкерлеге бәяныдыр.......................... 373
(Дөньяның мәкерлеге турында)........................................ 373
Дөньяга хирыслыктан тыелу бәяны ................................ 382
Коңгыз корты бәянында һәм хикәяте Карун.............. 382
Үрмәкүч һәм кырмыска бәянында .................................. 386
Хирыслыкның (комсызлыкның) бәяны ............................ 389
Тәвә белән филнең бәяны ................................................ 398
Вәгъдәдә төз тору бәяны ................................................. 406
Хикәят. Хәлил углы хәзрәте Исмагыйльнең бәяны ..... 409
Сәфәрдә юлдашларның миһербанлык бәяны .............. 416
Хикәят. Согыд вә Сәгыйтьнең бәяны............................. 420



www.darul-kutub.com

Мөэминнең даими курку һәм ялваруда
булуының бәяны ........................................................................ 422
Хикәят ........................................................................................ 425
Ходай Тәгаләнең рәхмәтенә өмет
бар булуы бәяны ........................................................................ 427
Чык суы бәянында ...................................................................... 430
Хикәят. Фасикъларның (бозыкларның)
гөнаһтан янганы......................................................................... 432
Казага риза булып бәлагә сабыр итү бәяны ........... 437
Хикәят. Габдулла Әнсари .......................................................... 440
Фәкыйрьләрне хур күрү бәяны .................................................. 442
Хыянәттән ерак булып, диянәтле булу бәяны ............. 447
Халыктан (кешеләрдән) рәнҗү һәм авырлыкка
түзү бәяны.................................................................................... 454
Хикәят. Чынаяк ясау бәяны ....................................................... 456
Алмас тимеренең бәяны ............................................................ 456
Хикәят. Пәйгәмбәр г-м төшенең бәяны ............................. 459
Хикәят. Хуҗа Бәһаэддин хәзрәтләренең
гавани (сакчыларга) юлыкканы................................................ 461
Авторның мөридләренә (шәкертләренә)
ялвару бәяны............................................................................... 470
Авторның улына әйткән нәсыйхәтләре.............................. 475
Мәк белән чикләвекнең бәяны .................................................. 479
Сүзне кыска кылып, китапны тәмамлау бәяны ........... 485